ISSN 0206—4189



# КАЗАН УТЛАРЫ

7.1986



# КАЗАН УТЛАРЫ

АИЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**7**

**1986**

## Бу санда

М. ХӘСӘНОВ. **Язгы аҗаган.** *Роман* . . . . . . 3
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. **Язуларга теркәлмәгән сүзләр** *Шигырьләр* . . . . . . 63
БАТУЛЛА. **Алып батыр маҗаралары.** *Повесть-әкият* . . . . . . 68
Ф. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. **Киңәшүләр кирәк.** *Шигырьләр* . . . . . . 100
И. ЮЗЕЕВ. **Сөйгәнемнең туган көне.** *Трагикомедия* . . . . . . 104
Я. ИГӘНӘЙ. **Тарихның нәни ярчыгы.** *Шигырьләр* . . . . . . 122

ОСТАХАНӘ

З. САДЫЙКОВ. **Тавык боты.** *Сатирик хикәя* . . 124
Г. БӘШИРОВ. **Җаваплылык сизеп. З.** *Садыйков хикәясе турында* . . . . . . 131
Г. МОРАТОВ. **Теләк.** *Шигырьләр* . . . . . . 133

КПССның XXVII СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

А. ХӘСӘНОВ. **Бал дисәң** . . . . . . 137

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

Ш. Ф. ТӘХӘВЕТДИНОВ. **Үсү юлыннан** *(Лениногорск районы)* . . . . . . 145

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. СВЕРИГИН. **Замандашлар бәхетен кайгыртып** . . . . . . 148
**Тәрҗемә турында сөйләшәбез** . . . . . . 154

БИБЛИОГРАФИЯ

М. БАКИРОВ. **Әдәбиятыбыз тарихына яңа адым** . . . . . . 158

Г. ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Т. КАҺҺАРИ. **Габдулла Тукай һәм уйгур әдәбияты** . . . . . . 162
Г. МӨХӘММӘДЕВА. **Тукай Әстерхан зыялылары арасында** . . . . . . 163
Ә. ФАТЫЙХОВ. **«Туган илем Кожамакты карьяседер»** . . . . . . 165

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

*Баш редактор*
**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
*(җаваплы секретарь)*
ТУФАН МИНИУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
СИБГАТ ХӘКИМ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066.
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

СӘНГАТЬ

З. САЛИХОВА. **Халыкчанлык тамырлары.** *Композитор Н. Җиһановның симфоник музыкасы турында* . . . . . . . . . 168

БЕЗНЕҢ ӘХЛАК

Д. ВӘЛИЕВ. **Сәер кешеләр** . . . . . . . . . 171

АЕК БУЛ — ЗАМАНГА ЛАЕК БУЛ!

ЗӘКИ НУРИ. **Куркыныч кунак.** *Шигырьләр* . . 187

**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . . 189

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Роман М. ХАСАНОВА «Весенняя зарница» (продолжение).
Повесть-сказка БАТУЛЛЫ «Приключения Алып-Батыра» (окончание).
Трагикомедия И. ЮЗЕЕВА.
Стихи Р. ФАИЗУЛЛИНА, Ф. ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ, Я. ИГАНАЯ, Г. МУРАТОВА.
В рубрике «Мастерская» сатирический рассказ молодого автора З. САДЫКОВА разбирает писатель Г. БАШИРОВ.
«Решения XXVII съезда КПСС — в жизнь» — статья А. ХАСАНОВА о проблемах пчеловодства в Татарии.
В рубрике «Татарстан — родной мой край» статья первого секретаря Лениногорского горкома КПСС Ш. Ф. Тахаветдинова.
«Литературная критика»: творческий портрет А. ГИЛЯЗОВА.
В журнале продолжается дискуссия о проблемах литературного перевода (А. Исхак, Р. Гатауллин).
Рецензия М. БАКИРОВА на 1 том «Истории татарской литературы». «К 100-летию Тукая»: статья Т. КАХХАРИ «Габдулла Тукай и уйгурская литература; статья Г. МУХАММЕДОВОЙ «Тукай среди интеллигентов Астрахани» и др.
В рубрике «Искусство» статья З. САЛИХОВОЙ о симфонической музыке Назиба Жиганова.
В рубрике «Наша мораль» эссе Д. ВАЛЕЕВА «Странные люди». «За трезвый образ жизни»: букет коротких фельетонов ЗАКИ НУРИ.
Дневник культурной жизни.
На нашей обложке — творчество художника Х. Якупова.

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Г. Салихҗанова, Ч. Фәтхуллина.*

Производствога бирелде 30.04.1986 ел. Басарга кул куелды 4.07.1986 ел. ПФ 05255. Офсет ысулы белән басылды.
Кагазь форматы 70×108 1/16. Учетно-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 62449. Заказ Б-178. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1986 ел.

# Мәхмүт Хәсәнов

# ЯЗГЫ АҖАГАН

РОМАН

Иргали өчен иң авыры — әҗәлгә тиңе — икенче көн иде. Дөрес, әллә ни хәвефләнерлек урын юк кебек, тавыш-тын ишетелми, булыр төсле дә түгел. Бары үз вөҗданы алдында газап чикте Иргали. Миңсылу күзенә чагылмас өчен, юк эшне бар итеп, күрәсе кешем бар иде дип, өйдән үк чыгып китте.

Чыгып китешли күрде Иргали, балдызкае, гадәттәгечә, күптән инде аякта, пыр туздырып эшләп йөри: мал-туарны эчереп, алларына сала, асларын җыештыра. Лапаста кош-корт мәш килә: казы-үрдәге, тавыгы-күркәсе — һәммәсе бер-берсен тапташып диярлек җим чүплиләр. Шунда ук бер көтү күгәрчен белән әрсез чыпчыклар да мәйханә килә.

Иргали, күкрәген тутырып сулыш алды да, гадәте буенча, күзләрен күккә төбәде. Игенченең шул инде, елның ел буе күзе һавада булыр. Яз көннәре турында әйткән дә юк, иксез-чиксез өметләр баглап, явым-төшем көтә ул: язгы яңгыр һичкайчан да артык булмый, янәсе. Гомумән, Иргали шашып ярата басу юлларын. Киң күкрәктәй тибрәлеп, тирән сулап яткан калку киңлекләрне ярата. Җиләс җилләрдә ефәк җаймадәй җилфердәп яткан куе-яшел төстәге уҗымнарны ярата. Җирне ярата!..

Урамны тутырып атлый Иргали. Җаны талпына, җаны очына. Төнге «сәяхәте» исеннән чыкмый аның, тынгылык бирми. Ә бит ул үзенең иманына тузан да кундырмам дип яши иде түгелме соң? Әлеге адымы иманының сыналуы түгел идеме? Чыннан да, аның тарафыннан кылынган ул гамәлне нинди бизмәннәргә салып үлчәргә соң?..

Бу вакыйганың тагы бер бик тә уңайсыз ягы бар иде, ул — Рәхимҗан... Соңгы вакытларда ир белән хатын арасында ниндидер низаг сыман нәрсә чыгуын Иргалигә үз колаклары белән ишетергә туры килде. Дөресрәге, балдызының соңгы сүзләрен ишетеп калды ул. Нәрсәгәдер ризасызлык белдереп: «Китче әле!.. Өстемдә торма, ичмаса. Атлаган саен чир белән мактанмыйлар...» — дип, чынлап торып Рәхимҗанны тиргәве көтелмәгән хәл иде Иргали өчен. Кем белә, бәлки күндәм ирнең сызланган яки арып чак кына хәл җыярга утырган чагы булгандыр.

Тагын уйлар. Бу юлы да балдызкае турында, үзарада килеп чыккан яңа мөгамәлә турында. Кем белә, бәлки бу миңа язмышымның соңгы бүләгедер дип, үз-үзен аклагандай итте Иргали. Азып-тузынудан килеп чыккан хәл түгел бит... Ул бит Миңсылуны чыннан да үлепләр ярата, үз итә. Балдызкае да аңа җаннарын бирергә әзер. Аларның үзара шаяры-

---

Дәвамы. Башы 5, 6 саннарда.

шып, бер-берсенә шактый үк кыю сүзләр әйтешеп ташлаган чаклары да булмады түгел, булгалады. Булмаган кая ул!

Әле дә булса хәтерендә, җәйге челләдә печән кибәне куйганда бугай, аларга янәшә басып эшләргә туры килде. Иргали, балдызкаена сиздермичә генә, аның эшләү рәвешен чамаларга теләгәндәй, күз салгалап алды. Озак еллар бергә эшләү дәверендә алар арасында тартыну-ятсынулар кимесә дә, Миңсылу һаман да әле җизнәсенең туры карашын күтәрә алмый иде. Шуны белгәнгәме, аңа күз тутырып карамаска тырышты Иргали. Әмма ул көнне балдызкае, уч иткән кебек, күз явын алырдай гүзәл, сылу иде. Өстендәге күкбаш чәчәкләре төшкән зәңгәрсу күлмәге дә, ап-ак алъяпкычы да, тула оек белән киеп алган җыйнак кына чабаталары да үзенә шулкадәр дә килешеп тора иде. Йөзләре алсуланган. Артка кайтарып бәйләнгән яулыгы астыннан, эре-эре алкаларны хәтерләтеп, бөдрәләнеп, чигә чәчләре күренеп тора. Хәрәкәт ясаган саен, икегә үреп салган авыр толымнары атынып-атынып куялар да талир тәңкәле чулпыларын чыңлаталар.

Җизнәсенең карашын тоюдан күзләрен яшерергә мәҗбүр булган Миңсылу, алны-артны, уңны-сулны абайламыйча, эшләвен белде, кулындагы тал агачыннан киселгән өч җәпле җиңел сәнәге белән шылтырап кипкән печән учмаларын кибән өстенә чөепме-чөя. Балдызының шулай бары тик татар хатыннарына гына хас сөйкемле оялчанлыгын шашып ярата. Берүк вакытта ул күңеленең кай җире беләндер сизенә дә: юк, гадәти ярату да, гадәти генә тартылу да түгел иде бу.

Шунда Иргали түземлеген җуеп,күңелендәген әйтергә мәҗбүр булды.

— Йа-а, балдызкай! Бигрәкләр дә матур, сылу икәнсең бит...

Тегесе дә җавабын таба тагын. Чак кына тулырак, елмаюы түгелергә торган иреннәре хәрәкәткә килде:

— И-и, җизнәкәй! Моңарчы күзкәйләрең кайда иде соң синең?..

Шулай диде дә, бит очларын уймакландырып тагын бер нурланып елмайгач, җәһәт кенә кибәннең икенче ягына күчте.

Бәндә баласы бәхеткә комсыз була. Бәлки Иргали дә балдызкаен күрү, тагын да якынайту, бөтенләйгә үзенеке итү максаты белән барган-дыр әлеге адымга. Чөнки бәхеткә омтылу, җанны җилкендерүчән теләк-хыяллар һәркемгә хас, тик аларны тормышка ашыру гына теләсә кемнең кулыннан килә торган нәрсә түгел. Иргалинең исә бу җәһәттән шәхсән ныклы фикере бар: алынсам — эшлим дигән уйда иде ул үзе турында.

Нинди хикмәттер, Миңсылуның ул бер генә мизгелгә дә эшсез торуын, ялгышлык белән генә булса да ял итәргә, хәл алырга туктаган чагын күз алдына китерә алмый. Ачы таңнан төн урталарына кадәр, әпипәгә биегәндәй, берөзлексез эш белән мәш килә. Ашарга-эчәргә утыргач та, табын янынннан җиде-сигез тапкыр кубар ул, я ризыкның икенче төрен китерер, азык-төлек калдыкларын сыпырып алыр, кемгәдер тастымал бирер, икенче берәвенең савыт-сабасын алыштырыр...

Бигрәк тә җәй көннәрендә хезмәт ишәя. Беренче кояш нурлары галәмне яктыртканда, Миңсылу көндәлек эшенең яртысын диярлек төгәлләп куйган була, терлекләр каралган, сыерлар савылган, көтү куылган, каз-үрдәк су буена алып төшә торган тыкрыкка куып чыгарылган. Кинәт тынып, бушап калган ишегалдында бары тик мал-туар, яңа савылган сөт исе генә хакимлек итә. Таш келәтнең ачык ишеге аша сепаратның гөжләве генә аермачык булып ишетелеп тора.

Икенче караганда инде Миңсылу бакчада, җиләк-җимеш куаклары, алмагачлар төбен йомшарта, яшелчәләргә су сибә, бәрәңге төпләрен өя. Ул арада иртәнге чәй вакыты якынлаша. Миңсылу янә ишегалдында. Кабат юынып алгач, самавырны алып чыга, елкылдап торуына да карамастан, ялт иттереп сөрткәли. Бары тик шуннан соң гына шаулатып су сала, ут элдерә. Итәкләрен кыстырып куеп, җәһәт кенә болдыр идәннәрен сыпырып-ышкыштырып ала — тирә-юнь елмаеп кала.

Юл уңаенда олы як мичен агарту белән мәшгуль Гөлүсәгә ярдәм итеп чыгарга да өлгерә. Алар тарафыннан акшарланган мичне күреп, күрше-күлән хатын-кызлары аһ-вах итәләр, мактау сүзләре таба алмый интегәләр: «Абау-у, мичегезгә керршән сөрттегезме әллә?» — дип, кулларын белән сыпырып карарга мәҗбүр булалар, агы йокмыймы, янәсе. Җиренә җиткереп эшләнгәч, кайдан килеп ак йоксын ди. Башта ак таш мунча мичендә яндырыла, пудра хәленә китерелеп төелә, аннан соң вак җиз иләк аша үткәрелә. Бары тик шуннан соң гына куе сөттә изелеп, сөзмә ясала.

Иртәнге чәй табыны алгы як сәкесе өстенә әзерләнә. Иң әүвәл сәкене тоташтан каплаган ак киез өстенә ындыр табагыдай олы киндер яшьяулык җәелә. Чынаяк-тәлинкәләр, савыт-сабалар, кашык-калаклар китерелә. Баздан балы, куе сөт өсте чыгарыла. Кичәдән калган таба ашы — коймак-кабартмалар куела. Икмәк турала. Бары тик шуннан соң гына табынның түренә, олы җиз поднос өстенә, тирә-юньгә пар бөркегән самавыр менеп кунаклый. Чәй пешерү, чәй ясау да Миңсылу карамагында: ул әзерләгән чәй эчеп туйгысыз тәмле була.

Табын янында сүз бик озаймый, бары тик башкарылган яки алда торган эшләр генә телгә алына. Әнә берьюлы ике ат җигеп Чаллыдан бүрәнә сөйрәтүче Рәхимҗанның сүзе булган икән.

— Теге шайтан малайлар ташлы урыннан узышканнар ахрысы, җирән байталның дагасы какшаган. Тимерчелеккә сугылып чыгасы булыр...

Рәхимҗан Гөлүсәгә бирнәгә бирелəсе бураның бүрәнәләрен ташый. Боерган булса, көзгә туйлары. «Шайтан малайлар» дигәне — Тажи белән Һади. Төнгелеккә хәзер алар йөри. Быел башлы-күзле булырга тиешле Гази абыйларын хәзер алар алыштырды.

Иргалинең дә сүзе булган. Ул сабан туе, печән өмәсе, кунак-төшем вакытында суелган сарыкларның тиреләре белән кызыксынды. Кичекмәстән иләтеп, «Шайтан малайларының» үлчәүләрен алып, тегүче Шәяхмәт абзыйларыннан тун тектереп алырга кирәк. Күндәм Рәхимҗанга әйт кенә — ул эшне башкарылганга сана.

Чәйдән соң һәркем үз эшенә алына. Табынны ялт иттереп җыештырган Миңсылу да җир йоткандай юкка чыга. Басудагы бәрәңге кырына чыгып чаба ул. Йорт җанлы Миңсылу аннан да буш кул белән кайтмас, баш түбәсенә кечерәк чүмәлә кадәрле үлән утырткан булыр. Сыер сауганда алларына салырга бик тә ярап куя ул.

Төш якынлашканда, Миңсылу янә ишегалдында. Үлән сүле, зәһәр билчән яшеллеге йоккан кулларын һәйбәтләп юып, аш-су хәзерләргә керешә. Ә инде аш-суга осталыгы, пакьлыгы турында әйтеп торасы да юк, ул әзерләгән нигъмәтләрне мактап туя алмыйлар. Казанда яшь тәкә ите кайный. Кунада ике җәймә токмач камыры әзерләнеп куелган. Миңсылу, мич алдында табалар белән матавыклана: пешерәнә-төшерәнә.

Икенче караганда инде мунча торбасыннан сузылып кына төтен күтәрелә. Миңсылу төз-нык аякларын кәз-кәз басып, инендәге көянтә-чиләкләрен тирбәлдереп, су ташый. Мунчаның мәшәкате күп аның: мул итеп селте суы әзерлә, баздан баш юарга ачы катык алып чык, сабагына саплы мәтрүшкә кыстырып бәйләгән берьюлы ике каен себеркесе пешеклә, аларны ләүкә өстенә куелган салкын сулы олы ләгәнгә тыгып куй. Мунчаны томалар алдыннан кабат һәйбәтләп юып чыгарасы бар...

Җәйнең бу чоры, ягъни беренче яртысы, ял гына ул. Көзгә таба башлана тормышның хикмәтләре. Көн ике-өч тапкыр озынрак булса да, бетәрлек булмый эш дигәнең. Игенченең урак уру, көлтә кертү, кара көзгә кадәр ашлык суктыру, бәрәңге алу кебек көндәлек төп эшенә тагын киндер, житен йолку, киндер чылату, аннан соң ташу кебек санап бетергесез эшләре өстәлә — өлгер генә!

Игенче хезмәтенең иң җаваплысы, иң кәттәсе, әлбәттә, миләр кайнап чыга торган урак өсте булыр иде. Андый вакытта Миңсылу күзгә күренеп

үзгәрә, аның дәртсенеп-җилкенеп эшләгәнен кайвакыт махсус тамаша кылып карап торырлар иде. Кишәрлекләп бүленгән кырда аны куып тотарлык кеше табылмас иде. Аның кулындагы Мәкәрҗә ярминкәсе бүләге — урагы, яшен урынына уйнап, челтер-челтер килеп, аһәңле аваз-лар чыгарып «җырлар» иде. Миңсылуның җиңсәләр киеп алган куллары-на күз иярми. Өлгер хәрәкәтләнеп, зур-зур учмаларны шундый иттереп сала, исләрең-акылларың китәрлек. Көлтә бәйләүләре турында әйткән дә юк: хәрәкәтләренә күз иярми, бәйлисе көлтәләр, җан кергән сыман, үз билләрен үзләре буып куялармыни! Җитмәсә тагын көлтәләре дә, нәкъ курчак сыман, матур булырлар иде. Куйган кибәннәре турында әйтәсе дә юк, чиркәү гөмбәзләре сыман тезелешеп утырырлар иде. Ә инде ын-дыр табагына күчкәч, тезеп салынган көлтәләр өстендә дөпе-дөпе биегән чабагачы яшен ташына әверелер иде.

Шуның өстенә Миңсылуның һәр эшкә кулы ябыша, ирләр кебек усал, Гөл апасы әйтмешли, теләсә нинди эшеңне кулыңнан тартып алып, җи-мертеп башкарыр иде. Җитмәсә тагын, беләкләрендә көч-егәр дә һәрчак сизелеп тора. Шуңадыр, ир-ат иңе сыгылырлык хезмәтләргә алынудан да тартынмый ул. Көрәк-сәнәккә ябыша, кирәксә, ат җигә, кыр эшләре вакытында тырмалауга гына түгел, сука башын тотарга да күп сорамас иде.

Гомумән, бу түбә астында кул кушырып эшсез торган кешене күр-мәссең. Сәламәтлеген югалткан, сырхауга саналган хуҗабикә Гөлниса-ның да шөгыле бихисап, тавык та чүпләп бетерерлек түгел. Ачы таңда барысы белән беррәттән торып, тау-тау итеп йон тетә. Бик матурлап би-зәлгән каба төбенә утырып, җеп эрли. Өйдә — үсеп буйга җиткән кыз. Бирнә әзерләргә кирәк. Шунлыктан бәйләү, тегү-чигү ише эшнең дә исә-бе-хисабы юк. Чүпләм сөлгеләр, кижеле тастымаллар, чиккән кашага-лар, ходайның биргәненә шөкер, җитәрлек булды бугай инде. Ул да тү-гел, Гөлниса олы хуҗалыкның чуты бетмәс башка эшләренә күчә. Бераз-дан инде ул, җилпучы өстенә кирәгеннән артык иелеп, иләгән дөпе-дөпе китереп, чоланда он или. Ә он мул тотыла: ипи бик еш салына, пеше-рену-төшеренүсез калган көн юк диярлек, булса да бик сирәк. Икенче караганда инде ул, болдыр баскычына чыгып утырып, кул тегермәне әйләндерә, ярма ярдыра. Димәк бәлеш салырга җыеналар. Аның шулай икәнлеген абзарда көтүдән аерып калдырылган бүлтерек бәрәннең бөтен дөньяны бер итеп бәәлдәвеннән үк сизенеп булыр иде. Шулай булгач, сугым пычагыңны барла, суыңны җылыт, эчен-маен алырга табак-савы-тыңны, кул сөртергә тастымалыңны әзерли башласаң да бик таманга туры килер...

Гөлниса шулай үз-үзен белештермәенчәрәк эшләп ташлый да, көч-хәл белән тураеп, билен уарга керешә. Йөзе күзгә күренеп үзгәрә аның: башта көзге яфрак төседәй хәсрәт сарыла, аннан килеп әрнү катыш усал-лык, көчсез ярсу галәмәтләре дә чагыла башлый. Сүзләрендә әр, агулы зәһәрлек ишетәсең килмәсә, андый чакта хуҗабикәнең күзенә чалынмау, аның тирәсендә булмавың хәерлерәк...

Эшнең иң авыры, көч-егәр таләп иткәне, әлбәттә, ир-ат җилкәсендә. Рәхимҗан сәламәтлеккә туймау сәбәпле, бүрәнәнең юан башын Иргали-гә күтәрергә туры килә иде. Әмма ул зарланмады. Эш — аның бәхете. Көннең-көн буе казганып, арып-ватылып, ярты төннәрдә өйгә кереп аву-лардан да рәхәтрәк нәрсә булдымы икән?!

Билгеле, күмәк хезмәтнең чын мәгънәсендә бәйрәм төсе алган чак-лары да була иде. Җитмәсә тагын, ел да кабатлана иде ул сабан туй-ларына тиң көн. Озынлыгы унҗиде сәгатькә җиткәндә, үлән-чәчкәләр-нең, агач-куакларның иң егәрле, иң сутлы чагында була ул әлеге бәйрәм көн. Халыкта ул вакытны июнь ае көзне кунакка көтә башлаган чак дип атыйлар. Зурдан кубып бик нык әзерләнеп, бәйрәм табынына гына куела торган азык-төлекне мулдан алып, берьюлы өч атны да җигеп, ачы таңнан чыгып китә торганнар иде. Шул бер тапкыр табигать куенында

булганда, урманның кеше сирәк аяк атлый торган ерактагы аланнарына сәйранга чыкканда, күпме төрле дәва үләннәре, кышка җитәрлек мунча себеркесе, яшь малга урман печәне, юкә, карама, өрәңге яфрагы юнәтеп кайтырлар иде.

...Ул көнне Иргали иртәнге чәйгә соңарып кайтты. Бу хәл ярап та куйды — балдызкае белән табын янында күзгә-күз очрашмады. Минсылу күптән инде абзар-кура тирәсендә эш белән мәшгуль иде. Чәйне дә хатыны Гөлниса ясап эчертте.

Көн чамадан тыш озын булып тоелды Иргалигә. Ниһаять, төн. Тирәюнь тәмам тынгач, ул яңадан мал-туарны карап керергә җыена башлады. Анда эш тә юк югын. Иргали белә, балдызы барысын да ялт итеп куйган: сыерларга башак болгатылган, атка солы салынган, яшь маллар алдыннан себерке-мазары, шау чәчкә чорында чабылган урман печәне өзелгәне юк.

Бөркәүне ачып керүгә, Иргалине яраткан аты кешнәп каршылады. Бу көннәрдә ул ялгыз. Иргали аты янына килде, ялларын, колак артларын сыйпаштырды. Һай-й, тел юклыгы чукындыра, югыйсә хуҗасына әллә ниткән ягымлы сүзләр әйтер иде малкай. Гадәти ат түгел ул, ә сауран дигән нәселле. Якын-тирәдә генә түгел, гомумән, күренгәне юк андый атның бу төбәктә. Гәүдә-сынга әллә ни эре булмаса да, ару-талуны белмәс юрга ул. Төсе дә бик мәзәк, бик үзгә аның — сыек җирән төстә. Әмма сырты буйлап койрык очына хәтле кара сызык сузыла. Яллары озын, койрыгы җирдән сөйрәлеп йөри. Шундый җилле юырта, аяклары җиргә тими сыман. Бигрәк тә адымнан юыртуга күчүен ярата Иргали, аны берни белән дә чагыштырырлык түгел.

Сауранның Иргали кулына эләгүе дә бик мәзәк булды. «Кузька-Бурлак сиңа калдырырга кушты»,— дип, бер чегән китереп бирде. Иренмәгән, Чаллыдан атап килгән. Таборлары белән Әстерханга төшеп китәселәре бар икән, югыйсә үлгәндә дә элегәтәты белән аерыласы булмаган. Уйнаклап-биеп торган сауранны капка баганасы бождрасына бәйләп куеп саубуллашканда, чегән чынлап торып елый. Ат, та бөтенләйгә аерылышуларын сизенгәндәй, башын хуҗасы иңнәренә куеп, тынып кала...

Иргалигә дә бик тиз ияләште сауран. Бахбайның алдыннан солы өзелмәде. Печәннең дә иң кәттәсе, үләнгә корт-фәлән төшкәнче чабылганы, мең төрле чәчкә исе, җәйнең чәлләсе сеңгәне булыр иде. Сауранның үзенә атап, җиңел тарантас, дирбияләр алды. Көмеш тәңкәләр тезелгән кара каеш йөгән-шлеясен, як-якка асылынып төшкән чукларын, җиз бизәкле ыңгырчагын, кара төскә буялган нечкә дугасын күргән кешеләр, соклануларын яшерә алмыйча, телләрен шартлатырлар иде. Ә инде җиңел, тимер табанлы көймәле чанага җигелгән сауранның җил уйнатып, утырып өлгермәгән карны тузгытып, өермәдәй узып китүләрен күргән кешеләр, барыр юлларыннан бүленеп: «Тә-тә-тә-тә-ә!..» — дип, хәйраннар булып карап калырлар иде.

Иргали шулай уй иркенә бирелеп, юк эшен бар итеп, болганды да тулганды. Төрле уй бимазалады аны. Вакыты белән күңелендә, ниндидер бер җыр-моң булып иңгән куанычлары, авыр пәрдә төшкән сыман томаланып калгалады: рәнҗетмәдемме икән? Хәтере калмадымы икән?..

Ничек кенә булмасын, күңелен, бөтен барлыгын биләп, көннән-көн буена бимазалап, бер генә мизгелгә дә калдырмыйча киеренкелектә тоткан, моңарчы һичкайчан да татылмаган илаһи ләззәтнең тагын бер тапкыр гына булса да кабатлануын тели иде ул. Бу теләк шулкадәр көчле иде, хәзер инде Иргалинең үз-үзен тотып, тыелып калырга тәкате дә, ихтыяр көче дә барыбер җитмәс иде.

Менә Иргали, кыяр-кыймас кына атлап, яңадан кечәге ишек янына килде. Нәрсә көтә аны? Күз яше катыш рәнҗүме, әллә?.. Ул инде чиертеп кенә үзенең килгәнлеге турында хәбәр салу өчен, кулын да күтәргән иде, әмма шулчак ишек тавыш-тынсыз гына ачылып китте. Минсылу аны бусагасына чыгып көтеп торган икән...

Шушы икенче очрашу барысын да хәл итте, аларны бер-берсеннән аерыла алмаслык дәрәҗәгә җиткереп бәйләде дә куйды. Шул көннән башлап оялу-тартынулар кими төште. Тора-бара җизни кеше белән балдызкайның үзара мөнәсәбәтләре шундый тирәнәйде, яшереп булмас дәрәҗәгә җитте. Миңсылу да ул кадәр үк читенсенми иде инде. Вакыты белән теле языла китеп, артыграк сөйләнеп ташлаган чаклары да булгалады. Җизнәсенең назлап-иркәләп: «Әйтче, балдызкаем, мине аз гына булса да яратасыңмы?..» — дигән соравына җавап итеп, күңелендәген ачты да салды. Баксаң, җизнәсенә карата иң саф, иң пакъ хисләрен ул инде күптәннән бирле йөрәк түрендә йөртә икән. Хәтта, кайчаннан бирле гыйшык тотуын, үлеп яратуын да тәгаен әйтеп бирде: беренче тапкыр күрү белән, атка утырып, Гөл апасының кайда эшләгәнен күрсәтергә барганда, җизнәсенең: «Үскәнем!» — дип, аркасыннан сөйгән көннән бирле гашыйк икән ләбаса! Җизнәсе аның өчен шул чакта ук инде ниндидер тылсымлы көч-кодрәткә ия үзгә бер зат, илаһи җан булып гәүдәләнгән булган. Яшүсмер кызга ул гади ир-ат булып кына күренмәгән, ул аңа табынып, аллага инанган сыман үз итеп караган икән. Чак кына үсә төшкәч, чын ир нәкъ менә аның җизнәсе кебек кыю, батыр, нык, таза, житди, горур булырга тиештер дип уйлый, күзаллый торган булган. Тәвәккәл ир — ил тераге диләр бит. Әгәр дә, ходай кушып, кияүгә чыгарга язган булса, бары тик яшәү рухы бөркелеп торган җизнәсе кебек иргетне генә сайлыйм дип хыялланып йөргән икән.

Нәрсә генә эшләсә дә, нигә генә алынса да, һәр эшне җиренә житкереп, җизнәсенә ошарлык, җизнәсенең күңеле булырлык итеп башкарырга тырышкан. Чөнки җизнәсенең бер җылы сүзе, бер ягымлы карашы аның өчен дөнья бәяләренә торган.

Тагын ул җизнәсенең кызу җәйге көннәрдә, бигрәк тә бакчада, умарталар тирәсендә кайнашып, тирләп-пешеп чыкканнан соң, билдән тиң чишенеп ташлап, салкын кое суы белән пошкырына-пошкырына юынуларын ярата торган булган. Ул бу минутларны сулар әзерләп, җилкәсенә яңарак кына сырлы бәләк астыннан чыккан киндер сөлге салып, түземсезлек белән көтеп алган. Чөнки бер кулы белән олы җиз чүмечтән су салганда, буш кулы белән — юышырга ярдәм итә, янәсе җизнәсенең мускуллар уйнап торган аркасына, калак сөякләренә кагылганда, дөньяда берни белән дә чагыштыргысыз ләззәт, тәм тапкан, үзенең дә тәне буйлап моңарчы таныш булмаган, ниндидер бер рәхәт кытыклану таралган. Андый чакта сулыш алуларына кадәр үзгәрә торган булган аның.

Иргали калага китә-нитә калса, Миңсылу, аның өчен янып-көеп, бөтен тынычлыгын җуя торган булган. Белмим, өйдәгеләрдән тагын кем дә булса Иргалинең сәфәрдән исән-имин кайтуын аның кебек өзелеп көттеме икән? Бер хәвефле вакыйга турында ишеткәч, Миңсылуның пошаманга төшүләре, ут йотулары тагын да арткан, төнге йокылары тәмам качкан булган.

Иргалинең: «Нинди вакыйгадан соң?» — дип соравына каршы Миңсылу: «Кама өстендә юлбасарлар каршылагач»,— дип җавап кайтарды. Чыннан да, шуңа охшашлы бер вакыйга булган иде бугай шул. Бик күптән инде, Иргали кибет ачып сәүдә итеп маташкан елларда. Казаннан кайтып килеше иде. Чанада, торыпша астында, шактый гына товар. Дөрес, кызыл мал юк югын, әмма чәй-шикәр, капчыгы белән өрек жимеше, йөзем ише нәрсәләр шактый. Авылның бала-чагасы кызыл билле прәннек дип шаша — ул да бар. Көн болытлы. Ай-йолдызлар күренми. Җәяүле буран себереп тора иде. Иргали, аллага шөкер, кайтып житәм бугай дип, атларын шактый җилле юыртып, Чулман өстенә төште. Әмма атлар, боз өстенә кереп китү белән, нәрсәгәдер килеп сөрлеккән сыман, кинәт туктап калдылар. Ул да түгел, ни күрсен, чананың як-ягында, кара күләгә сыман, ике кеше пәйда булды. Караса, алдарак тагын берәү тора. «Әһә-ә, хәлләр шулайрак икән...» — дип уйлап куйды Иргали. Җәһәт кенә иелеп, аяк астын — чана бөгәлҗәсенә кыстырып куйган балтасын

капшап карады. Хуш, балта үз урынында. Сәламсез-нисез генә әңгәмә башланды. Олау тирәсендәгеләр төпченә башлады: «Кайдан кайтыш? Кай якка? Юллар уңдымы? Шәт, уңгандыр, йөк мул күренә», янәсе. Җанлы күләгәләр торган саен әрсезләнделәр, торыпша астындагы әйберләрне капшаштыра ук башладылар. Ә анда, бу зобаныйларның күзен алартырлык нәрсәләр җитәрлек иде. Эшләр шулай җитди төс алыр микәнни? дип уйлады Иргали. Яманга китсә, эшләр харап... Күләгәләр, әнә, өчәү-дүртәү. Уен эш түгел бу. Якында гына, текә яр астында, балыкчыларның ау сала торган бәкеләре... Эзеңне дә таба алмаслар.

Күләгәләрнең берсе, сакал-мыегын бәс басканы, Иргалигә таба якыная башлады. Һәм искәрмәстән генә толыбының якасыннан эләктереп тә алды... Иргали дә елдам, толыбын салып сакал батыр кулында калдырып, кыяк кебек итеп кайралган балтасын суырып чыгарды да, яшен тизлеге белән сикереп торып, олау өстенә менеп басты. «Җә-ә!.. Хәзер үк чана тирәсеннән юк булыгыз, югыйсә башыгызны чабам да өзәм!..»— дип ялт та йолт китереп балтасы белән-яман кизәнә башлады. Баш очларында яшендәй уйнаклап торган балтаны күреп, тегеләр бермәлгә югалыпкаушап калдылар. Иргали, шул мизгелдән файдаланып, товарның үзенеке түгеллеген, Чаллыга гына кайтуын, Кузька-Бурлак йомышын йомышлап йөрүе турында әйтте. «Кузька-Бурлак» сүзе тегеләрне шундук айнытып җибәрде. «Баштарак шулай диләр аны!..» — дип, хәтта чак кына үпкәләрен дә белдерделәр. Ахыр чутта: «Кузьма Даниловичка сәлам тапшырырга онытма»,— дип, Иргалинең артыннан кычкырып калдылар. Ул юлы да аны зирәклеге белән тәвәккәллеге генә коткарып калган иде.

Елганы кичкәнче, аннары Чаллыны чыкканчы, атларын җан-фәрман чаптырды Иргали, бары тик авыл юлына төшкәч кенә, тирләре катканчы атлатып кайтты. Ун елдан артык вакыт үтүгә дә карамастан, әлеге вакыйганы Миңсылуның һаман да оныта алмавы гаҗәп иде. Алай гына да түгел, бу хәл турында Иргали; башка вакытта борчылып тормасыннар дип, өйдәгеләргә сөйләмәгән дә иде. Димәк, балдызкае аның әлеге маҗаралы сәяхәте турында сере сыярлык башка берәүгә сөйләгән вакытта тыңлап торган булган.

Миңсылу тагын җизнәсенең- балалар кебек беркатлылыгын, ярсу хисле булса да, кызып китеп, кешенең тетмәсен тетеп сүгеп ташлаган очракларда да, бик тиз кайтып төшүен ярата. Шуның өстенә, әле аның җизнәсе бик тиз мавыгучан, юк кына нәрсә дә аның күңелен чын мәгънәсендә җәлеп итүе мөмкин.

Миңсылуга ул нәкъ җилбәзәк яшь егетләр сыман гашыйк булды. Мәхәббәте торган саен көчәйде. Балдызкаенда Иргали уйламаган-көтмәгән күркәм сыйфатлар тапты. Хатын-кыз буларак та аннан иркә-назга, игътибарга сизгер, аннан нәзакәтлерәк, мөлаемрәк бүтән булмас. Ә инде шаярырга, уйнап-көлергә дисәң, беркемгә алыштыргысыз. Балдызкаенең бу якларын, мөгаен, бары тик Иргали генә белә торгандыр. Андый чакларда янып торган яшь хатынның күзләреннән менә-менә якты нур тамчылары сибелеп төшәр сыман иде.

Тормыш булгач, төрлесен кичерә башкайлар. Ара-тирә Миңсылуның да кинәт боегып-басынкыланып калган чаклары булгалады. Андый чакта ул, дөньяларын оныткан сыман, уйчан-серле итеп бер ноктага карап тора. Сүзләре дә серле-яман аның. «Җизнәкәй... Бу гөнаһларыбызны кая куярбыз икән? Ходай кичерерме икән безне?..» Иргали дә пошаманга төшә, югалып-каушап кала, юату сүзләре таба алмыйча иза чигә, кайчандыр инде бер тапкыр әйткән сүзләрен кабатларга мәҗбүр була. «Мәхәббәт язык түгел, балдызкаем. Мәхәббәтсез уйнашмыйбыз... Мин бит сине үлепләр яратам. Җанымдыр ла! Күз алмамдыр ла!..» Иргали кинәт йомшап, тынып калган балдызкаен янә юата, янә назлый, янә кочагына кысып, шашынып үбә башлый...

Язгы чәчүләр тәмамлангач көнне тагын бер вакыйга булды. Тырма-

лар, тубаллар салынган атлар алдан кайтып китте. Хәзер куып тотармын дип, юк эшен бар итеп, Иргали басуда калды.

Иләһи зур эш башкарганнан соң, Иргалинең шулай ялгыз калып, уй-хисләрен җайга сала торган гадәте бар. Сөенечле-шатлыклы да, мәшәкатьле-борчылу да булды быелгы яз. Көтелгән уңыш язмышы өчен шактый ук хәвефләнергә туры килде, озакка сузылган корылык игенче күңеленә шик-шөбһәне өстәп кенә торды. Иргали тупланган бөтен тәҗрибәсен, осталыгын кулланырга тырышты. Тиреснең дә суты җилгә очырылмады, кояш күзендә киптерелмәде. Сыналган элеккеге ысулларын кулланды. Нишләмәк кирәк, язын шулай кырык кат тир түгү — һәр игенченең изге бурычы. Барысына да түзәсең. Тикмәгә генә язның бер көне ел туйдыра дими торганнардыр.

Рәхимҗанны алданрак кайтарып җибәрүнең дә сере бар: караңгы төшкәләгәнче, сауранны җигеп, тиз генә Чаллыга барып кайтасы бар. Такта ярдырган өчен акча түләнмәгән. Әҗәтне көткән кеше исә бүген төнлә яки иртәгә таңнан каядыр сәфәр чыгып китәргә тиеш.

Ул арада урман ягыннан, бөтен күкне иңләп, болыт чыкты. Бераздан өзек-өзек кенә дөбердәп күк күкрәгәне дә ишетелде. Шул яктан салкын җил исте. Иргалигә бик тә рәхәт булып китте, эшеннән бүленде. Дилбегә белән бәйләп җибәрелгән атны җигеп, тиз генә кайтып китәргә дигән уеннан шундук сүтелде. Җир куенына кергән гәрәбәдәй орлыклар өстенә беренче шифалы яңгыр тамчылары төшүен үз күзләре белән күрәсе килде аның. Ул торыпшаны таратып, арба астында куыш сыман нәрсә ясады. Чәчүлектән бушаган капчыкларны җәеп, ятак әзерләде һәм, беләкләрен баш астына салып, сузылып та ятты. Чәчүнең хәвеф-хәтәрсез генә тәмамлануын, шуның өстенә, нәкъ һава кебек үк кирәк яңгырның якынлашып килүен тою, бик тә, бик тә рәхәт иде Иргалигә. Ниһаять, арба өстенә капланган каты брезентны шапылдатып, беренче тамчылар төште...

Шулчак шактый ук җилле юыртып килгән арба тавышы ишетелде. Иргали, җиргә кадәр төшеп торган торыпша кырыен күтәреп, куышы эченнән башын чыгарып караса, ни күрсен, җирән байталны җиккән Миңсылу якынлашып килә икән. Бу көтелмәгән хәлдән Иргали сагая калды, җәһәт кенә куышыннан чыкты.

— Нәрсә булды?..— дип каршылады ул Миңсылуны.— Бер-бер хәл булмагандыр бит?

— Юк, берни дә юк...— диде балдызы, ниндидер канәгатьсез бер тавыш белән.

— Ничек килеп чыгасы иттең соң?

— Гөл апа җибәрде... Нигәдер соңарды, җизнәңә ярдәм-фәлән кирәк түгелме икән диде.

Ул арада яңгыр көчәйде, тирә-юньне тоташ пәрдә белән томалап, шаулап ява да башлады. Иргали, җирән байталны арбага бәйләгән арада, Миңсылуга тиз генә куышка кереп яшеренергә кушты. Бераздан үзе дә балдызы янына кереп утырды.

Күлмәк җиңнәре белән йөзен сөртештергәч, балдызкаена күз салды. Аның төсе киткән йөзен күреп, янә сагая калды. Миңсылуның танырлыгы юк: иреннәр кысылган, дәрт чаткылары сүнгән күзләре тәшвиш һәм хәвеф белән тулы.

— Я-ә, әйт, нәрсә булды?— дип кабат сорарга мәҗбүр булды Иргали.— Ник әйтмисең? Нәрсәдер булган ич... Әйт тизрәк!..— дип тәкрарлады ул, гаҗиз калган тавыш белән. Үзенең башында берьюлы мең төрле уй: аларның яшерен мәхәббәтләре турында әллә сизенделәрме икән? Булса да булыр, аларның үзара мөнәсәбәте яшереп булмаслык дәрәҗәгә җиткән иде шул инде. Беренче булып кайсы сизенде икән: Гөлнисамы? Әллә Рәхимҗанмы?.. Ул инде балдызкаен юату сүзләре дә әзерли башлаган иде. Иргали аңа: «Ни генә булганда да, җил-яңгыр тидертмәм, җанашым! Хәтта, авыр сүз дә әйттермәм... Кагылып кына карасыннар!..» — дияр.

Әмма боларның берсе дә кирәк булмады. Куыш эченә әңгер иңгәнне генә көтеп торган сыман, Миңсылу да телгә килде, жизнәсенә үзенең иң зур серен — көмәнле булуын ачты. Бу сүзләрне ул, ни кайгылы, ни шатлыклы хәбәр икәнен аерып булмаслык бер битарафлык белән әйтте.

Аның каравы, Иргалине әллә нишләтте бу сүзләр. Ул утырган килеш җәһәт кенә борылды да, балдызының бөтен җире тулып түгәрәкләнгән гәүдәсен кочагына кысып, ике рәт гәрәбә аскан муенын, битен, иреннәрен шашынып үбә башлады. Үзе әзми дә куймый, берсеннән-берсе назлы сүзләрен тезде. «Бәгыремдер лә, бердәнберем... Я-а, ходай, миннән дә бәхетлерәк кеше бармы икән бу дөньяда! Әгәр дә мәгәр, балдызкаем, тупырдап торган бер малай табып бирсәң, сүзем сүз, кулларымнан төшермәс идем үзеңне...» Көрәктәй кулы астында яшь хатынның тыгыз, уттай кайнар күкрәкләрен тою тәмам шашындырды Иргалине. «Җаным-дыр ла!.. Багалмамдыр ла!..»

Иркәләү-назлаудан һуштан язу дәрәҗәсенә җиткән Миңсылу да жизнәсенең ихтыярына тулысынча буйсынды, куенына сеңде дә бетте.

Теләр-теләмәс кенә башланган яңгыр, нәкъ көзге явым-төшем кебек утырып коя башлады. Чебен-черки бимазалавыннан котылган атлар да тынып калдылар. Яңарак кына сөрелгән җир, беренче үлән исеннән, аннан да бигрәк, аңлашу шатлыгыннан исергән ике гашыйк, бер-берсенә елышып, дөньяларын онытканнар иде.

Ул кичне алар өйгә бик соңарып кайттылар.

Көзен, беренче кар төшкән көнне, Миңсылу ир бала тапты. Барысы өчен дә онытылмас вакыйга, зур бәйрәм булды ул. Куанычның иң зурысын Гөлниса белән Гөлүсә кичергәннәрдер, мөгаен. Монда җылы, һавасы да иркен дип, баланы олы өйдән чыгармаска булдылар. Зурдан кубып бәби туе үткәрделәр. Башы күкләргә тигән ата кеше: минем исемем Рәхимҗан, улыма я Галимҗан, я Сабирҗан кушыйк дип гайрәт чәчсә дә, Миңсылуның бу мәсьәләгә карата үз фикере булган икән. Бернинди дә «җаннар» кирәкми, улымның исеме заманча булсын әле, «Азат» кушабыз диде.

Бала дөньяга килгән көннән башлап Миңсылу үзгәрде, кыюлана төште, гомумән, үзен чикләнмәгән хокук яулап алган кеше сыман тота башлады.

Иргали турында әйткән дә юк, бөтен тормышы кинәт кенә үзгәреп киткән сыман булды аның. Яшәеше дә ничектер эчтәлеклерәк, үзенә бер төрле яктырак дөньяга әверелде дә куйды. Миңсылу белән торган саен ныграк мавыга баруын тойды ул. Яңа, моңарчы таныш булмаган тансык якынлык хисен йөрәгендә йөртүдән һич кенә дә арына алмады. Дөресрәге, арынырга теләми дә иде. Чөнки бөтен барлыгын яулап алган әлеге хис аның күңеленә көч бирә, рухын күтәрә, кара уйларын куа, тормышын тулыландыра иде.

Малай ай үсәсен көн үсте. Шуның өстенә әле бик терчән, тач ядрә кебек, кулдан атылып чыгарга гына тора иде. Елауның, көйсезләнүнең нәрсә икәнен дә белмәде. Әнисе эшләреннән бушаганчы, авызына каптырган имезлеген суырып, кулына нәрсә тоттырсалар, шуның белән уйнап-юанып, киндер төпле сиртмәле бишегендә тәпиләрен селкеп, үз теленнән сөйләнеп ятыр иде. Кулга иәләштереп, я күзсендерербез дип, нәни Азатны кирәксә-кирәкмәсә дә кулга алмау ягын карыйлар иде.

Сүз дә юк, шәп иде, күңел көр, тормыш җитенке, җан тыныч иде. Һәм менә көтмәгәндә-уйламаганда дөньяның асты-өскә килде дә куйды. Кайгы-хәсрәте, бәла-казасы берьюлы бөтен катылыгы һәм рәхимсезлеге белән өсләренә ишелде дә төште.

Бәла бәлага кул бирә ди. Бу яман хәбәр өстенә икенчеләре өстәлеп торды. Тикшерүчеләр ишегалдына басып кергәч, иң коты алынганы Миңсылу булгандыр. Аның йөзләреннән нур качкан, күзләрен пошаман катыш кара кайгы пәрдәсе томаландырган иде. Ә инде тәнлә белән кулга алырга килгәч, өйдәгеләрнең бөтенесе дә бер кешедәй аякка басты. Миң-

сылу, хэтта, эле яңарак кына яшен тутырган нэни Азатны да күтэреп чыккан иде. Барчасының да, күлэгэлэр сыман капка төбендэ тезелешеп басып калулары эле дэ булса күз алдында Иргалинең.

Замана, тормыш авырлыгы шулай берьюлы килэ торгандыр инде. Менэ Иргали дэ үзенең уй-сагышлары, үзэк өзгеч эч пошулары белэн җэһэннэм базында япа-ялгыз ята. Иң авыры, элбэттэ, үз-үзен яклау өчен кыл гына да селкетэ алмау иде. Шул чарасызлыктан да яман хэл юк. Йөрэге чыдый алмаслык дэрэҗэгэ җитеп сыкранган чакларда ул: эле дэ ярый бу дөньяда Миңсылу белэн нэни улым бар, дип уйлаштыргалый иде. Эй-йе, бу уй аның алҗыган йөрэгэ өчен бердэнбер шифа, туйдырмый торган бердэнбер дэвалы юаныч иде.

Ахыр чиктэ аның да дөньяда барлыгын ислэренэ төшерделэр ахрысы: «Мир-галиев, өс-кэ!..»— дигэн эмер яңгырады.

Иргалине тикшерүче янына алып бармадылар, шушы бинадагы махсус бүлмэгэ генэ керттелэр. «Биш кенэ минутлык күрешү»,— дип кисэтеп тэ куйдылар. Монда ул чатанлап үзенэ таба якынлашып килүче Бэһрам җизнэсен күреп алды.

Куллар кысышып күрештелэр. Бэһрам җизнэсе башта, танымаган сыман, Иргалинең сакал-мыек баскан, агарынып калган йөзенэ карап торды. Сулган йөзе тоткынны ничектер олыгайтып күрсэтэ иде.

Җизнэсенең текэлеп, кызганган сыман каравына Иргали дэ игътибар итте. Бу минутта ул үзен читтэн күргэн кебек булды, кайдадыр бик тирэндэ үз-үзен кызгану хисе тууын тойды. Тулышкан күңелгэ кинэт ташып китү өчен шул җитэ калды. Ул да түгел, иркенлэп, күкрэк тутырып сулыш алырга комачаулап, бугазына утлы төер менеп утырды. Бермэл Иргали тамагына тыгылган шул каһэр төшкэн төерне йотып җибэрэ алмый газапланды. Шушы бер генэ мизгеллек йомшаклыгы өчен дэ Иргали үз-үзен гафу итэ алмады. Ул белэ: мондый чакта ихтыярыңны җую башыңны җую белэн бер. Акылы көчсез, фикере таркау булса да, соңгы чиктэ әкренлэп телгэ сүзлэр иңэ башлады.

— Хэллэр шушылайрак бит эле, Бэһрам җизни...— диде Иргали зарын белдергэн сыман тавыш белэн.— Дөреслек булмаган җирдэ гаделлек юк дигэндэй, бер дэ гадел хөкем итэрлэр төсле түгел. Башым нахактан китэр ахры...

— Я сэнэ!..— диде җизнэсе канэгатьсезлеген белдереп.— Үз-үзеңэ ясин чыгып утырмачы, зинһар.— Шунда ук Иргалине исенэ китерергэ телэгэндэй өстэде.— Дөрес, сиңа җиңел булмас...

— Моннан да яманрагы булмас...— Бу сүзлэрне дэ тирэн эрнү белэн эйтте Иргали.

— Ташлачы, зинһар!..— дип кабатлады Бэһрам җизнэсе.— Кемдер нахакка рэнҗетте, кемдер этлек эшлэде дип, бөтен дөньяга каш җыерырга, йөз чытырга ашыкма эле син. Дөньяда ачу саклап яшэп булмый.

Каенесенең телэсэ нинди тэвэккэллеккэ барырга сэлэтле икэнлеген белгэнгэме, Бэһрам аны тынычланырга, сак булырга, барыннан да бигрэк сабырсызланмаска өнди башлады. Эй китте берзаман алып, эй китте, син күр дэ мин күр, бер дэ калдырмады, хэтта, башсыз син, серкэң су күтэрми, сүз көрэштереп мэгънэ чыкмаячак, җитмэсэ тагын кирэкмэгэн дуамалсың, шул кыркулыгыңны белгэнгэ күрэ эйтэм дэ бу сүзлэрне дип өстэп куярга да онытмады.

Иргали дэ сүз кыстырып куюны кирэксенде.

— Кара гайбэтне өнэмим!..— диде ул кырт кисеп.— Һэр түземлекнең дэ бер чиге була.

— Э син кызма! Кызма!.. Һай-й, шушы кызу канлыгыңны, ордыбэрде холкыңны. Кирэк чакта ярсу йөрэгеңне бераз баса, үз-үзеңне бераз тезгенли белергэ дэ кирэктер бит. Бэхэскэ кермэ, саксыз сүз ычкындыра күрмэ дип, мин сиңа башта ук бер кисэткэн идем ич инде. Ул — власть вэкиле. Аның кулында власть дип атала торган көч. Саксыз эйтелгэн бер сүзең белэн бөтен эшне бозып ташлавың бар. Кабатлап эйтэм: түз, сабыр

иг! Кызма!..— Бу сүзләр катгый киңәш тә, житди боерык та булып яңгырады.

— Адәм әйтеп, адәм ышанмаслык гаеп ташлаганда да түзәргәме?! Нәрсә ул чебеннән фил ясап маташа. Күрәләтә торып яла якканда кем соң әдәп кагыйдәләре белән санашып тора? Нахакка чыдар хәлем юк.

— Ә син барыбер түз,— дип бүлде аны Бәһрам.— Дөрес, бәла көткән күптән бәлале ди. Шулай да түзәргә, сабыр итәргә кирәк.

Бу сүзләрдән соң Иргали бары тик ярсый төште.

— Түз дә түз, имеш! Нигә дип әле мин җыен тузга язмаган сүзләргә баш иеп, бергә ун уйдырма кушып, ачы һәм шәфкатьсез гаепләүләр ташлаганда: «Баш өсте! Дөрес! Сез хаклы»,— дип торырга тиеш ди? Юк инде, рәхмәт! Муенчак салганда, баш иеп торучы мин түгел. Үлсәм үләрмен, әмма вөҗданыма хилафлык китермәм. Лутче аягүрә басып үләм. Әмма бил бөкте, баш иде юк. Булмас та! Көтмәсеннәр дә!..

— Үзең турында булмаса, өйдәгеләрең турында уйлар иден, бизбашка! Һич югында тикшерүләр беткәләгәнче түзәр, сабыр итәр иден...

Кызып киткән Иргали жизнәсенең сүзен бөтенләй ишетмәгән кеше сыман, дәвам итте:

— Ул, бәлки, мине өркер, куркудан мәлҗерәп-сыгылып төшәр дип уйлагандыр. Минем түбәнсенүемне көткәндер. Тотсын менә! Гаепле кеше шүрләсен. Куркаклык — үлем кардәшедер. Ходай белә, мин гаепсез. Намусым пакь. Гомеремдә кеше өлешенә кул сузганым булмады. Ә инде Үшән Халәбенә килгәндә, мин ул сасы көзән белән янәшә утырып... нитәргә дә җирәнә идем...

Аларга озак сөйләшергә ирек бирмәделәр, ачык ишек янында торган хәрби, стенадагы сәгатькә ым кагып: «Иптәш Кәрамов, биш минут үтте»,— дип кисәтү ясады.

— Хәзер, хәзер,— диде тегесе, әйтәсе сүзен әйтеп бетерә алмаудан курыккандай итеп.— Хәзер бетерәбез...— Ул җәһәт кенә Иргали ягына борылды.— Шуны бел, Иргали, усаллану — көчсезлек билгесе. Сабырлыгыңны җуеп, соңыннан төзәтеп булмаслык ахмаклыклар эшләп ташлавың бар...

— Ул кадәресен дә аңлыйм, жизни. Җүләр түгел. Тик ничекләр итеп түзмәк кирәк. Башыңны гына и, камыт кидерергә әзер торучылар күп булыр ул. Һәрнәрсәнең бер чиге була бит. Әнә күр... адәм акылы ирешмәслек нәрсәдә гаеплиләр ич! Хурлыгыңнан үләрлек бит... Тот та үл!..— Иргалинең тавышында шул хәтле ачыну, әрнү иде, бу хәлне сизенгән Бәһрам да тынып калырга мәҗбүр булды. Һәм ул, каенесен тынычландыра алуына тәмам өметен җуйган бер кыяфәттә саубуллаша башлады.

— Өйдәгеләргә берәр нәрсә тапшырасың бармы? — диде ул, ишек катында туктап калып.

— Тапшыр үзләренә... Борчылмасыннар, бик бетерешмәсеннәр,— булды Иргалинең соңгы сүзе.

Бәһрам жизнәсе белән очрашу да өмет чаткысы кабыза алмады Иргалинең күңелендә. Хәер, үзенең дә җавабы ничектер ярты-йорты гына булды, ярым бәхәс, ярым сүз көрәштерүгә кайтып калды бугай. Иң яманы, әлбәттә, өйдәгеләргә аз гына булса да җан юанычы булырлык, җан тынычлыгы иңдерерлек сүз таба алмау иде.

Иргали караңгы, тынчу, шыксыз бушлыкта янә әрле-бирле йөренә башлады. Бу минутта ул өмет итәрлек, таянырлык бер генә нәрсәсе дә калмаган кеше сыман хис итте. Җаны шундый сызлана, йөрәге шундый сава, түзсәң түз, түзмисең икән инде, йөгереп кил дә башыңны таш стенага бәр.

...Ары таба вакыйгалар баш әйләндергеч тизлек белән дәвам итте. Иң әүвәл, җинаять җәзасы билгеләү өчен Иргалине судка, хөкемгә тарталар икән дигән хәбәр таралды. Янә дә килеп: Иргали, элеккеге өяз шәһәре — Чистай төрмәсендә утыра дип тә, Казан тикле Казанга алып

киткәннәр дип тә сөйләнделәр. Һәм ниһаять, җан туңдырырлык шыксыз сүз дә килеп җитте: Миргалиевлар бөтен гаиләләре белән Себергә сөреләләр икән.

Бу хәбәрдән соң өйдәгеләрнең барчасы да тораташтай каттылар да калдылар.

## Бишенче көн

### 1

Күзләрем тәрәзәдә.

Хәзер инде бу төбәктә дә нефть районнарыбызга хас манзараларны төсмерләргә мөмкин. Иртәнге саф һавада әллә кайлардагы, Чулман арьягындагы таулар, тагын да ерактарак, рәшә аша зәңгәрсуланып торган урманнар — барысы да аермачык булып күренәләр. Икенче якта, дәрьяның бу ягында, бөтенләй үзгә күренеш. Әнә алда югары көчәнешле электр линияләренең көмешкә буялган челтәрле баганалары. Юлның як-ягында исә башлары белән ак болытларны терәп торган корыч бораулау вышкалары, күп төрле бүтән корылмалар чагылып калгалый. Җәйрәп яткан уҗым басуларының яшел хәтфәсе өстендә нефть бирүче скважиналарның сиртмәле насослары чайкала. Читтән караганда алар зур, башын бер иеп, бер калкытып, табышын чукучы шыксыз кошларны хәтерләтә. Шунда ук үлчәгеч резервуарлар, трап, арматура һәм акка буялган культбудкалар. Бераздан инде без төзелеп яткан цех мәйданында идек...

Ул көнне комиссия вәкилләре кунакханәгә бүтән һичкайчан да булмаганча, кутәренке күңел белән кайттылар. Хикмәт көннең аяз, юлларның такыр булуында гына түгел иде, әлбәттә.

* * *

— Бу ниткән эш инде, Гази улым? Тагын берни дә капмагансың бит. Ярый торган эшмени инде бу, ә?

— Борчылма, Гайния түти. Мин ашыйм. Эчем пошкан саен, торып чемченәм...

— Кая инде! Бар әйберләрең дә шул көе ич, бөтенләй капмагансың. Сөт өстенең дә әнә капкачы ачылмаган.— Чынлап торып ачулана башлаган Гайния түти, ризасызлыгын белдереп, суыткычның ишеген кирәгеннән артыграк шапылдатып япты.— Болайга киткәч, дежур билгеләми ярамас үзеңә...

— Юкка борчылма әле, Гайния түти...— диде Гази, сулышын җайга салырга теләгән кебек, чак кына туктап торып.— Иң әүвәл сөйләп җибәр, больницада нинди яңалыклар бар?

— Барысы да күп итеп сәлам тапшырырга куштылар үзеңә. Әй-ие! Теге, операция ясалган Мәскәү кешесе дә, ходайга шөкер, үзлегеннән аякланырга маташа...

— Менә монысы яраган!

Гайния түти тагын Дисә турында да сүз кузгатмакчы иде дә, аның күңелен кабат җәрәхәтләүдән курыкты. Сүзне яңадан Газиның үзенә күчерде.

— Кара әле, Гази улым,— диде ул кабат битәрле башларга җыенгандай итеп.— Әйтче, бәлки эчең эзләнәдер, ашыйсы килгән әйберең бардыр? Берәр таба ашы әзерлимме әллә? Болай валчык та ризык капмыйча ятып булмас бит. Авыру кешене чир җитәкли ди. Ашамыйча-эчмичә ничек савыкмак кирәк. Болайга киткәч, тәки больницага алдыртмый булмас үзеңне. Күз алдыбызда ятарсың ичмаса. Ялгызлык ул, Гази

улым, адәм баласына гына түгел, эт башына төшеп тә ябагаларын койдыра...

Гайния түти Газиның тизрәк савыгып аякка басуын теләп китеп барды. Яңадан Газины ялгызлык хисе талкый, җанын баса, җанын изә башлады. Гази күңелендә чокына, кирәгеннән артык казына-актарына башласа, мең төрле югалтулар, үпкәләр, сагыну-юксынулар, язмышның каһәрләре, бөтен дөньясына рәнҗүләр — барысы бергә җыелып, үткән еллар эләпәсе генә каплый алмаслык, кара кан саркып торган җәрәхәте сызлыйсын яхшы белә. Үзәк өзгеч үкенү ачысыннан укмашкан яра ул. Әлеге гомер узмаслык үкенү бары тик бер авыз сораудан гыйбарәт: нишләп болай булды соң әле бу?..

Менә тагын бер мизгел эчендә Газиның зиһенен телгәләп, әлеге аяныч сорау калыкты. Чыннан да, нишләп алай булды соң әле бу? Нилектән кавыша алмадылар соң әле яшьли сөешеп, вәгъдәләр бирешкән ике яшь йөрәк? Нәрсә комачаулады? Сәбәбе нәрсәдә?

Әйе, булды андый сәбәпләр. Барысына Гази үзе гаепле. Гази белән Гөлүсәне никахлаштырып кавыштырырга җыенулары турында комсомол башлыгы Кадыйр Надыйров та ишетеп калган булса кирәк. Газины аулаграк урында эләктереп алды да — сагалап торган булса кирәк — бик гадәти сүз алып баргандай, гәп сата башлады.

— Күрше районда бер комсомол белән ниләр булып беткәнен ишеттеңме әле? Юктыр, мөгаен. Яшәрлеген калдырмаганнар ди егетнең. Комсомолдан ук чөйгәннәр. Ни өчен диген? Бер нэпман калдыгының кызына өйләнгән. Бөтен шартларын китереп, никахлар укыткан ди бит намуссыз җан! Җә, әйт, комсомол әхлагына сыя торган нәрсәме шул? — Аннары, бик зур сер ачарга җыенгандай, ярым пышылдап диярлек әйтәсалды.— Дус булуыбыз хөрмәтенә генә искәртәм үзеңә. Уяурак була күр... Хәер, син байлыкка сусаган мал корты түгел, саф пролетариат, чын коммунист улы. Чәчбиеңнең... Гөлүсәнең дип әйтүем, кем булуын онытып бетермә дип кенә искәртеп куюым. Искелек ул, Гази дускай, кара канга батканда да тиз генә җан бирмәячәк! Аһ-һ, юк!.. Гасырлар буена көч-егәр туплаган шул ул. Әмма без барыбер җиңәчәкбез. Дөнья — күләм революция бөтен җир шарында тантана итәчәк! Әбәзәтелне итәчәк!..

Әлеге әңгәмә үзенекен итте. Гази икеләнә калды. Артык тугры, артык беркатлы, артык хәйләсез иде шул ул. Яшь Совет иленең бөек омтылышлары, илаһи идеаллары белән яши иде. Барысына да ихластан инанды. Шул якты идеаллар хакына берсүзсез җанын фида кылырга да әзер иде Гази. Кемнәрдер әлеге якты идеалларны үз мәнфәгатьләренә хезмәт иттерерләр, бер мәгънәсезлеккә әвереллдерерләр дип башына да сыйдыра алмый иде шул ул.

Аптырашта калган Гази төрлечә уйлап карады. Бу кадәр каныкмас иде дип уйлады ул Кадыйр Надыйров турында, әллә үзе Гөлүсәне яратамы, чукынмыш? Шул ук кичне ул Гөлүсә белән дә фикер алышкандай итте. Кызның: Ә син ни дип җавап кайтардың?— диган соравына, ярәшкән егет өзеп җавап кайтара алмады, җилкәләрен генә җыерды. Аннары зарланган сыман итеп тезде дә тезде: «Теш төбен сыкрата бит җүнсез, чат ябышты, өзми дә куймый да, һаман бәйләнепме бәйләнә...»

Тиздән, бик тиздән, тиң яр белән кавышу бәхетеннән нурларга коенып, күкләргә очардай канатланып яшәгән Гөлүсәгә әллә нәрсә булды да куйды, таныры калмады кызыкайның. Гамәлгә ашмас микәнни безнең бергә булабыз дип ашкынулар? — диган сыман, егетнең күзләренә керердәй булып өздереп карап торды да, «Кайтыйм әле, булмаса...» дип, Гази кочагыннан балык кебек шома гына шуып чыкты да йөгереп китеп тә барды.

Газидән битәр аптырашта калган Гөлүсә әлеге гәпне өендә дә чиште. Иргали: юк белән башыгызны катырмагыз, күрше авылдан берәр мулла чакыртып алырбыз да никахлашуыгызны күрше-күләң түгел, үзегез дә

сизми калырсыз дип көлде генә. Әмма ана кешенең фикере үзгә, бу хәбәр аның җан ачуларын чыгарды. Шундук үзенең соңгы сүзен дә әйтте: «Юк, юк, дөньяда булмаганны! Ниткән эш ди ул тагын... Оят-инсаф дигән нәрсә бар. Никахсыз яшәргә ул бит ниндидер үксез-ятимә дә, каяндыр читән астыннан табып алынган бала да түгел. Моның өчен җирбит булырга кирәк. Аллам сакласын! Кая ул! Минем алай көчләп яки ялвареп-нитеп бирергә дип үстергән артык кызым юк. Нәсел-нәсәптә булмаганны. Юк, юк! Минем ефәк чуктай кызым кемгә дә ярарлык. Яшьли сөешеп кавышканга ни җитә дип кенә ризалашуыбыз иде. Болайга китсә, кая ул!..

Күңелгә шөбһә сала торган әлеге сүзләр, көне-сәгате белән ут күршеләренә дә барып җитте. Сөмсере коелып, кара сөремгә төренгән Зәйтүнә тораташтай катты да калды. Әле кичә генә улы Газига: «Сине, балакай, алда ак бәхетләр, зур куанычлар көтә, тиздән мөстәкыйль тормышка аяк басачаксың. И-и, этиегезгә генә күрергә язмаган икән бу шатлыкларны! Каз өмәләре җиткәндә, туегыз кәтелә, боерган булса»,— дип, куанычлары эченә сыймаган иде ананың.

Хәзер менә кинәт кәефе кырылды, гайрәте чикте, тормышының бөтен хозурлыгы югалган сыман булды. Буыннарында хәлсезлек тойды. Имәнеп китеп, күңелендә чуалган уйларының очына чыга алмыйча иза чикте. Бәгыре көйрәүгә тәкате калмады. Шул инде дип уйлады ул, кайгы-хәсрәтне аны беркем дә көтеп алмый. Нишли бу тилемсә, нишли?!. Кызның гайрәтен үзеннән чигерер дә куяр, шул булыр. Я-ә, тиле түгел диген инде син аны!

Нәкъ шул вакытта Гази кайтып керде. Ана кеше, үзара аңлашырга җай чыкканга куангандай, вәгазь-нәсихәт укып-нитеп тормады, яулыгын күзләренә төшеребрәк бәйләде дә, әлеп алып селтәп тә салды: «Сәрхәнтәйнең дә сәрхәнтәе булырсың икән!.. И-и, дивана! И-и, авызына капканны йота алмаган нәмәстә... Акыл өләшкәндә, өй артында калгансыңдыр син, башкача булмас...» — Гази сүзнең нәрсә турында баруын шундук төшенде. Әнисенең танырлыгы калмаган. Бәгыренең хәсрәт ялкынында куырылган, күңеленең тулышкан чагы булгандыр, мөгаен. Йөзе агарынган. Ничектер сулып калган сыман. Күз карашы да болыт астына кереп баручы сүрән кояшны хәтерләтә иде. Гази үзе дә һичкайчан да тәзәтеп булмаслык ниндидер ялгыш адым ясарга җыенуын күңеле белән сизенсә дә, кире чигенерлек көч таба алмады. Әнисенең үпкә-рәнҗү белән әйтелгән сүзләре, бәгырен утлы тимердәй өтәләп алса да, сер бирергә теләмәде, аңгәмәне уенга борып җибәрергә маташты. «Ташлачы, әни! Һәр гыйшык тоту өйләнешү белән очланырга димәгәндер ич...» — дигән булды. Бу мизгелдә теле ни сөйләгәнне үзе дә ахырынача төшенеп бетми иде бугай.

Ул арада ана кеше елый ук башлады: «Чистый туң йөрәк икәнсең, кадалгыры!.. Бигрәк кеҗәләр үкенечләргә булган икән. Ил-көн алдында адәм мәсхәрәләренә каласыларыбыз бар икән. Ничекләр итеп түзәрбез!.. Шулайлар итеп хәзер инде ярәшкән-вәгъдәләшкән кәләшеңнән дә йөз чөереп маташкан буласыңмы? Кыз баланы вәсвәсәләндермиләр аны, гөнаһларын кая куярсың? Алла оруыннан курык, бер дә булмаса. Үкенәсе көннәрең алда әле, тик соң булыр. Матри аны! Тикмәгә генә: беренче мәхәббәт — йөрәк хуҗасы,— димиләрдер. И-и, тинтәк! И-и, тәкәббәр хәерче! Нәрсә, тамагың туйдымыни? Өс-башыгыз бөтәйдеме? Шулдыр шул! Кем аркасында? Ә?.. Әй-йе, кадер-хөрмәтләрен күп күрдек. Бердән — ходайга, икенчедән — аларга рәхмәт укырга тиешле кешеләр без. Каты баш!.. Тилебәрән орлыгы ашаган нәмәстә. Каян туды ул синдә андый юк-бар уйлар? Әллә теге Кадыйр мөртәтнең мәкеренә төшенмичә калдыңмы? Шуны бел, гаилә корганда кеше сүзе — агу ул. Исем-акылларым китә, валлаһи газимдер! Әгәр дә бик беләсең килсә, Гөлүсә сиңа хәрам ул. Теләсәгез нишләгез... Алайса йөрәгез инде зар-интизар булып,— диде ана, кеше үзе өчен дә, игелексез улы өчен дә берьюлы әрнеп.

Кадыйрның мажаралары моның белән генә чикләнмәде. Иргали абыйлары өстенә бәла килеп, баш очларында кара болытлар куерган көннәрнең берендә, район газетасында комсомол башлыгы тарафыннан оештырылган «Жәзаның иң катысы бирелсен» дигән мәкалә басылып чыкты. Иман әсәре булмаган әлеге язма астында үз фамилиясен күргәч, ярсуыннан, гарьлеге бууыннан, шартлар дәрәжәгә житте Гази. Очрату белән өзгәләп ташлардай булып Кадыйр янына йөгерде. Әмма тегесе бик тиз суытты егетнең кайнарлыгын. «Син нәрсә?!.— диде ул, Гази өстенә ябырылып килеп.— Имзаңны куеп, дөрес итмәгәнбезме әллә? Бәлки синең шул контрны, кеше үтерүчене яклап, аклап язарга теләгең бардыр, ә?.. Син әйт, тартынма. Без бит сиңа үзеңнең тирә-юньдә атаклы большевик, продкомиссар Хажи абый малае икәнлекне исенә төшерергә дә күп сорамабыз. Бәлки аларның иске-москылары, хәергә биргән чүпрәк-чапраклары күзеңне томалагандыр? Бәлки табыннарыннан калган каты-котылары авыз суларыңны корыткандыр? Шулар сыйнфый сизгерлегеңне оныттыргандыр?..»

И-и китте тезеп, и-и китте ярсып, авызыннан утлар чәчте, түз генә. Газиның күңелендә купкан давылы шундук юкка чыкты.

Ниһаять, Иргали абыйларын авылдан сөрү көне дә житте. Газиның күңеленә гомергә уелып калган күренешләр. Сыкы сарган март иртәсе. Кар өстендә энже-җәүһәр тузаны, күзләреңне генә түзсен. Тимерхут арбаларга төялгәнгә күрәме, олаулар кирәгеннән артык биек булып күренәләр. Чанага ияләшкән күзләр өчен, март аенда арбага жигүле атларны күрү бераз сәеррәк иде шул. Алда торган билгесез сәфәрнең юлы озын, озак буласын Иргали абыйсы бик яхшы белгәндер, күрәмсең.

Бәһрам абзыеның сүзләреннән шул кадәресен аңлады Гази: Иргали абыйсы бөтен гайрәтен, сәламәтлеген биреп тапкан мал-мөлкәтен тулысынча колхозга тапшырган. Өен балалар бакчасы итүен үтенгән. Итмаен, башка төрле азык-төлеген сакларга менә дигән кар базы, таш келәте бар, дигән. Сауранны жигелгән көймәле чанасын, лапас астындагы жиңел тарантасын дирбияләре белән идарәгә дип Бәһрам жизнәсенә бүләк иткән. Сабан-тырмаларын, кул жилгәргечен, башка бик күп эш коралларын ике көн буе колхоз дворына ташыганнар. Үзенә закон буенча тиешле бер кат кием-салым, беренче кирәк-ярак нәрсәләр, гаилә башына бер жигүле ат кына калдырган. «Акланып кайта-нитә калсам, куышсыз итмәссез, шәт»,— дип әйткән ди. Соңгы минутка кадәр хаклыкның жиңүенә, үзенең акланачагына өметен жуймаган булган икән.

...Кара болыт кебек жыелган халык, урталай ярылып, юл ачты. Жигелгән килеш торудан йончып беткән ат, чөңгерү белән, авыр йөкне шак-тый ук киерелеп йолкып алды да кузгалып китте. Икенче атның дилбегәсе Рәхимжан кулында иде.

Шушы мизгелне генә көтеп торган кебек яңадан шау-шу купты, хушлашу-саубуллашу авазлары тагын да көчәя төште. Арба юнәлешенә ияргән халык ташкыны Газины да үзенә ияртте. Аның күзләре, арба кырыена, әнисе янына чыгып утырган Гөлүсәдә. Кызның шәле белән яртылаш томаланган йөзе, иелеп утыргангамы, бөтенләй диярлек күренми. Сирәк-мирәк кенә баш калкытып күтәрелеп караганда да, Гөлүсәнең кеше күрмәс күз карашлары каядыр билгесез якка юнәлгән шикелле. Әмма ул жан тетрәткеч караштa үпкә катыш моңсулык та, кемгәдер рәнжү дә, гажизлектән аптырау галәмәтләре дә ярылып ята иде. Шул мизгелдә Гөлүсәнең күңелендә ниләр тулгануын, жанын нинди әрнүләр айкавын Гази үзе генә сизә кебек иде.

Әле кайчан гына Гази Гөлүсәнең сиздермәскә теләгәндәй яшертен генә бер томырылып карап алуыннан гына да төшләргә дә кермәслек гажәеп куаныч, жан рәхәте, татлы ләззәт кичерә иде.

Шундый уйларга бирелеп Гази атлый да атлый. Басу капкасына кадәр озата килүчеләр дә инде күптән артта калды, ә ул үзләре утырып барасы атны куып тотарга ашыкмады. Бу минутта ул озын-хәтәр сәфәргә

чыгучылар арасында Гөлүсәнең дә булуына ут йота: нинди курку мине шулкадәр өркетте? Нинди көчләр ихтыярымны сындырды? кебек сорауларга җавап таба алмаудан, үзенең көчсезлеген каһәрләүдән гаҗиз иде.

Алты-җиде җигүле аттан торган кәрван, киек кошлар кебек тезелешеп, һаман алга таба баруын дәвам итте. Нииндидер фәкыйрь генә бер авылга кунарга керүләре хәтерендә калган Газиның. Анда да ул, Гөлүсәне аулаграк урында очратып, сыңар гына да сүз әйтә алмады. Кадыйр, нәкъ кара күләгә кебек, аңардан бер генә адымга да калмады. Кем белә, бәлки ифрат та кимсетелгән, рәхимсез рәвештә рәнҗетелгән Гөлүсәнең дә Газига нәрсәдер әйтәсе, нидер аңлатасы, күңелен ачасы, соңгы сүзен җиткерәсе килгәндер. «Тора-бара гел барып чыктым мин...» — дип, кат-кат үзен сүгүдән башканы булдыра алмады Гази.

Икенче көнне төш авышканда, Бөгелмәгә барып җиттеләр. Аларга кирәкле урын шәһәрдән шактый читтә, алар килеп төшкән якта иде. Шунлыктан калага кереп тә тормадылар, «Монастырь» дип аталган, тирә-юне нигытманыкы кебек биек таш койма белән уратып алынган биләмәнең тоташ тимердән коелган иләмсез зур капкасы каршысына килеп туктадылар.

Гази өчен иң авыр мизгелләр. «Ни хәлләр итеп якынлашыйм янарына?.. Ни күзләр белән күреним үзләренә?!» — дип, җанын талкыган уй-хисләрен җиңеп, Гөлүсәләр олавы янына атлады. Бәхетенә Иргали абые аларны каршы алган хәрбиләр, документлар белән мәйханә килә иде. Гөлниса апасы да биек итеп төялгән олауның икенче ягында. Гөлүсә аны бер-ике адым алга омтылып каршылады. Газиның да хәле хәл иде: ул кызның күзләренә элеккечә туры карый алмавын сизде. Кутәрелеп караса, Гөлүсәнең күзләрендә йөрәк бәгыренә үтәрлек үпкә-рәнҗү күрүдән курыкты ул. Шулай нәрсә әйтергә белмичә ык-мык итеп торган арада, тирә-юньгә хәтәр хәбәр салгандай, тимер капканың яман шыгырдап ачыла башлавы ишетелде. Олауларга эчкә үтәргә дигән боерык яңгырады...

Һуштан язу дәрәҗәсенә җиткән Гөлүсә кабат Газига таба тартылып куйды. Гази да, ниһаять, ике иңеннән алып, кызның йөзенә текәлде. Текәлде дә дөньялардан китәрдәй булып катты да калды. Гөлүсәнең туры-рып, туры итеп караган күзләрендә мәңге онытмаслык итеп карап калырга теләү дә, гаҗизлек белән коелып төшү галәмәтләре дә, тел белән әйтеп аңлатып булмаслык тагын әллә нинди хисләр дә чагыла иде.

Гөлүсәнең көч-хәл белән иреннәрен кыймылдатып әйткән җан өзгеч сүзләре ишетелде.

— Гази!.. Аерылабыз да микәнни!.. Яа-а, йөрәккәем, ярылмыйча түзсәнче. Мәңгегә хушлашабыз бит...

Бу сүзләрдә дә: «Шушы хәлләрне булдырмаска да мөмкин иде түгелме соң?» — дигән ялвару-өзгәләнү сизелде шикелле.

Йөрәгендә өермә уйнаган Гази җавап сүзләре эзләде. Эзләде, әмма таба алмады. Ул арада алдагы атлар кузгалдылар. Газига да кинәт әллә нәрсә булды. Әллә инде вөҗданы уянды, ул җилтерәтеп кенә Гөлүсәне кочагына алды һәм соңгы сүзен әйтте:

— Ярар, Гөлүсә! Нишләмәк кирәк... Бәхил бул, җаным!..

Аның кочагыннан ычкынган Гөлүсә, егылып китүдән курыккандай, кузгалган арба урәчәсенә барып тотынды. Аннары, мәйдан кебек киң ишегалдына үткәч, соңгы тапкыр артка таба каерылып карады. Газига таба сузылгандай хәрәкәт ясады да, җан өзгеч тавышы белән һаваны ярды:

— Гази-и!.. Онытма ми-не-е...

Гөлүсәнең ачыргаланып кычкырган әлеге сүзләре мәңге-бакыйга, гомере буена онытылмаслык булып йөрәк түрендә уелды да калды.

Ул, арада, корбаннарын йоткан аждаһа сыман, буяулары кубудан ала-колаланып калган тимер капка да дөбердәп ябылды. Бары тик шунда гына Гази бу аерылышуның гомерлеккә икәнен бөтен җаны белән той-

гандай булды. Кыз баланың ярдәм өмет иткән сыман аңа таба кулларын сузып: «Га-зи-и! Оныт-ма ми-не-е...» — дип әрнеп-өзгәләнеп кычкырып калулары Газиның бәгырен чи яралап кына калдырмаячак, ә гомере буе эзәрлекләячәк. Бу тавышка ул төннәрендә чәчрәп-сискәнеп уяначак. Әсирлектә, концлагерьларда чит-ят хатын-кызларның ачыргаланып кычкыруы да аңа Гөлүсәнең ярдәмгә чакыруы булып ишетеләчәк...

Күңеле шулай бәргәләнеп, вөҗдан газапларыннан җанын кая куярга белмичә аңгыраеп йөргән көннәрнең берендә Гази тормышында искәрмәстән генә янә бер вакыйга булып алды. Бу хәлдән соң аның исеме дә атаклы этисенеке белән янәшә халык теленә килеп керде.

Көннәрнең берендә, күрше авыл егете Әхмәтне ияртеп, РКСМның беренче рәисе Саттаров килеп төште. Минут эчендә комсомол активын җыеп алырга кушты. Шунда барысының да чәчләре үрә торырлык шомлы-шөбһәле хәбәр җиткерде. Бөтен Кама-Чулман буен дер селкетеп, халыкның өнен алып, берсеннән-берсе яманрак җәбер-золым салып йөрүче, кансызлыгы белән даны чыккан Тимершик бандасы бу якларга килеп чыккан, имештер. Әгәр дә хак булса, бүген төнлә Салаязга орынып торган Тын Алан утарында башлыклары җыелачак икән. Бу бандаының вәхшилеге турында нинди генә тетрәндергеч хәбәрләр йөрми иде халык телендә. Авыл активистларын, колхоз һәм партия житәкчеләрен асу-кисүләр дисеңме, терелэтэ утта яндырулар, хатын-кызларны мәсхәрә итүләр, хәтта сабый балаларны үтерүләр дисеңме... Соңгы корбаннары күрше районның ике милиционеры булган. Урманда ботаклар астыннан табып алганнар үзләрен. Башларын-башка, гәүдәләрен-гәүдәгә ботарлап ташлаганнар ди.

Саттаров: «Борын төбегездә ниләр эшләгәнне белмичә ятасыз, пенимаешь!» — дип тиргәп тә куйгандай итте. Әмма алда торган җаваплы эш аңа бик иркенәергә ирек бирмәде. Ул шул банда җитәкчеләренең кемнәр булуын, кемнәрдә җыелачакларын төгәл белергә һәм сәгате-минуты белән районга, тиешле органнарга хәбәр итәргә тиеш икән.

Сүзне әллә ни озакка сузмадылар, шундук план сыман нәрсә дә кордылар. Яшьләр ике төркемгә бүленде. Төп төркем Гыймади бай өен күзәтү астына алачак. Бакча артларына тозак куелачак. Саттаровның уенча, бандитлар да, атлары да шунда, бай утарында булырга тиеш.

Әмма Тын Алан егете Әхмәт, РКСМ секретарен бүлеп, тагын бер көтелмәгәнрәк хәбәр өстәде: авылның Кара Гайнетдин дигән бер имансыз бәндәсе Гыймади байлардан капчык белән нәрсәдер күтәреп алып кайтканын абайлап калганнар. Үткәне караңгы, ниндидер җинаятьләре өчен заманында җавапка да тартылган әлеге Кара Гайнетдин өендә җыелмыйлармы икән? Каралты-курасы да шактый аулак урында, кеше күзеннән читтә ди.

Сүзгә Надыйров кушылды. Әлеге шикле Кара Гайнетдин дигән кешенең кайсыдыр яктан Газиларга чак кына чыбык очы булуы турында сүз куертып алды. Шул сүз комсомол Газины әлеге шикле кешенең өен тикшерергә җибәрү өчен җитә калды.

Гази юлда. Кеше күзенә артык ташланмасын өчен, ялгызын гына туры юлдан җибәрделәр. Бу хәлгә Гази теләсә дә, теләмәсә дә, ризалык бирде. Чыннан да, Кара Гайнетдин аңа әнисе ягыннан хәрендәшрәк кеше иде. Ләкин инде аларны үзара бәйләгән туганлык җепләре күптән өзелгән, аннан соң Гайнетдин ике-өч хатын башына җиткән кеше. Шулай булуга да карамастан, Газиның берничә тапкыр аның өендә булганы һәм «җизни» дип мөрәҗәгать иткәне бар.

Аяк асты туңдырган. Кантарлы булса да, такыр юлдан атлавы җиңел. Тирә-юньдә шыксыз бушлык, ачы җил генә хакимлек итә. Моннан берничә генә көн элек яуган беренче кар бөтенләй диярлек эреп беткән. Бары тик чокыр-чакыр урыннарда, куаклык буйларында гына кар көртләре күренгәли. Алар да инде көпшәкләнеп, җете аклыкларын югалткан-

2*

нар. Шуңа күрә, читтән караганда, егылган каен агачы кәүсәләрен хәтерләтәләр иде. Җил-җил атлаган Гази авыр болытлар әүмәкләшеп хәрәкәтләнгән күк йөзенә карап алды: ае гына да юк бит, ичмаса.

Шулчак, юлның сул як кырында үсеп утырган куакларның шәрә ботакларын, үләннәрнең кипкән сабакларын, коелган яфракларын кыштырдатып, нәрсәдер хәрәкәтләнеп алды. Йөрәге жу-у итте Газиның. Төнге кош яки куян-төлке ише нәрсәдер дип, үз-үзен тынычландыргандай итте ул.

Нәкъ шул мизгелдә фаҗигале үлем белән дөнья куйган этисе күз алдына килде. Продкомиссар Хаҗи Зәкиевне дә нәкъ менә шушындый караңгы төндә харап иткәннәрдер, мөгаен. Этисе икмәк төяп кайтып килгән юлның да як-ягы, нәкъ менә мондагыча, вак куаклык һәм кеше буе булып котырып үскән шайтан таяклары белән капланган булгандыр. Аларның да корыган сабакларын җил сыйпап узгандыр. Аерма тик шунда: ул вакытта яз иде.

Чыннан да, бандитлар өерләре белән каршысына чыгып, күкрәгенә обрез терәгәч, этисе үз-үзен ничегрәк тотты икән? Һәрхәлдә, атын жанфәрман куып кача башламагандыр, кешесе ул түгел. Уттай янган күзләрен бандитлардан алмыйча, гәүдәсе, як-якка җәелгән куллары белән арбадагы капчыкларны каплагандыр. Шулай итеп, ул икмәкне генә түгел, революция казанышларын да, Совет властен да саклагандыр. Ул вакытта, пролетар шәһәр ачлыктан интеккәндә, икмәк һәрнәрсәне хәл итә иде шул.

И-и, эти!.. Сыйнфый көрәшнең һаман да тынганы юк әле. Көчәя генә бара... Һәркөнне диярлек асу-кисү, ерткычларча җәзалаулар турында ишетеп кенә торабыз. Дошманнар, контрлар беренче коммуналарның хуҗалыкларын, икмәк амбарларын, мал-тўар каралтыларын яндыра... Әнә Бәһрам абзыйның да өең ишегенә язу кыстырып киткәннәр. Нибары бер авыз сүз: «Барыбер иманыңны укытабыз, коммун эте!» Менә мин дә хәтәр сәфәргә чыктым, эти...

Шундый уйларга бирелеп, биш-алты чакрым араны йөгереп үтүен сизми дә калды Гази. Тын Алан утары йоклый. Бик сирәк өйләрнең тәрәзәләрендә генә, тычкан уты сыман, яктылык чагыла. Кайдадыр урманга елышып утырган урамда эт өрә. Ямьсез итеп елап-улап өрә. Этнең алай өрүен бер дә яхшыга юрамыйлар.

Гази Кара Гайнетдин өенә арткы бакча ягыннан, су буе үзәнлегеннән күтәреләсе итте. Әмма караңгы тыкрыкка борынын төртүе булды, өстә, урам башында хәрәкәтләнүче ике күләгәне абайлап алды. Әйе, ике ир-ат. Әнә берсенең тәмәке уты да очкынланып алды.

Гази күрше бакчасына сикерде. Кара Гайнетдин өенә житәрәк, жилләсен өчен бәрәңге сабагы таратылган читән аша «жизнәсе» ишегалдына төште. Саклык белән ян тәрәзә янына килде. Әхмәт ялгышмаган булып чыкты, банда җыены, чыннан да, Кара Гайнетдиндә икән...

Кичкенә тәрәзә эчтән бик шәплэп томаланган. Бары тик читендә ут яктысы сызылган. Гази, бөтен булган игътибарын туплап, тәрәзәгә елышты. Эчтә бедер-бедер килеп берьюлы берничә ир-ат сөйләшә. Вакыты белән тавышлары шактый ук күтәрелеп алгалый, андый чакта сүзләре дә аермачык ишетелә. Әнә кайсыдыр кемгәдер янап куйды.

— ...берәр хикмәт чыгаргалаганчы, иманын укытырга да, вәссәләм!..

— Әйтмә дә!

— Этисе дә бер бәлшәвик азгыны иде аның.

— Әй-йе!.. Ходай орган, ил өстенә бәла-каза китерергә өндәүче ходай каргаган адәм актыгы...

— Кояштыр менә, шуны күрсәм, бөтен вөҗүдем, кальбем котыра...

Гази Гыйззәт хәзрәт тавышын ачык танып алды. «Аңа монда ни калды икән?» — дип уйлап куярга мәҗбүр булды ул. Бәлки биредә ил картлары гына җыелгандыр?.. Алай дияр иде, ни өчен тәрәзәләр шул тиклем томаланган да урамга бер түгел, икешәр дозор куелган?..

Гази, тагын да поса төшеп, тәбәнәк нигезгә менеп тезләнде дә, тәрәзәгә елышып, яңадан тыңлый башлады.

— ...Башына җитмичә туктамас ул, имансыз!

Кайсыдыр хәзрәтне тынычландыра башлады.

— Артык хәвефләнергә урын юк, хәзрәт... Иншалла...

Тагын берьюлы сөйләнеп алдылар. Кемнендер исән калу-калмавы турында гәп сата башладылар. Шунда бүтәннәрдән аерылып торган көр тавыш үзенең ризасызлыгын белдерде.

— Ишкәнсез икән алайса... Эх-х, сезне! Әтне аны үлде дигәч тә ярты көн кыйнарга кушканнар...

Шулчак үч иткән кебек, иске дранча түбәне шыбырдатып, мылтык ядрәсе сыман, ярмалы кар ява башлады. Урам яктагы ике ир-атның капкага таба якынлашулары да күренде. Болар сакка куелган кешеләр булырга тиеш иде.

Гази нәрсә эшләгәненә исәп-хисап биреп тормастан, шактый ук җилле итеп, тәрәзә рамасына каккалап алды. Шактый зур саксызлык күрсәтүен ул бары тик шунда гына сизенде. Ләкин соң иде инде. Өй эче дә тып-тын калды. Кар явуы аермачык булып ишетелә башлады. Гази җәһәт кенә ишек янына күчте.

Аны ишеткәннәр. Таныды Гази: Кара Гайнетдин тавышы.

— Кем?..

Югалып калырга һич тә ярамый иде.

— Бу мин идем, җизни. Ач әле...

— Кем диден?..

— Соң, мин инде... Синең Салаяз кайнишең — Гази...

— Ндә-ә, алай икән...— Кара Гайнетдин аптырашта иде булса кирәк. Тавышында пошаманлык. Үзен күрмәсә дә, сизенде Гази, хәрәкәтләрендә таркаулык.

— Ач инде,— дип кабат аваз салды Гази.

— Кара әле, кем, Газиулла кайнеш... Ни бит, миндә сырхау кеше бар иде...

— Барысын да беләм, җизни. Гыйззәт хәзрәтнең дә сездә икәнен беләм. Миңа ул кирәк...

— Ндә-ә!.. Алай икән. Тукта алайса... Чак кына сабыр ит...— Җизнәсе өй ишегенә юнәлде. Аның кунаклар белән кинәш-табыш итүе, кабаланып, ярым пышылдап гәп корып алуы ишетелде.

Гази әрсезләнүен белде, ишекнең тимер келәсен хәрәкәтләндереп кабат шакып куйды. Бу кадәресен Кара Гайнетдин дә көтмәгән булгандыр, мөгаен. Җизнәсе яңадан ишек янында.

— Нәрсә, кайнеш, йомышың шулай кичектергесез идемени соң? Ндә-ә, төнгә карап килүеңне әйтәм...

— Кичектергесез иде шул, җизни.— Гази, беткән баш беткән дип, алдаша ук башлады.— Хәзрәт бик кирәк иде... Йомышның иң зурысы — аңарда...

— Ндә-ә, алай икән!— Өй хуҗасы яңадан кунаклары белән кинәш-табыш итеп алды булса кирәк. Әмма озак түгел, шундук ишек артында тавышы ишетелде.

— Алай бик кирәк булгач, әйдә, үт инде. Тик ни бит... Ни дип торам...

Гази хуҗадан алда яктылыкка омтылды. Ут шәүләсе төшеп торган яртылаш ачык ишекне үзенә тартты. Шундук күңелен курку катыш шом өтәләп алды. Үзен искәрмәстән генә эрткычлар өненә эләккән сыман хис итте. Бик сәер күренеш каршылады аны. Өйнең яртысын биләп торган сәке алынган. Табын киез җәелгән идәнгә хәзерләнгән. Урта бер җирдә зур агач табак тулы ит турап куелган. Ашъяулык өстендә телем-телем итеп киселгән икмәк, казылык, ботарлап ташланган каклаган каз ите өемнәре...

Гази үзен бик тиз кулга алды. Ул белә: бертөрле дә шик-мазар ят-

маска тиеш, югыйсә харап. Күр әле син аларны, аулаграк урында очрашсаң да өннәрең алынырлыклар бит. Иң түрдә, урта бер җирдә, мендәргә янтая төшеп, таза гәүдәле бер бәндә утыра. Кием-салымы шәп. Карап торырга шактый ук чибәр үзе. Ап-ак киң маңгае да, чем кара мыеклары да үзенә килешеп тора. Күзләре ут. Вәкарьле карашы Газида.

Аның сул ягында — элеп киптергәнгә охшаган арык-какча бәдәнле бер зат. Каратут йөзен җиткән сакал-мыек баскан. Карашы ерткычныкы. Шундук Гыйззәт хәзрәт. Янында йөзе яртылаш капланган такыр башлы, тырпаеп торган йонлач кашлы бер кеше ята. Хәзрәт, шул кешенең баш очында, кулларын күтәреп, бөтен шартын китереп, дога кылып утыра.

Менә ул йөзен Газига таба борды. Йөзе нурсыз иде хәзрәтнең. Тавышында да ризасызлык.

— Яа-а, таңрем, кичерә күр берүк... Гүр иясе булырга яткан кешегә дә тынгы юк бит. Ләхәүлә! Иманнары беткере... Хак тәгалә эше белән мәшгуль булуымны белә торып, зиһенемне чуалтып йөрүләрен күр инде...

Гази үзенең аптырап та, каушап та, югалып та калуын яшерергә тырышып, авылдашының кичерүен үтенде.

— Мең кәррә гафу, хәзрәт!..

Хәзрәт ачуланырга ук кереште.

— Ни бар? Әйт тизрәк... Авыру янына утырып, иркенләп тәһлил әйтергә дә ирек бирмисез бит... И-и, хәсисләр!..

— Ни иде, хәзрәт... Сине эзләп бер ат җиккән кеше килде. Бик кирәк, хәзер үк кирәк диде. Менә мине йөгерттеләр...

Газига алдашып, хәйлә корып, озак баш ватарга туры килмәде. Нәкъ шул вакыт, бөтенесен берьюлы ерткычка әверелдереп, тышкы яктан агачмы, тимер әйбер беләнме, пыялалары коелып төшәрдәй итеп, тәрәзә рамасын төя башладылар. Бу көтелмәгән хәлдән Гази да коелып төште.

Аңардан битәр, өйдәгеләрнең хәле хәл иде. Гарасат җиле истемени, секунд эчендә дәррәү кубып, барысы да аякландылар. «Сырхау» беренчеләрдән булып чәчрәп сикереп торды. Ыгы-зыгы купты. Кайсыдыр ике лампаның берсен сүндерде. Икенчесенең карлыккан тавыш белән:

— Кабаланмаска!.. Берәмләп-икешәрләп кенә таралырга. Кораллар ахыр чиктә генә кулланыла... Төшендегезме? Ә хәзер, барыгыз... Марш! — дигән боерык ишетелде.

Шулчак Гази ярым караңгы тар аралыктан берәүнең мәче җәһәтлеге белән атылып чыкканын абайлап калды... Башкасын хәтерләми. Күз алдында гөлт итеп, исәп-хисапсыз очкыннар учмасы чәчрәвен һәм аяк астындагы идәннәргә җан кереп, каядыр бер якка шуып китүләрен генә чамалап калды.

Күпмедер вакыт үткәннән соң, колагына: «Газины үтергәннәр!..» — дип кычкырган өн килеп җиткәнен хәтерли тагын. Ә инде үз-үзен аңлар-абайлар хәлгә килгәндә, ул кантарлы юл буйлап доңгырдап тәгәрәгән арба өстендә сузылып ята иде.

Икенчеме, өченчеме көнне белде Гази: Кара Гайнетдин өенә җыелган банда җитәкчеләренең берсен генә дә кулга төшерә алмаганнар. Атлары да Гыймади бай абзарында түгел, су буе үзәнлегендәге рига бөркәве астында калдырылган булган. Бер Гыйззәт хәзрәтне генә, тикшерүчеләргә чакыртып, авыл белән район үзәге арасын таптаталар ди.

Газиның авыр наган сабы белән сугып ярылган маңгае шактый вакыт җөйләнмичә газаплады. Ялганган җөе дә, мәңгелеккә салынган мөһер сыман, бик мәзәк булып калды: кыл урталай бүленгән уң кашының кыйгачланып килгән өлеше, нәкъ кош канаты кебек, өскә чөелде, икенче өлеше, кемгәдер күз кысканга охшап, борынына таба тартылып тора иде. Егетебезгә «Тамгалы Гази» дигән кушамат та тагылды.

Аның каравы авыл яшьләре арасында Газиның дан-шөһрәте бермәбер артты. Өерләре белән җыелган бандитларның өннәренә басып кереп кара әле син, уен эшмени! Бер Бәһрам абзые гына хуп күрмәде аның бу

адымын: «Бизбашка икәнсең! Шул да булдымы егетлек... Үтереп китсәләр шунда...» — дип чынлап торып әрләде. Аннары: булмый икән синең белән, дигән кебек, шул ук көзне Газины Казанга укырга җибәрде. «Башын кая илтеп орырга белмәгән кеше сыман җил куып йөрмә әле, Гази энем,— диде ул.— Җан дустым Хаҗиның балалары турында мин дә кайгыртмасам, кем кайгыртсын ди...»

Казан медицина институты студенты булгалаганчы, әзерлек курсларына йөреп, рабфакта укып, ике-өч ел чамасы вакытның үтеп киткәне сизелмичә дә калды. Ә замана берни белән дә санашмыйча ага торды, берәүләр өскә калыкты, икенчеләре төпкә китеп юк булды. Кадыйр Надыйров, мәсәлән, еракларда күренерлек булып, дулкыннарның бик биекләренә күтәрелде, район Советы башкарма комитетына бүлек мөдире итеп эшкә алынды. Аның туганнан туган Илшат абые кыска гына вакыт эчендә колхоз председательлегенә сайланды.

...Кеше гомере — бер бөтен, диләр. Кемнәргәдер бәлки шулайдыр. Әмма Гази еш кына инде дүрт-биш кеше гомерен кичергәндәй тоя иде үзен. Бер гомере — балачагы, яшьлеге. Ятимлектә, ачлы-туклы үзса да, язгы таң кебек якты, сагышлы төш кебек татлы, моңлы җыр кебек матур булды аның яшьлеге. Бик яшьли, азларның гына бәхетенә тия торган чын мәхәббәтне белде, аның назын татыды, газапларын кичерде. Гомеренең иң бәхетле, берни белән дә чагыштыргысыз гүзәл, керсез, гамьсез мизгелләре шул еллар булгандыр, мөгаен. Тикмәгә генә яшьлектә һәр айның утыз көне утыз төрле дип әйтмәгәннәрдер. Шуңа күрә дә Газиның үзе бер гомергә тиң яшьлеге якты бер истәлек, чын ядкарь булып хәтеренә инде дә калды.

Аннары инде беренче һәм соңгы мәхәббәтен югалту ачысы... Казан каласы. Яңа тормыш, яңа дуслар. Алай итәм дә болай итәм дип хыяллану, үсеш-омтылыш еллары. Болары инде икенче бер гомер...

Һәм, ниһаять, бөтен дөньяны кара сугыш сөреме каплаган заман... Газиның да әсирлектә калып, фашизм афәтенең бөтен авырлыгын, тоткын кичерергә тиешле барлык газабын, ачысын, мәсхәрәсен, нәләтен, каһәрен күреп, нацистларның ерткычларча җәзалауларын татып — фашизмның мең төрле үлем «тегермәннәре» аша үтеп, исән калу еллары... Монысы да гомер дип атала. Аерма тик шунда, берничә кешегә бүлеп бирсәң дә, бик таманга килерлек гомер иде анысы. Бәлки шуңа күрәдер, географияне дә Гази бөтен Европаны биләп алган концентрацион лагерьлар, халыкны күпләп юк итү геттолары, җәзалау камералары, төрле илләрнең, төрле милләтләрнең хәрби тоткыннары күмелгән туганлык каберләре аша гына белә кебек...

Газиның тормыш дулкыннары, аямый-нитми, алай да бәрде, болай да сукты. Концентрацион лагерьларның да, төрмәләрнең дә төрлесен күрсәтте. Хәтта кешелек дөньясының хурлыгына — фашизм билгесенә әверелгән Освенцимны да күрергә язган булган икән...

Газига иң әүвәл «Үлем фабрикасы» дип даны чыккан Аушвиц концлагере «могҗизаларын» үз башыннан кичерергә туры килде. Менә кайда булган ул тәмугның тәмугы, җәһәннәмнең төпсез базы. Әле дә булса хәтерендә: лагерь башлыгы эсэсчы җәллад фриц Мэйдэн яңа килгән тоткыннар колоннасын болай дип «тәбрикләп» каршы алган иде: «Алдан ук кисәтеп куюны кирәк дип табам: безнең концлагерьдан чыгу юлы бер — крематорий морҗасы гына». Чыннан да, әлеге «комбинатның» уңлаган мичләре бер генә сәгатькә дә сүнеп тормагандыр. Анда «Фильтрация», «Экзекуция», яки турыдан-туры «төтенизация» дип, көненә берничәшәр йөз кешене юк итеп торалар иде. Шуның өстенә, юри дә төрлечә мыскыллау-түбәнсетүләр, бәрү-сугулар, төрлечә мәсхәрә итүләр, тоткыннарның карга чукырлык итләре калмаса да, этләрен өстереп, әсирләрне талату, кием-салымнарын өзгәләтүләр дисеңме — барысын да үз күзләре белән күрде, үз җаны-тәне белән татыды Гази. Бер сүз белән әйтсәң —

ерткычлык. Житмәсә тагын ачлык, ялангачлык, көч җитмәслек эшләр белән интектерүләр, коточкыч эпидемияләр...

Бер үк вакытта шул кадәресен дә күрде Гази: тоткынлыкның барлык газабын кичергәндә дә, бөтен ачысын татыганда да, әҗәл дигән нәрсә адым калмый үкчәгә басып йөргәндә дә әсирләр явыз, мәкерле дошман алдында баш имәделәр, сынсалар сындылар, әмма бөгелмәделәр, туган ил өчен көрәшкә даими әзер тордылар. Каршылык күрсәтү хәрәкәтендә катнашып, никадәр батырлык, фидакарьлек үрнәкләре күрсәттеләр алар.

Гази җәфаланган ике төрмә, өч концлагерьның, һәркайсында бар иде андый яшерен оешмалар. Концлагерьларның иң мәрхәмәтсезе булган Аушвицта, төрле милләт кешеләре тупланганга мы, әлеге оешма да «Хәрби әсирләрнең сугышчан бердәмлеге» дип атала иде. Гази һичкайчан да андый оешмалардан читтә калмады. Аушвицта да ул тиз арада үз кешегә әверелде, әлеге антифашистик оешманың элемтәчесе булып китте.

Юк, үзе эзләмәде Гази, вакыты җиткәч, күзәтү сынавы аша узгач, яшерен оешма әгъзалары үзләре таптылар аны. Чөнки Гази, дәвалаучы буларак, гадәттә, медпунктка билгеләнә торган иде. Ә медпункт, кагыйдә төсендә, әҗәл мәйданыннан, ягъни барак-блоклардан чак кына читтә, комендатура, каравыл казармалары, административ корпуслар урнашкан җирдә. Газины эшкә коралланган эсэс конвое алып китә иде. Аңынчы инде ирекә чыгарылырга тиешле шифрланган кәгазь кисәге Газига килеп җиткән була иде. Кәгазь бәләкәй генә, андый-мондый шик туа-нитә калса, шундук авызга кабып, йотып җибәрерлек кенә. Порошок салынган нәни кап сыман итеп төрелгән язуны Гази кешегә тапшырмый, дарулар, эреле-ваклы шешәләр, медикамент савытлары тутырылган пыяла ишекле шкафтагы бер тартма эченә сала. Күп тә үтми, кораллы полицай керә, җикеренгәләп, киръәксә-кирәкмәсә дә бәйләнеп, иснәнеп йөри. Шкафны да ачып күздән кичерә. Шул арада кәгазь дә юкка чыга.

Тагын бер хәл сәер булып тоелды Газига: беркайчан да аңардан җавап таләп итмәделәр. Бу эш бүтән канал буенча, башка кеше тарафыннан башкарылгандыр, мөгаен. Конспирация дигән нәрсәнең катгый законнары шуны таләп иткәндер, күрәсең.

Концлагерьда кешене исем-фамилиясе белән атау юк, берәр кушамат яки алдан-арттан киеменә сугылган сан белән атап йөртәләр. Газига да, эш урынында гел халат белән күренгәнгәме, «Фәрештә» дигән кушамат тактылар.

Көннәрнең берендә концлагерьның комендатурасы, каравыл казармалары урнашкан яктан төннең-төн буе күңелле музыка, шул музыкага кушылып гөр килеп җырлашу тавышы ишетелеп торды. Әсирләр: фронтта ул-бу булдымы икән әллә, шул уңай белән бәйрәм итәләрме? дип, бераз пошаманга да төшкәннәр иде. Әмма иртәгәсен «чыбыксыз телеграф» аша алынган хәбәр сәгате-минуты белән барын да ачыклады: Берлинның үзеннән олуг кунак килгән. Информация шулкадәр төгәл иде ки, кунакның кем булуы гына түгел, чин-дәрәҗәсе дә, нинди йомыш белән йөргәнлеге дә билгеле булды. «Кунак» — ата нацист, империянең иминлек баш идарәсе өлкән киңәшчесе рейхскомиссар обергруппенфюрер Отто Шульц иде. Йомышы да билгеле: Гиммлерның практик күрсәтмәсен алып килгән. Моннан ары берьюлы меңәрләп җәзалап үтерелгән тоткыннарның гәүдәләрен яндырмыйча күмү катгый рәвештә тыелачак икән. Моңарчы күмелгәннәрен дә казып алып яндырачаклар ди. Моның өчен лагерьда өстәмә рәвештә тагын берничә йөз кешедән торган махсус зондеркомандалар төзеләчәк икән. Димәк, кешелекнең иң явыз, иң вәхши дошманы фашизм да җинаятъ эзләрен юк итүне кайгырта башларга мәҗбүр. Димәк, сәбәпләре бар...

Икенче көнне дә шул ук хәл: әсирләр, эштән эт булып арыпалҗып кайтып, ятакларына аварга да өлгермәделәр, яңадан бөтен лагерь эчендә шау-шу купты. Тоткыннарның күңелләренә мең төрле шом салып, берсеннән-берсе яманрак уйлар кузгатып, тревога сиренасы үкерә башлады. Нәрсә бу? Союзниклар авиациясе һөҗүм иттеме әллә? Бәлки, парти-

заннар һөҗүм ясаганнардыр? Шау-шу торган саен көчәя барды. Яңадан этләр өрде. Әҗәл мәйданы апель-плацның таш җәйгән юлларыннан, дагаланган аяк киекнәре белән дөпе-дөпе басып, кемнәрдер йөгерештеләр. Сирена үкерепме үкерде. Көчле прожекторлар яктылыгы, барак тәрәзәләре аша үтеп, сәндерә-сәкеләрне ялмап-айкап үтте.

Шулчак, яман дөбердәп, барак ишеге ачылып китте. Аннан, кулларына автоматлар тоткан, өч-дүрт эсэсчы атылып керде. Туп-туры Гази белән аның ярдәмчесе поляк яткан агач сәндерә янына йөгерешеп килделәр. Килделәр дә, ут капкан диярсең, секунд эчендә киенергә куштылар. «Димәк, эзгә төшкәннәр... Бетүем шушы икән»,— дигән уй өтәләп алды Газиның миен. Шундук: «Ә полякның ни катнашы бар, ул бит минем яшерен оешма элемтәчесе икәнлегемне белми»,— дигән икенче бер уй да чагылып үтте.

Чыгып китәр алдыннан икешәр катлы ятаклар арасыннан кемдер: «Фәрештә», үзеңне сакла... кирәклегеңне онытма!» — дип хәбәр салды. Тавыш бик таныш иде. Ул арада конвойчыларның берсе, шул якка ыргылып, автоматы түтәсе белән кемнедер акыртып дөмбәсли башлады.

Ишегалларын, блоклар арасын йөгереп кенә үттеләр. Медпунктка барып җиттеләр. Бары тик шунда гына барысы да ачыкланды: рейхскомиссар лагерьдан көндезге ашлардан соң гына китеп барган. Әмма, ерак элдертә алмаган — лагерьдан ике йөз километрлар чамасы ераклыктагы таулы урманнарга җитәрәк партизаннар засадасына эләккән. Атышлар әллә ни озак дәвам итмәгән, эсэсчылар, ике автомашиналарын калдырып, кире борылырга мәҗбүр булганнар. Шунда җәллад рейхскомиссар да яраланган. Атыш вакытында лагерь хезмәткәрләренә хезмәт күрсәтүче баш врач та үтерелгән. Газиларны шул обергруппенфюрер Отто Шульцка операция ясарга дип чакырганнар икән...

Гази операция ясарга әзерләнә башлады. Һәр адымы санаулы, һәр хәрәкәте күзәтү астында. Ниһаять, Гази ике ут арасында. Инде нишләп карарга? Юк, үлем куркытмый иде аны, кеше канына баткан әлеге вәхши җәлладны дөмектерү өчен гомерне бирү дә кызганыч түгел. Моны һәрбер патриот бәхеткә санар иде. Җәзасын татыту да әллә ни кыен булмаячак, тиздән, бик тиздән Гази кулында яшендәй уйнап-елкылдап торган скальпель булачак...

Әмма ул — элемтәче дә. Баягы таныш тавыш та тикмәгә генә кисәтмәгәндер аны... Чыннан да, ничәмә-ничә ил вәкилләренең күзе аңа төбәлгән. Кем белә, бәлки ул бүгенге көндә тышкы дөньяга берләнбер каналдыр? Шул элемтә дә өзелсә, нишләрләр?..

Ул арада бер төркем офицерлар, як-ягыннан тотып, яраланган обергруппенфюрерны алып кереп, операция өсталенә салдылар. Газига тиз генә яраны карарга һәм кичекмәстән ярдәм итәргә куштылар. Аларга ап-ак халатлар киеп алган ике ханым да ияргән. Операция алар күзәтчелеге астында үтәчәк икән. Берсен таныды Гази: Эльза Кох. Концлагерь персоналларына медицина хезмәте күрсәтүче фельдшер. Берничә тапкыр вак-төяк йомыш белән медпунктка да кергәләгәне бар.

Гази өстәл янына килде. Шуны гына көтеп торган диярсең, офицерларның берсе, кобурасын чишеп, парабеллумын чыгарды да: «Андыймондый хәл була-нитә калса, икегез дә шушы урында шушы ук секундта юк ителәсез»,— дип янап-кисәтеп тә куйды.

Гази операциягә керешге. Поляк та үз урынына, өстәл янына басты. Өлкән киңәшченең ярасы әллә ни хәтәр түгел, партизан пулясы Отто Шульцның умырау сөягенә барып эләккән булырга тиеш. Гази, житезҗәһәт хәрәкәт ясап, скальпель белән иң әүвәл җилкә мускулын ярып җибәрде. Канны туктату чараларын күрде. Ниһаять, пуляны тапты. Бары тик шуннан соң гына, җәлладны акыртып-бакыртып, пинцет ярдәмендә пуляны каерып чыгарды. Аның һәрбер хәрәкәтен тын да алмый күзәтеп торган офицерларга «партизан бүләген» күрсәтте дә шалтыратып идәндәге ләгәнгә ташлады...

Баракка кайткач, Гази, төн дип тормады, тиешле кешегә булган хәлне бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Яшерен оешманың катгый карарын көтте. Иртәгесен эшкә киткәнче үк ишеттерделәр: «Фәрештә» дөрес иткән, безнең өчен «тышкы дөнья» белән элемтә бар нәрсәдән дә кыйммәтрәк хәзер. Ә обергруппенфюрер әллә ни ерак китә алмас, үз җәзасын барыбер алыр...

Ике атна үттеме икән, көннәрнең берендә Газиның эш урынына яңадан ике эсэсчы керде. Аны яңадан үзләренә ияртеп алып чыгып киттеләр. Ни күрсен, иреккә алып чыга торган зур тимер капка ягына таба алып киттеләр үзен. Менә түбәләренә зур-зур прожекторлар беркетелгән, тәрәзәләреннән пулемет көпшәләре тырпаеп торган ике манара уртасына урнашкан проходной янына җиттеләр. Ике-өч пост аша узгач, ниһаять, нейтраль зонага чыктылар. Чәнечкеле тимер чыбыклар белән уратып алынган тәмуг артта калды. Яа-а, хода! Төшме бу өнме? Монда бөтенләй икенче дөнья. Һавасына кадәр үзгә. Саф-саф агачлар утыртылган. Юлларга сары ком сибелгән. Түтәлләрдә гөлләр чәчәк ата, уртада — зәвык белән бизәлгән түгәрәк клумба. Гази янә аптыраште: кая алып баралар аны?..

Бераздан инде ул, крематорий морҗаларыннан чыккан кара-кучкыл төтенгә күрсәтеп, кайчандыр бу лагерьдан чыгу юлы бер генә дип кисәткән эсэсчы җәллад Фриц Мэндэн кабинетында иде. Зур зал сыман бүлмәдә, концлагерь хуҗасыннан тыш, тагын берничә югары дәрәҗәле офицер бар. Шундук таныды Гази, ул операция ясаган рейхскомиссар да бүлмәдә иде. Сул кулы кара тасма белән муенына асылган. «Коткаручымны күрсәтегез»,— дип, ул чакырткан булган икән. Авызын ерып, Гази янына килде. Кочакларга җыенган сыман итеп, сау кулын коткаручысының җилкәсенә салды, үзенең рәхмәтен белдерде. Башкалар да шат, көлешәләр, рус хирургын мактыйлар. Шундук фотограф бөтерелә, обергруппенфюрерга нәрсәдер әйтә, кочакларга куша булса кирәк, үзе маймыл житезлеге белән өстәлгә сикереп менеп тә, идәнгә кырын ятып та, аппаратыннан ялт та йолт китереп, ялкын көлтәләре очыртып, карточкага төшерә. Фотограф җитез хәрәкәтләре белән генә түгел, кашларына кадәр төшереп үстергән җирән чәче, эрекмән яфрагы чаклы зур колаклары, кызгылт-көрән төстәге кысан киемнәре белән дә маймылны хәтерләтә иде.

Газины озак тоткарламадылар. Империянең иминлек баш идарәсе өлкән киңәшчесе аны залның бер ягында әзерләнгән бәйрәмчә табын янына алып килде. Елкылдап торган ике бәллүр стаканга шнапс койды, чәкешергә ишарә ясап, үзенекен кулына алды. Әмма Гази эчүдән баш тартты. Аны кыстамадылар. Кулына тегермән ташыдай зур гына икмәк, бер кило чамасы ветчина, өч-дүрт плитка шоколад тоттырдылар да яңадан эш урынына — медпунктка кадәр озатып куйдылар.

Ләкин рейхскомиссарга бәйле хәлләр моның белән чикләнмәде. Көннәр көзгә таба авышкач, тагын бер вакыйгага булып алды. Концлагерьның яшерен оешмасы тарафыннан шифрлап язылган кәгазьне алырга кергән полицай, Гази алдына бер журнал китереп куйды. Берни дә аңламыйча торган докторның: «Бу ни?..» дигән соравына каршы, бары тик бер авыз сүз әйтте: «Бу журнал ярдәм дә итәр, вакытына карап, башыңа да җитәр...»

Гази әлеге сәер сүзләрнең мәгънәсенә төшенергә теләгәндәй, дәреслек форматындагы, әллә ни калын булмаган басманы кулына алды. Караштыра башлады. Урта бер җирдә, тулы бер биткә урнаштырылган фоторәсемне күреп катты да калды. Фотода әлеге җәллад... Башында биек кокардалы фуражка, күкрәге төрле зурлыктагы, төрле металлдан коелган тәреләр, тагын әллә ниткән елтыр орденнар белән бизәлгән. Рейхскомиссар Газины бөтенләй «үз итеп» кочагына алган сыман, берьюлы утыз алты тешен ыржайтып көлеп тора. Рәсем астында мондыйрак сүзләр: «Империянең иминлек баш идарәсе баш киңәшчесе обергруппенфюрер Отто

Шульц үзен үлемнән коткарып калган «Фәрештә» кушаматлы хәрби әсиргә — совет хирургына үзенең рәхмәтен белдерә».

Гази: «Эшләр менә кая таба киткән икән»,— дип, журналны да идәнасты төркеме җитәкчеләренә җибәрде. Алынган җавап янә ул кадәр хәвефләнерлек түгел иде: «Фәрештә» юкка борчылмасын, заманы шундый. Аның интернациональ Берләшмәгә күрсәткән хезмәтләрен Ватан һичкайчан да онытмас...

Юк, баш авыртканда бирелә торган дару да, сәлам хаты да•булмаган Гази тарафыннан ирекка юлланган кәгазь кисәкләре. Көннәрнең берендә, бөтен концлагерь территориясендә сәер тынлык урнашты. Мондый тынлык, гадәттә, яман давыл яки гарасат алдыннан була.

Ялгышмаган Гази: «Әзер торыгыз... бүген төнлә күтәреләбез...» — дигән хәбәр алар барагына да килеп житте. Чыннан да, төн урталарында, дөньяның кинәт асты өскә килгән сыман булды. Ут чыккан диярсең инде менә. Өзек-өзек итеп, өннәргә шом салып, тревога сиренасы үкерергә кереште. Тынуны белмичә үкерде ул. Аңа этләр өргән, кемнәрнеңдер яман кычкырып команда биргән тавышлары ишетелде. Мылтыклардан, пулеметлардан аткан тавышлар һаваны ярды. Аларга автомат тавышлары кушылды. Ул да түгел, гөрселдәп миналар, гранаталар шартлады.

Шул вакыт, тупсаларыннан очып төшәрдәй булып, шаулап, барак ишеге ачылып китте.

— Иптәшләр! Кузгалыгыз!.. Барыгыз да апель-плацка!.. Партизаннар налеты башланды... Комендатураны штурмлыйлар... Безне ирек көтә... Үлем ерткыч фашистларга! Алга, иптәшләр!..— дигән тавыш яңгырады. Тоткыннарны җил тузгыттымыни, дәррәү аякланып, ишеккә ташландылар.

Барактан атылып чыккан шәйдә чак кына каушап-югалып калган сыман булды Гази. Тирә-юньдә чын мәгънәсендә сугыш бара иде. Атышлар да кызганнан-кыза. Әледән-әле гранаталар, миналар шартлый. Апель-плац, нәкъ көндезге кебек, яп-якты. Көчле прожекторларның күзләрне камаштырырлык яктысы тирә-юньне айкапмы айкый. Һавага әледән-әле төсле ракеталар оча... Күпмедер күтәрелгәч, хәлләре беткән сыман, бер урында асылынып торалар... Шуның өстенә тагын, берничә урында яман ялкынланып, бензин сибеп ут төрткәнгә охшап, сак манаралары яна...

Нәкъ шул вакытта каравыл казармалары ягыннан көчле «ур-ра!» тавышлары яңгырады. Бу — баш күтәргән тоткыннар иде. Гази өчен тагын табышмак: күрче зинһар, әсирләрнең кораллары булган лабаса! Кайдан алганнар да кайда саклаганнар диген син аларны.

Шулчак концлагерьның штраф бараклары ягыннан да «Ур-ра!» тавышлары ишетелде. Димәк, «үлем комбинаты» партизаннар тарафыннан төрле яктан камап алынган булган. Шуннан соң атышлар чак кына тына төшкән кебек булды. Гази, кирәгем булыр дип, медпункт урнашкан корпуслар ягына йөгерде. Комендатура биналары, проходнойлар тирәсендә әле һаман да атышлар бара иде. Гази медпунктка керде. Эленеп торган сумкасын алып, иң элек кул астына эләккән кайбер хирургия инструментларын, һәрчак кирәк булачак медикаментларны җыя башлады. Тагын нидер эшлисе бар кебек тоелды аңа, әмма хәтеренә төшерә алмады. Ул арада агач бинаның баш-башыннан дөрләп килгән янгынның төтене бүлмә эченә тула башлады.

Гази тышка ыргылды. Ул баскыч төбенә чыкканда, атышлар тынган. Шулай да сирәк-мирәк көчле гөрселдәү тавышлары әледән-әле һаваны яра тора. Төшендә Гази, партизаннар крематорий мичләрен, ягулык хәзинәсен, баракларны шартлаталар икән. Тирә-юньдә бөтен дөньяны ялт иттереп, ялкын үкерә: агач барак-блоклар, тагын ниндидер корылмалар, сак манаралары яна.

Гаять зур мәйданны биләп торган апель-плац гөр килә. Халык белән шыгрым тулы ул. Анда митинг бара. Әледән-әле көчле ур-ра тавышлары яңгырый.

Гази да шул якка йөгерде. Ораторның соңгы сүзләре анын да колагына чагылып үтте.

— Сез азат, иптәшләр! Җегәре булганнар кулларына корал алсыннар... Ә инде партизаннар берләшмәсенә ияреп китәргә хәле житмәгән яралыларны, авыруларны лагерьның тышкы ягында олаулар көтә... Тагын бер үтенеч: бу тирәдән мөмкин кадәр ераграк китәргә тырышыгыз. Аерым-аерым да, зур булмаган төркемнәргә бүленеп тә таралыша башлагыз, иптәшләр. Кай якка гына юл тотсагыз да, авыллар тирәсенә барып чыгарга тырышыгыз. Кем икәнлегегезне белгәч, ярдәм кулы сузмый калмаслар. Тик үзәк магистральләрдән, олы юллардан читтәрәк булырга тырышыгыз. Ашыгыгыз, иптәшләр!.. Карательләр дә, эсэсчылар, патрульләр дә озак көттермәс...

Гази да, халык ташкынына ияреп, җимерелеп-каерылып ташланган иләмсез капка ягына юнәлде. Лагерьның тышкы ягында, комендатура корпуслары каршында мәхшәр: ыгы-зыгы, шау-шу, һаваны ярып төрле әмерләр яңгырый, атлар кешни... Килеп тыгылган олауларның да исәбе-хисабы юк. Партизаннарның күпчелеге эш белән мәшгуль. Бер якта каравыл казармалары турысында, чаналарга төрле калибрлы пулеметлар, автоматлар, башка төрле сугыш кирәк-яраклары төйиләр. Икенче бер урында тезелешеп торган олауларга кием-салым, азык-төлек ташыйлар. Һәркайда кызу эш кайный.

Көчле итеп ныгытылган лагерьны штурмлау шактый авыр, бәрелеш дәһшәтле булган ахрысы. Носилкалар белән дә, болай култыклап алып та яралыларны ташыйлар. Гази шул якка юл тотты. Әллә ни ерак барырга туры килмәде, комендатура корпусы каршындагы зур гына мәйданның бер читендә, ике-өч палатканы абайлап алды, яралыларны шунда туплыйлар икән. Мәйдан кырыенда торган юан гына каусәле бер агачка, кызыл хач белән ярым ай эмблемасы төшерелгән ак флаг кадаклап куелган.

Гази яралыларга ярдәм итү пункты янында әллә ни озак юанмады. Беренче ярдәм күрсәтелгән яралыларны олауларга утыртып озатып торучы фельдшерларга ярдәм итеп торды ул. Шулчак яралылар тезелешеп яткан олаулар янына тыны-көне беткән бер яшь кенә партизан йөгереп килде.

— Федорович!.. Бәла анда... «Батя» яраланган. Ярасы җитди булса кирәк... Хирург эзлиләр...

Бу хәбәр яшен суккандай тәэсир итте сакаллы фельдшерга.

— Кайда?.. «Батя» кайда дип сорыйм бит мин синнән...

— Комендатурада...

Бәлки минем дә ярдәмем кирәк булыр дип, Гази да, кабалана-кабалана Федорович белән янәшә атлаган партизанга иярде.

Гази комендатурага керү белән таныды: концлагерь шефы эсэсчы Фриц Мендэн кабинеты иде бу. Бернчә урында төрле төстәге юан шәмнәр яна. Түрдәге тимер рәшәткәле тәрәзә буенда, кара төстәге олы күн диван өстендә, яралы ята. Аны партизаннар чолгап алган. Киемнәренә, үз-үзләрен тотуларына карагaнда, берләшмә командирлары, комиссарлары булырга тиешләр.

Сакаллы фельдшер, терекөмеш йоткан сыман хәрәкәтчел партизан, аларга ияргән Гази кергәч, игътибар аларга күчте. Шулчак Федоровичны җилтерәтеп, кичекмәстән кемнедер табарга, ниндидер кичектергесез чаралар күрергә куштылар. Сакалбатыр үзенең тәмам аптырашта калуын белдерергә теләптер инде, җилкәләрен җыерып, кулларын гына җәяргә мәҗбүр булды.

Нәкъ шул вакыт, лагерь киемнәре өстеннән өр-яңа кыска тун киеп алган кеше, төркемнән аерылып, Гази янына килде.

— Менә сез кайда икән?! — дип, күптәнге танышын очраткан кеше сыман, Газиның кулын кысты. — Әйдәгез, танышып алыйк булмаса. Кызыл Армия полковнигы Кутырев. Ниһаять, менә якыннан таныштык. Әйтергә

теләгән сүзем шул: рәхмәт, иптәш!.. Барысы өчен дә рәхмәт Сезгә! Тоткыннарның бик тә яман, ифрат та авыр хәлен аз гына булса да җиңеләйтү өчен күп тырыштыгыз, зур көч куйдыгыз. Бу турыда ил онытмас...

Гази полковник Кутыревның «Хәрби әсирләрнең сугышчан Берләшмәсе» җитәкчеләренең берсе икәнлегенә шундук төшенде, әмма авыз ачып бер сүз дә әйтергә өлгерә алмыйча калды. Кызыл Армия полковнигы бөтенесенә дә берьюлы мөрәҗәгать итеп, болай диде:

— Менә, иптәшләр, таныш булыгыз, безнең беренче номерлы элемтәчебез. Шуның өстенә әле ул, нәкъ сез эзләгән, сезгә кирәкле кеше — хирург. Кирилл Павловичка да бердәнбер ярдәм итәр кеше шулдыр, минемчә. Куллары шифалы булырга тиеш. Кушаматы да «Фәрештә» аның...

Газига яралыны карарга куштылар. Аңа шәмнәр, кесә фонарьләре белән яктыртып тордылар. Яра җитди, кыр шартларында гына операция ясарлык түгел иде. Минамы, гранатамы ярчыгы ашказаны турысын тишеп үткән. Яра тирәнме, юкмы? Ярчык кай тирәдәрәк? Болай гына, рентгенсыз яки ачып карамыйча, белерлек түгел иде. Гази үз фикерен ачыктан-ачык әйтте. Яралыны бу хәлендә бер урыннан икенче урынга күчереп йөртү дә авыру файдасына түгел диде.

Шундук фикер алышу башланды. Яралыны партизаннарның моннан йөз илле, йөз алтмыш чакрым ераклыктагы төп базаларына алып кайту турында сүз булуы да мөмкин түгел иде. Алайса нишләп карарга? Бәлки шушында, комендатура бүлмәләренең берәрсендә генә ясаргадыр? Юк, бу да котылу юлы түгел иде. Беренчедән, катлаулы операция үткәрү өчен шартлар тудырып булмаячак. Икенчедән, концлагерь белән элемтә өзелүдән шикләнгән эсэсчыларның патрульләре, ике-өч сәгать тә үтми, килеп җитүләре бар... Дөрес, лагерь каравылына ярдәм тиз генә килеп җитмәсен өчен, тиешле чаралар күрелгән: элемтә сафтан чыгарылган, бу төбәккә салынган олы юлларның күперләре шартлатылган...

Ахыр чиктә концлагерьдан нибары утыз-утыз биш чакрым гына ераклыкта урнашкан, партизаннар үзләре генә белә торган урман кардонына юл тотарга дигән карарга килделәр. Бераздан инде алар, яралыны печән түшәлгән чанага һәйбәтләп сузып салып, җил уйнатып, иге-чиге күренмәгән басулар киңлеге буйлап элдертәләр иде. Алда да, артта да тагын атлылар. Аларында автоматлар, пулеметлар белән коралланган партизаннар бара. Озата килүләредер дигән нәтиҗә ясады Гази.

Алар бер чанада дүртәү. Яралы, аның янында ак тунлы, йонлач бүрекле комбат. Дилбегә фельдшер Федорович кулында. Яралының аяк очында, шинель өстенә тагын бер шинель киеп алган Гази.

Гази, теләсә-теләмәсә дә, яралы белән комбатның үзара гәпләшүенә игътибар итте.

— Я-ә, комбат...— диде яралы, шактый ук нык тавыш белән.— Югалтулар зурмы?..

— Кирилл Павлович... Сезгә хәзергә сөйләшү авырдыр. Барысы турында да соңрак...

Авыру үзсүзләнүен белде.

— Ә син сорауга җавап бирә торган бул...

Комбат буйсынды.

— Бар, Кирилл Павлович. Әмма зур түгел...

— Тоткыннар нинди хәлдә иде? Бик бетешмәгәннәрме?

— Төрлесе бар. Кулларына корал алып, шундук безнең сафларга кушылучылар да булды. Арада, әлбәттә, бөтенләй кешелектән чыгарылганнары да җитәрлек иде. Штраф баракларыннан яндырыр өчен әзерләнгән йөздән артык әсирне коткардык... Күтәреп алып чыгарга туры килде.

— Аларны нишләтергә булдыгыз?

— Кием-салым өләштек. Төрле базаларга алып китәчәкләр үзләрен. Күп булмаса да, транспорт кулга төшерелде: дүрт автомашина, унлап

мотоцикл... Лагерь тирәсеннән тизрәк эзне суыткалаганчы, аларны да файдаланырга булдылар. Ягулыклары беткәч, берәр җиргә мәтәлдерерләр үзләрен...

— Ә арсенал?..

— Кораллар мул булды. Сугыш кирәк-ярагы да җитәрлек алынды... Кирәкмәгәннәре юк ителде.

Таң атып, күктәге каурый болыт итәкләренә ут капканда, алар инде кеше үтеп керә алмаслык тоташ кара урман эчендә урнашкан, өчдүрт кенә йортлы кардонга килеп җиткәннәр иде. Операция бик уңышлы үтте. Яралының бәхетенә, эчке органнар артык зарарланмаган. Шулай да кырык сантиметр чамасы эчәгене кисеп алырга туры килде. Партизаннар шатлыкларыннан нишләргә дә белмәделәр. Сакалбай Федорович, рәхмәт йөзеннәндер инде, «Батя»ның кем булуын да чиште. Гази операция ясаган кеше Белоруссия Коммунистлар партиясенең Барановичи-Коссово партизан отрядлары берләшмәсенең командиры, Өлкә комитеты секретаре Кирилл Павлович Алидюк булып чыкты.

Комбат белән фельдшер Федорович яралы янында кардонда калды. Гази «Батя»ны озата килгән партизаннар белән аларның базасына китте. Исән калуым, котылуым шушы икән дип сөенеп бетә алмады ул. Әмма отрядта «Батя»га операция ясаган кеше төсендә кадер-хөрмәт казанып, әллә ни озак яшәргә туры килмәде Газига. Концлагерьны пыран-заран китереп тузгытканнан соң атна-ун көн үттеме икән, берләшмә разведкасы берсеннән-берсе яманрак хәбәрләр алып кайтты. Партизаннарның Гази килеп урнашкан «Н» төркеме һәрьяктан диярлек карательләр һәм эсэсчылар белән камап алынган. Партизаннарны юк итү операциясенә регуляр гаскәри частьлар тартылган. Анда пехотадан тыш, танклар белән самолетлар да катнашачак ди.

Алынган мәгълүматлар дөрес булып чыкты. Иң элек урман өстендә дошманның разведка самолетлары күренде. Түбәннән генә, агач башларына тияр-тимәс кенә очып уздылар алар. «Каршылык күрсәтү файдасыз, командирларыгыз белән большевикларны юк итегез дә бирелегез! Исән-имин калуыгыз гарантияләнә»,— дигән листовкалар ташладылар.

Бераздан урман эче яңадан гөрелте белән тулды. Болары инде бомбардировщиклар. Кинәт кояш яктысы күренмәс булды, тирә-юнь мәхшәргә әверелде. Бомбалар шартлаудан җирнең асты-өскә килде... Утытөтене, ялкыны-сөреме — бар да бергә аралашты...

Яралыларны кайчандыр штаб вазифасын үтәгән зур гына землянкага ташыдылар. Гази да, отрядның фельдшерлары, санитарлары белән бергә, яраларны бәйләде, башка төрле ярдәмнәр күрсәтте. Землянкада булсалар да, канкойгыч сугышның торган саен якынаюын, кызганнан-кыза баруын тойдылар. Яралылар да ишәйде, ярдәм күрсәтеп өлгерә алмый башладылар.

Дошман олы калибрлы минометлардан ут ачты булса кирәк, якында гына миналар ярылудан землянка тетрәп торды, яралылар өстенә төшәмнән мул булып туфрак коела башлады.

Атышлар тагын да якыная төште. Шулчак землянкага бер партизан атылып керәп:

— Иптәшләр!.. Чигенергә мәҗбүрбез...— дип өн салды.

Гази яңадан аптырашта калды: Нишләргә? Врач була торып, ул да партизаннарга ияреп чигенсә, бу яралылар нишләр? Мондый уйның икенче тапкыр тууы иде инде. Дөрес, монда калган тәкъдирдә дә, әллә ни кыра алмаячагын яхшы төшенде ул. Фашистлар яралы дип тормаячаклар, барыбер вәхшилекләрен итәчәкләр...

Ул арада атышлар чак кына тына төште. Шуны гына көтеп торгандай, якында гына этләр өргән тавышлар ишетелде. Димәк, дошман борын төбендә генә...

Гази землянканың түрге өлешендә яткан яралы янына килде. Җәрәхәте тирән, исән калуы икеле. Ул якынайганда, тап-таза яшь егетнең

башы кырыйга янтаеп төшкән, сулыш алуы туктаган иде инде. Бая иптәшләре күтәреп кертеп салгач, яралының күкрәген ачар өчен, Гази иң әүвәл аның наган тагылган киң каешын ычкындырып, коралын баш очына алып куйган иде. Хәзер ул шул коралны үз кулына алды. Ул арада землянка тирәсендә ыгы-зыгы купты, фашистларның үзләренчә кычкырып сөйләшүләре ишетелде. Нәкъ шул вакыт, автоматын алга таба сузып, нидер кычкырынып-җикеренеп, землянкага бер немец бәреп керде. Гази төзәп-нитеп тормады, атты... Фашист, ишек катында яткан яралыларга сөртенгән сыман, алга таба йөзтүбән ауды.

Ишектән төшкән яктылыкны томалап, бүселеп, тагын бер эсэсчы килеп керде. Анысы да, биленә тагылган кораллары белән доңгырдап, землянка идәненә ауды.

Әлеге олы гәүдәле немец солдаты артыннан ук, очраган бер кешене өзгәләп ташлардай булып, бозау кадәрле овчарка атылып керде. Аңа атар өчен Газиның пулясы калмаган иде инде. Кирәге калмаган коралын җәһәт кенә читкәрәк шудырды Гази.

Калганы саташулы төш күргән кебек кенә булды. Берьюлы бәреп кергән берничә фашист, халат кигән Газины шәйләп алып, землянкадан чыгарга куштылар. Үзләре дә аңа иярделәр. Яктыга чыккач, күзләре камашудан, берни дә күрми торды Гази, аннары аптырап калды. Землянка урнашкан мәйдан сыман олы аланлык автоматлы немецлар белән уратып алынган. Уртада, кай арада бергә җыеп өлгергәннәрдер, төрле кыяфәттә яралылар аунап ята. Күпчелеге канга баткан, кичекмәстән ярдәм кирәк. Әсир төшкән коралсызландырылган партизаннар да шунда.

Фашистлар, мәйданны бушатырга куштылар. Моның өчен әсир партизаннар, яралыларны землянкага күчерергә тиешләр иде. Башта Гази берни дә аңламыйча торды. Бары тик дошманнарның берсе, танкларга каршы кулланыла торган гранаталар бәйләмен тотып, землянка ишеге янына якынайгач кына нишләргә җыенуларын абайлап алды. Калганы күз ачып йомганчы булды. Землянка торган урын мизгел эчендә ялкын, төтен, тузан болыты эчендә калды. Сөрем чак кына тарала төшкәч күрде Гази: землянка юк, аның урынында гаять зур цурт кырлы чокыр гына ярылып ята иде.

Гази яңадан хәрби әсирләр колоннасында. Кая алып баралар — берәү дә бернәрсә белми. Элгәрege төнне ниндидер ташландык чиркәү ишегалдында, ачык һавада, мул булып яуган кар өстендә уздырдылар. Иртәгесен берничә кеше ауган җирләреннән тора алмады. Хайваннар урынына маңгайларына терәп диярлек атып чыктылар үзләрен. Егерменче гасыр вәхшиләренә карата нәфрәт вулкан сыман кайнаса да, буылып торган ярсу богауларны шартлатып өзәргә сәләтле булса да, түзәсең, соңгы тамчы көчеңне туплап, колоннага килеп басасың, коллык-тоткынлык юлын дәвам итәсең...

Икенче көнне кояш баегач, ниндидер тимер юл станциясендә тоткыннарны пульман вагоннарга тутырдылар. Таракан урынына катып үлмәсеннәр диептер инде, мичкәдәге балык урынына дыңгычлап төяделәр, ятып яки утыру түгел, берьюлы ике аякка басып торырлык та түгел.

Бу җәза ике тәүлек буе дәвам итте. Вагон ишеген дә ачмадылар. Ниһаять, поезд туктады. Ыгы-зыгы, шау-шу тулы шактый зур станция булырга тиеш. Ишек ярыгыннан тышкы якны күзәтүче «хәбәрче» сүзләренә караганда, состав тоташтан коралланган полицайлар белән чолгап алынган. Платформа буйларында этләрен житәкләгән карательләр дә бар...

Ниһаять, дөбердәп ишек ачылды. Җиргә аяк басты юк. Вагонның ачык ишегенә терәлеп үк диярлек, фургонлы автомашиналар килеп туктады. Бер фургонны икенчесе алыштырды. Бер дә игe-чиге юктыр кебек аларның. Ниһаять, Газига да утырыр чират житте. Ул утырган фургонның, ни хикмәттер, түбәсе юк, түбә урынына тимер рәшәткә генә. Бу турыда ул пилоткасын колагына кадәр төшереп кигән, әрәк кебек

арык күршесенә дә әйтте. Юк, зарланудан түгел, болай гына, сүз алышырга теләп кенә әйткән иде. «Юкка хафаланма...— диде тере мәет, телгә килеп.— Аның каравы... Фургонлы машиналар белән киткәннәргә карaганда... берничә сәгатькә соңгарак калып... көлең күккә очар. Фургоннарны танымадыңмыни... душегубкалар иде ич. Аларны... турыдан-туры Освенцимның крематорий мичләренә... озатачаклар...» Фашизмның вәхшилек билгесенә әверелгән «Освенцим» дигән сүзне ишеткәч, тәне эсселесуыклы булып китте Газиның. Анда, хәрби әсирләрне крематорий мичләрендә генә яндырып өлгермәү сәбәпле, меңләгән мәетне берьюлы агач белән аралаштырып штабельләргә өеп яндырулары турында партизаннар отрядында чакта ук ишеткән иде инде ул. Аушвиц концлагере, Освенцим белән чагыштырганда, «кече тәмуг» кына дип сөйләгәннәр иде.

Төн урталары якынлашканда, тиешле урынга килеп тә җиттеләр. Көчле прожекторлар, янып торган учаклар белән яктыртылган мәйданда, ниһаять, каты җиргә аяк бастырдылар. Төн булуга да карамастан, баракише җиргә кертеп тормадылар, олы мәйдан уртасында сафларга тезделәр. Алда да, артта да, унда да, сулда да коралланган солдатлар. Этләрен җитәкләгән карательләр дә, кара күләгәләр сыман, әрле-бирле йөренеп торалар.

Сафта торганда, тирә-юньгә күз салды Гази. «Тере мәет» ялгышмаган икән, як-ягында сак манаралары калкып торган иләмсез зур капкадан кайтып кергән автофургоннар, чыннан да, «пассажир»ларын төшерү өчен, мәйданда туктап-нитеп тормадылар, туп-туры ялкын шәүләсе уйнаган, кара төтен бөркелеп торган якка юл тоттылар...

Шулчак, Газиның уйларын бүлеп, колоннаның аргы башыннан рус телендә боерык яңгырады:

— Аушвиц лагере тоткыннары, өч адым алга! Марш!..

Юк, алга чыгарга атлыгып торучылар табылмады.

Әмма команда бирүченең моңа әллә ни исе китмәде: «Барысы да аңлашылды...» дигән сүзләре генә аермачык булып ишетелеп калды.

Ул арада бер төркем эсэсчылар, кемнедер эзләгәндәй итеп, тезелешеп торган хәрби тоткыннар сафы алдыннан уздылар. Иң алда, якалы шинель, биек кокардалы фуражка кигән офицер атлый. Муенында тәре ялтырый. Погоннары да елкылдап тора. Үз турысына җиткәч, дәрәҗә-чинын да күреп калды Гази: эсэс оберштурмбанфюрере иде. Янәшәсендә фельдполицай атлый.

Тагын күпмедер вакыттан соң кеше кыяфәтендәге шушы вәхшиләр, Газины да, колоннадагы берничә йөз башка кешене дә, тәмуг ялкынына салып, көл итәчәкләр... Нәрсә өчен? Нинди гөнаһлары хакына? Мин дә, нәкъ алар кебек, кеше ләбаса! Ә кешене табигатьнең тажы, табигатьнең алласы диләр. Шулай булгач, нигә дип әле бу вандаллар мине җир йөзеннән юк итәргә тиешләр ди? Башка милләт, башка дин, башка караштa булганым өченме? Нигә дип әле адәм баласы бер-берсенә карата шул кадәр мәрхәмәтсез булырга тиеш ди? Без бит болай да бу дөньяда кунак кына... Һай-й, бу сугышны! Аңардан да яман, аңардан да нәләт төшкере нәрсә юктыр бу җиһанда.

Гази шыксыз кара төтен бөркелгән крематорий торбаларына кабат күз салды. Тагын бер нәрсәгә игътибар итте ул һәм үзенчә нәтиҗә дә ясады. Үлем мәйданына алып керә торган зур бушлыкның як-ягында, тере коридор булып, ике-өч метр саен кораллы эсэсчы тора. Каравыл алынмаган. Тикмәгә түгел бу. Димәк алар колоннасын, алар партиясен сират капкасы аша кертеп җибәргәнне көтәләр. Ә инде «Һәркемгә үзенеке...» дип язып куелган капканың аръягына бер әләктеңме, үзеңне беткәнгә сана. Ни генә кылансаң да, соң булачак...

Әнә эсэс оберштурмбанфюреры үзенең өере белән отыры ерагая бара. Берничә минуттан... Юк, берничә секундтан соң... Газиның гомере өзеләчәк... гомер кояшы сүнәчәк...

Юк, бу мәгънәсез үлем белән килешәсе килмәде аның. Ни диеп әле ул күрәләтә торып үз аяклары белән тәмуг утына керергә тиеш ди?!.

Шунда ул нишләвенә исәп-хисап биреп тормастан, чәчрәп саф алдына бәреп чыкты һәм, җан-фәрман разбой салып, акыра-бакыра башлады: «Миңа оберштурмбанфюрер кирәк... Срочно чакырыгыз!.. Аңа әйтер сүзем бар...»

Бу көтелмәгән хәлдән тирә-юньдәгеләр шашып калды. Әмма озакка түгел. Газидан биш-алты адымда гына торган полицай русча: «Мол-чать, идиот!..» — дип, аның өстенә ташланды һәм автоматы белән бер сугуда юк итәргә теләгәндәй итеп, гөрселдәтеп, Газиның күкрәгенә тондырды. Өнсез булды Гази. Әмма ул барыбер аягында басып калды. Күкрәген тотырып сулыш алды да, киреләнгән кеше сыман, яңадан сөрән салды. Тагын шул ук сүзләрне кабатлады. Шунда, аның авазын туктату нияте беләндер инде, арткы яктан икенче бер каратель килеп, сыңар кулы белән бугазыннан буып алды. Шундый итеп буды, Газиның күз аллары әлҗе-мөлҗеләнә башлады. Ләкин ул бу юлы да югалып калмады, кисәк кенә алга таба иелде дә, буучыны башы аша чөелдереп, асфальтка тондырды. Кемнәндер искәрмәстән генә китереп сылавыннан, үзе дә бер читкә атылып китте. Аның егылуын гына көтеп торганнармыни, дагаланган күн итеге белән типкәли үк башладылар. Гази сикереп торырга теләп, тагын талпынып карады, тик өлгерә алмый калды, тешләрен яман ырҗайткан бозау кадәр овчарканың өстенә ташлануын күреп, куллары-терсәкләре белән йөзен капларга, җиргә иңәргә мәҗбүр булды.

Әмма чак кына хәрәкәт итәргә мөмкинлек туу белән, ул яңадан телгә килде, яңадан бөтен мәйданны яңгыратып берүк сүзләрне тәкрарлый башлады: «Срочно майорны чакырыгыз! Аның үзенә генә әйтәсе сүзем бар... Шулай ук тапшырасы нәрсә дә үзем белән. Менә ул...» — дип, шинеленең уң як күкрәгенә төртеп күрсәтте.

Бу хәл эткә караганда да яманрак котырынган карательләрне чак кына айныткандай итте. Берсе, җәһәт кенә иелеп, Газиның күкрәк тирәсен капшап карады. Кәгазь барын абайлап алгач, янындагыларга нәрсәдер әйтте. Тегеләре дә тынып калдылар. Шундук, җәһәт кенә җирдән күтәреп алдылар да, ике яктан эләктереп, туктап калган эсэсчылар янына алып киттеләр. Майорга рапорт биреп, алдына Газины китереп бастырдылар. Нәрсәдер аңлаттылар. Оберштурмбанфюрерның ризалык биреп ияк кагуын күргән карательләрнең берсе, Газиның эчке кесәсен сүтеп, юешләнеп эштән чыкмасын өчен ялтыравыклы кәгазьгә таслап төреп куйган журналын тартып чыгарды. Кирәкле битен ачарга Гази үзе ярдәм итте. Майорның берни дә аңламыйча торуын күргәч, фоторәсемдәге өлкән советник янында торган халатлы кешене күрсәтеп: «Менә монысы мин...» — дип аңлатып бирергә мәҗбүр булды. Майор кулындагы журналны янында үрә катып торган полицайга сузды. Тегесе, фонарь кабызып, журналның ачылган битен яктыртты да, рәсем астындагы текстны укып, тәрҗемә дә итеп бирде. Журнал яңадан оберштурмбанфюрер кулына күчте. «Бу, чыннан да синме?» — «Күрмисезмени, әлбәттә мин»,— дип җавап кайтарды Гази. Һәм кабат: «Әле дә ярый йөземне саклап яхшы иткәнмен, югыйсә танымаган булырлар иде»,— дип уйлап куйды. Сорау артыннан сорау башланды, җавап бирергә генә өлгер. «Ә ни өчен Аушвицтан качтыгыз?» — «Концлагерь тулысынча тар-мар ителде, таш өстендә таш калмады...» «Партизаннарга ничек барып эләктегез?» — «Кая барырга тиеш идем соң мин?..»

Фашистлар үзара әңгәмә корып алдылар. Ниһаять, майор үзенең соңгы сүзен әйтте. Ике эсэсчы, Газины уртага алдылар да мәйданның сул ягындагы озын баракка таба алып киттеләр. Тар гына тимер капка төбендә торган сакчылар янында туктадылар. Газины шуларга тапшырдылар. Әсирне исән-сау килеш кабул итәргә, кичекмәстән урын күрсәтеп, ашарына бирергә куштылар. Оберштурмбанфюрерның әмере шундый иде дип.

Шул вакыйгадан соң ике-өч көн үттеме икән, Гази эләккән барактагы тоткыннарны каядыр озатырга әзерли башладылар. Өс-башларын алыштырдылар. Көненә бер тапкыр гына булса да кайнар аш бирделәр. Тоткыннарны шулай чиста тотып, туйганчы ашатып, соңыннан яралаңган вермахт офицерларына бирү өчен, тамчысын да калдырмыйча каннарын сыгып ала торган махсус концлагерьлар да барын Гази ишеткән иде инде. Шуңа күрә дә ул бу хәлләрне нәрсә дип юрарга да белмәде.

Нәкъ шул көннәрдә берәү килеп, Газига өмет чаткысы салып, мондыйрак сүзләр пышылдады: «Күлмәк киеп тугансыңдыр син, егет... Болайга киткәч, яшисең икән әле. Сезне эшче батальоннары лагерена озатачаклар. Оҗмах ук түгелдер, билгеле, һәрхәлдә мондагыдай булмас...— Нурсыз йөзенә каткан елмаюлы битен Газига тагын да якынайта төшеп, дәвам итте: — Шулай да әйт әле, нинди могҗизалы көч коткарып кала алды сине?.. Югыйсә, оберштурмбанфюрер Рудольф Шпоннерның моңарчы беркемгә дә мондый мәрхәмәт-шәфкать күрсәткәне юк иде. Әнә синең белән бер партиядә китерелгән хәрби әсирләр, шул ук төнне күккә индeләр...» Нурсыз йөз, чукынып өчен изге сурәт эзләгәндәй, як-ягына каранып алды. Гази бу бәндә турында зондеркомандадандыр яки берәр бандеровчыдыр дип, үзенчә нәтиҗә дә ясаган иде инде. Аның имансыз йөзе, шыксыз елмаюы, шактый вакыт күз алдыннан китмичә газаплаган иде.

Чыннан да, берничә йөз кешедән торган тоткыннарны автомашиналарга төяп тимер юл станциясенә илттеләр. Вагоннарга төяделәр. Аерма тик шунда: бу юлы вагоннарга су баклары куелган, ашарларына да ике-өч көнгә җитәрлек паек биргәннәр иде.

Польша чиге буендагы Плипсе концлагерына күз ачкысыз буранлы көнне барып җиттеләр. Поезд составы лагерь эченә кереп туктаган. Вагоннардан стройга тезелешү өчен сикереп төшүләре булды, өске өлешенә чәнечкеле тимер чыбыклар сузылган иләмсез биек агач койма буенда дарга асып куелган егермедән артык ярым шәрә мәетләрне күреп, аптырап калдылар. Ачы җил исә. Шакырдап каткан мәетләр чайкалып, берберсенә шакы-шокы бәрелгәлиләр. «Менә сиңа җәннәт!» — дип уйлап куйды Гази.

Монда да эсэсчылар, монда да полицайлар. Этләр дә җитәрлек. Озак көттермәделәр, иярченнәре белән уратып алынган комендант күренде. Нотык сөйли башлады. Тылмач русчага сүзен-сүзгә тәрҗемә итеп тора.

— Бөек Германиянең көч-куәтен тагын да арттыру өчен күңел биреп эшлисез икән, тамагыгыз тук, өстегез бөтен, туган илегезгә — якыннарыгыз янына исән-имин кайтуыгыз гарантияләнгән булыр. Ул көнне якынайту тулысынча үзегезгә бәйле: моның өчен яхшы эшләргә генә кирәк. Тиздән, бик тиздән коллар, кимсетелгәннәр иле Россия тулысынча азат ителәчәк. Бөек Германиянең җиңелү белмәс гаскәрләре бернинди каршылыксыз һаман алга бара... Моңарчы динсез большевиклар тарафыннан изелгән барлык халыклар ирек алачак. Бер милләтне икенче милләт изү бетәчәк... Ирек алган һәр милләткә үз телендә сөйләшү, үз динен тоту, үз җирен үзе идарә итү статусы, ягъни аерым штат булып яшәү хокукы биреләчәк. Моны бөек фюрер үзе вәгъдә итә сезгә!..

Лагерь башлыгы әсирләрнең игътибарын дар агачларында асылынып торган мәетләргә күчерде.

— Болар — диверсиядә катнашучылар... ягъни, лагерьның эчке кагыйдәләрен бозучылар. Әмма, монда җәзаланганнарның барысы да җинаятьчеләрдер дигән фикердән ерак торам мин. Бәлки бөтенләй гаепсезләрдер... Чын җинаятьче исән калып, мыек астыннан гына көлеп йөридер. Болар — кою цехын сафтан чыгарып, ягъни, диверсия ясап, безнең эшкә аяк чалырга маташучылар. Кабатлап әйтәм, боларның, бәлки, бөтенләй гаепләре юктыр. Әмма безнең лагерьның эчке кагыйдәләре буенча, җинаять ясалса, аны башкаручы тотып бирелмәсә, диверсия ясалган цехта яки бүлектә эшләүчеләрнең һәр өченчесе үлем җәзасына хөкем ителә. Бу турыда әнә һәр җирдә акка кара белән язып куелган.

Әгәр дә исән-имин туган илегезгә кайтырга телисез икән, эш урыныгызда уяу булыгыз, бер-берегезне күздән яздырмагыз дип кисәтеп куям... Кою цехы әйә яңадан эшли.

Плипсе концентрацион лагерьдан бигрәк зур бер заводны хәтерләтә иде. Монда кою, тимерчелек, механика цехлары, җыю корпусы һәм уннарча мастерскойлар бар. Завод танкларны, зур калибрлы үзйөрешле тупларны төзәтү белән шөгыльләнә. Төзәтеләсе техника яу кырларыннан поездларга төяп кайтарыла. Янган, ярым җимерелгән, тубын яки чылбырын югалткан машиналарның бер дә иге-чиге юктыр кебек. Кайберләренең люклары да ачылмаган була, андыйларда янган мәетләр дә очраштыргалый. Тулы экипажлары белән.

Тагын бер нәрсәгә игътибар итте Гази: монда режим башка концлагерьларныкы белән чагыштырсаң, җир белән күк арасыдай. Эшкә дә, эштән дә конвойсыз йөриләр. Бары тик бараклар янында гына постлар куелган. Анда кемнең кайчан эшкә киткәне, кайтканы исәпкә алына.

Көннәрнең берендә, Гази янына, электросваркада эшләүче бер әсир кереп: «Агай-эне, кул пеште, берәр нәрсә сөрт әле... Бәлки бәйләп үк куярсың?» — дип саф татарча мөрәҗәгать итте.

Бу көтелмәгән хәлдән әллә нишләп китте Гази. Хәтта күңеле тулды кебек. Үзара әңгәмә корып алдылар. Эштән соң ничек тә очрашырга сүз куештылар. Җитмәсә тагын якташлар да булып чыктылар: сваркада эшләүче Сарман ягыннан икән.

Сүзендә торды Гази. Эштән соң санитар сумкасын асты да, бер авыруның җәрәхәтен ашыгыч бәйлисем бар дигән сылтау белән, якташы яшәгән баракка юнәлде. Пешкән кулны һәйбәтләп юып, яңадан бәйләгәнче, ярты сәгать чамасы вакыт узды. Туйганчы гәп саттылар. Сорауларның күбрәген Гази бирде.

Әмма Газига, туганнан да якын, җаннан газиз якташы барлыгын тоеп, озак яшәргә язмаган икән. Көннәрнең берендә ул медпунктка килеп керде дә, мәңгегә бәхилләшкән кебек итеп, Гази белән саубуллаша башлады.

— Менә, нәрсә, кордаш... — диде ул, докторны чынлап торып сагаеп.— Минем белән берәр хәл була-нитә калса, зинһар бердәнбер үтенечне үтә... Ил корткасы әниемә, җәмәгатемә, балаларыма мине кайда, нинди шартларда күргәнлегеңне җиткерә күр... Исән калып, өеңә кайту бәхетенә ирешә алсаң дип әйтүем. — Сарман татары авылын атады, үзенең исем-фамилиясен әйтте. Газиның хәтерендә мәңгегә киртләнеп калсын дигән кебек, кат-кат кабатлады.— Зинһар онытмаска тырыш...

Гази үзен шактый сәер тоткан якташының әлеге сүзләрен уенкөлкегә алырга тырышып карады:

— Юк сүз сөйләмә әле!.. Син нәрсә? Васыять әйткән кебек... Юкка рухыңны да төшермә, өметеңне дә өзмә. Хәзергә һәйбәт кенә эшләп торасың. Өстәмә паек та аласың түгелме соң әле?..

— Юк, кордаш!..— диде якташы. Газиның күңеленә иңә башлаган шомлы сагаюны тагын да көчәйтә төшеп.— Бу җәһәннәмнән, бу кыямәт базыннан чыгарга язмагандыр миңа...

Сарман ягы кешесе чыгып киткәч, Гази үз-үзенә урын таба алмый тинтерәде. Ә бит бу сөйләшүгә ике генә көн кала Гази аның ничегрәк эшләгәнен карап торган иде. Үз язмышына тәмам буйсынган кеше кебек, конвейерда тезелешеп торган танклар янында ут уйнатып йөрүен күрде. Шайтан житезлеге белән асларына кереп, анда очкын көлтәләре чәчрәтте. Ул да түгел, озын шланг-эчәгеләрен сөйрәп, башнясы аша да, астагы люктан да танк эчләренә кереп мәш килде... Аның җитезелгыр хәрәкәтләренә караганда, күңел биреп эшли сыман иде. Әллә шулай булып тоелды гына микән?..

Нәкъ шул көннәрдә лагерь хуҗалары өчен бәйрәмгә тиң тантаналы көн җитте. Комендант, янына офицерларны, төрле түраларне җыеп, фронттан танклар алырга кайткан фрицларны тәбрикләде. Кабул итеп

алыгыз дип, өр-яңа сыман елкылдап торган утыздан артык танк ягына күрсәтте. Арада тимгел-тимгел итеп буялган «тигр»лар да бар иде. Һәркайсының кабыргасына ап-ак буяу белән фашизм эмблемасы — тәре сугылган иде.

Саубуллашу сәгатьләре җитте. Хуҗалар ябь-яшь, берсеннән-берсе таза, арысландай фрицларга тагын да олырак җиңүләр теләп, кулларын кыстылар. Багана башындагы репродуктор аша дәртле марш яңгырады. Танкларның барысына да берьюлы диярлек җан керде. Җир иңри, җир тетри башлады. Тирә-юньне сөрем катыш тузан басты. Куәтле дизельләр үкерә, көпчәк чылбырларының яман чыңлавы-чакырдавы һаваны яра иде. Танклар, тигез колоннага тезелеп, төбенә кадәр ачып куелган капка аша чыга башлыйлар...

Әмма бу тантаналы озатуның ахыры дәһшәтле тәмамланды. Өч-дүрт сәгать тә үтмәде, полигонга китеп барган танклар дөбер-шатыр кире борылып кайтып, яңадан иртән кузгалып киткән урыннарында дизель-моторларын сүндереп, тынып калдылар.

Концлагерьда ут чыктымыни, ыгы-зыгы купты. Төркем-төркем булып коралланган эсэсчылар йөгерештеләр. Әсирләрне гадәттә иртә-кич тезеп куеп барлый торган мәйданга чакырып, чаң суктылар. Гази да, кара болыт кебек булып, тоткыннар җыелган мәйданга чыкты һәм үз урынына килеп басты.

Шулчак строй алдына кием-салымнары тетелеп беткән, танырлыклары калмаслык итеп кыйналган алты әсирне чыгарып бастырдылар. Арада Сарман кешесе дә бар иде. Әллә нишләп китте Гази, йөрәге чәнчеп-сызып куйды. Якташын бик нык җәзалаганнар булса кирәк, аягында көч-хәл басып тора. Йөзе дә, күмер төсенә кереп, кара көйгән иде.

Менә ни өчен соңгы тапкыр очрашканда васыять сыман нәрсә әйтеп калдырырга булган икән. Сүз дә юк, Гази кулыннан килгәннәрнең барысын да үтәр. Тик менә Сарман ягы кешесенең фамилиясе хәтерендә калмаган, авыл исеме дә онытылган. Һай-й, бу гамьсезлек! Хәер, Гази аның ул сүзләрен ничектер чынга да алмады кебек. Ә исеме? Исеме дә, ватылган пыяла сыман, таралып киткән кебек булды. Галимме, Сәлимме? Юк, Җәмил иде бугай? Әллә Хәлимме? Шулай булса кирәк. Эх-х, шайтан алгыры, хәтерен күр инде... Менә хәзер: «Кара әле, якташ, исем-фамилияң ничегрәк иде синең? Авылың исемен дә кабат әйт әле»,— дип бик сорарга иде дә, юк шул, соң...

Гази шулай баш ватып торган арада, концентрацион лагерь буенча чыгарылган боерыкны укырга өлгергәннәр иде инде. Җәлладлар, язмышлары хәл ителгән тоткыннарны як-яктан эләктереп алдылар да, койма буендагы дар агачлары янына алып киттеләр...

Бары тик соңыннан ишетеп белде Гази: Сарман татары, яшерен оешма карары буенча, фронтка озатылырга тиешле күпчелек танкларның төп көпшәләрен, кору замокларын электросварка белән эштән чыгарган булган. Танклар шул сәбәпле кире борылып кайтканнар икән.

Дөрес, Гази туган илгә әйләнеп кайткач, якташының соңгы әманәтен үтәргә тырышып карады. Сарман ягы кешеләре белән очрашкан саен, хәтергә төшмәсме дип, авыл исемнәрен дә әйттергәләде. Әмма күпме генә тырышса да, күңелдә өмет чаткысы кабызырлык сүз ишетә алмады. Ул сорашкан кешеләрнең күпчелеге берүк сүзләрне кабатлыйлар иде: «И-и, туганкай, кайтмый калган дип сорама син, кемнәр исән-имин кайту бәхетенә ирешә дип сора...»

Үзебезнекеләр тарафыннан азат ителгәнчегә кадәр Газига кабат җәзалау камераларын да, каты режимлы төрмәләрне дә башыннан кичерергә, кырыкмаса-кырык тапкыр әҗәл белән күзгә-күз очрашырга туры килде. Аушвиц концлагерендагы элемтәче полицай-антифашист: «Бу журнал ярдәм дә итәр, урынына карап, башыңа да җитәр»,— дип дөрес әйткән булган икән, «кара сакалы» — Европаның оккупацияләнгән халыклары өчен чыгарылган «Сигнал» журналы туган илгә аңардан да алданрак кайтып җиткән иде инде...

2

Һади Азнакайга беренче рейс белән барып төште. Иртә иде әле. Таҗи яшәгән урамны да бик тиз тапты. Поселокның иң тыныч һәм яшел почмакларының берсе икән. Менә Һадига кирәк булган коттедж. Ишегалдына кадәр яшеллеккә күмелгән. Шунда ук, терраса буйларында, өй кыегына кадәр сузылып үскән үрмәле гөлләр шау чәчәктә утыралар.

Уң якта эре Чупай ташыннан салынган гараж. Аның каршында ук куе зәңгәр төстәге «Волга» тора. Тагын бер «Волга» ишек алдында. Анысы аккош кебек ап-ак иде.

Шул вакыт күкрәгенә кадәр ачык калдырып тегелгән бизәкле сарафан кигән бер яшь кенә ханым, баскычтан йөгереп төште дә, җилкапкага арты белән торган «Волга» янына килде. Ишеген ачып, яртылаш машина эченә кереп, арттагы тәрәзә буена өелгән әйберләр арасыннан нәрсәдер эзли башлады. Бу сылу гәүдәле ханымны Һади баштарак: «Әллә минем яңа җиңгәчәем микән?» — дип тә уйлаган иде. Бәлки шуңа күрәдер, хатынга ишеттерү максаты белән, ул юри гадәттәгедән катырак кычкырып:

— Исәнмесез! — диде.

Хатын, җәһәт кенә машинадан чыгып, иләмсез күтәрелгән сарафан итәкләрен тарткалап куйганнан соң, егетнең сәламенә каршы русчалап җавап кайтарды. «Әллә инде үз телен дә онытканмы, җүнсез...» — дип уйлап куйды Һади. Үзе дә русчага күчеп, Зәкиевны күрергә теләге барлыгын аңлатып бирде.

— Ә ник өйгә кермисез? — диде әлеге чибәр ханым. Ул инде: «Рәхим итегез!» — дигән кебек, кулы белән ишек ягына ишарә ясап юл да күрсәтте. Һәм ялан аягына киеп алган артсыз босоножкаларын шапышопы китереп, баскычтан йөгерә-йөгерә менеп тә китте. Бусагадан атлап керү белән аның: «Таҗи Хаҗиевич! Ишетәсезме? Капка төбендә сезне бик чибәр бер егет көтеп тора»,— дигән тавышы ишетелде.

Абыйсы озак көттермәде. Башта: «Өйдә дә тынгылык бирмиләр», дигән кыяфәт беләнрәк чыкты ул. Җитмәсә тагын, табын янынннан гына күтәрелгән булса кирәк, йөзе-бите чак кына тирләгән, елкылдап тора. Өстендә җиңнәре сызганып куелган ап-ак нейлон күлмәк. Изүләре чишүле. Абыйсы да шактый үзгәргән, юаная төшкән, хәтта чак кына корсагы да бүлтәеп чыкккан.

Таҗи баскыч төбенә аяк басуга, энесен танып алды. Ике атлап, бер сикереп, эре-эре квадрат плиталар җәелгән ишегалдыннан йөгереп кенә үтте дә энесен кочагына алды.

— Кайттыңмы, малай актыгы! — дигән булды ул, Һадиның җилкәләрен төйгәләп.— Син нәрсә, әллә нинди бичура кебек капка төбендә басып торасың? Әйдә, өйгә рәхим ит! Яхшымы-яманмы, мин бит синең туган абыең бугай?!

Чак кына уңайсызланган, шул ук вакытта бераз дулкынланган Һади да телгә килде:

—Кунаклар бар, ахры?

— Булса соң! Әллә ни чит кешеләр юк анда. Бар да үз кешеләр... Туган-тумачалар. Минем туганнар синең дә туганнар була түгелме соң? Ә?..

Өйгә керделәр. Бишләрне ишек катында ташлап калдырдылар. Таҗи энесен җилкәсеннән кочаклап, ят-зат нигъмәтләр белән тулы табын янына килеп, кунаклар белән таныштыра башлады.

— Ханымнар һәм әфәнделәр! — диде ул ясалма пафос белән. Тавышы көр, каяндыр бөереннән чыга иде аның.— Таныш булыгыз: сезнең каршыгызда басып торучы бу блудный сын минем бертуган энем була инде. Исеме — Һади. Фамилиясе — Зәкиев. Рәхим итеп, арагызга кабул итүегезне үтенәм!

Абыйсының бу өйдә килде-китте кеше түгеллеген күрү өчен әллә ни зур тәҗрибә кирәкми иде. Табындагылар җанланып кына калмыйча, хәтта дәррәү урыннарыннан ук кузгала башладылар.

Табын янында утыручылар белән таныштыру эшен дә Тажи үз өстенә алды.

— Ә хәзер, әйдә, танышып та алыйк!..

Иң беренче булып, өстәлнең уң ягында, бая ишек алдында күргән ханым кебек үк җиңел сарафан киеп алган, чак кына тулыланырга өлгергән хатын-кыз каршысына килеп бастылар.

— Менә монысы Һади энем, синең җан җиңгәң булыр...

Ачык чырайлы бу ханым, урыныннан тормыйча гына, йөзекләр белән бизәлгән ап-ак нәфис кулын Һадига таба сузды. Ничектер, җыйнак-матур кулын үбәргә тәкъдим иткән кебегрәк итеп, аркасы беләнрәк сузды.

— Исәнмесез! — диде Һади, мөмкин кадәр илтифатлы булырга тырышып.— Һади...

— Исемем Алмазия. Алма җиңги дисәгез дә була.

Бая машина янында күрешкән ханым белән дә исемнәрен әйтешеп, кул биреп күрештеләр. Роза исемле икән анысы. Исеме җисеменә бик муафыйк, чыннан да, гөлчәчәктәй сылу икәнсең дип уйлап куйды Һади.

Соңыннан инде табынның иң түрендә утырган кунак янына якынлаштылар. Монысы урта яшьләрдәге, күрер күзгә шактый чандыр, хәтта бераз бетешкән кыяфәттәге ир-ат иде. Чигә чәчләрен тигез генә булып чал суккан. Нык карашлы, һәрбер хәрәкәтендә ихтыяр көче барлыгын сиздереп тора торган, тулы мәгънәсе белән замана кешесе иде бу.

— Ә монысы,— диде Тажи, тавышын тагын да көрәйтә төшеп,— кунакларыбызның да кунагы, табын күрке, хөрмәтле Галим Халимович Шәңгәраев була инде. Аның титулларын әйтеп тормыйм, чөнки бу фани дөньяда аны белмәгән бер генә зат та юктыр. «Нефть магнаты» дигән кушаматы да бар. Әлеге кушамат, казан төбенә касмак каткандай, ябышкан да калган үзенә. Рәхим итеп, танышып алыгыз!

Һади өлкән кунак белән кул бирешкән арада, Тажи һаман да сөйләнеп торды.— Роза ханымның ире. Ә безнеңчә, үзебезчәрәк әйткәндә, каенагабыз була...

Һади күрешкәндә үк Галим Халимовичның үткер карашын, кулларының көчле-ныклыгын тойды.

Аннан-моннан гына кулларын чайкаштырып алдылар да, Һадины җилтерәтеп табын янына утырттылар.

«Менә нинди тормышта яшәп ята икән...» — дип уйлап алды Һади, бик канәгать кыяфәт белән, дәрәҗәсен белеп, табын түрендә утырган абыйсына күз салып. Аннары алдына китереп өелгән нигъмәт-ризыкларга күз йөртеп чыкты. Кыздырылган ит-мазар, төрле салатлардан тыш, алма белән әфлисуннарга кадәр бар иде монда. Җитмәсә тагын әле генә агачтан өзеп алып табынга китереп куйганнар диярсең үзләрен!

Абыйсы сүз уңаенда, Һадиның Камчаткадан кайтып төшүе турында әйтте. Тиледән туры сүз дигәндәй, университеттан куылгач, вербовка белән китәргә мәҗбүр булуын да өстәде. Бу сүз дамаларны бер мәлгә сагайта калды. Кискен-житез хәрәкәтле каенага, ягъни мәсәлән, «нефть магнаты», хәтта, аның ни өчен университеттан куылуы белән кызыксынып куйды.

— Һы-ы!..— диде ул, Һадиның җавабын ишеткәннән соң.— Кыз намусына тап төшергән пошляк белән мин дә нәкъ шулай итәр идем. Аңламыйм мин бу бюрократларны...

Тажи, энесе Һадиның укырга юридик факультетка керүе, кайчандыр юрист булырга хыяллануы турында әйтеп куйды.

— Һы-ы! Үзегез дә тапкан булгансыз икән һөнәр,— дип эләп алды «нефть магнаты».— Эшмени ул! Аксак-чулак, сукыр-чукрак кебек җыен гарип-гораба хезмәте ич ул. Тик зинһар, кияү, бу сүзләрем өчен гафу итә күр. Һәрхәлдә, үзеңә кагылмый дип сана минем бу сүзләремне. Юриспруденция — синең шөгылең, юкка вакытыңны әрәм итмичә, юридик факультетка читтән торып укырга кер дип, мин үзем сиңа тәкъдим иттем. Монда сүз энең Һади турында бара. Мондый өрлек кебек килеш-килбәт

белән нефтьче булырга кирәк егеткә.— Аннары капылт кына Һадиның уй-фикерләре, хыял-максатлары белән кызыксынып куйды.

— Берәр җиргә эшкә керермен дип торам...— диде Һади, әлегә бу мәсьәләне өзеп хәл итмәгәнлеген белдереп.

— Эш дисең алайса? Эш яхшы нәрсә, әлбәттә.— Бу сүзләрне дә әлеге дә баягы «нефть магнаты» әйтте. Хәрәкәтләренә, сүз рәвешенә караганда, вакыты белән ул орды-бәрдегә, каян туры килде, шуннан чаба торган кешегә охшап куя иде. Бу юлы да башта Һади белән килешкәндәй итте, әмма шунда ук үз фикерен дә әйтмичә кала алмады.— Эш турында уйлавың, һичшиксез — шәп! Әмма гаилә белән уралышканчыга кадәр, төпле белем алу турында уйлау да комачауламас иде. Уку белән тату булмау харап итә безнең татар малайларын. Шуны бел: начар күпер йөкне күтәрә алмаган кебек, тотрыклы белеме булмаган кеше дә хәзерге көндә әллә ни майтара алмый. Замана кеше алдына башкарак, икенче төрлерәк таләпләр куя хәзер...— Галим Хәлимович тамагын чылатырга теләгән сыман, алдындагы рюмкасын алып, иреннәрен генә чылатты да кире куйды. Әмма аның әйтәсе сүзләре бетмәгән булган икән, чак кына Һади ягына борыла төшеп, тигез генә тавыш белән дәвам итте.— Аннары, сезнең яшьтә инде киләчәк турында, ягъни мәсәлән, карьера турында да уйларга бик вакыт. Сез мине дөрес аңлагыз: «карьеризм» димим мин, «карьера» дим. Боларның икесе ике нәрсә. Тормыш — мәктәп. Ә мәктәптә һәркем бер класстан икенче класска күчүне максат итеп куя. Тырышып, көч куеп та, нинди дер сәбәпләр аркасында бер үк класста утырып кала икән, кеше гарьләнә, газаплана, хәсрәтләнә... Бу исә үз чиратында кирәкмәгән башка төрле фикерләрне тудыра. Кеше үзен җәберләнгән, гаделсезлеккә тарыккандай хис итә башлый. Аңарда кешеләргә карата гына түгел, бөтен дөньяны кыралмау хисләре уяна...

Беренче карашка әллә ни күзгә ташланып тормаса да, йоннан төргән гөнҗәләгә охшашлырак бу кеше торган саен Һадиның күңелен җәлеп итә барды. Аның белән әңгәмә алып баруы, сүз куертуы рәхәт тә, уңайлы да иде. Шәңгәраев фикеренә әллә ни каршы килмичә генә Һади болай диде:

— Барыбер, бер-ике ел эшләп, баш-күз алмыйча, бераз аякка басмыйча, уку турында хыялланып булмас әле...

— Һы-ы!.. Бер-ике ел дисең алайса? — дип сорап куйды тегесе.— Ләкин бит хәзер вакыт берәмлеген еллап түгел, секунд-минутлар белән исәпли торган заман.— Аннары искәрмәстән генә Һадиның хәзер ничә яшьтә булуы белән кызыксынып куйды.

— Егерме алты,— диде егет.

Һадиның җавабы Шәңгәраевны гаҗәпләндерде.

— Егерме алты! — дип куйды ул, гадәттән тыш хәбәр ишеткәндәй итеп.— Мена, күрдеңме инде...

Сүзне Таҗи элеп алып дәвам итте.

— Укудан бүленеп, берничә ел колхозда механизатор булып эшләде,— дип аңлатты ул.

«Нефть магнаты», әйтерсең лә, шушы сүзне генә көтеп торган.

— Һы-ы!.. Соң бу бит инде нур өстенә нур дигән сүз. Безнең егетебез хәзер үк ярым нефтьче икән ләбаса! Хикмәте — техниканы белүдә.— Соңгы сүзен ул аеруча катгый рәвештә әйтте.— Юк, җәмәгать! Хәзер көн тәртибендә бары тик бер мәсьәлә калды: ул да булса, егетнең укуын дәвам иттерү...

Һади көлмичә булдыра алмады.

— Быел юк инде...— диде ул, «юк белән башыгызны катырмагыз әле» дигән кебек итеп.— Хәзер соң инде...

— Укырга бервакытта да соң түгел.

— Имтиханнар күптән башлангандыр инде...

Шәңгәраев ишетергә дә теләмәде.

— Башлану ул әле тәгәлләнү дигән сүз түгел.— Аннары искәрмәстән генә тагын сорау бирде.— Документларың үзең беләнме?
— Юк...
— Кайда алар?
— Университетта.
— Ягъни мәсәлән, Казанда?
— Әйе...
—Казан аша кайтмадыгызмыни?
— Казан аша да...
— Ник ала кайтмадыгыз?
— Ничектер... Кирәге булырдип уйламаган идем,— диде Һади, бу сорау алуга чак кына уңайсызланып.
Ләкин олы кунак, ниндидер карарга килгән кеше сыман, әйтә салды:
— Ярар, анысы әллә ни зур бәла түгел. Кайтартырбыз...— Шунда ук капылт кына хатыны ягына борылып, аңардан ниндидер блокнот сорады.
— Сумкададыр...— диде тегесе, иренең ни теләгәнен аңламыйча.
— Китер! Тиз бул...
Хатыны, шунда тәрәзә төбендә генә торган, бинокль тартмасына охшашлы сумкасын кулына алды. Аннан бармак бите кадәрле генә кызыл блокнот чыгарып, иренә бирде. Тегесе исә, шул нәни кенәгә кулына эләгү белән, урыныннан тормыйча гына телефон трубкасын алды. Заказ бирү номерын җыйды.
— Үскәнем, исәнмесез! Сезне Шәңгәрәев борчый иде. Әйе!..— Кулындагы сәгатенә күз төшереп алды да дәвам итте.— Миңа срочно Казан кирәк иде... Турыдан 71 белән алыгыз... Әйе, әйе! Зәкиев квартирасы белән тоташтырырсыз.
Телефон трубкасын урнына кую белән гаять гади мәсьәләне хәл итәргә җыенган сыман итеп, Һадины чын-чыннан шаккаттырырлык сорау биреп куйды.
— Хәзер иң әүвәл кайда укырга керүегезне хәл итәргә кирәк...— диде Галим Хәлимович бер дә исе китмәгән кыяфәт белән.— Кайда укырга теләр идегез? Мәскәүдә — Губкинадамы, әллә Уфадамы?..
Олы кунакның бу кыланышлары Һади өчен, ничектер, ярым шаярып, мәзәк ясау өчен генә шулай ителәдер кебек тоела башлады. Шулай җиңел генә хәл ителә торган нәрсәмени соң ул? Чынлыкта исә бу бит миллионлаган яшьләрнең иң изге хыялы... Баш җитмәслек нәрсә ич бу?.. Менә әкәмәт!
Һади шулай икеләнеп, нәрсә дип, ничегрәк итеп җавап кайтарырга да белмичә аптырап утырган арада, бу мәсьәләне Шәңгәрәев үзе үк хәл дә итте.
— Минемчә, «Икенче Баку» шартларында эшләргә җыенган кеше өчен, Уфада уку хәерлерәк булыр. Практика үткәндә дә уңай нәтиҗәләр бирә...
Шул вакыт аның сүзен кырт бүлеп, бик яман итеп телефон шалтырады.
— Әһә, шәһәрара... Димәк, мине!..— Галим Халимович трубканы алды.— Әйе, әйе!.. Казанмы? Да, да!.. Ул үзенә кирәкле телефон номерын әйтте.— Ничек? Җавап бирмимени?.. Һы-ы! Алайса чак кына сабыр итегез... Ә? Сабыр итегез дим.— Кабат блокнотын актарып, ниндидер номерлар эзләде. Һәм тапты бугай.— Ал-ло!.. Ишетәсезме?..— Яңадан телефон номеры әйтте.
Шундук җавап та бирделәр.
— Ал-ло!.. Кем әле бу?.. Ә-ә-ә!.. Салют, туган! Таныдыңмы? Әйе, мин борчый идем. Нинди йомышмы? Тыңла алайса...— Галим Халимович үзенең үтенечен аңлата башлады. «Срочно!..» диде, кая җибәрергә икәнлекне әйтте.
— Фамилиясе?.. Зәкиев. Зәкиев дим. Син, Кузьмич, язып ал әле...

Феномен хәтергә караганда, язып куярга ярый торган карандаш сыныгы һәйбәтрәк дигән бер акыл иясе. Яздыңмы?.. Зәкиев. Исемеме? Исеме... Һади. Әй-йе, әй-йе!.. Нәрсә? Монысы инде икенче Зәкиев. Зәкиевларның икенчесе... Кечерәге, яшьрәге. Юк, күп түгел. Нәрсә?.. Анекдот?.. Йә-йә, сөйләп кара алайса. Македонский?.. Соң шуннан... Шәп, шәп!..— Аннары искәрмәстән генә рәхәтләнеп, башын артка атып кычкырып көлә башлады.— Кара әле, җүнсез... Синнән дә бер адәм рәтле сүз чыгар икән. Ха-ха!.. Малай чагындагы баш сөяге дип әйтә диме? Ха-ха!.. Ярар, Кузьмич... Пока дим. Анекдотың өчен рәхмәт. Кларага сәлам. Хуш!..

Шәңгәрәев телефон трубкасын куйгач та әле, яңа гына ишеткән мәзәк тәэсиреннән арына алмыйча, көлүен дәвам итте. Аннары Таҗи ягына борылып, кем белән сөйләшкәнлеген аңлата башлады.— Син беләсең аны... Филиалда эшли. Хәтерлисеңме, таныштырган идем... Университет мәсьәләсен хәл иткәндә. Шуны искә төшерде. Ничәү соң ул Зәкиевлар, ди?.. Менә җүнсез! Баш сөяге белән сату итүчегә ошап киттең ди. Бер аферист шулай, музейларның берсенә кереп дә, Александр Македонскийныкы дип, баш сөяге тәкъдим итә. Алалар, әлбәттә. Һәйбәт кенә бәһа да түлиләр. Күпмедер вакыт үткәч, теге аферист яңадан шул ук музейга килә. Кулында яңадан баш сөяге моның. Тик, бик бәләкәй. Монысы кемнеке? дип сорыйлар тегеңәрдән. Күзен дә йоммый: Македонскийныкы ди. Соң без бит инде сездән бөек Искәндәрнең бер баш сөяген сатып алган идек ләбаса дигәч, тегесе дә югалып калмый: «Бусы аның малай чагындагы баш сөяге»,— дип җавап кайтарган ди. Ах-х, шайтан алгыры! Очраткач, күрсәтермен әле мин аңар атасының баш сөяген...

Галим Халимович һаман да әле көлеп, күңел көрлеге белән, алдында торган рюмкасын кулына алды.

— Менә, бер эш эшләнде дә!—дип әйтте ди җәллад, чираттагы корбанының башын чабып өзгәч. Безнең дә кайбер мәсьәләләр хәл ителде дисәк тә ярый...— диде ул, һәм шуның өчен эчеп куярга тәкъдим итте.

Ул арада әңгәмә кинәт кискен борылыш ясап, икенче якка кереп китте. Монысын инде хатын-кызлар башлады. Аларны Һади яклаган авыл кызының кем булуы, хәзер кайдалыгы һәм кем булып эшләве кызыксындырды.

Һади ике авыз сүз белән аңлатып бирергә мәҗбүр булды. Ә инде Айзәрәнең хәзерге вакытта тормышта икәнлеген ишеткәч, шул ук Галим Хәлимович, сүзне яңадан уен-көлкегә борып җибәрде.

— Һы-ы!..— диде ул, күзләре белән генә елмаеп.— Ышан син хатын-кызга! Гомумән алар, ягъни мәсәлән, хатын-кызлар, нәкъ көтелмәгән хәл кебек... Биш минуттан соң аларның нәрсә теләвен шайтан үзе генә белә...— Аннары креслосының аркасына тагын да янтая төшеп, искәрмәстән генә кеткелдәп көлә башлады.— Чит илләрдә төрле-төрле җәмгыятьләрне берләштергән бик күп төрле клублар эшли. Хәтта, игезәкләрне берләштергән клублар бар. Европа буенча сәяхәт иткәндә Швейцариядә дә булдык. Анда мәсәлән,«Тотрыклы ирләр» клубы эшли. Консультантлар булып, бик бай тәҗрибәле ирләр, гаилә башлыклары утыра. Өйләнергә җыенган яшьләр, гомумән, гаилә корып җибәрергә теләүчеләр, шунда кереп, үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап та алалар. Без дә кердек... Юлдашым, «Краснодарнефть» берләшмәсенең баш геологы, күпмедер акча түләп, кызык өчен бер сорау бирде. Хатын-кызларның нинди: кара, җирән, сары, яки коңгырт-кара төстәгесеме, кыскасы, чәче нинди төстә булганы тугрылыклырак була? — дип сорады ул. Консультант ике генә сүз белән җавап кайтарды. Безгә тәрҗемә иттеләр: «Чаларган чәчлесе...» — дигән икән.

Табын янында утыручылар көлешеп алдылар. Баштарак ничектер игътибар үзәгендә булган Һадины соңрак бермәлгә онытып тордылар. Әңгәмәләрен дә күбрәк үзләрен кызыксындырган, үзләренә кагылышлы мәсьәләләр тирәсендә йөрттеләр.

Һади «нефть магнаты»на, аннары аның сылу хатыны Розага карап куйды. Яннан бу ханым тагын да сылурак һәм иренә караганда шактый яшьрәк булып күренә иде. Бу ир белән хатын арасында да бары тик үзләре генә белә торган гаять катлаулы мөнәсәбәтләр һәм ниндидер мөгамәләләр бардыр кебек булып тоелды егеткә.

Бераздан бөтен табын белән дәррәү кузгалып, ыгы-зыгы килеп, бала-чагаларын җыеп, гүзәл Ык буена ял итәргә төшәргә әзерләнә башладылар.

Берьюлы ике «Волга»га төялеп, елга буена төшкәндә дә, аларны анда ниндидер ял итүчеләр күтәреп диярлек каршы алганда да, Һади ялгызы гына бер күл буена барып балык каптырганда да, тезелешеп утырып, шау-гөр килеп хуш исле, гаять тәмле уха ашаганда да, аның күңел төбеннән ниндидер бер хис күтәрелеп, үзендә ниндидер үзгәреш хасил булуын төшенде. Гаҗәеп нәрсә икән ул кеше психологиясе дигән нәрсә. Гаять нечкә, катлаулы һәм четерекле икән. Җитмәсә тагын «вакыт» дигән нәрсәгә буйсынучан, бирелүчән икән... Ә бит инде ул үзе кичергән гаделсезлекләрдән соң күңелендә туган ачы нәфрәтнең, йөрәгенә сызылган тирән яраларның, җан әрнүләренең һәм, ниһаять, каткан бәгыренең кайчан булса да бер эрүенә өметен җуя башлаган иде. Хәтта, Җәүһәрия җиңгәсен ташлаган өчен, абыйсы Тажины да һичкайчан кичермәс, гафу итмәс кебек булып тоелган иде. Андый ярсулы хисләр, шашынулы тойгылар күңел түрендә мәңге төзәлмәс тирән җәрәхәт булып калыр дип уйлаган иде ул.

Гаҗәп хәл! Вакыт дигән нәрсә үзенекен итә икән. Көтелмәгән яңа мохиткә эләгүе, чак кына тормыш хозурлыгына бирелү Һади күңелен әллә нишләтеп айкады да ташлады. Гүя университеттан куылулар, җәһәннәм читенә язылып китүләр бөтенләй булмаган, булса да ниндидер ямьсез, саташулы төш кенә булган, күңел төбендә исә бары тик шуның шыксыз юшкыны гына утырып калган...

Ямьле Ык буенда алар рәхәтләнеп су коендылар, кояшта кызындылар, болын-әрәмәлекләрдә чәчәкләр җыйдылар, бары тик шуннан соң гына, кояш баю ягына авышкач кына, кайтырга чыктылар.

Юлда шактый ук тынгысыз уйлар иза чиктерде Һадины. Беренче очрашкач та, Тажи абыйсы тормыштан бик канәгатьтер сыман булып тоелган иде. Бу халәт хәтта аның йөзенә дә чыккан иде кебек. Өйдә дә ал да гөл, гүзәл Ык буенда да аларны, биек койма эченә кертеп, өсләрен манара рәвешендә бизәп-чуарлап салынган өйләр каршылады. Өйләр янында алар өчен аш-су әзерләргә, башка төрле хезмәт күрсәтергә махсус кешеләр көтеп тора иде инде. Бу тирәләрдә олы түрәләрнең бик еш ялга килгәнлеге әллә каян сизелә. Өзелүне, черүне белми торган, «буровой җебе» дип даны чыккан капрон шпагаттан үрелгән садокта балыкның да җаның теләгәне тотып куелган. Җиз подносны хәтерләткән өчәрдүртәр килолы корбаннар да, чучка баласы кебек симез-йомры сазаннар да, күлдән тотып китерелгән табан балык белән кара балык та бар иде. Һәммәсе, әле яңа гына судан чыгарылган сыман тереләр...

Һади да, савыт-саба, урын-җирләр тутырылган махсус вагоннан бер кармак табып алып, яр астына, бөдрә тал төбенә төшеп утырды. Карасa, абые белән Шәңгәрәев тә аның янына килеп, яр өстендәге яшел үләнгә кырын ятып, үзара гәп сата башладылар. Кызык сөйләшүнең шаһиты булырга туры килде Һадига.

Китек күңел тиз җәрәхәтләнер дигәндәй, «нефть магнаты»ның абыйсы Тажи белән сөйләшүе, маңгайга чиерткәндәй шактый ук каты итеп, турыдан бәреп әйткән сүзләре Һадиның күкрәгендә ниндидер ачы әрнү калдырды. Ул, мәсәлән, Шәңгәрәевның кайбер сүзләрен күтәрә алмас иде.

— Юк, Тажи, бу синең эш түгел,— дип башлады Шәңгәрәев, кешенең хәтере калу-калмау белән санашмыйча.— Университетка, юридик факультетка читтән торып укырга кереп, бик тә яхшы иттең. Вакыт ул иң олы һәм мәрхәмәтсез хөкемдар, барын да җае белән үз урынына куя килә. Юриспруденциянең эш профиле киң, зур, иң әһәмиятлесе — ыша-

нычлы. Социалистик законлылыкны ныгыту, суд органнарында, юстиция, прокуратура, эчке эшләр органнарында эшләрсең. Юриспруденциядә ялгышудан курыкмыйча эшләргә мөмкин. Чак кына икеләнәсең икән, рәхим ит, синең карамакта юридик консультацияләр, кодекс китаплары, мең төрле белешмәлекләр... Статьялар да, пунктлары да акка кара белән язып куелган. Ә партия хезмәткәре булу кәсеп тә, һөнәр дә түгел. Ул ифрат та җаваплы, ифрат та иҗади эш. Аны теләсә кем булдыра алмый. Моның өчен призвание кирәк, табигый талант кирәк,— иң әһәмиятлесе — кешене үзеңнән дә артыграк ярата белү, бөтен галәмне иңләрлек олы җанлылык кирәк. Әнә, хатының Алмазия — врач. Ул кешеләр дәвалый. Бик һәйбәт! Ә бит партия хезмәткәрләренә бөтен кешелекне сәламәтләндерү миссиясе йөкләнгән. Шул бөек эшкә әзер дип саныйсыңмы үзеңне? Мин, мәсәлән, синең урында булсам, мондый сорауга үзеп җавап кайтарырга кыенсынып идем...

Абыйсы үзенә җинеллек китерерлек бер авыз аклану сүзе дә әйтмәде. Нинди кеше соң бу Шәңгәрәев? Ничек җөрьәт итә ул кешеләр белән шулай сөйләшергә?

Һадины иң гаҗәпләндергәне шул булды: алар кайтканда, махсус пакет эченә салынган документлары аны инде өйдә көтеп тора иде.

Икенче көнне иртән уянганда, аны капка төбендә Бөгелмә аэропортына илтеп кую өчен «Волга» көтеп тора иде инде.

— Менә сиңа «Сәлам хаты»,— диде әлеге дә баягы Галим Хәлимович.— Бу пакетны турыдан-туры ректорның үз кулына тапшырасың. Ә хәзер, әйдә, саубуллашыйк... Хәерле юл сиңа! Билет аэропорт кассасында көтә. Ә Уфада «Башкирия» гостиницасында номер броньланган.

Озата чыктылар. Хатын-кызлар, гаять зур эш башкаргандай тыз-быз килеп, юлга дип төйнәлгән төргәкләрне машинага урнаштырган арада, «нефть магнаты» Һади янына килде, култыклап чак кына читкә тайпылдырды. Һәм егетнең йөзенә текәлеп болай диде:

— Менә нәрсә, Һади Хаҗиевич... Әгәр дә мин хәзер сиңа, ничектер, ярдәм кулы сузам икән, моны дөрес аңла. Субъектив мотивлары бар моның. Чөнки синең хәзергә эшең дә, торыр урының да, дус-ишләрең дә юк. Шуның өстенә исемең дә тапланган... Ул нәрсә үзен атлаган саен сиздереп торачак. Чөнки син илләр гизеп, турне ясап кайтмаган... Аңлыйсыңмы? Хәзер синең хәлеңдә, синең урында башка берәр кеше булса, мин барыбер ярдәм итәргә тырышыр идем. Син мине дөрес аңларга тырыш. Киләчәктә дүрт ягың кыйбла, үз җаеңны үзең карарсың. Ә хәзер, әйдә, саубуллашыйк. Хәерле юл сиңа!..

...Һади имтихан вакытында беренче фәннән үк «5» ле билгесе «алуына» да карамастан, институтны ташлап китәргә мәҗбүр булган. Сәбәпләре турында ул миңа берничә ел үткәч кенә, бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

## 3

Менә ничәмә-ничә көн инде Гази исталекләр тозагыннан ычкына алмыйча ыңрап ята. Уйлары мең дә беренче тапкыр инде томаннар эчендә калган ерак елларны урый, хәтер дигән тынгысыз нәрсә үткәннәрне актара. Шунда бик ачык төшенде Гази: барлыгыңны биләп торган уй-хыяллар бер бәйдән ычкындымы, очар кошларга әверелүләрен көт тә тор, аннары инде син аларны тиз генә йөгәнләрмен димә.

Уй-хатирәләре һаман бер тирәдә аның: тормышының бөтен ямен, бар куанычын пыран-заран итеп үзе белән алып киткән Гөлүсә турында, берни белән дә чагыштыргысыз зур мәхәббәтенең илаһи куанычлар-сөенечләр белән башланып та уфтанулы үкенеч, кара фаҗига белән тәмамлануы турында. Аерылышу-югалту ачысын шул тикле авыр кичерде ки, тилерү, акылдан язуга якын ниндидер тоташ ыңрауга, тәмуг газабына әверелде. Иң яманы шул иде: бөтен барлыгын яулап алган әлеге сагыш-

юксынулар, әрнү-сызланулар, вакыт үткән саен, бары тик артты, тирәнәйде. Шунда янә бер нәрсәне ачык төшенде Гази: еллар түгел, гомер үткәндә дә, үлгәндә дә, яшьли сөйгән яр, беренче мәхәббәт сулмый да, сүрелми дә икән.

Шулай: кайда син? Исәнме? Исән-сау булсаң, кай тарафларда йөрисең, нинди уй-максатлар белән яшисең? дип, өзлексез сызу-сызланулар, өзгәләнүләр эчендә шактый гомерләр үтте. Гөлүсәсе белән кабат күрешә алу, аякларына егылып гафу үтенүләр турындагы иң татлы хыялларын тормышка ашыру өметләре тәмам челпәрәмә килгән бер чакта, бөтенләй көтмәгәндә-уйламаганда, Иргали абыйлары турында хәбәрдар булды да куйды...

Ул вакытта Гази Казан медицина институтында укый иде. Начар укымады. Курсташлары арасында авторитетлы булды. Хәер, һәркемнең социаль чыгышы, биографиясе хәлиткеч роль уйнаган заманда башкача булуы да мөмкин түгел иде. Әмма Гази һичкайчан да этисе дәрәҗәсенә аркаланмады.

Дөрес, ул елларда югары уку йортларына эләгү бәхетенә ирешүчеләр арасында бик күпләрнең биографияләре анықына охшаш иде. Авыл мәктәбе. Комсомол. Рабфак. Һәм, ниһаять, институт. Гази курсташларының һәркайсы диярлек «Я Советлар, я ачлык!» дигән лозунг астында мәрхәмәтсез сыйнфый көрәш барганда тик ятмаган кешеләр. Аерма тик шунда: Газиның уң кашын урталай бүлеп торган, маңгелеккә салынган мөһере — тамгасы бар.

Яшерен-батырын түгел, тыйнак, аз сүзле Гази кызлар күзеннән дә читтә калмады. Арада мәхәббәт үк булмаса да, дуслык тәкъдим итүчеләр дә табылды. Әмма бу хәл Газиның күңелендә бары тик Гөлүсәне терелтте, кызларга күз салганда да ул бары тик Гөлүсәнең чалымнарын эзләү белән генә мәшгуль иде.

Иң зур хыялын тормышка ашыргач — институтка керү бәхетенә ирешкәч, күңеленә утырган юшкыннар чак кына юылыр, йөрәктәге төерләре бераз язылыр дип уйлаган иде Гази. Кая ул! Җанын яулаган хыялый ашкынулары, сагыш-моңланулары яңа көч белән дөрләгәндәй булды. Шунда Гази ничәнче тапкырлар инде бер нәрсәгә анык төшенде, яшьлек мәхәббәте кешенең картаюы белән дә, авырып хәл эчендә ятуы белән дә санашмый, ул котылгысыз, ул үлемсез, аңардан качар әмәл юк икән.

Әле дә хәтерендә Газиның. Икенче курсны тәмамлаган көннәр иде. Искиткеч матур җәй башы. Туган авылына кайтып, ничәмә-ничә кышларның карлары эреп, шул кар сулары белән юылган яшьлек эзләрен эзләп, шигъри Чулман буйларында бер йөрермен, рәхәтләнеп бераз ял итәрмен дип уйлаган иде. Чөнки әлеге мәһабәт елга буенда кайчандыр печән чабулары, шунда Гөлүсә белән бергә хикмәтле төн уздырулары бөтен бизәкләре белән чәчелмичә-түгелмичә күз алларына килә дә баса. Ул көннәр аның яшь күңелендә гомер күренмәгән, гомер кичерелмәгән, мәңге-бакый онытылмаслык бер ямь, бер гамь, бер моң булып уелып калган иде.

Ә чалгы тавышлары... Алар кире кайтмас яшьлегебезнең, югалган бер матурлыкның гомерлек истәлеге булып, колакларда соңгы сулышыбызга кадәр чыңлап торыр ахры.

Ләкин Газиның бу хыялы да тормышка ашмый калды. Нәкъ шул елның җәй башында ил өстенә афәт килде, Бөек Ватан сугышы башланды. Шулай итеп аның әллә ни зурдан булмаган өметләре дә, кайсыдыр борылмалы-сыгылмалы юллар чатында адашып калып, юкка чыкты.

Ул елны медицина институты студентларын җәйге каникулларга таратмадылар. Тикмәгә генә булмаган икән. Атна-ун көн дә үтмәде, моңа тикле бик еракта сыман тоелган дәһшәтле сугышның үзе белән булмаса да, аның өрәге, кара күләгәсе, шәүләсе белән күзгә-күз очрашырга туры килде...

Сугыш башланган көнне үк институтның аудиторияләре тузгытылган умарта күче кебек гөр килде. Митинглар уздырылды. Дүртенче-би-

шенче курс студентларының күпчелеге фронтка җибәрүләрен үтенеп гаризалар яздылар. Парткомга, комсомол комитетына гариза күтәреп чабучылар арасында Гази да бар иде. Әмма беренче-икенче курс студентлары өчен махсус боерык эленде. Фронтка, беренче чиратта, медицина работнигы буларак нинди дә булса файдасы тиярлек кешеләр кирәк, шуны истә тотып, түбән курс студентларыннан кыскартылган махсус курсларда хәрби фельдшерлар әзерләнә башлаячак диделәр.

Аңар карап, Газиларга кул кушырып утырырга туры килмәде. Көн диме, төн диме санитар поездларын, пароходларны каршыладылар, яралыларны госпитальләргә урнаштырдылар, мәктәпләрдә, тулай торакларда оештырылган яңа госпитальләрне җиһазлауда булыштылар. Ә инде яралыларның артуы, дәвалаучы врачларның байтагы фронтка китү сәбәпле, студентларга да җиң сызганып эшкә алынырга туры килде.

Газига бәхет елмайды. Аны, лаеклы ялга китеп тә, хәзер яңадан үзенең эш урынына кайтырга мәҗбүр булган Казан каласының мәшһүр хирургы, республикада иң беренчеләрдән булып Ленин ордены белән бүләкләнгән Зифа Кадыйровна Акчуринага беркеттеләр. Шул атаклы хирургның ординаторы булды ул. Чак кына соңрак Гази, Зифа Кадыйровна белән янәшә басып, үзлегеннән әллә ни катлаулы булмаган операцияләр дә ясый башлады. Бигрәк тә яралыларның яңа төркемнәре кайткан көннәрдә авырга килә иде. Тәүлекләр буе операция бүлмәсеннән чыкмыйча, баштанаяк кара тиргә батканчы эшлиләр иде алар.

Газины башта ук: Акчурина мактауга бик саран дип кисәтеп куйганнар иде. Әмма аякларында басып торырлык хәлләре калмагач, Зифа Кадыйровна аны үз кабинетына чакырып алып, йомшак креслога утыртып ял иттерә иде. Көннәрнең берендә мәшһүр хирург юмартланды — бер авыз җылы сүз әйтте.«Синең, коллега, кулларың бик ипле күренә. Табигатең дә тыныч. Әгәр дә тырышсаң, иң әһәмиятлесе — үз эшеңне яратсаң, синнән, һичшиксез, әйбәт хирург чыгачак», — диде.

Ашау-эчүләр такы-токыга калды.

Кышкы каникул алдыннан Гази да фронтка китәргә рөхсәт алды. Сәфәр чыгарга бер атна чамасы калды дигәндә, туган авылына кайтып әнисе, хезмәт гаскәренә китәргә повестка алган энесе Һади белән саубуллашып килергә булды. Тажиның Алабугада, ниндидер курсларда укуы турында хат аша белә иде инде ул.

Гази таң белән тимер юл вокзалына килде. Пөзьяшәр картлар да хәтерләмәгән ифрат та яман, очканда кошларның сулышын буа, кешеләрнең җилекләрен суырып ала торган гадәти булмаган кыш иде ул.

Чатнама салкын булуга да карамастан, вокзал тирәсендә мәхшәр. Төтен, пар. Җир тетрәтеп, авыр составлар уза. Төрле авазлар чыгарып паровозлар кычкырта. Шәһәр тирәсе вокзалы ягында сабан туе диярсең, кара болыт сыман булып халык җыелган. Гармуннарда уйныйлар, җырлыйлар, бииләр. Шунда ук үкерешеп елыйлар.

Салкынга чыдый алмады Гази, тизрәк вокзалга узды. Ыгы-зыгы иде монда, шау-шу. Җиңнәренә кызыл тасмалар бәйләгән хәрби патрульләр йөренә. Каяндыр, репродуктор аша, әле яңарак кына чыгарылган җыр яңгырый. Ирләр хоры тарафыннан башкарылган әлеге җырның сүзләрендә генә түгел, музыкасында да ил өстенә яман афәт килгәне, халкыбызны зур сынау көткәне аермачык булып сизелә иде.

Гази балалар күтәргән, ачыккан-йончыган хатын-кызлар арасына чиратка басып, бер кечерәк кенә ипи телеме өстенә кибүдән кәкрәеп килгән карындык калынлыгы гына сыр куелган бутерброд сатып алды. «Безнең эшебез хаклы, без җиңәрбез!» дигән зур плакат астында торган көе ике капты да бер йотты аны.

Перронга чыкты. Вокзал алдындагы беренче юлга хәрби эшелон килеп туктаган. Бер башыннан икенчесен күрермен димә. Теплушкаларда солдатлар. Ачык платформаларда, брезент асларында танклар, канатлары аерып алынып төялгән самолетлар, күпшәләре тәртеп торган тагын

әллә нәрсәләр. Һәр вагонда диярлек толыпларына төренгән коралль сакчылар. Ул состав көпчәкләре белән яман чыелдап кузгалып китәргә дә өлгермәде, каршы яктан икенче бер эшелон килеп җитте. Анысы ашыга-кабалана, сәлам да бирми, үкереп узып та китте. Анысына да җыйнаграк келәт чаклы ящиклар, машиналар, йөз төрле станоклар төялгән. «Заводлар күченә»,— дип уйлады Гази.

Ул да булмады, вагоннарына хач билгеләре сугылган санитар поезды якынлашты. Анысы да Казан вокзалында ишекләрен ачып тормады, туктап өлгермәс борын ук кузгала да башлады. Җиргә поезд начальнигы формасы кигән бары тик бер кеше төште. Перронда торган дежурга нәрсәдер әйтеп, честь бирде дә, ачык ишеге янына юнәлде. Гази аның артыннан ташланды. Ике сүз белән хәлен аңлатты... «Минә повесткам, әни белән саубуллашырга дип җибәрделәр...» «Әни» сүзе теләсә нинди ишекләрне ачтыра торган могҗизалы сүзгә әверелгән иде шул. Вятка Аланына кадәр генә дип тә өстәгәч, начальник кеше каршы килмәде, тамбурда кайтырга рөхсәт итте. Ә Вятка Аланында исә, аны махсус көтеп торганнар диярсең. Чаллыга нииндидер станоклар алып барырга дип җыенган, иләмсез зур тимер чаналар таккан тракторларга тап булды.

Чаллы белән Салаяз арасы нибары унике чакрым чамасы. Тешләретешкә тими, бөтен гәүдәсе дерелдәгән Газига җылыну өчен бик ярап куйды ул йөгерү. Менә туган авылы. Соңгы тапкыр булганына күп дигәндә алты-җиде ай чамасы вакыт үткәндер. Әмма авылның танырлыгы калмаган, шундый бетәшкән, боегып, бушап калган. Бәлки шуңадыр, ул Газига мәет чыккан йортны хәтерләткән иде.

Аның каравы әнисе, гадәттәгечә, тавышына җанны эретерлек җылылык өстәп, күтәренке күңел белән күгәрчендәй гөрләп каршы алды Газины.

— И-и, балакайларым ла! Туңыплар үлә язгансың ич. Кая, чишенә күр җәтрәк. Менә монда мич тирәсенәрәк елыш. Хәзер, Гази улым, аш салып җибәрәм. Ит шулпасы. Ничек кайтасылар иттең?.. Ял дисәң ял, каникул дисәң, каникул вакыты түгел дигәндәй? Ярар, биграәкләр һәйбәт булган. Ничек соң, улым, укуларың ару гына барамы? Чак кына тартылыплар киткәнсең димме. Бик ачыгыплар яшәмисеңдер бит, улым?..

Гази зарланмады. Ә инде аның Чаллы аша кайтканлыгы турысында ишеткәч, Һади янына сугылып чыгу-чыкмавы белән кызыксынды. Гази өчен бу яңалык иде.

— Нәрсә, Һади шунда гынамыни? — дип сорап куйды ул.

— Бәрәч! Ул сиңа хат язып салдым дигән иде ич. Алмадыңмени? Ул җәһәттән җаным тыныч. Атна саен булмаса да, кайтыплар йөри ичмасам. Элеккеге пароходлар-баржалар төзәтә торган мастерскойларны сугыш заказларын үтәүче заводка әвереллдерделәр бит. Янына ук терәп, яңа биналар салалар ди тагын. Кичәгенәк Бөкре Әхәте кайткан иде. Шул сөйләп торды. Мылтык, автомат түтәләре, гранат диме шунда, шуңа саплар ясыйбыз ди. Ә Һадилар самолетларның, тупларның көпчәкләренә кидереп куя торган иләмсез зур, киң табанлы чаңгылар әзерли ди. Башта калын, яссы фанерны калайга төрәләр икән дә, аннан килеп астына, тач кошевой чаналарныкы кебек итеп, тимер табаннар куялар икән...

Гази әнисенең ябыгып-тартылып киткәнлеген абайлап алды. Күз төпләренә кадәр кара көеп тора. Сыеры-фәләне юк, ашау-эчүе такы-токыдыр дигән уй чагылып узды. Әй-йе, әнисе аның ифрат авыр чакта да кайгысын тышка чыгарып уфтанмаучы, хәсрәтен сабыр гына эчкә йота белүче гап-гади авыл хатыны, татар хатыны.

— Әни, нииндирәк эшкә әйтәләр? Бик авыр түгелме?

— Төрле эшкә йөрим. Тәнендә җаны булган кеше бу заманда эшсез тора аламы соң?! Мәңгелек каһәр, ләгънәт бу сугышка!..

Күр, нык тавыш белән әйтте ана кеше бу сүзләрне. Хәер, аның кәефе чыннан да ярыйсы ук күтәренке иде. Гази моның серенә дә төшенә: ярты гына ел үтүгә дә карамастан, бу дәһшәтле сугыш чамасыз

хәвеф-хәтәр китерергә өлгергән, бик күп гаиләләр кара кайгыларга уралган бер заманда, аның өч улының өчесе дә, ходайның биргәненә шөкер, исән-иминнәр. Башкаларныкы кебек ут эченә барып керсәләр дә, берни эшләр хәлең юк. Ил белән.

Гази тагын бер нәрсәгә игътибар итте: әнисе түсе-килбәте белән генә түгел, өстендәге кием-салымнары белән дә карчыкларны хәтерләтә иде. Озын чуар күлмәк өстеннән алдына эре бизәкле алсу төстәге алъяпкыч япкан, башындагы яулыгын да, нәкъ карчыклар сыман итеп, аркасына җәеп җибәргән. Эре тәңкәле чулпылары гына элеккегечә, ут уйнатып йөргән яшь чакларындагыча, дәртле чыңлый иде.

Шулчак: «Үземнең фронтка китүем турындагы хәбәрне ничекләр итеп җиткерергә инде?» — дигән уй кабат Газиның күңелен яман тырнап узды.

Ул арада Зәйтүнә, өстенә киеп тормастан гына, салкын кертүдән курыккандай ишекне җәһәт кенә ачып, өйалдына чыкты. Кай арада чормага күтәрелеп өлгергәндер, Гази үзенең баш очында, әнисенең аяк тавышларын ишетте. Түшәм ярыкларыннан пычкы чүбе катыш туфрак коелды. Әйе, дип уйланып алды ул, өй дә тәмам эштән чыккан. Моңарчы рәтләү чарасы күрелмәде, моннан соң кайчан кул җитәр...

Каз түшкәсе күтәреп кергән әнисе: «Һай-й, көннәрнең зәһәрлекләре!» — дип, суыктан зарланып, мич арасыннан кече якка узды. Үзе, эш арасында, һаман сөйләнүен белде.

— Ни... Ни дип торам, Гази улым, бездә дә бер яңалык булыр сыман бит әле,— диде ул, казанга шаулатып су салган арада.

— Нинди яңалык тагын?

— Укуын тәгәлләп кайту белән, Тәҗиебыз башлы-күзле булыр сыман...

— Кит аннан? — Газиның гаҗәпләнүе тавышына чыкты.— Кемгә өйләнмәкче соң?

— Аяк очы урамындагы Хаммат кызы Җәүһәриягә.

Гази тавышындагы гаҗәпләнү тагын да арта төште.

— Бәй!.. Бик яшь түгелме соң ул кызчык?

— Унҗидене тутырды инде.— Зәйтүнә учак астына өргәләп алды. Чырага чытырдап ут кабынганы ишетелде, өйгә янган каен тузы исе чыкты.— Фермада эшли. Савымчы. Үтерепләр уңган инде менә. Күкләргә чөеп мактыйлар үзен.— Ул да булмады, ана кеше тавышы кинәт үзгәрде.— Озын гомерле булыр әле чукынмыш! Әнә үзе кереп килә...

Зәйтүнә сүзен түгәрәкләргә дә өлгерә алмыйча калды, ишектә өстенә өр-яңа плюш жакет кигән, башына соры төстәге мамык шәл бөркәнгән, килеш-килбәтеннән, һәрбер хәрәкәтеннән тазалык-сәламәтлек бөркелеп торган түп-түгәрәк йөзле, алсу битле, ясап куйгандай матур кыз күренде.

— Гази абый кайткан икән ләбаса! Менә һәйбәт булган. Исәнме, Гази абый!..— Җәүһәрия — түргә узып, өстәл янында утырган, әмма кызны күрү белән, аягүрә баскан Гази белән кул биреп исәнләште.

— Исәнме-саумы, авылыбыз сылуы! — Гази мәгънәле итеп елмаеп, кызның җыйнак булса да, көч-егәр барын сиздереп торган нык кулын кысты.

Кыз оялды, сылу йөзе тагын да алсулана төште. Әле дә ярый, гадәттәгечә күгәрченнәр кебек гөрләп, Зәйтүнә чыгып өлгерде. Җәүһәрия дә, үзенең йомыш белән генә кергәнлеген сиздерергә теләгәндәй: «Менә, Зәйтүнә түти, теге син сораган нәрсә»,— дип, өй хуҗасына кечкенә генә төенчек сузды.

— Һай-й, рәхмәтләр генә яусын инде үзеңә, Җәүһәрия җаным! Коткардың бит, таки...— Зәйтүнә, төенчекне алъяпкычы белән каплагандай итеп, кече якка кереп югалды.

Җәүһәрия дә, мин китим әле дип саубуллашып, ишеккә таба юнәлде. Гази, урыныннан кубып, кызны озата чыкты. Баскыч төбендә, җаен

туры китереп, сүз дә катты. Әллә ни уратып тормады: «Туганлашырга җыенабыз икән әле».— дип турыдан гына ярды. Кызның сылу йөзенә кабат елмаю кунды, башы янә түбән иелде. Әмма Газиның әйтергә теләгәне, әйтергә җыенганы бу түгел иде. Ахырда тәмам үзгәргән, житдиләнгән тавыш белән эндәште: — Җәүһәрия, ускәнем, бер үтенечем бар сиңа... Хәзергә үзең генә бел. Мине дә алырга торалар. Саубуллашырга дип кенә кайттым. Үтенечем шул: әнине ташлап бетермәгез, яме. Үзең беләсең, армиягә алыну гына түгел бит...

Кыз да, сүзнең нәкъ шул турыда буласын белеп,әйтер сүзләрен дә алдан ук ятлап куйган диярсең.

— И-и, Гази абый! — диде ул.— Шаккатам! Үзегез дә инде... Бу турыда әйтеп торуның кирәге дә юк иде...

Ләкин авылдагы яңалыклар моның белән генә чикләнмәгән булган. Хәбәрнең иң зурысы, Газиның фикерен чуалтып, бер авыз сүз белән сынын катырганы, бусага аша атлап өйгә кергәч көткән икән.

— Гази, синме? — дип сорап куйды ана кеше, ишек ачылып-ябылуны ишеткәч.

— Мин, әни.

— Баядан бирле әйтергә дип җыенам, һаман җае чыкмыйча тора,— дип башлады Зәйтүнә сүзен.— Ни ич... Рәхимҗан абыең кайтып төште бит әле.

Гази:

— Кайсы Рәхимҗан? — дип сорау бирүен үзе дә абайламыйча калды.

— Кайсы дип, Рәхимҗан абыең бер генә иде ич. Иргали күршеләр белән Себергә киткән Рәхимҗан...

Газига әллә нәрсә булды, бөтен тәне кинәттән дертләп китте. Йөрәген әллә нинди тыелгысыз сагыш чеметтереп алуын тойды. «Гөлүсә... Гөлүсә янынннан кайткан...» Ул да булмады, күңел түрендә чынлап нечкә генә кыл өзелгән сыман әрнү сызып үтте. Тын алуларына кадәр үзгәрде. Бермәлгә ул үзен өн белән төш арасында буталып калгандай хис итте. Берсеннән-берсе яманрак уйлар өермәсе. «Гөлүсә... Исәнме икән? Кем белә, бәлки инде ул Гази өчен күптән юктыр...» Ничәмә-ничә еллар буе сызып, әрнеп торган. мәңге төзәлмәс җәрәхәте кинәт кенә кабат яңардымыни!..

Гази чак кына һушына килә башлау белән, үз-үзен кулга алырга булды. Күңелендәге үзгәрешне сиздермәскә тырышып, алай гына да түгел, хәтта бөтенләй исе китмәгән бер кыяфәт белән сораштыра башлады.

— Кайчан кайтты?

— Ике-өч көн генә әле.

— Үзе генә кайтканмы?

— Үзе генә...

— Кемнәрдә туктаган?

— Салиха карчыкта ди.

«Менә, кеше тормышы үз күчәре тирәсендә бер әйләнеш ясаган да...» дип уйлап куйды Гази. Ай-һай, мәзәк тә соң бу язмыш дигән нәрсә! Үе башкада булса да, теле икенчене сөйли:

— Безгә кердеме?

— Кереп чыкты. Абау, ходаем, кыяфәтләре! Чыкмаган бер жаны гына бар. Үлгән кешенең өрәген күргәндәй булдым. Бигрәкләр бетешкән инде, йөзенә балавыз сарысы йоккан. Как сөяккә калган. Чит-ят жир җилсез киптерер дия торганнар иде, тәгаен шулдыр.

— Чирләде микәнни?

— Әйе, саулыкка туя алмаган. Себер һавасы килешми ди үзенә. Салкын тын юлларын өтәли, үпкәләрне меңгә телә ди. Шул инде, яшьлегендә кыйналулар, күкрәк читләкләрен издерүләр эзсез генә узамы соң...

Гази әнисен урта бер жирдә бүлде.

— Чакырмадыңмы соң? Чәйгә дип әйтүем.

— Һәй-й, тиле! Чакырмыйммы соң! Гомерлек күршеләр булдык, кадер-хөрмәтләрен дә күп күрдек.— Әнисенең куна такталарын каккалап, иләк дөпелдәтә башлавы аермачык булып ишетелеп торды.— Тик менә, ике-өч көнсез дә керә алмам, берничә кешегә вәгъдә иттем диде. Кичә Сабир абзыйларда булган. Аның Себер хәлләрен сөйләвен ишетер өчен ярты авыл җыелган ди.

Бу хәбәрдән соң, билгесез бер куаныч кичерә башлавын тойган Гази, янә сорау бирде.

— Башкалар исән-саулар диме соң?..

Әнисе аның соңгы соравын әллә инде ишетмичәрәк калды, әллә инде ишетеп тә җавап бирергә ашыкмады. Ул бермәлгә тынып торды. Аның әйтер сүзләренең тышка бары тик авыр көрсенү булып кына чыгуын Гази бүлмә такталары аша аермачык ишетте.

Бу минутларда Газиның да җанында мең төрле кадерле мизгелләр җанлана, җанын сызландырган моңлы, ләззәтле тойгылар чайкала иде. Уйлый калсаң, чыннан да, акыл ирешмәс, җан җилкендергеч яңалык иде бу. Ул бүген үк, юк, менә хәзер үк сәгате-минуты белән Рәхимҗан абыен күреп, җанын, бөтен барлыгын биләп алган сорауларына җавап табарга тиеш.

Бакса, әнисе аның: «Башкалар исән-саулар диме соң?» — дигән соравын ишеткән ләбаса! Әнә ул, коштабак төбенә агач кашык белән еш-еш бәргәләп — тоз эретә булса кирәк — янә авыр көрсенеп, бары тик бер авыз сүз әйтте:

— Һи-и, балакай! Булган ди анда хәлләр!..

Ләкин Газиның Себер кадәр Себердә ниләр булганын төпченеп торырлык тәкате калмаган иде инде. Ул: «Әни, мин хәзер әйләнеп кайтырмын...» — дип, аннан-моннан гына киенде дә, чыгып та йөгерде. Зәйтүнәнең: «Ишетсен колагың, озаклап йөри күрмә, тиздән аш өлгерә, бәбкә каз...» дигән сүзләре генә ишетелеп калды. Нәрсә дисең соң тагын? Яшьли сөйгән ярны югалтудан да яманрак нәрсә, аннан да ачырак хәсрәт юклыкны, әллә ана күңеле сизми иде дисеңме!

Гази көрт ера-ера, бакча артлатып кына йөгерде. Гөлүсә! дип, бу инде аның беренче тапкыр гына канатлануы түгел иде. Моннан берничә ел элек тә шулай: тиздән, бик тиздән очрашабыз, күрешәбез, дигән өмет чаткылары кабынган сыман булган иде. Ил өстенә: Иргалине тәки аклаганнар икән, хөкемдә хаталык җибәрелгән булган дигән хәбәр таралып өлгергән иде. Ышанычлы кешеләр авызыннан чыккан иде ул сүз. Хак булса, Себер тикле Себердән кайтмый калыр идеме.

Гази шундый уйлар белән Салиха карчыкның абзар-лапассыз өенә барып җиткәнен сизми дә калды. Анда аны «ялган» йозак каршы алды.

Көтмәгәндә-уйламаганда алынган әлеге хәбәрдән җаны тәмам урыныннан купкан, тәкатен җуйган Гази: «Инде нишләп карарга?» — дип ут йотып, кыбырсый ук башлады. Әмма, нәкъ шул вакытта ул, тоташтан йонлач киемгә төрелгән бер кешенең ат юлыннан тар сукмакка төшеп, капкага таба якынлаша башлавын абайлап алды. Гәүдәсен тотуына, атлау рәвешенә караганда, бу, һичшиксез, Рәхимҗан булырга тиеш иде. Әнә җилкә-иңнәре төшкән, башы иелгән, гүя ул туган-үскән якларына кайткан да күптән югалткан һәм мәңге таба алмас нәрсәсен эзли чыккан диярсең. Аның бөтен килеш-килбәтендә, гәүдәсен тотышында, ниндидер кара хәсрәткә чуму, китмәс яман чирдән изалану галәмәтләре бар иде.

Гази аны җил капка янында каршылады. Ул инде: «Исән-имин генә кайтып җиттеңме, Рәхимҗан абый!» — дип, җан күршесен кочагына да алмакчы иде. Әмма аны бу адымыннан берьюлы берничә төрле сәбәп тыеп калды. Бердән, Рәхимҗан абыйсының үз-үзен тотышында ниндидер өнәмәү, читләшү сыман нәрсә барлыгын тою булса, икенчедән, күршесенең яртылаш ак мамык шарфка төрелгән йөзенә күз салу булды. Чыннан да, үләргә кайткан икән бу, дигән уй чагылып китте Газиның башында.

Ямьсез кара төс кунып ябыккан чырае күм-күк, яңаклары баткан, йонлач бүреге астында чокыраеп торган күз тирәләре күләгәле. Шуның өстенә тагын, тын алганда, күкрәкләре, сулыш юллары, бозык гармун күреге кебек, берьюлы берничә төрле зәгыйфь аваз чыгарып гыжылдый иде.

Газиның андый чакта хәл-әхвәл сорашып әйтелә торган гадәти сүзләренә каршы ул калкына-калкына ютәлләү белән генә җавап кайтарды. Гази кабат: «Әйе, тәмам беткән бу»,— дип уйлап куярга мәҗбүр булды.

Рәхимҗан шарф белән томаланган авыз-борынын ачмыйча гына: «Әйдә, керик»,— дип, ишеккә таба ишарә ясады. Керделәр. Урамдагы беренче тәэсире өйгә кергәч, Рәхимҗан өс-башын салып элгәч тә үзгәрмәде. Өске өлгеләре генә калдырып капланган, ачык өлеше дә ярым тунган тәрәзәләрдән яктылык саран саркып керә иде. Мондый өйдә Рәхимҗанның саргаеп суырылган, балавыздан койганга охшап калган йончу йөзе тагын да озынчаланып, тагын да шыксызрак булып күренде.

Сүзне шактый сәер башлады Рәхимҗан. Утлы күмер кебек янып торган күзләре белән Газиның йөзенә бермәлгә текәлеп карап торды да әйтә салды:

— Белмим, моннан ике-өч ел элегрәк ничегрәк очрашыр идек икән. Һәрхәлдә, болай күрешә алмас идек... Йөзеңә үк төкермәсәм дә, сәламеңне алмаган булыр идем...

Гази бу сүзләрнең мәгънәсенә төшенә алмый, аны ни дип юрарга да белми, бермәл аптырап торды. Аннары инде, Гөлүсәне үз янында калдырмыйча, адәм әйтеп адәм ышанмаслык бәла-казаларга дучар иткәнем өчен дер дигән нәтиҗә ясады. Ул инде: «И-и, Рәхимҗан абыем ла! Сез бер утта янсагыз, мин берьюлы мең утта яндым. Үкенүемнән үләр дәрәҗәләргә җиттем», дип аһ-зарын белдерү өчен авызын да ачкан иде. Әмма тегесе, әйтер сүзен әйтми калмагаем дигәндәй, берсеннән-берсе авыр сүзләрне тезде дә тезде. Гөлниса апасының илерә-илерә каргауларын да, «изгелеккә яманлык белән кайтаручы эт җан икән», дип тиргәүләрен дә, ике сүзнең берендә Газиның исемен ләгънәт белән телгә алуларын да калдырмады.

Бу сүзләр сагайта калды Газины. Хәер, җан күршесен беренче күрү, эчкә баткан күз карашларыннан сирпелгән яман салкынлыкны тою белән үк, ул юньле сүз ишетмәячәген, көткән әңгәмә булмаячагын чамалаган иде инде. Әмма Рәхимҗан абыйсы күңел төбенә мәңге эрүе бетмәс боз булып ятарлык сүзләрне соңгарак калдырган икән.

— Кыз бала ышаныч күрсәтә, дип андый түбәнлеккә бармыйлар аны. Чын ир-егет эше түгел ул. Кыз баланың абруе чук өстендә, аннан төшсә — чүп өстендә ди. Кыз баланың бәхетсезлеге намусы тапталудан башлана, гомере эрнү, үкенеч белән үтә...

Бу сүзләр инде Газины өнсез иттеләр. Бермәлгә зиһене чуалып киткән сыман булды. Чү-ү!.. Бөтенләй башка нәрсә турында сөйли түгелме соң бу? Шулай ич! Очрашканнан бирле тикмәгә генә кыз баланы кан елаткан намуссыз бәндәгә караган кебек карамагандыр.

Ахыр чиктә түзәр чамасы калмады Газиның.

— Ни сөйлисең син, Рәхимҗан абый? Нинди адым турында гәп алып барасың әле син? Кемгә саныйсың син мине?..

Тегесе күзен дә йоммады.

— Чәчәкне койган булгансың ич...

Гази искәрмәстән әйтелгән сүздән янә югалып, янә өнсез калды. Аягы астындагы идәннәрнең бер читкә шуышуларын тойгандай булды.

— Нинди сүз бу, Рәхимҗан абый! Нинди нахак сүз?!— Егетнең тавышы чатнады. Бер селтәнүдә, бер сүз белән үзенең гөнаһсызлыгын аңлата алмаудан ул ут бөркеп утыра иде.— Беләм... Үзем дә беләм... Гөлүсә алдында мин соңгы сулышымны алганда да гафу ителмәслек гаепле. Тик ул яктан түгел. Әгәр дә ул яктан катрә бөртеге кадәр генә гөнаһым булса да, аяз көнне яшен суксын, баскан урынымда җир убылсын! Әнием белән ант итә алам...

Элеккеге авылдашының сырхау йөзендә, эт кояшы сыман сүлпән генә шәфкать чалымнары чагылып, миһербанлык нурлары кабынгандай булды.

— Җә-җә, тынычлан, Газиулла,— диде Рәхимҗан, бераз көттереп кенә.— Сүзләрең хак. Соңыннан бар да ачыкланды... Ахыр чиктә Гөлүсә үзе танырга мәҗбүр булды. Баштарак сиңа биргән вәгъдә-антларына турылыклы булып калу өчен үз-үзенә яла яккан булган...

— Нәрсәгә кирәк булды соң андый хәлләр?..— дип өзгәләнде Гази. Тавышы тулы әрнү-уфтану иде аның.

— Булды инде... Кияүгә сорап, яучы килгәч купты ул низаг-зилзиләләр...

— Чыкмадымы соң?

— Юк, чыкмады. Сине оныта алмый ул, Газиулла.

Гази йөрәге әрнүгә чыдый алмаган сыман, кулларын күкрәге турысына кушырды.

— Эх-х, Рәхимҗан абый! Бер генә күрәсе иде үзен. Аннары үлсәм дә үкенмәс идем...

Күршесенең йөзендә сүлпән генә елмаю сыман нәрсә чагылып үтте. Бары тик шунда гына Гази, хисләренә бирелеп, артык сүз ычкындыруын абайлап алды. Үзен тизрәк кулга алып төзәтенде дә, сорау артыннан сорау яудыра башлады.

— Димәк исән?! Гөлүсәне әйтәм...

— Исән.

— Синең аша хат-фәлән җибәрмәдеме соң?

— Хат җибәрмәде. Ә миңа сәламнең иң кайнарын юллавымны үтенде. Бөтенләй үк онытып бетермәсен мине диде.

— Онытаммы соң?!

Рәхимҗан абыеның кабат чыгып китәргә җыенуын чамалап алды Гази. Шунлыктан, сүз югында сүз булсын дигән кебек итеп, әнисенең үтенеч-гозерен тагын бер тапкыр күршесенең исенә төшерде. Тегесе ике-өч көннән һичшиксез керәчәген әйтте. Иң әүвәл, баштарак вәгъдә иткән кешеләрдә буласы бар икән.

Хәзер исә ул югары оч Туктар картларга җыена иде. Кечкенә генә булса да күчтәнәч кыстырып бармыйча ярамас, килешеп бетмәс дип, алдан ук хәзерләп куелган шул күчтәнәчен алырга кайткан булган. Соңрак, үт алгачрак, Газига да шунда барып чыгарга кушты.

— Кич утырырбыз. Кичәгенәк тә халык бик күп җыелган иде. Авылдашларының язмышлары, хәл-әхвәлләре белән бик кызыксыналар...

Шул арада Рәхимҗан, сәке йөзлеге буенда торган, кечерәк сандыкка охшатып чыбыктан үрелгән әрҗәдән тәмәке янчыгы кадәр генә капчыкка салынган бер төенчек чыгарды. Монысы — Себер күчтәнәче — әрбет чикләвеге иде.

— Борының кычытмадымы? — дип, Гази кесәсенә дә бер кушуч чикләвек салды.— Белеп аша, үзем әзерләгән чикләвек.

Рәхимҗан яңадан киенде. Кичен очрашырга сүз куешып, урамга чыктылар.

Кичне көтеп ала алмыйча тинтерәп бетте Гази. Үзенә урын тапмады. Шулай да түзде Гази, чыгып чапмады. Әнисе белән бик тәмләп гәп сатып утырдылар. Күбрәк Зәйтүнә сөйләде. Кабат авылдашларын телгә алды. Рәхимҗан әйткәннәрне исенә төшерде. Мәсәлән, Себергә барып урнашу белән, Иргалине бригадир итеп сайлап куйганнар. Алтын җирдә ятмый шул ул дип, үзенчә нәтиҗә ясап куярга да онытмады.

Ә инде кояш баеп, яртылаш карга күмелеп утырган авыл өйләренең тәрәзәләрендә тычкан уты кебек кенә яктылык күренә башлау белән, Гази югары очка йөгерде. Ул Туктар картларга барып кергәндә, табын инде җыештырылган, шактый гына халык та җыелырга өлгергән иде. Өй һавасында итле шулпа, таба ашы исләре саклана иде әле. Хуҗалар Гази-

ны, яманлап йөрисең икән, авылдаш, дип, чак кына шелтә белдереп каршыладылар. Шулай да чәйләп алырга кыстагандай иттеләр.

Ул арада ишек артында, өйалдының туңган идәннәрен дөбердәтеп, дөпе-дөпе китереп итекне итеккә бәргән тавышлар ишетелде. Гази да, стена буендагы озын эскәмиядә утыручылар арасында урын табып, тиз генә шунда чүкте.

Ишектән, үзләренә мул итеп салкын иартеп, тагын берничә кеше керде. Гадәттәгечә шау-гөр килеп хәл-әхвәл, исәнлек-саулык сорашулар башланды. Өлкәннәр артыннан тагын бер төркем яшь-җилкенчәк керде. Бераздан инде утырырга яраклы, букән, урындык ише нәрсәләр дә бетте. Малай-шалайлар идәнгә, бозау бәйләнгән аралык тирәләренә урнаштылар. Ишек төбе дә буш түгел иде хәтта. Барысы да Рәхимҗанның Себер хәлләрен сөйләвен тыңларга килүчеләр иде.

Өйнең яртысын алып торган сәке йөзлегенең урта бер җирендә, асылмалы лампа каршында, Рәхимҗан утыра. Күрде Гази: элеккеге күршесенең йөзенә йоккан хаста сарылыгының эзе дә калмаган. Әнә ул, кәзәки изүен чишеп җибәргән дә янәшәсендә утыручылар белән нәрсә турындадыр сөйләшә, хәтта елмаеп та куйгалый. Йончыган йөзенә җан кергән, күз карашларына кадәр үзгәргән аның.

Җыелган халык, төп хикәяче, ягъни Рәхимҗан сүзгә керешкәләгәнче, бедер-бедер килеп, үзара гәп сата. Ничектер үзеннән-үзе, алдан ук сөйләшеп куйган кебек, авылдашлары тарафыннан Иргалинең исеме телгә алынды. Кемдер аның таза йөрәкле, корыч ихтыярлы булуын, солдаттан кайтып төшкән чакларын искә төшерде.

— Кайдан килгән диген син аңа шул тикле көч-гайрәт? Йокыны ялны белмәс иде. Башкаларның төшенә дә кермәгән уңыш җыеп алыр иде...

— Әйтмә дә! — дип элеп алды икенчесе.— Ул иккән игеннәр дугалы атларны күмәрдәй булыр иде, хикмәт.

Гази да Иргали абые турында уйланып утырды. Әлегрәк ул аны үзе өчен үрнәк кешегә санады. Чыны шул. Ниндидер кайгы-хәсрәт кичерүләр, бәлаларгә дучар булулар — ул әле батырлык түгел. Ә менә шул күтәрә алмаслык бәла-казаларны, ачы хәсрәтләрне эченә йотып, дөньясына ләгънәт укымыйча, еламый-нитми, төшенкелеккә бирелми, кеше булып калу, бу инде теләсә кемнең кулыннан килә торган эш түгел.

— Хаксызга рәнҗеттеләр кешене,— дип куйды кайсыдыр.

— Әйтмә дә! — диде икенче берәве.— Бигрәк караладылар шул үзен. Ил-көн каршында рисвай иттеләр. Иң яманы — кеше үтерүче исеме тактылар...

— Хет бер авылдашы яклап кыл селкетсен!..

— Бездә шул инде. Аның юктан бар булып, кешечә яши башлавын күралмадылар. Юкта — бирә алмый, булса — күрә алмый, дип тиккә генә әйтмәгәннәрдер.

Күңелләре сызган кайберәүләр: «И-и, бу коргыры тормышны!» — дип, хәсрәт ялкыны өреп, көрсенгәләп тә куйгаладылар.

Сүз ярә сүз китеп, кемдер Иргалине хөкем иткәндә хата җибәрүләре, аның акланы турында искә төшереп алды.

— Шундыйрак хәбәр таралган иде. Хак булдымы шул сүз?

— Хак иде,— диде Рәхимҗан.

Янә сүз куертып алдылар. Алайса нигә борылып кайтмады, янәсе. Әй-йе шул, дип дәвам итте икенчесе. Чит-ят җирдә яшәү түгел, үлүе дә яман бит. Гарьләнгәндер, артык ямьсез кыландылар шул дип, Иргалинең хәленә керергә маташучылар да табылды.

— Ул хәбәрне алырга Иргали абый белән бергә бардык,— диде Рәхимҗан, бу әңгәмәне түгәрәкләргә теләгәндәй итеп.— Ул вакыйга үзе бер хикмәтле, гыйбрәтле хикәя, иркенләбрәк сөйләрмен әле...

Төп сүзгә керешергә вакыт та җиткән иде инде. Шулчак Рәхимҗан искәрмәстән генә: «Кичә кай тирәдәрәк туктаган идек әле?..» — дип сорап куйды.

Берьюлы берничә яктан җаваплар яңгырады.

— Кызыл Ярга, ягъни Красноярскига барып җиттегез...

— Һәммәгезне дә этап дворына китереп яптылар...

— Ә, әй-йе! Шулай бугай...— дип ялгап алып китте Рәхимҗан.— Соң шул! Поездан төшерделәр дә, янадан бик җентекләп барлап, этап дворына алып киттеләр. «Двор» дигәч, әллә берәр станция ише җирме, дип уйлаган идем. Карасам, хәйраннар калдым: тирә-юне биек койма белән уратып алынган, кечерәк бер авыл тикле урын икән. Як-якта озын бараклар тезелеп киткән. Ара-тирә аерым йортлар, лапаслар да күренгәли. Иң күзгә ташланганы — килеп бөялгән олауларның күплеге иде. Бер дә исәбе-хисабы юк. Тормыш дулкыннары тарафыннан кагылган, кыйблаларын югалткан халык. Урта бер җирдә, мәйдан шикеллерәк урында, ду китереп сату итеп, алыш-биреш оештырып мәташәләр. Печән, солы ише нәрсәләрне йөге белән кала базарыннан китереп, «Двор» капкасы төбенә китереп сатуларын да абайлап алдык.

Безнең белән бер поездда килүчеләрнең барысын биек койма буенарак кысрыкладылар да, шунда урнаша торырга куштылар. Бик юл өстенә туры килмәвебезгә дә шатбыз. Атларны туардык, арбаларны җайлап куйдык. Илдә илле, берсеннән-берсе җилле дигәндәй, кырык мирдән җыелган халык, шунлыктан алны-артны чамалау, итәк-чабуны җыебрак тоту турында да онытты юк.

Сиражи исемле бәндә дә безнең янда. Ат-арбаларыбыз бер вагонга туры килү сәбәпле, юлда ук танышкан идек. Камышлы ягыныкы. Аның хәле безнекенә караганда да мөшкел. Хатыны белән икесенә өч бала. Җитмәсә тагын өчесе дә, кем әйтмешли, аяксыздан ыштансыз. Хатыны Мәрьямбикә атлы. Кыяфәте бик бетәшкәнгә охшый. Эчендәге хәсрәте ярылып яткан моңсу йөзендә чәй тәлинкәсе кадәрле олы күзләр генә. Кулында әле яңа күкрәктән аерган сырхау бала. Бала җанлы, бик кешелекле Сиражи безнең белән якынаюына сөенеп бетә алмый. Әлеге алла орган «сәяхәткә» чыгуының сәбәбен дә әллә ничә тапкыр сөйләп бирергә өлгерде. Колхоз төзелгәч тә: мал-туарны ярата дип, атлар карарга куялар моны. Ике-өч ел буена исеме макталып телдән төшми. Әмма көннәрнең берендә, җәйге матур таңнарның берендә, кырыктан артык ат төнгелектән кайтып керә. Сиражи инде күптән эш урынында. Янәшәдә торган коедан су чыгарып, салкыны сынв торсын дип, озын улакка тутырып куя. Тузан болыты күтәреп ажгырып кайтып кергән атлар, гадәттәгечә, озын улак янына килеп тезеләләр. Шунда көтелмәгән хәл була: сәгать-сәгать ярым эчендә бер-бер артлы унтугыз баш ат гөрселдәп җиргә ава. Кайберләре җиккән чакта, тәртә арасына кергәч аяк суза, берничәсе аранга кереп тәгәрәп үлә. Соңы шул — тикшерүләр башлана. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән әллә ниткән гаепләр актарып чыгаралар. Һәм, рәхим ит... Колхоз милкенә кул сузган корткычлар өчен Себер юлына үлән үсмәгән, янәсе.

Рәхимҗан, шактый ук эзлекле итеп, сөйләгәннәрен күз алдына китерерлек бастырырлык итеп сурәтләп, барысын да таңга калдырып, хикәяләпме-хикәяли.

Газиның үз уе. Бөгелмә станциясеннән ничегрәк итеп чыгып китүләрен, Красноярскига кадәр ничек барып җитүләре турында ишетә алмый калуына уфтанып утыра. Шундук: соңрак җаен туры китереп, бер сораштырырмын әле дип, үз-үзен тынычландырып та ала.

Рәхимҗан барысын да авызына караткан.

— Ятабыз шулай этап дворында ут йотып. Көн артыннан көн үтә. Барасы юл, җитәсе җир турында ләм-мим, беркем берни белми. Шул билгесезлек үтерә, пычаксыз суя. Һай-й, ул билгесезлек! Киләчәгеңдә, иртәге көнеңдә ни көткәнен белмичә яшәүдән дә яманрак нәрсә юктыр бу дөньяда. Бу хәл кешенең йөрәгенә шом сала, күңелен астыртын шик талый. Кая карама — аһ-зар. Билгесезлек афәте өркеткән халык нәкъ җил туздырып тузганак диярсең инде менә, мәш килә. Менә шундый чакта ке-

шеләр бер-берсенә елышучан булалар. җиде-ятка карата да якташлык хисе, туганлык тойгысы уяна. Андый чакта туган якның эте дә якын дин мәсләр иде аны.

Вакыт табып, этап дворын әйләнгәләп тә чыккаладым. Кая карама — мәхшәр, көне. Арабызда кая барып бәрелергә белмичә иңрәп, югалып-каушап калучылар да бар. Тавыкның бар сәяхәте — ындыр арты дигәндәй, гомерләренә авылларыннан ары җир күрмәгән бәндәләр дә очраштыргалый.

Тикмәгә генә — кеше тәмугка кергәндә дә юлдаш эзли димәгәннәрдер. Карыйм, шулай билгесезлек алдында шүрләп, югалып калучылар бер-берсенә елышу, берсе икенчесен барлау ягын карыйлар. Ничектер үзеннән-үзе шулай чыкты, бик күпләр, ниндидер өмет баглап, Иргали абый янына елыша башладылар. Бер караганда, гаҗәп тә түгел шикелле, чөнки һәркем көчлерәк затка, үзенә арка таянычы булырлык кешегә тартыла. Иргали абыйның шыңшымавын, бернәрсәдән дә зарланмавын, офтанып кутәрелеп бәрелмәвен, үз-үзенә нык ышанган кешеләргә генә хас тынычлыгын күреп, чыдам, нык, утны-суны кичкән, дөньяның ачысын-төчесен күп татыганга охшаганлыгын бик тиз чамалап алдылар. Заманында берничә ел Кызыл Армия сафларында да булганлыгын белгәч, аңа ышану икеләтә артты. Андый кеше барында бернинди афәткә дә, гаделсезлеккә дә, кимсетүгә дә юл куелмас, теләгән тәкъдирдә җилянгыр да тидермәс, дип өметләнделәр булса кирәк.

Чыннан да, Иргали абый, үзен ирексез мөсафир, ярым тоткын санап, җебеп төшмәде, өс-башына һәрчак чистаны кияр иде, үз вакытында ялт итеп кырынып йөрер иде. Өстенә үзенә килешеп торган шинелен киеп алды. Үзегез беләсез, төсе-кыяфәте килгән, буй-сыны килешле, ачык чырай, матур йөз. Бөтерелеп килгән гайрәтле мыегы гына да ни тора! Шуның өстенә күп йөргән, күп күргән, күп аралашкан. Русчасы нык. Үзе иблис кебек кыю. Тормыш таҗы — батырлык, дигәндәй, кемнең кем булуы белән санашып тормый, башын горур тотып, аяк терәп сөйләшә ала. Сүзе дә үтә.

Соң шул! Иң элек Касыйм татарлары чолгап алды үзебезне. Бераздан Сембер мишәрләре дә килеп җитте. Һәркайсы безнеңише — язмыш тарафыннан рәнҗетелгәннәр. Кем әйтмешли, кумәклектән күңелләребез күтәрелеп киткәндәй булды. Ни генә әйтмә, үз телебез, гореф-гадәтебез...

Бу хәл этап башлыклары күзеннән дә читтә калмаган, күрәмсең. Беркөн иртән биленә наган таккан бер хәрби кеше Иргали абыйны кәнсәгә чакыра килде. Хатын-кызларга коелып төшү өчен шул җитә калды. Гөлниса апа: «И-и, ходаем ла!» — дип, бизгәк тоткан сыман, калтырана ук башлады. Әмма Иргали абый анда әллә ни озак тормады, ниндидер куанычлы хәбәр ишеткәндәй, күтәренке күңел белән борылып та кайтты.

— Безгә дә сәфәр чыгарга вакыт җитә икән. Татарларның үзләренә бер партия әзерлиләр...— Шундук өстәп тә куйды.— Шул яңа партиягә мине, чегәннәрнең җитәкчесе сыман итеп, баш итеп куймакчылар. Бүген үк исемлек төзи башларга куштылар.

Шул сәгатьтән алып безнең Иргали абый, тәмам күз өстендәге кашка әверелде дә куйды. Моңа кадәр карап-сынап кына йөргән татарлар да, үзләренең риясыз ышанычларын белдереп, моңа чат ябыштылар. Алдан баручы түгел, артыннан ияртә белгән — җитәкче ди бит.

Исемлек төзи башлау белән, алагаем зур, авыр гәүдәсен алпан-тилпән китереп, яныбызга янә бер бәндә килде. Килеш-килбәте абруйлы, укымышлы кешегә тартым. Өс-башы бөтен генә түгел, затлы дип әйтерлек. Язгы кояш туры карап, көндезләрен шактый кыздырса да, башына камчат бүрек, өстенә кара постау тышлы бүре тун, аягына эт тиресе белән җылытылган пималар киеп алган. Кыяфәте — дәрәҗәле. Шуның өстенә, сүз рәвеше дә бик диндар кешегә тартым.

Яныбызга килде дә бу, бик күптәннән бирле зарыгып көткән кешеләрен очраткандай, сөйләнә дә башлады.

— И-и, бәрәкалла! Үзебезнең мөэмин-мөселманнар икәнсез ләбаса. Я-а, раббым! Әһле мөселман кардәшләрне тугры китерүеңә бер түгел мең шөкер. Аллаһе тәбәрәкә вә тәгаләнең рәхмәте зур, шәфкате диңгездәй киң ди шул. Үзегез кай яклардан, кай тарафлардан буласыз соң?

Безнең Чулман буеннан икәнлекне белгәч, янә элеп алып китте.

— Борынгы Чулман ягы — моңлы-аһәңле, белемле-мәгърифәтле төбәк дияләр иде. Борынгы Чулман ягы — моңлы-зарлы, канлы-яшьле тарихлы як, дип тә өсти торганнар иде әүвәлерәк. Әй-йе! — Шулай диде дә бу, рөхсәт-фәлән сорап тормыйча: «Яле бер дога!» — дип, арба янына чүгәләде дә, бөтен шартын китереп, әгузебисмиллаларын укырга керешге. Озак укыды. Ахырында учлары белән симез-итләч йөзенә килешеп торган чаларган сакал-мыекларын сыпыргалаганнан соң янә сөйләнеп алды.

— Риясыз ниятләү догасы булса, кайда зекер ителсә дә, кабул итәрмен, рази әйләрмен дигән хак тәгалә. Беренче күрүдә үк искәрдем: иманлы, шәфкатьле, тугрылыклы бәндә күренәсең. Кордаш-ыру, зат-кавемнәрегезгә, барлык әрвахлар шәрәфенә багышланган догам булсын, берүк!..— Карт иелә төшеп, симез, табак битен яшерә төшеп, елап та алды кебек.— Гафу итә күрегез, кан кардәшләрем... Нишлим соң?!. Туып-үскән җирләрдән аерылу кеше йөрәгенә шулай гомере буе төзәлмәс яра-җәрәхәт сала торгандыр шул инде. Фани дөньядан бакый дөньяга китәсе көннәрем дә бик житкән кана да бит!.. Нинди гөнаһларыбыз, кайчан кылган языкларыбыз бәрабәренә мондый җәзаларга, бәла-казаларга дучар ителәбездер. Яа-а, тәңрем!..

Шунда ук үзе белән дә таныштырып алды. Оренбург ягыннан икән. Исеме Шаһиулла. Галим-голәмә, укымышлы кеше икән. «Һәр тарафта олуг ихтирам казанган имам-хатиб, мөгаллиммен,— дип таныттьы үзен. Заманында «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыган.— Мәҗнүн бер руханимын. Диния нәзарәтендә рәсми дәрәҗә били идем, ягъни казый идем...» Кыскасы, үзен һич тә алыштыргысыз кеше итте дә куйды бу. Әлеге «алла тарафыннан каргалган» сәфәргә дә ул «үзе теләп», каенесен озата бару максаты белән чыккан. Каенесенең исеме Шаһбаз. Әйтүенә караганда, бик тә зиһенле, бик тә укымышлы, бик тә тәүфыйкълы бала икән.

Ахыр чиктә үзенең гозерен дә житкерде.

— Зинһарлап сорыйм, кем, изге бәндә... Безне дә үзеңнән калдыра күрмә. Ходай тәгалә хаҗ кылган саваплар бирер үзеңә. Алладан ярдәм, изгеләрдән мәдәт сорап, сәҗдә кылырмын. Күңелем сезгә карата гелән изгелектә, хәер-дога кылмакта булыр, ходай кушса. Алла хакы өчен дип сорыйм... Ике догамның берендә сезнең иманлы, рәхимле, шәфкатьле исемеңезне яд итәчәкмен, ходай кушса.— Салпы якка салам кыстырып куярга да онытмады, әлбәттә,— Алла илчесе Мөхәммәткә Җәбраил фәрештә аркылы күктән иңдерелгән изге Коръәндә мондыйрак аять бар. Тыңлап кына бакчы, кем, мелла, нәкъ синең кебек изге күңелле җан турында әйткән диярсең инде менә: «Алла туры юлдан алып барырга теләгән кешенең күкрәген ислам өчен киңәйтеп җибәрә, кемне юлдан яздырырга теләсә, аның күкрәген тарайтып куя». Хәтереңә иңдереп куй, кем, бу гыйбрәтле сүзләрне...

Олы җанлы, киң күңелле Иргали абый аларны да исемлеккә теркәде. Карт бик тә кызганыч бер кыяфәткә керде дә, сүзнең җеген-җеккә китереп, тәмләп кенә, көйли биреп, сөйләвен белде.

— Аллаһе тәгалә кешене каргаса, картлык көнендә туган туфрагыннан аерсын икән. Актык сулышымны ата-бабаларыбызның сөякләре күмелгән мөкатдәс җирдә, изге җирдә алырмынмы әллә дигән идем, язмаган икән. Я-а, ходай, гафур рәхим! Гомерләр аккан, язмышлар кичерелгән, кайгысын-хәсрәтен, шатлыгын-куанычын кичергән туган җир бит ул! Инде дә шушындый, туган җирләрне ташлап чыгып китү кебек иң каты, котылгысыз җәзага дучар ителгәнбез икән. Габдерәхим хәзрәт Утыз Имәни әйткәнчә: «Зәгъре михнәт чикте җисмем, тулды күзем зәгъре аз», ягъни, тәнем михнәт ачысы чикте, күзем яшь белән тулды, диясе генә

кала. Янә дә килеп бу хәлләрне ходай тәгалә безне сынар өчен җибәргән диясе, һәм дә килеп, диндәшләр буларак, тормыш мәшәкатьләребезне уртак итәсе кала. Беренче күрүдә үк сине, кем, мелла, аек иманлы зат, мәрхәмәтле кеше икәнлегеңне абайлап калдым. Бу изгелекләреңне соңгы сулышыма чаклы онытасым юк. Бөтен затың игелек күрсен. Боерган булса, һәрчак ярдәм булырбыз. Үз чиратымда мин дә бурычлы калмам... Мөхтәрәм ил карты, хөрмәтле аксакалы булырмын. Янә дә килеп, фикердәшең, мәсләктәшең булырмын. Киресенчә, терәк-таянычың булырга әзермен. Фидаиләрчә хезмәт кылырмын үзеңә. Дөнья булгач, үлем-чыгым, дәфен кылу ише нәрсәләр дә булмый калмас... Әй-йе! Шуңа күрә тормыш диләр аны. Балаларга сабак тыңлатырмын, гыйлем-мәгърифәт, тәрбия бирермен, аңлы, итагатьле булып үсәрләр. Акмулламыз болайрак фараз кылган:

> Адәмгә гыйлем, һөнәр пар канаттыр,
> Дөньяда гыйлем кеше асыл заттыр;
> Наданнар, беләсез бит, алла колы,
> Җактыны күрәлмәгән җарканатдыр...

Шул ук кичне Шаһи картның туганнан-туган энесе Шаһбаз да күренеп китте. Кунакка барырга чыккан диярсең егетне: киенгән-ясанган. Карчыганыкы кебек үткен зәһәр караш. Күсе койрыгы кебек нечкә мыегының чылгыйлары асылынып тора. Җае чыккан саен ул аларны әледән-әле аска таба тарткалап алгалый. Килеш-килбәт, буй-сын нәзакатле. Аксөякләр затыннан икәнлеге һәрбер хәрәкәтеннән сизелеп тора. Чегәндәй каратут йөзле, очкыннар чәчеп торган әрсез үткен караш. Юк, гади күз карашы түгел бу, карчыга карашы, кешене үтәдән-үтә тишәргә теләгәндәй итеп, ачыктан-ачык оятсыз-туры караш иде...

Гази, Рәхимҗан абыеның әлеге карт белән аның каенесе Шаһбаз турында тикмәгә генә шулай төпченеп, кабат кайта-кайта сөйләмәвен күңеленең кай җире беләндер сизенә дә башлаган иде инде.

— Исемлекне этап башлыгына илткәндә,— дип дәвамлады Рәхимҗан үзенең хикәясен.— Иргали абыйга мин дә иярдем. Анда Иргали абыйга карата булган мөнәсәбәтне күреп, кабат хәйран калдым. «Гражданин Миргалиев» дип кенә торалар. Кешенең абруе тирә-юнендәгеләрнең мөнәсәбәтеннән үк күренеп тора шул.

Иргали абый тәкъдим иткән исемлекне тикшерә-карый башладылар. Терки торгач, егерме өч олауга җиткәнбез. Барлыгы сиксән җиде кеше. Һәрбер кәгазь кисәген күздән кичерделәр. Иснәп кенә карамыйлар инде, мин сиңа әйтим!

Шулай да катыргы тышлыкка тегелгән бер «Эш»не: «Монысы хәзергә калып торсын әле»,— дип, бер читкә алып куйдылар. Документларның Шаһиулла карт белән аның каенесе, Шаһбазныкы икәнлекне белгәч, Иргали абый аларның ни өчен калдырылуының сәбәбе белән кызыксынды.

— Без аларны Себернең түренәрәк озатыласы партиягә билгеләргә дип торабыз,— диде биленә наган таккан хәрби киемле начальник кеше.— Статьялары үзгә... Гомумән, нәрсәләре беләндер күңелемә ятып бетми алар. Сизәм, куллары канлы аларның. Ниндидер могҗиза белән генә атылмый калган булырга тиешләр...

Иргали абый да һәр сүзгә буйсынып, дәшми кала торганнардан түгел. Картның бик нык ялынуын, гозерләвен, бик инде татарлар белән бергә булырга теләгеен белдерүен әйтте.

— Ә инде статьяларга килгәндә, беребез дә аларны сайлап алмадык,— диде ул ипле генә итеп.— Шулай ук иректә көннән дә йөрмибез... Анннары безне дә турыдан-туры җәннәткә озатырга җыенмый торгансыздыр бит?..

Начальник кеше мыек астыннан гына елмайды. «Үзегезгә карагыз, алайса»,— дип, Шаһи картларның документларын да безнекеләр янына

куйды. «Алабыз дисез икән, рәхим итегез! Тик соңыннан өстәмә мәшәкатьләр тудырып, күңелсезлекләр китереп чыгара күрмәсеннәр дип кисәтеп кенә куюым...»

Иргали абыйны үзегез беләсез, чая, телгә-тешкә үткен: «Зур көтү бүредән курыкмый, әллә ни кыра алмаслар», дип кенә җибәрде.

Шулай да минем якка борылып: «Нишлибез, Рәхимҗан туган, алабызмы үзләрен?» — дип киңәш-табыш итте. Миңа нәрсә, күнсәм дә күндем, күнмәсәм дә күндем. Эх-х, шунда: «Кемнең кем икәнен, Иргали абый, начальство яхшырак беләдер, тикмәгә кисәтми торганнардыр, әллә кабат уйлап карыйсыңмы?» — дип әйтсәм, ак сакаллы карт буласы икәнмен дә бит, кем белгән аларны! Изгелеккә дәгъва иткән кешеләр дә шул тиклем, адәм әйтеп адәм ышанмаслык бәла-казаларга, фаҗигаларга тарытырлар дип кем уйлаган?!

Олауларыбыз янына җыелган халык безнең кайтканны дүрт күз белән көтеп тора иде инде. Иргали абыйның фәрманы кыска булды: «Барыгыз, җыена башлагыз, иртәгә сәфәр!..»

Шаһиулла карт та шунда иде.

— Иншалла! Бу көнне дә көтеп алдык,— дип куйды ул.

Башкалар дәррәү кубып таралыша башласалар да, Иргали абый Шаһи картка чак кына сабыр итәргә кушты. Тегесе сагая калды. Иргали абый хәтер-фәлән саклап тормады, алар турында начальствоның бераз икеләнеп торуларын ачыктан-ачык әйтте дә салды.

— Нинди эш белән гаепләндегез? Статьягыз нинди иде? — булды Иргали абыйның соравы.

Картны алыштырып куйдылармыни! Кашлары җимерелеп кенә калмады, капчыкланып торган авыр, шешенке кабаклары астыннан гына сөзеп караган күзләреннән кинәт суык бәреп чыккан сыман булды. Йөзе агарынды. Сулыш алуларына кадәр үзгәрде моның.

— Алланың ачы каһәре суккыры... Себердән дә ары җибәрерлек әллә ни яманлыклар кылганыбыз юк. Бер аягым җирдә, икенчесе гүрдә дигәндәй, намазлы авыз белән ялган сөйләп тормам бит инде.

Шунда карт, миңа ышанмасаң, менә моңа ышан, дигән кыяфәт белән туныиың түш кесәсеннән таушалып тәмам эштән чыккан кәгазь кисәге чыгарды. Иргали абый: хафаланма, кирәкмәс, дигән сыман итеп, кулын гына селтәде.

— Андый шикле уйларга бирелеп, өстеңә тау кадәрле гөнаһлар ала күрмә берүк, кем, мелла. Шулай ук кара мөһер сугарга да ашыкма... Мөселманлыгыңа оят килер.— Тавышын йомшарта төшеп, янә тезеп китте бу.— Мөселман белән мөселман тылмачсыз да аңлашыр ди. Бар да үз фикереңне әйт... Безгә бик тә кирәкле кеше диген. Чыны шул ич. Бер тапкыр әйткәнемчә, тормыш булгач төрле чак булыр... Мәетләрне үзем юармын, кәфенләрмен, ясин чыгармын. Сәфәрләребезнең дә хәер-догалы булуын юл буе теләрмен, боерган булса. Ә инде барып җиткәч, балачагага сабак бирү эшен үз өстемә алырмын, ходай кушса. Хезмәт хакы-фәлән дә сорамам. Әй-йе! Тик зинһар дип, ялынып-ялварып, алла хакы өчен дип үтенәм...

Иргали абый картны бүтән газапламады, кайтып җыена башларга кушты. Озын юлга, ерак сәфәргә бергәләп чыгачагыбызны әйтте. Карт янә көйләп-вәзенләп дога сүзләренә керешге.

— И-и, ходайның изге бәндәсе! Хәзер барам да иман яңартып, иң изге саналган догаларымны кабатлыйм. Әй-йе! Безгә күрсәткән бу изгелекләреңне ходай тәгалә бише белән кайтарсын берүк. Кайсы изгеләр каныннан яратылган тәүфыйкълы бәндә син?! — дип илереп такмаклаган җиреннән кинәт кенә тавышын әкренәйтеп, Иргали абыйның үзенә генә ишетелерлек итеп болай диде.— Ходаем кәрим, ярлыка... Җыясы ризыкларыбыз бетмәгән булып, ходай саламәтлекләр биреп, бәла-казалардан имин кылса, юлларыбыз уң әйләсә, сүзем сүз, ниятләнеп, нәзер итеп әйтәм, буш итмәм...— Яхшылыкка яхшылык димештер изге китапта. Әманәткә хыянәт булмас, боерган булса...

Шулчак тыңлап утыручылардан берсе: «Нәрсә бирде соң?» — дип сорап куймасынмы.

— Бирер чукынса. Алырсың эт авызыннан белен,— дип җаваплады Рәхимҗан.— Шулай да вәгъдәсен онытмаган булган. Барып җиткәч, урнашкач исенә төшерде. Анысы өчен дә рәхмәт. Кем әйтмешли, исәп-хисапны да бик тиз өзде. Мин инде; мулланыкы мулдан булыр, дип зуррак нәрсә дә өмет иткән идем. Бирде, бирмәгән кая! Шулай да җавабын тапты тагын үзе: «Ат биргән — сызган, тун биргән — тузган, хәердога — барысын да узган!..» — дип, тез чүгеп, бик һәйбәтләп, озак итеп дога кылды. Шуның белән — аллаһе әкбәр, битебезне сыйпап торып калдык.

Рәхимҗан, сүзләренең авылдашлары күңеленә хуш килүен абайлап алгач, тагын да җанлана төшеп дәвам итте.

— Ир-егет яуда булмаса, юлда сыналыр ди. Иргали абый да этапка билгеләнгән халыкны ерак сәфәргә әзерли башлады...

Ниһаять, юлга чыгар көн дә килеп җитте. Баштарак «сәфәр» дигән хәбәр, ничектер, кешеләрне җанландырып җибәргән сыман иде. Ни әйтсәң дә, шомлы билгесезлекне көтеп, бер урында утыру түгел, әкренләп селкенә торырбыз, иртәме-соңмы, барыбер билгеләнгән урынга барып җитәргә туры киләчәк. Әмма шундук икенче уй: юллар озын, юллар хәвефле. Алда тагын да хәтәррәк билгесезлек, анданиләр көткәнен белүләре бик кыен.

Таң белән безнең олауларны капкага каратып тезеп куйдылар. Шактый озын иде ул. Сафның башында, азагында, пар атка мичәүләп җигелгән тимерхут арбалар куелды. Алары безне озата барасы коралы сакчылар өчен. Әллә ничәнче тапкыр олауларны санап, аларда баручыларны исемлек белән барлап, шактый ук теңкәгә тиделәр. Олауларның һәркайсында сандыклар, олы-олы әрҗәләр, төйнәп салынган урын-җирләр, иләк-чиләкләр, савыт-сабалар, эреле-ваклы төеннәр, чүпрәк-чапраклар. Һәрбер арбада диярлек, шул әйберләр арасыннан, бала-чага, карткортка баш калкытып тора. Читтән караганда — чат чегән таборы.

Ниһаять, олы капканы шыр ачып куйдылар һәм һаваны: «Куз-га-ал!..» дигән фәрман ярды.

Шаһиулла карт та аваз биреп куйды:

— Я-а, таңрем! Барысы да синең ихтыярда. Теләсәң нишләт. Ышанып, синең карамакка тапшырылдык. Изге сәгатьләрдә була күрсен берүк...

Шулай бергә укмашып, бергә тупланып, билгесез юлга чыктык. Уйлар борчулы, күңелләр гасабилана. Юл дигәнең бәхетлеләр өчен генә кыска да алар өчен генә җиңел. Йөрәгеңне хәсрәт тырнаса, акылыңны билгесезлек томаласа, күз алдында берсеннән-берсе яманрак күренешләр рәшәләнсә, үтеп кара син ул юл дигәнне, очы-кырые юк аның.

Бераздан Красноярск урамнарын артта калдырып, күгелҗем кара төстәге урман — тайга каплаган калкулыкка күтәрелә башладык. Тауның текә битләвендә атларны туктаттык. Һәркайсының күзе Кызыл Яр ягында. Әнә, Покровский дип аталган, тау түбәсенә урнашкан ялгыз чиркәү. Моннан ул ак болыт кисәге сыман гына булып күренә. Безне бу якларга китергән чуен юлдан торган саен читләшү дә әллә нишләтеп җибәрде. Бу хәл, туган якларыбыз белән бәйләп торган соңгы җепнең дә шартлап өзелүе сыман тәэсир итте. Күпләр елыйлар. Җитмәсә тагын ансыз да яралы бәгырьләрне телгәләп паровозлары да: «Ху-шы-гыз!.. Сау бу-лы-гы-ыз!.. Хәерле ю-у-ул!..» дигән сыман үзәкләрне телгәләде. Хуш, туган як, зарлы-моңлы як, төшләргә кереп газаплаган як! Кайчан булса да бер кайтып күрергә язганмы ул туган як дип атала торган изге җирне? Бу турыда һичкем берни белми...

Шушы урында Рәхимҗанның тавышы сынып, калтырап куйган сыман булды. Сәер тынлык урнашты. Аралыкка бәйләнгән бозауның юеш идәндә таюы да, сарык бәрәннәренең әлеп куелган юкә миннегән кетерт-кетерт ашаулары да аермачык булып ишетелеп куйды. Әмма Рәхим-

җан үзен бик тиз кулга алды, тамагын кыргалап янә сүзгә кереште.

— Туган якның кадерен белер өчен, чит-ят җирләрдә каңгыраеп йөреп карарга кирәк икән. Бары тик шул чакта гына туган туфракның газизлеген тоясың икән. Әй-йе!.. Күз яше чыгарырлык сагынулы көннәрне күп кичерергә туры килде. Баштарак бик җирсендек, туган як тартуга чыдар чамалар юк иде. Юк, туганнар, сагыш дигән нәрсә сүнми дә, сүрелми дә икән ул!

Ил гизүче киек казлар кебек тезелешеп барабыз да барабыз. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән якларга. И-и, җәяүле язмыш! И-и, каһәрләнгән язмыш! Ничәмә-ничә үрләр менелде, төшелде, әмма барасы юлның азагын белгән кеше юк. Тоташ кара урман эчләренә барып кергәч, арбаларның бөтен буыннары белән берьюлы иңрәп шыгырдавы тагын да ачыграк ишетелә башлый. Як-якта үркәч-үркәч таулар күренгәләп кала, аларны Себердә сопкалар дип йөртәләр икән. Тайга, тайга дип сөйләнәләр иде, ниһаять, тайганы да күрдек. Менә кайда икән ул кара урманнар! Кара дисәң дә кара, ичмаса. Үзләре сазлы-мүкле, җитмәсә. Иртә-киче томанлы юеш. Юлыбызның берничә көн атаклы Инәсәй елгасы буйлап төшәчәген Иргали абый белән алдан ук белә идек. Атларны ашатып-эчертеп, кешеләрне тамак ялгап алу өчен көндезге тукталышларыбыз шул мәшһүр елга туры килгәләде. Елга дисәң дә елга, ичмаса. Мул сулы, көчле агымлы, көмештәй саф сулы бу елга буена килеп чыккан саен хәйран калабыз, иркенләп сулыш алгандай булабыз. Безнең Чулман аның янында бер бәләкәй инеш кенә.

«Инәсәй тракты» дип аталган олы юл буйлап сәфәребезне дәвам итәбез. Гасырлар буе сөргенчеләрне, катырҗаннарны күреп, алар белә эш итәргә күнеккән җирле халык сине бар дип тә белми.

Юлаучы йортларына кунарга кергәндә җан урынында түгел, төннәр буе торыпша белән капланган арбаны карап, лапас астына туарып куелган атка күз-колак булып чыгасың.

Хәер, ул өйләргә керсәң дә, йоклармын, ял итәрмен, димә, чебенчеркигә чыдар чама юк.

Җитмәсә тагын, арада шактый ук четерекле, тынгысыз кешеләр дә бар. Шул ук Шаһиулла карт белән аның каенесе Шаһбаз, һәр сөрген пунктында диярлек, һаман ат-арба тирәсендә, һаман чышын-пышын киләләр, кемнәрнедер каядыр җибәрәләр. Шулай итеп алар акчага да, затлы нәрсәләргә дә алыштырып, көмешкә таптыралар.

Кузгалып китүнең өченче көнендә бугай, күрәм, Шаһбаз дигәне атын Гөлниса апа белән Гөлүсә бара торган олау артына төшерде. Төне буе эчүдән нәкъ пешкән балан сыман кызарып киткән күзләре тач иблиснеке. Аның керфек кагуны белмәгән кырыс, нәфрәт ялкыны бөркелеп торган күз карашлары белән очрашмас өчен генә дә әллә ниләр бирерсең. Ком гарәбенекедәй каратут йөз үзендә. Борыны, абзыеныкыннан үзгә буларак, карчыганыкы кебек кәкрәеп килгән. Ияге буйлап үскән салпы мыегы аның йөзенә тагын ниндидер җан кайтаргыч шыксызлык өсти. Ул җүнсезнең аяк атлауларында ук өмет юк иде. Атламый, гүя, сак кына басып, посып килә диярсең инде менә.

Гөлүсә исеме телгә алыну белән, барысы да бердәм хәрәкәтләнеп куйдылар. Тыңлап утыручыларның үзенә таба борылуларын тойган Гази, башын иярргә мәҗбүр булды. «Әнә нинди сынауларга озатканмын икән мин сине, бәгырем!..» дигән уйның, агуланган ук кебек, йөрәгенә килеп кадалуын тойды.

Ул арада Рәхимҗан хикәясен дәвам итте:

— Адәм баласының җелегенә төшәр өчен яратылган әлеге дөмеккерләре, икенче көнне дә атларын Гөлүсә утырып бара торган олау артына төшерделәр. Ә атлары сокланып туя торган түгел. Киң күкрәкле, озын торыклы нәселле ат. Аксыл-җирән яллары тезләренә төшеп тора. Ак бәкәлле зифа-сылу аякларын җиңел-елтыр атлауларын күрсәң, ул дә кит инде.

Арбалары яныннан узып барганда мине дә туктатты бу. Гөлүсә

турында бик төпченеп сораштыра башлады. Кияүдәме? Иргалинең кеме була? Ай-һай, гүзәл, янәсе. Нишләмәк кирәк, Гөлүсә кебек сылу кайда да күзгә ташланучан була.

— Юкка нәфесеңне сузма, сиңа тәти торганнардан түгел ул,— дидем. Сүзләремне ошатмады, күзләре белән ашардай итеп, үтә дә мәкерле итеп әйтә салды.— Алай җайлы-җайсыз сөйләшмик әле, агай-эне. Кушмак сездән, йөгермәк бездән дип, берьюлы бишкә бөгелердәй булып син бөтерелерсең әле каршымда...— дигән булды эт йөз.

Тегенең оятсыз рәвештә, бернинди тартынусыз күзләрен тасырайтып баруын чамалап алган Гөлүсәнең дә танырлыгы калмады, бичараның сылу йөзләренә хәвеф хикмәтләре чыкты. Бераздан ул Азатны тотып барган Миңсылу арбасына күчеп утырырга мәҗбүр булды.

Үзен ил олысы, ил карты итеп танытканы да кимен куймый иде булса кирәк, аның да итләч кызыл борыны, табак бите, кан чәчрәп чыгардай булып, тагын да шешенеп киткән, күз асларына күгелҗем капчыклар асылынган булыр иде. Арбадан төшүнең нәрсә икәнен дә белмиләр болар. Маңгайларын маңгайга терәп нәрсә турындадыр гәп сатып алалар да тәгәри-тәгәри көлешәләр. Боларның бу кыланышлары бер безнең генә түгел, башкаларның да нәфрәтен кузгатты. Алар ягына һәркем диярлек күзләренең агы белән генә карый иде. Бары тик бер Иргали абый тыйнак-сабыр кыяфәттә. Яңак итен кимерсә кимерде, әмма сүз катмады, түзде.

Шулай итеп барабыз да барабыз. Көпчәкләр һаман әйләнә, камыт баулары, тәртә башлары авыр шыгырдый, арбалар як-якка авып-түнеп китәләр, әмма тирбәлә-чайкала, һаман алга тәгәриләр. Кайвакытларда ерткыч кыяфәтенә кергән Шаһбаз, арбага кырын төшеп шыңшый башлар иде. Җыруына кадәр әллә нинди, җан кайтаргыч иде аның.

Кая китте яшь чакларым?
Шаһзадә булган вакытым?..
Йөз мең алтын торыр иде
Минем атланган атым...

Бер тапкыр шулай, сопканың текә итәге буйлап төшкәндә бугай, бу җүнсезләрнең аты, алда барган олау өстенә менә язды. Башкалар атның башын тотып төшкән җирдә, болар дилбегәне дә кулларына алырга теләмәгәннәр, арба башына чалынган килеш калдырганнар. Ат куш аякланып, кеше арбасына менгәч кенә акылына килгән Шаһбаз: «Тып-ру-у, кабер тактаңны!..» — дип, атның авызлыкланган тезгенен шундый итеп тартты, камыт-дуга малкайның колаклары турысына менеп кунаклады. Мескен хайванның ертылып чыккан авыз кырыеннан күбек катыш кара кан китте. Шуннан соң мин боларның иманы юклыкка тәмам төшендем.

Шул хәлдән соң, җаны кыйналуның аръягына чыккан Иргали абый да түзмәде, болай диде: «Нәрсә, акчагыз бик күпме әллә? Көн дә кызмача булуыгызны әйтәм. Барасы юллар озын... Анда да безне әзерләп көтеп тормыйлардыр...»

Шаһиулла карт, киек барын сизенгән ау эте сыман сагайды. Һәм үтә җитди кисәтелгән сүзне йомшартырга теләп әйтте. «Һай-й, кем, мелла, син дә сөйлисең сүз! Гомере буе сәдакага яшәгән ил картына каян килсен ди ул күп акча. Мәрхүмәмнең кыз чагыннан килгән вак-төяк зиннәтләре бар иде, шуларга алыштырып алгалыйм... Каенеш кызганыч. Йөрәге җанулардан кая керергә тишек таба алмый, котырган сыер сөте түгел, агу эчәрсең. Әйдә, хәерле каза булсын, азга гына булса да дөнья мәшәкатьләреннән, кайгы-уфтануардан онытылып торсын, дим».

Үр артында үр, офык артында офык дигәндәй, кара урманнар үтеп, тау-кыялар арасын кичеп, һаман алга барабыз. Сәфәр чыгуыбызга нәкъ тугыз көн булды дигәндә, ниһаять, җәйрәп яткан гүзәл Инәсәй елгасы буена урнашкан пристеньгә килеп җиттек. Тоташтан агачтан салынган кечерәк кала сыман җир икән.

Олы юлдан читләшүебезне таң белән сәфәр чыккач ук төшендек. Пристен урнашкан поселокның иң кырый өйләре турысыннан узып, кара урманга керү белән, үзебезне нәкъ җир астына барып эләккән сыман хис иттек. Шул тиклем куе томан төшүен күрү түгел, хәтта ишеткәнем дә юк иде. Күзгә караңгы төндә, бөтен дөньяны баскан су эченнән барабызмыни! Кул сузымында берни күренми. Үч иткән кебек юл да изрәп, тәмам эштән чыгып беткән. Үзең атлыйсың, үзең кая басачагыңны, нәрсәгә барып төртеләсеңне белмисең. Тирә-юньдә авыр йөк салынган арба күчәрләре шыгырдый да атлар пошкырып куйгалый.

Үзең атлаган буласың, ә үзеннең йөрәгең сыза — хет кычкырып җыла. Күңел күгендә сыңар йолдыз өмет чаткысы гына да юк бит, ичмаса. Тоташ билгесезлек.

Тап-тар юлның як-ягында, тоташ стенага охшап, ике-өч кеше колачы житмәслек коточкыч юан агачларның кәүсәләре пәйда булды. Аларның, дымланудан каракучкылланып, бары тик кәүсәләре генә күренә, ябалдашлары кайдадыр өстә, куе томан эчендә. Менә кайда булган икән ул чын мәгънәсендә кара тайга! Тайга дисәң дә тайга, ичмаса! дип, хәйранга калдык.

Көн туды. Аңа карап кояш яктысы күрмәдек. Биек эрбет, нарат, чыршы, карагай агачларының куе ябалдашлары, бинибая чатырны хәтерләтеп, баш очыбызда тоташып үскәннәр.

Бераздан як-ягын биек үрләр чорнап алган, көн яктысы да рәтләп үтеп керә алмый торган бер үзәнлек сыман җирдә туктадык. Яр астында, эреле-ваклы ташлар арасыннан, сикереп-ярсып инеш агып ята. Үч иткән кебек, көненең дә рәте-чираты юк. Иртә яктан ук яман җилләп, болытлап торды. Аннары, Каф таулары артыннан мәшрикъ белән мәгъриб җилләре килеп чыктымыни — тайга тоташ шауга күмелде. Карт эрбет, нарат агачларының түбәннән генә йөзгән болытларга терәлгән ябалдашлары җан өшеткеч авазлар чыгарып шаулашалар. Кара тайга, үзенә чираттагы корбан таләп иткән ач ерткыч сыман үкерепме үкерә. Тоташ кара урманның караңгы кочагында, кафенлеккә төренгән шомлы күләгәләрне хәтерләтеп, аксыл-күгелҗем томан хәрәкәтләнә...

Әле кичәле-иртәле генә Иргали абый, җае чыккан саен, үзенә иярткән кешеләрнең күңелләрен күтәреп, рухларын ныгыту ягын карый иде. «Борчылмагыз, туганнар, адәм баласы яши алмаслык җиргә илтеп ташламаслар, заманы ул түгел.— Аннары күзләре белән генә елмаеп өстәп тә куяр иде.— Кайда да бер күк-җир арасы. Аннары бит әле без бөтенләй үк чит-ят җирдә дә булмаячакбыз... Яхшымы-яманмы, бу бит безнең кан кардәшләребезнең борынгыдан килгән изге туфрагы...»

Шулай итеп ул кешеләрне төшенкелеккә бирелүдән, өмет-ышаныч дигән нәрсәләрен сындырудан саклады. Безнең хәлдәге кешеләр өчен өметен җуюдан да яман, аннан да хәтәр нәрсә юклыкны яхшы төшенә иде булса кирәк.

Ул көнне сөрген пунктына караңгы төшкәч кенә барып кердек. Шул ук көнне Иргали абый, бер генә тапкыр бозаулаган, җыйнак кына гәүдәле бер ала сыер сатып алып, безнең арба артына китереп бәйләде. Таң белән сәфәр чыгарга гына торганда, бу хәлне каравыл башлыгы абайлап алды. Һәм кешене зур җинаять өстендә тоткандай итеп: «Ярамый! Инструкциядә мал-туар ияртеп барулар катгый рәвештә тыела. Гаилә башына — җигүле ат — и все!..» — дип, Иргали абыйга ябырылды.

Күкрәгендә диңгез кайнаганда да сабыр-түземлеген югалтмый торган Иргали абыйга әллә нәрсә булды, кинәт кенә катгый-кырыс тавыш белән: «Кая, юлда ук балаларын үтереп бетерергә дип язылган инструкцияне күрсәт алайса. Совет власте раслаган инструкциядә шулай диелгәнме? Кая, карыйк әле!..» дип үзе үк конвой хуҗасын әләп алып селкеп салмасынмы! Юлга җыенган мөсафирләр авызларын ачтылар да, курку белмәс Иргали абыйга карап, хәйран калдылар.

Урынлы-урынсыз сыер турында сүз кузгатуына сакчылар башлыгы

үкенде булса кирәк. Сәфәр чыккач, ул инде бу турыда бөтенләйгә онытткан кеше сыман, Иргали абый белән янәшә атлый, нәрсә турындадыр гәп сатып, чын күңелдән рәхәтләнеп көлә иде.

Сыер алуыбыз бик тә ярап куйды. Әнисе алдында утырып барган Азат, яңа савып алган сөт эчеп рәхәтләнә генә. Хәер, Миңсылуга да эш артты, малкайга терт-терт атларга җиңел булсын өчен, көненә өчәр тапкыр сава, сабый балаларга сөт өләшә. Сыерлы булганнан бирле миңа да оек-чабаталарны салып, черем итеп алулар тәтеми башлады.

Ниһаять, район үзәгенә килеп җитүебез турында хәбәр салдылар. Чыннан да, олы үзәнлектә, як-ягын урап узган әллә ни киң булмаган елга буенда зур гына поселок күренде. Авылларның һәркайсы кебек, моның да тирә-юнен, өстенә авардай булып, саргылт-яшел тайга диңгезе чолгап алган. Аерма тик шунда: поселок ныгытмага охшаган, аны башлары очланган биек бүрәнәләр коймасы чолгап алган иде.

Конвой башлыгы, үзләренең килеп җитүләренә куангандай итеп, әйтә салды:

— Менә, заманында каты режимлы булуы һәм үзенең ныгытмалары белән дан казанган острог шушы була инде.

— Острог дигәне нәрсә тагы?..— дип аваз бирде кайсыдыр аргы почмактан.

— Тирәсен ныклы ныгытмалар әйләндереп алган өтерманнәрне шулай атый торган булганнар,— диде Рәхимҗан, бик белдекле кыяфәт белән.

Шулчак кемдер төн уртасы якынлашуын искә төшерде. Хуҗалар да: «Бәй, чыннан да!.. Бик соң икән инде»,— дигәч, бер Рәхимҗан гына түгел, көндәлек эшләрен, зарури шөгыльләрен онытып, төрле шомнарга батып тыңлап утырган авылдашлары да дәррәү урыннарыннан купты.

Хуҗалар Рәхимҗан өчен дип самовар яңарта калды. Гази да, аларның барчасына хәерле төн теләп, таралыша башлаган авылдашларына иярде.

*Ахыры киләсе санда*

# Равил Фәйзуллин

❁

Язуларга теркәлмәгән сүзләр күпме!
Чын, хак сүзләр,
ялган сүзләр,
йомшак сүзләр,
үткен сүзләр...

Очалар да кемнәрнеңдер ирененнән,
җил аларны сибеп йөри дөнья буйлап —
кыйтгалардан кыйтгаларга...

Югалалар?
Юк, югалмый, бетми алар!
(Сүз кадәр сүз ничек бетсен!)
Чыга алар я таш булып,
я шыталар гөлләр булып...

Күрәләр дә бу хәлләрне
(Кешеләрне күрми димә!),
туа Җирдә яңа шытым —
я Изгелек,
я Яманлык...

## Тау өстендә

Болытлардан өскә менү —
балачакта хыял иде!
Болытлар әнә түбәндә —
тәкәббер җан, куан инде!

Кыйгачлап очкан кошларның
өстән күзләп канатларын,
оран сал да тыңла изрәп
кайтавазлар кабатлавын.

Җиңгән яу башлыгы кебек
караш ташла өстән аска.
Мөлдерәп карыймы дөнья
биектәге синең башка?

Ә түбәндә кемдер йөри —
рухы белән тау булган җан.
Йолдызлардан да биектә
хыяллары сау булган җан!

Бәлки аларны күрмисеңдер —
карашларың офыкларда...
Хаҗәт булса, сине әзер күк
ак болытлар ышыкларга.

Һай, дивана! Күпме генә
торалырсың җил иркендә?
Тәкъдирең береккән булгач
үзәннәрнең хөкеменә!

Ә шулай да, менү зарур
җаныңа иш биеклеккә.
...Ничек итеп төшәреңне
уйлап менсәң — булыр хикмәт!

---

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН (1943) — шагыйрь, «Аҗаган», «Мәрмәр», «Шигырьләр һәм поэмалар» һ. б.— егермедән артык татарча һәм русча шигырь китабы авторы, ТАССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт, Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премияләре лауреаты. Казанда яши.

## Нигә шулай?

Нигә шулай багам һаваларга,
канатларым юк ла иңемдә?
Туган якка кайткан кошлар юлы
үтә мәллә минем күңелдән?

Нигә шулай тыңлыйм искән җилне,
әллә берәр хәбәр көтәмме?
Хәбәр түгел, көтәм кошларымның
талга басып сайрар иртәне.

Нигә шулай тансык кошлар өне,
кош сайраудан сагыш кимерме?
Кошлар булып, ахры, җаным җырлый
искә алып үткән гомерне.

## Чиләбе. Төн. Вокзал. Күпердә.

Төрле шәһәр вокзалларында,
платформа күперләрендә
ничә тапкыр басып торылган да
күпме төнге утлар күрелгән!

Ымсынулар катыш сагыш белән
озатылган күпме поездлар!
Алар киткән якта әллә ничек
серле яна иде йолдызлар...

...Менә тагын торам күпердә мин.
Алда-артта — юллар, составлар...
Чуен яллы корыч айгырларның
Ник берсенә утырып чапмаска?

Тик кай якка? Их, берәрсе шунда
яшьлек тарафына булсачы!
Тупикларга керсә, урман ярып,
барыр идем кебек юл ачып.

Шәп исемнәр куеп чыгар идем
үзем ачкан станцаларга!
«Саулык» станцасы,
«Хыял»,
«Шатлык»,
«Бәхет»,
«Сагыш»...
Монсы бераз ямансыларга...

Борылмалар саен — яшьлектәге
ялгышларны күмәр идем дә,
язулы таш куеп, яшьрәкләргә:
«Гыйбрәт алыгыз!» дияр идем мин.

...Төрле шәһәр вокзалларында,
платформа баскычларында
дөньяның күпме җил-төтене
Йөзләремә килеп сарылган!

Ят җирләрдә офыкларга багып,
күзнең нуры күпме түгелгән!
Шул җуйганнар өчен берәр яңа ямь
җыя бара килдем күңелемә.

Шуны табыш итеп, юллар буйлап
ташып йөрим бугай илемә.

...Җир өстендә күпме яңа юллар
яшен эзләредәй ярыла!
Поездлары гына никтер күбрәк
ашыгалар шәфәкъ ягына...

...Яшьлек эзләреннән хәзер ешрак
кабат-кабат урыйм уйларда.
Ә тирәмдә яшь малайлар үсә,
хыялланып сәфәр чыгарга...
Ничә буын язмышлары ята
көмеш йөзле чуен юлларда!

## Җилнең сурәте нинди?

Җилнең мөгезләре бармы?
Бардыр. Бардыр...
Юкса тамырлары белән
агачлар аумас иде.

Тырнаклары?
Бардыр. Бардыр...
Юкса түбә калайларын
куптара алмас иде.

Томшыгы да бардыр әле!
Бардыр. Бардыр...
Юкса камышлар эченә
кереп тула алмас иде.

Канатлары?
Бардыр. Бардыр...
Юкса күктә болытларны
җилпеп куа алмас иде.

...Ә рәсемгә төшерә калсаң,
кыяфәте нинди соң?
Кошмы? Берәр җанвармы?
Әллә берәр җенме соң?
Белмим. Белмим.
Үзе әнә форточкадан
миңа карап ыслап тора,
нидер әйтеп выжлап тора...
Тик телен төшенә алмыйм!
Шуңа күрә әйткәннәрен
кәгазьгә төшерә алмыйм...

## Самолетта очканда

Аста — болытлар.
Уйнаклый яшен!
Шомланып куям:
бит аста — Җирдә
сөйгәнем яши!..

Җирдән күкләргә
карыйдыр ул да.
Бәлки, әйтәдер:
бит өстә — күктә
кадерлем юлда!..

Хәвеф — кемгә аста,
хәвеф — кемгә өстә.
Яшенле күктә,
ут булып, гүя,
уйлар кисешкән.

## Таныйм да, танымыйм да...

Без утырткан бакча бит бу! —
Юкәсе, каены да...
Еллар үткәч, кайткан идем —
таныйм да, танымыйм да...

Якташлар ихлас чакырды
өенә, табынына,
Карыйм сынап яшен-картын —
таныйм да, танымыйм да...

...Кайсысының оныгы бар.
Кайсысы — аерылган...
Бергә укыган кызларны
таныйм да, танымыйм да...

Зиратыбызда йөрдем,—
«әрвахлар янында».
Әүвәлге ташбилгеләрне
таныйм да, танымыйм да...

Күпме нәрсә төс үзгәрткән
елларның агымында!
Саеккан инешнең юлын
таныйм да, танымыйм да...

...Миннән дә сорыйдыр бу Җир:
«Син әле каян монда?»
Гөлләре әйтә шикелле:
«Таныйм да, танымыйм да...»

## Төнге күктә кыр казлары өне...

Фильм бетте. Чын сәнгатьчә әсәр.
Сурәтләнә язмыш хәлләре.
Залда ут янгач та, тәэсираты
күңелләрдән китми барды әле...

Экран тормышы әле урамда да
дәвам итте уйны биләвен.
...Кинәт өстә — язгы төнге күктә
нинди авазлар бу? Чү әле!..

Ялгышмыйммы? Кошлар авазы ич!
Кайтып килгән казлар тавышы!
Әсәрләнеп тыңлыйм. Кинодагы
вакыйгалар очты барысы.

Балачакта гына була торган
бер халәткә кайттым яңадан.
ФТРлар салган улау түгел,
бу — илаһи иңрәү һавадан.

Шәһәр күкләрендә беренче кат
ишетәм бугай өнен казларның?
Кабатланмас сихри бүләк бит бу
кабатланып килгән язларның.

...Һич бәхәс юк: олы сәнгать — юлдаш
гаделлеккә, ямьгә, аклыкка.
Тик ул азрак — кеше үзе тоеп,
Табигатьтән алган шатлыкка.

## Уяну

Сихри төндә йөрдек икәү ак атларда!
Ал офыкта җуйдым сине таң атканда!..
...Ярым айнып төштән, чыксам өй алдына —
тышта суык яңгыр ява талгын гына...

Өндә түгел, төштә күргән матурны да
югалтырга кемнәрнеңдер хакы бармы?
...Яланнарда җилләр йөри — җыры булып
каберләре дә калмаган батырларның...

## Яп-яшь килеш сәрхүш булган таныш түгел берәүгә

Әйтеп торырга кирәкме? —
дөньяда, дип, күпме ямь!
Ә соң нишлим: күзеңдә
өметсез бушлык күрәм.

Күрәм: сиңа таңнар ни дә
болытлар агышы ни...
Балалар көлүе ни дә
чишмәләр тавышы ни!..

Күк, Җир, Су матурлыгына
битараф булгач инде,—
димәк, эш вәгазьдән узган,
җаның, тәгаен, чирле.

Димәк, үз хәлең хәл инде,
җителгән соңгы чиккә.
Матурлык та көчсез булгач,
талпынуларың — тиккә...

...Күргәч сине, үземнең дә
башым иелгән кебек.
Ниндидер ялгыш җибәреп,
яуда җиңелгән кебек.
Гаеплелек энәләре
мигә сибелгән кебек...

Бер уйласаң, син кем миңа?
Беренче күрәм алда.
...Без — Җирдәш шул. Кеше булып
яшәргә килгән җаннар.
Шушы уй, утлы күмер күк,
тынгылык бирми аңга.

**Батулла**

# АЛЫП БАТЫР МАҖАРАЛАРЫ

ПОВЕСТЬ

## Сак белән Сок



Алып Бәргән, Аждаһаны эзләп, Каф тауларын узды. Тәбризгә килеп житте. Тәбризнең кәрвансараенда ил-җир күргән сәяхәтчеләр белән берничә көн мөзәкәрә кылып, Аждаһаның кайдалыгын сораштырды.

— Бөтен явызлык Дәрвишай чүлендә! — диде бер мосафир.— Син, батыр, шул чүлгә барып кара.

Ниһаять, көтә торгач, Алып Бәргән Тәбриздән Кытайга бара торган кәрванга тагылып, Дәрвишай чүлен кичә башлады.

— Һавалар артык тыныч, тиздән сәмум башланмагае! — диде кәрванбаш.

Дөрестән дә, көн урталарында, өйлә намазы вакытында, кинәттән генә давыл купты. Коточкыч зур өермә кирәк-яракларны гына түгел, хәтта кайбер кешеләрне дә үзе белән бөтереп алып китте. Кеһеләр кайсысы агачка ике куллап ябышты, кайсысы атын иясә дөясен муенынан кочаклап комга ятты. Ком бураны яткан дөяләрне, кешеләрне күмеп ташлады. Алып Бәргән, авызына ком тулмасын дип, атына капчык кигезде. Үзе дә билбавын сүтеп, битенә чорнады да аты белән янәшә ятты. Күпме вакыт узгандыр, сәгатьме, тәүлекме, Алып Бәргән анысын белми. Сәмум тынгач, ул ком астыннан көч-хәл белән чыкты да, Кораңгыш тирәсендәге ком тавын куллары белән көрәп, атын якты дөньяга чыгарды. Эшен бетереп, тирә-ягына караса, кәрван юк. Кәрванчылар, Алып Бәргәнне барлап тормаенча, ашыгып китеп барганнар.

Чүл уртасында байтак адашып йөреде ул. Шулай каңгырып йөри торгач, офыкта бер каракучкыл нәрсә шәйләнде. Якынрак баргач, бу нәрсәнең урман икәнлеген күрде. Урман кырыенда сарык көтүе йөри. Карт кына бер көтүче таягына таянган да, сарыклар утлаганга карап, борын эченнән генә бер көй шыңшый иде.

— Әссәләмегаләйкем! — диде Алып Бәргән.

— Вагаләйкем әссәлам! — диде карт.

— Алда нинди ил ул? Бу нинди урман? — дип сорады Алып Бәргән.

— Сак-Сок иле! — диде бабай.

Алып Бәргәнне аяз көнне яшен суккандай булды. Ни гомер күрергә хыялланып йөргән Сак белән Сок иле аның борын төбендә ләбаса!

...Сак-Сок иле — каргыш иле. Вакыт анда туктап калган кеби. Сүзен тыңламаганга күрә, йомыш үтәмәгәннәре өчен бичара ана игезәк балаларын елый-елый каргый. Ананың күз яшьләре балалары өстенә кара каргыш булып төшә. Газиз улларының берсе Сак, икенчесе Сок дигән

---

[1] Ахыры. Башы 6 санда.

кошка эверелеп, тәрәзәдән чыгып оча. Уллары мәңге шулай кош булып калган. Ана белән ата мәңге шулай кара кайгыда яшәргә мәҗбүрләр...

— Сак-Сок иле — минем күптәнге хыялым! — диде Алып Бәргән көтүче картка.

— Ашыкма! — диде карт.— Бу урманга кергәнче, Сак-Сок иленә аяк басканчы, син бер хакыйкатьне аңла, батыр. Синең көчең күп. Син дөньядагы иң куәтле, иң мәкерле затларны җиңгән батырга охшыйсың. Синең күңелең саф, теләгең изге булырга тиеш. Сине байлык та, җиңел яуланган ләззәт тә аздыра алмый. Син — чын-чынлап халык батыры. Ләкин Сак-Сок фаҗигасы катлаулы. Аңа катнашырга ярамый. Хәтта саф күңелле, изге кешенең дә моңа хакы юк! Аңладыңмы, батыр? Әгәр аңласаң мәрхәбә! Уз Сак-Сок иленә! Күр син ачы бер каргышны. Гыйбрәт итеп башкаларга сөйләрсең!

Картка рәхмәтләр укып, Алып Бәргән Сак-Сок иленә кереп китте. Урманнары гадәти урман кебек, һич аерма юк сыман. Киек-җәнлек, кош-корт, җиләк-җимеш — барысы да бар. Тик әнә шул матур-бай урман эчендә Зур Сагыш та бар. Үкенеч белән тулы авазлар үзәккә үтә. Бу — Сак белән Сок тавышы. Шулай бара торгач, Коралгыш аны бер авылга алып чыкты. Матур гына төзек бер авыл. Каралты-курасы, мал-туары дисеңме, шау чәчәккә күмелгән бакчалар, авыл өстенә авам дип торган урман дисеңме, челтер-челтер аккан чишмәләр тавышы дисеңме, урамнары тулы бала-чага дисеңме — бар да бар. Мул, тыгыз, таза тормыш кайный. Тәрәзәләре дә хуҗалары сыман шат чырайлы. Өйләр елмаеп, миһербан чәчә шикелле.

Ата-аналар:

— Балам, балакаем! — дип өзелә.

Бала-чага:

— Әти, әткәем! Әни, әнкәм! — дип, тәмле тел белән сөйләшә.

Искиткеч бер ярашканлык, җылылык, якты нур вә миһербан сибелә бу кешеләрдән. Бары тик бер өйнең генә тәрәзәләре кайгыдан елый кебек. Бу йортта Сак белән Сокның ата-анасы яши икән. Кинәт өй эченнән үзәк өзгеч бер аһәң ишетелә. Сак-Сокның әнисе балалары турындагы бәетне көйли. Бу — Сак-Сок моңы. Балалар да, ата-аналар да шомланып Сак-Сок бәетен тыңлыйлар. Аннан тагын эш, тагын уен, тагын шатлык башлана. Гомер буе шулай яши икән бу авыл.

Алып Бәргән сагышлы өйгә керде. Аның сәламен алучы, аңа сәлам бирүче булмады. Өй түрендәге сәкедә ана утыра. Ишек катындагы җылы мичкә аркасы белән сөялгән ата утыра. Алып Бәргәннең кергәнен алар күрми-сизми калды ахрысы. Ана оекбаш бәйли. Бәйли-бәйли дә кире сүтә. Үзе Сак-Сокны көйли:

Мәдрәсәләрдәй китап киштәсе,
Сак белән Сокның таушын ишетәсе...

Ата кеше итеккә олтан сала. Олтанны тегә-тегә дә тагын сүтә. Диварда сәгать йөри. Күпме генә йөресә дә сәгать телләре гел бер урында тора. Казан астында ут яна, аш кайный. Ут күпме генә дөрләсә дә сүнми. Аш күпме генә кайнаса да кимеми. Матур итек тә әзер, оекбаш та бәйләнеп бетте, аш та пешеп өлгерде...

— Сәгать кичке тугыз бит инде, атасы. Балалар һаман юк, бәгырькайләрем! — ди ана.

— Кайта алмый торганнардыр, бичаракайлар! — ди ата.— Кавыша алмыйлар бит алар. Араларына тау үсеп чыга бит аларның. Япа-ялгызлары карурманда, бахыркайлар...

Шуннан соң тагын олтанны кире куптарып ата. Әзер оекбашны янә сүтә башлый ана. Гел шулай кабатланып тора.

Ана белән атаның бетмәс-төкәнмәс кайгысыннан Алып Бәргәннең җаны өши башлады.

— Йә дөнья! — дип ялварып кычкырды ана.— Зинһар, кичер мине. Зинһар, ал кайгымны! Кайтар балаларымны! Кабат мәңге дә мин аларны

каргамас идем. Карынымда йөреттем, сигез яшькәчә иркәләп үстердем дә үзем каргадым. Үзем башларына җиттем. И Тәңрем, кан аралаш күз яшьләрем хакына, ничәмә-ничә еллар йокысыз үткәргән төннәрем хакына сүземне тыңласана! Ал бу хәсрәтләрне, ал бу кайгыларымны. Ярлыка мин бичара хатынны...

Юк, Тәңре җавапсыз калды. Ана тагын баягы эшенә тотынды. Учактагы ут янә терелде, сәгать янә текелди башлады.

Алып Бәргән бу хәсрәткә чыдый алмыйча тиз генә чыгып китте. Ул бар дөньясын онытып йөгерде дә йөгерде. Шулай йөгерә торгач, урманга килеп җитте.

— Бичара ана, мескен ата! — диде Алып Бәргән.— Сезнең балаларыгызны кушып, кире кайтарырга кирәк! Ул балаларны мин коткарырга тиеш. Ата-анага мин бәхет бирергә тиеш!

Шулчак аның сул ягында «Са-ак» дип, уң яктагы агачлар арасыннан «Со-ок» дип еламсырап кычкырган тавышлар ишетелде. Кояш баегач, тавышлар якынайды. Алып Бәргән сулышын тыеп тыңлый башлады.

— Са-ак...

— Со-ок...

Тора-бара кошларның кешечә сөйләшкәннәре ишетелде.

— Са-ак, мин куркам... Син якын кил, Са-ак, бергә-бергә җылы булыр...

— Мин дә куркам, Со-ок, мин дә туңам... Әткәй-әнкәй янында җылы иде...

— Кеше хәленә кире кайтсам, мин беркайчан да анамны рәнҗетмәс идем, Сак.

— Үз хәлемә кайтсам, мин беркайчан да анам сүзеннән чыкмас идем, Сок...

— Са-ак, якынрак кил, бергә-бергә җылы булыр...

Инде кавыштык дигәндә генә ике туган арасына зур тау үсеп чыкты. Алып Бәргән куркуыннан читкә тайпылды. Сак белән Сокның берберсен эзләп кычкырган кызганыч тавышлары ерагайгач кына, тау кире үз урынына төшеп, җир тигезләнде. Алып Бәргән икенче кичкә кадәр тагын көтте. Һәр кичне шулай кабатлана. Һәр төнне туганнарны мәкерле тау аера.

— Җирне кем шулай астан күтәрә икән? — дип, Алып Бәргән озак баш ватты.

Эзләнә торгач, ул җир астына алып төшә торган яшерен ишекне тапты. Җан көченә бөҗрасыннан тарткан иде, якты бер дөньяга килеп керде. Бер почмакка посып, ниләр булыр икән монда дип, озак сагалады. Өстә, урманда, Сак белән Сок тавышы якынайганы ишетелә башлады. Тегеләр инде кушылды дигәндә генә, әллә каян тау чаклы җир асты филе килеп чыкты да түшәмне урманы-җире белән өскә калкыта башлады.

— Менә кем икән ул Сак белән Сокны аерып торучы!

Алып Бәргән җен ачуы белән филнең маңгаена гөрзи белән китереп орды. Фил, аңгыраеп, берни булмагандай туктап калды. Алып Бәргән фил айныганчы тагын берничә тапкыр җир селкетерлек итеп филгә сукты. Шуннан соң гына җир асты филе гөрселдәп ауды. Җир кире үз урынына кайтты.

Һиҗрәттән соң тугыз йөз утыз тугыз ел узгач булды бу хәл.

Алып Бәргән атылып өскә чыкты. Караса, ни күзләре белән күрсен, алан уртасында бер-беренә тач охшаш ике ир бала басып тора. Алар кочаклашып елаштылар да:

— Тизрәк атай белән анай янына кайтыйк! — дип авылга таба йөгерделәр.

Алып Бәргән, балаларның ата-анасы белән кавышканын сиздермичә генә читтән карап торды да, атына атланып кайтып китте.

Алып Бәргән чиксез бәхетле иде.

Урманны чыккач та ул көтүчесез калган сарык көтүен күрде. Маллар

төрлесе төрле якка сибелгән, ә бичара карт көтүче юл кырыенда хәрәкәтсез ята.

— Бабай, бабакай, сиңа ни булды?

Ул картның үлем шаукымы кергән күзләренә бакты. Бабай нидер әйтергә теле иде. Тик аның иреннәре кыймылдый алмый. Алып Бәргән тиз генә тулымыннан бабайның иреннәренә салкын су тамызды.

Су эчкәч, карт хәл алды:

— Их, син...— диде бабай, чак ишетелерлек итеп.— Мине аңламагансың... Сак белән Сокны кушып, син халыкка сөйләп бетергесез зыян эшләдең... Авылда бер гыйбрәт бар иде — Сак белән Сок! Хата кылып та, соңыннан гафу ителәсен белсә, кеше беркайчан да җинаять эшләүдән курыкмаячак. Теге дөньяда оҗмах булыр дип тынычландыру янсә теге дөньяда җәһәннәмдә янарсың дип куркытырга тырышу — ул үзе җинаять. Хата кылгансың икән, җәзасын бүген үк ал. Яхшылык эшләгәнсең икән, аны түләү сорама! Мин тәрбиясез ике балага җәза бирдем. Артык кискен, рәхимсез рәвештә балаларын каргаган анага кайгы китердем. «Сак-Сок» вакыйгасын мин бәет итеп бөтен дөньяга тараттым. Гыйбрәт алсын миһербансыз бала дидем. Сак-Сок дигән олуг бер мәкамле бәетнең азагына син кул тыктың. Мең ел буе аналарга хөрмәт тәрбия итә торган бәетнең азагын үзгәрттең. Беләм, сиңа гына түгел, бик күпләргә ахыры яхшы беткән вакыйгалар ошый. Ләкин азагы яхшы тәмамланган әсәр кешеләрне тынычландыра, канәгать калдыра. Сак-Сок вакыйгасы үкенече белән куәтле иде. Фаҗигасе белән, каргышны мәңге кире алып булмаслыгы белән ул гасырлар буе инсафлы кешеләр тәрбияләде. Син ул тәрбия коралын сындырдың, батыр!.. Соңгы сулышым житте... Син үтергән фил — мин ул. Филдә иде минем җаным...

Алып Бәргән картның күзләрен йомдырды, авызын сөлге белән бәйләп куйды, өстенә бөркәвеч каплады да кире авылга китте.

Кырыйдагы йортның тәрәзәсен чиртеп, ул:

— Анда көтүче бабай үлгән, алып кайтып җирләгез! — диде.

Сак белән Сокның кайтуына багышланган зур бәйрәмнән Алып Бәргән качып китте.

## Гыйфрит урлаган кырык чибәр кыз

Һиҗрәттән соң тугыз йөз кырык ел узгач булды бу хәл.

Сармат дигән илнең патшасы хатынын, балаларын, кырык вәзирен алып, кырык сунарчы белән кырык пешекчесен ияртеп, сахрага чыкты. Балалары күбәләкләр куып, чәчәкләрдән такыялар үреп уйнады. Патша үзе вәзирләре белән җиргә кырын ятып, шәраб эчеп, төрле мәүзугъларга мөзәкәрә кылып, күңел ачты. Кырык суңарчы аткан кошларны кырык ашчы кырык төрле итеп пешереп, сәйранчыларны кырык тапкыр сыйлады. Бу патшаның буй җиткән бик матур бер кызы бар иде. Күрше илләрнең кырык шаһзадәсе, ул кызга өметләр баглап, хатлар яза, Сармат патшасыннан кызын сорыйлар, дөнья байлыклары вәгъдә итәләр иде. Сармат патшасының иң кадерле хәзинәсе — кызы. Шуңа күрә, патша кичен йокларга ятканда, кызының чатыры янына кырык сакчы куйдыртты. Сармат патшасы, сакның ныклыгына ышангач кына, үз чатырына кереп китте. Төн уртасында бер кара болыт пәйда булып, давыл купты. Кыз йоклый торган чатырны җир кубарып алып китте. Сакчылар чатыр артыннан йөгерде. Кире әйләнеп кайтсалар, патша кызыннан җилләр искән! Ятак буш. Кинәт чыккан давыл кинәт кенә туктады. Куркышып уянган вәзирләр дә, патша да офыкка таба очып баручы кара болытны күреп:

— Бу — диюләр патшасы! — диделәр.

Сармат патша тиз генә диван вәзирләрен җыйнады. Күрше-күлән илләргә дә шундый афәт килгән икән. Утыз тугыз патшалыкның иң чибәр кызын шул дию урлаган. Утыз тугыз патшалыктан утыз тугыз пәһлеван кызны коткарырга дип яуга киткән, ләкин берсе дә кире әйләнеп кайтмаган ди.

Вәзирләр, хәбәрчеләр, өндәүчеләр атларга атланып кычкырып йөрсәләр дә, кызны коткарган кешегә алтын таулары вәгъдә итсәләр дә, бу эшкә бер генә батыр да кузгалмады. Имеш, ул дию җиңеп булмый. Имеш, ул дию бөтен диюләргә баш икән.— Бу эшкә бары тик Болгарстанның Утыз Имәнле батыры Алып Бәргән генә алынса алыныр! — диде вәзирләр.— Шул батырны чакыртып, чапкын җибәрик!

Шулай эшләделәр дә. Бер атка атланып, өстәмәгә ике ат алып, чапкын хатларны илтә китте.

Бу вакытта Утыз Имәнлегә бара торган юл буйлап Алып Бәргән соңгы сәяхәтеннән кайтып килә иде. Ул дөньясын онытып, авыл агайлары белән салмак кына гәпләшеп утырырга, кымыз чөмерергә, казылык ашарга, рәхәтләнеп бер йокларга хыяллана. Нәүмизә белән күрешергә ясканып кайта...

Алып Бәргәнне әнисе каршылады. Ат кешнәгәнен ишетеп, ишегалдына йөгереп чыкты, бахыркай. Улкаен-батыркаен җилкәсеннән сөяргә үрелгән иде дә, буе җитмәде. Алып Бәргән, көлә-көлә иелеп, аркасыннан сөйдертеп торды.

Берзаман ишегалдына аңа таныш булмаган, тузанга баткан бер юлаучы килеп керде. Чит кеше Алып Бәргәнне күргәч, букчасыннан хат чыгарып батырга сузды.

— Алып Бәргән, бәла килде илебезгә! — дип аңлатырга тотынды чапкын, ләкин Алып Бәргән аны тыңламый иде инде. Ул хатларны ачып укырга тотынды. Укып бетергәч, кабалана-кабалана юл киемнәрен кия башлады. Киенгән арада үзе бертуктаусыз:

— Менә мин эзләгән явыз шушы булыр! Ниһаять, эзенә төштем мәлгуньнең! — дип кабатлый.

Алып Бәргән әче итеп сызгырды, еракта ат кешнәгән тавыш ишетелде. Ул киенеп беткәндә, Корангыш кайтып җиткән иде инде.

— Кая барасың, улым? — дип сорады анасы.— Коймак суына бит.

— Анам,— диде Алып Бәргән.— Кичер мине, мин китәргә тиеш. Мин теге мәлгуньнең эзенә төштем, юлга коймак төр, тулымга салып кымыз бир. Әйдә, чапкын, юл чатына чаклы озата бар мине!

Анасы төенчекләрен тотып урамга чыкканда, Алып Бәргән инде ат өстендә иде. Чапкын кисмәккә ятып кына су эчте дә, атын алмаштырып, Алып Бәргән артыннан чабып китте. Юл уңаенда сораштыра-сораштыра, Алып Бәргән шуларны белде.

Бу явыз зат — Аждаһа түгел, диюләр патшасы Гыйфрит икән, ул карурманнар белән капланган, кыя-ташлар арасына яшеренгән җирдә яши ди. Бу ил Дәүстан, ягъни Диюләр Иле дип атала икән. Дәүстан иленә бара торган юл чатында алар чапкын белән аерылдылар.

— Һәй, олан! — диделәр юл чатындагы кешеләр батырга барчасы бер авыздан.— Юк эшкә алынгансың. Бу юлдан кырык пәһлеван узды. Барган юллары бар, кайткан эзләре юк. Дию генә түгел, диюләргә дию Гыйфрит патша бит ул, балакаем! — диделәр.

Очраган бер юлаучы белән сөйләшә торгач, беленде ки, Гыйфрит мәлгуньгә кырык дию буйсына, хезмәт итә икән. Шул кырык дию карап торырга кеше кыяфәтле затлар ди. Ләкин кара халыктан мал-туар таларга килгәндә, чып-чын диюгә әвереләләр икән.

— Гыйфриткә син барып та житә алмассың, олан! Аның кырык диюе сине харап итеп бетерәчәк! — дигәч, Алып Бәргән уйга калды.

Шуннан соң ул, Сармат патшасының ярлыгын күрсәтеп, йокларга урнашты. Кара чуралар аның атын тугайда йөртергә алып китте. Амбарчылар аңа әүкать әзерләде. Матур бу тугайда яшәп, Алып Бәргән Гыйфрит белән сынашыр өчен көч тупламак булды.

Кара чабаннар, иң симезләрен генә сайлап, ашаган саен, аңа бер куй суя тордылар.

— Менә, олан,— диде кара чабаннар башлыгы.— Син бер-ике атна

шушы тәгамне җыйсаң, куәтең унлата артыр. Иншаллаһ, Гыйфритне алуың да ихтимал булыр, бәлкем?..

Берәүсе учак тергезеп җибәрде, икенчесе учак өстенә казан асты. Берәүсе бәрән чалып, агач күләгәсе бер карыш озынайганчы, бәрәнне тунап, итен сөякләрдән аерып бетерде. Башын, сөякләрен казанга салды. Башка берәүсе кузгалаклар, төрле үләннәр өзеп килде дә, шуларны юып, шулпага төшерде. Бәрәннең итен тозлап, борычлап, нар җимеше сутын сибеп, серкә суында тотып, киредән бәрәннең үз тиресенә салып, камыт энәсе белән тыгызлап тектеләр. Аннан соң шаулап торган күмер өстенә элеп куйдылар. Тиренең бөтен йоны өтелеп бетте дә куырылып, кызарып килде. Ара-тирә әйләндерә торгач, кара чабан:

— Җитешегез, батыр олан! — диде.

Бу эшкә нибарысы шәүләнең ике карыш озаюы җитте.

Чабаннар әзерләгән кавырман ашап туйгысыз иде. Алып батыр берүзенә бер бәрәнне «эһ» тә итмичә ашап бетерде. Аннан соң шулпа бирделәр. Хуш исле бу шулпаны да Алып Бәргән бик ошатты. Шулпадан соң куе сөт белән ясалган каты чәй, чәйдән соң салкын кымыз эчерттеләр. Кымыздан соң әчкелтем алма килде.

Алып Бәргән атна-ун көн шулай чабаннар янында тәрбия күрде. Ул көн саен дала буйлап йөгереп килә. Аннан соң сап-салкын чишмәдә коена. Су коенганнан соң атын чаптыра. Шулай итеп, ул шактый көч туплады.

Аерылышыр вакыт җитте. Кара чабаннарга хуш сүзләр әйтеп, Алып батыр Гыйфрит патшалыгына таба сәфәр китте.

Дала буйлап бер тәүлек баргач, кыя таулар калкып чыкты. Тарлавыклар аша барып, Алып Бәргән куе урманга килеп керде. Урман бер дә куркыныч сыман тоелмады Алып Бәргәнгә. Котны алып кычкырган сәер тавышлар да ишетелми, бүре дә уламый, бик матур, бай урман иде бу. Кеше килгәннән дә курыкмыйча, кошлар онытылып-онытылып сайрый. Киек-җәнлекләрнең курку исләрендә дә юк, үз эшләре белән мәшгульләр. Йөз адым саен урман чишмәсе очрый. Һәр чишмә янында утыргычлар җайлап куелган. Һәр чишмә янына агач чүмечләр эленгән. Сусаган юлчы рәхәтләнеп ял итсен, сусынын бассын дигәндәй, яңгырдан саклавыч кечкенә чатырлар эшләнгән. Бөтен җирдә тәртип, пөхтәлек. Алып Бәргән чишмә саен урман суы татып барды. Шулай бара торгач, ул гаҗәп матур бер аланга килеп чыкты. Алан уртасында күз яуларын алырлык мәһабәт алтын сарай калкып тора. Сарайның тирә-ягын мең төрле төстәге чәчәкләр бакчасы урап алган. Шул чәчәкләргә кырык кыз су сибеп йөри. Һәр кыз янында бер сакчы тора. Кызларның киемнәренә карап, Алып Бәргән шаккатты. Мондый җиңел ефәк күлмәкләрне патша кызлары да кими торгандыр. Мондый кыйммәт асылташлы балдакларны хан кызлары да киеп йөри алмыйдыр. Шулчак иң кырыйдагы кыз Алып Бәргәнне күреп алды да янында басып торучы егеткә нидер пышылдады. Сакчы егет Алып Бәргәнгә таба борылды. Алып Бәргәнгә якын торган егет кыю атлап килде, чак сизелерлек итеп баш какты.

— Хуш киләсең, батыр егет! Уз! — диде сакчы.

Алып Бәргән ирексездән аңа иярде. Алтын сарай янындагы матур ханәкәгә килеп җиттеләр.

— Син шушында ятып ял ит, аша, эч! Иртәгә сине патшабыз янына алып керербез! — диде озата килүче егет.

Хезмәтчеләр Алып Бәргәннең тамагын туйдырдылар, чиста җәймә җәеп, урын көйләп бирделәр.

— Бу нинди ил? — дип сорады Алып Бәргән. — Мин бит Гыйфритне эзләп бара идем!

Коллар бер сүз дә әйтмәделәр, алар хәтта батырның сүзенә колак та салмадылар шикелле.

Иртән иртүк Алып Бәргән чиста киемнәрен киеп, коралларын тагып бетергәч, ханәкәгә кичәге асыл егет килеп:

— Падишаһыбыз сине көтә, батыр! — диде.

Асыл егет аны алтын сарайга алып керде. Тәхет залындагы матур чәчәкләрне, су атып торучы көпшәләрне күреп, батыр егет тагын хәйран калды. Су көпшәләре янындагы күчмә тәхеттә асылларның асылы, мәһабәт бер егет утыра иде.

— Менә! — диде аны озата килгән сакчы.— Диюләр патшасы Гыйфрит шушы була!

— Ничек? — дип кычкырды Алып Бәргән.— Шушы асыл егет Гыйфрит патшамы?

Тәхеттәге егет елмайды:

— Гаҗәпләнмә, Алып Бәргән! — диде ул.— Сез, кешеләр, куркынычны ямьсез итеп кенә күрергә өйрәнгәнсез. Шуңа күрә күп вакыт матурлыкка алданасыз. Дөрес әйтте минем пәһлеваным: мин Гыйфрит буламын!

Алып Бәргән кинәт кенә кылычы белән Гыйфритнең башын чабып өзәргә уйлаган иде дә, тыйлыгып калды. Патша янында Алып Бәргән кебек үк кырык баһадир басып тора. Алар берьюлы аңа ташланса, Алып Бәргәнгә исән котылу әләкмәс. Бу Гыйфритнең нәрсәгә сәләтле икәнен дә белеп булмый. «Сабыр итим әле, алга таба нәрсә булыр икән,»— дип уйлады батыр.

— Хәзер без синең белән тамак ялгап алырбыз! — диде Гыйфрит. Тамак ялгагач, мөзәкәрәмезне дәвам иттәрбез!

Гыйфрит өч тапкыр кул чапты. Читтәрәк басып торган кырык чибәр кыз шундук юк булды. Бераздан алар, матур төпсәгә салынган ризык алып кереп, патша белән Алып батыр алдына куйдылар. Аннан соң кырык кувшинга салып, салкын шәраб китерделәр.

— Мин Мисыр күгәрчене яратам! — диде патша.— Шуңа күрә, синең яндагы менә бу кызны Мисыр фиргавене Әсламхатиптан урлап алып кайттым. Ул кыз Мисыр күгәрченен гаҗәп тәмле кыздыра...

— Син монда ниләр генә ашамыйсың да нинди шәрабләр гына эчмисең, Гыйфрит! — диде Алып Бәргән.— Анда халык ачыга. Халык синнән иза чигә!

— Халык? — дип көлемсерәде Гыйфрит.— «Халык» дигән сүзне без, патшалар, чәйнибез дә төкерәбез, төкерәбез дә чәйнибез. Шуннан килеп чыга мәкальләр: халык — судагы балык. Ягъни аны тотасың да табага салып куырасың. Халык — сарык ул. Ягъни аңгыра. Бер сасы кәҗә тәкәсенә ияреп, көтүе белән упкынга барып төшә ала...

Гыйфритнең бормалап-сыргалап сөйләвеннәнме, әллә көткән дошманының дустанә елмаюыннанмы, Алып Бәргән югалып калды.

— Житеш, батыр! Казандагы табында дигәндәй, бигайбә! — диде дә Гыйфрит бер күгәрченне шатырдатып урталай аерды.

«Юк,— дип уйлады Алып Бәргән,— хәзер кылычымны суырып чыгарам да Гыйфритнең җанын алам! Батыр тагын тыелып калды. Якында гына кырык пәһлеван аның һәр кул хәрәкәтен күзәтеп тора. «Ярый,— диде Алып Бәргән эчтән генә.— Мин дә башымны юләргә салып карыйм әле!».

Алып Бәргән дә күгәрчен ботарлый башлады. Чыннан да, тәмле ризык икән бу нәмәстә. Кошның эченә мәмердәп торган итчел кара җимеш тутырганнар да тегеп куйганнар. Бөтнек, бакча әнисе, сарымсак вә борыч измәсе белән күгәрченне сылап чыккан булырга тиешләр. Аннан соң камырга төреп, кайнар мичкә тыгып кыздырганнар. Алып Бәргән ун кувшин шәраб эчеп, егерме күгәрчен белән тамак ялгап алгач, тагын сүз башларга булды.

— Шәп яшисең син, чукынтый! — диде Алып Бәргән.— Кая соң синең чәлдермеш кырык кызың? Син аларны, качмасыннар дип, базда асрыйсыңмы?

Гыйфритнең дә кәефе шәп иде, ул көлә башлады.

— Менә бит каршыңда кырык кыз... Ә менә бу егетләр! — хуҗа

әйләнәсендәге кырык пәһлеванга ымлады.— Болары шул кызлар артыннан килгән батырлар булыр.

Алып Бәргән чәчәкләргә су сибүче кызларны таныды.

— Шулай! — диде Гыйфрит. Күрәсең бит, алар бәхетле илдә яши! Биредә матурлык, байлык, ләззәтият!

Ашап-эчкәннән соң бар да тамаша залына китте. Анда кызлар саз, курай, сорнай, чыңгырак уйнады. Егетләр гөслә чиртте. Аннан соң Гыйфрит падишаһ үз һөнәрен күрсәтте. Ул кара болыт булып оча торган диюгә дә, ажгырып торган Гыйфриткә дә әверелә ала икән. Күз ачып йомганчы, тау хәтле була да, аны һичкем җиңә алмый икән. Сөйләшкәннәрдән, күргәннәреннән Алып Бәргән шуны аңлады: кызларның илләренә һәч тә кайтасылары килми. Егетләр үзләренең кем икәнлекләрен дә онытып булып чыкты.

— Мин ирексезләп тотмыймын аларның берсен дә! — диде Гыйфрит патша.— Күр, бел, кайткач, кешеләргә сөйләрсең. Гыйфрит беркайчан да кыз ризалыгыннан башка гөнаһ кылмый диген. Күреп бак, кайткач сөйләрсең: Гыйфрит беркайчан да монда килгән пәһлеваннарның канын агызганы юк диген. Гәрчә мин олы куәт иясемен. Үзең шаһит: мин аларны җәберләмимен! Кыз белән башта күрешеп, бер-ике мизгел сөйләшеп алам да, алар үз ризалыклары белән минем патшалыгыма килә. Монда килгәч, бу рәхәтлекне, матурлыкны күреп, дөньяларын оныталар. Кызлар шушы гүзәллектән нигә качсын? Егетләр шушы муллыктан нигә тузан, кара эш, мескен халык янына кайтсын? Мин аларны бәйләп тотмыймын. Китсеннәр, юлларына ак җәймә. Ләкин кырыктан ник берсе китсен! Син дә китә аласың, Алып Бәргән. Син китәргә тиеш. Беренчедән, мин синең куәтеңнән куркам. Икенчедән, монда күргәннәреңне син кешеләргә сөйләргә тиешсең. Кешеләр гөнаһсызга каргый мине. Мин алар уйлаганча мәлгунь түгел бит. Ә хәзер ял ит, аша-эч, кунак бул. Үзең теләгән чакта сәфәр чыгарсың.

— Торып тор! — диде Алып Бәргән.— Сөйләшеп бетерик, Гыйфрит. Ярый, ал да гөл икән синең эшләр. Син Гыйфрит түгел, фәрештә ди. Ә синең диюләрең талаган маллар өчен халык каршында кем җавап бирер? Сыгасың бит син халыкны, агайне, ай-һай каты сыгасың. Савасың син бичара кешеләрне!

Гыйфрит Алып Бәргәннең җилкәсенә дусларча гына сугып куйды:

— Гәүдәң үскән синең, акылың үсмәгән, Алып Бәргән батыр! Бүре беркайчан да актык малны бумый. Мине бүредән акылсызрак дип уйлыйсыңмыни? Мин дә бит үземә җитәрлек кенә алам халыктан. Аннан соң, кем кемне талый торгандыр бит әле! Син атна буе сыйлана торгач, ярты көтү куйны бетердең. Ә минем пәһлеваннарым атнасына берәр сарык, берәр сыер гына ала...

Алып Бәргән Гыйфритне бүлдерде:

— Миңа ул сарыкларны кешеләр үз куллары белән суеп бирде, ә син шул ук малларны талап, урлап аласың!

— Юк, урламыйм! — дип кычкырды Гыйфрит патша.— Нахак яла ягу батыр кешегә килешми, Алып Бәргән! Үз гомеремдә бер генә тапкыр да кеше малына кул якмадым. Миңа ул малларны менә шушы егетләр алып кайта.

— Кешеләрдән талап алып кайта! — диде Алып Бәргән.

— Таласа соң! Синең ни эшең бар, Алып Бәргән! — диде Гыйфрит.— Кешеләрдән үз батырлары талый. Мин түгел! Әнә кара, кырык илнең кырык батыры, кулларына пычак алып, җилдән җитез атларына атланалар да, үз аталарына каршы баралар, үз туганнарын талап кайталар. Талап түгел, дөресрәге, үз өлешләренә тигәнне генә җыялар. Менә бу — минем иң яраткан хатыным, күптән түгел генә Сармат патшалыгыннан алып кайткан гүзәл. Сөйләш син аның белән. Ул сиңа барын да аңлатып бирер,— диде дә Гыйфрит патша үз юлы белән китеп барды.

— Сармат патша кызы! — диде Алып Бәргән икәүдән-икәү генә кал-

гач.— Мин, атаң үтенече белән, сине шушы мәлгунь тырнагыннан коткарырга килдем. Юлга әзерлән!

— Юк! — диде кыз.— Мин моннан беркая да китмим!

— Сине Гыйфрит сихер көче белән алдап тота. Анда сине туган йортың, атаң-анаң, энеләрең, ахирәт кызларың көтә. Һәм, ниһаять, ярәшелгән егетең көтә.

— Бичара син, Алып Бәргән! — диде кыз.— Хатын-кызны аңламыйсың. Ул мәми авыз авыл егетләре белән миңа кызык түгел. Гыйфрит минем сөйгәнем. Куәтле ир һәм байлык! Сармат илендәге кайсы егет шуны миңа бирә ала? Күрәсең бит, батыр егет, монда җыр, монда шигырь: монда сихри табигать, монда мәхәббәт! Кичер мине, якташ, мин синең белән кайта алмыйм. Менә ошбу хатны Сармат патшасына ирештерсәң, минем рәхмәтләр сиңа! Хуш!

Кыз кулындагы хатны батырга тоттырды да сукмак буйлап китеп барды. Алып Бәргән аны саклап йөри торган пәһлеванга дәште:

— Әй син, Сармат пәһлеваны, әйдә кайтыйк илгә. Уян йокыңнан, батыр егет!

Пәһлеваннар барысы бергә җыелып, Алып Бәргәнне урап алдылар да сабыр гына, ләкин каты итеп болай әйттеләр:

— Егет, безне котыртып тагын бер сүз әйтсәң, кырыкка турап, гәүдәңне кырык козгынга ташларбыз. Мә, ал бу кырык хатны. Җитсен илләргә — без үз иркебез белән монда калабыз. Без сәгадәткә ирештек!

Алып Бәргән карап-карап торды да тагын бер карап куйды. Ул үзенең көчсезлеген аңлады. Ошбу кызлар: «Коткар безне»,— дип торсалар, Алып Бәргән кырып салыр иде кырык егетне. Ләкин аларны Ватан, Бурыч, Ата-ана дигән бөек сүзләр белән игә китереп тә, оялтып та, үкендереп тә булмасын ачык күрде батыр. Егетләр аңа мыскыллы карый. Борыннарын чөйгән кызлар, хәерчегә баккандай, мәгърур басып Алып Бәргәнне күзәтә. Аларның бу кыяфәтеннән:

— Бар, кит, бичара Алып Бәргән! Син безгә тиң түгел, чөнки без җәннәт хурлары! — дигән мәгънә аңлашыла иде.

Алып Бәргән, күңелсезләнеп, саубуллашу сүзләре мыгырдап, аланнан чыкты. Алан кырында аны аты Корангыш көтеп тора иде. Алып Бәргән атының тезгененнән тотып озак кына бер ноктага карап торды.

— Нишләргә соң? Кайтып, кара кайгыдагы ата-аналарга: кызларыгыз мәңге кайтмас, — дияргәме? Әллә кызларыгыз һәм улларыгызны Гыйфрит харап иткән диеп әйтү кирәкме? Гыйфритне җиңә алмадым, сугышырга курыктым дип, адәм көлкесенә калыргамы? Батыр әҗәлдән үлмәс, ояттан үләр! Сугышып үлим Гыйфрит белән!

Шулай уйланып торды Алып Бәргән, аннан соң кәпәченнән киңәш сорады.

— Ашыкма! — диде кәпәч.— Синең куәтле чагың, ләкин кырык пәһлеванда сихри дию көче бар. Гыйфрит үзе генә дә кырык диюгә тора. Хәйлә кирәк. Гыйфритнең җилдән җитез аты бар. Корангышны шунда җибәр. Хуҗасының серен аттан башка кем белер? Гыйфритнең җаны кай тирәдә икән? Шуны белсен.

Алып Бәргән алтын сарайга кире әйләнеп керде.

— Диюләргә дию Гыйфрит патша! — диде Алып Бәргән.— Ерак юлда атым арыды, кайтыр юлга җегәре җитмәс. Бер-ике көн җәйләвеңдә атларың берлә утлап йөрсен иде.

— Мәрхабә! — диде хуҗа.

Барча хезмәтчеләрен чакырып, кунакка ачык чырай күрсәтергә боерып, Гыйфрит каядыр китеп югалды.

Алып Бәргән черем итәр өчен үзенә күрсәтелгән ханәкәгә кереп ятты. Корангышияр-йөгәннән арынгач, утлаудагы атлар арасына барып керде.

Алып Бәргән мәрткә киткәндәй уянмыйча өч көн, өч төн рәттән йоклады. Шул гомер эчендә Гыйфрит Сәмәндәл иленнән тагын бер кыз

урлап кайтты. Шул гомер эчендә Корангыш кырык тай белән узышып, куышып йөри торгач, ниһаять, Гыйфритнең Җилҗитмәс аты белән дуслашты. Шул гомер эчендә кырык пәһлеван кырык илне талады.

Алып Бәрган уянып салкын чишмәдә юынды да Корангышын чакырды. Сызгыру белән Корангыш хуҗасы алдында биеп тора иде инде. Бахбай әйтте:

— Озак йокладың, батыр! — диде.— Хәзер Гыйфрит яңа кызы белән әчкәрге бүлмәдә күңел ача. Кырык дию егете мал таларга китте. Җилҗитмәстән белдем. Диюләр диюе Гыйфритнең кара сакалы арасында бер бөртек җирән төге бар икән. Шул төкне утта яндырган кеше Гыйфритне үзенә буйсындыра ала ди. Гыйфрит атнага бер тапкыр сакал-мыегын төзәттерә икән.

Корангышыннан Алып Бәрган батыр белде: бу егетләр чын кеше түгел, бу кызлар да чын хатын-кызлар түгел, ә чын кешеләр кайдадыр базда, зинданда тоткынлыкта икән...

Атна буе бүлмәсеннән чыкмыйча яшь хатын белән күңел ачкач, Гыйфрит патша чәчтарашын чакыртып алды. Чәчтараш аның чәчен кырды, сакал-мыегын төзәтте. Эшен бетергәч, Гыйфритнең башын, чыраен исле май белән хушландырып чыкты. Аннан соң идәндәге чәч-сакалны бергә җыеп, чүплек башына чыгарып ташлады. Алып Бәрган шуннан җирән сакал бөртеген аралап алды да, сарайга таба китте. Аның каршысына чип-чиста итеп кырынган патша үзе килә иде. Диюләргә дию Гыйфрит патша белән батырлар батыры Алып Бәрган күзгә күз очраштылар.

— Озак йоклаганнан соң батырның карыны ачкандыр дип, мин шарлама кырында учак яктырдым. Кичен шунда көтәм сине! — диде Гыйфрит патша.

«Бик яхшы булыр! — диде Алып Бәрган эчтән генә.— Менә шунда мин синең сары сакалыңны утка атармын да, бөтен кабәхәтлекләреңне фаш итәрмен!»

Сөйләшенгән вакытта алар икесе дә учак тирәсендә иделәр. Пешекчеләр казан аскан. Алып Бәрган эшне коры тотарга уйлады.

— Һәй, диюләргә дию Гыйфрит патша! — диде ул кулындагы сары сакал бөртеген учак өстенә китереп.— Менә бу синең сары сакалың булыр! Чак кына кыймылдасаң да синең җаның җәһәннәмгә китәчәк!

— Алып Бәрган, зинһар, ташлама! — дип үкереп, Гыйфрит Алып Бәрганга таба ыргылган иде, Алып Бәрган сакал бөртеген кисәү өстенә ыргытты. Күз ачып йомганчы учак янында коточкыч бер әверелеш булды.

Дию пәрие Гыйфрит Алып Бәрган сурәтенә керде, Алып Бәрган Гыйфрит кыяфәтен алды.

Алып Бәрган кыяфәтендәге Гыйфрит шаркылдап көлә башлады:

— Ха-ха-ха, Алып Бәрган, ахмак батыр син! Сине алдаганнар. Җилҗитмәс тулпарым шулай алдый батырларны. Синең шулай эшләреңне мин алдан күреп, белем тордым... Әйттем мин сиңа, ташлама дидем. Без бит урыннарны гына алмаштык. Син эчтән кеше, тыштан Гыйфрит. Син Гыйфрит кыла торган эшләрне башкарырга мәҗбүрсең. Мин гомерем буе Алып батыр вазифаларын үтәргә тиеш булам. Урын алмашудан ни файда соң кешеләргә? Кырык көн эчендә син әкренләп чын Гыйфриткә әверелеп бетәчәксең. Кырык көн эчендә мин Алып Бәрганга әйләнермен. Аннан тагын Алып Бәрган Гыйфритне үтерергә килер, тагын шушындый алмашыныш булыр... Алып Бәрган һәрвакыт Гыйфритне җиңәр дә, үзе Гыйфриткә әверелер... Тик моннан халыкка һичнинди файда булмас!

Шул мәлне учак янында кырык егет белән кырык кыз пәйда булды. Алар Гыйфрит кыяфәтле Алып Бәрган алдында баш иделәр.

— И, бөек падишаһыбыз Гыйфрит! — диде баш пәһлеван.— Безгә кунак килми, килсә китә белми. Алып Бәрган инде күп кунак булды, аңар юл күрстәтергә вакыт җитте!

Гыйфрит эчендәге Алып Бәрган: «Мин бит Гыйфрит түгел, әнә

тегесе сезнең патшагыз»,— дип әйтергә авызын ачкан иде, ләкин авызы теләгәнен әйтмәде:

— Хатларын тоттырыгыз да, өч көнлек азык биреп озатыгыз!

Алып Бәргән кыяфәтендәге Гыйфрит атына атланып, кайтыр юлга чыкты. Гыйфрит кыяфәтле Алып-Бәргән, җил-давылга әверелеп, Сәрәндип патшасының кызын урларга китте.

Шулай итеп, Алып Бәргән Гыйфрит тормышы белән яши башлады. Көннәр узган саен ул Утыз Имәнлене дә, Нәүмизәсен дә, Караңгышны да ераграк исенә төшерде. Тора-бара ул бу тормышка шулкадәрле күнегеп китте, үзенең Алып Бәргән батыр икәнен дә онытa язды. Караңгытынчу базлардагы кырык егет һәм кырык кызны иреккә чыгарырга дип, күп тапкырлар кулына ачкыч алды. Бакча аша барганда, хур кызларын күреп, ул кая барганлыгын оныта иде. Кырык батыр белән кырык гүзәл зинданда кала бирделәр. Алтын сарайның китапханәсендә утырганда ул саргаеп беткән бер китапка күз ташлады. Бу «Гыйфрит-намә» иде. Шул китапта язылган: Гыйфритнең җаны, имеш, алтын сарай бакчасындагы гөлләрнең берсенә яшерелгән. Шул чәчәкне табып өзгән кеше Гыйфритне җиңә ала имеш. Шул сихерле чәчәккә бер генә бал корты да кунмый, бер генә шөпшә дә якын килми, бер генә бөҗәк тә ул тирәдә очмый икән.

Көннәрдән бер көнне Гыйфрит Утыз Имәнле авылына барып, Нәүмизә исемле иң чибәр кызны урлап кайтты. Һәй, ду килде Утыз Имәнле халкы! Кычкыралар, аталар, чаң кагалар, этләр өрә, йодырык күрсәтәләр. Кемдер бераү:

— Алып Бәргәнгә әйтергә кирәк, Гыйфритне барып үтерсен дә Нәүмизәне коткарсын! — дип акыра.

Ә Гыйфрит эчендә Алып Бәргән икәнен һичкем белмәде. Хәтта каз бәбкәләренә җим сибеп йөргүче әнисе дә батыр улының Гыйфриткә әверелгәнлеген башына китермәде. Шулай итеп, Гыйфрит авылның кызын түгел, утыз имәнен дә төбе-тамыры белән йолкып алып китте. Утыз Имәнле авылы имәнсез, Нәүмизәсез калды.

Китап актарып утырганда Гыйфрит шулар турында уйлады.

— Димәк, хәзер үк бакчадагы теге чәчәкне эзләп табарга һәм өзәргә кирәк! — диде Гыйфрит эчендәге Алып Бәргән.

Ул ашыгып бакчага чыкты. Йөзләгән матур чәчәкләр тирәсендә меңләгән бөҗәк бөтерелә. Шулай эзли торгач, Алып Бәргән ялгыз гына, бөҗәкләрдән читтә утыручы кара мәк чәчәген күрде. Кара чәчәккә һичбер күбәләк, һичбер бөҗәк килми. Чәчәкне өзәргә дип, Гыйфрит кулын сузды да кинәт туктап калды:

— Чәчәкне өзсәм, мин үләм ич! — диде ул үзалдына.

Һәм тиз-тиз атлап сарайга кереп китте.

— Мәк чәчелгән түтәлләрне аеруча нык сакларга! — дип бөтен хезмәтчеләрен кисәтеп куйды Гыйфрит.

Кырыгынчы көн килеп житте. Ул инде бүген тулысы белән Гыйфрит булырга тиеш. Рәхәт, матур тормышта яшәгәндә ул бөтен дөньясын онытты, бар җан иясе дә аның кебек рәхәт эчендә яши дип уйлый иде. Һәм, кирәк булса, шушы урыннан төшмәс өчен ул теше-тырнагы белән көрәшәчәк иде.

Алып Бәргән кыяфәтендәге Гыйфрит байтак көннәр яманлык кылып йөрде. Егерме көн узгач, ул яхшылык эшләргәме, әллә яманлык юлына басаргамы дип баш ватты. Кырык көн тулганда инде ул үзен чын Алып Бәргән дип уйлый иде. Кырыгынчы көнне ул туган авылы Утыз Имәнлегә кайтып керде. Шунда авылга Гыйфрит килеп, Нәүмизәне урлап, авылны туздырып китканлеген белде. Ул әнисе белән күрешеп кенә чыкты да Гыйфритне эзли китте.

Нәкъ теге юлы кебек, Алып Бәргән кара чабаннар янында кунак булды. Аннан тагын алга китте. Таныш сыман тоелды аңа бу юл. Менә хәзер юлда алан булыр. Алан уртасында алтын сарай торыр.

Анда кырык дию егете белән кырык хур кызы яши торгандыр. Һәм шулай булды да. Алып батыр Гыйфрит патшалыгына килеп житте. Гыйфрит аны туганы кебек яхшы кунак итте. Нәүмизәне ул шунда очратты. Ләкин Нәүмизә Утыз Имәнлегә анын белән кайтырга теләмәде. Корангыш белән алар Гыйфритнең Җилҗитмәс атыннан жирән сакал серен белделәр. Алып Бәргән сакалны утка ташлады. Шунда тагын могжизалы бер әверелеш булды. Гыйфрит белән Алып Бәргән кыяфәтләрен алмаштылар. Чын Алып Бәргән әлеге әверелештән соң, башына күсәк белән сугып миңгерәүләтелгән кебек, озак кына башын чайкап торды. Аннан соң рәхәтләнеп көлә башлады. Гыйфрит тә бу үзгәрештән канәгать иде ахрысы, ул Алып Бәргәнне дәстәрхан янына чакырды. Шарлама янындагы учакта җәйран түшкәсе кызып өлгергән иде.

— Менә шундый-шундый хикмәтләр бу дөньяда! — диде Гыйфрит патша.— Хәзер син хәл ит! Сугышыргамы минем белән, юкмы? Тагын сары сакалны яндырсаң, без урыннарны гына алмашачакбыз. Ачыктан-ачык сугышсак, син көл булачаксың. Сайла! Теге пәһлеваннар да, нәкъ синең кебек, минем сакал серен белгәннәр иде. Нәтиҗәсе нәкъ шушылай бетте. Мин һаман Гыйфрит. Ә алар — минем колларым. Риза бул, Алып батыр. Кал син дә алтын сараемда. Минем хатыннарымны сагалап йөрерсең!

Алып Бәргән уйга калды. Бераз шулай тын утырганнан соң ул кинәт үзгәрде, бер чүлмәк шәрабны тын да алмыйча эчеп бетерде. Гыйфрит тә аннан күрмәкче, бер чүлмәкне бугазына койды. Алар шулай озак күңел ачып утырдылар. Соңрак кочаклашып бакча-сарайга таба киттеләр. Кәефе килеп, Алып Бәргән җыр башлады:

Карурманда карак бар,
Атларыңны карап бар.
Без китәрбез таң алдыннан,
Тәрәз ачып карап кал.

— Матур җырлыйсың! — диде Гыйфрит бакча уртасына җиткәч.

— Син күзгә төтен җибәрмә, Гыйфрит дус! — диде Алып Бәргән.— Син миңа Нәүмизәне бир. Әгәр бирмәсәң, камышны кыйган кебек итеп кенә башыңны өзеп төшерәчәкмен!

— Беләсенме, дус кеше! — диде Гыйфрит.— Мин сине яраттым бит, малай! Кызык кеше син, Алып батыр.

— Ә мин сине яратмадым! — диде Алып Бәргән.— Син — минем дошманым!

— Ашаган табагыңа төкермә, Бәргән батыр! — диде Гыйфрит. Син барыбер мине җиңә алмыйсың! Маташма, ахири. Чөнки мин — үлемсез! Минем тәндә җан юк. Җансыз нәмәстәне син үтерә алмаячаксың!

— Беләм, ахир, Гыйфрит дус!

Шулай диде дә Алып Бәргән яшен тизлегендә мәк түтәленә сикерде. Күз ачып йомганчы кара мәк чәчәген өзеп ике учы белән сытты. Гыйфритнең җаны көя күбәләге булып һавага очты. Күбәләкне карлыгач шул мәлне үк кабып йотты. Гыйфрит чибәр егет кыяфәтеннән иләмсез зур гәүдәле, йөнтәс бер дию пәриенә әверелде дә сукмакка аркылы егылды. Шулчак кырык кыз, кырык дию егете берьюлы кайсы убырга, кайсы кәҗә тәкәседәй сатанага әверелеп, кача башладылар. Алып Бәргән ике атлап, бер сикереп, сиксән тапкыр селтәнеп, хәшәрәтләрне турап бетерде. Зиндандагы барлык батырларны, кызларны иреккә чыгарды. Кызлар арасында Нәүмизә дә бар иде.

— Ашагыз, эчегез, рәхәтләнегез! — диде Алып Бәргән.— Бу байлык, бу матурлык сезнеке.

Кырык көн бәйрәм иткәннән соң кайтыр юлга чыктылар. Алып Бәргәннең бу батырлыгы турындагы хәбәр җиде иклимгә таралды.

Төрле илләрнең батырлары Гыйфрит сихереннән котылып, һәрберсе үз иленең гүзәлен алып, һәрберсе үз ватанына юл тотты.

Кырык илгә уртак бәхет килде.

## Кандала Ялмавыздан да куркынычрак икән

Алтын сарайның иң яхшы атын иярләп, Алып Бәргән кәләше Нәүмизәне шуңарга атландырды. Үзе Корангышына менеп, алар Утыз Имәнле ягына очтылар. Кара чабаннар янында бер-ике көн юандылар. Өч көн, өч төн чапкач, алар Биштишек авылына керделәр. Иблисне тотып биргәне өчен Алып Бәргән белән Нәүмизәне мунча ягып кунак иттеләр.

Биштишектән өч көн, өч төн киткәч Түбән Шырдыклы авылы күренде.

— Монда минем бер ахири бар, Җантык исемле! — диде Алып Бәргән.— Монда да шәп кунак итәчәкләр безне. Мин монда Ялмавызны дөмектергән идем. Хәзер рәхәт яшиләрдер.

Ләкин Шырдыклы авылын чак кына таныды Алып Бәргән. Тагын Ялмавыз талап киткән диярсең, билләһи. Элек тә болай хәерче түгел иде бит бу авыл! Урамда арык сыерлар, эченә кыршау тыккан этләр йөри, салам түбәле, кырык тәрәүле өйләр җиргә сеңгән. Өй тәрәзәләре шулкадәр сагышлы карыйлар, җан әрнеп куя. Алып Бәргән телсез-сукыр-чукрак Бәккол картның өенә туры китте. Бәккол карт өенең карындык каплаган бердәнбер тәрәзәсе аркылы-торкылы такта белән кадакланган иде. Алып Бәргәннең йөрәге чәнчеп куйды. Бичаракай ятим картны бераү дә тәрбияләмәгән икән.

— Нәрсә булды сезнең авылга? — дип сорады ул иңрәеп чыбык күтәреп кайтучы карчыктан.

— Ялмавыз бер яктан талый, икенче яктаҥ Җантык атлы кандала канызбызны эчә. Ясак белән салымнан баш чыккан юк, балам.

— Ялмавызны үтергән идем бит мин! — диде Алып Бәргән шаккатып.

Әби Алып Бәргәнгә шик белән озак кына карап торды да берни дәшми китеп барды. Очраган икенче кеше дә күп сөйләшергә теләмәде. Каршысында Алып Бәргән торганны аңлагач, өченче кеше, як-ягына карана-карана булса да, түбәндәгеләрне сөйләп бирде:

— Җантык батыр, Ялмавызны үтереп кайткач, Колавызның кызы Хөрмиягә өйләнеп, үзе түрә булды...

Дошманны җиңеп кайткан батырны халык башта бик яраткан, зур-зур бүләкләр биргән. Тора-бара Җантык бүләкләрне сорап ала башлаган, аннан соң таләп итәргә тотынган. Соңра шундый фәрман тараткан: «Мин — җантык батыр, Ялмавызны җиңгән кеше буларак, эшләмичә ятарга хаклымын. Сез мине ашатып-эчертеп -киендереп торырга тиешсез!» — дип, халыкны чынлап талый башлаган.

Түзә алмагач, кешеләр баш күтәргән. Ясак-салым түләми башлаган. Бәхетсезлеккә каршы, Ялмавыз үлмәгән булган икән. Җантык Ялмавыз белән дуслашып алган. Беркөнне Ялмавыз тау башыннан торып болай дигән:

— Мин — Ялмавыз, сезнең өстән башлык итеп Җантык түрәне куям. Сез миңа дигән малларны аңа тапшырырга тиешсез!

Шуннан соң кешеләр атна саен бер баш сарык, бер баш сыер, бер олау икмәген Җантыкка тапшыра башлаган. Җантык яртысын үзенә алып калып, калганнарын көтүе белән каядыр, таулар артына Ялмавызга илтә икән. Бирмәсәң, Җантык Ялмавызга йөгерә. Ялмавызга каршы барырга берәүнең дә кулыннан килми.

— Коткарсаң, син генә коткара аласың инде безне, Алып Бәргән батыр! Хәзер Җантык кандала Ялмавызга әләкләшергә менеп китте. Озакламый тау башында Ялмавыз пәйда булыр! — дип сүзен бетерде ага кеше.

Өч тапкыр чаң сукканы ишетелде. Йончыган, фәкыйрь кешеләр берәм-берәм мәйданга җыела башлады. Тау башында Ялмавызның иләмсез гәүдәсе калыкты.

— Сез! Шырдыклы кешеләре! — диде Ялмавыз.— Сез тагын гыйсьян куптарасызмы? Ясак-салымнарыгызны иртәгә өзеп бетермәсәгез, авылы-

гыз урынында көл генә уйнаячак! Җантыкның һәр сүзе сезгә минем сүз булырга тиеш! Таралыгыз!

Халык һич ни әйтмичә генә тарала башлады. Алып Бәргән шаккатты, тау башында чыннан да Ялмавыз басып тора бит. Ничек терелгән ул? Алып Батыр аны үз куллары белән үтергән иде бит.

— Таралмагыз, кешеләр! — диде Алып Бәргән.— Ялмавызга бер авыз сүзем бар!

— Кем ул миңа сүз катарга җөрьәт итә? — дип кычкырды Ялмавыз.

— Бу мин! Сине бер тапкыр үтереп, койрыгыңны кисеп истәлеккә алган батыр — Алып Бәргән буламын!

Моны ишеткәч, Ялмавыз телсез калды.

— Нигә дәшмисең, Ялмавыз? Әллә Җантык батыр телен йоттымы? Мин сине икенче тапкыр үтерергә дип килдем! Һәллүр, Корангыш! — диде Алып Бәргән үкчәләре белән атының корсагына кагылып.

Корангыш күз ачып йомганчы хуҗасын тау башына алып менгерде. Алып Бәргән Ялмавыз белән янәшә басты да түбән таба карап кычкырды:

— Һәй, кешеләр, сезне куркытып торган Ялмавыз — кабарткан коры куык кына. Ягъни, мин үтереп үләксәсен Җантыкка бүләк иткән чын Ялмавызның кабыгы гына ул! — диде дә Алып Бәргән кылычын Ялмавызның корсагына тыкты.

Ялмавызның тыны пышлап чыга башлады. Куык шиңеп беткәч, барча халык Ялмавыз карачкысы артында торган симез, түгәрәк гәүдәле Җантыкны күреп алды. Җантык үкереп елый иде.

— Кичерегез мине, кешеләр, мин кабат алай эшләмәм! — дип туктаусыз кабатлый үзе.

Җантыкның бар амбарлары да ачылды. Халык хәләл икмәген, үз көче белән тапкан малларын кире алды. Түбән Шырдыклыга да бәйрәм килде бүген. Тик бәйрәмдә Җантык кына күренмәде. Ул оятыннан җир тишегенә кереп киткән иде, ахрысы.

Бу хәл һиҗрәттән соң тугыз йөз кырык ике ел узгач булды.

## Алып Бәргән Эллэй халкына яхшылык эшли

Кайдан гына эзләмәде Алып Бәргән Аждаһаны! Мәгърипкә дә, Мәшрикъкә дә барып карады — юк Аждаһа! Кемнәрдән генә сорашмады ул Аждаһа турында. Талый да кача, кая киткәнлеген һичкем белми, һичкем күрми кала икән. Ил гизүче кәрванчылар белмәсме икән дип юлга чыкты. Диңгезләрне айкаучылар белмәс микән дип корабларга утырып йөрде. Юк, бер генә кеше дә Аждаһаның кайдалыгын әйтә алмады.

— Бер генә тараф калды син булмаган! — диде Алып Бәргәнгә Кәпәче.— Ул да булса — Котып! Кар каплаган илдә син булмадың.

— Этөрер агачыннан ясалган чаңгыдан башка син кар илендә берни дә эшли алмассың! — диде әнисе.— Этөрер чаңгысын кигән кешене эт тә, ат та, җил дә куып җитә алмый.

— Ярый алайса,— диде Алып Бәргән.— Мин урманга менеп, этөрер агачын кисеп алып кайтыйм әле.

— Юләр! — диде ана.— Этөрер агачын беркем дә таба алмый. Атаң мәрхүм аны гомере буе эзләде, табалмады.

— Ятып калганчы атып кал! — диде дә Алып Бәргән атына атланып урманга китте.

Көнозын йөрде ул, төнозын эзләде, ләкин этөрер агачын табалмады. Өченче көнгә киткәч кенә өметкәйләре өзелеп, кайтыр юлга борылды. Шулчак карурман уртасында эт өргән аваз ишетелде. Алып Бәргән тавышка таба китте. Куе чытырманлыкта бер агач эт өргән тавыш чыгарып утыра иде. Батыр егет этөрер агачын кисеп алды да, шатлыгыннан нишләргә белмичә, атын чаптырып өенә кайтып китте. Шул агачтан ул чаңгы ясады, баулар такты, арткан агачтан ике таяк юнды. Чаңгы-

ларны жиләс түбәгә элеп, һәйбәтләп кенә киптерде дә Корангышына атланып, Котыпка карап юлга чыкты.

Һиҗрәттән соң тугыз йөз илле ел узгач булды бу хәл.

Казык йолдызга туры бара торгач, ниһаять, тирән карлы илгә килеп җитте. Корангыш бил тиңентен карга кереп батты. Күпме генә талпынса да, бичара хайван алга таба бара алмады.

— Корангыш! — диде Алып Бәргән.— Син шушында агач бөреләре белән тукланып мине көтәрсең. Мин әйләнеп кайтканчы китмә!

Шуннан соң батыр этөрер чаңгысына басып юлын дәвам итте. Бер талпынып таяклары белән этенсә, ике тапкыр атласа, Алып Бәргән ике фәрсах җир китә. Шулай итеп, ул ат белән бер ел үтәрлек араны өч көндә узды. Шул гомер буе аның юлында бер генә авыл да, бер генә шәһәр дә, бер генә кеше дә очрамады. Ниһаять, дүртенче көнне генә ул ап-ак кар дәрьясында кара-кучкыл нокталар күрде. Тора-бара ул нокталарның очлы өйләр икәне ачыкланды. Очлы өйләр янына бер төркем халык җыелган. Күбесенчә хатын-кызлар, бала-чага, карт-коры иде монда. Калганнары кысык күзле, җыерчык каплаган чырайлы вак ир-зат иде. Кешеләр, Алып Бәргәннең киләсен алдан ук белгәндәй, аны каршы алырга чыкканнар, ахрысы. Унлап эт җигелгән чанага утырып бер карт килде.

— Безнең шаман әйтте, балкышка каршы яктан бер яхшы ир килер диде. Без сине көтәбез!

Очлы түбәле, тире-кайры белән капланган бу өйләр «чум» дип атала икән. Кешеләрнең башында аю бүрек, аю тун, аякларында аю итекләр, кулларында аю бияләйләр. Урта чумнан ике карт чыкты. Аларның икесен дә тиреләр белән түшәлгән махсус урынга утырттылар.

— Бу — безнең башлыгыбыз! — диде Алып Бәргәнне каршы алган кеше.— Икенчесе — безнең шаман! Хәзер синең хөрмәткә ярыш башланачак!

— Һәй-һой! — дип кычкырды уен башлыгы.

Шул тавышны ишеткәч, этләр җигелгән чанага утырган бер кыз һәм икенче чанадагы берничә ир-зат ыргылып кузгалып китте. Кемдер чанасыннан тәгәрәп төште. Аның булдыксызлыгын дәррәү көлеш белән мыскыллладылар. Бераздан кыз беренче булып әйләнеп кайтты. Егетләр утырган чаналар әллә кайда артта калган иде. Башлык кеше шаман дигәннәре белән нидер пышылдашып алды да бик ачыргаланып:

— Бөтен өметем бетте! — диде.— Ир кеше юк икән арагызда. Хатын-кыз әсәрәтен дә куып тота алмыйсыз!

— Һәй-һой! — дип боерды тагын уен башы.

Бу юлы әлеге кыз да, кайтып җиткән ир-затлар да чаңгы киделәр, кулларына таяклар алдылар. Оештыручы карт тагын «Һәй-һой» кычкырды. Узыш башланды. Әлеге кыз бураннар уйнатып иң алда чаба. Алып Бәргән дә чаңгы таккан егетләр белән рәттән тора иде, ул кинәт кенә узыш дәртенә бирелеп, егетләр артыннан кузгалды. Бер-ике талпынган иде, бөтен егетләрне дә узып китте. Тагын бер омтылган иде, кыз белән ара яртылаш кыскарды. Куып җиттем дигәндә генә кыз кинәт кенә борылды да чумнар ягына таба элдерә башлады. Алып Бәргән аның артыннан томырылды. Тагын бер талпыну белән кызны куып та җитте, тотып та алды. Чумнар тирәсендәге бала-чага һәм карт-коры кычкыра, сызгыра башлады. Башлык кеше белән шаман дигәннәре урыннарыннан төшеп, сикерә-бии иделәр.

— Менә ул чын ир-егет! — дип кычкыра башлык.

Шаман белән башлык Алып Бәргәннең аркасыннан сөя-сөя урта чумга алып керделәр. Алып Бәргәнне зур хөрмәт белән түргә, сәкесыман җиргә дәштеләр. Әлеге кызны да аның белән янәшә утырттылар.

— Менә сиңа әкәмәт! — дип уйлады Алып Бәргән.— Әллә болар мине шушы кызга өйләндерергә маташалар инде?

Чит илдәге гадәтләрне белмәссең дип дәшми калды.

— Син безнең иң кадерле кунагыбыз! — диде башлык.— Шуңа күрә без сиңа иң тәмле, иң яраткан ашыбызны ашатачакбыз!

Тутырган карын, чыннан да, бик тәмле булып чыкты. Алып Бәргәннең тәмләп, озаклап, күп ашаганын күреп, картлар соклануларын яшерә алмыйча:

— Хай-хай-хай-хай! — дип сөенешеп утырдылар.— Менә бу ир ичмасам, менә бу егет ичмасам!

Аннан соң Алып Бәргәнгә күрше чумнан сөт алып керделәр. Бу — каткан кымыз иде.

— Җәй көнендә без көнъяккарак күчәбез дә, шунда сыер-атлар асрап, кымыз ясыйбыз. Шул кымызны алып килеп шушында бозландырабыз. Кымыз унар ел буе бозылмыйча саклана,— дип аңлатты хуҗа.

Шулай бик озак кына сөйләшеп утырганнан соң башлык әйтте:

— И җилдән җитез аяклы батыр! Без бик аз калдык. Әнә күрәсең, нибары сигез чатыр бар. Чир алып китте күп балаларны. Сугышта үлде күп ирләр. Аудан кайтмады калганнарыбыз. Шулай итеп, борынгы бабабыз Элләй нәселе корып калырга мөмкин. Син — чын ир-егет! Кал минем илдә, бул киявем минем!

Алып Бәргән үзенең кала алмаячагын әйтте. Карт башлык күз яшьләре белән елап, ялвара башлады.

— Зинһар, кал! Күпме телисең, эт бирәбез. Күпме телисең, төлкеаю тиресе алырсың. Кымыз тавы сиңа булыр! Зинһар, сүземне аяк астына салып таптама, батыр егет! Бу кыз гомерлек ярың, хатының булыр.

— Юк, мин калалмыймын! — диде Алып Бәргән.— Минем илем бар, халкым бар, максатым бар. Мин Аждаһа атлы хәшәрәтне табып, җиңәргә тиеш. Бу минем соңгы сугышым булачак!

Башлык белән шаман шуннан соң да озак ялындылар Алып Бәргәнгә. Алып Бәргән сүзендә нык торды.

— Алайса,— диде башлык,— ихтыярың, батыр егет! Ләкин кызым белән бер йоклап кит. Әгәр разый булмасаң, без сине җибәрмәячәкбез!

Алып Бәргән тәбәнәк буйлы ир-затларга карап елмайды: утызын берьюлы билбавына кыстырып, үзем белән алып китә алам мин аларны, янәсе.

— Көлмә, Чит Кеше! — диде башлык чын йөрәктән.— Вак халык дип көлмә бездән. Безнең ата-бабаларыбыздан калган горурлыгыбыз бар. Без сине көч белән алдырмасак, хәйлә куәте белән мәңгегә шушында калдыра алабыз. Без кеше ирегенә кул сузучы халыклардан түгел. Әмма ләкин, егет, күрәсең, нәсел кырылып бетәргә күз тоткан. Эллэй батыр токымын саклап калу өчен, без сиңа хәйлә кулланырга мәҗбүрбез.

Башлык шаманны чакырып китерде.

— Һәй-һой! — диде башлык.

Шаман дигәннәре аяк-кулларына кыңгыраулар таккан, башына эт-балык сөякләре элгән, кулына чуклы, шөлдерле чаңгырак тоткан.

— Уру-уй... ай-халай... юуру-юуң... ае-туя-ан... Урдах-урдах, Җәсәгәй-Җәсәгәй! — дип акыра-кычкыра бии башлады.

— Камла әйдә, шаман, камла тизрәк! — диде башлык.

Шаман шул ук сүзләрне кабатлый-кабатлый тагын да кызурак бии башлады. Озак кына шулай кыланганнан соң, шаман күз бәбәкләрен акайтып, җиргә егылды. Аннан соң, бума чиреннән айный башлаган кешедәй торып утырды.

— Я, нәрсә диде тәңребез Урдах Җәсәгәй? — диде башлык.

— Ят кеше моннан китә алмый! — диде шаман.— Ят кеше эзли торган яманый затның кайдалыгын шаман белә!

— Кайда! — дип сикереп торды Алып Бәргән.—Кайда ул Аждаһа мәлгунь? Әйт, шаман!

— Юк! — диде башлык.— Шаман сиңа Аждаһаның кайдалыгын бары тик безнең шартны үтәгәннән соң гына әйтәчәк!

Алып Бәргән бер шаманга, бер башлыкка карап алганнан соң, аңлады — бу ике карт серне чыннан да әйтмәячәк! Карт шаман инде яшәсен яшәгән, башлыкның да гомере әллә ни озын калмагандыр. Бу ике картны бернинди үлем дә куркытмый!

— Ярар! — диде Алып Бәргән.— Сыегыз өчен рәхмәт! Юл кешесенең юлда булуы хәерле, мин кузгалыйм! — дип өйдән чыкты.

Чыкса, ни күзләре белән күрсен: тирә-яктагы очлы чумнар урынында җилләр генә исә. Этләр дә юк, эзләр дә юк, Алып Бәргәннең этәрер чаңгысы да юк. Әйләнә-тирә ап-ак кар, ап-ак кар... Бары тик бер чум калган. Ул чум эчендә карт башлык, карт шаман һәм кайгысыннан елап утыручы кыз. Алып Бәргән чумга кире керде.

— Менә шулай! — диде башлык.— Синең җилдән җитез чаңгыңны минем кешеләрем еракка-еракка алып киттеләр. Чаңгысыз син беркая да бара алмыйсың. Этләр белән айлар, еллар буе барырга кирәк синең илгә җитү өчен. Җәяү китсәң, син суыктан, ачтан интегерсең. Син мондагы ауны белмисең. Бар, киребеткән Чит Кеше, юлыңда бул! Син безнең йоланы мыскыл иттең, без күрсәткән кызны яратмадың. Бар, кит!

Алып Бәргән, ачынуыннан нишләргә белми үкереп, кылыч белән картларга кизәнде. Кыз Алып Бәргән аягына егылды.

— Тимә картларга! — дип кычкырды ул.

Картлар күзләрен дә йоммадылар. Кизәнгән батырга сабыр гына карап торалар.

— Туракла безне, батыр егет! — диде карт башлык.— Болай да бер уч калган халыкның акылын, динен, бердәнбер нәселле кызын үтер! Менә булыр батырлык!

Алып Бәргән үзенең бик четерекле хәлдә калганлыгын аңлап, кылычын кынысына салды да савыты-ние белән күтәреп, салкын кымыз эчте. Бичара кыз сикереп торып, Алып Бәргәнгә тагын бер савыт кымыз бирде.

— Шулай! — диде башлык.— Сез кызыш халык икәнсез. Ләкин сезне кызышлыгыгыз харап итәчәк. Сез башка кешенең йоласына төкереп карыйсыз икән. Кызыбызны харап итмә. Без теләп биреп тә, кыздан баш тартсалар, кыз шул көнне үк үзен-үзе үтерергә тиеш!

Алып Бәргән, ни әйтергә белмичә, уйга калды. Нишләргә соң? Чаңгыны эзли чыгу — акылсызлык. Каян табасың инде ул кешеләрне? Кайтыр юлга чыксаң — тугры үлем! Күп ашаганлыктанмы, әллә юл йөреп арылганмы, әллә кымызлары шулай изрәтә — Алып Бәргән талгын гына йоклап китте. Уянганда чумда алар икәү генә иде.

Шулай итеп, Алып Бәргән Котып уртасындагы ялгыз чумда яши калды. Кызның исеме Җаргылай булып чыкты. Боз базында алар өчен түшкә-түшкә аю, болан, балык ите бар. Икенче бер боз базында кантар-кантар катырылган кымыз саклана. Җаргылай көн саен ит куырып ашата. Кымыз белән сыйлый. Алып Бәргән чыгып-чыгып чум тирәли әйләнеп керә. Кайдадыр аның туган иле, туган авылы Утыз Имәнле. Кайдадыр аның сөйгәне Нәүмизә. Кайдадыр мәлгунь Аждаһа яши...

Ак төннәр бетеп, кара төннәр башланды, кара төннәр бетеп, тагын ак төн килеп җитте. Алып Бәргән белән Җаргылай бер-берләренә ныклап ияләнделәр. Тора-бара Алыпка бу кыз ошый башлады. Чыннан да, Алып Бәргән Җаргылайга сөеп карый. Җаргылайның да бәхете хәттин ашкан иде, ул көннәр буе Алып Бәргәнгә үз халкының язмышы турында риваятьләр сөйләде.

Шаман әйтте:

— Имеш, безнең халык бөек була алмый. Бездә батырлар юк. Ул батыр кайчандыр туган булган. Аңа Мөгез Угыл дип исем кушканнар. Чөнки аның тәне гел мөгез сымак каты калкан белән капланган булган. Мөгез Угыл җиде яшьтә чакта бөтен ирләрне борып кына сала торган булган. Шуннан соң монда куркып, көнләшеп карый башлаганнар. Тыгын дигән усал комсыз кеше аны үтерергә уйлаган. Ләкин күпме генә тырышса да Мөгез Угылны үтерә алмаган. Мөгез Угылның тәненә пычак та,

ук та үтеп керми икән. Шуннан соң Тыгын Мөгез Угылның анасын куркытып серне сораган. Ананы үтерсә дә, серне ала алмаган Тыгын бай. Болардан качып, урманда яшәргә мәҗбүр була Мөгез Угыл. Йоклап ята торган яшерен җирендә Мөгез Угылны эзләп табалар. Без белән күзенә кадыйлар Тыгын кешеләре. Мөгез Угыл үләр алдыннан: «Озакламый озын борынлы әшәке кешеләр яу белән килер, шул чагында сез, аһ, Мөгез Угыл булса дип, үкереп еларсыз, ләкин мин булмам»,— дигән дә җан биргән...

Чыннан да, Мөгез Угыл үлгәннән соң биш ел узгач, иләмсез озынборыннар килеп, ирләрне кырып, егетләрне коллыкка алып киткәннәр. Шуннан безнең халык бик аз калган. Калганы да гарип-гораба, карт-корылар гына... Шаман әйтә: «Җаргылайдан туган ир бала бу халыкны токымсызлыктан да, озынборыннардан да коткарачак»,— ди...

Шулай озак айлар яшәп ятканда Җаргылай бер ир бала тапты. Җаргылайның шатлыгын күреп, Алып Бәргән дә сөенеп куйды. Яшь ана яңа туган баланы күтәреп өй тирәли әйләнеп йөри башлады.

— Чыпчыклар катып үләрлек салкында балага салкын тидерәсең бит! — дип кычкырды Алып Бәргән.

— Чум тирәли тәңребез Урдах Җәсәгәйгә рәхмәт әйтеп йөргәндә дә салкын тисә, ул баланың нигә кирәге бар? — диде ана.

Җаргылай хуш исле май белән сөртеп, каймак кебек юка иләнгән йомшак тире биләүгә баласын биләде. Шуннан соң яшь ана ике көчекнең берсен өстереп, кар даласына чыгарып җибәрде.

— Маһмай әтиләргә ир бала туганлыгын хәбәр итәргә китте! — диде бәхетле ана.

Ике көннән соң Алып Бәргән иртән торып тышка чыкса, ни күзләре белән күрсен: чумнар үз урыннарында, шаман да шунда шашып бии, барча халык шатлана. Карт башлык, сөенеченнән елый-елый, нидер кычкыра:

— Урдах Җәсәгәй! Урдах Җәсәгәй!

Бәйрәмнең чиге булмас кебек иде. Балага Тимер Кул дип исем куштылар.

— Менә чаңгыларың, Үз Кеше! — диде шаман.

— Син, Үз Кеше! — диде башлык карт.— Диюләрне, иблисләрне җиңгән батыр, рәхмәт! Ә безнең халык өчен синең батырлыгың алардан да кыйбатрак! Менә синең батырлыгың! — дип карт башлык Тимер Кулны һавага күтәрде.— Рәхмәт, Үз Кеше, рәхмәт!

— Сау бул! — диде Җаргылай.— Менә сиңа миннән истәлек! — дип, Җаргылай теге көчекләрнең берсен Алып Бәргәнгә тоттырды.— Ал син аны, читенсенмә! Ана «Тайбыр» дип дәшәрсең. Тайбыр синең иң тугры ярдәмчең, дустың булыр. Бу — шаманнар эте. Ул тәңребез Урдах Җәсәгәйдән куәт алган. Авыр чакта син аңа дәшсәң, ул кеше теле белән сөйләшә башлар. Хуш, баһадир!

— Хәерле юл, Үз Кеше! — диде башлык.— Юлыңда бул, без сине тотарламыйбыз!

Шаман әйтте:

— Син эзләгән явыз зат Мәгърибтә, чатыр кебек үр өстендә — диде Тәңребез Урдах Җәсәгәй. Үрнең бер ягында дала. Ул даланы талый. Үрнең икенче ягында диңгез булыр. Ул диңгезне талый. Үрнең өченче ягында таулар булыр. Ул тауларны талый. Үрнең дүртенче ягында урман булыр. Ул урманны талый. Ләкин аны җиңү мөмкин түгел диде Тәңребез. Бар, кулыңнан килсә, коткар халыкларны шул бәладән, Үз Кеше!

Алып Бәргән көчекне куенына тыгып, чаңгыларын киде дә:

— Сау булыгыз, Әлләй балалары! — дип кайтыр якка борылды.

Бераз баргач Алып Бәргән артка борылып карады: еракта, бик еракта ап-ак кар даласы түрендә кара нокталар күренә, һәрбер нокта бер адәм. Шулар арасында аның токымы Тимер Кул һәм Тимер Кулның анасы Җаргылай.

Алып Бәргән шуны аңлады: ул беркайчан да үзенең улы Тимер Кулны да, мөлаем Җаргылайны да күрмәячәк.

# Үкереп елый Алып Бәргән батыр

Хуҗасы Алып Бәргәнне көтә-көтә Корангыш көтек булды. Котып ягына карый-карый муеннары каерылып бетте, күзләре күгәрде. Бер ел булды дигәндә генә, ап-ак карны пыр туздырып Алып Бәргән кайтып төште. Хуҗасын ул ерактан ук кешнәп каршы алды. Алып батыр атының муенын сыпыра-сыпыра сөйде, ялларын тарый-тарый иркәләде, кочаклап елап та алды бугай шунда. Чаңгысын салып, тире капчыкка тыгып, ияр артына бәйләде. Аннан соң иярга менеп утырды. Корангыш сыртында җайдак күрмәгәнгә кырык ел узгандай сагынып, тансыклап, һәйдәгәнне дә көтмичә алга очты. Ләкин Алып Бәргән Аждаһа патшалыгына кай яктан барырга икәнлеген чамалап та белми иде. Кәпәче дә бу сорауга җавап бирә алмады. Шулчак Алып Бәргәннең куйнындагы Тайбыр кыймылдап куйды.

— Һәй, Тайбыр! — диде Алып Бәргән.— Аждаһа өненә ничек барырга?

Тайбыр, хуҗасының куенынннан башын чыгарып, болай диде:

— Мин башымны, танавымны кайсы якка каратып тотсам, шул якка бар! Шуннан соң эзләгәнеңне табарсың!

Озак булды бу сәфәр. Мең бәлаләргә очрап, чүлне кичтеләр. Чүлләрдә, диңгез буенда да, мескен халыклар, телен оныткан кешеләр очрый. Очраган кешеләр, Алып Бәргәннең кая барганлыгын белгәч, елый-елый ялвара башладылар:

— Барма анда, зинһар, батыр егет! Сугышма, зинһар, Аждаһа белән!

Алып Бәргәннең туктамасын белгәннәр аның артыннан каргыш ташладылар:

— Дөмек шунда, җүнсез батыр! — дип калдылар.

— Сәер, сәер! — диде Алып Бәргән.— Бөтен кеше явыз затка каршы яуга киткән батырларны рәхмәтләр укып, изге теләкләр теләп озата торганнар иде. Боларга ни булган соң?

Алып Бәргән диңгезне дә, тау илен дә, урманны да узды. Озакламый Аждаһа патшалыгы булыр, ахрысы. Алга барган саен кеше-ат сөякләре, сынган кылычлар, умырык калканнар еш очрый. Эчкә кергән саен сөякләр күбәя, атка аяк басар җир күренми. Алда ак калкулык күзгә чалына. Якынрак баргач, аның кеше баш сөякләреннән өелгән тау икәнлеге беленде.

— Күп батырлар шушы галәмәтләрне күреп, шушында ук җан биргән икән! — диде Алып Бәргән.

Сөяк тавының аргы ягыннан яхшы юл башлана икән. Юл кырында зур мәрмәр ташка:

**АЖДАҺА ПАТШАЛЫГЫ**

дип язылган иде. Корангыш, чикне узаргамы-юкмы дигәндәй, икеләнеп туктады.

— На-а, һәйдә! — дип хуҗасы кычкыргач, теләр-теләмәс кенә алга атлады.

Алда гаять матур табигать манзарасы ачыла. Яшеллек, көтүлекләр, тугайлар, елга буендагы тал-тирәкләр, бихисап мал көтүләре, каерылып үскән арпа-арыш кырлары; һавадагы меңләгән тургайлар тавышын, су коенырга кыстап кычкыручы күкеләрне тыңлап, Алып Бәргән хәйран калды. Нинди Аждаһа булсын да, нинди куркыныч булсын монда? Менә дигән матур тормыш!

Шулай бара торгач, ул чатырлар корылган җәйләү күрде. Әйтерсең лә яр якасына чатыр-шәһәр төзеп куйганнар! Мөгаен, бер-бер аксөяк түрә үзенең туганнары белән сәхрәгә чыккандыр дип уйлады Алып Бәргән. Чатырлардан ерак түгел генә ап-ак таш кала ялтырый. Шул ап-ак манараларны, кәрвансарайларны, таш диварларны зәп-зәңгәр күк пәрдәсенә ябыштырып куйган кебек. Манараларның алтын гөмбәзләре кояшта ялтарап, күзне чагылдыра. Күз явын алырдай шушы матурлыкны күреп,

Алып Бәргән генә түгел, аты Коранғыш та, эте Тайбыр да авызларын ачып шаккаттылар.

Юл туп-туры чатырларга алып килде. Зәңгәр, яшел, шәмәхә төстәге чатырлар белән Ак Шәһәр арасында йөзләгән ир-егет кайнаша. Алар җиргә җәеп салынган келәмнәргә кырын ятып, әхтәри уйныйлар, кәрт сугалар иде. Уйнаучылар да, аягүрә басып уенны тамаша кылучылар да шешәләрнең бугазыннан гына кымызмы, шәрабмы чөмерәләр, тәмәке пыскыталар. Янәшәдәге казаннар тирәсендә җыйнак-матур киенгән чибәр кызлар әш-мәшә килә.

— Мин бер-бер бәйрәм яки сабан туе шикелле нәрсәгә килеп эләктем, ахрысы,— дип фараз кылды Алып Бәргән.

Атыннан төшеп, ул егетләргә сәлам бирде. Уенчылар һәм тамаша кылучылар Алып Бәргәнгә борылып та карамадылар. Төркем арасында таныш йөзләр күреп, Алып батыр шаккатты. Әнә, алгы келәмдәгесе күрше авылның Гали батыр. Аргысында әхтәри уйнаучыларның берсе Карахмәт бугай. Алар бит кайчандыр Аждаһага каршы яу белән киткән батырлар.

Халык, Аждаһа белән сугышып үлде дип, алар өчен кан-яшь түгә. Ә болар исән-сау лабаса. Рәхәтләнеп гомер кичерә, шәраб эчә, кызлар коча.

Шулчак аның янына берничә кыз килеп баш иде.

— Мархабә, и олуг батыр! — диде кызлар башлыгы.— Табынга рәхим ит!

Чирәм өстенә җәелгән дәстарханга ымлап, кызлар егетне кыстый башладылар. Берничәсе батырның атын су эчерергә алып китте. Батыр гамьсез егетләргә аптырап карады.

— Син аларга аптырама, егет! — диде дәстархан башлыгы.— Аларның иң кызган чагы. Алар көн саен шулай әхтәри уйныйлар.

— Бу нинди ил соң? — дип сорады Алып Бәргән.— Чик буенда «Аждаһа патшалыгы» диеп язылган. Кайда соң Аждаһа патшалыгы?

Кыз җавап бирергә өлгермәде, кәрт сугучылар башлыгы Алып Бәргәнгә карамыйча гына болай дип кычкырды:

— Алып Бәргәнне дивана дип әйтә торганнар иде, хак икән!

— Ачуланма син аларга! — диде кыз.— Бу чыннан да Аждаһа иле.

— Нишләп соң алар шулай гамьсез, кайгысыз? Нишләп соң алар Аждаһага каршы сугышмыйлар?

Кыз әйтте:

— Аждаһа коточкыч куәтле, мәкерле зат. Аңа каршы сугышуның файдасы юк. Аждаһага каршы сугышу бары тик халыкка зыян гына китерә. Шуңа күрә, бу егетләр Аждаһа белән әшнәләште. Син дә сабыр бул, зинһар, бәйләнмә аларга. Бу егетләр рәхимсез, алар сине үтерер, егет.

— Алайса бу әшлексезләр, халыкка зыян килмәсен дип, шушылай кәеф-сафа корып ята? — диде Алып Бәргән барысы да ишетерлек итеп.

Кыз кеше Алып Бәргән алдына җанын ни тели, шуны китереп куйды. Ләкин Алып Бәргәннең ашауда кайгысы юк иде. Ул ачуыннан шартлар дәрәҗәдә бүртенеп кычкырды:

— Һәй, сез, илнең батыр егетләре! Анда халык ярым ач, ялангач яши. Ачлыктан балалар кырыла, җан саклар өчен кешеләр үлән ашый, кайры кимерә. Ни йөзегез белән сез тук кыяфәттә монда кәрт сугып ятасыз, оятсызлар!

Бу сүзләр дә уенчыларны урыныннан кузгата алмады. Алар Алып Бәргәнне күрмәмешкә салыштылар. Аларның бу гамьсезлеге батырның канын кайната башлады.

— Нигә сез Аждаһага каршы бәйгегә чыкмыйсыз? Нигә сез һич югы илегезгә кире кайтмыйсыз? Хуҗалыкта файдагыз тияр иде ичмасам!

— Чәпчемә әле син! — диде Гали батыр.— Утыр, әйдә. Аша, эч, аннан соң безнең белән әхтәри сугарсың. Синдәй кызу канлы баһадирлар күп булды монда. Әнә, андыйларның баш сөякләре теге тау түбәсендә.

Алып Бәргән кызганнан-кыза барып, тузанлы итекләре белән уенның нәкъ уртасына барып керде дә аяклары белән тегеләрнең әхтәриләрен туздырып ташлады. Уенның рәте китте. Егетләр сабыр гына таралышып табын янына килделәр. Алар шулай эндәшмичә генә чүлмәкләрдәге салкын шәрабне күтәреп эчтеләр дә тәмәке кабыздылар. Алып Бәргән дәстархан паласын күтәреп атты. Андагы ризык, шәраб тулы чүлмәкләр туфракка тәгәрәде. Шунда гына уенчылар башлыгы нидер ысылдады. Бөтен батырлар Алып Бәргәнне урап алды. Башлыклары зәһәрле күзләре белән Алып Бәргәнне тишәрдәй итеп, сөзеп карады да, кысылудан каны чәчрәп чыга язган юка иреннәре белән ысылдап, болай диде:

— Ссин, мокыт! Нишлис-сең с-син? Пычрак аякларың белән тәгамга басып керәсең. С-син тапкан мал түгел бит ул, дивана! Сине анаң: икмәкне таптама, ризыкны хөрмәт ит дип өйрәтмәдемени, надан?!

Баш егет тимердәй йодрыгы белән Алып Бәргәннең күкрәк турына сукты. Алып Бәргәннең тыны капланды. Ул бөгелеп төште. Куеныңдагы Тайбырны җиргә төшерим дип, изүен чишкән иде, баш егет хәнҗәр белән кизәнде. Шул чак Тайбыр хәнҗәрле егеткә ыргылып, аның борынын тешләп алды. Баш егет авыртуга түзә алмыйча акыра-бакыра башлады. Үзе арлы-бирле чаба, танавына шытырдатып ябышкан этне алып атарга чамалый. Көтелмәгән бу хәлдән егетләр өере каушап-аптырап калды. Ул арада Алып Бәргән якында торучы егетләрнең муен тамырларына менеп төште. Берничәсен баш аркылы күтәреп, җиргә сылады. Ике егетне тотып, маңгайлары белән бер-берсенә орды. Сугышыр кеше калмагач кына Алып Бәргән туктап калды. Хәер, бер егет аяк өсте басып калган иде. Сугышка катнашмыйча, ул егет бер читтә күзәтеп торды. Егет Алып Бәргәннең оста сугышуына соклана иде бугай. Шуңа күрә, Алып Бәргән аңа кагылмады. Башлык егет ике учы белән чыраен каплаган, аның бармаклары арасыннан кан ага. Тайбыр белән Кораңгыш, без әзер дигәндәй, Алып Бәргән артына килеп басканнар. Кырыклап егет, ух-вах килеп, туфракта ята. Алып Бәргән сөякләре тайганнарның буыннарын утыртып йөрде. Кызларга яралыларның җәрәхәтләрен юып бәйләргә кушты. Бераз хәл алгач, Алып Бәргән сабыр гына болай диде:

— Китерегез Аждаһагызны, җебегәннәр! Үзем сугышам!

Җавап бирүче булмады. Кызлар да эндәшмәде. Алар, сугышка катнашмаган әлеге чибәр егеткә карап, тынып калдылар.

— Китерегез Аждаһагызны! — дип кабатлады Алып Бәргән.— Әйтегез шул бәдбәхеткә, чыксын мәйданга! Алып Бәргәннең куәтен татысын бер!

Шулчак теге чибәр егет әкрен генә Алып Бәргән каршына килеп болай диде:

— Чыннан да, куәтле батыр икәнсең! Син диюләрне күп кыргансың, сүз юк. Син иң куәтле кырык батырны кыйнап ташладың. Тагын кырык булса да, син аларны да җиңәр идең. Ышанам мин моңа! Ләкин Аждаһа белән алышырга сиңа киңәш юк, батыр. Ул көчле. Ул куәтле. Шулар өстенә ул мәкерле, явыз. Аждаһа җиңелә торган зат түгел. Аның белән әшнә булырга гына кирәк. Яки...

— Куркак син, тәтәй егет! — диде Алып Бәргән.— Кит юлымнан, мин үзем барам Аждаһа каласына! Кайда ул Аждаһагыз, күрсәтегез миңа шул хәшәрәтне!

— Мин ул — Аждаһа! — диде әлеге чибәр егет.

Алып Бәргән аптырап калды.

— Син ялгыш ишетмәдең, Алып Бәргән батыр. Аждаһа — мин ул!

— Алайса, чык мәйданга! Алыштанмы, салыштанмы? — дип кычкырды Алып Бәргән.

— Ялгышма, Алып батыр! — диде чибәр егет.— Сүземне тыңлап бак! Көрәшмә син минем белән. Кө-рәш-мә! Миңа кылыч күтәргәнең өчен син соңыннан бик нык үкенерсең, үкереп еларсың. Әгәр дә исән калсаң, халкың сине ачы каргыш белән каргар. Кал син монда. Җаның теләгән

матур кызга өйләнеп җибәрерсең, мин сиңа йорт-җир бирермен! Сайла!

— Син — куркак җан! — диде Алып Бәргән.— Карарым нык! Аны берәү дә какшата алмас! Чык мәйданга, хәшәрәт!

— Алайса,— диде чибәр егет усал итеп.— Әзерләгез мәйдан!

Берничә җайдак Ак калага таба чабып китте. Шәһәрдә чаң кагарга тотындылар. Ак кала капкасыннан бик күп кешеләр бу таба агыла башлады. Тиздән дала халык белән тулды, түгәрәк мәйдан ясалды. Гөж килә халык. Быргылар чакыру уйный башлады. Барабаннар дөмбердәп, көрәш башланганын белгерде.

— Башта коралсыз көрәшәсез! — диде уен башлыгы.

— Бик шәп! — диде Алып Бәргән.

Аты белән этен, коралларын кырда калдырып, Алып Бәргән бил тиңентен чишенеп, мәйданга чыкты. Аның җилкәсен, муен тамырларын, бәдәненең корычтай каты икәнен күреп, мәйдан «аһ» итте.

— Һоп, башлагыз! — диде уен башлыгы.

Алып Бәргән бу чәндер-чибәр егетнең биленнән алып җиргә сылыйм әле дип ыргылган иде, чибәр егет кинәт Аждаһага әйләнде. Алып Бәргән каушап калды. Аның алдында мөгез борынлы, таш калканчык гәүдәле, иләмсез зур авызлы, пычак кебек кисә торган үткер койрыклы бер зат үкереп тора иде. Аждаһаның койрыгы бертуктаусыз сызгырып, Алып Бәргәннең аякларын кисәргә чамалый. Аякларын кистермәс өчен Алып Бәргән сикерә башлады. Шулай сикерә торгач, Алып Бәргән көче кимегәнлеген сизде. Ул инде койрык килгәндә чак-чактан гына сикереп өлгерә. Аждаһаның очлы мөгезе туп-туры Алып Бәргәннең бугазына төбәлгән. Аждаһа арткы аякларына басып, алгылары белән Алып Бәргәнне кочакларга килә. Алып Бәргән чигенә-чигенә барды да кинәт атына сикереп менде, кылычын суырып чыгарды. Ләкин ул атка менү белән Аждаһаның гәүдәсе өч тапкыр зураеп, манара биеклеге булды. Кылыч Аждаһага тия дә очкыннар чыгарып кире бәрелә. Кылыч чак-чак Алып Бәргәннең үзенә тими кала. Никадәр көчле бәрсә, кылыч шулкадәр үк куәт белән кирегә атыла. Болай сугудан мәгънә чыкмаячагын батыр аңлады. Шулчак Тайбыр ат артыннан өрә-өрә чаба башлады:

— Аждаһаның муенында калкансыз йомшак җире бар! — диде эт.

Эт нәрсә өргәнне Алып Бәргәннән башка берәү дә аңламады. Алып Бәргән бераз сулыш алгач, Корангышны бар көченә чаптырып Аждаһага каршы китте. Аждаһа турына җиткәч, Алып Бәргән тезгенне каты итеп үзенә тартты, ат кан баскан күзләрен акайтып бер кешнәде дә, арт аякларына басты. Алып Бәргән өзәңгегә аякларын нык терәп, бар куәте белән кылычны Аждаһаның калкансыз җиренә чапты.

— Кылычым күк керсен, кызыл чыксын! — дип кычкырды батыр.

Аждаһаның башы җиргә тәгәрәде. Башсыз калган ятим гәүдәсе бертуктаусыз кан сиптерә-сиптерә артка чигә башлады. Алып Бәргән, зур җиңүдән канәгать рәвештә, атын уйнаклатып, түгәрәк буйлап китте. Шул чак мәйдан кул чәбәкли башлады. Алып Бәргән бу котлауларны үзенә дип уйлады, ләкин түгәрәк борылгач, иярennән егылып төшә язды. Аның каршысында тегесеннән дә зуррак ике аждаһа үкерә-үкерә тырнаклары белән җир казый иде. Аждаһаның киселгән башына — яңа гәүдә, гәүдәсе ягына яңа баш үсеп чыккан иде. Халык шушы әверелешне хуплап кул чапкан икән. Аны-моны уйлап тормастан, Алып Бәргән аждаһаларның башларын тагын чабып төшерде. Мәйданда дүрт аждаһа пәйда булды. Аждаһалар батырны урап алды.

— Егет! — диде аждаһаларның берсе.— Күрмисеңмени, мин бит синең белән шаярам гына. Син тычкан, мин мәче. Тычканның кайчан мәчедән качып котылганы бар? Күрмисеңмени, син селтәнгән саен без арта гына барабыз. Элек халыкларны бер генә Аждаһа талый иде. Хәзер без дүртәү булдык. Кешеләргә бер Аждаһа туйдырып, ачлы-туклы яшәве әйбәтрәкме, әллә дүрт Аждаһа туйдыру рәхәтрәк булырмы? Дивана булма! Куй бу эшеңне! Халкыңның бәхете өчен тукта сугыштан!

Алып Бәргән, ачуыннан кысып, кылычының сабын сындыра язды. Нишләргә соң? Нишләргә? Шулай җиңелеп китәргәме? Бу сорауга кәпәч тә, көчек тә, Корангыш та җавап бирмәде. Алар да аптырап калганнар иде. Алып Бәргән, шулай аптыраган хәлдә, мәйдан уртасында берүзе тырпаеп калды. Халык таралып бетте. Аждаһалар, егетләргә әверелеп, сәхрәгә күңел ачарга китте. Кич җиткәч, шәфәкъ баткач, һавага дүрт Аждаһа күтәрелеп, дүртесе дүрт якка очып китте. Күп тә үтмәде, алар дөнья кадәр мал күтәреп, берәр кыз урлап Аккалага кайтып төштеләр. Төштеләр дә дүрт чибәр егеткә әвеределәр. Егетләр тагын сәхрәдә кәрт суга башладылар.

— Әле һаман айный алмыйсыңмыни? — диде чибәр егетләрнең берсе.— Каласыңмы, әллә кайтып китәсеңме, батыр?

Шунда гына Алып Бәргән, аяк өсте йокыга китә язгандагыдай, сискәнеп китте. Ул, бер сүз әйтмичә, атын борып кайтып китте. Юлда кайтканда очраган бер сәләмә кеше Алып Бәргәнне каргап, артыннан таш атып кала.

— Син Аждаһага каршы сугышмаган булсаң, без болай ук хәерче булмас идек. Хәзер дүрт яктан кимерә башладылар! — ди, хатын-кызлар өй түбәсеннән Алып Бәргән өстенә юынтык су коя.

Бала-чага пычрак атып кала. Карт-коры ачы сүгенеп төшсез авызлары белән төкереп калалар. Алып Бәргән кеше күрмәстәй аулак җиргә барып, үкереп елый башлады. Бу яшенә җитеп, аның мондый хурлык вә ялгызлыкны кичергәне юк иде. Кәпәче дә, айгыры да, Тайбыры да аның белән сөйләшми. Халык аны дошман күрә. Нишләргә соң? Нишләргә?

Туган авылына кайтасы килми. Аның маҗараларын анда күптән ишеткәннәрдер инде. Ни хурлык, ни оят! Шулай кеше күзенә күренергә куркып, ялгыз качкын булып яши башлады Алып Бәргән батыр.

Һиҗрәттән соң тугыз йөз илле өч ел узгач булды бу хәл.

## Җәбәл Зәррах тавында

Беркемне күрәсе килмичә, Алып Бәргән качкынлыкта байтак яшәде. Иң якын дуслары Корангышка да якты чырай күрсәтми, әте Тайбырның да хуҗасыннан яхшы сүз ишеткәне юк. Кәпәче дә тузанланып, беләүләнеп бетте. Шулай сакал-мыек баскан килеш, ул таулар арасында аю ташлап киткән мәгарәдә яшәде. Беркөнне моның әте Тайбыр юкка чыкты. Шул көнне үк аты Корангыш югалды. Атын да, этен дә эзләп-эзләп, чакырып-чакырып карады, инде таба алмагач, өмете өзелеп, кәләпүшенә дәште.

— Җә, Кәпәчем, ни кылаем соң? Сукам ташка терәлде! — диде.

— Әйтер сүзем бетте! — диде кәпәч.— Мин атаң башында күп йөрдем, бабаң башында илләр гиздем. Аның батырлыкларына шаһит булдым. Җен-пәриләргә каршы көрәштә ата-бабаңа якын-яхшы киңәшләр бирдем. Ләкин бүген мин аптырашта. Бүген аждаһалар да элеккеге аждаһалар кебек түгел. Элек ап-ачык иде. Яман затлар яман төстә, яхшы затлар яхшы адәмнәр сыйфатында иде. Хәзер аңламассың, җен-пәри, албасты-аждаһалар кайда да, чын кешеләр кайсы якта? Аерыр хәл юк. Яхшы кеше дип уйлыйсың, ул — Иблис икән. Шәп хатын дисең — ул Юха елан булып чыга. Чибәр егет алдыңда басып тора — ул мең башлы Аждаһа икән. Юк, хуҗам Алып Бәргән, мин сиңа һични әйтә алмыйм!

Япа-ялгыз шулай тормыш кичерде Алып Бәргән батыр. Туган авылы да, кәләше Нәүмизә дә, хәтта карт анасы да хәтерненң бер читендә генә торып калды. Иң алда, зиһенне бораулап, Аждаһа мәсьәләсе тора иде. Аждаһага каршы сугышмаса, бер зыян. Аждаһага каршы сугышса, мең зыян! Нишләргә соң? Нишләргә? Шул сорауга гына җавап юк. Әллә ничә тапкыр аның баш очыннан аждаһалар ажгырып үтеп китте. Мал таларга баралар, кыз урлаудан кайталар кабәхәтләр. Яшиләр бит, дөньяның артына тибеп яшиләр.

Зиһене киткән карт кешедәй, Алып Бәргән шулай үзалдына сөйләнеп йөргәндә эт өргән, ат пошкырган тавышлар ишетте. Алып Бәргән, сагаеп, кулына корал алды. Берзаманны җан дуслары эте Тайбыр белән аты Коранглыш килеп чыкты аның янына. Аларны күргәч, Алып Бәргәннең күңеле тулды. Ташламаганнар икән, бахырлар. Корангышның иярендә бер токъсай азык-эчемлек иде. Алып Бәргән кабалана-кабалана ашарга тотынды.

— Кайда йөрдегез? — диде Алып Бәргән бераз тамак ялгаганнан соң.

Иң беренче булып, Тайбыр телгә килде, алар Корангыш белән янәдән Аждаһа патшалыгына барганнар икән. Атны чик буенда калдырып, койрыгын бот арасына кыстырып, сукбай эткә охшап, сиздерми генә Аккалага кергән дә, андагы этләр белән ырлашып, талашып, танышып, дуслашып беткән. Бер затлы гына сарай хезмәтчесенең эте аша Тайбыр Аждаһаның серен белгән.

— Имештер, бер сихерләнгән язуда Аждаһаның җаны саклана. Ул язу яшерен китапханәдә икән. Ул китапханәгә Аждаһа үзе һәм аның иң яраткан шул вәзире генә керә ала икән. Әгәр дә кеше шуны укый алса, язылганнарны аңласа, Аждаһаны җиңә ала икән. Ләкин ул язуга кадәр барып җиткән бер генә батыр да аны укый, аңлый алмаган. Бер генә батыр да гарәпчә укый белми икән, нәсых-тәгълик язуын танымыйлар ди. Тайбыр шул язуны әлегә вәзирнең этеннән урлаткан.

Корангыш алгы аякларына тезләнде. Тайбыр җәһәт кенә ияр астыннан каен тузына язылган серле язуны хуҗасына алып килде. Алып Бәргән мондый язуны яхшы таный иде. Ул кычкырып укый башлады:

«Камчыңны ал. Камчыңның сабын аер. Сапның тишекләренә ачуташлар беркет. Төләйманнан чүлмәк алып тор. Чүлмәккә камчы сабын ябыштыр. Чүлмәкне казыкка элеп куй. Соңра көянтә белән чага торган чиләкләреңне алып суга бар. Алайман бабаң очрар. Аңа, чага торган чиләгеңне көянтәдән аерып, су эчер. Ул сиңа тунын салып бирер. Шул тунны киеп, бер күрергә зар-интизар булганың янына кит. Ул сине сыйлар. Син дә аңа бүләкләреңне бир. Синең тамагың туяр».

Ат белән эт ял итәргә ятты. Алып Бәргән язуны кат-кат укып чыкты. Камчысын кисеп ташлады. Чыбыркы сабына ачуташ эзли китте. Өч көн, өч төн баш ватканнан соң, Алып Бәргән язуны туры мәгънәсендә түгел, читләтеп әйтелгән мәгънәдә укырга кирәклегенә төшенде. Ә нәрсә соң ул «камчы?» Ни соң ул «көянтә»? «Төләйманы» кем булыр тагын?

Шулай тау сукмагында уйланып йөргәндә ул бер еланга тап булды. Бәләкәй чактагы кебек, еланга ул «елан» дип дәшмәде. Елан дисәң — чага, камчы дисәң — кача, дип өйрәтә торган иде аны әнкәсе. Димәк, «камчы» — елан дигән сүз. Димәк, еланны үтереп, баш сөяген аерырга кушкан язу.

— Төлке-Төлке Төләнтәй,
Төнлә кая барасың?

— Әбиләргә барамын! — дип такмаклый торган иде бала-чагалар.

Димәк, Төләнтәй ул — Төлке. Көянтә ул — җәя, чагучы чиләкне ук дип аңларга була. Алып Бәргән язуны үзенчә тәрҗемә итеп чыкты. Каен тузына менә нәрсә язылган иде:

«Еланны үтереп, баш сөяген киптер. Ике күзе урынына зөбәрҗәт ташы куй. Төлкене үтереп, бүрек тек. Бүреккә зөбәрҗәт ташы куелган елан башын так. Бүрекне башыңа ки. Аннан соң җәяң белән угыңны алып, ауга бар. Аю атып ал. Тиресен туна. Аю тиресен ябынып, Аждаһа каршысына бар. Ул сине үтерергә теләр. Син дә аңа сугарсың. Син җиңәрсең».

Язуны аңлагач, Алып Бәргән шундук эшкә кереште. Бөтенесен язу кушканча башкарды. Төлке, аю атуы әллә ни мәшәкатьле булмады. Еланның баш сөяген алу да чүп кенә икән. Ләкин зөбәрҗәт ташын каян табарга икәнлеген Алып Бәргән белми иде. Ул асылташны хан кызла-

рында гына күреп була даләр бит. Авылга кайтсаң, анда сиңа кем зөбәрҗәт табып бирсен? Сатып алырга Алып Бәргәннең сукыр бакыры да юк кесәсендә. Шуннан соң ул күрәзәчегә барды. Ике куян, бер бурсык тиресе биргәч, күрәзәче:

— Зөбәрҗәт ташы бары тик Җәбәл Зәррах тавында гына була! — диде.

Ә Җәбәл Зәррах тавы Гарәбстанда икән.

— Нишләмәк кирәк! — диде дә Алып Бәргән ерак Гарәбстанга, Җәбәл Зәррах тавын эзләп китте.

Мәккәгә кадәр ул хаҗга баручылар кәрванына ияреп, тиз һәм ансат барды. Җәбәл Зәррах тавы Мәккәдән дә ары икән. Нишләмәк кирәк, чүлләр аша ул юлга чыкты. Бер ел булды дигәндә Алып Бәргән Җәбәл Зәррах тавына килеп җитте. Шул тауда меңләгән ташчылар, алама-сәләмә киенгән бичара кешеләр тау актарып, асылташ эзлиләр. Алып Бәргән дә аларга килеп кушылды.

Өч ел тулды дигәндә Алып Бәргән борчак хәтле генә зөбәрҗәт табып алды. Эченә кинәт тулган куанычын яшерә алмыйча, ул тауларны шаңгыратып, акылдан ычкынган кешедәй бер кычкырды:

Аһа-һа-һай-иии...

Таулар аңа: «Ай-ии».— дип җавап кайтарды.

Аждаһаны җиңәр өчен күпме оятлар кичереп, күпме баш ватып, күпме юл газаплары күреп, туган илен, газиз анасын, өзелеп сөйгән ярын ташлап, ничә еллар ачлы-туклы таш ватканнан соң, үҗәтләнеп эзләгән асыл таш синең уч төбендә ятсын әле, кычкыру түгел, чыннан да акылдан язарсың, билләһи. Алып Бәргән акылдан язмады язуын, ләкин инде хыялы белән Аждаһа патшалыгына якынлаша иде. Иртән иртүк торып юлга чыгарга дип, бәхетле батыр асылташ эзләүчеләр кереп йоклый торган тау куышына кайтып ятты. Ятканда ул зөбәрҗәтен ияре астына куеп, йокыга китте. Өч ел буе рәтле-башлы йокы күрмәгән Алып, мәрткә киткәндәй, каты йоклаган иде. Уяну белән ул ияр астына кулын тыкты. Зөбәрҗәт таш урынында юк иде. Батырның йөрәге ду купты, миенә кан йөгерде, сулышы кысылды. Бөтен дөньяны актарып чыкса да, асылташ табылмады. Ул өч көн, өч төн йоклаган арада кемдер зөбәрҗәтне чәлдергән булып чыкты.

— Кем булсын! —диде кырык ел шушында асылташ эзләп тә, бәхетен таба алмаган бер бичара карт.— Синең белән өч ел бер табактан ашаган, бергә йоклаган теге йолкыш инде.

Алып Бәргән йокыга китү белән шул йолкыш алама-сәләмәләрен тиз-тиз төйнәп, китеп барган.

— Аны куып җитәлмәссең, балам! — диде әлеге карт.— Өч көн, өч төн эчендә ул җәһәннәм читенә барып җиткәндер инде!

Алып Бәргәннең моңарчы шундый зур кайгы кичергәне юк иде. Әйләнеп-тулганып, авылга кайтып бер оятлы булды. Биштишек авылы хатыннары кыйнап, ике оятлы итте. Ничә тапкыр җиңелде. Боларның барысы да чүп кенә тоелды бу кайгы белән чагыштырганда. Ике учы белән башын тотып, ул хәсрәтеннән айный алмыйча байтак утырды.

— Соң, улым! — диде әлеге карт.— Атың бар, җилкәңдә куәтең бар, нигә соң син авылыңа кайтып җир генә сукаламыйсың? Сиңа да байлык кирәкмени соң?

Алып Бәргән зөбәрҗәтнең ни эшкә кирәклеген картка сөйләп бирде.

— Алайса, синең эшләр хәтәррәк икән, улым! — диде дә теге карт уйга калды.

— Беләсеңме, батыр,— диде ул янә.— Зөбәрҗәт ташының иң затлысы, сиңа кирәклесе Солтан Бабир падишаһның кызы Гөлбәдән-бәгим таҗында булыр. Патшалыкның башкаласы Аһрә каласында бүген Бабирның углы Һәмаюн падишаһ утырыр. Һәмаюн падишаһ үзенең сеңлесе Гөлбәданны өзелеп сөя икән дип сөйлиләр. Ләкин ул илдә кырык аяклы, коточкыч зур су айгыры Кәррух пәйда булып, тирә-якны талап

тормыш көне ди. Шул Кәррух җүнсез Һәмаюн падишаһны гына түгел, әйләнә-тирәдәге бик күп түрәләргә, солтаннарга ясак-салым йөкләп, халыкларны да, патшаларны да бөлдереп тора ди. Аңа каршы ялгыз батырлар гына түгел, батырларның бытыры булган баһадирлардан торган гаскәр яу белән күп мәртәбәләр барган, ләкин кырык аяклы бу Кәррух дигән су айгыры гыйфритләрдән дә куәтле вә житез булып, бөтенесен таптап сыткан, кабып йоткан. Хәзер инде вак патшалар да, хәтта ни куәтле Һәмаюн падишаһ та кара язмышына буйсынып, су айгыры Кәррухка баш органнар. Хәзер инде чират Һәмаюнның яраткан сеңлесе Гөлбәдән-бәгимгә килеп житкән. Су айгыры Кәррух шуны сорый, имеш. Һәмаюн падишаһ Кәррухны җиңү хәйләсен тапкан кешегә хәзинәсендәге ярты байлыгын вәгъдә иткән. Зөбәрҗәт кирәк булса, син, улым, су айгырына каршы бар!

Алып Бәргән уйлап-уйлап торды да, карт сөйләгән су айгыры Кәррухны эзләп китәргә булды.

— Һәмаюн падишаһның башкаласы Аһра шәһәре Җамна дәрьясы буена урынлашкан булыр,— дип Алып Бәргәнгә юл өйрәтеп җибәрде карт.

## Алып бәргән су айгыры кәррух янында

Тау аша таулар үтеп, дәрья аша дәрьялар кичеп, чүл аша чүлләр гизеп, Алып Бәргән Җамна елгасына килеп чыкты. Елга үзәненә салынган Аһра каласын күреп, Алып Бәргән хәйран калды. Андагы сәер манараларны, гөлбакчаларны манзара кылып, Алып Бәргән ник килгәнен дә онытып җибәрә язды. Чит илдә сәйран калырга дип түгел, су айгыры явыз Кәррух белән сугышырга дип килде бит ул. Шушы муллык, матурлык эчендә аңа якты чырайлы бер генә кеше дә очрамады. Бар да кайгыда, бар кеше дә борчулы.

— Һәмаюн падишаһ сине кабул итмәс! — диде капка сакчысы. Илебезнең иң кайгылы көннәре. Өч көннән соң Кәррух атлы су айгыры Җамна дәрьясыннан чыгып, падишаһыбызның сеңлесе Гөлбәдән-бәгимне алып китәчәк...— диде дә капка сакчысы үкереп елап җибәрде.

— Мин су айгыры Кәррух белән сугышырга килдем! — дигәч, Алып Бәргәнне падишаһ янына алып керделәр.

— Үзеңне харап итмә, читтән килгән Батыр! — диде Һәмаюн падишаһ.— Су айгыры белән сугышырга ялгыз батыр түгел, йөзләгән-меңләгән батырлар атка атланып та, сугыш филләренә менеп тә яуга бардылар. Берсе дә исән кайтмады. Су айгыры күп аяклы, ул таптыйсыта. Су айгыры зур авызлы, кабып йота. Су айгыры койрыклы, койрыгы белән кисә-ура гына. Аннан котылыш чарасы һич юктыр!

Шулай диде дә падишаһ үкереп елый башлады. Шул чак падишаһ янына гүзәлләрнең гүзәле бер кызны алып керделәр. Алып Бәргән бу кызның Һәмаюн падишаһның сеңлесе Гөлбәдан-бәгим икәнлеген аңлап алды. Гөлбәдан-бәгимнең таҗындагы искиткеч матур яшел ташның балкышын күреп, Алып Бәргән алга ымсынып куйды. Менә ул зөбәрҗәт ташы!

Падишаһ белән Гөлбәдан-бәгим кочаклашып елаша башладылар.

— И бөек падишаһ Һәмаюн солтан! — диде Алып Бәргән.— Мин үз гомеремдә күп җиңүләргә ирешкән батыр буламын. Иблис, Юха, Ялмавыз, диюләр патшасы Гыйфрит дигән явыз затларны дөмектергән кеше. Әгәр дә ки мин су айгыры Кәррухны да җиңә алсам, патшалыгыңны аннан коткара алсам...

— И батыр йөрәкле адәм! — диде падишаһ кабаланып.— Хәзинәмдә ни бар, шуны алырсың. Ярты патшалык, атың башы чаклы алтын...

— Миңа алтын да, патшалык та кирәк түгел, и бөек падишаһ Һәмаюн солтан! — диде Алып Бәргән.— Миңа ун мыскаллык зөбәрҗәт ташы булса, шул җиткән!

— Әгәр дә син су айгыры Кәррухтан мине коткара алсаң! — диде Гөлбәдан-бәгим.— Мин сиңа үземнең тажымдагы кырык мыскаллы зөбәрҗәтемне кызганмам!

Алып Бәргән шул көнне үк юлга чыкты. Аһра каласыннан Җамна дәрьясына кадәр йөз чакрым ераклыкта, су астында яши икән ул Кәррух дигән хәйвани зат.

— Шул юл белән бара торгач, ян-якларга утыртылган казыкларга барып чыгарсың,— дип өйрәтеләр картлар.— Һәр казык очында берәр баш сөяге эленгән. Сиксән чакрым юл буе ике яклап шундый казыклар торыр. Баш сөякләре һәлак булган батырларның башлары булыр. Шуннан соң гына син Җамнаның иң тирән җиренә барып чыгарсың.

Алып Бәргән өйрәтелгән юлдан китте. Баш сөякләренә килеп җиткәч, ул шикләнеп калды. Сөякләр шулкадәр күп, һәр казык башында берәр баһадирның башы икәнлеген саный китсәң, су айгыры Кәррухны күрмичә дә котың алынып үләргә булыр иде.

— Ах-мак бул-ма-а! — диде казык башындагы баш сөяге телгә килеп.— Су айгырына каршы кылыч күтәрмә син!

Алып Бәргән, ыржык авыз сөяк-башларны тыңлап тормастан, алга китте. Узып киткәндә һәр баш сөяге тешләрен шакылдатып, ыржаеп, шул ук сүзләрне кабатлап кала.

— Ах-мак бул-ма-а! Су айгыры кырык аяклы, таптый-сыта. Ул кочаман зур авызлы, кабып йота. Ул үткен койрыклы, кисеп сала. Ул гәүдәсе белән аунап, йөз меңлек гаскәрне изеп ташлый.

Алып Бәргән дә, Корангыш та, хәтта Тайбыр да шым булды.

— Беткән баш беткән! — диде Алып Бәргән.— Су айгыры мине җиңсә, мин дә казык башына менеп, ыржаеп, кешеләргә акыл сатып торырмын.

Шулай бара торгач, ул чиксез дәрья ярына килеп чыкты. Яр якасына утыртылган баганага язу кадакланган. Язу бик күп телләрдә язылган. Алып Бәргән үзе аңларлык язуны эзләп тапты да, укый башлады:

«Сугышасы килгән батырлар өчен игълан! — диелгән иде язуда.— Су айгыры Кәррух. Аңтага ике тапкыр чыга. Чыгу көннәре: атна башы, төшкә кадәр. Атна азагы, төштән соң».

— Алай икән, — диде Алып Бәргән. — Бүген атна азагы, кояш төшкә авышты, әзерләнергә кирәк!

— Ашы-ыкма-аа! — диде иң кырый казыкка эленгән баш.— Сугышны күчерә кил, батыр. Бер атнага, бер айга, бер елга күчерик диген су айгырына. Шулай итеп, рәхәттә генә яшәрсең. Сугышны күчергәннәргә ачуланмый ул Кәррух...

Шулчак дәрья тик торганда гына дулкынлана, кайный башлады. Тирә-яктагы кош-корт, җәнлек-җанвар качып бетте. Табигать тә, казыктагы башлар да шым булды. Карлыгачка охшаган кошлар, давыл буласын сизенгәндәй, чыелдый-чыелдый астан очалар. Корангыш ал аяклары белән җиргә тибә, бер урында таптана, пошкыра башлады. Тайбыр койрыгын бот арасына кыстырып, гаебе бар эттәй, башын иеп чиный да чиный. Чиксез дәрья уртасында иләмсез бер тау хәтле гәүдә калыкты. Бу — су айгыры Кәррух иде. Шул арада әллә каян гына яр буенда бихисап адәмнәр пәйда булып, араларыннан башлык сыманы Алып Бәргәнгә дәште:

— И олуг баһадир, сине атабыз су айгыры Кәррух Кырылыш Мәйданында зарыгып көтә! — диде.

Кәррух дәрьядан ярга чыкты да, Кырылыш Мәйданы дип аталган такыр басуга таба китте. Кырылыш Мәйданы дигәннәре өч йөз мең елкы көтүе сыярдай иркен иде. Кәррух кырык аягы белән җирне таптап, койрыгы белән имәндәй каты кырык агачны турап, мөгезе белән мәрмәр ташларны ватып, такыр басуда үкерә-үкерә ауный башлады. Кәррух үзенең нинди куәткә ия икәнлеген күрсәтә, янәсе. Чыннан да,

су айгырына каршы торырлык көче юклыгын аңлады Алып Бәргән. Кәррух байтак кына шулай аунаганнан соң сырт йоннарына, койрыгына ябышкан туфрак һәм тузанны калтыранып-дерелдәп койды да, такырның аргы башына барып ятты. Алып Бәргән кыяр-кыймас кына Кырылыш Мәйданы эргәсенә килеп басты. Мәйдандагы халыкның иге-чиге юк иде. Бар да тамаша карарга килгән.

— Мин әзер! — дип кычкырды су айгыры Кәррух.— Уеңнан кире кайтмадыңмы, йолкыш батыр?

— Юк, уемнан кире кайтмадым! — диде Алып Бәргән.— Мин ерак юл узган кеше. Атым да, этем дә бик нык арыды... Сугышны атна башына күчереп булмасмы икән, Кәррух?

— Ярар! — диде су айгыры.— Ял ит! Минем бихисап башорганнарым сине ашатыр, эчертер. Син көч җый. Атна башында Кырылыш Мәйданында бул! — диде дә Кәррух дәрьяга ажгырып кереп китте. Дәрья суы, ярларыннан аркылып, тирә-юньдәге авылларны басып китте.

Башорганнар таралды. Берничә хезмәтче Алып Бәргәнне махсус сарайга алып бармакчы булганнар иде дә, Алып Бәргән баш тартты. Башорганнар, батырны ялгызын гына калдырып, китеп бардылар.

— Йә, нишлибез? — диде Алып Бәргән.— Өч көнгә мин гомерегезне озайттым, дуслар. Өч көннән соң Корангышны су айгыры кабып йотар, Тайбырны таптап сытар, ә минем баш кәләпүше белән казык башында ыржаеп торырмы?

Корангыш та, Кәпәч тә, Тайбыр да дәшмәде. Сугыш буласы көнгә каршы төнне таң алдыннан Алып Бәргәнне чабуыннан тартып Тайбыр уятты.

— Таптым, хуҗам! — диде Тайбыр, дошманнар ишетмәсен дигәндәй, Алып Бәргәннең колагына нидер пышылдады.

Алып Бәргән сикереп торды, Кырылыш Мәйданы буйлап йөгереп килде. Салкын чишмә суы белән бил тиңентен юынды. Башорганнар аны иртәнге ашка чакырганнар иде дә, Алып Бәргән бу юлы да алар азыгын ашарга бармады. Үзенең катып беткән ләвәшен чишмә суына манчып, тамак ялгады да, атына атланып, бөтен сугыш коралларын тагып, такыр мәйданга чыкты. Бүген халык тагын да күбрәк җыелган иде. Бары да хәтәр сугыш булуын түземсезлек белән көтә. Кәррух бүген ни өчендер ялындырып, көттереп кенә чыкты. Ул тагын сулар кайнатып дәрьядан калыкты, тагын ятып үкерә-үкерә аунады, тагын җитез аяклары белән Кырылыш Мәйданын таптады. Аннары Алып Бәргәнне сугыштан баш тартырга кыстай башлады. Ләкин Алып Бәргән карарында нык торды.

— Ярар! — диде су айгыры Кәррух.— Синеңчә булсын! Үлемең алдыннан исемеңне әйт! Минем башорганнарым язып куйсын! Син меңенче ахмакның башы казык башында булыр!

— Һәй, су айгыры Кәррух! — дип кычкырды батыр.— Мин — Болгар иленең Утыз Иманле баһадиры Алып Бәргән булам. Сиңа сөалем бар: син аттан да, коштан да, уктан да җитез йөгерәсең, дөрес! Әмма син йөгергәндә кырык аягыңның кайсын башта атлыйсың? Ничек алар буталышып бетмиләр?

Бу сүзләрне ишеткәч, Кәррух кыты-кыты көлә башлады.

— Ах-мак! — диде ул көлеп туйгач.— Кем инде уйлап атлый. Үзеннән-үзе атлана инде ул. Уйлап торганым юк, чабам да китәм...

— Ә син уйлап кара әле, Кәррух! — диде Алып Бәргән.— Уйлап кара да, минем янга чабып кил. Шул чагында без сугыша башларбыз!

Кәррухка бу уен кызык тоелды, ахрысы, ул көлә-көлә аягүрә басты.

— Хәзер чабып барам да, башта атың белән этеңне, аннан үзеңне кабып йотам! — дип иләмсез акырып, су айгыры алга ыргылды.

Ике дә атлый алмады, гөрселдәп җиргә ауды ул. Аның гәүдәсе ауганнан тирә-яктагы шәһәрләрдә җир тетрәде. Кәррухның аяклары буталып беткән иде.

— А-а, аякларым тыңламый! Ярдәм итегез, башорганнар! — дип кычкыра үзе.

Кәррух тагын торып басты, тагын ыргылды, ләкин һаман шулай баскан саен гөрселдәп егыла. Аның ауганыннан бөтен шәһәрләр тетрәп торды. Башорганнар аңа ярдәм итеп карадылар, кая ул? Су айгыры Кәррухны күтәрер өчен бөтен дөньядагы батырларны җыйсаң да торгыза алмассың.

— Һәй, Кәррух, су айгыры! — диде Алып Бәргән.— Хәзер мин синең бөтен әгъзаларыңны берәм-берәм турап чыгам. Аннан соң үзеңнең башыңны казыкка утыртып куям!

— Зинһар, алай итмә, батыр! — диде Кәррух.— Җанымны калдыр!

— Хуш! — диде Алып Бәргән.— Мин кылычымны синең пычрак каныңа буямыйм. Син судан башка озак тора алмыйсың. Үзең генә син дәрьяга чаклы барып житә алмыйсың. Син шушында, Кырылыш Мәйданында, кояш астында кибеп үләргә мәхкүм!

Башорганнар инде күптән Алып Бәргәнгә йөз борганнар иде.

— Барыгыз, өйләрегезгә кайтыгыз! — диде Алып Бәргән башорганнарга.

Башорганнар Алып Бәргәнне Аһра каласына кадәр җырлый-җырлый, бии-бии озата кайттылар. Алдан киткән чапкыннар Һәмәюн падишаһка Алып Бәргәннең бөек җиңүе турындагы хәбәрне вакытында җиткергән булып, батырны каршыларга бөтен ил халкы, Һәмәюн падишаһ үзе, аның сөєлесе Гөлбәдан-бәгим чыкканнар иде. Батыр хөрмәтенә падишаһ моңарчы күрелмәгән, моңарчы ишетелмәгән сый мәҗлесе уздырды. Ул мәҗлестәниләр генә юк иде. Алма, хөрмә, әфлисун, лимон дисеңме, Алып Бәргәнгә таныш булмаган ят җимешләр: панияла, бадхал, чирунчы, сантара, садафал, дисеңме, Кәркадан ите, нилагу шулпасы, чыбыкка тезелгән тәвә торнасы, бүздәк кошлары китерделәр. Ул мәҗлес гаҗәп матур гөлбакчага корылган иде. Анда тутыйлар, шәрәк, куил кебек сайрар кошлар тавышын тыңлап, Алып Бәргән истирәхәт алды. Гөлбәдан-бәгим Алып Бәргән батырга иң кадерле, иң матур зөбәрҗәтен шул бакча уртасында бүләк итте. Ул рәкысчы матур хатын-кызлар искиткеч биюләр күрсәтте.

Һәмаюн падишаһ Алып Бәргәнне:

— Кырык көн кунак булып китәрсең! — дип кыстаса да батыр өч көннән артык тора алмады. Ул, җанынннан да кадерле зөбәрҗәтен учына кысып, кайтыр юлга чыкты.

Тугыз йөз илле сигезенче елның Рәҗаб аенда булды бу хәл.

## Алып Бәргән Аждаһаны җиңә

Корангыш төзек юлдан салмак кына атлый. Юл өстендәге Әҗәрай шәһәрендә җәүһәрче остага асылташны урталай бүлдереп, еланның баш сөягенә урнаштырырга кушты Алып Бәргән. Ап-ак елан баш сөягеннән ямь-яшел ике күз янып-карап тора. Искиткеч матур да, куркыныч та иде бу караш.

Шуннан соң ул, атын бар көченә куалап, Аждаһа патшалыгына китте. Ул Аккалага килеп җиткәндә әхтәри уйнаучылар тарала башлаган иде инде.

— Кузгалмагыз! — дип кычкырды Алып Бәргән ерактан ук.

Аждаһа да, аның куштаннары да Алып Бәргәнне чак-чак кына таный алдылар.

— Картайгансың син, Алып Бәргән батыр! — диде тәти егет кыяфәтендәге Аждаһа.— Ниһаять, син мине аңладың, миңа хезмәткә килдең?

— Юк! — диде Алып Бәргән.— Исәп-хисапны өзәргә дип килдем мин!

Аждаһа әйтте:
— Ял ит, юл тузаннарыңны как, мунча кер, аша, эч. Аннан соң сөйләшербез!
Батыр әйтте:
— Хәзер үк мәйдан җый!
— Мәйлең! — диде Аждаһа.— Ихтыярың — куш кыярың!
Аннан соң зәһәрле тавыш белән:
— Мәйданга-а! — дип кычкырды.
Тагын халык түгәрәкләнеп мәйдан ясады, тагын быргы уйнадылар, тагын барабаннар кактылар.
— Бу юлы мин сине исән килеш җибәрмәячәкмен, Алып Бәргән батыр! — диде Аждаһа.— Васыятеңне әйтеп кал!
— Васыятем шул! — диде Алып Бәргән.— Әгәр дә мин җиңелсәм, гәүдәмне тураклап, сөякләремне киптереп, төеп җилгә очырырсыз. Каберем дә калмасын! Аждаһаны җиңә алмаган кешегә, халкын коллыктан коткара алмаган батырга шул кирәк!
— Һо-оп, башлагыз! — дип кычкырды баш уенчы.
Алып Бәргән кылычы белән кизәнгән иде, мәйданда дүрт аждаһа пәйда булды. Аждаһалар бу юлы эшне тиз тотарга исәплиләр, ахрысы, дүртесе берьюлы якынаялар. Алып Бәргән тиз генә аю тиресен иңнәренә салды, төлке бүреген башына киде. Шулчак төлке бүрекка тагылган, ап-ак елан сөягенә уелган зөбәрҗәт ташы күз камаштырырлык итеп балкый башлады. Алып Бәргән кайсы аждаһага караса, шунысы чыдый алмыйча, җиргә шартлап ава. Дүрт аждаһа дүртесе тиң берьюлы сукыраеп, җиргә ятып ауный-үкерә башладылар. Бу үкерештән бөтен дөнья калтырый иде.
Шуннан Аждаһа болай диде:
— Ул еланны үтергән — анда минем чирек җаным иде. Ул төлкене тунаган, анда минем чирек җаным иде. Ул аюны аткан, анда минем чирек җаным иде. Ул зөбәрҗәт ташын таккан, анда минем соңгы җаным!
Аждаһалар барысы да Алып Бәргән каршысына килеп башларын иделәр. Батыр аларны вак кисәкләргә турап ташлады. Егетләр дә, мәйданга җыелган халык та нишләргә белми аптырап утыра калды.
— Сезне нишләтим соң? — дип сорады ул егетләрдән.
— Үтерсәң, үтер! — диделәр егетләр баш орып.
— Юк, мин сугышып туйдым инде! — диде Алып Бәргән.— Сезне мин исән калдырам. Сез бар таланган байлыкны, урланган кызларны илләренә кайтарасыз! Аккаланың уртасына мәрмәр ташлардан Аждаһага каршы көрәштә вафат булган батырлар ядкаре итеп, матур һәйкәл салдырасыз! — диде дә Алып Бәргән туган ягы Утыз Имәнлегә кайтып китте.
Бу — һиҗрәттән соң тугыз йөз алтмышынчы ел иде.

## Күктә аҗаган уйныймы?

Юлда кайтканда Алып Бәргән гаять арыганлыгын, картаеп та киткәнлеген сизде. Менә ул бая гына коточкыч дошманын — Аждаһаны җиңде. Дөнья чистарып калды. Бар да рәхмәт әйтә, балалар батырга сокланып карый. Бар кеше дә батырны өенә кунакка чакыра. Кирәк икән аңа кызын бирергә әзер торучылар да байтак. Юк, Алып Бәргән шат күңелле бу кешеләр белән бәйрәм табынына утыра алмый. Юк, алар димләгән кызларны ул хатынлыкка алып кайта алмый. Ул туган ягына, Утыз Имәнлегә ашкына. Үзе белән бер көнне туган, үзе белән бөтен авырлыкларны күргән, үзе белән картая барган аты Корангыш та ара-тирә пошкыргалап куя. Эте Тайбыр да сикерә-сикерә чапмый. Әллә нигә ямансу боларга. Алып Бәргән гомере буе Аждаһаны җиңәргә хыяллanып йөрде. Хыялына ул зур кыенлыклар аша иреште. Ни өчен пошаманда

соң бөек батыр? Җәбәл Зәррах тавында асыл таш эзләгәндә үк Нәүмизә бүләк иткән яулыкның чигешләре уңа башлаган иде.

— Нинди бәла килде икән илгә? Нәрсә булды икән Нәүмизәгә? Әнкәй карчык ни хәлдә икән? — дип кайгыра батыр.

Шуңа күрә ул һичбер алга-ялга туктамыйча атын куалады. Аты да, эт тә әлсерәп беттеләр. Ниһаять, алар Утыз Имәнлегә кайтып керделәр. Алып Бәргән туп-туры үз өйләренә таба юыртты. Үз турларына җитәрәк батырның йөрәге «жу» итеп куйды. Ул туып-үскән өйнең тәрәзәләре кадакланган, өй җиргә сеңгән, ишегалдында бер җан иясе юк. Бакчаларны, мунча алларын күе алабута, тигәнәк баскан. Алып Бәргән капканы ачып, ишегалдына узды. Өйнең җаны юк, коты качкан. Корангыш болдырга килеп, башын бәләкәй улакка төртте. Улак шакыраеп кипкән иде. Батыр өйгә керде. Пәрәвезгә уралып беткән мендәрләрдән башка һични юк иде, бер-ике кашык, ярык агач савыт сәкедә-идәндә ауный. Казан урыныннан куптарып алынган. Караңгы, сагышлы өйдән тизрәк ишегалдына чыкты Алып Бәргән батыр. Эте Тайбыр да аптыраган, менә-менә улап җибәрердәй булып утыра. Ә Корангыш елый иде. Атның яшьләре мөлдерәмә булып керфекләренә тула, яңаклары буйлый тәгәрәп төшәләр дә, коры улакка тамалар. Кешеләр авылга кергән җайдакның Алып Бәргән икәнлеген ишетеп өлгергән иде инде: ишегалдында берән-сәрән карт-коры, карчык-корчыклар, күршеләр күренә башлады.

— Ике ел инде мәрхүмәне җирләгәнгә! — диделәр агайлар.— Каерылды да сине көтте, каерылды да сине көтте, бахыр.

— Үлгән хәбәрең авылга моннан өч ел элек килсә дә ышанмады, мәрхүмә анаң. Улым исән дип чат торды. Күңеле сизгән икән...

— Нәүмизә бичара көтте-көтте сине... Атасы кыйнап та карады. Юк! Барыбер Алып Бәргәнемне көтәм, диде. Башкага чыкмады — биш ел көтте. Аннан соң син калдырган хәнҗәрнең ике ягы да күгәргәч кенә разый булды... Аргы Як Мөхти баласы Чаргыйга китте. Нәүмизә белән никахлашкач, Чаргый болай дип әйткән имеш: «Алып Бәргәннең хәнҗәрен мин алмаштырдым. Шундый ук башка бер хәнҗәр ясадым да, тозлы суга салып күгәрттем, атасына биреп алмаштырттырдым,— дип әйткән икән.

— Аннары син китеп озак та тормадың, менә инде биш еллап була, Ачәрвах атлы күбәшәр бирәни зат арыш өлгерер алдыннан килә дә һавадан төшеп бөтен арыш басуларын ашап бетереп китә. Арышның иң сөтле чагында гына ашый икән ул Ачәрвах. Менә, олан, иртәгә арыш серкә очыра башлый инде. Ачәрвах быел тагын килер дип котларыбыз чыгып тора инде...— дип кич буе карт-корылар Алып Бәргәнгә авыл хәлләрен сөйләп утырдылар.

Картлар таралды. Авылга төн төште. Корангыш та ат көтүе ягыннан ямансу гына әйләнеп кайтты. Эте Тайбыр ара-тирә улагандай чинап куя. Алып Бәргән дә җанына урын табалмыйча, бер өйгә керде, бер ишегалдына чыкты, бер урамнарны әйләнде. Аннары болдырга ятып, ирләрчә, саран күз яшьләре белән сыгылып-сыгылып елады. Ямансулык, сагыш, үткән яшьлек — барысы да аның болай да ялгыз, китек бәгырен үтереп талый иде. Авыл йокыга талгач, Алып Бәргән атын иярләде, этен чакырып алды да, Ачәрвах дигән бирәни затны эзли чыгып китте.

Һиҗраттән соң тугыз йөз илле тугыз ел узгач, Күсе Елында булды бу хәл.

Тегермән артына җиткәч, йокылы өйләр бераз артта калгач, Алып Бәргән үзе дә сизмәстән җыр башлады:

Карурманда карак бар,
Атларыңны карап бар.
Без китәрбез таң алдыннан,
Тәрәз ачып карап кал...

Ләкин бер генә тәрәзә дә ачылмады.

Утыз Имәнле халкы олуг батыры Алып Бәргән авызыннан бу җырны йокы аралаш соңгы тапкыр ишетә иде.

Олы юлга чыккач, Алып Бәргән керфекләрендә төшәр-төшмәс эленеп торган ике яшь бөртеген кул сырты белән җилпеп төшерде дә эче итеп бер сызгырды:

— Һәй, Корангыш, борыннарны салындырмыйк әле! Тизрәк атла! — дип кычкырды ул шат тавыш белән, сагышын басарга тырышып.

Хуҗасының көр тавышын ишеткәч, Корангыш дәртле итеп бер кешнәп җибәрде.

Олы юлның тузанын куптарып, алар офыкка таба чаптылар.

Утыз Имәнле авылы мәңгегә артта калды. Шул китүдән Алып Бәргән әйләнеп кайтмады. Төрле хәбәрләр йөрде аның турында. Имеш, аны үтергәннәр икән диделәр кайберәүләр. Икенчеләре Алып Бәргән Ачәрвах белән сугышта һәлак булган икән диде.

Халык арасында шундый риваять тә таралды. Арыш чыбыркылаганда, серкә очырганда күктә Аҗаган уйный.

— Нәрсә ул? — дип сорый балалар.— Яшенме шулай күктә балкый?

Яшен түгел ул, оланнар. Күк чалт аязда нинди яшен булсын? Ачәрвах белән Алып Бәргән шулай сугыша. Алып Бәргән Ачәрвахны арыш өлгергәнче тотып тора. Ачәрвах сөтле арыш башагы ашамаса, көчсезләнә. Ел саен Алып Бәргән шуны сагалап ята. Шулар сугышканның ялкыны күккә төшә.

Менә тагы арыш өлгереп килә. Офыкта Аҗаган уйный...

— Аҗаган түгел ул, сугыш шәүләсе шулай балкый, балалар... Ачәрвах белән Алып Бәргән сугыша...

# Флера Гыйззәтуллина

## Киңәшүләр кирәк

Сөйләш әле, әткәй,
Минем белән сөйләш! —
Кискенләште җирдә
Яшәү,
Сөю,
Көрәш...

Элек сез күзгә-күз
Килгән вәхши бүген
Синең онықларга
Яный төрле яктан.

...Сыны таштан — әмма
Һәйкәлләргә хәтта
Көрәш гаме капкан! —
Һәйкәлләр дә, әткәй,

Хәрәкәткә килә,
Булып безнең аңга,
Намусларга терәк!
...Сөйләш әле, әткәй,
Киңәш әле, әткәй! —
Аяк өсте торып
Киңәшүләр кирәк.

Минем онык белән,
Үз оныгың белән
Әткәй, сөйләш әле!..

...Әткәй — аяк өсте!
Мин дә — аяк өсте!..
Аяк өсте — Җирнең
Бездә киләчәге!

## Авыллар... Юллар... Юлдашлар...

Никтер ямансулыйм әле...
Табылса берәр юлдаш,
Туган-үскән авылыма
Бер кайтып килми булмас.

Елгалар кичмичә булмас,
Яфрактан басма төшәп.
Яфрактай сарыла җанга
Башлардан ашкан исәп...

Исәйдем исәпләремдә,
Нечкәрдем хисләремдә:
Үрелә иркә тирәкләр
Олы юл өсләренә.

●

Авылда бәйрәмчә табын,
Каршылап алалар да...
...Шауласа, авыл — урман иң!
Һәм терәк калаларга!

Тамырларыбыз исәнме?! —
Бик сирәк кайтып күреп,
— Авылда үстек без,— дибез,—
Калада кала биреп.—

Яшәтер туган як дибез,—
Бүлеп һәр кабымлыгын...
Тотармы мәңге тамырлар
Кәүсәләр калынлыгын?

---

ФЛЕРА ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА — шагыйрә, «Чишмә юлы», «Сәлам хаты», «Акчарлагым — асыл кошым» һ. б. шигырь китаплары авторы. Казанда яши.

●

...Исәйдем исәпләремдә
Уелдым уйларымда:
Чайкала куе урманнар
Олы юл буйларында.
Ял ала сыман олы юл
Авылга кергәч кенә!..
Авыллар,
юллар,
юлдашлар
Чорларны берләштерә.

## Көзге кайтаваз

Кояш төшә баю уңаена...
Түбән инде Кояш, бик түбән.
Баешлардан — уңыш,
Таңнан — тумыш,
Көннән хәерле кич үтенәм...

Мин сорыймын сездән, көз кошлары,
Сайрауларның язгы аһәңен...
Ничә еллар буе бу урманга
Килә алмый ничек яшәдем?..
Үз моңымны мин бит шәһәрләрдә
Көзге кайтаваздан аулadым.

...Кояш төшә баю уңаена,
Җилфердәтеп алсу байрагын.
Кояш төшә...
Әмма, алтын нуры
Наратларда чал төс яңарта.
Яшьлегемнең сайрар пар былбылы
Килеп кунды иң чал наратка.

Кош сайратыр өчен сайладым мин
Көзге моңсу кояш баешын.
Үзе дә бит кояш бу мәлендә
Тансыклаган былбыл тавышын.
Шушы мәлдән — наратларга чал төс,
Ә йөзләргә кунган алсулык...
Йөзә урман — минем шигъри урман,—
Шәфәкъ алсуына манчылып.

●

...Тибрәлсәк — без дә тирәк ич!
Яктырсак — юлга маяк!
Бер кәүсә бер үк тамырда —
Сабыр җан, йөгерек аяк!..

Таныйлар безне якташлар
Авылча йөрешләрдән...
Без олыгайсак, авыл яшь —
Елларга бирешмәгән.

...Сагыну-сагышлар ташканда
Йөрәктән тулып-тулып,
Авылга кайтып төшәбез,
Бер бушанмакчы булып.

Кайтабыз күпләп, күмәкләп,
Сый-хөрмәт, бәрәкәткә...
Күрәбез:
Авыл кешесе
Һәрвакыт хәрәкәттә!

●

...Дөрес юл ярып
Алдан барганда,
Юл күрсәткәндә
Яхшы-яманга:
Оялмыйк әле
Күз яшебездән,
Кулларыбыздан
Һәм эшебездән!

Эш-мәшәкатьсез,
Тумый көн яме!..
Җанда — күкрәүле
Яңгыр бит әле!..
...Безнең бу кулны,
Сөялле кулны
Үбәрдәй ирләр
Бардыр бит әле!?

## И, киләчәк!

Көн нурыннан эчә гөлләр
Киләчәкнең тыныч моңын.
Гөлбакчамнан табып алдым
Бушап калган кылыч кынын.

Бушап калган кылыч кыны —
Коралсызлык билгеседер...
Бер ярасыз кулларымда
Гөл иседер... Гөл иседер...

Бу табылдык кынның урыны
Музейдадыр... Музейдадыр:
Шушы якты юравыма
И, киләчәк!
Кул изә бер?!
И, киләчәк! И, күрәчәк! —
Мең бәхил! дип, бәхилләә бер?!
Чорга чиксез тугрылыкны
Чит итмәде безнең бәгырь!

## Вакыт тыңлый

Телевизор карыйм:
Яп-якында
Туп ярыла,
Ярыла миллион йөрәк...

Һәм якыннан гына диктор сөйли:
— Сугышларны туктатырга кирәк!

...Вакыт тыңлый төрле ераклыктан
Исән йөрәкләрнең тибешләрен,
Төн дикторы телеэкранга
Калдырса да ябып көмеш шәлен.

## Утлы минутлар

Узган сугышларның авырлыгын
Тарта бит ул шушы көнгәчә! —
Улы гына түгел, оныгы да
Аңа:
— Әткәй! — диеп эндәшә.

Анасыннан яшьли аерылганга,
Канатлары җилдә каерылганга
Үксеп елый бала акчарлак...
Бала көйләү, дөнья көйләү өчен
Бишек ясый һаман карт солдат.

...Ата бала хакын хаклаганда,
Бишекләрдән төшеп, тездән төшеп,
Тәпи атлаганда оныклар,
Канатлана давыл акчарлагы...
Кабатлана утлы минутлар.

## «Шахта көе»н җырлап

Көн тууга, келтер-келтер кителә гомер:
Бу газиз баш нишләп йөрер? Ниләр күрер?..
Эшләр эшем, йөрер юлым, уйлар уем
Бүгенемә, иртәгәмә ниләр бирер?

Уйларым да, юлларым да, эшләрем дә
Күмер ятмалары сыман, катлам-катлам.
...Җәйнең җылы яңгырлары битне юса,
Кышкы буран карын сибә төрле яктан.

...Шахталарда — калган эшкә карлар яумый;
Эш бетмичә әмма күңел тынмый иде! —
Без сулаган дымлы шул катламнар тыны
«Шахта көе» төсле тирән, моңлы иде.

Катламнарын чабып алгач, буш лавалар
Басылалар, калып тынлык куенында! —
Күкрәк көче, кул көчләре белән бергә
Күмелмидер кемнең нинди уе монда!?

...Үткән гомер... Уйланган уй, куйган хезмәт
Бездән китеп югалмый ул ансат кына;
Яңа ятма, яңа лава өеп китә
Иртәгәсен — ирешәсе максатыңа.

Хезмәт өчен егәр туплар йөрәк сыман,
Тыгызланып, җир ул һәрчак кызып тора...
...«Шахта көе»н җырлап урам урыйк әле,
Яшьтәшләрне кызыктыра-кызыктыра.

## Илдар Юзеев

# СӨЙГӘНЕМНЕҢ ТУГАН КӨНЕ

ИКЕ АКТЛЫ ТРАГИКОМЕДИЯ

**КАТНАШАЛАР:**

Бану апа — 70 яшьтә.
Шәфикә — 38 яшьтә.
Тәнзилә — аның кызы, 19 яшьтә.
Самат — 34 яшьтә.
Мәдәния — 34 яшьтә.
Зөлфәт — уллары, 12 яшьтә.
Сандугач — 33 яшьтә.
Вәлит — 32 яшьтә.
Ак халатлы кеше.

Вакыйга бүгенге көндә шәһәрдә бара.

## БЕРЕНЧЕ АКТ

**Арткы планда — зур фоторәсем проекциясе күренеп китә: Бану апа кечкенә балалар арасында. Ерактан скрипкада уйнаган көй ишетелә. Вәлит өстәл артында клиентлар кабул итә.**

1

Вәлит. Керегез!

Бану (*керә*). Исәнме, балам?

Вәлит (*башын күтәрми генә*). Утырыгыз.

Бану (*утыра*). Балам, хәлләрең ничек? Сәламәтме үзең?

Вәлит (*көтелмәгән сораудан гаҗәпләнеп*). Рәхмәт, әби, зарланмыйм.

Бану. Итекченең итеге юк дигәндәй, кайчак врачлар үзләре дә авырып китәләр.

Вәлит. Булгалый.

Бану. Гаиләдә татулыкмы? Хатының, балаларың исән-саулармы?

Вәлит. Аллага шөкер... дисезме әле? Әйдәгез, болай итик. Доктор буларак, Сез түгел, мин Сезгә сораулар бирәм. Нидән зарланасыз?

Бану. Син әйтмешли, аллага шөкер, тамак тук, өс бөтен. Бүгенге көндә зарланып утырсаң, замана үпкәләр. Тормыш бик бөтен, балам, бик тә килгән, тәнеңәгъзаларың гына сау булсын.

Вәлит. Йокыгыз нормальме?

Бану. Безнең яшьтә йокы кая инде ул... (*Төп уена күчеп.*) Калды... ерак...

Вәлит. Ә?.. Нәрсә калды?

Бану. Юк, бернәрсә дә калмады.

Вәлит. Сәер... Нишә сәгать йоклыйсыз?

Бану. Кем санап торган инде аны.

Вәлит. Нигә йокламыйсыз?

Бану. Әллә нәрсәне югалтканмын кебек...

Вәлит. Нәрсәне?

Бану. Бик кирәк нәрсәне.

---

ИЛДАР ЮЗЕЕВ (1933) — шагыйрь һәм драматург. РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт һәм Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премияләре лауреаты. «Мәхәббәт китабы», «Мәңгелек белән очрашу», «Кыр казлары артыннан», «Бөркетләр кыяга оялый» һ. б. поэзия һәм драматургия китаплары авторы. Казанда яши.

Вәлит. Шулай да?

Бану. Үзем дә белмим... Белсәм, табар да идем.

Вәлит. Ниләр уйлыйсыз?

Бану. Хәзерме?

Вәлит. Төнлә... йокламыйча?

Бану. Чумам төрле уйларга...

Вәлит. Мәсәлән?

Бану. Мәсәләнме? Әйтик, күршем Зәйнулланы алыйк. Эчми, тартмый, гакыллы гына совхозда эшләп йөрде. Менә дигән йорт, сарай, гараж салды. Машинасы ялт итеп тора, күз явын алырлык! Инде кеше булдым дигәндә, Зәйнуллабыз, мин сиңа әйтим, дуңгызга әйләнде! Эчә башлады каһәрең! Сүгеп тә карадым, әйбәтләп әйтеп тә... Юк, аякка басалмый. «Нигә эчәсең? — мәйтәм,— элек эчми идең бит?» «Минем элек максат бар иде,— ди,— хәзер барысына ирештем,— ди,— хәзер миңа берни дә кирәкми»,— ди мәлгунь. Төне буе шул Зәйнулла өчен борчылып ятам. Өй тулы балалары бигрәк жәл!

Вәлит. Тагын ниләр уйлыйсыз?

Бану *(төп уена күчеп, көйләп)*. Җырлата да, елата да...

Вәлит. Ни дидегез?

Бану. Берни дә әйтмәдем.

Вәлит. Тагын ниләр уйлыйсыз дим?..

Бану. Әйтик, мәсәлән, газетада укыдым: Африкада бер хатын алты бала тапкан ди, бахырым. Ушларың китәр. Нишләр инде ул мескенем? Үзе бер балалар бакчасы! Кемнәрдән ярдәм сорар? Сабыйлар жәл! Безнең илдә булса әле бер хәл. Төннәр буе шул балаларны күз алдына китереп ятам. Әллә үзем китим микән, балам, шунда, җибәрмәсләрме?

Вәлит. Дару эчеп карадыгызмы?

Бану *(төп уена күчеп, көйләп)*. Зинһар авыр кагылмагыз...

Вәлит. Ни дидегез?

Бану. Берни дә әйтмәдем.

Вәлит. Дару эчмисезме дим.

Бану. Эчмәгән үлән калмады, хәзер — тәэсир итмиләр шул... Тагын газетада укыдым. Югославия дигән илдә армиядә бер солдат бар икән. Мәхлүгемнең бер төн дә йокы күргәне юк ди. Төнге каравылга куйсалар,— сөенә ди. Әй, бала, бала, өйләнсә, хатынына төне буе йокы бирмәс инде, ничек кенә яшәрләр... Шул солдат бичараны кызганып ятам-ятам да... йокы мичкәсенә чумганымны сизми дә калам... *(Көлә-ләр.)* Синең йокың ничек соң, балам?

Вәлит. Әз-мәз.

Бану. Син дә йоклый алмыйсыңмы? Син, балам, төнлә уйланма, көндез генә башыңны ват. Безнең кебек башсызларга синең кебек башлы адәмнәр бик кирәк. Уйланма... *(Төп уена күчә, көйләп.)* Мәхәббәтнең сулган көне...

Вәлит. Ни дидегез?

Бану. Юк, әйтмәдем. Мин инде шулай үз-үзем белән сөйләшәм кайчак. Үзем белән генә түгел, бөтен дөнья белән. Дөньяны аңлыйм да кебек, дөнья мине аңламый. Бер хыялым бар әле, балам, әллә бөтен илләр җыелган оешмага барып әйтим микән?

Вәлит. Нинди хыял?

Бану. Дөньяны һәлакәттән коткару өчен бер генә юл бар дип...

Вәлит. Кызык. Нинди юл?

Бану. Кешеләр, хыяллары белән булса да, бала чакларына кайтсыннар, үзләренең хәзерге тормышларын балачактагы уйлары белән чагыштырып карасыннар. Акыллары белән олы кеше, күңелләре белән бала булсыннар. Шул чакта адәм балалары бер-берсен куралмаудан, дошман күрүдән баш тартырлар.

Вәлит. Әмма бу юл белән генә...

Бану. Димәк, син үзең дә моңа ышанмыйсың. Без, адәм балалары, шулай шул: ышанмыйбыз, үзебездәге яшеренеп яткан күңел җәүһәрләрен тагын да тирәнгәрәк күмәбез, үзебез белән теге дөньяга алып китәбез. Әллә синең балачагың юк идеме, бала? Әнкәң тудыргач, син дә якты хыяллар белән генә җирдән атлап киткәнсеңдер...

*(Тагын үзенең төп уена кайта, көйләп.)* Юк һәм булмас минем өчен... *(Берничә тапкыр кабатлый.)*

Вәлит. Карап-карап торам да, кем апа, Сез миңа дөрес килгәнсез кебек. Миңа атап килдегезме?

Бану. Килгәч-килгәч, сиңа да күренергә ниятләдем. Агыйделдә әйттеләр: «Анда баргач-баргач, нервлар докторы Газизовка күрен!» — диделәр.

Вәлит. Килүегезнең төп максаты?

Бану *(көйләп)*. «Сөйгәнемнең туган көне».

Вәлит. Ә?

Бану *(көйләмичә)*. Сөйгәнемнең туган көне.

Вәлит. Ә, шулаймыни?.. Апа, сезгә дәваланырга кирәк дип табам. Әмма бер шартым бар.

Бану. Әйт.

Вәлит. Сез миңа тулысынча ышанырга тиешсез. Ни әйтсәм, шуңа...

Бану. Әгәр дә мәгәр минем авыру икәнемне исбат итә алсаң, шартыңа күнәм. Мин чыннан белергә тиеш: авырумы мин, сәламәтме? Анда мине печать сугылган справка белән көтәләр кайбер адәмнәр.

Вәлит. Кечкенә формальность. Сезгә — карточка ачабыз. Авыруыгызның тарихы...

Бану. Авыру булсам...

Вәлит. Тикшерербез. Исем-фамилиягез?

Бану. Бану апа.

Вәлит. Бану апа? *(Текәлебрәк карап.)* Фамилиягез?

Бану. Миңа фамилия белән дәшүче юк. Олысы-кечесе: Бану апа!

Вәлит. Туган елыгыз?

Бану. Житмеш — тулар-тулмас.

Вәлит. Әйе...

Бану. Яшьлек килә дә китә, картлык килә дә... китми.

Вәлит. Адресыгыз?

Бану. Агыйделкәй — алкын, суы — салкын,

Аккошлары үргә йөзәдер...

Вәлит. Семья хәлегез?

Бану. Ялгызлыкка хатын-кызлар түзә,

Ир-егетләр ничек түзәдер.

Вәлит. Һөнәрегез?

Бану *(хыялланып).*

Әлли-бәлли-бәлли- бәү,

Әлли-бәлли-бәлли-бәү...

Вәлит. Бала караучы, димәк...

Бану. Тәрбияче.

Вәли. Озакмы?

Бану. Гомер буе.

Вәлит. Кайларда эшләдегез?

Бану. Агыйдел. Казан. Педучилище. Тагын Агыйдел.

Вәлит. Казан? Кайчан?

Бану. Сугыштан соң.

Вәлит. Ике катлы таш йорт?

Бану *(сөенеп).* Әйе!

Вәлит. Тукай урамы?

Бану. Тукай урамы!

Вәлит. Доктор Айболит! Хәтерлисезме?

Бану. Айболит?

Вәлит. Бану апа!

Бану. Син кем, балам, кайсысы?

Вәлит. «Вәлит, син доктор Айболит булырсың, исемең дә килеп тора». Моны син әйттең, Бану апа!

Бану. Бану апа үзенең иске ак күлмәгеннән халат тегеп бирә. Син, янәсе, укол кадау өчен, тәрбияче апаңның оек энәсен сорамыйча гына аласың...

Вәлит. «Авыру»ларга укол кадаганда, энәне идән ярыгына төшереп җибәрәм. Ә ул...

Бану. Син, шаян, качасың. Ә ул...

Вәлит. Доктор Айболитны, тотып алып, колагын бора. Мин кычкырам: «Бану апа! Ой, болит! Ой, болит!»

Бану. Менә мин хәзер, күпме еллар узгач, яратып кына, тагын колагыңны борам!

Вәлит. Ой, болит! *(Кочаклап.)* Бану апа, кадерлем. Нигә соң Сез кергәч тә кем икәнегезне әйтмәдегез? Чак таныдым...

Бану. Синдә шул ук халат, авырулар...

Вәлит. Вәлитне доктор Айболитка әйләндерүче — Сез, Бану апа! Уеннан уймак!

Бану. Йоклата алмыйча иза чигә идем үзеңне. Мин әкият сөйли башлау белән, һәммәсе күзләрен йома, ә син, терекөмеш кебек күзләреңне тәгәрәтеп ятасың да ятасың.

Вәлит. Шуннан соң Сез безне скрипкада уйнап йоклатырга өйрәттегез. Гомер буе шул моң арттан калмый ияреп бара. Юк, ияреп түгел, алдан бара, тынычландыра, гамьләндерә. Хәзер мин, Бану апа, невропатолог буларак, авыруларны йоклатып дәвалыйм. Әнә шул көй белән тынычландырам, йоклатам. Сезне дә дәв静аларбыз, Бану апа. Үз моңнарыгызда тибрәтеп кенә...

Бану. Тамаша! Башкалар кайда соң, күрәсеңме?

Вәлит. Миндә — уникаль фоторәсем! Зурайтырга алып килгән идем. *(Рәсем ала.)* Карагыз! Иң уртада — Бану апа!

Бану. Илаһым! *(Сөенеп, күз яшьләренә төелеп.)* Монысы — син! Ә менә бу почык борын...

Вәлит. Рөстәм Таймасов — танылган скрипач! Сезнең тәрбия! Искиткеч мөлаем кеше!

Бану. Монысы... Монысы...

Вәлит. Сәүбан Гәрәев. Төзүче. Социалистик Хезмәт Герое. Исегездәме, йорт төзергә өйрәткәнегез?..

Бану. Хикмәт... Зәкия!

Вәлит. Бала тапканда үлде, мәрхүмә. Атказанган укытучы иде. Исегездәме, Бану апа булам ди торган иде...

Бану. Истә, бәгырьләрем, истә. Самат түгелме соң бу?

Вәлит. Әйе. Сандугач...

Бану. Самат, Сандугач... бәләкәчләрем. Исәннәрме-сауларммы?

Вәлит. Сандугач миңа килгән иде. Искә алып утырдык. Самат та, ул да элекке балалар бакчасына ике өй аша гына торалар.

Бану. Минем анда болай да барасым бар. Күрми түзәлмәм.

Вәлит. Нинди йомыш, Бану апа?

Бану. Сөйгәнемнең туган көне.

Вәлит *(сәерсенеп).* Сезгә башта дәваланырга тәкъдим итәм, Бану апа! Иртәгә — килегез!

Бану. Калды — ерак

Күзләремне

Шатлык моңы юган көне...

*(Скрипка уйнала. Бану шул моңга таба китә.)*

## 2

**Коммуналь өйдә Шәфиканың бүлмәсе. Стенада Тәнзиләнең биш-алты яшьтә төшкән фоторәсеме, скрипка. Төн җиткән. Шәфика кайтып керә. Кулында — хуҗалык сумкасы. Ут кабыза. Тәрәзәне ачып куя. Кухняны карый. Тәнзиләнең һаман кайтмавын белеп, авыр сулап, креслога утыра. Аптечкадан дару алып эчә. Йокымсырый. Ишектә Тәнзилә күренә. Кулында дипломат.**

Шәфика. Кайда булдың?

Тәнзилә. Су коендым.

Шәфика. Кемнәр белән?

Тәнзилә. Дусларым белән.

Шәфика. Көне буемы?

Тәнзилә. Кояш көне буе кыздыра бит.

Шәфика. Сиңа ничә яшь?

Тәнзилә. Унтугыз тула!

Шәфика. Унтугыз яшьтә мин иртә таңнан төнгә кадәр фермада...

Тәнзилә. «Тездән пычракка баттың. Эти-әниеңне карадың. Ә син...» Шулаймы?

Шәфика. Якынрак кил! *(Үзенә таба тарта.)*

Т ә н з и л ә. Иркәлисең киләме?

Ш ә ф и к а. Кемнәр белән булдың?

Т ә н з и л ә. Егетләр белән! Мөстәкыйль тормыш башлый торган вакыт. Унтугыз яшь бер генә тапкыр була! *(Магнитофон куя.)*

Ш ә ф и к а. Туктале, кызым... Туган көнеңне уткәреп өйрәнмәгәч ни... Кая инде истә тоту. Бүгенмени соң әле... Кара әле... Ачуланма инде, Тәнзилә... *(Өстәл әзерли башлый.)* Акрын. Сәгать уннан соң — ярамый! Тегеләр тагын тавыш куптарырлар.

Т ә н з и л ә. Синеңчә булсын. *(Музыканы акрынайта.)*

Ш ә ф и к а. Тәнзилә, син инде балигъ булган кыз...

Т ә н з и л ә. Беләм.

Ш ә ф и к а. Киләчәгең турында уйларга вакыт.

Т ә н з и л ә. Уйлау — картайта. Әнә синең кырык яшьтә чәчләрең агара.

Ш ә ф и к а. Күбесе синең өчен кайгырып. Сине ательега эшкә кертү өчен генә дә күпме иза чиктем.

Т ә н з и л ә *(шифоньердан күлмәген алыштыра).* Юкка гына! Мин кичә расчет алдым.

Ш ә ф и к а. Ташладың?

Т ә н з и л ә. Әйе.

Ш ә ф и к а. Кем рөхсәт итте?

Т ә н з и л ә. Үзем!

Ш ә ф и к а. Әниең бармы синең?

Т ә н з и л ә. Бар!

Ш ә ф и к а. Аның белән киңәштеңме? *(Җавап юк.)* Кем синең өчен, бәхетле булсың дип, йөрәге авыру килеш, көне-төне тырышып йөри? Ике мәктәптә икешәр смена музыка дәресләре биргәч, кем кичләрен өйдән-өйгә йөреп, төнгә кадәр балалар өйрәтеп йөри? Синең өчен түгелмени?

Т ә н з и л ә. Миңа берни дә кирәкми.

Ш ә ф и к а. Ник эшеңне ташладың? Иртәгә ук барасың!

Т ә н з и л ә. Аяк та атламыйм!

Ш ә ф и к а. Нинди бала син? Беркемдә мондый бала юк. Берни теләмисең. Сине музыкант итәсем килә иде, юк, музыка мәктәбен ташладың. Медицина институтына керергә көчләп карадым, кулыңнан тотып, имтиханнарга алып бардым, юк!.. Ни генә телисең син?

Т ә н з и л ә *(тәрәзә янына килеп).* Мин бала чактан ук күккә очарга теләдем. Әле дә телим! Әтием кебек...

Ш ә ф и к а. Аны искә төшерәсе булма!

Т ә н з и л ә. Самолет очып киткән саен «Әти!» — дип кычкырып йөгерә идем.

Ш ә ф и к а. Ялгышкансың.

Т ә н з и л ә. Балалар бакчасында хыялланып, зәңгәр күккә карап ята идем...

Ш ә ф и к а. Буш хыял!

Т ә н з и л ә. Әти мине алырга килгәч, кочагына ташланып: «Әти, мине дә зәңгәр күккә алып мен әле!» — дип ялына идем. «Хыял гына булсын, Тәнзилә, син дә очарсың!» — дия торган иде.

Ш ә ф и к а. Искә төшерерлек түгел синең атаң. Ул сине ташлады.

Т ә н з и л ә. Ул *(басым ясап)* сине ташлады. Аның урынында булсам, мин дә...

Ш ә ф и к а. Дәшмә! Син аллә аңардан башка яши алмабыз дип уйлыйсыңмы? Китсен, юлына — ак җәймә! Дөньяның тоткасы бездә — хатын-кызларда! Ул, мескен, миңа баш булырга теләде.

Т ә н з и л ә. Муен булмаган җирдә — баш булмый. Хәзер мин башсыз да, муенсыз да.

Ш ә ф и к а. Тәнзилә, борчылма, кызым, икәү рәхәтләнеп яшәрбез. Йөрәктәге яра онытылыр. Бәхетнең дә койрыгы бар — бер эләктерсәк, ычкындырмабыз.

Т ә н з и л ә. Ә ул... Ул? Кире кайтмасмы?

Ш ә ф и к а. Кайтмасын. Гаиләсен ташлаган ир — бәхетсез.

Т ә н з и л ә. Ул... монда бәхетсез иде. Тынчу иде, монда һава җитмәде аңа. Шушы вак тормыш ыгы-зыгысыннан ычкынып киткәч, зәңгәр күктә рәхәт булгандыр аңа. Мине дә үзе белән аласы килгән иде,— бирмәдең. Ул мине һаман күккә, биеккә чакыра.

Ш ә ф и к а. Йолкып ат күңелеңнән! Ул безгә лаек түгел!

Т ә н з и л ә *(тәрәзәгә карап).* Баш әйләнгәнче биеклеккә менәсе, парашюттан тирбәлә-тирбәлә яшел болыннар, кара урманнар өстенә сикерәсем килә. Аэроклубка язылгач, барып, исемемне сыздырдың. Кистең очар канатларымны!

Ш ә ф и к а. Очу — кызлар һөнәре түгел. Әниеңнең болай да хәсрәтләре азмы? Егылып төшеп харап буласың киләме?

Т ә н з и л ә. Яратмаган эштә озак еллар саргаеп сулганчы, зәңгәр күктә бер сәгать очып, егылып төшүең артыграк!

Ш ә ф и к а. Атаң каны котыра синдә!

Т ә н з и л ә. Котырсын!

Ш ә ф и к а. Атаң холкы белән ерак китә алмассың...

Т ә н з и л ә. Яши-яши аңладым: әти, сине ташлап, дөрес иткән.

Ш ә ф и к а. Ә?.. Ни дидең?! Күз алдымнан югал, җүнсез кыз! *(Үзен-үзе белештермичә, хрусталь савыт алып, Тәнзиләнең аяк астына ыргыта.)*

Т ә н з и л ә. Әти истәлеге... *(Җыя.)* Бердәнбер ядкарь... *(Шәфика йөрәген тотып, креслога утыра. Шау-шу ишетеп, күршеләр җыела башлый.)*

С а м а т *(керә).* Тагын тавыш!

М ә д ә н и я *(керә).* Тагын гауга! Янәсе!

С а м а т. Хатыным Мәдәния белән бергәләп, йөз дә беренче тапкыр кисәтәбез. Онытмагыз, бу — коммуналь квартира. Әгәренки тагын бер генә тапкыр сәгать уннан соң тавыш куптарсагыз, лично үзем өстегездән анонимка язам. Хезмәт иярләренә үз хатыннары белән тынычлап йокларга мөмкинлек тудырасызмы сез, юкмы?

М ә д ә н и я. Тудырасызмы сез, юкмы?

Т ә н з и л ә. Гомер буе дус яшәгән күршеләребезне кунакка чакырмакчы идек мена әнием белән. Өстәл әзерләгәндә ялгыш тәлинкә төшеп китте.

М ә д ә н и я. Янәсе.

Ш ә ф и к а *(хәлсез).* Кыланма.

Т ә н з и л ә. Менә әнием өстәл әзерлә-

де сезнең өчен. *(Дипломатыннан шампан шәрабе ала.)* Шампанское алды...

Мәдәния. Янәсе...

Самат *(шикләнеп).* Юк инде!

Мәдәния. Самат, туз, бирешмә!

Тәнзилә. Кадерле күршеләр, килегез өстәл янына. *(Бокаллар алып куя.)* Сәбәпсез мәҗлес түгел. Миңа — унтугыз яшь тулды! *(Тегеләр бер-берсенә карашалар да өстәл янына киләләр.)* Әни, син дә кил... *(Шәфика көч-хәл белән өстәлгә якыная)*

Самат. Туктале, алла бәндәләре, без бит сәгать уннан соң шауламаска дип кул куйган адәмнәр.

Мәдәния. Янәсе! Минем Саматым бик принципиальный!

Самат. Кул куючылардан тагын бер фамилия җитми! *(Сызгыра.)*

Сандугач *(йөгереп керә).* Миннән башка... төнлә тавыш куптарасыз?!

Мәдәния *(Саматка).* Әһә! Син шулай чакырасыңмыни Сандугачны? Шулай очрашасызмы?

Самат. Ярар инде, Мәдәния! Үзең дә беләсең, овчаркага шулай дәшәм!

Сандугач. Янәсе... Кем? Минме овчарка?

Самат. Юк инде.. Безнең эт турында сүз бара. Күптән түгел генә алдык. Затлы нәселдән. Искиткеч матур Сандугач исемле икән.

Сандугач. Әһә! Минем гүзәл исемне эткә тактыгыз?!

Самат. Яратып инде, сөеп...

Мәдәния. Янәсе? Сөеп? Кемне?

Самат. Сандугачны инде...

Мәдәния. Әһә, син шулаймы әле!.. *(Саматның чигәсенә ялтырата.)* Янәсе...

Сандугач. Рәхмәт!

Самат. Сдача кирәкме?

Мәдәния. Кирәкми. Рәхмәт!

Самат. Мин бит үзебезнең этне әйтәм. Шундый исем биргәннәр ич! Исемен үзгәртми булмас. Шул көннән башлап, күрше белән этле-мәчеле яшибез. Беркөн дә: «Сандугач, прогулкага!» дип кычкырган идем, ике Сандугач килеп чыкты.

Мәдәния. Янәсе... Хәзер парик ясаган җирән чәчеңне алып атам, кияү табалмый тилмергән нәрсә!

Сандугач. Крокодил! *(Саматка.)* Ал овчаркаңны!

Шәфика. Туктагыз, зинһар өчен... Кешеләрчә бер генә көн булса да яшәгән юк бит. Этләр, мәчеләр, тигрлар дуслашалар...

Мәдәния. Сандугачкаем, кара әле моны, ничек сөйләшкән була, янәсе!

Сандугач. Фәрештә!

Мәдәния. Янәсе! Тавыш-гауганың үзәге шушы! Көне-төне скрипка акырта.

Шәфика. Менә хәзер сәбәп тә юк тавышланырга.

Мәдәния. Бар! Бик бар!

Самат. Сәбәп бик зур! Бүген сез баштап сәбәпсез тавыш чыгардыгыз! Менә — сәбәп!

Сандугач. И миннән башка! Менә сәбәп!

Тәнзилә *(бокалларга коеп).* Күршеләр, әни... Тотыгыз бокалларыгызны! Бүген сезнең белән күрше булып яшәүгә унтугыз ел тулды!

Мәдәния *(авыр сулап).* Янәсе! Унтугыз ел!

Самат. Түзә адәм!

Сандугач. Краннан күпме сулар акты!

Мәдәния. Исегездәме, Сандугач кранны ачып калдырып, бөтен өйне су баскан иде...

Сандугач *(җырлап).*

Узган гомер кире кайтмый
Сулар үргә акса да!

Самат. Күпме тәлинкә ватылды...

Мәдәния. Бергә яшәдек, бергә картайдык... янәсе.

Шәфика. Бер-беребезнең гомерләрен кыскарттык.

Тәнзилә. Ә гомер нинди кыска, күршеләр! Мин сезне гомергә бер тапкыр кунакка чакырдым. Унтугыз елда, хөрмәтле күршеләрем, мин сездән күп нәрсәгә өйрәндем. Рәхмәт сезгә! Сез мине бер-береңнән көнләшергә, бер-береңнең уңышы өчен кайгырырга өйрәттегез! Рәхмәт сезгә! Бу сыйфат та миңа кирәк булыр. Аннан соң сез мине усал булырга өйрәттегез... Монысы өчен дә рәхмәт! Тормышта кулланырмын! Күтәрегез, күршеләр, бокалларыгызны! Мин туганчы ук әнине сез үзегез кебек вакланырга өйрәтеп өлгергән идегез инде. Рәхмәт!

Шәфика. Тәнзилә!

Тәнзилә. Әни, бүгенгә булса да тыел! Бер генә сәгатькә соңга калып кайтса да, синең этигә: «Кем белән йөрдең?» — дип бәйләнүләреңә, минем алда да, болар алдында да аны кимсетүләреңә, күршеләрнең дә сезнең араны бозу өчен тырышулары истә, һаман да истә! Тырышлыкларыгыз бушка китмәде, рәхмәт! Йомшак күңелле, сабыр холыклы әти түзде-түзде дә, сезнең ваклыкларыгыздан, боз катламы кебек көнкүрешегездән ычкынып, зәңгәр күккә күтәрелде! Тынчу миңа монда этидән башка, тын җитми миңа, сезнең атмосферагыз кыса, һаман түбән идерә минем башны. Мин сездән... китәм!

Шәфика. Кая китәсең?

Тәнзилә. Зәңгәр күккә!

Шәфика. Атаң янына барасы булма!

Тәнзилә. Юк, этигә түгел, эти киткән якка.

Шәфика. Ул кадәре үк шәфкатьсез бала булырсың дип уйламадым.

Тәнзилә. Мин синнән өзелеп төшкән бала! Күршеләр, сезнең шатлыгыгыз өчен тост күтәрик: кухняда — бер кеше ким...

Мәдәния *(Саматка)*. Эч инде җае туры килгәндә.

Самат *(эчеп)*. Маладис, кызым! Дөрес эшлисең китеп.

Мәдәния *(эчеп)*. Бик узыналмас хәзер әниең!

Сандугач *(көнләшеп)*. Кияүгә чыгасыңмы әллә? *(Эчә. Җырлый.)*

Коммуналь фатирлары!
Кияү тапса, исем киткән.
Яңадан кайтыр әле!

Самат. Пропискадан төшәргә онытма!

Тәнзилә *(чемоданын алып)*. Бар да сез теләгәнчә... Шуны онытмагыз, күршеләр, әнине, мин юк дип, кыерсытмагыз.

Мәдәния. Янәсе!

Сандугач. Тагын да явызланыр әле!

Тәнзилә. Кыерсытсагыз, онытмагыз: үзегезчә җавап бирермен! Озату кичәсе шуның белән тәмам! *(Усал.)* Хушыгыз! *(Күршеләр, китәргәме-китмәскәме дип, бер-берсенә карашып торалар.)* Хушыгыз! *(Тегеләр чыгалар.)*

Шәфика. Кызым, китмә...

Тәнзилә. Беренче бәхәс түгел! Монысы хәлиткеч! *(Җыена.)*

Шәфика. Кешеләрчә сөйләшеп, аңлашып була иде бит...

Тәнзилә. Син мине кайчан аңларга тырышканың бар? Кызыңның кайчан туганын да белмисең бит син. Мин спектакль ясадым, миңа унтугыз яшь өч айдан тула.

Шәфика. Әниеңә рәнҗеп китәсеңме?

Тәнзилә. Юк.

Шәфика. Үпкәләпме?

Тәнзилә. Юк.

Шәфика. Иртән китәр идең ичмасам.

Тәнзилә. Зәңгәр төнне яратам.

Шәфика. Сине каян эзләргә?

Тәнзилә. Эзләмә, әни! Табалмассың. *(Чыга.)*

Шәфика. Кызым! Тәнзилә! *(Тәрәзәгә ташлана.)* Тәнзилә!.. Китте... *(Акрын атлап, аптечкага бара, дару алып эчә.)* Киттеләр... *(Бераздан хәл кергән кебек була. Ул, нидер исенә төшереп, скрипкасын ала. Уйнарга тотына. Ишектә звонок. Ул аны ишетми, уйнавын дәвам итә. Бану апа кереп, көйне-җырны бирелеп тыңлап тора.)*

Бану *(көй беткәч)*. Мөмкинме? Исәнмесез?

Шәфика *(әйләнеп карамыйча)*. Китегез, барыгыз да китегез! *(Скрипкасын өстәлгә куя.)*

Бану. Саумы, балам!

Шәфика. Берегез дә кирәкми! *(Кинәт борыла, Бануга игътибар да итмичә, башын тотып, диванга каплана.)*

Бану *(аның янына барып)*. Тукта, сеңелем, шашынма. *(Чәченнән сыйпап.)* Берәр кайгың бармы?

Шәфика. Китегез! Югалыгыз!

Бану. Авырыйсыңмы, берәр җирең авыртамы? Врач чакыртыйммы?

Шәфика. Берни дә, беркем дә кирәкми!

Бану. Авырмасаң, тор, утыр, кызым... Берәр ярдәм кирәкме?

Шәфика. Валидол алып бир! Әнә!

Бану *(редикюлен актара)*. Йөрәгең авыртамы, кызым?.. Мә... Җиңел булып китәр... *(Өстәлдән су алып бирә.)* Су кабып җибәр. Хәзер тор, күтәрел, менә шулай... *(Шәфикага торырга ярдәмләшә.)*

Шәфика. Син кем?

Бану. Бану апа.

Шәфика. Нинди Бану апа? Нигә кердең?

Бану. Моннан ике йорт аша гына — мин сугыштан соң эшләгән балалар бакчасы. Хәзер — тып-тын, шаклар да каттым: склад ясаганнар, җансызлар. И гомер, и тормыш... Озак-озак карап уйланып тордым: нәниләрем йөгерә-чаба, шаяра-көлә килеп чыгарлар кебек. Шулчак, илаһым, колакларым ялгыш ишетәме дисәм, сезнең тәрәзәдән шундый да якын, шундый да таныш көй ишетәм. Ялгыш кермәдемме, син минем баламмы?

Шәфика. Балаң? Мин нишләп синең балаң булыйм? Ялгышкансың, апа...

Бану. Бер дә ялгышмадым; шушы йорт! Тыштан ук таныдым: төсе генә үзгәргән. Килеп кердем мин бу өйгә, онытылырлык түгел. Син әллә, кызым, Харисның кызы, туганымы?

Шәфика. Ишеткәнем дә юк.

Бану. Харисның улы Айвазны беләсеңдер мөгаен...

Шәфика. Белмим.

Бану. Күп сулар акты шул... Кызым, балалар бакчасына йөргәнеңне хәтерлисеңме?

Шәфика. Кая безгә ул елларда бакча... Сугыштан соң...

Бану. Уйла, ашыкма. Бу мин бит инде: тәрбиячең Бану апа.

Шәфика. Бернинди Бану апаны да белмим. Мин авылда туып үстем.

Бану. Шулаймыни... Ә каян беләсең бу көйне? Аны бит балаларга мин өйрәткән идем. *(Көйләп куя.)*

Шәфика. Тәнзилә кызым җырлый иде.

Бану. Ә кызың кемнән ишеткән?

Шәфика. Әтисеннән.

Бану. Әтисенең исеме ничек?

Шәфика. Нәҗип.

Бану. Нәҗип? Ике Нәҗипне беләм. Чәчләре керпенеке кебек үрә торган каты чәчле Нәҗипме?

Шәфика. Чәчләре йомшак, сирәк иде.

Бану. Алайса башкасы. Мин аларга «Очты, очты...» дигән уен өйрәттем. «Очты-очты гәҗитләр очты, очты-очты Нәҗипләр очты...» Нәҗип наным кул күтәргәч, әйтәм: «Ялгыштың, Нәҗипләр оч-

мый!» «Оча, Бану апа, ди бала, Нәҗип летчик була, оча!» — ди. Шул Нәҗипме?

Шәфика. Шул!

Бану. Кайда ул?

Шәфика *(күккә күрсәтеп).* Очты! Очты. Нәҗипләр очты! Син нәрсә әле миннән сорау аласың? Ни кирәк сиңа? Нигә кердең? Юлыңда бул!

Бану. Хәзер китәм... Берәр ярдәм кирәкмиме? Кибеткә, аптекага чыгып керергә?.. Туганнарың?..

Шәфика. Бәлки син, төннәрен кереп, квартира талап йөрүче карчыктыр.

Бану. Алай тәмсез телләнмә, кызым... Биздергән дә, сөйдергән дә тел ди. Йөзләрең агарып киткән. Ят, сиңа тынычлык кирәк. *(Башын тотып.)* Һай, башың кайнар икән. Температураң күтәрелгән. Син торма, әзлекмә, ятып кына тор... Менә шулай. Өзлексез дару да эчмә. Менә дигән үләннәр белән үзем дәвалармын. *(Чәчләреннән сыйпап.)* Кай төшең авырта соң, бала?

Шәфика. Йөрәк.

Бану. И нечкә урын ул йөрәк дигәнең. Шатлыклар да, хәсрәтләр дә шул нәни кош шикелле тыпырчынган йөрәккә җыела. Торма, бала, ят тынычланып. Мин хәзер сине тирбәтәм. Йом шомырт төсле түм-түгәрәк күзләреңне... *(Бишек тирбәткән кебек.)* Тыңла Бану апаңны... Сөйләшми генә ят. *(Өстенә одеал алып яба. Көйли.)*

Әлли бәлли-бәлли бәү,
Күзләреңне йом гына,
Шундук йоклап китәрсең,
Ятсаң уйсыз — тын гына...

Бану апаң — үз гомерендә исәпсез-хисапсыз нәниләрне йоклаткан апа ул. Сабыйларны йоклата да үзе дә изрәп китә торган апа. Менә хәзер син рәхәт йокыга талырсың. Синең бар дөньяң түгәрәк, бар җирең җиткән... Син әкрен искән җил уңаена ямь-яшел болын буйлап юыртып баручы колын сыман... Хәзер син минем Бану апа икәнемә ышандың... Әйт әле, балам, Бану апа, диген...

Шәфика *(уяулы-йокылы).* Бану апа...

Бану. Әйт хәзер Бану апаңа... нинди хәсрәтең бар?

Шәфика. Менә, ташладылар, Бану апа...

Бану. Кемнәр?

Шәфика. Башта — ирем очты... Зәңгәр күккә! Гомерем буе үкенерлек... ялгыштым... Белмәдем кадерләрен...

Бану. Бану апаңның да күп андый үкенечләре.

Шәфика. Бердәнбер кызымны югалттым. Аңламадым күңелен. Адаша бала...

Бану. Күңелендә изгелек булса, кайтыр... Хәзер оныт барысын да... Йокла. Сине беркем дә ташламаган. Син ямьсез төш кенә күргәнсең... Бану апа йоклаткан бала беркайчан да куркыныч төшләр күрмәс. Син йоклап киткәч кергән төш матур, бик матур булыр. Тыңла, бер әкият сөйлим... Сөйлимме, кызым?

Шәфика *(йокыга китә-китә).* Сөйлә, Бану апа...

Бану. Борын-борын заманда, кәҗә команда, саескан — сотник, үрдәк — урятник булган заманда яшәгән ди бер карчык. Аның исеме булган ди Бану апа... Аның бик күп балалары булган ди... Кызым, тыңлыйсыңмы? *(Шәфика җавап бирми.)* Тыныч йокла...

Шәфика *(уянып, бала тавышы белән).* Бану апа, китмә, мин куркам... Алай-болай булып куйсам... Бану апа! Васыять әйтергә беркемем дә юк. Тыңла, Бану апа!

## 3

**Шул ук бүлмә. Унбиш көннән соң. Стенада — Шәфиканың рәсеме, скрипка. Беркем дә юк. Зөлфәт керә дә башта Шәфиканың рәсеменә карап тора, аннан, скрипканы алып, уйнарга тотына. Бану кайта да Зөлфәтне тыңлап тора. Зөлфәт, Бануны күреп, ачык тәрәзәдән сикерергә уйлый.**

Бану. Балам, курыкма...

Зөлфәт. Мин берни дә алмадым.

Бану. Ышанам. Кил монда!

Зөлфәт. Ә... тотар идең бугай!

Бану. Синең бер гаебең дә юк.

Зөлфәт. Скрипкә уйнадым ич.

Бану. Бик тә өздереп уйнадың... Үзеңнең скрипкаң юкмыни?

Зөлфәт. Юк шул... *(Банугә якыная бара.)*

Бану. Кем өйрәтте?

Зөлфәт. Шәфика апа исән чакта, монда кереп, тегеләрдән качып уйный идем.

Бану. Кемнәр алар «тегеләр»?

Зөлфәт. Кем булсын... Әти, әни.

Бану. Ни диләр?

Зөлфәт. Юк белән хыялланма диләр. Җырлап баеп булмый диләр. Әти гармунында уйный идем, сатты...

Бану. Үскәч кем буласың килә, Зөлфәт?

Зөлфәт. Тегеләргә әйтмисеңме?

Бану. Валлаһи, билләһи, әйтмим!

Зөлфәт. Музыкант. Шәфика апа кебек. Һәр кешене җырларга өйрәтәсе килә.

Бану. Хыялыңа ирешерсең, балам!

Зөлфәт. Юк шул. Тегеләр миңа: «Гастроном директоры буласың»,— диләр. Мин теләмим. Шәфика апа нишләп үлде ул?

Бану. Йөрәк авыруыннан.

Зөлфәт. Йөрәк нидән авырта?

Бану. Һаман хәтеремдә... Бәләкәй чакта...

Зөлфәт. Синең дә бәләкәй чагың бар идемени?

Бану. Кил, балам, якынрак кил... Исемең ничек синең?

Зөлфәт. Зөлфәт.

Бану. Нигә минем исемемне сорамыйсың?

Зөлфәт. Әбиләрнең исеме буламыни...

Бану. Бану апа мин. Шулай, Зөлфәт дус, бәләкәй чакта, бер малай рогаткадан атып, сыерчык баласын үтерде.

Зөлфәт. Үтерде?.. Мин аны!

Бану. Менә шул көннән мин йөрәкнең барлыгын, еш-еш тибүен тойдым. Шафика апаң да әнә шундый хәлләрне күп күргәндер, мәрхүмә.

Зөлфәт. Ә син скрипкадә уйный беләсеңме?

Бану. Беләм. Уйныйммы?

Зөлфәт. Маташтырып кара. *(Бану уйный.)* Кара, син миннән дә остарак уйныйсың ич...

Бану *(балага әйләнә бара).* Икебез дә әйбәт уйныйбыз, ә-әме, Зөлфәт?.. Мин әкиятләр дә яратам әле.

Зөлфәт. Мин дә.

Бану. Әкият геройларыннан кем буласың килә? Камыр батырмы?

Зөлфәт. Кит аннан... Камыр батыр...

Бану. Нигә?

Зөлфәт. Эти әйтә: «Хәзерге заманда Камыр батырны сразы кабып йоталар, лутчы аждаһа бул!» — ди.

Бану. Ә син?

Зөлфәт. «Сезнең өчен аждаһа, үзем өчен Шүрәле булам!» — дидем.

Бану. Нишләп Шүрәле буласың килә?

Зөлфәт. Каеш тотып, миңа сугарга килгәч кенә, этине кытыклап көлдерәм.

Бану. Зөлфәт, әйдә уйныйбыз!

Зөлфәт. Әйдә!

4

**Вәлитнең дәвалау кабинеты. Караңгы. Скрипкада таныш көйне уйныйлар.**

Вәлит тавышы. Дәвалау сеансын башлыйбыз! Урыннарыгызга ятыгыз! Хәзер барысын да, барысын да онытыгыз. Үзегез кичергән авырлыкларны, кайгы-хәсрәтләрне дә онытыгыз. Күңелегез хуш, дөнья матур, иркен, сез аллы-гөлле, чәчәкле табигать кочагында тирбәләсез. Менә сезнең арыган күзләрегез рәхәтлек тәэсиренә бирелеп, әкрен генә йомылалар.

Бану тавышы. Самат, киттек, акыллым!

Самат тавышы. Бану апа, кая алып барасың?

Бану. Бакчага.

Самат. Анда нипи бираләрме?

Бану. Бирәләр, сөеклем. Туйганчы ашарсың.

Самат. Туйганчы? Туйгач, нишләрбез?

Бану. Уйнарбыз.

Самат. Уйнап туйгач, нишләрбез?

Бану. Уйларбыз.

Самат. Нәрсә уйларбыз?

Бану. Тормыш, кешеләр, яшәү турында уйларбыз, акыллым.

Самат. Мин үскәч сине гел-гел кунакка чакырырмын, Бану апа.

Бану. Вәлитне дә...

Сандугач. Сандугачны да. Нәҗипне дә... Барысын да. Барырсызмы, Бану апа?

Бану. Барыбыз да бергә җыелып килербез, Самат үскәнем!

**Музыка тына. Яктыра.**

**Шул ук өйдә. Саматлар квартирасы.**

**Мәдәния ялгызы счет төймәләрен тарта. Самат кайтып керә дә, дәшмичә, тәрәзәгә карап тора.**

Мәдәния. Ике мең дә өч йөз дә илле биш тәңкәгә китереп кушабыз... Саматкаем, кайттыңмы? Китереп кушабыз, шалт итеп, мин бүген күбек сатып җыйган үн тәңкәне! Илла да яратам шул сыра чөмерүче ирләрне, рәхәтләнеп алданалар, мокытлар. Саматкаем, син генә үз акчаңа әчә күрмә, барлык ирләр сыра мичкәсенә кереп ятсын, тончыксын, тагын терелсен, аракы ирләрне аллаһе тәгаләдән аерса да, аллаһе тәгалә ирләрне аракыдан аермасын! Мин сугып кайткан ун тәңкәгә, шалт итеп, син алып кайткан... Самат, чыгар бала өлешен... Күпме алып кайттың?

Самат. Тот капчыгыңны!

Мәдәния. Шулкадәр күп каердыңмы? Эшләр майланган кебек бара, Саматкай. Кеше рәтенә чыгарыйк әле Зөлфәтебезне. Бер заман, малайкаем, килеп чыга безнең Зөлфәт гастроном ишегеннән! Шоферы көтеп тора! Арткы ишеккә килгән эреле-ваклы начальникларга теләр-теләмәс кенә сәлам биреп, министрга китеп бара! Янәсе! Самат, алла директор итмибезме соң Зөлфәтне?.. Директорлар киләләр-дә китәләр... Ә урынбасар кала. Давай урынбасар гына итик. Хуҗаның урынын басар-басмас кына йөрсен балда-майда йөзеп... Китер бала өлешен! Сиңа әйтәм...

Самат. Сукыр бер тиен дә юк!

Мәдәния. Юк?!

Самат. Юк.

Мәдәния. Алдама!

Самат. И булмас та!

Мәдәния. Шаярма!

Самат. Уен эш түгел.

Мәдәния. Ни булды?

Самат. Аяк чалды! Тез астына сукты!

Мәдәния. Кем?

Самат. Екты! Изде!

Мәдәния. Акчаңны югалттыңмы?

Самат. Югалтмадым! Колак кактым!

Мәдәния. Таладылармы?

Самат. Югалса да, таласалар да, насыйп акча үзе кесәгә килеп керә. Акчаның кылын кисте!

Мәдәния. Кем ул шулай балабызның киләчәген кисә! Начальнигыңмы?

Самат. Начальник булса әле бер хәл. Төртсәң аварга торган бер...

Мәдәния. Янәсе! Хәзер мин аны үзем аударам! Кем ул? Әйт!

Самат. Әйтергә оят! Хурлык! Аяк чалырлык хәле дә юк бер...

Мәдәния. Кем?

Самат. Карчык!

Мәдәния. Янәсе! Карчык?

Самат. Җитмеш яшьлек карчык.

Мәдәния. Кайсы карчык?

Самат. Шәфика булмәсендә калган карчык!

Мәдәния. Кит аннан! Шул?

Самат. Шул.

Мәдәния. Нишләтте?

Самат. Беләсең бит, каршы йортта капремонт ясыйбыз! Соңгы айда Саматның күпме табыш белән кайтканын беләсең. Менә шул карчык, имансыз, өйдән-өйгә кереп, «ул слесарьга акча тиеш түгел, бер тиен дә бирмәгез!» — дип үгетләп йөргән. И юк акча! Юк! Кабахәт!

Мәдәния. Намуссыз! Җир бит!

Самат. Аждаһа! Әгитәциягә бирелеп өлгермәгән берәүдән биш тәңкәне элəктереп кайтып килә идем, каршыма килеп чыкмасынмы шул корткa: «Габдуллин, кесәңдәге биш тәңкәне пенсионерга кире кертеп бирмәсәң, хәзер үк милиция бүлегенә алып керәм!» — ди.

Мәдәния. Янәсе! Кире бирдеңме?

Самат. Бирми кара!

Мәдәния. Я, нишләтә?

Самат. Күз бәбәкләремә шундый карап куя: сикереп җибәрәсең.

Мәдәния. Янәсе! Шул хәлсез карчыктан куркып, биш тәңкәңне кире бирдең? Их, үзекәйләрем булсам... бирер идем мин аңа! *(Звонок.)*

Самат. Шул! Тагын эзләп килгән.

Мәдәния. Нишлибез? Кертәбезме?

Самат. Кертмәсәң дә, керә ул... Мин качам! Ач! *(Шифоньер эченә кереп кача.)*

Бану *(керә).* Исән-сау гына яшисезме, күршеләр!

Мәдәния. Янәсе! Исән булмасак, докторсыңмы әллә?!

Бану. Безнең Агыйдел буйларында күрше-тиранe такта чәй, якты чырай белән каршы алалар, кызым.

Мәдәния. Бездә башкачарак: чырае бар, чәйнең тактасы да, бөртеге дә юк! Ни йомыш?! Янәсе...

Бану. Безнең Агыйдел якларында күрше-тирәгә иләк-чиләк сорап кына түгел, хәл-әхвәл сорап та керәләр.

Мәдәния. Бездә иләк тә, чиләк тә юк. Без — кала кешеләре, сала кешеләре түгел! Ни йомыш?

Бану. Кызым, миңа слесарь Габдуллин кирәк иде, биреп тор әле.

Мәдәния. Янәсе... Самат өйдә юк! *(Шул вакыт шифоньер эчендә нәрсәдер төшеп китә.)*

Бану. Самат дисеңме? Кызым, тагын бер кабатла әле: Самат... *(Утыра.)* Менә синң кирәк булса... Са-мат... балам. И-и язмыш, и-и гомер! Габдулла малае Самат... *(Шифоньер янына килә.)* Самат, син мине танымадыңмыни, балам? Ачуланма, бәгырь, мин дә сине танымадым. Кыяфәтең таныргысыз түгел шул, бигрәкләр дә нык үзгәргәнсең. Нинди таныш тавыш, нинди таныш йөз дим. Исемеңне әйткәч кенә келт итеп исемә төште. Самат наным, исеңдәме, балалар бакчасында, миңа үпкәләп, шкаф эченә кереп качканың? Эзлибез, тапмыйбыз. Мин синең йомшак ягыңны беләм... *(Кинәт кычкырып.)* Самат, чык, анда тычкан бар! *(Шул вакыт шифоньердан атылып Самат килеп чыга.)* Самат... улым, нигә миңа үпкәләдең? Нигә миннән качасың?

Самат *(инстинкт буенча бала сыман башын иеп тора).* Белмим...

Бану. Самат, беренче һәм соңгы тапкыр әйтәм, наным, кеше әйберенә тияргә ярамый! Аңладыңмы!

Самат. Аңладым.

Мәдәния. Кара, нәрсә шул карчык алдында, гаепле бала кебек, башыңны иеп торасың! Күтәр башыңны! Мин күтәрткәнне көтмә!

Самат *(балалыктан ычкынып, уз халәтенә кайта).* Карчык, сиңа миннән ни кирәк?!

Бану. «Эндәшә батыр утынчы: «Сиңа миннән ни кирәк?» Мин сиңа «Шүрәле»не өйрәткән идем, онытып бетермәгәнсең икән...

Мәдәния. Янәсе... Ни сөйли бу, Самат?

Самат. Шүрәле? Син үзең Шүрәле!

Бану *(сөенеп).* Исеңә төштемени? Әйе шул, мин Шүрәле булдым, син — Былтыр... *(Уйнап.)*

Бик озак торгач карашып,
күзне күзгә нык терәп,
Эндәшә батыр утынчы:

Самат *(тупас, чынлап, уенга кермичә).* Сиңа миннән ни кирәк?

Бану.
Бер дә шикләнмә, егет, син, мин каракугры түгел,
Юл да кисмимен, шулай да мин бигүк тугры түгел.
Гадәтем: ялгыз кешеләрне кытыклап үтерәм;
Мин әле күргәч сине, шатланганымнан үкерәм...
Самат, нәнием... *(Балачак шаянлыгы, сафлыгы уятырга теләп, Шүрәледәй, бармакларын селкетеп, тегеләрне кытыклау хәрәкәтләре ясый.)*

Самат. Якын килмә, урман сарыгы!

Мәдәния. Каравыл, үтерәләр! Милиция! *(Кытыклауның көлү-елмаю урынына ямьсез тавыш белән акыру китерер чыгарганын күргән Бану аптырап кала. Әмма әле бөтенләй үк өметен өзми.)*

Бану. Самат... синме бу? Исеңдәме мин сине биергә өйрәттем... *(Кул чәбәклап.)*

Бие, бие, Хәйбулла,
Биегән кеше бай була,
Бай булмаса, тук була,
Ашарына юк була.

Әле дә биисеңме, Самат балам?

Мәдәния. Янәсе... Буш кайтса — биетәм!

Бану. Сугыштан соң ачлык еллар... Шушы өй бит... Шушы бүлмә. Ул чак шыр ялангач иде. Анаң авыру, атаң — сугыштан кайтмады. Ашарыгызга юк. Шундый да кызгандым үзеңне, кочаклап алдым бер чак. Авызымнан өзеп сиңа, әниеңә ашаттым.

Мәдәния. Янәсе... Адәм ышанмаслык сүзне, чын булса да, сөйләмә, карчык!

Бану. Елый-елый бакча мөдиренә кердем. Барыбер урнаштырдым үзеңне. Самат... Таныдыңмы инде, балам? Әле һаман танымыйсыңмы? Исеңдәме, мин синең башыңнан сыйпап сорыйм: «Самат, акыллым, үскәч кем буласың?» Син, бәгырь, түм-түгәрәк зәңгәр күзләреңне мөлдерәтеп, әйтәсең: «Бану апа булам!» Алдыңда әнә шул сине көннәр-төннәр буе баккан, тәрбияләгән, ашаткан Бану апаң тора лабаса... Я, Самат улым, кил инде, бер кочакла Бану апаңны! Таны мине, бәгърем, таны! *(Тынлык.)*

*(Мәдәния Саматка усал итеп карый).*

Самат. Знать не знаю! Синең кебек карчыклар завались: кайсын танып бетерәсең...

Мәдәния. Әһә! Акылың алтын икән! Кайчандыр бер телем икмәк ашаткан да, кырык ел узгач, онытылып беткәч, хәлдән тайгач, исәп-хисап ясарга килгән, янәсе...

Самат. Нәрсә, карчык, шуның өчен акча сорап килдеңме?

Мәдәния. Бездә Әндри казнасы юк. Башкаларга, байларга бар соранып...

Бану. Самат, синме бу, әллә ялгыштыммы? Юк... юк... Бәхетсезлегемә каршы, син шул бу! Мин тәрбияләгән бала...

Мәдәния. Янәсе... Бала... бала... Аны мең кеше тәрбияләгән. Берсе дә эзләп килми! Ник килдең, йомышыңны әйт тә...

Бану. Мин Зөлфәт белән уйнарга кердем. *(Тегеләр бер-берсенә карашалар.)* Ул өйдә юк икән. Самат та бәләкәй чакта гел Зөлфәткә охшаган иде. Хыялы нинди татлы, матур иде, наный... *(Үзалдына сөйләнә.)*

Агыйделдә ике басма
Берсеннән чыгалмадым;
Күрмәенчә күпме түздем,
Исемнән чыгармадым.

Эзләдем, таптым... Шулай ук югалттыммыни? Мин бит сезне күрергә килдем. *(Чыгарга кузгала.)* Нишләдегез сез, балакайлар? *(Скрипка уйнала. Бану, башын иеп, әкрен генә чыга.)*

Зөлфәт *(йөгереп керә).* Бану апа кермәдеме?

Мәдәния. Нигә ул сиңа?

Зөлфәт. Уйнарга.

Мәдәния. Бала-чага булдыңмы әллә шуның белән уйнап йөрергә! Утыр — алгибраңа! Кибеттә кирәге чыгар!

Зөлфәт. Каникул! Бераз китап укыйм да — уйнарга! *(Утыра.)*

Мәдәния. Зөлфәт!

Зөлфәт. Әү, әни!

Мәдәния *(кечкенә тартма биреп).* Тот! Янәсе...

Зөлфәт. Нәрсә бу?

Мәдәния. Шәфика апаңны ярата идеңме әле?

Зөлфәт. Ярата идем.

Мәдәния. Бу — аның төсе. Йөзек. Исән чакта сакларга калдырган иде. Мәрхүмнең әйберен өебездә тоту — хәерле булмас. Син моны Шәфика апаңның өстәл тартмасына салып куй, янәсе...

Зөлфәт. Ярый, әни!

Самат. Карчык... Үзенә алса?

Мәдәния. Бу — аны сынау да! Кара аны, теге карчык күрмәгәндә генә кертеп куй, янәсе. Бу хакта аңа — ләм-мим! Шәфика апаң хакына. Төшендеңме?

Зөлфәт. Төшендем. Киттем. *(Чыга.)*

Самат. Төшенмәдем...

Мәдәния. И жирафым, жирафым... Әләктерәбез карчыкны!

Самат. Әләгерме? Зөлфәтне юкка...

Мәдәния. Белми дә кала ул. Кибеткә кергәнче, замдиректор булганчы, шомара торсын. Янәсе...

## ИКЕНЧЕ АКТ

**Вәлитнең дәвалау кабинеты. Караңгы. Скрипкада — таныш көй.**

Вәлит тавышы. Хәзер барысын да онытыгыз. Олы яшьтә икәнегезне дә, үзегез кичергән авырлыкларны, кайгы-хәсрәтләрне дә онытыгыз. Гомерегездә кичергән иң матур күренешләрне күз алдына китерегез!

Бану тавышы. Сандугач кызым, кара әле күккә!

Сандугач тавышы. Ой, нинди матур! Нәрсә ул?

Бану. Салават күпере!

Сандугач. Салават? Нигә Сандугач күпере түгел? Ул — минем күпер!

Бану. Ул, балам, барыбыз өчен дә. Табигатькә дә, адәм балаларына да!

Сандугач. Мин анда менәргә телим! Әйдә, Бану апа!

Бану. Кара әле, исәпсез күп төсләр: ал, кызыл, зәңгәр, яшел...

С а н д у г а ч. Мин менәм! Ул төсләрне тасмама тагам! Барысын да!

Б а н у. Ул матурлык, кызым, Вәлиткә дә, Саматка да, Сандугачка да...

С а н д у г а ч. Бану апага да...

Б а н у. Бану апага да... Табигатьнең иң гүзәл, иң сабый чагы шулдыр. Кагылмыйча гына карап торыйк, кызым.

С а н д у г а ч. Ярый, Бану апа, кагылмыйк... Үскәч мин салават күпере булам!

Музыка.

5

**Сандугачның бер бүлмәле квартиры.**

С а н д у г а ч *(көзге алдында)*.
Әй, бөдрә чәч, күзең кара, кашың кыйгач,
Ха-ха-ха, сандугач,
Өзелеп сайрый таң тугач... *(Звонок. Ишекне ача.)*

Б а н у *(керә. Кулында чәчәк бәйләме.)*
Сандугач баласымы, карлыгач баласымы,
кемнәр яшәп ята икән бу өйдә?

С а н д у г а ч. Бәрәч, син әле китмәдеңмени?

Б а н у. Юк әле, кызым.

С а н д у г а ч. Күмдең Җидесен үткәрдең. Тагын ни көтәсең?

Б а н у. Нәҗип баламны, Тәнзилә кызымны тапмыйча китмим.

С а н д у г а ч. Әзлисеңмени?

Б а н у. Әзлим.

С а н д у г а ч. Юкка гына сандугач кунасы ояга керәсең, әбиюшкә! *(Ритмик музыка куеп, биюле гимнастика ясарга тотына.)*

Б а н у. Күрше белән сөйләшергә сандугач теле кирәк. Әти-әниең сандугач сыман татлы телле итәргә теләптер, гүзәл исем кушканнар. Теләкләре кабул булсын?!

С а н д у г а ч. Нәрсә ул кулыңда?

Б а н у. Иртә белән алсу чәчәк тотып,
Кердем, балам, синең яныңа...

С а н д у г а ч. Сатасыңмы? Ни хак?

Б а н у. Үзем сатып алдым.

С а н д у г а ч. Берәр танышыңа бирәсеңме?

Б а н у. Әйе.

С а н д у г а ч. Кемгә?

Б а н у. Күршемә.

С а н д у г а ч. Кайсы күршеңә?

Б а н у. Сиңа.

С а н д у г а ч. Миңа?

Б а н у. Әйе, сиңа, кызым.

С а н д у г а ч. Нигә аны миңа бирәсең?

Б а н у *(бәйләмне өстәлгә куеп)*. Туган көнең котлы булсын, кызым?

С а н д у г а ч *(гимнастикадан туктап)*. Туган көнем?

Б а н у. Әйе, кызым.

С а н д у г а ч. Минем?

Б а н у. Синең.

С а н д у г а ч. Шаяртма!

Б а н у. Ихлас.

С а н д у г а ч *(паспортын алып карый)*. Дөрес. Минем туган көнемдә синең ни эшең бар? *(Бану дәшми.)* Каян белдең? Анам да белмәгәнне...

Б а н у. Үземнең балаларымның кайчан туганын белә идем мин ул чакларда...

С а н д у г а ч. Үз балаң? Кем?

Б а н у. Син, Сандугач кызым.

С а н д у г а ч. Ялгыш кергәнсең, әби. Мин синең балаң түгел! *(Түгәрәк алып, биләндә әйләндерергә тотына.)*

Б а н у. Балам...

С а н д у г а ч. Нәрсә алимент сорап килдеңме әллә? Шулай да, әби, мине каян беләсең?

Б а н у. Балалар бакчасына йөргәнеңне хәтерлисеңме?

С а н д у г а ч. Әллә...

Б а н у. Исеңдәме, эти-әниләрең ялга киткәч, сиңа күз-колак булырга дип, өегездә мине калдырганнар иде.

С а н д у г а ч *(качалка урындыкта тирбәнә)*. Булгандыр.

Б а н у. Шул көнне без синең туган көнеңне үткәрдек. Бер группада йөргән Нәҗипне, Саматны чакырдык. Өчегез дә бик дуслар, татулар идегез. Ничек истә калган дисәң, минем ул көнне үземнең дә туган көн, сезгә әйтеп тормадым. Әниең кушканча, ул көнне мин, мунча ягып, бик шәпләп каен себеркесе белән сине чаптым. Исеңдәме?

С а н д у г а ч. Искә төшә башлады бугай бераз.

Б а н у *(такмаклап)*.
Атаң кискән утын түгел,
Анаң яккан мунча түгел,
Картны күрсәң, бабай диген,
Карчыкны күрсәң, әби, диген.
Тәмле-татлы телле бул,
Минем кулым түгел,
Әйшә-Батманың кулы,
Минем телем түгел,
Идел кичкән инәкәләр теле...

Шуннан соң мин сине йокларга салдым. *(Качалкада тирбәтеп.)*

Йоклый торган чаккаең,
Йоклый инде ак каен,
Күзләреңне йом инде,
Йокла, сандугачкаем.

Шулкадәр дә изрәп-оеп йокладың. Күз тидерүдән куркып карап тордым. И гомер! Нинди мөлаем, татлы телле идең ул чакта. Нишләдең син, Сандугачым? Кешеләрне сокландырып сайрарга туган кошчыгым, нишләдең?

С а н д у г а ч. Бану апа, башымнан сыйпа...

Б а н у. Мин сине бүген яратмыйм.

С а н д у г а ч. Ни өчен?

Б а н у. Гөнаһың бар.

С а н д у г а ч. Нинди гөнаһ!

Б а н у. Кассирша икәнеңне белеп, самолетка билет сатканыңны карап тордым. Ар-

тык акча алдың... күз алдымда! Димәк, беренче тапкыр түгел?!

Сандугач. Июль-августта билет — дефицит! Билет миндә! Телим — бирәм, телим — юк!

Бану. Ни өчен кешеләрнең хәләл акчасын аласың?

Сандугач. Талап алмыйм — үзләре бирәләр. Ничек алмыйсың ди... Бер мин генәме?

Бану. Иртәгә үк гаебеңне төзәт! Юкса...

Сандугач. Юкса?

Бану. Начальнигыңа җитәкләп алып керәм. Үзем!

Сандугач. Ярый, оныт, Бану апа. *(Скрипка моңында балалыкка бирелеп).* Чәчемне сыйпа әле, Бану апа.

Бану. Нишләдең, ә, бала?

Сандугач. Чыннан да, нишләдем мин? Озын төннәр буе газапланам.

Бану. Ни борчый сиңе, кызым?

Сандугач *(ачылып).* Башкаларның бәхетеннән көнләшәм...

Бану. Көнләшү адәмгә зур газап китерә, бәхет китерми, балам...

Сандугач. Шулай икәнен дә беләм... җиңәлмим үземне.

Бану. Ачыл, кызым. Бану апаңнан яшермә серләреңне. Нигә сиңа күршеләреңнең оясын җимерергә кирәк иде?

Сандугач *(сикереп тора.)* Ни өчен Нәҗип мине түгел, Шәфиканы яратты? Мин кай җирем белән ким Шәфикадан? Ни өчен мине түгел, аны?

Бану. Сиңа җиңеллек килдеме соң? Оя таралды. Нәҗип гаиләсен ташлаган. Шәфика — вафат. Тәнзилә — китеп югалган...

Сандугач. Яратмаган өчен, Нәҗиптән үч алдым! Теләгемә ирештем.

Бану. Шуның белән җаның тынычландымы соң, кызым?

Сандугач *(утыра).* Юк, Бану апа, газаплар артты гына. Синдә тылсымлы үләннәр бар диләр, дөресме?

Бану. Дөресен дөрес...

Сандугач. Сизәм: серле карчык син, курыкма, беркемгә дә әйтмәм. Бану әби, малай, давай мине теләсәң нишләт, өшкер, төкер, но управдом Сәләхов күз салырлык кыз яса! Әби...

Бану. Әбекәем, жаныкаем диң.

Сандугач. Әбекәем, жаныкаем.

Бану. Зинһар өчен диген.

Сандугач. Зинһар өчен.

Бану. «Мөмкин булса, үтенеп сорыйм»...

Сандугач. Уф! Мөмкин булса, үтенеп сорыйм. Әбекәем...

Бану. Мин әйткән шартларны үтәсәң, үзеңнән Сәләхов кына түгел, үткән-сүткән, узган-барган, күрше-күлән күзен алмас.

Сандугач. Акчасыннан тормам... Әйт әле, әби, нигә соң миңа каһәр суккыры ирләр карамыйлар? Күзләренә кереп тә карыйм, ни генә кыланмыйм, көн саен киемне алыштырам, нечкә билле булу өчен гимнастика ясыйм: итәк тә, джинсы да киеп карыйм... Авызым тулы алтын, муеным тулы — асыл таш, беләгем тулы — көмеш, шифоньер тулы — дефицит кием! Мин кемнән ким? Барысыннан да артык! Мәдәниягә кадәр ир тапты бит. Бигрәк ямьсезмени соң мин, адәм карамаслык?! Төсем-битем, кыяфәтем дә килгән кебек, бәләкәй генә борыным да үз урынында, ни җитми миңа, әбекәй? Эте-бете кияүгә чыга, талашып булса да торалар да, рәхәтләнеп аерылалар. Мин, сабака, шулардан киммени соң? Шулай үтәр микәнни яшь гомерем кеше бәхетеннән көнләп? Өшкер-төкер, дарула әле, әбекәем... Ышанмыйм даруларыңа, барыбер, өшкер...

Бану. Аңладым хәлеңне, кызым... Самат та, син дә төне буе йоклый алмый интектегез. Ә Нәҗип — юк. Бану апагыз да сезне уйлап керфек какмады. Дару бар миндә, кызым... Мин сезгә Агыйдел буйларының тылсымлы чишмә суларында болын чәчәкләрен кайнатып алып килдем... Әмма кызык хасияте бар бу серле даруның. Аны эчү алдыннан хыялың белән балачакка кире кайтырга, бөтен тәнеңне-җаныңны сафландырырга кирәк. Бу даруны эчү алдыннан да, эчкәч тә, якын-тирәдә яшәүче кешеләр, күршеләр турында, аларның гүзәллеге, сафлыгы турында уйла, бәхетсезләрнең кайгысына кер, хәлләрен уртаклаш, «җаным,— бәгърем, канатым, гүзәлем, кадерлем» кебек татлы сүзләреңне кызганма кешеләрдән. Шул шартларны җиренә җиткереп үтәгәндә генә, бу могҗизалы дару сине матурлар, җаныңны сафландырыр, тылсымлар, сихерләр... Синнән дә гүзәл кыз булмас. *(Сулы шешәне өстәлгә чыгарып куя.)*

Сандугач *(шешәне тартып алып).* Шушыны... Эчәргә?

Бану. Бер дә шикләнмә. Саф, чиста. Челтерәп тора.

Сандугач. Күпме сорыйсың?

Бану. Табигатьнең күз яшьләре сатылмый.

Сандугач. Бар инде, әбекәем, кит!

Бану. Рәхмәтең кайда, адәм баласы?

Сандугач. Эчеп, әкияттәге гүзәл кызга әверелсәм, әйтермен.

Бану. Мин үз сүземдә калам, кызым. Әгәр гаебеңне төзәтмәсәң, иртәгә үк начальнигыңа барам. Син акча алган кешене мин беләм... *(Чыга.)*

Сандугач. Менә сиңа — көтмәгәндә — ревизор! Котылырга кирәк! *(Шешәгә карап.)* Менә — милициягә — факт! Әллә бераз чөмереп карарга инде? *(Эчә.)* Тфү! Тәмле! Тәмле! Без бит эчегә өйрәнгән, әбиюшка! Күрше ояны Саматлардан йолкып алып, управдом Сәләховны йортка кертмәсәм! — исемем Сандугач булмасын!.. *(Ритмик гимнастика ясый.)*

**Авансцена.**

Б а н у *(керә).* Туганнар, кордашлар, энесеңелләр, балалар! Тәнзилә исемле кызны күрмәдегезме? Әнкәсенә охшаган зәңгәр күзле, моңлы тавышлы, үзе сипкелле, үзе сөйкемле бер кыз булыр. Очрасагыз, әйтә күрегез: аны өендә көтәләр!

*(Мәдәния белән Самат, Сандугач керәләр.)*

М ә д ә н и я. Менә ул! Эзенә төштек!

С а м а т. Эләкте!

М ә д ә н и я. Качып китмәкче! Янәсе!

С а н д у г а ч. Әйттем мин сезгә: ычкына бу! дип...

Б а н у. Ни булды, балалар?

М ә д ә н и я. Тотыгыз! Талады! Өйне басты! *(Саматка.)* Кычкыр!

С а м а т *(әкрен).* Каравыл...

С а н д у г а ч. Сихерләде! Харап итте!

Б а н у. Кем кемне талады?

М ә д ә н и я. Кем дигән кеше! Янәсе! Син! Өй басучы! Карак!

С а н д у г а ч. Аферистка! *(Кулындагы шешәне селкетеп.)* Менә шушы нәстә белән сихерләде! Экспертиза таләп итәм! «Бөтен ирләр сиңа гына карап торыр»,— диде. Әйләнеп тә карамадылар. Ни карап торасыз, тотыгыз аны!

Б а н у. Җыелган халыктан оялыгыз!..

*(Шау-шу, ыгы-зыгы.)*

М ә д ә н и я. Янәсе! Менә шушы йөзегемне урлап, өстәл тартмасына яшергән! Шаһитләр, дисезме? Бар! Янәсе! Менә... *(Саматка.)* Әйт!

С а м а т к а *(теләмичә генә).* Мин...

М ә д ә н и я. Менә... иң якын күршем Сандугач! Янәсе!

Б а н у. Сандугач, син дә шуңа ышанасыңмы?

С а н д у г а ч. Үз күзләрем белән күргәч, ышандым! Мин — шаһит! *(Тавышлар: «Менә сиңа заман карчыклары!», «Ни җитмәгән инде аңа!», «Милициягә тапшырыгыз!»).*

М ә д ә н и я. Әйдә, карчык, атла! *(Килеп тота Саматка.)* Тот!

Б а н у. Туктагыз, балалар... *(Самат туктап кала.)* Мин үзем дә барам. Җыелган халыкка бер сүзем генә бар.

*(Тавышлар: «Тыңлап тормагыз!» «Әйтсен!»)*

М ә д ә н и я. Янәсе...

Б а н у. Туганнар, кордашлар, эне-сеңелләр! Тәнзилә исемле кыз юкмы арагызда? Мәрхүмә әнисенә — Шафикага охшаган зәңгәр күзле...

Т ә н з и л ә *(атылып чыга).* Мәрхүмә?! *(Кычкырып җибәрә.)* Әни!..

Б а н у. Кызым, Тәнзилә, синме бу?!

Т ә н з и л ә. Әнием кайда минем? Нигә дәшмисез? *(Тегеләр каушап калалар.)* Мәдәния апа?.. Самат абый?.. Сандугач апа?.. Минем әнием... үлдемени?

Б а н у. Әниеңнең туфрагы җиңел булсын, кызым Тәнзилә. Мин Бану апаң булам. Шафика мәрхүмәне соңгы юлга озатучы апаң.

С а н д у г а ч. Бу — явыз карчык, ышанма. Шафика яши иде әле — ул аны сихерләде!

М ә д ә н и я. Фатирыгызны басып алу нияте белән!.. *(Саматка.)* Печать бас! Янәсе!

С а м а т. Дөрес!

Б а н у. Син мине тыңла, Тәнзилә кызым. Болар өскә тагын яла якканчы, әниеңнең төсен — ядкарен тапшырыйм. Алкалары...

С а н д у г а ч. Сак бул. Тәнзилә!

М ә д ә н и я. Безне тыңла! Янәсе!..

*(Тәнзилә, нишләргә дә белмичә, ике арада бәрелеп-сугылып йөри.)*

Б а н у. Син мине тыңла. Тәнзилә балам. Мин әтиең Нәҗипнең адресын таптым. Менә... ал! Әтиеңне эзләп тап та шушы хатны укыт, аннан үз өегезгә кайтыгыз. Анда сезне васыять көтә. Мин өйдә булырмын.

*(Тәнзилә, кулындагы адреска карап, аптырап кала.)*

М ә д ә н и я. Нәрсә шуны тыңлап торасың...

С а н д у г а ч. Милиция үзе хәл итәр!

С а м а т. Без сине кулга алабыз, карчык!

Б а н у. Туктагыз, балалар... Бер сүз әйтәсем бар сезгә. Сандугач кызым, сез үзегез оныткансыз, минем һаман хәтеремдә, мин сезне бакчадан озатканда менә шундый җыр җырлаган идем:

Очыгыз, кошлар, очыгыз,
Агыйдел суын эчегез,
Үсеп җиткәч күрешербез,
Ә хәзергә хушыгыз...

Әле һаман да ышанмыйм... Әллә инде Бану апагызга иң авыр чакларда гына көйләгән җырын җырларга насыйп булдымы?

С а м а т. Атла, карчык!

М ә д ә н и я. Кызгандырмакчы... янәсе...

С а н д у г а ч. Синең кебекләрне күп күргән!

Б а н у. Мин инде өлкән кеше, әз генә туктап, шуны гына җырлап алыйм, балалар... *(Туктый.)*

Агыйделдә үскән лә анасы,
Кай күлләрдә икән баласы,
Газиз балаларын эзли-эзли,
Диваналар була анасы.

С а м а т. Кругом! Марш!

Б а н у *(Саматка карап, соңгы өмет белән).*

Бик авырта кулларым, дустым, җибәр, зинһар, җибәр,
Шүрәлене рәнҗетүдән нәрсә бар, сиңа ни бар?

С а м а т. Разговорчики!

Б а н у. И җегет, һич юк икәндер мәрхәмәт хиссең синең.

Әйтче, зинһар, мәрхәмәтсез! кем син? исемең кем синең? Тәнзилә, мин сине күтәрмен!..

*(Бануны алып чыкканда, Зөлфәт йөгереп керә.)*

Зөлфәт. Бану апа?! Сине кая алып баралар? Туктагыз, ул нишләгән? Җибәрегез аны!

Мәдәния. Өйгә кайт!

Самат. Ну-ка!..

Бану. Зөлфәт, балам, борчылма, мин кайтырмын, без синең белән әле уйнарбыз... Милициягә кереп чыгыйм инде, йомышларым да бар. Кит, Зөлфәт!

Зөлфәт. Милициягә?! Ни өчен?

Сандугач *(чыга-чыга).* Анаңның йөзеген урлаган өчен, баштан сыйпамаслар.

*(Бануны алып китәләр.)*

Зөлфәт. Йөзек?! Бану апа! Әни! Әти! Ул йөзекне мин салып куйдым! *(Артларыннан йөгерә.)*

Тәнзилә *(алкаларны кулында тоткан килеш).*

Кайттым.
«Бусы — алкалары,
Бусы — кабере».— диделәр.

7

**Авансцена.**

**Унитаз күтәреп, Самат уза.**

Мәдәния *(керә).* Са-мат!

Самат. Каян таныдың?

Мәдәния. Артыңнан.

Самат. Артымда — унитаз. Уф! *(Унитазны куя. Бала чагындагы бер шигырьне искә төшерергә тырышып)*

Бар иде мәдрәсәдә бер уни... таз...

Мәдәния. Янәсе... Нинди таз?

Самат. Юк ла... унитаз.

Мәдәния. Кемгә бу?

Самат. Теге бүлмәгә — үзебезгә!

Мәдәния. Ыштансыз билгә — каеш! Алырсың ул иблистән!

Самат. Чигенмә!

Мәдәния. Милициядә хур итте. Җир тишеге булса — кер дә кит!

Самат. Зөлфәт бозды. Эттән туган нәрсә! Ярдым үзен!

Мәдәния. Бозалар малайны! Башта — Шәфикалар, хәзер — карчык!

Самат. Бөтенләй безгә охшамаган... Әллә...

Мәдәния. Янәсе?

Самат. Әллә күршеләр эше инде?

Мәдәния. Бәләкәч кенә үз ирем була торып, үз хатынын да ташлаган күршедән бала табаммы соң? Янәсе...

Самат. Юк... шикләнмим анысы — сиңа кем карасын!

Мәдәния. Тач үзең, җебегән! Үземә охшаса, о! Өйрәтергә вакыт кына тими.

Самат. Тегеләр коткысы димәкчемен.

Мәдәния. Шулай булмый! Үзебез — көне-төне эштә! Күршеләрдә үсә бит! Инде — карчык котырта!

Самат. Бүген кич кунакка чакырган буламы? Хи-хи-хи! Бакча балалары диган буламы... Хи-хи-хи... Әллә керикме?

Мәдәния. Бүлмә безнеке булмыйча — бусагадан атламыйм.

Самат. Мин дә! *(Хыялланып.)* Их, шул бүлмәләргә кереп, шушы унитазларга утырып көннәр булырмы бер... Күрербезме шул рәхәтлекләрне?

Мәдәния. Унитазыңны бик күрсәтеп торма! Килеп чыкса...

Самат *(унитазга утыра).* Син дә утыр... Күренмәсен.

Мәдәния *(утыра).* Юк белән башыбызны ашамасын, башсыз нәрсә! Их, күрербезме икән шундый рәхәтлекләрне? Янәсе!

Сандугач *(керә).* Бик әре генә утырган буласыз, баедыгызмы әллә, күршеләр?

Мәдәния. Баербыз да шул!

Сандугач. Нәрсәгә утырдыгыз сез, күршеләр?

Мәдәния. Юк. Утырмадык...

Сандугач. Утыргансыз ич...

Самат. Төп башы ич...

Мәдәния. Төп башы икән...

Сандугач. Төп башына гына түгел, унитазга утырта әле ул сезне карчык... *(Көлә.)*

Мәдәния. Ә без авыз ачып карап торырбызмы?

Сандугач. Сез болай да ачык авызлар! Сезгә диган фатир — менә! *(Кукиш күрсәтә.)* Без уйлаганча, карчык фатирны басып алырга уйламый да! Тәнзилә белән Нәҗип өчен саклый! Ул аларны эзләп тапкан. Алсам, мин ала идем ул фатирны! Аңлагыз, мокытлар, эш фатирда гына түгел... Карчык сезгә дә, миңа да — бөтен барлыгы белән куркыныч кеше! Алар җирдә яшәгәндә — безгә рәхәт тормыш, тынгылык юк! Аңладыгызмы, мокыт иптәшләр?

Мәдәния. Анысы дөрес, күрше.

Самат. Мокыт тәк мокыт!

Мәдәния. Нишләргә соң?

Самат. Ничек котылырга аннан?

Сандугач. Шул сорауны көтәм. Уйлыйк!

Мәдәния. Өчебез өч яктан... Тотабыз да...

Самат. Бәргәләп чыгарабыз!

Сандугач. Консерваторлар! Искергән метод!

Мәдәния. Таптым!

Самат. Тапты...

Мәдәния. Чакырып, ялган телеграмма бирәбез.

Самат. И котылдык!

Сандугач. Селәгәйләр ысулы!

Самат. Дөрес!

Мәдәния. Үзең әйт, күрше!

Самат. Коткар!

Сандугач. Кайчаннан шул сүзне көтәм. Аның милициядә үзен ничек тотуын күрдегез. Алдында: «Бану апа, Бану апа!» — дип кенә йөриләр. Милиция дә: «Гап-гади чишмә суы!» — дип яклап калды. Ул активлаша башлады. Әлегә кинаяә белән генә сезнең дә, минем дә гөнаһлар барлыгын әйтте. Карчык ярты юлда кала торганнардан түгел... Операция безнең хурлыклы җиңелү белән тәмамланды. Аңардан котылу өчен бердәнбер юл бар!

Мәдәния. Күрсәт юл!

Сандугач. Үзебезгә — активлашырга! Ызгыш-талашларны онытып, вакытлыча гына булса да, безгә... берләшергә... Әйе, әйе... берләшергә кирәк!

Мәдәния. | Берләшергә?
Самат. |

Сандугач. Берләшергә! Авыр булса да!

Мәдәния. Ни өчен?

Сандугач. Ул безгә — таш белән, ә без — аш белән!

Мәдәния. Янәсе... Без — таш белән!

Самат. Юк, мин — юк!

Сандугач. Без — аш белән! Ашын ашаган, яшен яшәгән әбекәйгә ярдәм кулы сузарга кирәк...

Мәдәния. Янәсе... Ярдәм?

Самат. Кул? Юк, мин — юк!

Мәдәния. Кит аннан! Сине тыңлап торган без җүләр...

Самат. Мин — юк! *(Китәргә кузгалалар.)*

Сандугач. Күршеләр! Килегез әле якынрак!.. Үзегезнең файдага? *(Тегеләр теләмичә генә якынаялар)* Ул безне бүген кунакка чакырды... *(Колакларына нидер әйтә: тегеләр канәгать булып, хуп күреп, көләләр.)* Әйдәгез, хөрмәтле күршеләрем, карт кешене көттермик!...

*(Китә. Мәдәния белән Самат аңа ияреләр. Мәдәния унитазга ымлый, Самат кире кереп унитазны күтәреп китә.)*

8

**Шәфикә бүлмәсе. Бану өстәл әзерләп йөри.**

Бану *(көйләп)*.
Бүген бигрәк күңелемнең
Мөлдерәмә тулган көне...

Сандугач *(ишекне ачып)*. Бану апа, мөмкинме?

Бану. Кемнәр анда? Керегез!

*(Сандугач, аңа ияреп Мәдәния белән Самат керәләр.)*

Сандугач. Исәнмесез, җаным-бәгърем Бану апа!

Мәдәния *(кычкырып)*. Саумы, күрше?

Самат. Сәлам, карчыгым!

Бану. И, күршеләр икән, әйдәгез, аз гына иртәрәк килсәгез дә, рәхим итегез!

Сандугач. Сезне сагынуга түзәлмичә, йөгереп кердек, Бану апабыз!

Бану. Узыгыз, түрдән узыгыз, кунаклар!

Сандугач. Узарга да оялабыз кичәге хәл өчен. Бик җайсыз килеп чыкты. Кичерегез зинһар өчен...

Мәдәния. Зөлфәт бутады...

Самат. Эттән туган нәрсә!

Мәдәния. Бала-чага бит. Без — ышандык.

Самат. Мин аны! *(Каешына тотына.)*

Бану. Узган эшкә — салават! Утырыгыз, балалар, утырыгыз! Хәзер башка балаларым да килеп җитәр. Вәлит, Нәҗип, Сәүбан, Рөстәм, Санияләрне дә чакырдым. Сөенеп бетә алмыйм: шундый да саф күңелле кешеләр булып өлгергәннәр балакайлар... Самат белән Сандугач бире дә... Рәхәтләнеп сайрашырсыз әле бәләкәй чактагы дусларыгыз белән... Бер утыру — бер гомер ди.

Сандугач. Нигә башта ук әйтмисең аны, Бану апакаем. Белсәм — тагын да модныйрак, тагын да импортныйрак джинсымны киеп керер идем... Монысы ничегрәк? *(Кыланып йөри.)*

Мәдәния. Шторлары яңа икән.

Самат *(ачып карап)*. Унитаз искергән икән. Бану апа, син өйрәттеңме әллә мина такмак? «Бар иде мәдрәсәдә бер унитаз»...

Бану *(сөенеп)*. «Мәдрәсәдә бар иде бер таз малай» дип өйрәткән идем шул... Их, Самат, Самат, син бик тыңлаучан малай идең ул чакта. Бу керүеңдә аз гына шул Саматны хәтерләтеп куйдың. Бер эш кушам әле үзеңә. Син чүкеч тотарга әвәс идең. Шушы рәсемне стенага куеп бир әле, наным. Әле генә фотографиядән зурайттырып алып кайттым. Ачып карарга да курыктым. Бозсалар, аңа охшатмасалар, нишләрмен?.. Менә, әл, балам... *(Самат, нишләргә икән, дигән сорау белән тегеләргә карый, ризалык алгач, рәсемне ала, ача, стенага беркетә. Рәсемдә — ак күлмәк кигән, япь-яшь егет. Скрипка уйнала. Караңгылана. Прожектор нуры рәсемдәге Айвазны һәм Бануны яктырта. Бану, чын Айваз белән очрашкан кебек, онытылып, хыялга бирелеп, рәсемгә омтыла.)* Айваз! Бу — син... син! Нәкъ мин белгән, мин сөйгән унсигез яшьлек Айваз! Хәлил белән Галиябану кебек, бер-беребезне яратышкан, мәңге бергә гомер кичерергә вәгъдәләр биргән идек. Арабызга сугыш керде, сине дошманнар үтерделәр. Яуга киткән чакта әйткән сүзләрең ничә еллар инде йөрәгемне яндырып тора: «Исән кайтсам, бәхетле яшәрбез, бик күп балалар үстерербез, синең кебек мин дә балалар яратам, өй тулы балалар бакчасы булыр... Сугышлар узар, кешеләр бер-берсенә тагын да ныграк якынаерлар, бер-берсенең кадерен күбрәк белерләр»... Их, Айваз газизем, әйләнеп кайтмадың... Юк, юк, мин синнән башка беркемне дә сөймәдем, кияүгә дә чыкмадым... Сиңа гына дип саклаган яшьлек чәчәкләрем коелдылар. Балалар да юк, оныклар да... Сугыш минем тамырларымны кисте... Кайгырма, Айвазым, мин бәхетсез түгел шушы килеш тә, башкаларныкы булса да, балаларым — күп. Бәхетем дә, бәхетсезлегем дә — шуларда. Исәндәме, сиңа җитмеш яшь тулган көнне, балаларыбызны, оныкларыбызны алып, үзең яшәгән шушы бүлмәдә очрашырга сүз куештык. Мин килдем, Айваз! Син дә кайттың. Хәзер балаларыбыз җыела. Туган көнең котлы булсын, Айвазым! *(Чәчәк бәйләме куя. Рәсемгә кагылып.)* Күзләреңдә әз генә үпкәләү сизелә сыман: әйе, синең шушы бүлмәдә яшәвеңне, кайчандыр җирдә яшәвеңне бире дә беркем дә белми, онытканнар,— күп еллар узган шул... Балалык сафлыгын саклаган җаның нинди пакь, юмарт иде! Бөтен йорт, күршетирә — бер гаилә кебек тату, ихлас иде сез

исән чакта. Кадерле, изге миңа бу бүлмә! Без монда бер-беребезне таптык. Синең үлгән көнең юк, туган көнең генә бар! Күңелемдә гомерем буйларына бер җыр йөрттем. Ул җыр синең белән очрашкач, бөтенләй тулышып, ташып чыкты... Бүген... минем моңлы бәйрәмемдә... Сөйгәнемнең туган көнендә...

Сандугач *(караңгыда)*. Сиздегезме?

Мәдәния. Сизелмәслекмени...

Самат. Кызык! Һәмит!

Сандугач. Нәкъ вакыты! Әйдәгез!

Мәдәния. Тәвәккәлләдек!

Сандугач. Юлыбыз уң булсын!

*(Сандугач артыннан чыгалар.)*

Бану җыры. Калды ерак
Күзләремне
Шатлык моңы юган
көне...
Җырлата да,
Елата да
Сөйгәнемнең туган
көне.

*(Зөлфәт керет, тыңлап тора да, түзәлмичә, стенадан скрипканы ала, уйнап кушыла.)*

Бүген бигрәк
Күңелемнең
Мөлдерәмә тулган көне,
Зинһар авыр
Кагылмагыз,—
Сөйгәнемнең туган
көне.
Юк һәм булмас
Минем өчен
Мәхәббәтнең сулган
көне,
Яу кырында
Ятып калган
Сөйгәнемнең туган
көне...

*(Яктыра.)*

Бану. Зөлфәт? Син... Кем уйный дисәм... Ничек өйрәндең?

Зөлфәт. Стена аша. Сездән ишеттем.

Бану. Рәхмәт, балам. *(Кочаклый.)*

Зөлфәт. Айваз абый исән булса, ул безне аңлар иде.

Бану. Әйе, аңлар иде... Ул аңлый, Зөлфәт, әнә бит... Канәгать...

Зөлфәт. Бану апа, нигә алар алай итәләр?

Бану. Кемнәр? Нишлиләр?

Зөлфәт. Шундый чакта... чыгып китәләр?..

Бану *(реаль дөньяга кайтып)*. Ә-ә-ә... Мин гаепле. Кунакларны онытып, истәлекләргә бирелгәнмен. Кайчак шулай хыялланып, ычкынып китәм инде мин.

Зөлфәт. Шәфика апа үлгәч, мин дә шулай булдым. Бану апа, нигә алар шулай итәләр?.. Теге вакытта да... Йөзек...

Бану. Күңелең йөзек кашы кебек чиста, балам. Гомерең буе тап төшермә. Мин киткәч тә

Зөлфәт. Син китәсеңмени, Бану апа?

Бану. Менә-менә Тәнзилә апаң белән Нәҗип абыең кайтыр. Аларны кавыштырам да китәм.

Зөлфәт. Алар да кайтсын, син дә кал! Скрипкада кем уйнар? *(Скрипкасын суза.)*

Бану. Син уйнарсың, Зөлфәт. *(Скрипканы ала да Зөлфәткә кире бирә.)* Мин аны сиңа бүләк итәм.

Зөлфәт. Миңа? Ул — Шәфика апаныкы.

Бану. Шәфика апаң аны миңа васыять итте. Ә мин — сиңа. Ал, балам!

Зөлфәт. Миңа?! Скрипка! Рәхмәт, Бану апа!

Бану. Йөрәгеңнән чыккан саф моңнарны Шәфика апаңның, Бану апаңның ядкаре итеп сакла.

Зөлфәт. Киткәч, сине каян эзләргә, Бану апа?

Бану. Бик сагынсаң, айга кара,
Айда очрашыр күзебез!

Зөлфәт. Бану апа, үзең белән мине дә алып кит!

Бану. Син кал, бала. Әти-әниеңне ташлау — егетлек түгел. Әмма, алар каршы килә дип, күңелеңдәге балачак моңын югалтма. Ямьсезләнмичә генә аңлатырга тырыш әти-әниләреңә.

Зөлфәт. Аңламасалар?

Бану. Кирәк чакта Шүрәле булып кытыкла, кирәк чакта Былтыр егет бул!

Зөлфәт. Әйдә, син киткәнче, тагын бер уйныйбыз! *(Скрипканы өстәлгә куя.)*

Бану. Нинди уен?

Зөлфәт. Сукыр тәкә.

Бану. Әйдә!

Зөлфәт. Мин синең күзләреңне бәйлим.

Бану. Бәйлә! *(Яулыгын салып бирә.)*

Зөлфәт. Күренмиме?

Бану. Борчылма, Зөлфәт, минем күзләрем болай да караңгылана баралар. Кач!

Зөлфәт. Эзлә, Бану апа! *(Кача.)* Мин монда! Кәк-күк! *(Шифоньер эченә кереп китә.)*

Бану *(куллары белән капшаланып, Зөлфәтне эзли)*. Зөлфәт, кайда син? Мин сине эзлим... *(Кинәт туктап кала, хыялга бирелә.)* Мин сезне эзлим, балакайлар, аваз бирегез! Айваз, хәзер син дә миңа бала бит. Әллә кайларга китеп югалдың. Барыгызны да бергә җыясым, үзем исән чагында, әлегә күзләрем аз-маз чамалаган чагында, күрәсем, хәлләрегезне беләсем килә. Сез кайда, җавап бирегез...

Зөлфәт. Кәк-күк! Кәк-күк!

Бану. Үскәч, Бану апагыздан барыгыз да качтыгыз качуын, барыбер эзләп табармын, шаяннарым! *(Шифоньер янына килә.)* Зөлфәт улым, син дә миннән качарсыңмы, син дә балачагыңны югалтырсыңмы? *(Эзли.)*

Зөлфәт. Кәк-күк!

Бану. Зөлфәт, кайда син? Әллә мин үзем дә балачагымны югалттыммы соң? Юкса, балаларым мине ташлап качмаслар иде. *(Җырлый.)*

Агыйделнең аръягында
Калды балачакларым

Калыр идем, китмәс идем,
Белсәм калачакларын.

Зөлфәт. Мин монда!

Бану. Юк, балакайларым, мин Бану апагыздан качкан өчен бер дә рәнҗемим, балачактан качмагайлары дип кенә борчылам. *(Эзли. Мәдәния, Самат һәм Сандугач ак халатлы, озын буйлы, гайрәтле ике кешене ияртеп керәләр.)*

Сандугач. Менә! Үзегез карагыз!

Мәдәния. Ышанмый хәлегез юк!

Самат. Тс-с-с!

*(Бану, Зөлфәтне тотам дип, Мәдәнияне килеп кочаклый.)*

Мәдәния. Әбәү! Коткарыгыз! Самат!

Бану. Барыбер тотам! *(Ак халатлы кешене тота.)*

Мәдәния. Элэктерегез!

Сандугач. Шашкан чагы!

Самат. Үзен тотыгыз!

*(Бануны ике яктан элэктереп алалар.)*

Бану *(яулыгын чишеп)*. Ярабби, ни бу?

*(Ак халатлы кешеләрнең берсе өстәл янына утыра. Кәгазь, каләм ала.)*

Мәдәния. Ычкына! *(Бануның икенче ягыннан тота.)*

Ак халатлы кеше. Бану?

Мәдәния. Бану, Бану!

Бану. Бану апа!

Зөлфәт *(шифоньердан чыгып)*. Бану апа! *(Барысы да борылып карыйлар.)* Нигә эзләмисең? *(Аптырап кала.)* Бану апа, сине нишләтәләр? Җибәрегез аны!

Мәдәния. Ычкын!

Бану. Зөлфәт, балам, кер өеңә. Борчылма.

Зөлфәт. Тимәгез аңа!

Самат *(каешына тотына)*. Ну-ка! *(Зөлфәт чыга.)*

Бану. Балалар, тотмагыз, вакытым тыгыз. Кунаклар каршылыйсым бар.

Мәдәния. Китми тор, әбекәй...

Ак халатлы. Сез бу әбинең күршеләреме?

Мәдәния. Алла сакласын, каберең якын булмасын!

Сандугач. Оҗмахта да шундый күршең булмасын... Фу!

Самат. Ул безгә ни брат, ни сват...

Мәдәния. Урамнан килеп кергән карчык. Башта без аны өй талап йөрүче дип уйладык.

Сандугач. Аферистка дип.

Мәдәния. Домоуправлениегә жалу яздык.

Самат. Игътибар итмәделәр. И дөрес булган!

Сандугач. Милициягә илтеп бирдек...

Самат. Алмадылар! И дөрес!

Сандугач. Хәзер генә барып җитте: кызганабыз да инде үзен...

Мәдәния. Мескен!

Самат. Теге йортка... ягъни сезгә мохтаҗ әби булып чыкты.

Ак халатлы. Бу шәһәрдә кемең бар, әби?

Бану. Килгәндә беркемем дә юк иде...

Ак халатлы. Хәзер?

Бану. Туганнарым да, дусларым да бар.

Мәдәния. Янәсе... Юк, юк, беркеме дә юк!

Ак халатлы. Кемнәр ул туганнарың?

Бану. Шәфика мәрхүмә... Тәнзилә... Зөлфәт...

Самат. Мәхлук... безнең малайны әйтә...

Мәдәния. Күрәсез ич... Сорап та тормагыз...

Ак халатлы. Бу шәһәргә каян килдең син, әби?

Бану. Балачактан.

Сандугач. Балачактан картлыгына килгәндә... ниткән... адашкан...

Самат. Саташкан.

Мәдәния. Бала акылына кире кайткан.

Сандугач *(пышылдап)*. Сез аны бик җәфаламагыз инде... безнең интектергән дә җиткән... Тәмам ниткән бит, бичаракай.

Ак халатлы. Бу әбинең башкалардан аерылып торган тагын нинди сәер билгеләрен әйтә аласыз?

Мәдәния. Безгә күрше, туганым, дип дәшә...

Самат. «Балам» дип тә җибәрә.

Сандугач. Мин аңа җиде ят бит инде: мине котлап, чәчәк бәйләме керткән...

Мәдәния. Урамдагы бер тапкыр да күрмәгән узган-барган белән бер чакрымнан исәнләшә.

Самат. Гомергә бер күрмәгән карчыкларны, ахирәтләрем дип, чәйгә җыйган. Тегеләрдән ни индийский чәй, ни запчас сорамаган.

Сандугач. Сөйгәненең туган көнен үткәрергә җыена...

Мәдәния. Үзенең бер бөртек баласы да юк, «балаларны күрергә килдем» дип саташа, бахыр...

Самат. Безнең балага да «балам» ди...

Мәдәния. Бер көнне скрипка күтәреп балалар бакчасына барган.

Самат. Тили-тили, тили-тили...

Сандугач. Бөтен бакча баласы артыннан йөри...

Мәдәния. Бала-чага тиле-милене кызык итә бит... «Бану апа, Бану апа, скрипка!»

Ак халатлы *(сикереп тора)*. Скрипка? Бану апа?.. Тәрбияче Бану апа, сезме бу? Сугыштан соңгы елларда соңгы телемен балаларга ашаткан Бану апа? Сезме бу? *(Бану башын селки.)* Минем абыемны су астыннан алып чыккан Бану апа, сезме бу? *(Бану апа елмаеп, башын селки, күзләрендә — яшь.)* Бердәнбер пальтосын ялангач балаларга кидергән Бану апа?!

Бану. Рәхмәт, балам...

Ак халатлы. Мин сез эшләгән бакчага соңрак килдем. Сезнең хакта легендалар сөйлиләр иде.

Бану. Улым, мин ашыгам... Хәзер балаларым килә...

Сандугач. Сез... нәрсә, аны шундый хәлдә ташлап китәргә уйлыйсызмы?

Мәдәния. Харап итә... Үзен дә, безне дә!

Самат. Алмасагыз — жалу!

Ак халатлы. Әйе... Картлык. Сезне... алып китәргә туры килә, әбекәй. Машинага!

Бану. Балаларыма әйтегез, мин озакламый әйләнеп кайтырмын.

Мәдәния. Янәсе...

Сандугач. Көтәрбез, әбекәчкәем!

Мәдәния. Борчылма, кайтырсың!

Самат *(уйланып)*. Кайтырсың...

Сандугач. Котылдык!

Мәдәния. Аллага шөкер!

Самат. Кайтыр микән?... Ай-яй-яй...

Мәдәния. Нәрсә, әллә кызганасыңмы?

Самат. Чыннан да дивана түгелме соң ул?...

Сандугач. Нинди аерма, дивана ни, түгел ни...

Мәдәния. Янәсе... Барыбер!

Сандугач *(тәрәзәгә карап)*. Карагыз! Машина артыннан кем йөгерә?

Мәдәния. Зөлфәт! Эт сөйрәгере малай!...

Самат *(тәрәзәгә карап)*. Искә төште Бану апа артыннан шулай йөгергәнем...

Сандугач. Борчылма!...

Мәдәния *(Саматка)*. Йөгерер-йөгерер дә синең кебек калыр әле...

Самат *(уйланып)*. Әйе... Минем кебек...

Сандугач. Карагыз, кемнәр килә?

Самат. Вәлит... Сәүбан... Рөстәм...

Сандугач. Бер бакча балалары...

Мәдәния. Һе-һе-һе, Бану балалары... Янәсе!...

Самат. Мин киттем...

Мәдәния. Кая?

Самат. Әллә ничек... *(Читкә китеп баса.)*

Сандугач. Бу заманда оялып торсаң... Оялдым ди! Әй, дуслар, бакчадашлар, без монда!

*(Кулына чәчәк бәйләме тотып, Вәлит керә.)*

Вәлит. О, бакчадашлар, исәнмесез!

Сандугач. Исәнмесез, Вәлит Рәхимович!

Мәдәния. Хуш киләсез!

Самат *(әкрен генә, читтән)*. Узыгыз...

Вәлит. Кадерле юбилярыбыз хөрмәтле Бану апаның җитмеш яше тулу көнен котларга килдегезмени, балачак дуслар? *(Тегеләр дәшми.)* Юбиляр үзе кайда соң? *(Тынлык.)* Нигә дәшмисез? Әллә?...

Сандугач. Вәлит Рәхимович, кичкенә уңайсызлык: Бану апаны әле генә алып киттеләр...

Вәлит. Кая? Кая алып киттеләр? *(Тынлык.)*

Мәдәния. Кая булсын — теге йортка!

Сандугач. Тәмам ниткән... мескен... ычкынган... Әйбәтләп кенә озаттык... Нишлисең бит...

Мәдәния. Тиле артыннан тилереп булмый... Бик кызгандык... Еладык аерылышканда...

Сандугач. Сабый акылына кайткан... Адашкан...

Вәлит. Сез... сез!... Аны алып киткәнне тыныч кына карап тордыгызмы? *(Җавап юк.)* Әллә үзегез фатиха бирдегезме? *(Җавап юк.)* Әллә үзегез шалтыраттыгызмы? *(Дәшмиләр.)* Мин, Бану апаны соңгы көннәрдә тикшергән, дәвалаган доктор буларак, әйтәм: Бану апа — абсолютно нормаль кеше! Дөрес, сәер тотышына карап, башта миндә дә бераз икеләнү булды. Акыл һәм күңел сафлыгы белән ул барыбыздан да аерылып тора, гайре табигый сыман күренә. Кем ычкынган? Бану апаның бер баласы — мин сездән сорыйм: кем адашкан?...

Тәнзилә *(керә. Стенадагы Шәфика рәсеменә карап)*. Әни! Соңга калып булса да акылга килгән адашкан кызыңны гафу ит! Бану апа!... Кайда ул? Әнием урынына калган Бану апа кайда? Хәзер эти дә кайтып җитә. Бану апа... Ул... кая китте?

Вәлит. Дуслар! Бану апабыз — авыр хәлдә! Әйдәгез минем арттан! *(Вәлит ашыгып китә. Тынлык. Самат, икеләнеп тора да, башын иеп, кыюсыз гына Вәлит артыннан китә. Скрипкада — үзәк өзгеч моң.)*

Пәрдә

## Ямаш Игәнәй

# ТАРИХНЫҢ НӘНИ ЯРЧЫГЫ

Утка салган инквизитор аны
Юк итәргә теләде микән?
Ә ул янган — мәңгелеккә балкып...
Һәм утында
Палачларның үзен көл иткән.
Инквизиторның эзе дә юк,
Исемен дә тарих җилгәргән.
Бруно яна якты учак булып...
Тамырларын
Гасырларга җәеп җибәргән!..
Тарих битләренә генә түгел,
Җаннарга да уелып ул калган.
Кешелекнең Бөек Януына
Символ булып яна ул һаман!
...Ә мәйданда — инквизиция
Үз-үзенә хөкем чыгарган...

Җирдә бар да үз урынында:
Гомер — аны кичәр өчен,
Юл — максатка җитәр өчен,
Яр — юлыңда очрар өчен,
Биеклекләр — менәр өчен,
Упкын — юлың бүләр өчен,
Авырлыклар — җиңәр өчен,
Болын — чәчәк үсәр өчен,
Чәчәк — бүләк итәр өчен,
Офык — җанга сыяр өчен,
Шатлык — тәмен тояр өчен,
Дошман — чалып егар өчен,
Дус — шулчак кул сузар өчен...
Язмыш — сине сынар өчен,
Рух — барына чыдар өчен,
Бәхетеңә чыгар өчен...

Бакчамда түтәл ясадым...
Әллә кемнәр килде:
Кемдер анда Гөл утыртты,
Кемдер Серен күмде.
Кемдер анда Таш ыргытты,
Кем тик таптап үтте.
Кем Мәкерен чәчте, кемдер
Күз яшьләрен түкте.
Кемдер чәчте Нәфрәт, Каргыш,
Тагын әллә ниләр...
Барысы да тишелсә... Дөнья
Миңа нәрсә дияр?..

---

ЯМАШ ИГӘНӘЙ (1938) — шагыйрь, «Сәфәр чыгам» һ. б. шигырь китаплары авторы. Брежнев шәһәрендә яши.

Җыр ургыла ишек, тәрәзләрдән,
Нәни кыйтга — авыл ызбасы.
Керәшен туе бүген бу кыйтгада —
Борынгы җыр, болгар йоласы:

«Тәрәзә төбендә әй, тутый кош,
Ак мамыклар белән тотыгыз.
Безнең бәбкәебез сезгә килә,
Какмый гына, сукмый тотыгыз».

Кода-кодаларның җор телләре
Чакма белән гүя чакматаш.
Җыр бәрелеп җырга очкын чәчри,
Тапкырлык һәм акыл башма-баш.

«Урманнарга кердем атым бәйләп,
Кисепкәйләр алдым киртәлек.
Хезмәтләрен килен аямаса —
Шунда булыр аңа иркәлек...»

Ничек бөреләнгән яңа дәвам —
Үткәннәргә, яле, күз салыйк:
Асылташта кояш чагылгандай
Һәр йолага сыйган бер тарих.

Болгар учагыннан бүгенгегә
Төшкән чаткы-чорлар аркылы...
Авыл ызбасында керәшен туе —
Чал тарихның нәни ярчыгы.

Шул ярчыкта күпме ышанычы,
Һәм өмете балкый ил-көннең.
Йөрәкләргә төреп, киләчәккә
Илтиекче аны, и энем!..

●

Мылтык тавышыннан, ахры,
Сискәнде офык чите...
Кайгымы, шоммы, төтенме
Томалап алды күкне.
Юеш Кояш ярчыклары
Җиргә коелып төште...

## Тәкъдир

Кемдер яшереп күмеп калдырган —
Хәзинә саклый төбендә Имән.
Тик белә микән, тамырларына
Әҗәлен кочкан... хәзинә белән...

●

Үрмәкүч ятьмә үрә,
Нәрсә эләктерергә? —
Күпме җан һәлак булган
Эләгеп пәрәвезгә? —

Ул чаклысын кем белә?..
Күңелемә шом иңә,
Үрмәкүч ятьмә үрә,
Инде тәмамлап килә...

**Заһир Садыйков**

# ТАВЫК БОТЫ

**САТИРИК ХИКӘЯ**



Альберт Робертович Хәбибуллин үзенә күк капусы ачылмауга тәмам аптырады. Башкалар чуртан тизлеге белән менә дигән карьера ясаганда, ул унөч ел инде һаман йөз утыз тәңкәгә тир түгә. Аны түргә дә дәшмиләр, күрмиләр дә. Шушы унөч ел эчендә өч бүлек мөдире алышынды. Беренчесен үстерделәр, икенчесен төшерделәр, өченчесен әллә кайдан, бөтенләй читтән җил ташлады. Пединститут кына бетергән үзе дип пышылдашты бүлектәге сазаган кызлар. Ә Альберт Робертовичларның институты бәрәңгене сабакта үстерү буенча бик зур фәннипрактик эш алып бара иде. Киләчәктә бәрәңгене алма кебек сабактан гына өзеп алыр өчен институт әһелләре өч докторлык, егерме кандидатлык диссертациясе яклады.

Унганнары, Альберт Робертович кебекләре, күзлек алыштыра-алыштыра, сыза-боза каләм туздыра, гомер уздыралар, ләкин бер дә сабакка менәсе килми бәрәңгенең. Ялгап та карадылар, асып та — әле сабагы сыгыла, әле төптән үк егыла.

Баштарак Альберт Робертович, миңа да даһи уйлар килми калмас әле, барыбер академик булырмын дип хыялланып йөрде. Ләкин андый уй кермәде дә кермәде. Башы яхшы эшләсен өчен, кофе эчеп, шикәр суырып карады. Әмма бары йокысы гына качты. Шуннан соң ул бөек ачышлар тарихын өйрәнергә кереште һәм шундый кызык бер нәрсәгә тап булды: Ньютонга гравитация законы турындагы фикер башына алма өзелеп төшкәч килгән икән ләбаса. Альберт Робертович шул көнне үк хатынын култыклап бакчасына китте. Җиргә җәймә җәйде дә алмагач астына кереп утырды.

Җилләр исте, яфраклар селкенде, ләкин алма коелмады. Йомырка баса торган каздай, ике сәгать, өч сәгать утырды. Буыннары оеды, тәненең бала йоннары кабарды, әмма алма өзелмәде. Инде торам дигәндә генә янына кортлы бер хәчтрүш кипкән алма өзелеп төште төшүен, әмма башына тимәгән алма фикер китермәде. Ул хатынын чакырды.

Әйтергә кирәк, Лиана ханым иреңең даһи академик булуын бик тели иде. Альберт Робертович йокысыз яткан төннәрдә ул үзен колагына якут алкалар таккан, чәч бөдрәләтергә дә ак «Волга»да гына сызгыртып барып кайта торган мөхтәрәм академик хатыны итеп төшләр күрә иде. Иренең йокысыз төннәре арткан саен, бәхетле таң якыная сыман тоелды аңа. Тора-бара алар берсен-берсе каш сикертүдән үк аңлый башладылар.

Менә әле дә ипле Лиана ханым ирен ярты ымнан аңлап алды. Кытай халатының җиңнәрен сызганды да алмагачны селкетә башлады. Альберт Робертовичның башына шыбыр-шыбыр алма коелды. Алтын фикер генә юк та юк. Агачта бердәнбер алма калды. Лиана ханымның күзләренә яшь саркыды. Юк фикер өчен күпме нигъмәт коелды җиргә! Берәр ай сабыр итсәләр, согын сыгарга булса да ярар иде мондый яшел алма, ә болай елыйсы килгәндә генә ашарлык ич. Лиана ханым соңгы яшел алманы өзеп алды да, әллә ачудан, әллә изге

---

ЗАҺИР САДЫЙКОВ (1951) — завод шифаханәсенең баш врачы. Вакытлы матбугатта хикәяләр, «Идел» альманахында «Ялгышсыз язмыш» повестен бастырды. «Казан утлары»нда беренче тапкыр чыгыш ясый.

теләктән Альберт Робертовичның баш түбәсенә тондырды. Ире чайкалып үк китте. Ичмасам ник бер фикер түгелсен шул чайкалган вакытта!

Альберт Робертович шуннан соң тәҗрибәне бәрәңге белән үзе генә дәвам итәргә карар кылды. Иң авыр бәрәңгене сайлап алды да, аны җепкә бәйләп, алма ботагына асты, үзе ботак астына кереп утырды. Җепне сул кулы белән тартып, бәрәңгене күтәрде дә кинәт ычкындырып җибәрде. Бәрәңге «шап» итеп аның башына килеп төште. Күзләреннән очкыннар чәчрәде. Фикер генә пәйда булмады. Тагын бер, тагын бер кабатлады. Башы күбеп чыкты. Хатыны туктатмаса, икесенең берсе: я баш, я бәрәңге изелгән булыр иде мөгаен. Алар тәҗрибәне киләсе елда өлгерәчәк алма белән дәвам итәргә килешеп, ай калыккач кына кайтып киттеләр.

Хәрәкәттә бәрәкәт, ди халык. Атасы Роберт та хәрәкәт, дип тәкрарларга ярата иде. Теләсә нинди хәрәкәттә дә булмый ул бәрәкәт. Агым уңаена йөзгәндә генә иңә. Алтын фикер әйтеп үсә алмаячагын аңлагач, Альберт Робертович бөтәнчә уңуны кайгыртып баш ватарга тотынды. Туган-тумачага, таныш-белешкә таянып үсүчеләргә гаҗәпләнми иде ул. Шулай тиеш сыман кабул итә иде. Ә менә бернинди агай-энесез, дус-ишсез кинәт кенә үсеп киткән кешеләргә карап телен шартлата иде. Шуның тылсымын кайдан чамаларга? Бөтен дөнья үсеш үзгәрештә, ул гына бозга каткан шыртлака кебек, иркен сулыш ала алмый интегә.

Бөек ачышлар турында хыялланган кеше төрле имеш-мимешләргә ышанучан була икән. Альберт Робертович унөч санын үзе өчен изге фал тапты. Әйе, аның язмышындагы тарихи борылыш нәкъ менә быел булачак. Ни өчен быел? Чөнки аның бәрәңге институтында эшли башлавына быел унөч ел, үзенә өч тапкыр унөч, ягъни утыз тугыз яшь тула. Торган йорты егерме алтынчы йорт, ягъни, ике тапкыр унөч. Квартиры алтмыш җиденче. Димәк, алты белән җиденe кушсаң, тагын унөч килеп чыга. Олы кызы унынчыда, уртанчысы өченчедә укый, ә кечесе әле укымый. Тагын сумма унөч дигән сүз. Яшәүләре генә тугызынчы катта. Хәер, дөнья гел син дигәнчә генә булмый инде ул.

Альберт Робертович юкка гына өметләнмәде — быел югарыдан күрсәтмә килеп, аларның институтына колорадо коңгызы белән көрәшүне йөкләделәр. Институтның исемен үк үзгәрттеләр. Рәхмәт югарыдагыларга! Бәрәңге илен коңгыз кавеме басып алганда, чыннан да, ничек итеп микроскоп астында күбәләк аягы белән чәчәк серкәләндереп утырмак кирәк? Альберт Робертович эшли торган «бәрәңге чәчәге анатомиясе» бүлеген «колорадо коңгызы физиологиясе»нә алыштырдылар. Яңа директор булып Колорадоның коңгызын гына түгел, үгезен дә җиңәрлек дәү гәүдәле Галихан Сәмерханович Кәбиров килде. Элеккеге директорны Алабута институтына күчерделәр. Пешерделәр, пешерделәр үзен, ә барыбер күчерделәр. Шундый бит хәзер замана: пешерсәләр төшермиләр, төшерсәләр пешермиләр. Иске директор үзе белән педагог мөдирне дә алып китте. Шулай итеп, Альберт Робертович алдында киң мөмкинлекләр ачылды сыман. Өшкертсәң дә, язмыш кояшы болай борылмас сиңа. Бәхет чәчәген үрелеп, сузылып түгел, тешләп кенә өзә торган лабаса. Тик менә агымга гына эләгергә кирәк. Аңлады хәзер Альберт Робертович агымның нәрсә икәнен. Түрәнең күз уңында булу икән ул. Ул үссә, син дә үсәсең. Ул батса, син дә... Юк, үзе батса да, сине калкытырга көче җитә әле аның. Киләчәктә я үзенә, я баласына ярап куюың бар.

Уйлап карасаң, мөдир өчен койган да куйган кеше инде Альберт Робертович. Маңгае киткән мөдирнекеннән чама белән биш сантиметрга киңрәк. Шуңа да карамастан, урләү чарасын табалмыйча иза чикте Альберт Робертович. Лиана ханым аңа юк эшне бар итеп, турыдан-туры яңа директорның үзенә юлыгырга киңәш итте. Кайчан очраса да, үрә катып исәнләшергә, түрәне күрү белән, кош тоткан сыман, шатланып елмаерга кушты.

Йөз ирнең туксан тугызы хатын сүзеннән чыкмый хәзер. Альберт Робертович та... директорны күргән саен стенага сыланып исәнләште, җитмәсә башын мөмкин кадәр түбәнрәк иярgә тырышты. Аннары төннәр буе шул бәхетле мизгелләрне кабат күңеленнән кичереп ята торган булып китте. Берничә көн, исәнләшү өчен җай эзләп, гомер тартмаган тәмәкесен тотып, гел коридорда директорны сагалады. Өч очраса өч, биш очраса биш тапкыр исәнләште. Ә директор, үч иткәндәй, гел каядыр ашыга. Альберт Робертович янынnан «выжт» итеп кенә үтеп китә иде. Институтны яңа эзгә салу җиңел эш түгел шул. Мәшәкате күптер дип, гелән аклый иде ул директорны.

Институт ун көн инде пыр тузып коңгыз өйрәнә, тик ул бөҗәкнең үзен генә күргәннәре юк иде әле. Галихан Сәмерханович монда озак тукталып тормаячак, трамплин өчен генә килгән, коңгызны җиңү белән, аны каядыр югарыга үрләтәчәкләр, хатыны ниндидер бер зур кешенең кызы имеш дигән сүз да

ишетелде. Альберт Робертович бу хәбәрне дә хәтеренә төйнәп куйды. Казанырга кирәк аның игътибарын, чукынсаң да казанырга, дип уйлады ул кабат-кабат. Шуңа күрә, алны-ялны онытып, коңгызны өйрәнә башлады...

Бер генә кош та чүпләми икән үзен. Әмма аны юк итү чарасы табылырга тиеш. Бәлки әле нәкъ менә аның бәхетенә алыштырганнардыр тикшеренүләр темасын. Чөнки ул заманында авиация институтын тәмамлаган кеше. Коңгыз да оча ич. Менә кайда, ниһаять, аның махсус белеме кирәк булачак! Менә кайчан ул үзенең тирән вә киң мәгълүматын күрсәтәчәк, очу теориясен ачып салачак!.. Кем белә, бәлки табигать тә коңгызны аның бәхетенә генә яраткандыр әле!

Альберт Робертович хатынына күз салганда төнге сәгать ике иде инде. Лиана ханым тыныч кына йоклый. Кызлары булмәсеннән дә тигез сулыш ишетелә. Рәхәт хатын-кызга! Ә ир кеше төнлә дә баш кашырга мәҗбүр. Юк, гадел түгел бу тормыш. Кемдер йокысызлыктан җәфа чиксен, кемдер борын сызгыртып татлы төшләр күреп кәефләнсен. Галихан Сәмерханович та рәхәтләнеп йоклый торгандыр. Хәер, ул җиңү кәгазенә кул гына куясы кеше. Төп көрәшне бүлек мөдирләре алып барачак бит... Тукта! Әгәр коңгызга каршы медицина чараларын кулланса? Кешеләрнең гомерен кисүче сәбәпләр арасында беренче урында — йөрәк авырулары, икенче урында — рак, өченче урында эчүчелек тора, дип укыганы бар Альберт Робертовичның. Коңгызларга да йөрәк, рак авырулары йоктырсаң, я булмаса эчләрен җибәрә торган нәрсә ашатсаң? Юк, бу ярым-йорты чара гына булачак. Ә менә өченчесе бик тә кулай. Коңгызларны эчүчелеккә сабыштырсаң, гаиләләрендә ызгыш-талаш китәчәк. Бәрәңге корытасы урында алар барысы да алкоголь тәпәне янына җыелачаклар. Шул вакыт коңгыз көтүен себерәсең дә аласың. Эчүчелек аркасында балалары да зәгыйфь туачак, олылары исерек баштан үзара сугыша башлаячак, күзләре тонып бәрәңге урынына алабутага ташланачаклар. Кышкы салкыннарда ире хатынын яки хатыны ирен өннәреннән куып чыгарачак. Күпмесе исерек килеш көрт астында катып үләчәк. Ә күпмесе ачтан... Иртәгә үк кереп әйтәчәк үз ысулын Альберт Робертович. Бәхетенә, иртәгә яңа директор Галихан Сәмерханович килгәнгә нәкъ унөченче көн. Тагын изге фал ич бу!

Альберт Робертович шатлыгыннан хатынының күпереп торган битенә иренен тидереп алды да татлы йокыга китте. Соңгы елларда аның әле бер тапкыр да болай рәхәт йоклаганы юк иде.

Иртән сикереп торып, яңа тормыш башларга әзерләнеп, Альберт Робертович күнегүләр ясады. Лиана ханым иренең шат йөзеннән бөек фикернең кичә — унөченче төндә туганлыгын шәйләп алды. Ирен мөмкин кадәр назларга тырышты. Кызларын да әтиләренә игътибарлы булырга кисәтеп куйды. Альберт Робертович, бүген эшенә иртәрәк барып, әллә кемнәр кәефен җибәргәнче, Галихан Сәмерхановичка үзенең гаҗәп нәтиҗәле ысулын түкми-чәчми сөйләп бирергә булды. Укымышлылыгын күрсәтү өчен, коңгызның корсагын «фюзеляж» дип атарга уйлады. Сыек көрән төстәге румын күлмәген, аксыл поляк костюмын киде, куе көрән төстәге чех галстугын такты, түрәсе алдында үзен озын итеп күрсәтү өчен, елга бер генә тапкыр — туйларга гына кия торган, әле кибет исе дә китеп бетмәгән биек үкчәле киң башлы венгр туфлиен киде. Менә дигән европейский кеше булып китте Альберт Робертович. Лиана ханым белән кызлары эти кешегә кыюлык һәм уңыш теләп озатып калдылар. «Җебеп торма, анысы-монысы кирәк булса, әйтегез генә диген. Аш алдында баш иелә ул», — дип кычкырды артыннан хатыны.

Альберт Робертович трамвайда, үзенең ничек директор бүлмәсенә килеп керәчәген, ничек күрешәчәген, сүзне ничек башлап, ничек бетерәчәген — бөтенесен йөз кабат күз алдыннан кичереп барды. Әйе, әйе, җаен туры китереп, минем хатын ашханә мөдире булып эшли, тегесе-бусы кирәк чакта тартынып тормагыз, Галихан Сәмерханович, дип басым ясамаса да, бу хакта үтемле итеп әйтеп куячак.

Эшкә килгәндә бүлектә берәү дә юк иде әле. Моны да яхшы фалга юрады Альберт Робертович. Ул очрашу күренешен тагын бер тапкыр күзаллады да директор тарафына китте. Кабул итү бүлмәсендә беркем дә юк, секретарь да килмәгән иде әле. Директорның ишегендәге ачкыч кына уңга-сулга селкенеп, Галихан Сәмерхановичның яңа гына килүен белгертеп тора иде. Хәзер үк борчу тәрбиясезлек булыр, бераз хезмәт ритмына керә башласын, сабыр итим дип уйлады Альберт Робертович. Хәтсез сабыр иткәннән соң, аны әллә нинди салкын уйлар билəп алды. «Кинәт килеп чыгуы бар. Ә ул монда яшерен кәгазь чәлдерергә кергән шпион сыман утыра. Эш сәгате башланмаган ич әле. Секретарь да килмәгән. Гомумән, гадәт буенча, башта секретарь директорның кабул итү

теләген-мөмкинлеген ачыкларга тиеш... Әгәр иптәш Кәбиров иртәнге аш вакытында хәләл җефете белән низаглашкан булса? Рәхәттән шушы сәгатьтә эшкә тотынмас иде ич инде. Белә ул Альберт Робертович начальник хатыннарының ирләрен ничек биеткәннәрен! Кул астындагы кешеләр алдында гына әтәчләнә алар, өйләрендә суга төшкән тавык кебек йөриләр.

Үз уйларыннан үзе куркып, калтыранып куйды Альберт Робертович. Якягына каранды. Ярый әле мине эт тә күрмәде, ниятләремне берәү дә белмәде дип, шыпырт кына кабул итү бүлмәсеннән чыгып китте. Үзе торып-торып сөенеп тә куйды. Нинди һәлакәттән котылды бит, әй!.. Кулъяулыгы белән маңгаен киптереп алды да бүлеккә юнәлде. Үлеп яратмый иде ул дәрәҗәле кеше ишеге төбендә көтеп торуларны. Әгәр кодрәтеннән килсә, дөньяны ишекләрсез ясар иде. Альберт Робертович үзен хәзерге вакытта иң бәхетсез кеше итеп тойды. Беренчедән, хуҗага керәсе бар. Икенчедән, керергә аның батырчылыгы җитми. Ник кадалып китми шунда мөдирлек дияр идең, исенә өч кызы, якут алкалар һәм Лиана ханым килеп төшә...

Сәгать унынчы ун минут киткәндә, Альберт Робертович янә кабул итү бүлмәсенә юнәлде. Шулчак үзенә-үзе «шеф янында берәр кеше булса ярар иде, секретарь, эше күп, дисә ярар иде»,— дип барды. Һәм директор ишеге төбендә коңгыз нәселе бүлегеннән өч хатын-кызны күргәч, шатлыгыннан очып китәрдәй булып, кызу-кызу тагын үз бүлегенә кайтты. Юк, диде ул, хәзер үк кермим. Хатын-кызлар шефның кәефен бозып чыгарга мөмкин, иң яхшысы, төшке аш вакытында, ничектер табигый һәм очраклы итеп кенә очрашырга кирәк. Болай рәсми рәвештә керсәң, я, «өч тиенлек сафсатасы белән алтын вакытымны әрәм итте»,— дияр. Әйе, әйе, иң яхшысы — төшке аш вакытында, бүтән җирдә урын тапмаган кеше шикелле, итагатьле генә рөхсәт сорап, аның янына килеп утыру һәм җай гына, ләкин кыю итеп сүз башлау. Әңгәмә аккан судай гади, иплә дәвам итәргә тиеш.

Бүлекнең сазаган кызларыннан ул Галихан Сәмерхановичның «ТУ-134» сигареты гына тартуын белеп алды да, тегеләр икенче тапкыр чәйләргә утыргач, Әт әчәгесе институтына барып киләм әле, дип чыгып, киоскыдан биш кап әлеге сигаретны алып керде. Нияте ният: төшке аштан соң хуҗаны кабинетына озатып куйганда, ул сигарет тәкъдим итәчәк. Тамагы туйса, түрә кешенең дә кәефе яхшыра бит. Аннары төштән соң алар ял итеп алучан булалар. Галихан Сәмерхановичның Альберт Робертовичны: «Әйдәгез, кереп сөйләшик әле»,— дип бүлмәсенә чакыруы бик мөмкин! Менә шунда инде, йөрәге сикерүдән туктагач, минутына сиксәннән кимрәк тибә башлагач, күзләрен гашыйкларча ялтыратып, тавышын шагыйрьләрчә калтыратып: «Беләсезме, Галихан Сәмерханович, мин бит кайчандыр авиаконструктор булмакчы идем, күңел әле һаман биеккә ашкына»,— диячәк. Кеше бушка булса, күбрәк тарта бит. Иптәш Кәбировка икенче мәртәбә сигарет тәкъдим иткәндә, капны жонглер сыман әйләндереп: «самолетның рәсемен генә күрсәм дә, йөрәк сикерә башлый, беренче мәхәббәтем белән очраштыммыни»,— диячәк. Аннан соң, сүз арасүз китеп, бик кызык бер мәзәктән, ягъни, артподготовкадан соң, үзенең коңгызга каршы чиксез нәфрәтен белдерергә һәм, шул мөртәтне тәмам җиңгәнче, армый-талмый көрәшүне үзенең гомерлек бурычы санавын әйтергә, коңгызлар арасында алкоголизм тарату ысулының уңай якларын ачып салырга кирәк. Самолетны яратуы, күңеленең биеккә ашкынуы аны әле хыялы үлеп бетмәгән, иҗади омтылышлы хезмәткәр итеп танытырга һәм аны мөдирлеккә иң кулай кеше итеп күрсәтергә тиеш...

Альберт Робертович, башка өстәлләр артында буш урын калмасын өчен, ашханәгә юри бераз соңрак төште. Анда-монда каранды да, теләгенә ирешүенә куанып, язмыш мәрхәмәтенә мең рәхмәтләрен укый-укый, төрле икеләнүле уйлар биләп алганчы дип, өстәл артында бер үзе ашап утырган директоры янына юнәлде.

— Рөхсәт итегез, Галихан Сәмерханович,— диде ул үз кыюлыгына үзе сокланып.— борчыган өчен гафу гына итә күрегез инде, бер генә буш урын да калмаган...

— Зарар юк, утырыгыз, утырыгыз,— диде директор Кәбиров бер дә исе китмичә.

Баш кешенең җылы сүзләре үлгән җанны да терелтә торгандыр, билләһи! Электр урындыгына утырган кебек курыкса да, директорның тыныч тавышы юаныч бирде Альберт Робертовичка.

— Ашыгыз тәмле генә була күрсен инде,— диде ул гап-гади теләккә иҗади төчелек кертеп.

Директор дәшмәде, чәнечкесен авызына китергән арада сәгатенә карап алды да кабат кыяр кетердәтергә тотынды. «Юри иштәмәмешкә салыша, мине

өнәп бетерми, аппетитын да боздым ахры »,— дигән уйлар йөрәген өтеп алды Альберт Робертовичның. Колаклары хәтта башын пешерә сыман тоелды аңа. Куера барган киеренкелекне таратырга теләп, хәзер инде нечкә, зәгыйфь тавыш белән:

— Ашыгыз тәмле булсын,— дип кабатлады ул. Тавышым бетә дигән тагын бер кайнар уй йөгереп үтте башыннан. Аның укыганы да, ишеткәне дә бар: хәтәр хәлләрдә кинәт югала икән кешенең тавышы. Хәлен төзәтер өчен ул сиздермичә генә ботын чеметеп алды. Шушы авыртудан искиткеч рәхәт булып китте аңа. Теләсә нинди җәзага да риза иде ул, тик директор янынннан гына берәр кая алып китсен иде аны илаһи көч.

Официант кыз, Галихан Сәмерхановичның салат тәлинкәсен алып киткәндә, Альберт Робертовичны югарыдан килгән кунак итеп кабул итте ахры:

— Ә сез нәрсә телисез? — дип эндәште.

Бары тик шунда гына ул үзе алдында берни дә юклыгын күреп алды. Артык кызулавы аркасында, чиратка басарга да оныткан икән бит, шайтан алгыры. Утырган урындыгы кызган табага әйләнде, йөрәге янә урыныннан купты. Ул: «Мәшәкатьләнмәгез, хәзер мин үзем», — дип тормакчы иде дә, тора алмады, гәүдәсе урындыкка ябышкан булып чыкты.

Ярдәмгә әле ярый директор үзе килде:

— Әйтегез, әйт, тартынмагыз,— диде ул бәрхет төсле йомшак тавыш белән.

Альберт Робертовичка бераз җан керде:

— Миңа с-салат белән икенчене г-генә,— диде.

Унөч ел эшләсә дә, Альберт Робертовичның әле беркайчан да бу өстәл артында утырганы юк иде. Ашап кына өлгер, официант тыз-быз ташып кына тора. Ә башкалар һәрвакыт үзләре чиратка баса. Беренче елларны чиратны озак көтмәс, үзенә артык игътибар җәлеп иттермәс өчен, ул шактый соңрак төшә торган иде. Аннары, җыен каты-коты, калдык-постык кына калуын күреп, иң алдан йөгерә башлады. Соңгы елларда бөтенләй остарып җитеп, төгәл беренче яртыда түгел, шактый алданрак төшәргә гадәтләнеп китте.

Официант кыз аңа кыяр салаты китереп куйды да, ялт борылып, тирә-юньгә хушбуй исе таратып, ничек килде — шулай югалды. Альберт Робертович чәнечке алгач кына кулының ничек калтыравын сизде. Калтыратмас өчен ул бармакларын ныклап кысып ашый башлаган иде, кыяр кисәге, җайсыз эләгеп, лапылдап поляк чалбарына килеп төште, аннан алыйм дигәндә генә, бармагыннан шуып, венгр туфлиенә чәпәлде. Гади генә төшмәде, күңелне бозып, чалбарында һәм туфли башында каймак эзе калдырып төште. Кунак диеп, каймакны кызганмыйча салганнар иде аңа.

Ул арада директор ашын ашап бетерә язган иде инде. Түрәңнән акрын ашау, аны көттереп утырту оятсызлык булыр дип, Альберт Робертович чемченгән килеш кенә салатны этәреп куйды. Ашаганда эш турында сөйләшүне иң кара тәрбиясезлек санаганлыктан, ул тиз генә ризыгын капкалап бетерергә, Галихан Сәмерхановичны затлы сабырлык белән көтеп алып, урыннан торганда гына: «Рөхсәт итсәгез, миңа бер-ике минут кына кадерле вакытыгызны бүләк итүегезне үтенер идем»,— диярга җыенган иде.

Икенчегә китерелгән тавык ботын күргәч, Альберт Робертовичны очкылык тотып алды. Биредә унөч ел эшләү дәверендә аңа әле беркайчан да андый затлы нәрсә эләккәне юк иде. Теләсә кайсы җиргә эләгә, ә миңа бот... Аптырый иде ул кешеләргә карап, исләре китә иде — ничек башкаларга гел бот, аңа гына итсез җире эләгә соң аның? Элегрәк: «Соң төшкәнгә эләкми»,— дип уйлый иде. Иртә төшә башлагач та шул ук хәл кабатланды. Элек ул, ботлар тиз бетә, дип уйлый иде, тора-бара, алар кемнедер көтә, дигән фикергә килде. Бүтәннәр ашамлык бүлеп торучы хатын-кызларга шаян сүз әйтәләр, көлдерәләр, исәнләшкән, хәл-әхвәл сорашкан булалар да, я нәкъ Альберт Робертович алдыннан, я нәкъ аның артыннан ук ботны эләктереп алалар. Кайберәүләре туп-туры: «Галиякәй, миңа ботын сал әле»,— ди, һәм аларга салалар. Альберт Робертович моннан бернничә ел элек, мин кемнән ким, дип, батыраеп: «Галиякәй, миңа да ботын сал әле»,— дигән иде. Теге хатын күзләрен акайтып: «Сез нәрсә, тавыкта унике тәпи бар дип беләсезме әллә, кайдан җиткерик аны һәрберегезгә?» — дип кенә кычкырды. Шуннан бирле Альберт Робертовичның ялгышып та бот сораганы булмады. Гомумән, ул кош итеннән баш тартты, гуляш, бифштекс кебек нәрсәләргә күчте. Аның каравы, ашханәдә эшләүче хатынының сумкасына юл уңаенда гына кысылып кайта торган тавыкның ике боты да өендә әллә ничек кенә гел аңа эләгә иде. Ләкин өйдәге бот өйдәге бот инде ул, менә эштә эләктереп кара син аны!.. Шуңа күрә әлеге бот Альберт Робертович өчен патша түендагы нигъмәт белән бер иде. Ботны күргәч, куллары да калтыраудан туктады,

тавышы да кире үз куәтенә кайтты. Мөдир булсам, шәт, ешрак әләгер әле миңа мондый калжа, дип, директорның җылы сүзеннән терелә башлаган җаны бөтенләй канатланып китте. Альберт Робертович ботны нык итеп бер башыннан тотты да, ризык ләззәтен тулырак, нечкәләбрәк татырга теләп, күзләрен йомды һәм ботның иң итләч җиреннән батырып тешләп алды. Аннары, бер симез карабодай бөртегенә текәлеп карап, әле уң яктагы үз тешләре, әле сул яктагы тимер тешләре белән бик озак кына тәмләп чәйнәде. Йотып җибәргәндә тагын күзләрен йомды. Бот итенең тәмнәре үк бөтенләй икенче шул дип уйлады ул һаман куана-куана. Икенче тапкыр ботны капканда аның бәхетле күзләре каршыда утырган директорга төште... Менә сиңа, мә! Ул бит шушы каһәр суккан калжа аркасында алдында түрәсе утыруын да оныткан!..

Директор Кәбиров карабодайны чүпләп бетереп, шулай ук тавык ботына керешкән иде. Хәер, аңа тавыкның боты түгел, ә койрык үсә торган җире эләккән булып чыкты. Алай итте, болай итте Галихан Сәмерханович, кулына алып тешләп, чәнечке белән астын өскә әйләндереп, тиресен каезлап та карады, тик барыбер ашар җирен тапмады. Альберт Робертович, күзләре чәчрәп чыгарлык булып, хуҗасын күзәтте. Тамагы нидәндер шул хәтле каты буылды, ул хәтта беравык тын да ала алмыйча утырды. Директорын кызганудан үкереп елап җибәрәсе килде. Ул аңа кулындагы ботны сузарга теләгән иде дә, итен умырып алырга өлгергән икән ләбаса. Нишләп ашыкты соң әле ул ай буе ач торган бирән шикелле? Бераз гына сабыр иткән булса, хәзер тәлинкәләрне алыштырып: «Юк инде, Галихан Сәмерханович, бусы сезгә»,— дип ботны шефына сузар иде. Ояты ни тора бит, әй! Бетте, чәлпәрәмә килде хыяллары!..

Альберт Робертович әле кулындагы ботка, әле директорына күз йөгертеп, нишләргә белмичә аптырашта калды. Гүя ул сул кулына бот түгел, ә наган тоткан сыман тоелды. Шул наганны хуҗасына тоттырып: «Мәгез, Галихан Сәмерханович, атыгыз мин юньсезгә, үтенеп сорыйм сездән! Йөрәгемә пычак кадагыз алла рәхмәте өчен!» — дип ялварасы килде. Шушы минутта яшен яшеннәсә яки җир тетрәсә, аны һәлакәттән йолып калыр иде бәлки. Ник кенә шартламый икән бу дөнья?.. Юк, юк, директор тыныч булып кылана гына, җанында җеннәр котырганын әллә кайдан күреп тора Альберт Робертович, күрмәсә — сизә.

Ул шундый уйлардан тинтерәгән арада, директор, компотын эчеп бетереп, Альберт Робертовичка тәмле сыйлануны теләп, чыгып та китте. Мәңгелек бәхете белән саубуллашкандай, ул ишектән чыгып югалганчы, кайгыга батып озатып калды шефын Альберт Робертович. Ботны кимереп бетермәкче иде дә, теше үтмәде — суынган, катыланган иде инде калҗасы. Компот эчмәкче булды, анысы да тамагыннан узмады.

«Мария Павловна, сезне Галихан Сәмерханович чакыра»,— дигән тавыштан гына аңына килде Альберт Робертович.

Мария Павловна аларның ашханә мөдире иде. Әһә! Тавык боты өчен чакырта. «Ник миңа ботын түгел, койрык үсә торган җирен китердегез? Ач калдырдыгыз ич, ишетәсезме?» — дип тетмәсен тәтәчәк.

Мария Павловна директор янында озак тормады. Альберт Робертович, башын ауган кәбестә кебек кыйшайтып, күз кырые белән генә ашханә хәлләрен күзәтте. Мөдир официантка кызны кыздыра башлады. Беренчесе агарынган, икенчесе кызарынган иде. Кызыкай елый-елый нәрсәдер сөйли, аклана иде күрәсең, ә мөдир хатын аны тыңларга да теләми, үзенекен тезә иде. Кайдан белсен ди ул яшь-яшь кыз кемнең түрә, кемнең түмгәк икәнлеген. Мин гаепле монда, Мария Павловна, кызга сүз әйтмәгез, диясе килде Альберт Робертовичның. Бар гаепне үз өстенә алса, хәле җиңеләер кебек иде. Ул көчкә урыныннан купты, егылмас өчен урындык аркасына бераз тотынып торды, аннары өстәлдә бер тәңкәлек көмеш акча калдырып, сдача бирүләрен дә көтмичә, акрын гына ишеккә юнәлде.

Залда соңарган берничә кеше генә ашап утыра иде. Алар берсенә-берсе иелә-иелә нидер сөйләшә, Альберт Робертовичның гайбәтен саталар иде булса кирәк.

Ул, авыр гына кымшанып, бүлегенә таба атлады. Идән аның табанын пешерә, стеналар, ишек тоткалары, артыннан төртеп күрсәтеп, көлеп калалар шикелле тоелды. Коридорда да кешеләр очрап кына торды. Юри йөриләр, аның хурлыкка калуын беләселәре, тел чарлыйсылары килә сыман иде.

Альберт Робертович килеп кергәндә, бик кызып аны чәйнәп маташкан хезмәттәшләре башларын кинәт кәгазьләренә төбәп, шып булдылар. Ул тыйнак кына үз урынына узды, өстәл тартмасыннан бер бит кәгазь чыгарып, әле һаман уйлана-уйлана, рәсем ясый башлады. Уникe көн буе ул коңгыз рәсеме генә

ясаган иде, ә бүген кулы үзеннән-үзе тавык боты сурәтен төшерде. Аның янына тавыкның койрык үсә торган җирен дә ясап куйды. Әйтерең бармы, ботның ите, әлбәттә, күбрәк булырга тиеш иде. Ә тегесенең, түрәгә түгел, безнең ише «шыртлакаларга» да ашар җире юк.

«Бу мәтәлгере тавык боты гүргә кертә бит инде мине»,— дип уйлады Альберт Робертович хәвефләнеп. Әйдә, сөйләсеннәр, көлсеннәр, шул кирәк аңа. Үз бәхетен үзе кисте ләбаса. Хатыны, кызлары бәхетен бер тавык ботына алышты бит, әй! Бу хәлдән соң аны Галихан Сәмерханович һич тә мөдир итеп куймаячак, билгеле. Бәлә, бик яхшы бәлә Альберт Робертович түрәләрнең холкын, күңеле нечкәлеген. Онытмыйлар алар кул астындагы кешенең мондый мәнсезлеген. Йөз елдан соң уятып сорасаң да: «Әйе, булды шул, бераү хәләл өлешемә кул сузган иде. Әмма аннары күрсәттем дә соң үзенә комагайлыгы өчен!» — диячәк...

Альберт Робертовичның кызлары да шулай кияүсез тилмерерләр микән инде? Нәчәлникнең аерылып кайткан кызы артыннан да бер көтү егет йөри. Ә синекеләр шәбрәк булса да, игътибардан читтә кала бирә.

Альберт Робертович түземсезлек белән эш сәгате бетүен көтте. Вакыт, үч иткәндәй, гел акрын узды. Аның тизрәк өенә йөгереп кайтасы, кемне дә күрмәс, ишетмәс өчен, җиде кат юрган астына кереп ятасы килде. Шушы күңелсезлек онытылганчы, гайбәтчеләр теленә бүтән берәр кеше эләккәнче, юрган астыннан башын да чыгармас иде ул.

Альберт Робертович эштән кайту белән, чыннан да, түшәккә ауды. Кызларына: «Нишләптер температурам күтәрелде, салкын тидердем ахрысы»,— дип алдады. Хатынына да: «Кермәдем әле хуҗа янына, әллә нишләп үземне начар хис итәм»,— диде. Хатыны: «Тавык пешергән идем, сиңа ике боты калды, ашыйсың килсә, тор»,—дигәч, чак үлми калды Альберт Робертович. «Бар кешегә дә мөдир, директор булырга дигәнмени? Ул бит әле бөтенләй төшеп калган кеше түгел, бөлеме югары, эше чиста, план да куа торган түгел. Әнә күпме кеше шуңа да ирешә алмый ләбаса!» — дип тынычландырырга тырышты үзен Альберт Робертович. Тик тынычлану мөмкин түгел иде инде.

Ул көнне ашханәгә Альберт Робертович ярты сәгатькә соңрак төште. Директорның күзенә күренәсе килмәде. Әле кичә генә игътибар иттерүне хыялланган кеше бүген сөргенгә сөрелүгә дә риза, тик хуҗасы күзенә генә күренмәскә тели иде.

Альберт Робертовичның күзләре ашханәдә пешекчеләр җыелган төркемгә төште. Алар арасында кичәге официантка кыз юк иде. Йөрәге «жу» итеп китте Альберт Робертовичның, тамагына тагын кичәге төер тыгылды. Аны мыскыл итеп койрык китергән өчен директор теге кызны эштән кудырткандыр. Моңа һич тә шикләнмәде ул. «Чиратта мин, мине дә куачак, Лиана»,— дип куйды эченнән Альберт Робертович.

Бу көнне аның эше тагын эш булмады, иртәдән кичкәчә ихтыярсыздан коңгыз урынына янә тавык боты ясады. Төнлә исә йоклый алмый интекте. Кайта-кайта һаман теге тавык боты турында уйланып ятты. Яңа директорга күреним дип йөргән аяз, төтен хәтле дә болытсыз көннәре исенә төште. Рәхәтләнеп кенә яшәгән булган икән. Бәлки директор ул чакта да аның турында: «Нишләп бу адәм гел коридорда, аяк астында уралып йөри, эше юк микәнни моның?» — дип уйлагандыр. Альберт Робертовичның ачудан маңгаен бәреп ярасы килеп китте. Ничек мондый фараз аңа ул көннәрдә үк килмәде икән? Ахмак, хыялый, гөмбә баш, тилебәрән орлыгы ашаган нәрсә!..

Маңгаена берничә тапкыр йодрыгы белән кундырып та алды. Их! Куачак аны директор эштән, бер көн дә тотмаячак. Әүвәл эшсез йөрде, аннары каршысына утырып, күзенә кереп, борын төбеннән тавык ботын чәлдерде... Шулай итеп заводка китәр микәнни Альберт Робертович? Күнегелгән эш иде бит, җылы бүлмәдә чиста эш иде. Майлы булмаса да, җайлы иде хезмәте. Заводта тавыш, газ, төтен, план... Беркөнне заводны телевизорда күреп тә ютәле кузгалып куйган иде.

Альберт Робертович икенче көнне дә, өченче көнне дә эшкә бара алмады. Температурасы күтәрелде. Калтыранып, туңып чирли башлады. Хатыны участок врачын чакырды. Врач — уртача яшьләрдәге кыю гына хатын, бер атналык бюллетень биреп калдырды. Альберт Робертовичның бюллетеньне, яңа директорны күрмәс өчен, гомер буена, һич булмаганда, Галихан Сәмерханович яңа эшкә киткәнче озайтасы килә иде. Тик поликлиникада бюллетеньне яптылар. Берни белми бу врач халкы, әй! Синең җаныңда пәриләр пошкыра, ә алар сиңа: «сез — сәламәт», ди.

Альберт Робертович бюллетеньнән эшкә чыкканда алар бүлмәсендә алтын тешле, юан гәүдәле яңа мөдир утыра иде инде.

«Нигә минем белән болай бик төче көрештә соң әле бу? — дип уйлады Альберт Робертович.— Йомшак җаеп катыга утыртырга чамалыймы әллә? Директорның үз кешеседер инде».

Шул арада мөдирне директор чакыртып алды. «Әһә, минем турыда әйтәчәк ул аңа. Синең бүлектә бер пешмәгән бәндә эшли, карарсың әле, аңардан фәнгә берәр файда бармы, юкмы?» — димәкчедер.

Тагын эше эш булмады Альберт Робертовичның. Әле йөрәге чәнчеп, әле эче борып, әле колагы чыңлап азаплады. Ашханәдә исә тәртип күзәтеп яңа ханым йөри иде. Мария Павловна күренмәде. «Беттем, ашханә мөдирен дә алыштырганнар»,— диган уй төште Альберт Робертовичка. Шул бер тавык боты нигә кешенең башына житте буламы инде бу? Гомер буена көчек кебек сөяк кимерергә риза, тик менә үткәненнән шул тавык ботын гына сызып ташлыйсы иде. Тамагына тәмам кадак булып утырды бит, әй!..

Бүлеккә килеп керү белән, аны үз янына яңа мөдир чакыртып алды:

— Альберт Робертович, конгыз буенча алып барган эшегез турында хисап бирүегезне үтенер идем,— диде ул.

Юри тәмле телле булып кылана, ә үзе бугазыңны чәйнәргә дә әзер. Нигә шундук: «Гаризаңны яз»,— дип кенә әйтмидер.

— Иртәгә мөмкинме? — дип сорады Альберт Робертович, аңа хәтле башына берәр юньле фикер килеренә ышанган сыман,— мин әле терелеп житмәдем, эшкә үзем генә сорап чыккан идем...

— Зыян юк. Килештек,— диде мөдир.

Нәрсәдән зыян юк: хисап бирүне иртәгәгә калдыруданмы, әллә Альберт Робертовичның үзе теләп иртәрәк эшкә чыгуыннанмы? — Аңламады ул. Куачаклар, эштән куачаклар! «Сау бул инде иркен өстәл, бәхил бул җылы урындыгым»,— дип өстәле белән урындыгын кочаклап, үксеп-үксеп елыйсы килде аның.

Өенә кайткач, Альберт Робертович тагын юрган астына чумды. Бик тиз йокыга китте. Һәм шушы йокысыннан ул тора алмады.

Альберт Робертовичны бик зурлап күмделәр. Сазаган кызлар, үзләре уйлап тапкан йола буенча, институт хезмәткәрләре каберенә бер төп бәрәңге утырталар иде. Кабер иясе гомерен бәрәңгегә багышлаганны белсеннәр, янәсе. Альберт Робертович каберенә дә бәрәңге утырткannар иде дә, институтның яңа юнәлештә эшли башлавын сизгән шикелле, зираттагы бәрәңгегә коңгыз төште. Бер генә яфракны да исән калдырмады.

# ҖАВАПЛЫЛЫК СИЗЕП

## ЗАҺИР САДЫЙКОВ ХИКӘЯСЕ ТУРЫНДА

Сатирик каләм белән язылган әсәрләрне бездә күбесенчә көндәлек матбугатта, анда да «Чаян» журналында гына очратырга мөмкин диярлек. Инде бу хакта сүз кузгалган икән, безнең әдәбиятта сатира жанрының үги бала хәлендәрәк яшәвен дә әйтеп узарга кирәк. Күрәсең, моның үзенә күрә сәбәпләре дә бардыр. Бердән, Г. Тукайдан соң көчле каләм белән язылган сатираны укырга насыйп булмады шикелле. Икенчедән, сатирага без теш ыржайтып иһаһайлап көлү белән генә шөгыльләнүче җиңелчәрәк бер нәрсә дип карарга күнегеп бетмәдекме икән? Минемчә, бездә сатира шундый сәбәпләр аркасында җитди әсәрләр янына түргә уза алмый булса кирәк.

Матур әдәбиятны тормышның көзгесе диләр. Әгәр көзге «кыек» булмаса, дөрес булса, ул каршысындагы манзараны, бер урынын да күләгәдә калдырмыйча, гадел рәвештә бөтен барлыгы белән күрсәтергә тиеш. Тәмам камиллеккә ирешкән җитди әдәбиятта, эпик, лирик жанрлар белән янәшә үк, сатира да, гадәттә, үзенә лаек урынны алган була. Сатираның әһәмиятен аңлау өчен, Г. Тукай «Кисекбаш»ының ничә еллардан бирле сәхнәдән сөйләнүен, кат-кат басылып чыгуын искә төшерү дә җитсә кирәк. Соңгы вакытларда исә замана бездән иҗтимагый һәм шәхси тормышыбыздагы җитди кимчелекләргә, шулар арасыннан ваемсызлык, битарафлык, җавапсызлык кебек тискәре күренешләргә каршы кискен көрәш ачуны таләп итә. Бу көрәштә сатира да үзенә лаеклы урынны алыр дип ышанасы килә.

Яшь язучы Заһир Садыйковның «Тавык боты» дип исемләнгән хикәясе дә сатира теле белән язылган. Хикәя турында фикер йөрткәндә бу аның сатира бакчасына беренче адымы икәнлеген дә истә тотарга кирәк була торгандыр.

Шулай да ул кызыксынып укырлык җитди әсәр язган. Хикәя укучыны битараф калдырмый, ышандыра, уйландыра һәм борчый. Хикәянең төп персонажы булган институт хезмәткәре Альберт Робертович Хәбибуллин укучы күз алдына шәп-шәрә хәлендә килеп баса, үзенең җебегәнлеге, кешелек дәрәҗәсен мыскыллауга кадәр түбәнгә тәгәрәгән вак җанлылыгы, җирәнгеч ялагайлыгы белән нәфрәт уята. Әйе, тормышта, кызганычка каршы, андыйлар, яисә, аңар ук тиң булмасалар да, аңа охшаган кешеләр юк түгел. Альберт Робертович төрле урында төрле кыяфәткә керергә, хезмәт урыннарында бик төрле булырга мөмкин. Әмма алар кайда гына пәйда булмасын, нинди генә хезмәт баскычында тормасын, андыйлар җәмгыятьнең сәламәт тәненә ябышкан яман чир булып, аяк астында буталып, алга омтылучыларга һәрвакыт уңайсызлык тудыралар. Андыйлар никадәр тизрәк, никадәр рәхимсезрәк фаш ителсә, шулкадәр яхшырак; андыйларга карата никадәрле көчлерәк нәфрәт тудыра алсак, кайбер урыннарда яшәп килгән ваемсызлык, җавапсызлык, безнең җәмгыятькә бөтенләй чит булган кысыр битарафлыктан шулкадәр тизрәк арына алыр идек.

Һәркемгә мәгълүм булса кирәк, сәнгатьтә, әдәбиятта чама микъдарының әһәмияте әйтеп бетергесез зур. Әгәр берәр нәрсә чамадан артып китсә яки җитмәсә, ул шунда ук сизелә, бөтенлекне бозып, ышандырмый башлый, канәгатьсезлек тудыра. Күп булмаса да, андый чамасызлык бу әсәрдә дә очраштыргалый. Менә бер мисал. Әсәрдә: «...Лиана ханым иренең даһи академик булуын бик тели иде».— диелә. Белгәнебезчә, академик булу ул инде үзе ук фәндә иң югары дәрәҗәгә ирешү дигән сүз. Академикның да даһие булу хакында хыяллану исә майны майлап ашагандай яисә мөлдерәп торган савытка тагын да сыекча өстәгәндәй чамадан ашып китә. «Эт эчәгесе институты» дигән атаманы да мин шундыйлардан санар идем. Артык ясалмалык, көлдерер өчен генә юрамалый уйлап чыгарылган арзанлы «табышлар» әсәрне һич тә бизәмиләр. Сатираның да төп чыганагы реаль чынбарлык булуын истән чыгармыйк.

Мәгълүм ки, сатираның үзенә хас теле дә бар. Автор бу телнең үзенчәлекләреннән урыны-урыны белән ярыйсы ук уңышлы файдалана дип әйтер идем. Әсәрдә шаян сүз уйнатулар, мәгънәсе белән генә түгел, әйтелеш формасы, яңгырашы белән ук эчтәлекне тирәнрәк ачарга ярдәм итә торган гыйбарәләр ярыйсы ук еш очрый.

«Шундый бит хәзер замана: пешерсәләр, төшермиләр, төшерсәләр, пешермиләр»...— дип яза автор.

Шулай да... Фәндә һәм тормышта нәрсәне дә булса «тиешле кондициягә җиткерү» дигән төшенчә яшәп килә. Әгәр дә шул төшенчәне әдәби телгә карата да кулланырга уйласак, бу хикәядә «тиешле кондициясенә җитмәгән» җөмләләр дә очрый дип әйтергә туры килә.

Пешерделәр, пешерделәр үзен, ә барыбер күчерделәр... — дип язган автор.

Гәрчә татар сүзләреннән оештырылган җөмлә булса да, турысын гына әйткәндә, бу безнеңчә түгел, бәлки калька. Язучы әйтергә теләгән фикерне укучыга бөтен тулылыгы белән җиткерик дисәк, татарча ул болайрак булыр иде: Пешерепме пешерделәр үзен, шулай да күчерделәр...

«...ипле Лиана ханым (?)», «алла рәхмәте өчен» («алла хакы өчен» булса кирәк), «алтын фикер әйтеп үсә алмаячагын аңлагач...» кебекләрне дә тәмам «кондициясе җиткән» камил җөмләләр дип әйтеп булмый. Туган телнең мөмкинлекләреннән уйлабрак, остарак файдаланганда алар башкачарак — дөресрәк, ягымлырак яңгырарлар иде.

Яшь авторларның әсәрләрен укыганда я аның стилендә, я башкасында ара-тирә, ерактагы елдырым шәүләсе сыман, нинди дә булса бер классик әсәр тәэсире күзгә чалынып киткәли. Мин үзем монда гаҗәпләнерлек берни дә күрмим. Чөнки яшь язучының, әдәбиятта үз сукмагын салганчы, үзеннән элек язылган әдәбият тәҗрибәсенә таянуы, эзләнүе, өйрәнүе бик табигый хәл. Ләкин өйрәнү белән өйрәнүнең аермасы бар. Ул иске сабакны яңа шартларда шул килеш кабатлауга гына кайтып калмаска тиеш. Әгәр дә яшь иптәш элек кулланылган нинди дә булса иске алымга яңа сулыш өрергә омтыла икән, элекке традицияләргә таянып, яңа чорның үзенә хас яңа сүзен әйтүне, тагын да көчлерәк, үтемлерәк итеп әйтүне максат итеп куя икән — хәерле юл! Андый өйрәнүне хупларга гына кала.

Заһир Садыйковның бу хикәясе тормышыбыздагы кайбер кимчелекләрнең яшәп килүенә борчылудан килеп туган. Ул тәнкыйть утын, үткен сүзен шуларга юнәлткән. Иҗтимагый әһәмияте зур булган җитди темаларга алыну яшь автордан, язу сәләтеннән тыш, шәхси кыюлык та таләп итә. Яңа әсәрләрен язганда бу сыйфатлар аңа һәрвакыт юлдаш булыр, ул әдәби осталыкның тагын да югарырак яңа баскычына күтәрелергә омтылыр, дип ышанабыз. Бу юнәлештә үсәргә аңа, бу әйтелгәннәрдән тыш, тагын башкара торган хөрмәтле һәм җаваплы хезмәтендә туплана барган тормыш тәҗрибәсе дә, халык белән турыдан-туры аралашуы да, гражданлык вазифасын тирән аңлавы да ярдәм итәр.

Гомәр **БӘШИРОВ.**

# Газинур Моратов

## Телəк

Мəхəббəттəн талчыкканмы? —
Хислəре... калган телдəн:
Ярын тели аңларга ул
Беркатлы җаны белəн.

Гаугалардан арыганмы —
Кан сауганмы кальбенə? —
Чорны тели аңларга ул
Риясыз җаны белəн.

Хəтерлəүдəн ялыкканмы? —
Хəтер — утлы күмер лə...
Тарихны тели аңларга
Ул — мəҗрух җаны белəн.

Əллə үзеннəн туйганмы? —
Кан тама калəменнəн.
...Вакытны тели аңларга
Ул — фани җаны белəн.

## Мəрхəмəт

Ялгызым болынга бардым,
Чəчкəлəр серен алдым...

— Əй, егет, ни сагышың бар,
Сиңа җандашың дəшə:
— Телимсең, сөйгəнең булам —
Диде шаян милəүшə.

— Əй, егет, ни хəсрəтең бар,
Ни кайгың,— баштан ашкан?
Гомер юлдашың булыймы? —
Диде горур ромашка.

— Əй, егет, кемеңне җуйдың,
Өнеңне күрдем төштə.
Телимсең, əнкəең булам,—
Диде уйчан мəтрүшкə.

Ялгызым болынга бардым,
Чəчкəлəр серен алдым.

---

ГАЗИНУР МОРАТОВ (1959) — яшь шагыйрь, «Җир хəтере» исемле шигырь китабы авторы. «Ялкын» журналы редакциясендə эшли.

## Без — Хәтер!

*Илһам Шакировка*

Бу катмарлы дөньялыкка
Без үксеп, елап килдек...
«Карурман»ны ишетмәсәк,
Без сагыш булмас идек.

Бу катмарлы дөньялыкка:
— Син нинди садә! — дидек.
Илләр имин, тату торса,
Без кайгы булмас идек.

Бу катмарлы дөнья безгә
Азмы көч, ныклык бирде!
Җирдә мәкер яшәмәсә,
Без нәфрәт булмас идек.

Бу катмарлы дөнья безне,
Юк, бөгә алмас инде.
Җанда ышаныч toймасак,
Без шатлык булмас идек.

Бу катмарлы дөнья гамен
Без панцирь итеп кидек.
Шагыйрь иманы булмаса,
Без хәтер булмас идек.

...Без хәтәр булмас идек!

## Ул көн...

Һәммәсенә түзгән, күнгән хәтер —
Күнегалмас ләкин үлемгә...
Өчпочмаклы кайгы булып яши
Авылымда ул көн бүген дә.

Әбкәйләрнең сандык төпләрендә
(Ак бүзләре белән янәшә),
Өчпочмаклы кара хәсрәт булып
Яши ул көн... яши һәм яшәр!

Һәм фашистның яңа варислары
Табынганда кабат тәрегә,
Борманнардай посып ята ул көн
Ярчык булып —
Илем тәнендә.

Замананың неовәхшиләре
Үрелгәндә кабат кыныга,
Ракетадай посып ята ул көн
Җирнең күкрәк куышлыгында.

Һәммәсенә түзгән, күнгән хәтер
Күнегалмас ләкин үлемгә...
Кара кайгы булып яши ул көн
Авылымда минем бүген дә.

Әбкәйләрнең сандык төпләрендә
(Туй күлмәге белән янәшә!)
Соңгы набат булып күкри ул көн.
Хәтер белән хәтер ярәшә...

## Сурәт турында баллада

*Билгесез татар рәссамына*

Гасыр әле күкрәк баласыдай
Тыпырчынган чакта бишектә,
«Соңгы хәбәр» йөрде мәхәлләдә,
Шакый-шакый килде ишеккә.

— Тагын теге денсез, хәлфә улы
Гаурәт ясап безне хур иткән.
Ул азгынга тизрәк чара күрик,
Я ләхәүлә,
Ул кафер икән.

Һәм рәссамны тотып алдылар да
Кыз сурәтен утка салдылар.

Аягүрә ялкынланды учак,
Әверелде сынга — шул чакта
Үз йөрәген алып салды рәссам
Мәгъшукасы янган учакка.

Ә бер читтә чапан, түбәтәйләр
Дога кылды: «Корсын нәсле дә!»
...Янган сурәт бик тә охшаш иде
Пикассоның мәшһүр рәсменә. [1]

## Тракай

Тракайда — Литва татарлары,
Горур татар, серле татарлар!
Нинди генә җилләр ташлагандыр —
Мәгърибтә дә азмы татар бар!?

Нинди генә җилләр ташлагандыр,
Тарих, әйдә, үзе сөйләсен...
Яр буенда тыпырчынып ята
Нух бабайның ярык көймәсе.

## Мәкальнең... дәвамы

Шундый заман җирдә,
Шундый вакыт, димәк:
Нотык сөйләү түгел,
Кылган гамәл кыйммәт!

Җир саулыгы өчен,
Ил саулыгы өчен —
Син — хакиме Җирнең...
Һәм хадиме, Кешем!

Шушы юлда — Илнең
Олтаны бул, Кешем!
...Илдә олтан булу —
Солтан җаннар эше!

---

[1] Рәссамның «Майорка утравында яшәүче испан кызы» картинасы күздә тотыла. *Автор.*

## Авылдаш имәнгә мәрсия

Ул ышана иде әле
Шаулап, күкрәп үсәсенә,—
Яшен теле, елан булып,
Уралмаса кәүсәсенә.

Яшен теле, елан булып,
Уралды шул билләренә...
Ныклык бир, җирем, имән күк
Мәгърур, асыл ирләреңә.

Мәрхәмәтле язмыш телә —
Күңелләр болай да китек:
Азмы яшьтәшне — имәндәй! —
Яшибез бүген яд итеп!

## Сүзләр йөри

Төрле сүзләр йөри шагыйрьләр хакында.
Тере һәм мәрхүм шагыйрьләр хакында...
Берәве ач-фәкыйрь яшәгән, янәсе.
Берәве уңмаган хатыннан.

Бер шагыйрь көн иткән ди сукбайлыкта,
Өстен булам дип даннан, байлыктан...
Бер шагыйрь, янәсе, сыра бик яраткан.
Бер шагыйрь фәкать «Мальборо» тарткан.
Ә бер шагыйрь гашыйк булган
Чит бер хатынга...

Ләкин, ни хикмәт,
Шигырьләр турында түгел, сүз...—
Шагыйрьләр хакында...

## Альберт Хәсәнов

# БАЛ ДИСӘҢ...

Мин аларны: «Нәниләрем, нарасыйларым, җечкәбилләрем!»— дип иркәлим.

Алар үзләре дә мине яраталар. Әгәр җәйләр матур килеп, тәрбияләвең дә килешсә — алар сине балга коендыралар. Бер оясы көчәнми-нитми генә бер көянтә бал җыя да бирә. Уңганнар-булганнар, игелеклеләр алар!

Алда торган зур сүзне, мөгезеннән генә эләктереп, күңелле җиреннән башлап китим әле. 1984 елның җәендә республикабыз умартачылары өчен бик куанычлы тантана булды: алар дәүләткә бал сату буенча Россия күләмендә беренчелекне яуладылар. Социалистик ярышта җиңүчеләргә билгеләнгән байрак һәм зур күләмдәге акчалата бүләк республикабыз халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең конференц-залында күмәк алкышлар белән тапшырылды. Совет Татарстанының йөзен умартачыларыбызның уңганлыгы аша да күрсәтерлегебез бар икән! Азык-төлек Программасын тормышка ашыру җәһәтеннән безгә бу шөгыльнең отышлымы, файдалымы-юкмы икәнлеген дә кабат күздән кичерү кирәктер.

— И-и, отышлы түгелме соң? — дияр иде бу сорауга каршы умарта тоткан авыл агае.

Умарта тоткан авыл агайларының, үзегез беләсез, йортлары ук башка: әүвәл-әүвәлдән буяулы калай түбә, имән баганалы урыс капка...

Умартачылык турындагы сорауга җавап биргәндә, Россия умартачылыгының тарихи остасы Петр Иванович Прокопович искә төшә. Умартачыларның Халыкара оешмасы «Апимонди»нең Ватикан территориясендә урнашкан резиденциясе бинасына аның түбәндәге сүзләре язылган: «Умартачылык — тик зирәк акыллылар шөгыле». Ул 1775—1850 елларда яшәгән. Әтисе бөлеп баручы дворян була. 1786 елда ул унбер яшьлек Петрушаны Киевтагы руханилар академиясенә укырга бирә. Академияне тәмамлаганнан соң ул Мәскәү университетына керергә тели. Әтисе аяк терәп каршы төшә, улын хәрби кеше, офицер итәсе килә. Малаен кычкыртып, көчләп, үзенең бертуган энесе, хезмәттәге гвардия капитанына илтеп бирә. Шулай итеп, булачак умарта галиме, теләсә-теләмәсә дә, хәрби кеше булып китә. Суворов походларында катнаша, күпләрне таң калдырып, батырлык та күрсәтә. Хәрби хезмәт — карьера яулауның иң җиңел юлы, әмма Петр Иванович исә моннан котылу ягын карый, 1798 елда поручик чинында отставкага чыга.

Аңлашыла ки, әтисе моңа каршы була. Прокоповичка егерме дүрт яшь. Нәрсәгә тотынып карарга, тормышны нидән башларга? Егет игенчелек белән шөгыльләнергә карар итә, берничә дисәтинә җир сатып ала. Шул ук җәйне бертуган энесенең утарында умартачылык белән таныша. Гомеренең шул чорларын исенә төшереп ул: «Мин умартачылык белән баш күтәрми шөгыльләнергә карар иттем. Бу өлкәдә мыскал... белем булмаса да, миндә сөйләп биргесез зур теләк бар иде»,— дип яза.

1802—1803 нче еллар умартачылык өчен искиткеч уңай киләләр. Прокопович бал һәм балавыз сатып аякка баса. Умартaларның санын 580 башка җиткерә. Соңыннан ул:

— Мин нибары ике хезмәтче тотып егерме биш ел буена гел умартачылык белән генә яшәдем,— дип яза.— Шул керем зур гына имение сатып

алырга, үз хисабыма умартачылар мәктәбе ачарга мөмкинлек бирде. Умартачылык белән шөгыльләнә башлагач, мин нужа күрмәдем, хәерчелекне татымадым... Яхшы урыннарда умартачылык бер сумга йөз сум табыш бирә. Умарта асрау өчен уңайсызрак җирләрдә дә бер сум чыгымга ышанычлы ун сум табыш китерә.

Прокопович шушында ук әйтеп тә китә: «Умарталарны карый белмәүчеләрне исәпкә алырга ярамый. Шуның аркасында нык бөлгән, бөтен кортларын кырдырып, үтереп бетергән хуҗалар турында да мисалларны күп китерергә булыр иде». Шушы сүзләренә аерым басым ясап, тагын бер кабатлый: «Умартачылык — зирәк акыллылар шөгыле!»

Бал дисәң, бер кими, кашык тыксаң, бик тиз бетә торган үзе татлы, үзе шифалы бу ризыкны чәчәкләр керфегеннән җыючы әлеге тырыш җаннар безнең планетабызда кешегә кадәр илле биш-алтмыш миллион еллар алдан яралган дип исәпләнә. Шуңа күрә баш бирми, авызлыклатмый ул. Борынгы халыклар тормышында да бал кортлары аерым урын тота. Мәсәлән, Түбән Мисырның гербына да умарта корты сурәте төшерелгән. Мисырлылар умарта кортларына батырлык, тугрылык, дошманга аяусыз булу, чисталык һәм тәртип символы итеп караганнар. Фиргавеннәрнең беренче династиясе (безнең эрага кадәр 3210—2780 нче еллар) табутлары өстенә бал корты рәсеме ясата торган булганнар. Мисырлылар үзләре дә бик тырыш һәм уңган булганнар. Балны күбрәк җыю өчен, умарталарын күчереп йөртергә иренмәгәннәр. Умарталарны, көймәләргә төяп, баллы үләннәр алты атнага иртәрәк чәчәк ата торган җирләргә, Нилның түбәндәге үзәненнән югарыдагы болыннарына күчерә барганнар. Димәк, бер сезонда ике уңыш җыйнаганнар.

Борынгы Һиндстанда бал кортлары алланың иң якын юлдашлары булып исәпләнгәннәр.

Борынгы Грециядә, умарталарны күчереп йөртеп, шулай ук бик файдаланганнар. Аларны корабларга төяп кайда баллы чәчәкләр күп, шул утрауга озата торган булганнар.

Урарту дәүләтендә умарталарны бал һәм балавыз өчен генә түгел, дошманнардан саклану өчен дә асраганнар.

Инде урта гасырларда булган бер вакыйга. Шуны үз күзе белән күргән бер сәүдәгәр болай дип язып калдыра. Экипажы нибары кырык-илле кешедән торган бер сәүдә корабына диңгез юлбасарлары һөҗүм итәләр. Сәүдә корабында берничә чүлмәк умарта корты да була. Инде беттек дигәндә генә, капитан башына шундый уй килә: ул үз матросларына битлекләр кияргә куша һәм пиратлар корабы өстенә бер-бер артлы әлеге чүлмәкләрне тондыра. Чүлмәк эченнән котырышып чыккан кортлар аҗгырып юлбасарлар өстенә ташланалар. Тапкыр капитан экипажы биш йөз кешедән торган корабны кулына төшерә, юлбасарларны әсир итә.

Тарихи мәгълүматлар безнең якларда умартачылык белән ныклап торып моннан ике-өч мең еллар элек шөгыльләнә башлау турында сөйлиләр. Тарихчылардан Б. И. Греков һәм А. Якубовский «Болгардан Хорезмга» бара торган товарлар арасында бал һәм балавызның иң беренче урында булуын күрсәтеп үтәләр.

Инде безнең көннәргә якынлашыйк. 1919 ел. Апрель ае. Мәскәү. Кремль. В. И. Ленин кабинеты. Яшь Совет Россиясенең авыр көннәре. Илдә гражданнар сугышы бара. Ильичка нинди мәсьәләләрне генә хәл кылырга туры килми. Әмма шушындый көннәрдә дә Ильич умартачылык мәсьәләсен карарга да җай тапкан. Владимир Ильич барлыгы җиде пункттан торган «Умартачылыкны саклау һәм үстерү турында»гы декретка кул куя. Биредә, чит кеше хезмәтеннән файдаланмаганда, умартачыларга умарталыкларын теләсә нинди күләмдә киңәйтергә, ә бал кортларының баш санын теләсә нинди күләмдә үрчетергә мөмкин диелә. Мин үзем Әлмәт районында безнең көннәрдә дә җитмеш-сиксән баш умарта тотып, хөкүмәткә елның елында бик күп бал һәм балавыз тапшырып килгән Семисынов дигән агайны беләм. Умарталыгында булып, балын татып, чәен эчкәнем бар.

Фамилиясе Семисынов булса да, уллары аның өчәү генә. Менә шул өч улы белән ду китерәләр алар умарталыкларында эшләп. Иртә яз башында тал, өянке чәчәк аткан әрәмәлеккә чыгып утыралар. Машинага тагып йөри торган будкалары бар. Анда газ плитәсе, тәсле телевизор, ике җиңел караватъ. Әрәмәлектән өрәңгелеккә күченәләр. Өрәңге, чәчәк атканда, нектарны шулай ук бик мул бирә. Аннары кыр ышыклау урман киңлегенә сәрви чәчәгенә күченәләр. Аннары юка чәчәк ата, карабодай өлгерә, көзгә таба көнбагыш чәчәккә күмелә. Семисыновлар да кортларын көнбагыш басуына

күчереп утырталар. Тырышкач, тозлы тир түккәч, рәхәтен дә күрәләр. Өчесенең дә «Волга»лары бар. Йорт-җирләр дә таштан.

Ишле генә умарта тоткан тагын байтак гаиләләр бар. Менә Имам абзый. Ул башта «Авангард» колхозында утыз биш ел корт карады. Пенсиягә чыккач, Лениногорскига килеп йорт салды. Аның унбер баласы бар. Җиде егет, дүрт кызның һәркайсының үз балалары өчәү дә дүртәү. Гаиләдә җитмешкә җитеп килгән Имам абзыйның әйткән сүзе — закон. Аның кортлары да иртә яз башыннан, Шөгер урманына чыгып, матур бер аланга утыралар. Алар елның елында балдан мул уңыш алалар.

В. И. Ленин кул куйган декретта умартачылык белән шөгыльләнүче хуҗалыкларга һәм аерым кешеләргә махсус налоглар салмаска дип тә күрсәтелгән. Өстәлендә яткан әлеге документка имза салганчы, В. И. Ленин, аны кабат укып чыга да тагын бер пункт өсти: «шушы карарны бозуда гаепләнүчеләр РСФСР законнары тәртибендә җавапка тартылачаклар»,— дип куя. (В. И. Ленин. Сайланма әсәрләр. т. 38. 531-532 б.)

Дөньяда беренче социалистик дәүләтне төзүче юлбашчыбыз бөек Ленин үзе васыять итеп калдырган умартачылык эше республикабызда ниндирәк хәлдә? Аның алдында ниндирәк мәсьәләләр тора? Сүз уңаенда шуны әйтеп китим, безнең Татсоюзның чит илгә сата торган товарларының күп процентын бал тәшкил итә.

Татарстан балы чит илдә бик югары бәяләнә. 1976 нчы елда Биектау районы Суксу авылында Вебер фамилияле бер немецны очраттым. Ул, Татсоюз белән килешеп, колхозлардан балны үзе сайлап ала икән. Русча да бераз белә. Татар сүзләрен дә өйрәнеп өлгергән. Миңа кызык тоелды.

— Безнең балның нәрсәсенә кызыктыгыз? — дип сорадым.

— У-у! Самый вкусный баль — Казань! — сәүдәгәрләрчә күзен хәйләкәр кысып, немец иреннәрен ялап куйды.— Лейпциг ярмарка. Казань баль, во!

Шулай да, республикабыз умартачылыгы ни хәлдә? Кай якка йөз тотабыз соң? Бу сорауларга җавапларны төгәлрәк бирү өчен үзебезнең Лениногорск һәм Әлмәт районнары мисалыннан файдаланырга булдым. Безнең Лениногорск районы колхоз-совхозларында илле бер умарталык бар. Кышка өч мең башлап калдырыла. Әлмәтлеләр — өч мең алты йөз баш. Һәвәскәр умартачыларга да тагын шул чама туры килә. Ике районга ун-унике мең баш тирәсе чыга. Йөз меңнәрчә гектарлар җире булган ике районга аз, әлбәттә, гаять аз. Шуның аркасында меңнәрчә гектар мәйданнардагы чәчүлекләр серкәләнми кала, кайбер игеннәрнең уңышы меңнәрчә центнерларга түбәнрәк була. Үсемлекләрне серкәләндерү, минемчә, тиз көндә хәл ителүен көтә торган глобаль мәсьәләгә әверелеп бара. Шөпшәләрнең, төклетураларның ояларын сакламыйбыз: урман тирәсендәгеләрен малай-шалай туздыра, кантар астындагыларын трактор-комбайн таптап китә. Химикатлар да аларны күп кыралар. Шуның аркасында клевер, люцерна һәм серкәләндерүгә мохтаҗ башка күп культураларның уңышы елдан-ел түбәнәя. Ахырда хәл бөтен илдә нык кискенләшкәч, Воронеждагы төклетуралар, шөпшәләр үрчетү станциясе бу игелекле бөҗәкләрне Канададан сатып алырга мәҗбүр булды. Шуннан соң гына алар соңгы елларда аз-маз күзгә күренгәли башладылар. Аларның ояларын сакларга иде!

Бездәге төп серкәләндерүчеләр — бал кортлары. Ләкин аларның баш саны да елдан-ел кими. Шушы уңайдан тагын бер гыйбрәтле мисал китерим әле. Эмитида яшәүче (Нью-Йорк штаты) Эттер фамилияле агалы-энеле ике туган арасында ызгыш чыга. Берсе — умартачы, икенчесе бакчачы икән. Энесе, синең умарталарың минем бөтен алмаларымны җиләк-җимешләремне тешләп, тишкәләп бетерәләр дип, абыйсын бакчасыннан куа. Ага кеше, башка җир алып, кортларын шунда күчерә. Әмма ике елдан соң энесе, умарталарны кире күчерүен үтенеп, агасы каршына килеп тезләнергә мәҗбүр була, чөнки аның агачлары җиләк-җимеш бирми башлаганнар икән.

Бал кортлары серкәләндермәсә, алма, груша, чия, слива, өрек, лимон, мандарин, кура җиләге, крыжовник, карлыган кебек җиләк-җимешнең мул уңыш бирмәвен хәзер кем дә белә. Умарта кортлары серкәләндермәсә, карабодайның да чәчәкләре кысыр кала. Умартачыларның Халыкара оешмасы «Апимонди» президенты (милләте — румын) профессор В. Харнаж, оешманың Мәскәүдә булган XXVIII конгрессында ясаган докладында, бал кортлары бүгенге көндә чәчәгендә нектар булган үсемлекләрнең бары ун процентына гына куна, дип белдерде. Умарталарның баш саны аз булганлыктан, меңнәрчә центнерлар нектар җыйналмый, миллионнарча гектар үсемлекләр серкәләнderелми кала.

Безнең колхоз-совхозлар умарталарны нигә күп итеп үрчетмиләр соң? Республикабызда алар һаман кимүгә таба йөз тота. Мин бу мәсьәләне өйрәнүгә бер җаемне багышладым, башка өлкәләрдә дә булдым. СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең Умартачылык павильонына да кагылдым, умарталарын карадым. Күргәзмәнең иң аргы башындагы бакча эчендә ике йөз илле башлап корт тоталар.

СССР авыл хуҗалыгы фәннәре академиясенең умарталыгы аеруча яхшы тәэсир калдыра. Һәр оя янында бер аспирант, ике-өч студент кайнаша. Липецкида умартачылык комплексы төзиләр. Ул инде бал җитештерү белән генә түгел, ә умартачылыкның башка продуктларын да халык хуҗалыгында киң файдалануны тәэмин итәчәк. Биредә мәсьәләне киң колач белән хәл итәргә омтылыш сизелә.

Безнең республикада исә умартачылык чәчәк ата дип һич тә әйтмәс идем. Күп хуҗалыкларда һәм совхозларда умарталык гомумән юк. Эш нәрсәдә? Сәбәпләр җитәрлек. Беренчедән, караучылар, умартачылар юк. Хезмәткә түләү түбән. Әйтик, 120 баш умартаны карасаң, көнлек хезмәт хакы 3 сум 59 тиен. Умарталыкта алар икәү. Ярдәмчесенеке —3 сум 15 тиен. Елда 280 эш көне дисәк, хезмәт хакы аена 95—90 сум чыга. Моңа кайсы ирнең селкенеп йөрисе килсен?! Шуңа күрә ир-атның мәйдан тотардае техникага утыра. Бу хезмәтнең башка күңелсез яклары да җитәрлек. Колхоз идарәсе тирәсендә кыяр-кыймас кына ат сорап, салам сорап, шикәр комы сорап торган юаш агайны очратсаң, умартачы шул булыр. Ә эше авыр аларның, аны үзе татыган кеше генә белә. Чәчәкле урман яланы, тынлык, кошлар сайравы, саф һава — алар беренче тәэсирләр генә. Ата-бабадан калган кәсеп дип, үзем дә биш-алты баш умарта тотып юанам мин. Менә шуларны карап чыкканчы да, бил уклау булып ката. Турая алмый ай да вай киләсең. Колхоз умартачысы карамагына кимендә 150 баш тапшырыла. Ул көне буе, бөгелгән хәлдә, ояны барлый, рамнар куя, ашарларына бирә. Урман аланы белән ләззәтләнеп торырга ара юк. Көне буе төсләгеч белән эшләргә, ачы төтен суларга туры килә.

Лениногорск районы «Шушма» колхозының умарталыгына бал сыккан вакытка туры килдем. Умартачының ни дип җавап бирәсен белсәм дә:

— Балың баллымы, Касыйм агай? — дип сорадым.

— Тозлырак шул,— ди.

Тозлы булмыйча, тир түгеп тапкан ризык, әлбәттә, тозлы була. Дөрес, мул бал җыеп алгач, газаплары онытыла. Үз эшеңнән тәм табу ләззәте барын да оныттыра!

Минемчә, умартачылыкны үстерү, аннан мул итеп уңыш ала башлау өчен, хуҗалыкның бу тармагына мәйдан тотучы яшьләрне тартырга иде! Дөрес, бу юлда хаталарыбыз булды. Балаларны әллә нинди һөнәрләргә кызыктырып үстердек, космонавт булырга чакырдык. Әйтерсең, туган җирдә менә дигән һөнәрләр беткән. Умартачылык гадәттә авылдан дүрт-биш чакрым читтә, урман эчендә була бит инде. Клубта һәр кич кино, биюле уеннар. Күрше авылдан кунак кызлары килгән. Унсигез-егерме яшьлек егет, йөрәгенә май үсмәгән булса, шушы урман уртасында япа-ялгызы синең умартаңны саклап ятсынмыни? Әмма бу хәлдән дә котылырга мөмкин. Мин булсаммы — умарталыкка ут үткәрер идем, төсле телевизор, суыткыч алып куяр идем. Умартачылыкта эшләүче егеткә шәп мотоцикл алып бирер идем. Кичен выжлап кына авылга төшеп сөйгән кызын клубтан озатырга да өлгерсен, шунда ук кире әйләнеп умарталыгына да менә алсын. Бүгенге колхоз-совхозлар өчен боларны эшләү чүп тә түгел. Күп урыннарда шушы эшләнми. Нәтиҗәдә хуҗалыклар умарта асрамыйлар, булганнары да арттырылмый. Лениногорск районының Муса Җәлил исемендәге колхозда кайчандыр биш умарталык булган. Хәзер бер баш та юк.

Бал уңышы өчен умарталыклар тирәсенә нектарлы культуралар чәчәргә кирәк. Карабодай — шундыйларның берсе. Тагын эспарцет һәм кандала үләне дигән культуралар бар. Менә алар бирә инде балны! Алар печәнне дә җәйгә өч мәртәбә бирәләр. Моннан ике ел элек Лениногорск кошчылык фабрикасы илле-алтмыш гектар мәйданда кандала үләне чәчкән иде. Беренче чапканда ике-өч метр биеклеккә үскән үлән арасыннан чапкычлар, төягеч машиналар күренми дә иде. Монысы — бер хәл. Шушы хәлдән соң Лениногорск умартачылары фабрика директоры Анатолий Кудашев белән ерактан ук баш иеп исәнләшә башлады. Чөнки шушы илле-алтмыш гектар җирдән кортлар балны сыктылар гына! Нектар өченче тапкыр баш калкыткан үләндә дә чамасыз иде.

Хуш исле юкә дә, кәефе килгәндә, балны шактый мул бирә. Безнең районда юкәлек массивлары унбер мең гектарлар чамасы. Шуның җиде меңе балигъ, җитлеккән, ягъни бал бирә торган юкәләр. Юан гына бер юкә, елы килсә, бер гектар карабодай җиренә караганда да юмартрак. Ә 1981 елны шундый хәлгә тап булдым. Шөгер юкәлегенә чыгарылган умарталарны сакларга чиратым җиткән иде. Исрафилов абзый белән таң алдыннан шөбһәле тавышка сискәнеп уяндык. Матур итеп таң аткан, кояш күтәрелеп килә. Җил әсәре юк. Үләнгә мул итеп чык төшкән. Кортлар эшкә тотынганнар. Урман «гөж» килә, самавыр кебек шаулый. Юкәгә бал төшкән икән! Кортлар оя янындагы юкәдән очу тактасына җилпенеп түгел, «шып» та «шып» егылышып төшәләр. Чөнки канатларына хәтле нектарга баткан. Оя эченә мүкәлимүкәли генә керәләр дә, җиңеләеп, яңадан юкә чәчәгенә ашыгалар.

— Болай булса, энем, булган тәпәннәр генә җитмәс,— ди Исрафилов абзый.

Әмма мондый көн тәүлек ярымнар гына торды. Икенче көнне төш алларыннан төньяктан ямьсез салкын җил исә башлады, күк йөзен болытлар басты. Җил-яңгырлы көннәр унөч көнгә сузылды. Юкә чәчәкләре бетте, урманда кортларга ямь калмады. Әмма көчле оялар шушы кыска вакыт эчендә дә кәрәзләрен бал белән тутырырга өлгергәннәр иде. Бу урман аланыннан без бик канәгать булып кайттык.

Юкә дигәннән, аның хәле дә ярдәм көтә. РСФСР Министрлар Советының стационар умарталыклар урнашкан җирләрдә юкәләргә кимендә өч километр радиусында кагылмаска, кисмәскә дигән карары бар. Әмма урман хуҗалыкларына мунчала планы килеп төшкәч, әзерләүләр оешмасы аныңмоны тикшереп тормый. Берсендә мин алар янына барып:

— Бу мунчала нигә хәҗәт? Нинди яхшы юкәләрне харап итәсез,— дип сораштырып карадым.

Мунчаладан балык промышленносте министрлыгына кап ясап бирәләр икән. Балык тутырып йөртү өчен. Капларны күптән капроннан ясый башларга бик вакыт югыйсә?! Балык министрлыгының үз мәнфәгате. Балыклар гына күп булсын да, аларны тутырып йөртергә каплар җитеш торсын!

Аеруча борчыган тагын бер мәсьәлә бар. Матур җәйләр җитеп, агачлар яшел шәлләрен бөркәнеп алуга, республикада яфрак азык хәзерләү кампаниясе башлана. Чын мәхшәр көннәр инде бу. Бирәдә исәп тә юк, хисап та юк. Кайсы хуҗалык күпме хәзерләргә теләсә, урманны шул хәтле туный. Ямь-яшел урман шәрәләнә дә кала. Бу вәхши чарада үземнең дә катнашканым бар. Бер хәлең юк, кушкач — барасың. Үзебез шефлык иткән колхозга килү белән, ферма чормаларын былтыргы яфрак себеркеләрдән арындырасың. Аларны чүплеккә машина-машина илтеп түгәбез. Димәк, кирәге чыкмаган. Алай булгач, нигә аны шулай итеп күп хәзерләргә соң? Шуңа да карамастан, быелгы план былтыргыдан да артык. Үтәми кара! Бөтен яшь үсентеләрен югалткан урман яраларын күзгә кадәр төзәтеп өлгерә алмый. Кышка ул хәлсезләнеп керә, әз генә суыклар башлану белән өши, харап була. Яфрак азык хәзерләү вакытында урманнарны саклау мәсьәләсе ныклы тәртипкә салынмаса, республикабыз Гоби чүледәй шәрә сахрага әйләнмәсме?!

Инде кулыма каләм алгач, мине нык борчыган икенче бер мәсьәләгә дә туктап китәсем килә. Бөек Ватан сугышы чорында без Дөбъяз районы Ташлы Кавал авылында яшәдек. Ачлыгын да күрдек, хәерчелеген дә. Әмма минем шуңа исем китә: авылыбызда озын сугыш чорында ник бер кеше ашказаны бозылу, эч китү, дизентерия белән интексен!? Эш нәрсәдә? Беренчедән, без аерткан сөттән оетылган катыкка рәхмәт укырга тиешбез. Академик Виноградов, татар авылларына махсус экспедицияләр оештырып, катыкның тылсымлы көчен күпьяклап өйрәнгән. Бу катыкта һәм сөзмәдә гаять файдалы дистәләрчә бактерияләр барлыгы исбат ителгән. Мең рәхмәт, әниләр-әбиләр безне катыктан өзми торганнар иде. Икенчедән, безгә витаминнар да мул эләкте. Аларын инде иртә яздан кара күзгә кергәнче ашый идек. Сары чәчәк, сабын чәчәге, юа, кузгалак, акбаш, әче кабы, урыс какысы, балтырган, баллы кәпшә, кәҗә сакалы — барысын да көлтә-көлтә җыя идек. Җиләк-җимешне әйткән дә юк. Ашарга яраклы үләннәрнең мин генә дә иләләп төрен таный һәм җыя идем. Эчеңә шул хәтле төр витаминнар кереп торгач, сине авыру ега аламы инде?! Хәзер бу үләннәрне оныттык. Балалар да аларны белмиләр дә, танымыйлар да. Бу хакта укытучылары да уйламый. Дөрес, язын укулар тәмамлангач, укытучылар үз классларын ияртеп урманга чыгалар. Табигать җәбер-золым гына күреп кала. Бәйдән ычкынган бозау

дай котырынышкан балалар аланнарны таптыйлар, агачларны сындыралар, тәкыя үрергә дип кочак-кочак чәчәкләр җыялар да юлда ук ташлап та калдыралар.

Авыр елларда авыру-хасталарга бирешмичә, нараттай төз, имәндәй нык булып үсүебезгә өченче сәбәп — минемчә, урман чикләвеге. Ул елларда атлан май да күрмәдек, итне-колбасаны әйткән дә юк. Барысын да шул чикләвек алмаштыра иде. Аның составында нинди генә матдәләр юк! Хәзер республикабызда чикләвек куагы массивлары елдан-ел кими. Урманчылар үзләре дә аларны кисеп, бу мәйданнарга нарат, чыршы утыртуны яхшы күрәләр...

Ярый, сүземне, бал дисәң,.. дип башлаган идем бит. Бал дисәң, бер кими, кашык тыксаң, бетеп китә. Табигатьтә дә ул Байкал күле булып утырмый. Корт, бер очыш ясаганда, оясына нибары 30—35 миллиграмм, тамчының йөздән бер өлеше кадәр генә нектар кайтарып ала. Анысын исә йөздән алып өч йөзгә кадәр карабодай чәчәгенә, яисә сигез-тугыз йөз алма чәчәгенә кунганнан соң гына җыя. Бер килограмм бал туплау өчен кортлар кимендә ун миллион чәчәккә кунып алырга тиешләр. Бер килограмм бал җыю өчен кортлар ояларына нектар белән 120—150 мең рейс ясарга тиешләр! Ояга кайткан зәмзәм әле ул бал түгел. Балга әверелгәнче әле ул ярты авырлыгын югалта. Әгәр карабодай кыры умарталыктан чакрым ярым ераклыкта тора икән, бер кило бал җыю өчен һәр кортка 360—450 мең километрлап юл узарга кирәк була. Менә ни ул — бер кашык бал. Менә ни өчен умартачы саран. Ашаган түгел, тураган белә!

Бал — гаять югары калорияле продукт. Ә химик элементларга байлыгы ягыннан аның белән тагын кайсы гына ризык тиңләшә ала икән?! Кеше организмы исә шушы элементларга һәрвакыт мохтаҗ.

Бал файдалы да, шифалы да, татлы да. Кортлар тоту, алар белән көндәлек аралашып тору да кешегә сөйләп бетергесез ләззәт бирә. Күзәтергә генә иренмә — алар сине әллә ниләргә өйрәтәләр. Көннең бүген нинди булачагын син ояга бер күз салу белән чамалый аласың. Кортлар иртә күтәрелсә, көн кояшлы булачак. Әгәр инде «без-без» килеп, ояларында утыралар икән, көт тә тор, төш алдыннан яңгыр коеп китәчәк.

Кортларның үз-үзләрен тотышларына, ояда кәрәз коруларына карап, алдагы ун-унбиш көндә һаваларның ничек буласын белергә мөмкин. Алар — чисталык яратучы җаннар. Әнкә корт күкәйләрне дә гәрәбә кебек сап-сары кәрәзләргә салуны хуп күрә. Икенче карыйсың, әнкә, чисталарны калдырып, серкәләрне иске, кара кәрәзләргә сала башлаган. Димәк, дүрт-биш көннән һавалар бозылып, суынып китәчәген көт. Әнкә корт шуны сизгән, серкәләрне, каралып бетсә дә, җылы «оя»га салырга мәҗбүр булган. Яз башында әнкә корт эшчәнлеген сары кәрәзләргә йомырка салудан башлый икән, шикләнмәскә мөмкин — яз җылы киләчәк. Утыртасы әйбереңне утырт, чәчәсе әйбереңне курыкмыйча чәч.

Кортларның үз-үзләрен тотышларына карап, әллә нинди ачышлар ясап булыр иде дә, белмибез, аңламыйбыз телләрен. Наданлыгыбыз көчле.

Бер елны, бәрәңге алганда, көннәр бозылып китте. Районның баш агрономы Анатолий Аркадьевич Храмов тәмам өзгәләнә, бәрәңгеләр җир өстендә калып өшер инде дип борчыла. Әмма кортларымның тәртибе башка. Әнкәләре серкә сала бирә, үзләре рам чистарталар. Юкка борчылмагыз, Анатолий Аркадьевич, әле тагын ике атна чамасы җылы, матур көннәр булачак дип кереп шатландырдым мин аны. Һәм шулай булып чыкты да.

Икенче бер елны мин шундый сәер хәл күзәттем. Умарталар иртә көз башыннан ук ояларын җылытырга, бөтен тишек-ярыкларын прополис белән томаларга керештеләр. Бер дә тикмәгә генә болай тырышмыйлар болар дим. Димәк, кыш салкын булачак.

Базарга барсаң, еш кына шундый күренешнең шаһиты буласың. Бал алырга дип савытларын кыстырып чыккан абыстайлар әле теге агайның балын кабып карыйлар, әле бу умартачыныкын. Әйе, бер үк тырыш кортлар җыйган баллар бер-берсеннән төсләре белән дә, тәмнәре белән дә, хуш исләре белән дә нык аерылалар.

Әйтик, сәрви балы. Иң югары сортлы балларның берсе. Сыек чагында ул үтә күренмәле диярлек. Утыргач, ап-ак була. Кристаллары вак, кар кебек. Ел килгәндә, сәрви балны бик мул бирә.

Әгәр мин булсаммы, миннән генә торсамы-бакча башларына, мәктәп алдына, клуб каршына, барлык ташландык чокыр-чакырларга сәрви утыртырыр идем.

Карабодай балы карасу саргылт, куе көрән төстә була. Каты булып утырмый, ботка хәлендә кала. Авызга алу белән тамак төбен кытыклый башлый. Бу бал кан азлыктан интегүчеләргә бигрәк тә шифалы. Шуңа күрә халыкта: «Кара бал төссезләргә файдалы», дигән сүз дә йөри.

Әгәр миннән генә торсамы?! Умарталыклар тирәсенә мин карабодайны, унар-уникешәр көн ара калдырып, өч мәртәбә чәчәр идем. Кортлар җәй буена кайгы-хәсрәт күрмичә тик рәхәтләнеп бал җыеп ятсыннар иде.

Юкә балы безнең халыкта аеруча югары бәяләнә. Бер гектар юкә чәчәк атканда, бер мең килограмм, хәтта аннан да артыграк бал җыеп була. Ләкин юкә бик «холыксыз» агач, нектарны һәр елны бүлеп чыгармый.

Әгәр миннән генә торса, мин урмандагы бер генә юкәгә дә балта чаптырмас идем. Юкәнең шундый үзлеге бар, ул дым тарта, дым ярата. Төбендә дымы кими башласа, юкә урманы әллә кайдагы болытларны «дәшеп» ала. Кулымнан килсә, мин бөтен авылларны юкә бакчасына әйләндерер идем.

Бал турында шулай зурдан сүз кузгаткач, менә шул турыда да берничә сүз әйтеп китим. Кайбер кешеләр, умартачылар балга шикәр кушалар дип шикләнәләр. Бу — яла ягу. Шулай да мондый ямьсез сүз нидән чыга соң? Менә кайдан. Маэмайга сөяк, сыерга печән, атка солы бирүгә бераү дә каршы түгел. Аны гадәти хәлгә саный. Умартачы кибеттән шикәр комы алса, бу аның күршесен шиккә төшерә. Ә бит кортларны да ашатмыйча булмый! Бездә кайбер елларны яз көйсез килә. Һич көтмәгәндә бозлы яңгырлар, хәтта кар явып куя, кортлар карлыган, алма, кура җиләкләреннән мыскал да нектар җыя алмый калалар. Юкә чәчәгенә, болындагы чәчәкләргә кадәр әле ай ярымнар бар. Корт әнкәләре исә, ояга һәр көн диярлек кимендә ярты кило нектар кереп тормаса, серкә салмый башлый.

Яхшы, уңган әнкәләр һәркөнне 2—3 мең серкә салып торырга тиеш. Әнкәсе серкә салудан туктаса, гаилә кәегә, аның көче кими. Менә шушы, ягъни табигатьтә нектар булмаган чорда һәр ояга көн аралаш кимендә кило ярым сироп биреп торырга кирәк. Мин үзем бу сиропны шикәр комын саф чишмә суында (колонка суы ярамый, анда хлор бар) ярты өлеш аерткан сөт кушып, берәр кашык серкә, чеметем генә лимон кислотасы өстәп, ясап бирәм. Шушыны алар, тоз ялаган сыер кебек, әчкелтем-төчкелтем ризыкларны тансыклаган яшь килен кебек, дөньяларын онытып эчәләр. Сиропка, бер ояга бер миллион берәмлек исәбеннән, унар көн аша пенициллин, биомицин, мономицин кебек антибиотиклар да кушам. Кортларга бит салкын да тия, тамаклары да шешә. Антибиотиклар эшче кортларның гомерен ун-унбиш көнгә озайта. Бал төшкән чорларда һәр корт унбиш көнгә озаграк яшәсә, бу бит үзе генә дә өстәмә тәпән бал дигән сүз!

Дөрес, витаминнар кушып, лимон кислоталары өстәп тәмләндереп бирергә тырышсаң да, шикәр сиробы алар өчен кипкән арыш саламы гына. Табигатьтән әз генә нектар керә башлау белән, алар синең сиробыңнан шунда ук баш тарталар.

Шикәр ширбәтен кышка да бирү кирәк. Көз башланып, ояларны ныклап тикшереп, артык рамнарны алып, кышка хәзерләп куйдым дигәндә генә, агачларга яфрак балы төшә. Кортлар шушы яфрак балын ташырга керешәләр. Бу бал кеше организмы өчен бик файдалы. Аның составында бик кыйммәтле минераль тозлар күп. Лейпциг ярминкәсендә яфрак балы иң югары бәядә йөри. Ә менә кортлар өчен ул зарарлы. Минераль тозлар аларның тамакларын киптерә, сусата. Кышын, су эзләп, корт күчтән аерыла һәм шунда ук туңып үлә. Ширбәттә исә, минераль тозлар юк, ул кортның сусынын да баса.

Кайчак бал чүлмәге өстендә биш-алты сантиметр калынлыгында сыек бал хасил була. Инде бу хәлне дә аңлатып китим. Әйтик, синең кортларың юкәдән я карабодайдан яхшы гына бал җыйнадылар. Сиңа хәзер шуны аертып алырга кирәк. Һәр төр балны икенчесе белән катыштырмау яхшы. Ләкин көнендә генә аертып алырга вакыт юк. Ял җиткәнне көтәсең. Син аертырга гына керешәсең, моңа кадәр бер атна эшсез утырган кортлар нииндидер чәчәктән нектар ташырга өлгергәннәр. Рамнардан шыбырдап нектар тама. Аңа карап бит инде туктап булмый, аертуны дәвам итәсең. Ахырдан карыйсың, бал булып җитлекмәгән шушы нектар өстә бөтенләй аерылып тора. Саф глюкоза, фруктоза бу. Аларның кыйммәте шунда, авызга алу белән, ике-өч минут эчендә канга сеңеп, тәнгә шундук көч-сихәт бирәләр.

Бал кортлары биргән башка нәрсәләр турында берничә сүз. Беренчесе —

әнкә сөте. Аның белән тиңләшерлек шифа дөньяда башка юк. Аның ясмык бөртеге тикле микъдарын тел астына салу белән, җитмеш-сиксән яшьлек умартачы бабайлар да йөгереп кенә йөри башлый. Монреальда (Канада) булып узган Бөтендөнья күргәзмәсендә әнкә сөтенең килограммы алтын белән утыз мең доллар дип бәяләнде.

Тагын әле чәчәк комы, чәчәк серкәсе (перга) бар. Аны балаларына ашату өчен ташыйлар. Боларын мин китаптан укып кына язам. Китапта: «Чәчәк серкәсенең бер граммы мең кешене баш миенә кан савудан саклап калыр иде».— дип язылган.

Прополисның дәвалау көче турында да риваятьләр йөри. Мин шуны гына беләм, прополис — бик көчле антисептик, антибиотик.

Умарта корты агуыннан, әнкә сөтеннән, пергадан һәм прополистан төрле дарулар ясала. Аларны теләсә кайсы аптекадан табарга була.

Мәскәүгә баргач, илебезнең иң баш умартачысы, умартачылык югары институты директоры, Халыкара умартачылар оешмасының вице-президенты Григорий Данилович Билаш янына кергәнем бар. Аның төп резиденциясе Рязань өлкәсенең Рыбное шәһәрендә. Институт биредә ике умарталык тота. Институтта 164 кеше эшли. Шуларның 66 сы — фәнни хезмәткәрләр, алар арасында бер фән докторы, 28 кандидат бар. Григорий Даниловичның улы Олег Григорьевич Билаш — шулай ук танылган умартачы, фәннәр кандидаты. Шунысы кызык, институтның студентлары барысы да югары белемле зоотехниклар, ветеринарлар, врачлар, химиклар, биологлар. Мин алар арасында Казанның ике врачын да очраттым. Алларында — микроскоп, бал кортының анатомиясен өйрәнәләр. Бу институтта уку срогы — ике ел.

Доктор Григорий Данилович Билаш Татарстан умартачыларын яхшы белә, миңа ул һәрчак умартачылык турында язарга, аны пропагандаларга да киңәш итә.

Бу язмамны тәмамлап, соңгы ноктасын куйганнан соң, мин аңа шактый вакыт кагылмый тордым. Нигә дисәгез — әллә каян гына килеп чыккан варроатоз зәхмәте кортларны кыра башлады. Утыз җиде ел рәттән умартачы булып эшләгән, исеме Мактау такталарыннан төшмәгән, СССР халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе медале белән бүләкләнгән Касыйм ага Кашапов та каушап калды.

— Умарталыкны малайга тапшыруын тапшырдым. Ә бер кыш эчендә кортлар кырылып бетсә, адәм хуры булабыз инде,— ди ул.

Кыш үтте, матур җәйләр җитте. Бу зәхмәтнең беренче дулкыны безнең тарафлардан авышты төсле. Тырыш умартачылар аның белән көрәш чараларын да таптылар. Нәтиҗәле даруларның берсе — «Фольбекс». Хәзер ул «Зооветтехснаб»ның барлык район бүлекчәләрендә дә бар. Касыйм ага Кашапов та юкка хафаланган икән. Борчулы кыштан соң алар дәүләткә 27 центнер бал тапшырдылар.

Лениногорск районы «Победа» колхозы умартачысы Звонарев Николай Александрович тагын да зуррак уңыш ялады: умарталарның баш санын 120 дән 140 ка җиткерде. Һәрбереннән уртача 28,3 килограмм бал җыйнады. Дәүләткә 34 центнер — бал; 62,8 килограмм балавыз тапшырды. Сезон эчендә һәр оядан сигезәр рам кәрәз төзәттереп алган. Николай Александровичның үзенә «1984 елда районның иң алдынгы умартачысы» дигән мактаулы исем бирелде.

Әлмәт районы умартачылары да сынатмадылар. 1984 елда алар дәүләткә 332 центнер бал озатып, еллык планнарын 130 процентка үтәделәр. Бу, әлбәттә, беренче чиратта — шушы эштә 1947 елдан бирле эшләүче, умартачылык буенча районның уңган һәм тырыш баш зоотехнигы Нуретдин Баһаветдинович Закиров агайның тырышлыгы нәтиҗәсе.

Россия умартачыларының атасы саналган Петр Иванович Прокопович: «Умартачылык — зирәк акыллылар шөгыле» — дигән.

Әгәр миннән генә торса, мәктәпләргә умартачылык фәне дә кертер идем. Зирәк акыллы малайлар азмыни?! Һич югында шуның уннан берсе, йөздән берсе умартачы булып китсә дә, нинди зур файда бит. Әлегә исә, бал кортлары азлыктан, умартачылар җитешмәгәнлектән, табигатьтә елның елында ун меңнәрчә центнер бал җыйналмый, татлы ризык булып өстәл түребезгә менеп утырмый кала.

Их, кулымнан килсә, һәр авыл кешесенең өй түрендә, шәһәр кешесенең балконында кимендә ике-өч умарта асратыр идем. «Асрату» дигән сүз дөрес тә түгел әле. Чөнки умарта һәр очракта кешенең үзен асрый.





**Ш. Ф. Тәхәветдинов,**

КПССның Лениногорск шәһәр комитеты беренче секретаре.

# ҮСҮ ЮЛЫННАН

Илдәге шәһәрләребезнең бер-берсенә охшаш яклары да күптер, әмма шул ук вакытта һәммәсенең кабатланмас тарихлары да бар. Мин бу сүзләремә мисал итеп районыбызның үзәге булган Лениногорск шәһәренә тукталырга телим.

Лениногорск — Татарстанның көньяк-көнчыгышына урнашкан кала. Ул 1955 елның 18 августында шәһәр итеп танылды. Аның Яңа Писмән авылы булудан башлап бүгенге заман шәһәрләре дәрәҗәсенә җиткән үсү юлы Бөек Октябрь казанышларына барып тоташа.

Бу яклар гомер-гомердән үзенең кара туфраклы, мул уңдырышлы басулары белән дан тоткан. Гасыр башында бүгенге Лениногорск шәһәре урнашкан мәйданда да игенчеләр дулкынланган әле. Дөрес, Бөек Октябрь революциясенә кадәр үк бу җирләрдә нефть ятмалары булырга тиеш дип тә фараз кылганнар. Тик аның запасы зур промышленность промыселлары көйләп җибәрерлек микъдардамы-юкмы икәнлеген белгели алмаганнар. Бары 1941 елда гына А. В. Лукин җитәкчелегендәге геологлар Иске Шөгер авылы янында беренче тирән коены казыйлар.

Хәзер бу урынга һәйкәл куелган. Аның турында, кызганычка каршы, бик аз беләләр. Чөнки бу беренче кое Ромашкинодагы өченче кое кебек мәшһүр чыганак түгел иде. Ромашкиноның даны исә бөтенләй башка. 1943 елны бораулау мастеры Ғарифулла Хәмидуллин бригадасы беренче коеның тәүлегенә 20 тонна чамасы нефть бирергә тиешлеген белгели. Шул ук вакытта Шөгер мәйданының 2000 метр тирәнлектәге девон катламын да тикшерә башлыйлар. Өч кое казыла. Девон катламына «сәяхәт» алымнары ныклап өйрәнелә, девонның комлы ятмасындагы нефтьне барлау мәсьәләләре чишелә. Партиянең Шөгер райкомы да, районның хуҗалык оешмалары да нефтьчеләргә зур ярдәм күрсәтәләр.

1947 елның гыйнварында бораулау мастеры С. Кузьмин бригадасы ул чактагы Яңа Писмән районы, Ромашкино (Тимәш) авылы янында өченче коега «һөҗүм» итә. 1948 елның 26 июнендә эш тәгалләнә. 1775 метр тирәнлеккә җиткәч, тәүлегенә 120 тонна нефть бирә торган фонтан бәрә башлый. Ромашкино чыганагы әнә шулай ачыла.

Еллар үтә торды. Яңа Писмән авылы урынында мәһабәт ташпулатлары, киң урамнары, гүзәл бакчалары, Культура сарайлары, стадионнары булган күркәм шәһәр барлыкка килде. Аны фидакарь кешеләребез салды. Шәһәребезнең үсүе исә кешеләребезнең данын еракларга алып китте. Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булган нефтьчеләребез А. Г. Тимченко, Г. М. Баһманов, К. А. Вәлиев, М. П. Гринь, М. Г. Гыймазов, Г. Н. Драцкий кебек баһадирлар төбәгебезнең мактанычына әйләнделәр.

Үткәне генә түгел, районыбызның бүгенгесе дә данлыклы. Эшчәннәребез казанышларга һәрьяклап өлеш кертәләр. Монда илебез халыкларының төрле милләт вәкилләре: рус, татар, украин, чуваш, мордвалар бердәм омтылыш белән, тырышып эшлиләр, дус, тату яшиләр. Җиребездә «кара алтын» ятмалары ачылгач, безгә ярдәмгә илнең төрле якларыннан тәҗрибәле бораулаучылар һәм нефть чыгаручылар килде. Кыенлыкларыбыз да, уңыш-шатлыкларыбыз да бөтен илнең уртак кичерешләренә әйләнделәр.

Хәзер районда унҗиде — промышленность, унике — төзелеш, тугыз транспорт оешмасы бар. Сәүдә һәм коммуналь хуҗалык оешмалары да үз вазифаларын яхшырт-

каннан-яхшырта баралар. Лениногорскида Мәскәүнең Губкин исемендәге нефтехимия һәм газ промышленносте институтының гомумтехник факультеты эшли. Нефть техникумы, педагогия училищесы, музыка һәм рәсем сәнгате мәктәпләре, унбер урта мәктәп һәм махсус урта мәктәп, ике һөнәр училищесы, М. И. Калинин исемендәге Техниклар йорты, стадион, спорт комплексы, җиде спорт мәктәбе, нефть музее — шәһәребезнең мактанычы менә шулар.

Шулай да, ни генә әйтсәң дә, төп байлыгыбыз — нефть, әлбәттә. Район үзәгендә нефть хезмәтенә бәйле дүрт зур оешма урнашкан: «Лениногорскнефть», «Иркеннефть», «Лениногорскбурнефть» һәм катламнарның нефть бирүен арттыру һәм скважиналарны капиталь ремонтлау идарәләре.

СССРның 60 еллыгы исемендәге «Лениногорскнефть» коллективы илгә нефть һәм газ бирү буенча инде утыз биш ел тырышып эшли. Илленче елларда миллион тонна нефть алу өчен аңа берничә ел вакыт кирәк була иде. Хәзер, хезмәтнең югары җитештерүчәнлеге аркасында, бу байлыкны ике-өч ай эчендә табабыз. Коллектив үз тарихында барлыгы 340 миллион тоннага якын сыек ягулык бирде. Идарәгә эштә яңадан-яңа отышлы ысуллар ачу, аны бөтен ил нефтьчеләренә үрнәк итеп тарату хас. Аның эш алымнарындагы кайбер ысуллар дөньякүләм яңалык булып та танылды. Катламдагы басымны саклау өчен су кудырту, торбаларның эчен пыялалау кебек яңалыклар — шундыйлардан. Коллектив уңганнарының җиде йөздән артыграгы СССР орден һәм медальләре белән бүләкләнде.

1964 елда төзелгән «Иркеннефть» идарәсе турында да шундый ук мактау сүзләрен кабатларга мөмкин. Унберенче бишьеллыкта гына да аның нефтьчеләре, техниканы камилләштерү буенча, гомуми файдасы 3,1 миллион сумлык 156 яңалык керттеләр.

Бораулаучыларыбыз исә барлык уңышларыбызның әйдәп баручыларыннан санала. Соңгы бишьеллыкларда бораулаучылар сафына яшьләр күп килде. Унберенче бишьеллыкның вакытыннан шактый алда, 1985 елның 16 ноябрендә ук үтәлүендә дә, минемчә, бу хәл шактый зур роль уйнады.

Нефть табудагы гомуми җиңүләрдә, һичшиксез, ремонтчыларыбызның фидакарьлеге дә бәхәссез. Алар хәзер уникенче бишьеллыкта хезмәтне тагын да нәтиҗәлерәк итеп оештыру турында ныклап уйланалар. Бигрәк тә хәзер, Татарстан нефтьчеләре Көнбатыш Себер катламнарын үзләштерүгә катнаша башлагач, ремонтчыларыбызның бу омтылышы ифрат кирәк.

Мәгълүм ки, күптән түгел «Татнефть» берләшмәсе Ханты-Манси автономияле округындагы Покачев промыселы нефтен үзләштерергә алынды. Бу зур эшкә Лениногорск нефтьчеләре дә үзләренең зур өлешләрен кертәләр.

Районның колхоз-совхозлары ашлык, яшелчә, бәрәңге, сөт, ит, йомырка җитештерү белән шөгыльләнәләр. Авыл эшчәннәре партиянең һәм Совет хөкүмәтенең уникенче бишьеллыкта алга куйган зур бурычларын тирәннән аңлыйлар.

Безнең авыл хуҗалыгы карамагындагы сугарулы басуларның мәйданы 9200 гектардан артты. Шуның 5700 гектарлабы — көтүлекләр. Соңгы елларда, гомумән, авыл хуҗалыгы ныклы индустриаль нигезгә күчә бара. Бу хәл исә хуҗалыкларның специальләшүенә, концентрацияләшүенә китерә. Хәзер районда сөтчелек буенча — дүрт, дуңгыз ите җитештерүгә көйләнгән ике комплекс бар. Мелиорацияләнгән җирдән файдалану буенча хуҗалыкара берләшмә булдырдык. Терлекчелек комплексларында авыр эшләр механикалаштырылган, аларда хезмәт җитештерүчәнлеге сизелерлек арта. Элек егерме биш сыер тәрбияләүче савымчыларыбыз хәзер йөз егерме баш сыерны үз карамакларына алдылар.

Һәр күркәм эшнең әйдәп баручылары — коммунистлар. Коммунистларның 76 проценттан күбрәге материаль җитештерү өлкәсендә хезмәт итә.

Без үзебезнең өлгер нефтьчеләребезне дә, авыл хуҗалыгы уңганнарын да бик кадерләп йөртәбез. Менә алар: бораулау остасы Ф. Вәлиуллин, өлкән оператор И. Гаязов, яшь оператор А. Симбиров, слесарь Ю. Петров, мастер Г. Яминов, савымчылар З. Кирдянова, А. Фәрхетдинова, Е. Петрякова һәм башкалар.

Күп эшләребезнең төп таянычы булып яшьләр, комсомоллар санала. Шәһәр комсомол оешмасы ун меңләп егет-кызны берләштерә. Тормышыбызның һәр тармагында алар башлап йөри. Хуҗалыкларда, көнкүреш хезмәтендә үзара ярыша-ярыша эшләүче 137 комсомол яшьләр коллективының 66 сы «Коммунистик хезмәт коллективы» исемен яулап алды.

Районыбызның өлкәннәре халыкка һәм илгә бирелгәнлекнең үрнәге буларак кадерле. Бөек Ватан сугышында Советлар Союзы Герое исемен алган Г. Гафиятуллин, С. Садриев, В. Яницкий, И. Заварыкин, А. Хәйретдинов, Г. Баһаветдинов, И. Халиков, И. Мурзин, Е. Яковлев, М. Хәлиуллин — безнең егетләр. Бу каһарманнарның сугышчан юллары — язылачы романнар өчен хәзинә. Әлегә аларның нибары берсе, Сугышлы авылы егете, гәүдәсе белән дошман утын каплап, коралдашларына җиңү

юлын ачып биргән сержант Газинур Гафиятуллин турында гына әсәрләр бар. Язучыларыбыздан, композитор һәм рәссамнарыбыздан егет-кызларыбызның Ватан өчен көрәштә һәм тырыш хезмәттә күрсәткән батырлыкларына багышлап язылган әсәрләр көтәбез.

Район үзәгендәге «Батырлар аллеясы» металлдан коелган мәгърур фонтан, нефть фонтанына килеп чыга. Бу монументны без кадерле җиребездә булган нефть байлыгын ачучыларга багышладык. Аны 1975 елның 6 сентябрендә тантаналы төстә куйдык. Монументны мәшһүр өченче коены бораулаган мастер Сергей Кузьмин, Социалистик Хезмәт Герое Анатолий Арестов һәм ремонтчы Габдел Хәсәенов ачтылар. Монумент астына, 2005 елда гына укырга, дип, егерме беренче гасыр яшьләренә Мөрәҗәгать язып салдык. Аны Лениногорск төзелгәнгә 50 ел тулу тантанасында алачаклар.

Район үзәгебез сокландыргыч матур безнең. Аның тирә-ягын табигый урманнар, серле таулар бизи. Шуңа өстәп, яз саен үзебез дә өй тирәләренә, бакчаларга чәчәкләр, агачлар утыртабыз. Кунаклар Лениногорскины «әкияттәгедәй гүзәл шәһәр» дип мактыйлар. Шәһәр кешеләре, бигрәк тә төзүчеләр аның бу күркәмлеген кадерләп саклыйлар. Соңгы вакытта якында гына күлләр дә булдырдык.

Авылларыбызны матурайту, мәктәпләрнең, клубларның яңа биналарын салу буенча да зур эшләр алып барыла. Әле күптән түгел шагыйрә Г. Зәйнәшеваның бер җырында макталган урында — Керкәле тау итәгендә «Чәй йорты» ачтык.

Уңган кешеләребезнең тырыш хезмәттән соң ял вакытлары да мәгънәле узсын өчен, спорт заллары, агитмәйданнар төзү көн тәртибенә басты.

Районыбызда яшь иҗат көчләрен туплап торучы «Чишмә» берләшмәсе бар. Шәһәрдә СССР рәсем сәнгате фондының остаханәләре ачылганга әле күп вакыт та үтмәде, әмма аның шәһәрне тагын да күркәмләндерүдәге тәэсире әллә каян сизелеп тора. Рәссамнарыбызга иҗат өчен илһам эзләп ерак китәргә түгел, әсәрләрнең каһарманнары булырдай шәхесләр күп бездә. Бәхеткә каршы, иҗат көчләребез дә бу хакыйкатьне тирәннән аңлыйлар. Рәссамнарыбызның тормышчан әсәрләре «Зур Идел» күргәзмәсендә (1985), башка рәссамнарыбыз Казанда Бөек Җиңүнең 40 еллыгына багышланган күргәзмәдә катнаштылар.

Матурлыкка, яктылыкка омтылыш, иҗатта шул хисне чагылдыру төбәгебезнең талантлы кешеләренә элек-электән хас булган. Безнең якта яшәгән һәм мөгаллимлек иткән шагыйрь Габдрәхим Утыз Имәни — шундыйларның берсе. Тимәш авылында аның кабере саклана. Түбән Чыршылы авылы мәдрәсәсендә Риза Фәхретдинев укыган. Соңрак ул үзе шунда ук укыткан, беренче хезмәтләрен язган. Тагын безнең районнан чыккан Ф. Туйкин, В. Тихонов, К. Сушков кебек әдипләрне күрсәтергә мөмкин. Аларның юлын яшьрәк буыннар дәвам итә: Роза Хафизова, Гәрәй Рәхим, Җәмит Рәхимов, Җәүдәт Дәрзаманов, Мәхмүт Газизов, Шамил Бикчурин, Кәшшаф Әмиров, Альберт Хәсәновның да күп әсәрләре Лениногорскида яшәгәндә язылды.

Бертуган Камил һәм Фазыл Фәсиевлар, Индус Таһиров, Сәгадәт Ибраһимов, Гали Даутов, Әнвәр Шәрипов кебек галимнәр; Шәех Зәбиров, Мөкатдәс Йосыпов, Касыйм Тәхәветдинов кебек журналистлар да — безнең якташлар. Бөек Ленин исемен йөртүче районыбызны тагын да ныгыту, матурайту теләге белән янып яшибез.

**Рифат Сверигин**

# ЗАМАНДАШЛАР БӘХЕТЕН КАЙГЫРТЫП...



Тормышның хәрәкәтен һәм закончалыкларын сәнгатьчә ача, яктырта белүче, эзләнүчән һәм тынгысыз каләм ияләренә әдәбият һәрвакыт мохтаҗ була. Ә инде рухи һәм иҗтимагый тормышның үзгәрүе, баюы этапларында әдәбиятны яңа сыйфат үрләренә күтәрүче сүз осталарының булуы аеруча кирәк.

Илленче еллар ахыры, алтмышынчы еллар башында яшь язучыларның бер төркеме: Рафаил Төхфәтуллин, Гариф Ахунов, Әхсән Баянов, Аяз Гыйләҗев һ. б. яңа эстетик кыйммәтләрне үзләренчә — җанлы тормыш рухында, сугыш елларында үскән яшьләр күзәтүе һәм кичерешләре рәвешендә әдәби образларда гәүдәләндерү теләге белән прозага килделәр. Алар арасында иҗади-эстетик карашларының шактый ук тенденциозлыгы, фикерләренең үткенлеге һәм сугышчанлыгы, искергән, инде таушалып, тормыш һәм сәнгать үсешенә комачаулый башлаган күренешләргә килешмәүчән мөнәсәбәте белән Аяз Гыйләҗев аерылыбрак торды. Аның иҗат тынгысызлыгы әдәбиятны уй-фикер торгынлыгы, образлы чараларның бертөрлелегеннән арындыруга, тормыш хәрәкәтендәге котылгысыз үзгәрешләрнең асылын аңларга, шушы яңа рухны сәнгатьчә ачарга, үзләштерергә ярдәм итәрдәй чараларны эзләү җирлегендә туган иде. Бәлки ул чакта күпләргә бу борчу-эзләнүләр яшьлек кайнарлыгы булып кына тоелгандыр. Әмма 30-35 ел үткәч тә тормышка актив мөнәсәбәте, гражданлык пафосының, кешелек җәмгыятен гүзәлрәк итәргә теләү омтылышына кушылып, яңадан-яңа әдәби образларда гәүдәләнә торуы инде танылган әдипнең иҗат позицияләре очраклы сайланмавы, эзлекле әзерләнүе, какшамаслыгы хакында сөйли.

Прозасының нигезен тәшкил иткән «Урамнар артында яшел болын» романы, «Өч аршын җир», «Берәү», «Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», «Мең чакрым юл», «Җомга көн, кич белән», «Әтәч менгән читәнгә», «Кызлар хатлары», «Күзгә-күз» повестьлары, күп санлы хикәяләре әдипнең иҗат колачын, идея-тема диапазонын, стиль үзенчәлекләре һәм төсмерләрен билгеләргә һәм ачыкларга мөмкинлек бирәләр. Авторның драматургия өлкәсендәге актив эшчәнлегендә дә идея-эстетик позицияләренең бердәмлеге, максатлы юнәлеше ачык гәүдәләнә.

Аяз Гыйләҗевның әдәби эзләнүләре, беренчедән, тормышыбызны, әйләнә-тирәбезне сафрак, матуррак, кешеләрне олы җанлырак итеп күрергә теләү хисенә буйсындырылган булса, икенчедән, шул кешеләр — замандашларның рухи яңарышына ирешү өчен әдәбият-сәнгать чараларының үтемлерәк, тәэсирлерәк ысулларына яшәү хокукы бирү, укучылар аудиториясен шул яңалыкларны эстетик планда әзерләүгә кайтып кала.

«Өч аршын җир»дә (1962) кеше һәм аның туган җире, коллективы, әйләнә-тирәсе, урыны кебек җитди мәсьәләләр күтәрелә. Татар прозасы өчен болар берсе дә яңа түгел. Әмма мәсьәләләрнең куелышы һәм әдәби чишелеше үтә кызыклы, үзенчәлекле.

Кешеләрдән читләшкән, барлык психик һәм физик көчләрен индивидуальлек фәлсәфәсенә буйсындырган Мирвәлине төп герой рәвешендә тәкъдим итү шактый ук сәер иде. Әлбәттә, андыйлар моңа кадәр безнең прозада булмады түгел, тик алар барьерның теге ягында булгангамы, һәрвакыт диярлек, эчке дөньяларыннан мәхрүм персонажлар

рәвешендә бирелә иделәр. Әдәбият үзе һәм әдәбият фәне озак еллар дәвамында уңай герой психологиясен өйрәнү белән шөгыльләнде. Ә биредә исә психологик анализ чит элементка — җәмгыятьтән аерылган, аннан читләшкән типка карый. Повестьта Мирвәлигә каршы социалистик җәмгыять нормалары рухында яшәүчеләрнең таза тирәлеге куелган.

Әсәрдә Мирвәлине яклаучы, хәтта аңа битарафлык саклаучы бер зат та юк. Берәү дә аның белән килешми. Әлбәттә, бу мохиттә башкаларны санламау, мин-минлек, җәмгыятькә, тарих агышына үзеңне капма-каршы кую фәлсәфәсе үсә дә, тамырлана да алмаячак. Кайчандыр, үч итеп, йорт-җирләрен яндырып, күмәк хуҗалык амбарларындагы икмәкне яраксыз хәлгә китергән Мирвәлине авылдашлары шулай да ахыр чиктә үз яннарына сыйдыралар — картайган кешенең хәленә керәләр. Әмма әхлакый планда бу — гафу итү түгел. Инде ничәмә-ничә еллар авылда беркемнең дә балаларына Мирвәли исемен кушмавы — җитди хөкем. Менә шушы факт дөньяда карашлар мәсьәләсендә бернинди дә ташлама, килешү булмаячак дигәнне аңлата. Мирвәлине авылга сыендыру исә — аның үчлеккә, әшәкелеккә нигезләнгән фәлсәфәсенең соңгы дәлилләрен юк итә — аңа кешеләр арасында яшәргә, җәмгыятькә хезмәт итәргә генә кала. Бу — халыкка каршы баручыларның әхлакый һәлакәте дигән сүз. «Кешеләр янындагы өч аршын җиреңә дә лаеклы бул»,— шушы рәвешчә индивидуаль шәхеснең җәмгыятьтәге җаваплылыгы идеясе көчәйтелә. Нәкъ шушы тәмамланышка укучыны әзлекле, дәлилле алып килүе Аяз Гыйләҗевның бу повестьтагы кыйммәтле иҗат табышы булды.

Аяз Гыйләҗев прозасының бер үзенчәлеге — ул контрастлылык. Повестьларының берсе «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» (1973) дип аталуы да тикмәгә түгел. Яхшылык һәм явызлык, матурлык һәм ямьсезлек, мәхәббәт һәм нәфрәт, саф әхлак һәм мещанлык — әнә шулар әсәрләрнең сюжет контрастлылыгын билгелиләр. Бер очракта дөньяга капма-каршы карашлар маңгайга-маңгай бәрешә («Өч аршын җир»), икенчесендә төрле мөнәсәбәтләрнең каршылыгыннан бигрәк, аермасын гына күрәсең («Берәү»), өченче очракта укучы геройның дөньяга карашында кискен үзгәрешләр шаһитына әверелә («Урталыкта»). Укучының мәхәббәтенә лаеклы һәм нәфрәтенә дучар ителерлек персонажларны автор ерак тарихтан яисә чит җирләрдән эзләми, алар үзебезнең тормыш чынбарлыгыннан әсәрләргә килеп керә. Гомумән, Аяз Гыйләҗев — заман язучысы, үз заманының художнигы. Материалы — үзе күргән-белгән, кичергән тормыш вакыйгалары. Әледәнәле укучы күз алдына Бөек Ватан сугышы чорындагы авыл кешеләре, бигрәк тә шул вакытта зур тормыш юлына аяк атлаган намуслы, саф күңелле, тыйнак авыл яшьләре килеп баса. Автор дөньяга яшь кеше күзләре белән карый, ул күп хикәя һәм повестьларда авыр тормыш сынауларын үтә-үтә чыныгып килүче яшь герой рәвешендә кабатлана, әмма моны бертөрлелек дип түгел, ә күркәм, югары әхлак сыйфатларына ия образның тулылана баруы дип кабул итәсең. Аңа әнә шундый зур урын бирелүе дә акланган — аның зур идея функциясе бар — автор иң алгы планга яшьләрдә югары әхлак, коммунистик сыйфатлар тәрбияләү максатын куя.

Гомумән, Аяз Гыйләҗев әсәрләренең конкрет адресы бар: аларның иң зур күпчелеге яшьләргә юнәлдерелгән.

«Дүртәү» (1958) һәм «Язгы кәрваннар»да (1972) яшүсмерләр Ибраһим, Дамир, Әдилә, «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят»тә унынчы класс укучылары Искәндәр һәм Рифгать, бер генә яшькә олырак булса да, аларны укытучы Арзу, «Качак» (1959) хикәясендәге сыер савучы Тәнзилә, «Берәү» (1959) повестендагы Исхак һ. б. образлар аркылы сугыш һәм сугыштан соңгы елларда үскән татар авылы яшьләренең тулы бер буыны, сөйкемле, уңай типик герой үткән тормыш юлының аерым кисәкләре, этаплары гәүдәләнә. Ә дөньяны аңлау, аңа мөнәсәбәткә килгәндә, бу персонажлар арасында әллә ни аерма юк, аларның һәммәсен янәшә куеп, билгеле бер чор яшьләр буынының типик сыйфатларын берләштергән характер дип бәяләргә мөмкин. Димәк, Аяз Гыйләҗев әнә шундый җыелма характерның гаять тормышчан, дөрес образын иҗат итә алган.

А. Гыйләҗев әсәрләрендә заман һәм тормыш җәмгыять алдына әледән-әле китереп куйган һәм чишелешен көтә торган проблемалар күтәрелә. Алар арасында уйландыра, борчый, тизрәк хәл итүне сорый торганнары да бар. Җәмгыять милкенә дөрес булмаган мөнәсәбәт, яшьләрне тәрбияләү эшендәге ялгышлар, авылда эшче көчләр белән бәйле күренешләргә дә язучы үз мөнәсәбәтен белдерергә тырыша. Мәсәлән, авылдан яшьләрнең китүе, эшче көчләрнең кимүе процессының А. Гыйләҗев мораль ягына игътибар итә.

«Берәү» повестеның драматизмы Исхакның туган җиреннән читләшә, аерыла башлавында. Якташлары, туганнарының, дөнья күргән олы кешеләрнең үзенә карата мөнәсәбәтләре салкынлык башлавын тою — егеткә иң кырыс һәм катгый хөкем. Исхак үз ялгышын аңлый башлый.

Мөгаен, мондый әсәрләрнең тууына яшьләрнең авылдан шәһәргә агылуы, авылның эшче кулларга ярлылануы кебек экономик-социаль процесслар сәбәп булгандыр. Тора-бара Аяз Гыйләҗев мондый борчылуларның үзеннән-үзе барлыкка килмәвен һәм алардан алай җиңел генә котылып булмавы хакында тирәнрәк уйлый башлаячак («Җомга

көн, кич белән», «Әтәч менгән читәнгә»), тормышның катлаулы һәм җитди проблемаларын чишкәндә кешегә күп очракта үз намусы, вөҗданы каршында бергә-бер калырга туры киләчәген, һәрвакытта да янындагы изге, ярдәмчел кешеләргә исәп тотып булмавын аңлаячак («Урамнар артында яшел болын», «Урталыкта»). Ә хәзергә, алтмышынчы еллар башларында исә, автор игътибарын тормыш проблемаларының үзара катлаулы бәйләнеше, комплекслылыгыннан бигрәк, аерым эмоциональ яклары — якты һәм караңгы бизәкләре, буяулары, күренешләре җәлеп итә.

Авторның конкрет сурәтләр белән эш итү осталыгы үсә бара. Әсәрдән-әсәргә юл сурәте, образ көчеп йөри. Тормыш юллары, шул юллардагы киртәләрне үткәндә кыенлыклар һәм сөенечләр... Кешеләрнең ихтирамын казану юллары... «Язгы кәрваннар» һәм «Дүртәү» әсәрләрендә сурәтләнгән көзге һәм язгы авыл, урман юллары күренешләре күз алдына рәссам сурәте рәвешендә генә килеп басмый, гүя үзеңне шул авыр юлларны үтүче хәлендә тоясың.

«Дүртәү» хикәясендә табигать үзе һәм кешенең физик халәте бергә тасвирлана. Хикәянең төп пафосы — караңгыдан яктыга таба бару. Вакыйгалар бер тәүлек эчендә сурәтләнә. Ә шулай да бу тәүлек, бигрәк тә төн, арбага икмәк төяп юлга чыккан дүрт яшүсмергә генә түгел, укучыга да мавыктыргыч, очсыз-кырыйсыз булып тоела.

Ниһаять, кыенлыклар артта кала, басынкы, төшенке, күңелсез күренешләр әсәр ахырында очраган картның мәгънәле әкияте белән алмашына. Хикәя геройлары — яшүсмерләр күңелендә дә зур үзгәреш була, аларның рухи яктыруы әнә шул сюжет тәмамланышы белән тәңгәл килә.

Әлеге ситуациянең тагын бер вариантын «Язгы кәрваннар» повестенда очратабыз. Вакыйгаларны бәйләүче композицион алым бер төрле: юл сынаулары һәм ашлык ташу булса да, бу әсәр бөтенләй башкача, якты, оптимистик сурәтләр, буяулар ярдәмендә эшләнгән. Ачлы-туклы яшәп кыш чыккан кешеләрнең бик авыр, җаваплы, газаплы һәм шатлыклы юлы бу.

Кыен минутларда юлчылар бер-берсенә ярдәмгә ашыгалар, авыррак йөкләрне үз чаналарына салып тартырга тырышалар, соңгы икмәк, бәрәңгеләрен бергә бүлешеп ашыйлар. Дуслык, татулык, бердәмлек мисалларын повестьтан бик күпләп китерергә мөмкин. Юл кешеләрнең мөнәсәбәтләрен, бу очракта ярдәмчеллекләрен күрсәтергә мөмкинлек бирә. Димәк, ярдәм сүздә түгел, эштә, гамәлдә күренә. Укучыны уңай мисаллар аша тәрбияләү омтылышы ачык. Авылдашларының үзара җылы мөнәсәбәтләре үтә табигый, самими, ышандыра — менә шушы үзара кайгыртучанлык, яхшылык тантанасы бигрәк тә ачык булып Ибраһим һәм Әлбинә мөнәсәбәтләрендә гәүдәләнә.

«Язгы кәрваннар»да җитди, моңсу лирик стиль өстенлек итә. Лирик штрихлар бик чамасын белеп кенә кулланыла, нәкъ әнә шул эчке күңел җылылыгы белән сурәтләнгән лирик хисси күренешләр әсәрнең гомуми лирик фонын билгели (язгы авыл пейзажы, ерактан ишетелгән моңлы җыр, герой уйларының салмак, эзлекле агышы һ. б.).

Язучы бу повестьта халкыбызның кунакчыл, кумәк эштә бер-береңне кайгырту, бер-береңә булышу кебек күркәм милли сыйфатлар ачык гәүдәләнгән кайбер әсәрләргә — Шәриф Камал, Галимҗан Ибраһимов иҗатларына таяна, шул традицияләрне дәвам итәргә чакыра.

Әсәрдә реалистик детальләр төгәллеге белән яшьлеккә хас югары романтик хисләр пафосы искиткеч матур үрелә.

«Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», «Берәү» повестьларының геройлары — сугыш чорында үскән авыл яшьләре — барысы да элек-электән бөртекләп җыелган, тупланган халык тәҗрибәсен, күркәм гадәт-карашларын хөрмәт итүче сабыр, акыллы, тыйнак, хезмәт кешеләренең шифалы йогынтысында тәрбияләнәләр. Әнә шул аларга дәһшәтле чор сынауларын намус белән үтәргә көч, мөмкинлек бирә.

Характерны формалаштыручы әлеге мохитне туган авыл, якын тирәлек рәвешендә генә сурәтләү берьяклы һәм кирәксез идиллиягә әверелеп китәргә дә мөмкин иде. Бәхеткә каршы, әдип иҗтимагый һәм көнкүреш мөнәсәбәтләренең чынбарлыкта шактый ук катлаулы, каршылыклы икәнлеген, әлегә без күрергә теләгән килешү — үзара аңлашу, гармония дәрәҗәсеннән түбәнрәк һәм ерраграк торуын вакытында сизеп алды.

«Җомга көн, кич белән» (1979) повестенда без кешеләр арасында эчкерсез, саф, дусларча, туганнарча мөнәсәбәтләр тарафдарын — Бибинур карчыкны очратабыз. Биредә А. Гыйләҗев повестьларын аз-азлап урата башлаган идиллиянең эзе дә калмаган. Укучыны менә нәрсә уйландыра: бөтен гомерләрен башкаларга багышлаган, кешеләр бәхете өчен яшәүчеләр үз ихтыяҗларына килгәндә артык тыйнаклар, үзләрен якларга алар күнекмәгәннәр һәм намуссызлык, битарафлык, әрсезлек каршында көчсезләр, башкаларга ярдәмчелләр кыен вакытта үзләре ярдәмсез калалар... Нинди зур гаделсезлек!

Рәхимсез, күпләргә шәфкатьсез булып тоелган финал — Бибинурның ялгызы, урман чокырында кыргыйлашкан этләр өере уртасында калуы — повестьның әнә шул уйланылышына гаҗәп төгәл туры килә, төп идея шул рәвешчә ассызыклана. Авылдашларының

битарафлыгы, якыннарының онытуы, туганнарының хыянәте шушы эпизодта яңача ассоциацияләнә һәм әсәрнең логик эзлекле, драматик тәмамланышы рәвешендә әсәрнең эмоциональ пафосын көчәйтә. Бибинур язмышы үзара ярдәмләшү, туганлык тойгыларын кадерләү, табигый кешелекле бәйләнешләр, кеше ихтыяҗына игътибарлылык кебек гадәти, гади һәм аңлаешлы хакыйкатьләр турында бик җитди уйландыра. Шушы гади хакыйкатьләр онытылып, әхлак кагыйдәләрен бозуга юл куелса — олы фаҗигага юл ачык дия сыман язучы.

Күренешләрнең асылы, эчке мәгънәсе, сәбәпләренә тирәнрәк төшә, якынрак бару белән сораулар кимеми, киресенчә, арта бара. Бибинур һәм Зөһрәбану, игезәкләр була торып та, ничек итеп аларның берсе мәхәббәт тарафдарына, ә икенчесе кешеләр нәфрәтләнерлек фигурага әйләнгән? Ни өчен үз канаты астына алып үстергән балалар Бибинурны онытканнар, ташлаганнар?

Аяз Гыйләҗев әнә шулай кешеләрнең үз-үзенә таләпчәнлеге кимегәндә котылгысыз әхлаксызлык, мещанлык, паразитлык дөньясына күчү процессын күзәтә, шул үзгәрешнең сәбәпләрен рухи ярлылык, рухи сукырлыкта күрә.

Әсәрдә Бибинур образының әдәби эшләнешенә, гаять үзенчәлекле булуына игътибар итми мөмкин түгел. Тәнкыйть героиня язмышы аша үтә җитди һәм актуаль проблемалар күтәрелүен бердәм билгеләп үтте, мөлаем характерга сокланып, бу биографияне күздән кичерде, образның социаль-мәгънәви функциясенә анализ ясады.

Шуның белән бергә, «Җомга көн, кич белән» повесте төзелеше, әдәби стиль, сурәтләү чаралары сайланышы белән дә үтә үзенчәлекле әсәр — әгәр бу игътибардан читтә калса, анализ һәм бәя тулы булмаячак.

Бибинур образы повестьның буеннан-буена үтә. Фәкать беренче бүлек кенә башка персонаж турында. Биредә сүз Бибинур тормышында хәлиткеч роль уйнаган кеше — колхоз председателе Җиһангир Сәфәргалин турында бара. Беренче бүлектә үк аның үлеме тасвирлана — кешеләр бәхетенә гомерен багышлаган коммунист Җиһангир алар тормышында якты эз, ә Бибинур күңелендә матур мәхәббәт хисе кабызып, дөньядан иртә китеп бара. Бибинур күңелендә аның турында хатирәләр кат-кат яңарачак әле — истәлекләр, уйланулар аша Бибинурның тормыш сәхифәләре яктыртыла, характерның төрле яклары ачыла бара.

Образның үтә җентекләп эшләнүенә, ышандыру көченә күп төрле юллар белән ирешелә: Бибинурның кешеләр белән бәйләнеш җепләре бөтен нечкәлекләре, бөтен ваклыкларында тасвирлана. Сүз уңаенда героиняның үз эченә бикләнгәнрәк икәнлеген дә искәртик. Шулай булгач, Бибинур — Җиһангир, Бибинур — Зөһрәбану, Бибинур — авылдашлары һәм Бибинур белән ул үстергән балалар арасындагы мөнәсәбәтләрне шактый ук детальләп сурәтләргә кирәк булган. Бу мөнәсәбәтләр максималь тулылыгында бирелә, биредә кабатлаулар да урынлы, мөнәсәбәтләрнең үзләре урынына, шул кешеләр турындагы уйлар, фикер йөртүләр дә күп очрый.

Аяз Гыйләҗев тормыш-көнкүреш штрихларының дәрәҗәсе, төгәллегенә һәрвакыт тугры булды, бу — аның әһәмиятле кредосы. «Җомга көн, кич белән» повестенда мондый төгәллек бик зур роль уйный — героиняның ышандыру һәм тәэсир көчен арттыра.

Икенче бер принцип — ул язу манерасының мавыктыргыч, гади, аңлаешлы һәм кызыклы булуына ирешү.

Характер сайланышы һәм яктыртылышына тукталыйк. Гомумән, яшьләр турында язарга яратучы Аяз Гыйләҗев бу повесть үзәгенә олы кеше — тәҗрибәле, тормышның ачы-төчесен татыган, гомере юлының ахырына якынлашып килүче кеше образын куя. Бу өлкәдә татар прозасы туплаган тәҗрибә шактый зур. Шундый образ — характер аша җитди актуаль проблемалар кую мисалын язучы Әмирхан Еникиның «Әйтелмәгән васыять» хикәясендә очраткан идек.

Бибинур образының драматизмы капма-каршы куюга нигезләнгән. Ул гомерен башкаларга багышлаган, тик кешеләргә булган олы мәхәббәте җавапсыз калган. Тәрбияләп үстергән балалары аны онытканнар. Фаҗигале үлеме — коточкыч гаделсезлек, эшәкелек тантанасы булып аңлашыла. Мондый гаделсезлек, мондый хәлләргә юл куярга ярамый, күңел сукырлыгыннан котылырга кирәк — әнә шулай укучыда тискәре күрешләргә карата актив мөнсәбәт, мондый күренешләрне кабул итә алмау, кире кагу мөнәсәбәте тәрбияләнә.

Повестьның катлаулы композицион структурасында поэтик детальләр бик зур роль уйный. Мәсәлән, поэтик рефрен — авыл читендәге буаның шаулаган тавышы — гомер агышының символы һәм героиняның уйлары истәлекләр дөньясына юнәлүен ишарәләүче бер билге ул. Гади көнкүреш вакыйгалары һәм баш геройның соң чиккә җиткән күңел сыкравы янәшә куелганда бу детальнең тәэсир көче арттыра көчәя: «Бибинур карчык та көтте. Бер кайтырга тиеш бит инде алар! Җаннары булса, аналары янына Сабан туена бер кайтырга тиешләр!

Почта кызлары гөр-гөр килеп сөйләшәләр, алар Бибинур карчыкны юри күрмәмешкә салышалар. Алар карчыкның ни көткәнен бик яхшы аңлыйлар.

Ә буа шаулый. Шаулый! Җиһангир Сәфәргалинны озаткандагы кебек ул моңсу шаулый...

Буа. Почта. Ялгыз һәйкәл...

Буа тавышы бер акрыная, бер көчәя. Бибинурга гына шулай тоеладыр ул, чөнки аның зиһене кинәт кенә томаланып куя, аннан тагын ачыла... Ул егылып китмәс өчен чытырдатып күзләрен йома... Егылмый, турая, күзен ачканда буа тагын да ныграк шаулый башлый. Әллә кайларга чакырып шаулый буа!»

Аяз Гыйләҗев житди проблемаларны укучыга җиткерүнең яңа юлларын эзли. Беренче карашка җиңел һәм мавыктыргыч булып тоелган вакыйгалар, сюжет конструкцияләре, җитди фикерләр алып киләләр, укучы аңына катлаулы сораулар куялар, уйландыралар. Моның иң уңышлы мисалы — «Җомга көн, кич белән» повесте. Мондый эзләнүләр «Өтәч менгән читәнгә» повестенда (1980) да дәвам иттерелде. Бу — ыгы-зыгылы, шаян, күп бизәкле, бетерелмә, үтә уйнак бер тонда язылган әсәр. Әдип әхлак, яшьләр тәрбиясе, олыны — олы, кечене — кече итә белү кебек җитди әйберләр хакында да сүз кузгата.

Язучыны кеше тормышының көнкүрештәге гадәтилегеннән бигрәк, кискен рухи үзгәрешләре кызыксындыра. «Урталыкта» (1971) повестеның үзәгендә иҗат кешесе образы тора. Сәгыйть әкрен-әкрен олы идеалларын оныткан, аның интерес-ихтыяҗлары күбрәк дача, йорт-җир кирәк-яраклары, кәеф-сафа яратучы дусларының күңелен күрүдән читкә китми башлаган. Иҗатында да торгынлык — ул чын иҗатчы булудан бигрәк гап-гади һөнәрчегә әверелеп бара. Үзенә карата туры сүзне күзгә карап әйтүчеләр белән ачуланышкан, сүзгә кергән. Әнә шундыйларның берсе — гадел, намуслы режиссер Баязит Гарифуллинның тезәлмәслек чир белән авырып китү хәбәре Сәгыйть күңелен тетрәтеп, үзгәртеп җибәрә. Остазы белән очрашып, сөйләшеп, аның бәхилләшү сүзләрен алу герой өчен үтә җитди бер нәрсәгә әверелә. Бу очрашу, сөйләшү булачакмы, юкмы — әсәр сюжетының төп сызыгы да шуннан уза. Чөнки ул Сәгыйтьнең алга таба бөтен тормышының мәгънәсен билгеләячәк.

Повесть авторның «мин»е исеменнән алып барыла. Ләкин геройның иҗат кешесе булу факты шулай да бу әсәрне автобиографик әсәр дип атарга мөмкинлек бирми әле. Аяз Гыйләҗев повестьны биография мотивларына максималь якынайтып, фәкать бер бурычны күздә тоткан: ул укучыга күңел тупаслануы, әхлак позицияләрен югалту, мещанлык чире һәркайсыбызга яный, һәрвакыт чын кеше булып кала белегез, дип искәртә.

Әдип иҗатында, шул рәвешчә, тагын бер тематик юнәлеш — «шәһәр» линиясе, шәһәр яшьләре, интеллигенция темасы нык үсеп килә. Алтмышынчы-җитмешенче елларда язучы иҗатында бу тема зур урын алып тора. Шулай да йөрәктән кичереп язылган әсәрләр күбрәк авыл материалына карый кебек. Шәһәр повестьларының кайберләре уртача беллетристик әсәрләр дәрәҗәсеннән югары күтәрелмәделәр (мәсәлән, «Күзгә-күз», «Мең чакрым юл» повестьлары). Бу урында Аяз Гыйләҗев иҗатының сыйфат ягыннан бик үк тигез булмавы хакында да әйтергә туры килә.

Ләкин «шәһәр» әсәрләрен дә әдипнең төп иҗат магистраленнән читкә куеп карамаска кирәк. Бирedә сүз идея, максатлар аермасыннан бигрәк, тормыш материалы арасындагы аерма турында гына була ала.

«Зәй энҗеләре» (1963) повестенда А. Гыйләҗев заман героен иҗат итү юлында шактый уңышлы адым ясады. Әсәрдә төзелеш мастеры Гәрәй Шаминның чын тормыш борчулары, эш мәшәкатьләре, шатлыклары, үзе инанган максатка бару юлындагы киртәләрне җимерү, вакытлы җиңелүләрнең ачысы — барысы да вакыйгалар тезмәсе рәвешендә генә түгел, ә күңел хәрәкәте аша җанландырып сурәтләнә. Яшь белгечнең осталыгы арту үзеннән-үзе аңлашыла, әмма безне, барыннан да бигрәк, Гәрәй күңелендәге үзгәрешләр кызыксындыра. Повестьны чын-чынлап Гыйләҗевныкы иткән бер сюжет сызыгы барлыкка килә: күмәк эшне оештыру барышында Гәрәйнең үз күңеле тупаслана, ярлылана бара. Мастерның дорфалыгыннан намуслы, яхшы эшчеләр дә интегә башлыйлар.

Әсәр ахырында Гәрәй — Гәүһәр мәхәббәте белән бәйләнгән сюжет сызыгы геройны рухи савыктыру функциясенә буйсындырыла. Кызганычка каршы, нәкъ шушы урында автор кинәт кенә вакыйгаларны җентекләп дәлилләү принцибыннан читләшә, һәм, әйтергә кирәк, мондый игътибарсызлык яисә ашыгу сәбәпле әсәрнең бик матур, җитди уйланылган идеясе — кеше рухын олылау, бер-береңне аңлау, аңларга омтылу кирәклеге идеясе тоныкланыбрак кала.

«Урамнар артында яшел болын» дип аталган роман да (1969) заманыбыз кешеләрен борчучы проблемаларның муллыгы һәм үзенчәлекле төзелеше белән игътибарны җәлеп итә. Иң алгы планга кешенең җәмгыять, халык, ил алдында җаваплылыгы, бурычы мәсьәләсе куела. Бу сорау романның баш геройлары — яшь журналистлар Идрис һәм Әхәт алдында да тора. Характерлары, табигатьләре белән бер-берсеннән нык аерылсалар да, бу ике егетне үзара якынайта торган яклар да бар — икесе дә намуслы, әйбәт булсын дип эшләүче, профессиональ яктан югары әзерлекле, культуралы, мәгълүматлы кешеләр алар. Идрисне дә, Әхәтне дә Җир шарындагы хәлләр, кешелек язмышына кагылышлы хәбәрләр уйландыра һәм борчый. Сүз, әңгәмә уңаенда аларның әдәбият, сәнгать, культура өлкәсендә дә хәбәрдар, яхшы хәзерлекле булулары аңлашыла. Биредә сюжет агышына турыдан-туры бәйләнмәгән, очраклы рәвештә, сүз уңаенда гына әйтелгән

реплика-штрихларга да укучы игътибарлы, сизгер булырга тиеш. Алтмышынчы еллар татар прозасы өчен бу да яңарак, сәеррәк күренеш иде. Биредә Аяз Гыйләҗев түбәндәге хакыйкатьне истә тота: һәр яңа әсәрдән алдынгы фикерләр, тирән эчтәлек, тәрбияви эффект таләп ителә икән, бу үз чиратында, яңа әдәби формалар, алымнар, күңел дөньясын сурәтләүнең дә башка чараларын сорый.

«Урамнар артында яшел болын» — нигезенә әйбәт, якты фикер салынган, чын дуслык, тугрылык, совет җәмгыятендә кешенең кешегә булган мөнәсәбәтләренең матурлыгы идеяләрен яклаучы әсәр дип бәяләнде. Шуның белән бергә, әдәби җәмәгатьчелек бу әсәрнең композицион яктан таркаурак булуына да игътибар итте. Мәсәлән, Ә. Еники фикеренчә, роман «бер мәсьәлә белән тоенләнгән, бер фикер һәм хис белән сугарылган булырга тиеш. Әмма әсәргә бөтенләй җитеп бетми. Анда өч төрле сюжет бар, өч төрле проблема күтәрелә. Әсәрдә баланың тирә-юньгә мөнәсәбәте шактый киң бирелгән. Ә автор романда шундый зур проблеманы ташлап, икенче бер мәсьәләгә күчә, укучыны ярты юлда туктатып калдыра». («Социалистик Татарстан» газетасы, 19 июль, 1970 ел.)

Планета язмышы, кыләчәге өчен борчылучы журналист егетләр («Урамнар артында яшел болын»), кешеләр бәхетенә бар булган гомерен багышлаган колхоз председателе Җиһангир («Җомга көн, кич белән»), үз эшенә, туган ягына сокланып яшәүче Галимҗан («Үги ана яфраклары») һәм башка бик күп шундый геройлар әдипнең иҗат йөзен, күтәренкелеген, оптимизмын билгелиләр. Менә шуларның берсенә тукталып үтик. Колхоз шоферы Галимҗан («Үги ана яфраклары») өчен бу гадәти эш көне түгел. Бу — аның күңел хисләре ташыган, нечкәргән вакыты. Бүген ул сөйгән кызы Сөмәясе белән аңлашачак, көне буе күңеленнән шуңа хәзерләнеп, уйланып йөри. Көзге кыр эшләренең кызулыгы, бертөрлелеге фонында геройның күңел очышы, омтылышы аеруча матур сурәтләнә.

Кинәт кенә алдан исәпләнгән план-хыяллар юкка чыга — кичен икмәк төяп станциягә — өстәмә рейс белән юлга чыгарга кушалар. Бурыч һәм бәхет арасындагы дилемма — хикәянең характерын да, төп идеясен дә ачардай үзәк нәкъ шушы урында. Шәхси бәхет һәм иҗтимагый бурыч шушы нигездә үзара бәрелешәләр. Биредә эчке көрәшнең булмавы мөмкин түгел — егет үзенең хис-тәләкләрен йөгәнләргә мәҗбүр. Шулай да Галимҗанның үз-үзен тотышында да, эчке уйларында да, инстинктив рәвештә генә булса да, канәгатьсезлек сизелми. «Аның күңел капкасы башкалар өчен ябык, бикле иде».

Шулай да, әйләнә-тирәдәге җансыз әйберләр аша рухи халәт ачыла: «Мотор теләр-теләмәс кенә кабынды». «Көне буе ак күлмәк якасының аклыгын саклап йөргән иде, хәзер күлмәгә дә каралды. «Әй, хәзер барыбер инде».

Теләр-теләмәс кабынган мотор да, ниһаять аклыгын җуйган күлмәк тә — тышкы атрибутлар — әмма алар язучының чын иҗат табышлары. Рухи хәрәкәтне бу күренештә шулар аша гына белеп була.

Автор характерлар контрастлылыгын да ныклап эшкә җигә. Биредә начар белән яхшының пычакка-пычак килеп бугазлашуы юк. Сүз дөньяга, тормышка карашларның төрлелеге турында бара. Грузчик Хәнәфинең килеш-килбәте, үз-үзен тотышы, тупас теле — берсе дә Галимҗандагыча түгел. Хәнәфинең дөньяга сокланучан Галимҗанга төбәп: «Гомер үтте күләгә булып, шәүлә булып» дип әйтелгән сүзләрендә әлеге аермага бигрәк тә басым ясала. Ә инде Хәнәфи өстәмә рейстан баш тартып, машинадан ук төшеп калгач аерманың сүздә генә түгел икәнлегенә төшенәсең.

Галимҗанга да шушы юлдан китәргә була иде бит, ләкин характер үсешенең логикасы моңа туры килми шул — әсәрдәге янәшә һәм капма-каршы куелган детальләр тезмәсе ачык идея бурычына буйсындырылган, әдипнең симпатиясе Галимҗан ягында. Геройның матурлыгына укучыны да сокландыру максатында автор байтак сурәтләү чаралары куллана: үзенчәлекле диалог, табигать параллельләре, образлар контрастлылыгы, һ. б.

«Үги ана яфраклары» әдипнең әдәби техника, форма өлкәсендә ачылмаган мөмкинлекләре гаять зур булуын раслаучы иң яхшы хикәяләреннән иде. Аның иҗатында иң төп казанышлар да хикәя һәм лирик повесть жанрларында ирешелде. Роман, озын повесть юнәлешендәге эзләнүләр аңа әлегә тиешле, көткән нәтиҗәләрне биреп җиткермиләр. Аерым уңышсызлыклар, кагыйдә буларак, композиция пропорцияләренә игътибар җитмәгәндә күзәтелә. (Мәсәлән, «Мең чакрым юл»). Татар лирик прозасының иң яхшы традицияләреннән берсе — кешене табигатьнең иң гүзәл, иң камил заты итеп карау, уңай характерларның олылыгын табигать матурлыгы гармониясенә тәңгәл кую — Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә уңышлы дәвам иттерелә.

Хәзерге проза стильләренең бай һәм шактый чуар фонында Аяз Гыйләҗевның эзләнүләре аеруча игътибарга лаек. Менә шушы — яңалыкны сизү, раслау тойгысы әдипнең бөтен иҗат юлы дәвамында шактый эзлекле үткәрелеп килә — ул һәрвакыт яңалык, ачыш эзли, тормыш күренешләрен башкачарак, үзенчәрәк күрә һәм аңлата. Ә болар, реализм әдәбиятының башка бик әһәмиятле таләпләре: югары принципиальлек, сәнгатьчә осталык, заманчалык, тормышчанлык, халыкчанлык, партиялелек онытылмаган очракта уңай нәтиҗәләр бирми калмый.

# ТӘРҖЕМӘ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

**Журналыбызның быелгы 2 санында Р. Сафаров һәм Л. Леронов хатлары буенча тәрҗемә турында сөйләшү башланып киткән иде. Аннан соң дискуссияне М. Рафиков, Р. Кукушкин, Н. Арсланов, Р. Юсупов, Ә. Баянов, Л. Хәмидуллин дәвам итте. Бу санда сүзне шагыйрьләр Әхмәт Исхак һәм Рәдиф Гатауллин ала.**

## Әхмәт Исхак:

Әдәби әсәрләрне бер телдән икенче телгә тәрҗемә итеп, төрле милләт укучыларын ул әсәрләр белән таныштыру, һичшиксез, халыкларның үзара аңлашуына, якынлашуына, бер-берсен ихтирам итүенә һәм дуслашуына хезмәт итә.

Сугышка кадәрге һәм бигрәк тә сугыштан соңгы елларда бик күп халыкларның проза һәм поэзия әсәрләрен һәм җыентыкларын тәрҗемә итү бездә шактый күләм алган иде. Бу исә бездә художество ягыннан югары сыйфатлы тәрҗемә әсәрләр тудыручы талантлы кадрлар үсүгә һәм ишәюгә дә хезмәт итте. Мин андый әсәрләр һәм кадрларны санап тормыйм. Бу һәркемгә мәгълүм. Ләкин соңгы вакытларда бу эш беркадәр сүрәнләнде шикелле. Бигрәк тә мондый хәл поэзия әсәрләрендә үзен сиздерә. Ихтимал, моның җитди сәбәпләре дә бардыр. Ләкин мин мондый хәлне нормаль дип исәпли алмыйм һәм әдәби җәмәгатьчелегебезнең игътибарын шуңа юнәлдерергә телим.

Тукай, Такташ һәм Муса Җәлил әсәрләренең русчага тәрҗемәләре әлегә тулысынча канәгатьләнерлек дип әйтеп булмый. Тукай һәм Такташ әсәрләренең тәрҗемәләреннән беркадәр өлешен редакцияләү процессында мин андый кимчелекләрне бетерергә тырышып карадым, ләкин канәгатьләнерлек нәтиҗәгә ирешә алмадым. Моның сәбәбе, минемчә, оригиналның телен барлык нечкәлекләре белән белүче тәрҗемәчеләрнең булмавында. Бүгенге көндә бездә татар теленнән турыдан-туры рус теленә тәрҗемә итүче яшь кадрлар үсеп килә, ләкин алар әлегә җитәрлек санда һәм зур тәҗрибәле түгел. Бу өлкәдә безнең күп эшлисебез бар.

Тәрҗемәнең сыйфатына кагылганда, мин беренче урынга оригиналның телен камил белү кирәклеген куйдым. Чөнки бу — тәрҗемәнең иң мөһим төп шарты. Мин үзем тәрҗемә иткән күп санлы поэма һәм шигырьләрнең иң зур күпчелеген оригинал теленнән (рус, украин, белорус, казах, төрекмән, әзербәйҗан, үзбәк, уйгур һ. б. телләрдән) тәрҗемә иттем. Кулымда оригинал булмаганда соратып алырга, оригиналның теле шундук аңларга кыен булганда, ул телне өйрәнергә тырыштым (мәсәлән, Нәваиның «Фәрһад вә Ширин» поэмасын тәрҗемә итү өчен миңа борынгы үзбәк телен өйрәнергә туры килде).

Оригиналның телен белмәгән очракларда тәрҗемәчегә подстрочник дигән нәрсә, ягъни, әсәрне сүзгә-сүз яки юлга-юл тәрҗемә иткән прозаик текст ярдәмгә килә. (Безнең татарча әсәрләребезнең һәммәсе диярлек русчага шундый подстрочник аша ителәләр). Бу чара тәрҗемәнең сыйфатына йогынты ясамый калмый. Чөнки ул подстрочникны эшләүченең һәр ике телне барлык нечкәлекләре белән белү яки белмәвенә бәйләнгән. Ә тәрҗемә итүче исә, аңа тулысынча ышанып эш итә һәм подстрочникны художестволы итеп эшкәрткәндә, үз теләнә буйсындырып үзгәрешләр кертми калмый. Күпчелек очракта бик яхшы тәрҗемәләр килеп чыга, ә кайчакта исә, «куян шулпасының шулпасы» гына килеп чыга. Подстрочник ярдәме белән эш иткәндә, кем соң бирәдә тәрҗемәнең авторы — подстрочник ясаучымы, әллә тәрҗемәчеме, дигән сорау туарга мөмкин. Моның җавабы бер генә: автор, әлбәттә,— подстрочникны художестволы әсәр итүче тәрҗемәче.

Төрле халыкларның әсәрләрен татарчага күчергәндә, ул әсәрнең русчага тәрҗемә ителгән тексты аша тәрҗемә итү юлы да бар. Мин андый юлны бик ашыгыч хәлләрдә генә (мәсәлән, төрле даталар, юбилейләр өчен ашыгыч рәвештә кирәк булганда) куллану ягында торам. Мондый юл белән тәрҗемә иткәндә, оригинал барлык башка чараларга караганда да күбрәк югалта.

Чөнки монда русчага тәрҗемә итүченең йомшак үзен сиздерә. Мин моны Җамбул шигырьләре җыентыгын тәрҗемә итәргә бирелгән заказны үтәү процессында ачык күрдем. Минем кулда Җамбул әсәрләренең оригиналы юк иде. Мин аны эзләп таптым һәм русчага тәрҗемәләре белән чагыштырып карадым. Аерма зур иде. Шигырьләрнең кайбер строфалары төшереп калдырылган, кайберләре икенче урынга күчерелгән, сурәтләү чаралары үзгәртелгән, милли колорит бик күп урында югалган иде. Мин оригинал аша тәрҗемә итү юлын сайладым.

Әсәрне бер телдән икенче телгә тәрҗемә иткәндә, хәтта иң талантлы тәрҗемәче нинди зур осталык кулланмасын, оригинал барыбер беркадәр югалтуга дучар булмый калмый. Бу хәл бигрәк тә поэзия әсәрләрендә урын ала. Кайвакыт аның үлчәме яки ритмы туры килми. Нәтиҗәдә музыкаль яңгырашы бозыла. Кайвакыт милли сурәтләү чаралары, икенче телдә яңгырамау аркасында, башка чаралар белән алмаштырылып, әсәрнең милли колориты югала. Төрле телдә аерым сүзләр төрле озынлыкта булганлыктан, кайбер юллар юлга сыймаганлыктан яки төшеп калалар, яки юлларның саны арта, оригиналдагы иң матур рифмалар һәм аллитерацияләр юкка чыга һ. б. Моңа бер мисал рәвешендә Тукайның «Күңел» исемле шигыренең русчага тәрҗемәсен китерергә була. Аны танылган тәрҗемәче Р. Моран бик матур тәрҗемә иткән, ә менә рифмалары Тукайдагыча (сызлансыкган, сүнгән-күнгән һ. б.) яңгырашлы түгел, кайберләрен бөтенләй рифма дип әйтеп булмый (не вновe — надломленное, погасло — привыкнувшее, стремящееся — стремящееся һ. б.).

Уңышлы тәрҗемәнең тагын бер шарты — тәрҗемә ителә торган әсәр авторының яшәү шартларын, тарихын, культурасын, йола һәм гадәтләрен белү кирәклеге. Шулай булмаганда, мәзәк хәлләр килеп чыгуы да бик ихтимал. Мисалга Тукайның «Бәйрәм вә сабыйлык вакты» дигән шигыренең элекке тәрҗемәләреннән берсендәге ике строфаны китерергә була. Татарчасы аның болай:

Төшә искә Гарәфә көн яткан чагым,

Уйлап, кайчак таң дип, ул атмаган таңым.
Тәти читек, тәти күлмәк, штаннарны
Баш астыма өеп куеп яткан чагым.

Бу юллар русчага болай тәрҗемә ителгән иде:

Припомнишь Гарафи канун, когда со сном борясь,
Ждал той зари, что и досель, увы, не занялась.
Припомнишь блузу и штаны — дню торжества подстать, —
Что — ими горд — клал в головах, бросаясь на кровать.

Революциягә кадәрге татар авылында нәни Тукай сәкедә яки идәндә түгел, тимер караватта ятып йоклаган булып чыга иде.

Милли колоритның бозылуын Л. Пеньковский кебек тәҗрибәле тәрҗемәченең иҗатында да очратырга була. Мәсәлән, Нәваиның «Фәрһад вә Ширин» поэмасындагы көнчыгыш шагыйрьләренә хас арттырып сөйләү алымы бик мәгънәсез тәрҗемә ителгән.

Бергә җыеп әйткәндә, тәрҗемәнең төп принциплары мондый: бернинди иреклелеккә бирелмичә, авторның төп фикерен, әсәрнең эчтәлеген укучыга төгәл ирештерү, оригиналның ритмик төзелешенә туры килә торган үлчәмне табып куллану, язылышының һәркем аңларлык дәрәҗәдәге гадилеген һәм милли колоритын саклау, үзлегеңнән бер генә сүз һәм образ да өстәмәү яки төшереп калдырмау, шул ук вакытта тәрҗемәченең үз телендә язылган оригинал әсәр кебек яңгыравына ирешергә омтылу. Тәрҗемәдә әсәрнең эчтәлеген һәм авторның фикерен бирүне иң беренче шарт итеп куюны нигезләү өчен В. Г. Белинскийның шигырь турындагы түбәндәге сүзләренә таянырга була: «Шома һәм яңгыраулы шигырь, эчтәлектән башка хәлдә, бары тик поэтик формага сәләтне күрсәтә... Шигырь поэтик булсын өчен шомалык һәм яңгырау җитми генә түгел, хис кенә дә җитми: фикер кирәк, һәр поэзиянең чын эчтәлеген шул тәшкил итә» (Өчтомлык, т. 2, бит 244).

## Рәдиф Гатауллин:

Күптән түгел миңа Мәскәүдә шигърият буенча Бөтенсоюз киңәшмәсендә катнашырга туры килде. СССР Язучылар союзы идарәсе уздырган бу киңәшмәдә бүгенге поэзия турында барган сүз, әлбәттә, тәрҗемә мәсьәләләрен дә читләп үтмәде: рус һәм тугандаш республикаларның вәкилләре, күренекле шагыйрьләр — Е. Исаев, Д. Кугультинов, Г. Абашидзе, И. Тарба, И. Драч, Р. Бородулин, Ю. Шесталов һ. б. русчага тәрҗемә, Мәскәүдә басылган шигырь китаплары турында да сөйләделәр. Тәнкыйть гадәттәгечә, сыйфатка — начар тәрҗемәчеләргә һәм подстрочникларга, бу эшнең күп очракта кәсеп булуына кагылды. Очраклы тәрҗемәләр, очраклы авторлар... Бу зур хезмәткә яратып, олы максатлар белән тотыну кирәклеге, тәрҗемә ителә торган шагыйрьне һәм халыкның тарихын, телен, мәдәниятен, рухын чагылдыручы милли атрибутларын, фольклорын, традицияләрен белмәү очраклары турында әйтелде... Шул ук вакытта яхшы тәрҗемәчеләрнең эше дә искә алынды. Югарыда саналган, киңәшмә-

дә катнашкан зур шагыйрьләр иҗаты да бөтенсоюз укучысына әйбәт тәрҗемә аша барып җитте бит! Әдәбиятларның үзара аңлашуы турында, милли әдәбиятларның, шагыйрьләренең ил күләмендә танылуын билгеләп, Д. Кугультинов, мәсәлән, Тукай һәм Җәлил шигъриятенә дә тукталды, геройшагыйрьне ничек тәрҗемә итүен дә искә алды...

...Үз чыгышымда миңа да тәрҗемә аша инде илгә танылган шагыйрьләребез, шулай ук русча китаплары белән киң яңгыраш алып килүче урта буын вәкилләре һәм әлегә тәрҗемәчесен көткән, әмма заманча яңгырый алачак, үзенчәлекле күп шагыйрьләребез турында сөйләргә туры килде...

Сибгат ага Хәкимнең соңгы елларда язган поэмалары бөтенсоюз укучысына барып иреште. Бу — сөенечле хәл. Әмма шагыйрь И. Юзеев, Ә. Баянов, Р. Мингалим поэмалары әле тиешенчә яңгыраш алды дип әйтә алабызмы? Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Г. Рәхимнәрнең яхшы тәрҗемәләренә куанабыз. Әмма Н. Арслан, Роб. Әхмәтҗанов, Зөлфәт, С. Сөләйманова, Ф. Яруллин һ. б. шагыйрьләрнең бүгенге тәрҗемәләре рус укучысының күңелен яулый алырлыкмы?

Ә классика?! Быел, зур юбилейлары елында, бөек Тукайның да, Такташ, Туфан, хәтта Җәлилнең дә үзебез күрергә теләгәнчә бик яхшы, милли колоритны саклаган тәрҗемәләре бармы?! Үз бөеклегендәме алар?! Димәк, аларга аерым бер игътибар, хәзерлек белән зур шагыйрь-тәрҗемәчеләр алынырга тиеш... Шигырьне — чын шигырь теленә,— эчтәлек сөйләп кенә яки формаль рәвештә генә түгел,— бөтен рухы, моңы, образлы җаны, югары шигърилек белән тәрҗемә итүне һаман әле көтеп калабыз. Бу — озак өйрәнүне, ил-халыклар тарихын, милли үзенчәлекләрне белүне таләп иткән дәвамлы, күп көч сораган эш.

Киңәшмә вакытындагы тәэсирләрем, уйланулар булып «Литературная газета»да барган бәхәскә ялганды: тәрҗемә турындагы дискуссиядә катнашкан тәҗрибәле, талантлы, ышандыра алырлык аргументлар табучы иптәшләрнең сүзенә колак салсак, һаман үзебезнең хәлгә — үз тәрҗемәләребезнең «тәрҗемәи хәл»енә әйләнеп кайтырбыз.

Әле утызынчы еллар башында ук М. Горький инициативасы белән башланган милли әдәбиятларны тәрҗемә итү эшенең бүген инде шактый зур тарихы, сабаклары бар. Әмма алда торган сораулар да шул көе кала бирә: тәрҗемә өчен тел белү зарурмы? Подстрочник булу җитәме? Әллә тәрҗемәченең эрудициясе, культурасына бәйле яңа бер версия, продуктмы ул тәрҗемә әсәре?!

Укучылар күңелен яуласа, оригиналдан ераклашса да мөмкиндер бит? Кайсы яхшырак?

...Әлбәттә, бәхәсләрнең нигезе бик дөрес: тел белү мәсьәләсе... Узган гасыр тәрҗемәчеләре, яки безнең йөздә В. Брюсов (антологиясе өчен кирәк булгач, хәтта әрмән телен дә өйрәнгән!), Блок, Маршак, Пастернак... Болар — тәрҗемәнең күп телләр белгән бөек осталары.

Әмма безнекеләр? Милли шагыйрьләрнең тәрҗемәчеләре безнең телләрне белә, өйрәнә аламы? Ә татарчаны белмәсә дә, А. Ахматова тәрҗемәләре начар булдымыни? Яки Тарковскийның көнчыгыш шагыйрьләреннән тәрҗемәләре? Пастернак та, грузин телен белмәвенә карамастан, шагыйрьләренең классик тәрҗемәсен эшли алган бит. Димәк, бу — югары культура, чын талантка бәйле?! Ләкин бит алар турында язганда да, бу тәрҗемәләрнең төгәл булмыйча, бәлки зур шагыйрьләр тудырган вариант-версия булуына ишарә итәләр. Юкка гына Н. Бараташвилиның «Зәңгәр төс» шигыренең Пастернак тарафыннан классик тәрҗемәсе яки Галактион Табидзеның «Мэри» кебек шигыре (Ахмадуллина) варианты турында бәхәс алып бармый бит грузин тәнкыйтьчеләре... Димәк, грузин укучысы, тәрҗемәсе нинди генә шәп булмасын, камил үзенекен якын итә, оригиналны яклый...

Назыйм Хикмәтнең дә К. Симонов белән очрашып, танышкач ук, тәрҗемә турында бәхәскә кереп, үз шигыренә тәрҗемәче «өстәгән матурлыклар, ялган бизәкләр» белән килешмәвен әйтүе, ягъни шигырендәге фикерен, гадилеген яклавын искә алыйк...

Ә без үзебез соң? Тәрҗемә китапларыбызны алып актарсак, кайчак шигыребезне таный да алмыйбыз лабаса! Ягъни яхшырткаңнар, шомартканнар, тел чатаклыклары, томанлы фикерләр, сурәтләр юкка чыккан — кыскасы, рәхимле тәрҗемәчеләр безнең өчен шигырьне эшләп үк биргәннәр лабаса! Тәрҗемәчеләребезнең дә төрлесе бар... Татарчасын да укып, төгәл тәрҗемә итә алган Р. Бөхараев кебек уңган, сәләтле, ике телне дә белгән шагыйрьләргә рәхмәттән башка сүз юк.

Әмма бу дөресме?!. ...Барыбыз да тәрҗемә ителергә, хәтта беребездән беребез уздырырга тырышмыйбызмы? Һәр язганыбыз да лаекмы тәрҗемәгә? Хәзер хәтта үз телебездәге шигырь белән танылу тапмаган, хәтта шигърилектән мәхрүм үк кайберәүләр дә рус теле аша, яки Мәскәү аша шигърияткә «килү», шагыйрьлек хокукы алу юллары эзлиләр. Аларга каршы нишли аласың? Алар — әрсез... Подстрочник аша шигырьнең логик конструкциясе белән яңа шигырьгә, фикер, фәлсәфәгә дәгъва кылалар, хәтта тәрҗемәчене ышандыралар (ул, әлбәттә, бу иптәшләрнең тәрҗемәсе чыгу фактының гына да бездә сәерсенү тудыруын белмәс... Белсә дә, изгелек эшләү, яки «провинциядә

аңланмаган бөек»не яклау йөзеннән дә тәрҗемә итәр...) Шәхси симпатия, дуслык, әшнәлек мөнәсәбәтләре дә үтеп керә бит әле бу эшкә. Безнең көннәр гримасасы бу! Һәм әлеге тәрҗемә итә торган шагыйрьнең телен, нигезен белмәү бәласе!

...Тәрҗемәдә әсәрнең үз вакытында күренүе дә мөһимдер. Юкса, 60 яки 70 елларда язылган, үзебездә танылу тапкан әсәрнең 80 елларда русча басылуы бүгенге укучыга яңалык китерерме?.. Классиклар белән әле икенче хәл: яхшы биографик аңлатма, иҗат тарихы белән бай материалга төреп бирелсә, зур кыйммәтле әдәби әсәрләр анахронизм булмаячак, әлбәттә. Әмма бүгенге, агымдагы шигъри әсәрләр белән эш башка. «Онытылып» торган яки тәрҗемә чираты көткән шагыйрьләребезнең русча басылгач яңгырамавы шуңа да бәйләнгәндер. Хәер, бөтенсоюз укучысын «шаккатырыр» күп әсәрләребез басылмый — тәрҗемә ителми ята дип тә әйтә алмас идек. Сүз — кайбер иптәшләрнең тәрҗемә китабы булмау турында. «Чират» аларга да җитәр... Әмма, нәтиҗәләр турында да бергәләп уйларга кирәктер. Тукай, Дәрдмәнд, Такташ, Җәлил, Туфан, Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи һ. б. аз һәм өлешчә яхшы тәрҗемәдә дә ил буенча үзләренең зурлыгына «ышандыра алдылар» бит! Алар һаман ихтирам, сөю яулыйгына баралар, без — моның горур шаһитлары. Ә бүгенге шагыйрьләр? Сибгат ага Хәкимнең үз моңы, характеры, фикер, уй агышы белән гражданлык кушылган колачын тәрҗемәдә дә күрсәтә алганны шатланып әйтеп буладыр. Үзебезнең Казан тәрҗемәчеләре — рус шагыйрьләре дә бик яратып тәрҗемә итте аны. Бу — үзе бер сабак. Аннан, 50 еллардан ук башлап төрле буын шагыйрьләрнең тәрҗемә китаплары чыккан. Ә сыйфат? Күбесенең тәрҗемәдә эшләнеше, яңгырашы, уртача дисәм, килешерләр бит?

Әмма бу тәрҗемәләрне бастырып чыгарырга үзебез үк ризалык биргәнбез. Үзебезгә дә, тәрҗемәчегә дә ташлама ясаганбыз.

Тәрҗемәчеләрнең дә даими осталык үстерү мәктәбе булу шарттыр. Мәсәлән, «Дружба народов» журналында, «Комсомолец Татарии» газетасында бер шигырьне тәрҗемә итүгә багышланган конкурс булып, аңа кызыклы йомгак ясалган иде. Соңгы берничә елда рус телендә чыккан китапларыбызны тәфсилләп, татарчасы белән чагыштырып өйрәнү, сөйләшү кирәклеге алга басты, бу — шагыйрьләр секциясенең алдагы бер утырышына нигез булачак.

Тәрҗемә ителми торган шагыйрьләр бармы? Минемчә, юк. Дөнья әдәбиятының күпме бөекләрен төрле төгәллектәге тәрҗемәдә укыйбыз бит. Әле күптән түгел генә өлкән шагыйрь Әхмәт ага Исхак үзенең күп еллык татарчага тәрҗемәләрен китап итеп чыгарды. Аның иң яхшы тәрҗемәләре — безнең тел-шигъриятнең бер вакыйгасы, үз факты буларак кабул ителә. Бу — шатлыклы хәл. Әмма тәрҗемә өчен авыр бирелә торган шагыйрьләр, әсәрләр барлыгын да беләбез. Такташны тәрҗемә итү мәсьәләсе — күптәнге тема... Әмма авырлыкларны җиңү процессы үзе бер зур батырлык бит! Ә матурлыкка һәрвакыт батырлык юлдаш булуы шарт. Безнең чорда бигрәк тә...

Французларда элек-электән шигърият тәрҗемә ителә алмый торган жанр булып санала. Шуңа да шигырьне проза белән тәрҗемә иткәннәр. Әмма безнең илдә тәрҗемәнең практикасы, үз ысуллары бар. Аларны камилләштерергә генә кирәк. Бу — шигырьне чын шигырь теленә күчерә, яратып укыла торган яхшы тәрҗемә аша халкыбызның рухын, моңын, бай традицияләрен, күңел байлыкларын югалтмыйча, башка күңелләргә җиткерү, бөекләрне бөекләр теленә күчерү дигән сүз.

Хәзер бу инде хыял түгел, бәлки процесс һәм тарих та...

**Хөрмәтле укучылар!**
**Журнал битләрендә тәрҗемә турында сөйләшү дәвам итә. Сездән хатлар һәм кызыклы мәкаләләр көтәбез.**

библио графия

# ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА ЯҢА АДЫМ

Күптән түгел әдәбиятыбыз тарихының беренче томы дөнья күрде[1]. Вакыт ягыннан том урта гасырлар дәверен үз эченә ала, дөресрәге — әдәбият белемендә борынгы чор һәм урта гасырлар чоры дип йөртелгән дәверләрне берләштерә. Әлеге дәверләрнең иң ерак чиге барлык төрки халыклар өчен уртак булган борынгы төрки чорыннан — VII—VIII йөзләрдән үк башлана, иң якын чиге исә XIX йөзгә барып тоташа.

Шулкадәр зур һәм катлаулы аралыктагы әдәбиятның үсеш юлын эзлекле һәм бербөтен итеп күз алдына бастыру, билгеле, җиңел түгел. Менә шуңа күрә дә бу җаваплы эшкә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының үз хезмәткәрләреннән тыш, Казан вузлары укытучыларының, шулай ук Мәскәү, Ленинград, Уфа һәм Алабуга галимнәренең дә җәлеп ителүе бик табигый.

Әмма авторлар коллективы никадәр генә әзерлекле һәм көчле булмасын, әгәр аларның эшчәнлеге үзара координацияләнмәсә, уртак максатка һәм уртак принципларга буйсындырылмаса, хезмәтнең эчтәлек һәм төзелеш ягыннан чагыштырмача бер бөтен булып чыгуы бик шикле булыр иде. Институтның әдәбият секторы һәм редколлегия бу яктан шактый зур сизгерлек һәм түземлек сорый торган эш башкарганнар. (Бу урында мин томны эшләүгә аеруча күп көч салган Шакир Абилов, Нурмөхәммәт Хисамов һәм Хатип Миңнегулов исемнәрен аерып күрсәтер идем.) Нәтиҗәдә коллектив бүгенге көн таләпләренә, димәк, фәннең соңгы казанышларына туры килә торган хезмәт тудырган.

Беренче томның уңышы, барыннан да элек, тарихилык принцибына нигезләнеп эшләнүендә. Әдәбиятыбызның нинди җирлектән башлангыч алуын һәм нинди үсеш этаплары үтүен күрсәтү өчен, урта гасырлар дәвере халкыбызның социаль һәм культура тарихындагы борылыш моментларына карап, үзе берничә чорга бүленә: Болгар дәүләте чорына, Алтын Урда чорына, Казан ханлыгы чорына һәм Казан ханлыгы рус дәүләте составына кертелгәннән соң килә торган чорларга. Тик ни өчендер әлеге чорларның беренчесе генә бүлекчәнең исеменә чыгарылган («Болгар чоры әдәбияты»), калганнары исә, тарихи-әдәби чор белән теге яки бу гасыр нисбәте төгәл тәңгәл килеп бетмәсә дә, гасырлар белән генә күрсәтелгән.

Хәзмәттә һәр чорның иҗтимагый-идеологик үзенчәлекләре турында күзәтү бирелә. Теге яки бу әдәби күренеш яки аерым язучыларның иҗаты һәм дөньяга карашы да, кагыйдә буларак, шул тарихи күзәтү фонында, билгеле бер чорның социаль һәм культура мохите җирлегендә карала. Мәсәлән, әдәбиятыбызга иң борынгы җирлек булган мифология һәм беренче фольклор үрнәкләре табигый рәвештә Болгар чорына кертеп анализлана, суфичылык күренеше Казан ханлыгы Россия составына кушылганнан соңгы чорга, ягъни әлеге агым Идел буенда шактый көчәеп киткән заманда нисбәттә тикшерелә. Урта гасырлар дәвамында бер язучыдан икенчесенә көчәп килгән дини идеология йогынтысын, шулай ук көчле һәм гадел хөкемдар идеясен дә авторлар нәкъ шул заманнар өчен хас булган шартларга һәм карашларга бәйләп аңлаталар, боларның феодаль чор өчен табигый булуын расльйлар.

Шуның белән бергә — монысы инде аеруча мөһим — авторлар элгәрге язучыларның иллюзион-утопик һәм консерватив идеяләр фонында, шулай ук дини образлар һәм сюжетлар җирлегендә прогрессив һәм гуманистик идеяләр күтәреп чыгуын да күрсәтәләр. Хезмәтнең йомгагында бик дөрес билгеләнгәнчә, урта гасыр татар әдәбиятында дөньявилык, тормышка актив мөнәсәбәт төп юнәлеш булды. Аның үзәгендә кеше торды, ул хезмәт кешесен зурлады, аның җирдә бәхетле яшәү мөмкинлегенә өмет уятты һәм тормышны үзгәртеп коруга ышаныч тәрбияләде.

Хезмәтнең тарихилык калку булып гәүдәләнгән тагын бер катламы күчемлелекне, ягъни әдәби процесстагы үсеш-үзгәрешләрнең үзара бәйләнешен һәм дәвамлылыгын күрсәтүгә кайтып кала. Без югарыда сүз алып барган тарихи-әдәби чорлар асылда идеяләр, образлар һәм поэтика чараларын бу-

[1] Татар әдәбияты тарихы. Урта гасырлар дәвере. 1 т., Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1984.

ыннан-буынга тапшыру яки үстерү ягыннан да эволюцион баскычлар булганнар һәм сыйфат сикерешләрен тәшкил иткәннәр.

Әмма урта гасырларда болгар-татар әдәбиятының гомуми үсеше түбәннән югарыга таба барса да, Казан ханлыгы рус дәүләте составына кертелгәннән соң, фәндә күрсәтелгәнчә, шәһәр культурасының, шулай ук өстен сыйныфлар кулында булган язма тарих һәм профессиональ әдәбиятның үсеше тоткарлана. Чөнки феодаль дәүләтчелек бетү аркасында язма культураның социаль заказчылары һәм укучылары өчен дә, шулай ук аны тудыручылар өчен дә җирлек кысыла, хәтта урыны-урыны белән юкка чыга.

Менә шундый шартларда инде язма әдәбият традицияләренең бер өлеше ярым әдәби, ярым гамәли жанрлар (сәяхәтнамәләр, васыятьнамәләр, мемуарлар, шәҗәрәләр) тудыруга яки булганнарын активлаштыруга җайлаша. Моннан тыш, язма традицияләр халык иҗаты мәйданында да үзләренә ярашыр юл табалар: бердән, язма культура белән фольклор арасында торучы бәет жанрының җанлануына ярдәм итсәләр, икенчедән, фольклор дастаннарының язмада теркәлүенә һәм эшкәртелүенә китерәләр.

Кыскасы, Казан ханлыгы Россия составына кертелгәннән соң килгән чор әдәбият үсешендә катлаулы һәм каршылыклы дәвер иде, һәм ул, һичшиксез, әдәбият тарихында да шул рәвешле яктыртылырга тиеш иде. Кызганычка каршы, томда бу чорның каршылыклы яклары һәм аларның әдәби процесска тәэсире тиешле югарылыкта яктыртылмаган. Аерып әйткәндә, XVII йөз әдәбиятына хас югалтулар һәм тайпылышлар киң социаль-эстетик контекстта түгел, ә аерым әдәби күренешләр (мәсәлән, суфичылык көчәюе һәм фольклор дастаннарына мөрәҗәгать итүнең активлашуы) мисалында гына каралган. Классик әдәбиятның торгынлыкка дучар булуы һәм аның тарихи сәбәпләре исә, хәтта чорның культура һәм әдәби мохитенә багышланган күзәтү өлешендә дә, игътибар үзәгеннән бөтенләй читтә калган.

Ләкин Идел буеның Россиягә кушылуы, царизмның милли-колониаль изү политикасы үткәрүенә карамастан, һичшиксез уңай күренеш иде. Хезмәттә дөрес күрсәтелгәнчә, Россия составында татарлар рус культурасын үзләштерделәр һәм рус дәүләтен уртак Ватаннары итеп таныдылар. Уртак дәүләт идеясенең көчәюенә бәйле рәвештә һәм патша хөкүмәте ясарга мәҗбүр булган кайбер ташламалар җирлегендә татар классик әдәбияты торгынлыктан җанлануга юнәлеш алды, милли язма культураның үсүе өчен яңа политик шартлар барлыкка килде.

Әдәбиятыбызның төрле чорлары арасындагы бәйләнешләрне һәм уртаклыкны анализлаганда, авторларга тарихи күчемлелекнең шактый четерекле яклары белән дә очрашырга туры килгән. Монда без Болгар, Алтын Урда дәүләтләре һәм Казан ханлыгы арасындагы политик дәвамчылыкның чагылыш үзенчәлеген күздә тотабыз. Аерып әйткәндә, томда Казан ханлыгы кайбер авторлардагы кебек Алтын Урдадан аерылып чыккан дәүләт итеп түгел, ә Болгар дәүләтенең дәвамы, варисы итеп карарга тырышыла һәм Казанның заманында Яңа Болгар («Болгар әлҗәдид») дип йөртелүе, халкының нигезен дә җирле болгарлар тәшкил итүе күрсәтелә. Әмма дәүләтара күчемлелекне аңлатканда, каршылыкка, эклектизмга юл калдыра торган тарихи төгәлсезлек тә җибәрелгән: «XV йөзнең беренче яртысында Казан кенәзлегендә идарә итүче династияләр алмашына, башында хан торган Казан чоры дәүләте башлана» дип бирелгән. Асылда Казан дәүләте XV йөзгә кадәр үк, ягъни тәхеткә Алтын Урдадан килгән чыңгызый Олуг Мөхәммәд утырганчы ук инде оешкан була, һәм ул нәкъ менә яңа политик үзәк тирәсенә болгарларның тупланувы нәтиҗәсендә формалаша.

Болгар дәүләте белән Казан ханлыгы арасындагы күчемлелек элек-электән үк халыкның тарихи аңында да чагылыш таба килгән. Мәсәлән, манара һәм янмый торган кыз хакындагы, шулай ук Алып һәм шайтан каласында ил чиген саклаучы аждаһа турындагы легендалар һәр ике дәүләткә бәйләп тә сөйләнгәннәр, тарихи чорга карап, төрле үзгәрешләр кичергәннәр. Тик ни өчендер «Болгар мифологиясе һәм халык иҗаты»на багышланган махсус мәкаләдә бу легендаларның тарихи күчемлелеге, рухи мирас булып Казан ханлыгы чорына тапшырылуы хакында бер нәрсә дә әйтелмәгән.

Хезмәтнең фәнни тикшерү методы белән бәйләнгән икенче уңышлы ягы аның комплекслы планда эшләнүендә, ягъни әдәби мирасыбызның халкыбызның тарихи, иҗтимагый-социаль тормышы һәм культура үсеше белән тыгыз бәйләп тикшерелүендә. Аерым алганда, томда, әдәбиятның эчке үсеш тенденцияләре һәм үзенчәлекле закончалыклары анализланудан тыш, әдәби процессның, гражданнар тарихы, иҗтимагый фикер, философия, әхлак, эстетика, фольклор һәм тел белән бәйләнешле якларын ачыклауга да шактый игътибар ителгән. Бу исә, беренчедән, әдәбият тарихын киң фонда һәм күпьяклы бәйләнешләрдә ачарга мөмкинлек бирсә, икенчедән, урта гасырлар әдәбиятының синкретик табигатен һәм аның состав өлешләрен органик берлектә карарга уңайлык тудырган.

Татар әдәбиятын киң контекстта карау, гомумтөрки һәм көнчыгыш әдәбиятлары белән тыгыз бәйләнештә анализлау — беренче томның шулай ук уңай һәм отышлы ягы. Болгар чоры әдәбияты алдыннан борынгы төрки язмачылык турында (ягъни руник һәм уйгур язулы ядкарьләр хакында) махсус мәкалә урнаштырылуы, шулай ук аерым чорларга багышланган һәр бүлекчәдә татар

әдәбиятына бәйләнешле көнчыгыш язучылары һәм аерым әсәрләр турында мәгълүматлар биреп барылуы моны ачык дәлилли.

Шул ук вакытта хезмәттә Болгар чорындагы әдәбият үсешенең сәбәбе берьяклырак аңлатылуын, ягъни болгарларга ислам дине һәм гарәп алфавиты керүгә генә кайтарып калдырылуын да, һичшиксез, күрсәтеп китәргә кирәк. Никадәр генә таралган булмасын, бу караш, безнеңчә, тар һәм тарихи яктан төгәл түгел. Болгар дәүләтендә культура-әдәбиятның төп үсеш сәбәбе — «Көнчыгыш ренессансы» яки тарайтыбрак «Көнчыгыш гуманизмы» дип аталган мәдәни-идеологик күренеш. Асылда болгар әдәбияты да Урта гасыр Көнчыгышындагы шушы күренеш орбитасына кергән булган һәм, бердәм культураның аерылгысыз өлеше буларак, Көнчыгыш әдәбиятлары белән уртак үсеш процессы кичергән.

Борынгы һәм Урта гасырлар татар әдәбияты — бай язма әдәбият. Менә шуңа күрә дә беренче томның реаль-фактик җирлеген кайбер әдәбиятлардагы кебек фольклор материаллары түгел, ә исемнәре киң билгеле булган язучыларның иҗаты тәшкил итә. Болгар, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында иҗат иткән Кол Галинең атаклы «Кыйссаи Йосыф»ы, Котбның «Хөсрәү вә Ширин»ы, Харәзминең «Мәхәббәтнамә»се, Мәхмүд бине Галинең «Нәһҗел-фәрадис»ы, Хөсам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан»ы, Сәйф Сараиның «Гөлстан бит-төрки»е һәм «Сөһәйл вә Гөлдерсен»е, Мөхәммәдъярның «Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» поэмалары — шуларның иң күренеклеләреннән. Бу әсәрләр турында китапта шактый тирән һәм киң планлы итеп эшләнгән теоретик тикшеренүләр урнаштырылган. Аларда язучының биографиясенә бәйләнешле мәгълүматлар да, әсәрдә күтәрелгән идея һәм проблемалар да, шулай ук поэтика-стиль мәсьәләләре дә чагылыш тапкан. һәм, басым ясап әйтергә кирәк, әдәбият белемендә моңа кадәр билгеле булмаган күзәтүләр, яңа нәтиҗәләр ясалган. Бу яктан «Кыйссаи Йосыф», «Хөсрәү вә Ширин» әсәрләренең һәм Сәйф Сараи иҗатының анализлануын аеруча уңышлы үрнәкләр итеп карарга кирәк.

Казан ханлыгы Россия составына кергәннән соң иҗат иткән урта гасыр язучыларының иң күренеклеләре — Мәүлә Колый һәм XIX йөзгә дә караучы шагыйрьләрдән Г. Утыз Имәни белән Таҗетдин Ялчыгол. Бу язучыларның тормышы һәм иҗаты турында да кызыклы гына күзәтүләр ясала. Шул ук вакытта томда исемнәре фәнгә яңа керә башлаган шагыйрьләрдән Габди һәм Габдессәләм турында да аерым мәкаләләр урнаштырыла. Ахыр килеп, XVII—XVIII йөзләргә багышланган бүлекчәләрдә «Җәмигъәт-тәварих», «Дастаннар мәҗмугасы» һәм «Мәҗмуг-эл-хикәят» кебек әсәрләрне аерым-аерым анализлауга да урын бирелә.

Китапта мөһим табышлары һәм фикерләре күзәтүләрдә файдаланып та, исемнәре һәм хезмәтләре күрсәтелми калган белгечләр булуын да искәртергә кирәк. Бу очракта без А. Н. Самойлович, А. Е. Крымскийның тикшеренүләрен һәм хәзерге белгечләрдән А. Фәтхинең «Мәгърифәт төбәкләре һәм әдәби багланышлар» («Казан утлары», 1968, 2 сан) дигән хезмәтен күздә тотабыз.

Хезмәттә урта гасырлар әдәбиятының синкретик табигатен һәм яшәү үзенчәлекләрен ача торган фактларга да юкрәк урын биреп булыр иде. Әйтик, бездә элек әдәбият белән рәсем сәнгатенең үзара кушылуына нигезләнүче шамаил сәнгате популяр булган. Классик поэзия музыка белән дә тыгыз үрелгән, чөнки шигырьләр элек көйләп укылганнар: уен коралына, хәтта оркестрга кушылып, халык моңнарына һәм сюита характерындагы классик мәкам («пәрдә») көйләренә башкарылганнар. «Җөмҗөмә солтан» әсәреннән тыш, бу хакта «Кыйссаи Йосыф»тан, «Мәхәббәтнамә»дән һәм «Хөсрәү вә Ширин»нән кызыклы мәгълүматлар табарга була. Я булмаса кульъязма китап дигән төшенчәне һәм китап күчерү культурасына бәйләнешле мәсьәләләрне алыйк. Ә. Кәримуллин һәм М. Госманов хезмәтләренә таянып, болар ярдәмендә дә элгәрге әдәбиятның яшәү үзенчәлекләрен күрсәтеп булыр иде.

Аерым язучыларның иҗатына һәм аерым проблемаларга багышланган тикшеренүләр, төрле авторлар тарафыннан язылганлыктан, табигый инде, аларның фәнни-теоретик дәрәҗәсе бар очракта да бердәй яки тигез түгел. Арада «Кисекбаш китабы», «Дастаны Бабахан» һәм «Әдәби бәйләнешләр» кебек чагыштырмача йомшаграк эшләнгән мәкаләләр дә бар. Аларның беренчесендә «Кисекбаш»ның Идел буена бәйләнешен ачыклау да, шулай ук аның героик эпос традицияләреннән үсеп чыгуын күрсәтү дә юк дәрәҗәсендә.

«Дастаны Бабахан» турындагы тикшеренүдә дә (авторы Ф. Әхмәтова) шагыйрьнең һәм әсәрнең җирлеккә бәйләнешен исбатларлык төпле дәлилләр табылмаган. Дастанның заман белән бәйләнешен, конкрет тарихилыгын ачыклыйсы урында автор әсәрдән ыруглык дәвереннән үк килә торган архаик мотивлар эзләү белән мавыга, тарихи-чагыштырмача методка нигезләнеп ясалган кызыклы гына күзәтүләр дә әдәби-эстетик анализ белән керешми, ә фольклористика кысаларында гына кала.

«Әдәби бәйләнешләр» исемле өченче мәкаләнең (авторы Ә. Шәрипов) йомшак ягы исә томдагы башка тикшеренүләрдә әйтелгән, инде таныш булган фактларга күп урын бирүендә, авторның хәтта вакыт-вакыт үз-үзен кабатлавында.

Әгәр без монда нигездә уңышлы эшләнеп тә кайбер кирәкле мәсьәләләрне ачыкламыйча яки игътибарсыз калдырган тикшеренүләргә дә тукталмасак, характерлы кимчелекләрнең бер өлешенә күз йомган булыр идек. Ә андый хезмәтләр бернечә. Мәсәлән, «Тел һәм стиль» турындагы мәка-

ләдә борынгы әдәбият поэтикасы өчен аеруча хас булган афористик фикерләү һәм кысалы-каймалы кыйсса кебек традицион алымнар да, шулай ук художестволы вакыт һәм пространствоның гәүдәләнеш үзенчәлеге дә анализланмаган. Безнеңчә, Д. Лихачевның борынгы рус әдәбияты поэтикасына багышланган хезмәте соңгы моментларны ачыклауда уңышлы үрнәк була алган булыр иде. «Суфичылык» дигән мәкаләдә исә (авторы Ш. Абилов) теманы аңлау өчен зарури күренеш булган дәрвишлекнең асыл табигате аңлатып бирелмәгән һәм поэзиядәге суфичылык символикасына да тукталынмаган. Һәм, ниһаять, «Борынгы төрки язмачылык»ка багышланган мәкаләдә (авторы Х. Короглы) «Урхан-Енисей ядкарьләрендә бар нәрсә дә эпос стилендә бирелгән» дип күрсәтелгән, ә инде ритмик яктан бер өлеш текстлар «ирекле шигырь формасы»на нигезләнгән дип расланган. Хәлбуки фәндә әлеге руник язмалар ярым сәнгатьчә, ярым тарихи характердагы эпитафик жанр булганнар дигән караш та бар (В. М. Жирмунский, А. М. Щербак, Л. Грибичек һ. б.).

Томда ахырга кадәр унификацияләнеп бетмәгән, ягъни үзара яраштырылмаган моментлар да бар. Мондый кимчелекләрнең бер өлеше чорларны һәм хәттә елларны бутап күрсәтү очракларына кагыла. Мәсәлән, «Бабахан дастаны»на багышланган мәкаләдә әсәр XVII—XVIII йөзләрдә иҗат ителгән дип дөрес күрсәтелсә дә, дастан үзе бернинди нигезсез һәм исбатлаусыз XV—XVI йөзләр чорына кертеп анализлана. «Кыйссаи Аук»та бер урында кистереп XIV йөз әсәре дип, икенче урында исә бердәй дәрәҗәдә XV йөзгә караучы иҗат дип раслана. Аллаярның туган һәм вафат булган елларының бирелеше дә ике урында ике төрле: 1630—1721 (1723) һәм 1616—1713. Хәтта шагыйрьнең исеме дә төрле язылышта алынган. Мондый мисалларны хәтсез дәвам итеп булыр иде.

Унификацияләү җитешмәгән икенче төр кимчелек аерым жанрларны бутауга, исемнәрен урынлы кулланмауга кайтып кала. «Кисекбаш китабы» турындагы мәкаләдә, мәсәлән, легенда һәм миф жанрлары берничә җирдә ялгыш «риваять» дигән термин белән бирелгән. «Мәҗмуг-эл-хикаят» турындагы тикшеренүдә (авторы Н. Исмәгыйлев) «әкият» атамасы соралып торган очракларда да «хикәят» сүзе кулланылган һәм, шуңа күрәдер инде, җыентыктагы әсәрләр тылсымлы һәм маҗаралы авантюр әкият эстетикасы белән дөньяви әдәбият очрашкан ноктада анализланмаган. XVIII йөзнең культура һәм әдәби тормышына багышланган күзәтүдә исә Пугачевка багышланган тарихи җырлар, искергән традициягә ияреп, «бәет» дип исемләнгәннәр. Болардан тыш, мәснәвинең, ягъни рифмалашу формасының кистереп жанр дип аталуы (392 б.), ә чыннан да жанр булган тоек формасының «авазлаш сүзләр» дип кенә бирелеше (204 б.) белән дә килешеп булмый. Һәм, әлбәттә, «Нәһҗел-фәрадис»ка багышланган мәкаләдә «хикәячелек жанры» дигән терминны «чәчмә эпик әсәрләр»нең һәм «проза жанры»ның синонимы буларак куллану да акланмый, чөнки хикәяләү формасының шигъри-поэтик текстта (яки жанрда) да килә алуы бәхәссез.

Әдәби бәйләнешләр турындагы мәкаләдә болгар-татар әдәбиятына караган әсәрләр «халыкның үз әдәби телендә язылган» дигән фикер үткәрелгән. Сыйнфый җәмгыятьтәге язма әдәбиятның телен болай тулысынча халыкның үз теленә кайтарып калдыру да хакыйкатькә туры килми, чөнки язма культура элек өстен сыйныфлар кулында булган һәм, М. Зәкиевнең мәкаләсендә дөрес күрсәтелгәнчә, «гомумхалык теле сыйнфый җәмгыять шартларында язма әдәби телгә тулысынча нигез булып ята алмаган». Болардан тыш, «Идел-Урал буендагы төрки әдәбиятның чәчмә төре шул төбәктә башта гарәп-фарсы телләрендә язылган әсәрләрдән үсеп чыга» (230 б.) дип раслау да берьяклырак, мондый караш борынгыдан ук килүче гомумтөрки язма традицияләрен дә һәм фольклордагы проза жанрларын да исәпкә алмый. Шулай ук халыкның сыйнфый-колониаль изелүгә каршы ризасызлыгына «шул чордагы идея юлбашчылары — дин әһелләре җитәкчелек иттеләр» (437 б.) дип карау да, безнеңчә, тәгәл түгел. Чынында җитәкчелек итмәделәр, ә йогынты ясадылар.

Хезмәтнең нигездә уңышлы эшләнгән фәнни-техник аппаратында да төрлелеккә урын калдырылган. В. И. Ленин әсәрләре астөшермәләрдә, мәсәлән, һәм русча, һәм татарча басмалардан китерелгән; аерым язучылар иҗатына яки аерым әсәргә багышланган тикшеренүләрнең бирелше вак-вак бүлекчәләргә бүлеп, өстәмә башлар белән бирелгән, икенчеләрендә исә бу принцип сакланмаган.

Беренче том урта гасырлар әдәбиятын тарихи-теоретик юнәлештә һәм комплекслы планда өйрәнүдә әле беренче тәҗрибә булганлыктан, билгеле, анда төрле җитешсезлекләрнең теге яки бу дәрәҗәдә урын алуы табигый. Хезмәтнең гомуми йөзенә һәм җитди уңышларына күләгә төшерерлек дәрәҗәдә булмасалар да, алар турында һичшиксез уйланырга, төп үзенчәлекләрен һәм туу сәбәпләрен ачыкларга кирәктер. Бу әдәбиятыбыз тарихының калган томнарын тагын да системалырак һәм эзлеклерәк итеп эшләргә һәм андый характердагы хаталарны кабатламаска ярдәм генә итәчәк.

Томның иң зур уңышы, әлбәттә, урта гасыр әдәби ядкарьләрен бер чылбырга җыю һәм динамик хәрәкәттә күрсәтү пафосы белән сугарылуында. Халкыбызның әдәби мирасын әлеге хезмәт бай традицияле, шактый тулы һәм зур иҗат итеп күз алдына бастыра. Аның тарту көче һәм төп әһәмияте дә әнә шунда.

**Марсель БАКИРОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

Торсын Каһһари

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ УЙГУР ӘДӘБИЯТЫ

Яңа дәвер уйгур әдәбиятына татар әдәбияты ясаган игелекле тәэсирнең әһәмиятен ачып, аның эзлекле тарихын язу — ул киләчәк бурычларның берсе. Шулай ук татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай иҗатының уйгур әдәбиятына булган йогынтысын җентекләп өйрәнү дә — махсус тикшеренүне сорый торган мөһим мәсьәлә. Шул ук вакытта, әйтик, урта гасырлар уйгур мәдәниятының һәм язма әдәбиятының башка төрки халыклар, җөмләдән татар халкының язма культурасына ясаган тәэсирен дә искә алмый мөмкин түгел. Күренекле шәрык әдипләреннән Ибне Сина, Фәраби, Сәгъди, Нәваи иҗатларының татар әдәбиятына ясаган йогынтысы турында сүз барганда, Идел буенда урта гасырларда кулланылыш тапкан уйгур язуын, шул чор уйгур әдәбиятының нигез ташларын салучы Мәхмүд Кашгарый, Йосыф Хас Хаҗиб мирaслары да хаклы рәвештә тәкъдир ителә.

Уйгур-татар әдәби һәм мәдәни багланышларының яңа дәвер тарихы Россиядәге 1905—1907 еллардагы буржуаз-демократик революциядән соң башлана. Бу хәрәкәт иң беренче чиратта татар әдәбиятының яңару, Россиядәге төрки халыклар арасында киң таралу, хәтта илнең чикләре аша чыгып китү процессы белән бәйле. Татар әдәбияты үзе белән бергә Урта Азия, Казахстан һәм Шәркый Төркстан халыкларының әдәби тормышларына рус-европа культурасының көчле тәэсирен дә алып килде. Шул чор төрки халыкларының әдәби телләре арасындагы тарихи якынлык, бигрәк тә гарәп хәрефләре нигезендә язу уртаклыгы мондый аралашуга уңайлыклар тудырган иде.

Урта Азия һәм Шәркый Төркстан өлкәләрендә татарча газета-журналлардан «Аң», «Шура», «Яшен», «Ялт-Йолт», «Вакыт», «Тормыш», «Фикер», «Кояш», «Йолдыз»лар киң тарала, казах, үзбәк һәм уйгур укымышлылары тарафыннан яратылып укыла. Бу газета һәм журнал битләрендә Галиәсгар Камал, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Дәрдмәнд, Сәгыйть Рәмиев, Мәҗит Гафури һ. б. күренекле һәм тәрәккыйпәрвәр әдипләрнең әсәрләре киң басыла. Әлеге әдипләрдән уйгур әдәбиятына бигрәк тә Г. Тукай иҗатының нык тәэсир ясаганлыгы мәгълүм. Шәркый Төркстандагы Үрүмче, Голҗа, Чугучәк шәһәрләрендә яшәгән, эшләгән уйгур укымышлылары арасында Тукай иҗаты белән таныш булмаган, аның шигырьләрен яттан белмәгән кешеләр аз очрый иде. Моңа революциягә кадәр Казаннан килгән матбугат та, Октябрьдән соң Алма-Ата һәм Ташкент шәһәрләреннән алынып торган газета-журнал һәм китаплар да сәбәп булдылар, әлбәттә. Шул ук вакытта Төркстан шәһәрләрендә эшли килгән татар мәктәпләренең уңай эшчәнлеген дә онытмаска кирәк. Моңа бер мисал итеп соңгы дәвер Шәркый Төркстан уйгур әдәбиятының иң күренекле вәкиле — революцион шагыйрь Лотфулла Моталлиб иҗатының формалашу һәм үсү фактын күрсәтергә мөмкин. Ул Голҗадагы татар мәктәбендә башлангыч белем ала һәм шунда татар әдәбияты, бигрәк тә Габдулла Тукай, Һади Такташ иҗатлары белән якыннан таныша, аларның шигъри үрнәгендә үз иҗатын да башлап җибәрә. Моның шулай икәнлеген Лотфулланың үз әсәрләреннән дә, аның кызыклы иҗатын җентекләп тикшергән уйгур әдәбиятчыларының хезмәтләреннән дә күрергә мөмкин. Мисал рәвешендә Алма-Ата, Ташкент шәһәрләрендә яшәүче уйгур әдәбияты тарихы белгечләре К. Хәсәнов, С. Муллавудов, Р. Кадыйри һәм Кытай Халык Республикасында яшәүче Т. Алиев һ. б. хезмәтләрен күрсәтергә кирәк.

Л. Моталлибның рус әдәбияты үрнәкләре белән танышуы да татарча, үзбәкчә басма сүз ярдәмендә булганлыгы бәхәс тудырмый.

Г. Тукайның соңгы дәвер уйгур әдәбиятына ясаган тәэсире турында сөйләгәндә бу халкның бердәнбер күренеш булмавы югарыда әйтелгән иде инде. Фикерне дәлилләп, түбәндәге фактларга күрсәтәсе килә. Моннан берничә ел элек журналда чыккан бер мәкаләбездә («Казан утлары», 1977, 11 сан, 162—165 битләр) Голҗа шәһәрендә татарларның элек-электән күпләп яшәүләре һәм аларның җирле уйгур мәдәниятенең үсүенә керткән өлешләре хакында шактый тәфсилләп язган идек. Андагы мәгълүматларны кабатлап тормыйча, кайбер өстәмә фактлар китерү белән канәгатьләнәбез. Мәсәлән, 30—40 нчы елларда Голҗа шәһәрендәге уйгур мәктәпләрендә укытучыларның зур өлешен (уйгурча иң зур уку йорты булган «Өмет» мәктәбендәге утыз укытучының уннан артыгын) татар мөгаллим һәм мөгаллимәләре тәшкил итә иде. Алар уйгур балаларын аларның үз ана телләрендә дә өйрәтәләр, татар әдәбияты буенча да мәгълүмат бирәләр. Әгәр Шәркый Төркстанда ачылган беренче яңа ысул («җәдит») мәктәпләренең дә татар мөгаллимнәре эшчәнлеге белән бәйле икәнлеген һәм, иң беренче чиратта, 1912—1916 елларда Голҗада мәгърифәтчелек хәрәкәтен җәелдереп җибәргән атаклы мөгаллим Габдулла Буби исемен искә төшерсәк, әлеге фикеребез тагы да куәтләнә төшәчәк. Голҗада беренче халык китапханәсе Г. Буби оештырган «Нур» мәктәбе каршында булып, аны «Кыйраәтханәи нур» дип атыйлар иде. Кыз балаларның мәктәпләргә барып укый башлаулары да Г. Буби алып килгән зур яңалык иде (элек уйгурлар арасында хатын-кызны пәрәнҗә астында тоту, укудан тыю гадәте хөкем сөргәнлеген дә онытмыйк).

Шәркый Төркстандагы башка шәһәрләрдә дә кызларның мәктәпләрдә укый башлаулары еш кына татар мөгаллим-мөгаллимәләренең эшчәнлегенә барып тоташа. Мәсәлән, Чүгүчәк шәһәрендә туып үскән татар кызы Гөлəндәм Хәбибуллина (1887—1974) мөгаллимәлек хезмәтен үзенең туган шәһәрендә башлап җибәрә, кызларны укыту эшенә тотынганлыгы өчен җирле фанатиклар тарафыннан мыскыл-хурлауларга, җәберләргә дучар ителә. Алдынгы карашлы уйгур зыялылары, Гөләндәм мөгаллимәнең бу фидакарьлеген югары бәяләр, аны башкаларга үрнәк итеп куялар. 1919 елны, мөгаллимәлек эшен яңа шартларда, ягъни элек кызлар мәктәбе бер дә булмаган шартларда башлап җибәрер өчен, аны Торфан шәһәренә чакыралар. Гөләндәм мөгаллимә анда 1933 елга кадәр кызлар укыта. Шуңа күрә Торфан халкы аны «безнең шәһәрнең белем чырагын яндыручы» дип олылый. Аннары ул яңадан үзенең туган шәһәре Чүгүчәккә кайта һәм янә дә укытучылык эшен дәвам итә. 42 ел дәвам иткән укытучылык чорында, шәкертләренең берсе исәпләп чыгаруга караганда, Гөләндәм мөгаллимә Хәбибуллинадан барлыгы 6229 шәкерт кызлар дәрес тыңлаган икән!

Бу фактлар киң колач җәйгән татар-уйгур мәдәни мөнәсәбәтләренең конкрет чагылышы, иң якты үрнәге. Шул ук вакытта Г. Тукайның бәрәкәтле иҗаты да үз нәүбәтендә халыкларыбыз арасында мәдәни-агарту эшләренең киң колач җәюенә, тирән тамыр җибәрүенә сәбәп булды.

Бөек шагыйрь Габдулла Тукайның олы юбилеен бәйрәм иткән елда уйгур әдәбияты һәм мәдәнияте вәкилләре дә аның якты һәм олы истәлеге алдында, аны үстергән татар халкы алдында тирән ихтирам белән баш иялəр.

*Алма-Ата.*

# ТУКАЙ ӘСТЕРХАН ЗЫЯЛЫЛАРЫ АРАСЫНДА

1911 елда бөек шагыйребез Габдулла Тукай Әстерхан шәһәрендә булып кайткан иде. Бу хакта матбугатта шагыйрьнең замандашлары язып калдырган ике-өч истәлек дөнья күрде. Шул вакытта Әстерханның Кышкы театр бинасында Габдулла Тукайны хөрмәтләп, тантаналы рәвештә үткәрелгән әдәби кичәдән соң анда катнашкан бер төркем кешеләрнең шагыйрь белән бергәләп төшкән фоторәсем дә бар. Бу рәсем 1926 елда Казанда чыккан «Татар театры, 1906—1926» исемле китапта да, 1966—1978 елларда, Г. Тукайга багышланган фотоальбомнарда да басылган иде. Ләкин ул басмаларда фоторәсемдәге кешеләрнең өчесенең генә исем-фамилияләре күрсәтелгән.

Хәзерге көндә бу кешеләр дөньяда булмасалар да, аларның балалары, якыннары бардыр һәм аларда Тукайга бәйләнешле материаллар сакланып калган булуы ихтимал.

Әгәр шагыйребезнең тормыш юлын, иҗатын өйрәнүче иптәшләр рәсемдәгеләрнең кем икәнлекләрен белеп, аларның якыннарын эзләүне кирәк тапсалар, бәлки бу язма аларга бераз ярдәм күрсәтер дигән өмет белән рәсемдәгеләрне укучыларга танытырга булдым.

Урта рәттә сулдан уңга таба утырганнар:

1 — Касыйм Туйбактин — җәмәгать эшлеклесе, революциядән соң Әстерхан мөселман комиссариаты председателе була, 1918 елда контрреволюцион фетнә вакытында үтерелә.



2 — Зәйнелгабидин Солтанов (Зәйни Солтанов). Нариман Нариманов Әстерханда чагында оештырып калдырган драмтүгәрәктә режиссерлык вазифасын башкара. Революциядән соң Казанга күчеп китә һәм Татар академия театрының режиссеры булып эшли.

3 — Габдулла Тукай.

4 — Сәгыйть Рәмиев.

5 — Биккинин — артист.

6 — Давыт Мөхәммәдов — суга баткан пароходларны өскә күтәрү остасы. Драмтүгәрәктә полицмейстердан кичә үткәрүгә, спектакль куюга рөхсәт алу, Кышкы театр бинасын арендалау, афиша бастыру кебек эшләрне башкаручы. Минем әтием.

7 — Һаҗәрхан Мөхәммәдова — Әстерхан татар хатын-кызлары арасында беренче булып сәхнәгә чыккан хатын. Бу турыда Зәйни Солтанов «Татар театры. 1906—1926» исемле китаптагы мәкаләсендә искә алып үтә. Г. Камал пьесаларындагы усал хатыннар ролен бик яратып уйный иде. Минем әнием.

8 — Зәйнәп Динникаева — костюмерша.

Артта, сулдан уңга таба басып торганнар:

1 — Сәмәки Габдерәхим (чын фамилиясе Әбүбәкеров). Әстерханнан ерак түгел Сәмәк исемле авылдан. Укытучы. Бу кеше Габдулла Тукай белән аның Уральскида яшәгән чагында ук таныш булган. Шагыйрьнең матбугатта басылып чыкмаган эпиграммаларын да яттан белә дип сөйлиләр иде.

2 — Басыйри Габдерәхим — прогрессив фикерле укытучылардан. Гарәп телен яхшы белә иде.

3 — Гайфи Шәһит — газета һәм журналда бастырган карикатуралары өчен жандармерия эзәрлекли башлагач, Калмык базары исемле авылга күчеп китә һәм шунда укытучылык итә. Габдулла Тукай аның өендә атна-ун көн кунак булып, кымыз эчеп дәвалана. Минем белүемчә, Тукайның «Мияубикә» исемле китабының беренче басмасындагы мәчеләр рәсемен Шәһит Гайфи ясаган булырга тиеш. Аннары, Тукайның «Бер шәехнең мөнаҗәте» исемле эпиграммасын җанландырып күрсәтер өчен, Ш. Гайфи үзе шәех булып, хатыны Нурбиби ханым яшь кыз булып киенеп, алларындагы табынга казы, кузы, каз, кымыз куеп, рәсемгә төшәләр. Габдулла Тукай турындагы истәлекләргә кер-

гән һәм Ш. Гайфинең энисе тарафыннан язылган истәлектә бу рәсемне төшергән фотографның фамилиясе күрсәтелә. Рәсем открытка рәвешендә басылып, халык арасында бик киң таралган иде.

4 — Әбүбәкер Мазини (чын фамилиясе Хәлилев). Әстерханнан ерак түгел Майлы күл исемле авылдан. Башта укытучы булып эшли. Соңыннан, 1922 елда булса кирәк, авылына кайтып, мулла була.

5 — Зөлкарнәй Байкин — драмтүгәрәк әгъзасы. Соңрак, Байкиннардан дүрт кеше түгәрәккә катнаша башлады. Болар арасыннан иң талантлысы Сара Байкина революциядән соң профессиональ артистка булып, труппада беренче рольләрне башкара иде.

Алгы рәттә сулдан уңга таба:

1 — Солтанов Рәхим. Зәйни Солтановның туганнан туганы. Революциядән соң большевик. Егерменче еллар башында карагруһчылар тарафыннан үтерелә.

2 — Басыйр Абдуллин — драмтүгәрәк әгъзасы.

3 — Адаков Габдерахман — талантлы артист. 1926 елда авырып үлгән.

4 — Туктар Динникәев — фельдшер, драмтүгәрәк әгъзасы, суфлер. Кулындагы китап Тукай кичәсендә уйналган пьесадыр дип уйлыйм.

Гөлсем **МӨХӘММӘДОВА**.

# «ТУГАН ИЛЕМ КОҖАМАКТЫ КАРЬЯСЕДЕР»

Илленче елларның башы. Бөек шагыйребез Габдулла Тукай юбилее уңае белән кичәләр уздырып йөргән чак. Авылларда әдипнең иҗат юлы турында лекцияләр укыла, аның шигырьләреннән һәм аның сүзләренә язылган җырлардан концертлар куела. һәм һәркайда диярлек кичәне оештыручыларга шундый сорау бирелә: «Безнең районда Тукайга туган тиешле кеше яшәгән, ул да шигырьләр язган дип сөйлиләр, кем булды икән ул?» Сүзләр йөри, ә аларны ачыклый алган кеше юк, чөнки ул вакытта әле Миргазиз Укмаси китабы басылып чыкмаган, архивларга күз салучылар да юк. һәм без, китапханәчеләр, укучыларның өметләнеп биргән сорауларына бернинди дә җавап бирә алмыйбыз.

Тукай әллә кайсы заманнарда яшәмәгән, картлар сөйләвеннән без аның исән чагында Барда (Пермь өлкәсе) ягында туып-үскән, Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган егетләр белән очрашып торганлыгын, шагыйрьнең Барда ягыннан хатлар алып торуын ишеткәләгән идек, ә менә аның туганлык җепләре ни дәрәҗәдә булган, бусын безгә беркем дә әйтә алмый.

Күп еллар үткәннән соң миңа партиянең Барда райкомы кушуы буенча Пермь архивларында актарынырга туры килде. Бу вакытта инде мин М. Укмаси китабы буенча Тукайның бабасы Зиннәтулланың Барда кешесе булганлыгын беләм һәм Пермь дәүләт өлкә архивында русча «Ревизские сказки» дип аталган, халык санын алу документларыннан шушы исемне эзлим. һәм, ниһаять, 1850 елда үткәрелгән халык санын алганда Пермь губернасы Уса өязе Барда авылында 107 нче итеп теркәлгән Әмирхан Әмиров гаиләсенә тап булам. Гаилә хуҗасы үзе «1836 елда үлде» дип күрсәтелә. Аннан соң 25 яшьлек улы Зәйнелбәшир теркәлә. Зәйнелбәширнең Габидә исемле хатыныннан 5 улы булып, алар арасында Зиннәтулла иң өлкәне була. Бу вакытта аңа 20 яшь тула. Зиннәтулладан кала Зәйнелбәширнең тагын дүрт улы турында түбәндәге мәгълүматлар теркәлгән: Гыйниятулла — 1835 елда үлгән, Әюп — 10 яшь, Гомәр — 7 һәм Хөсәен 4 — яшь[1].

Әмиров гаиләсе 1859 елгы халык санын алу документында да шул ук составта теркәлә, ләкин бусында Барда авылы дигән сүзләрдән соң җәя эченә алып «Казмакты тож» дип язылган, ә 1816 елда үткәрелгән халык санын алу вакытында 102 нче сан астында 47 яшьләк Әмирхан Әмировның (документта ул бу юлы русча Амурхан дип язылган) 40 яшьлек хатыны Базеха, ике улы — Мөфашәр (16 яшь), Зәйнелбәшир (14 яшь) һәм бер кызы — Хөббениса (10 яшь) булуы әйтелә[2].

Миргазиз Укмасиның Г. Тукай турында аның апасы Саҗидә Хәбибуллинаның истәлекләреннән файдаланып язылган «Шагыйрьнең тормыш сәхифәләреннән» дип аталган истәлекләрендә («Сайланма әсәрләр», 1958) Зиннәтулланың Казан өязе Кышкар авылы мәдрәсәсендә укуы, Кушлавыч авылы мөәзине, Өчиле авылы мулласы булуы, «үзенең

[1] Пермь дәүләт өлкә архивы (алга таба — ПДӨА), 111 ф., 1 тасв., 2013 эш.

[2] ПДӨА, 111 ф., 1 тасв., 1971 эш.

гомерен китаплар күчерү һәм оригиналь шигырьләр язу» белән үткәрүе турында әйтелә. Шунда ук без «ул байлыкка, малга әһәмият бирми, язган китап һәм кулъязмаларын, үзе үлгәч, элекке Казан өязе, Солабаш авылының мулласы Хәсәнгата Габәшигә... илтеп бирергә васыять итеп калдыра», дип укыйбыз. М. Укмаси үрнәк итеп, истәлекләрендә Зиннәтулланың кызы Мәмдүдә үлгәч язган һәм аның кабере янында укыган бер шигыреннән өзек тә китерә.

Вакытында Пермь өлкәсенең Барда районында йөртеп укылган «Калын дәфтәр»не (кайберәүләр аны «Бәет һәм шигырьләр дәфтәре» дип тә атыйлар иде) табу бәхетенә ирешә алмасам да, кулыма иске китап алган саен мин анда Тукайның бабасы Зиннәтулла Әмировның да берәр шигыре килеп чыкмасмы дип ачам. Чөнки М. Укмаси безне «Тукайның бабасы Зиннәтулла да шагыйрь була... аның моннан башка да язган шигырьләре күп булырга тиеш», дип өметләндергән иде.

Эзләнә торгач мин 1930 елгы «Белем» журналының 2 нче санында басылган бер мәкаләгә тап булдым. Ул 1929 елның җәендә Чиләбе өлкәсенә ясалган экспедиция отчеты иде. Фольклор әсәрләре җыю өчен җибәрелгән отряд членнары анда ике импровизатор шагыйрь яшәгәнлеге турында ишетәләр һәм аларның берничә әсәрен язып алалар. Аларның берсе яшь чагында Гашир исемле татар авылында балалар укыткан Зиннәтулла Әмиров, икенчесе — күрше Тәхәлим исемле башкорт авылыннан Хәким хәлфә була. Алар икесе дә бер мәдрәсә бетергәннәр, бер ук елны эшли башлаганнар, укыган чакларыннан ук шигырь язу белән мавыкканнар һәм бер-берсенә хатларны да шигырь итеп язганнар. Гашир авылы кешеләре Зиннәтулланың бәетләре, җырлар чыгаруы, аларны мәҗлесләрдә укуы һәм җырлавы турында сөйләгәннәр. Отчетта Зиннәтулланың егет белән кызга кара-каршы сөйләшү өчен язган бер әсәре китерелә[3].

Егет: Ач ишекең, бән күрәем, синең
бүйың зифа дирләр...
Кыз: Бәнем буйым зифа дирсең, су буйында
кугаларны күрмәдеңме?
Егет: Ач тәрәзәң, бән күрәем, синең йөзең
гүзәл дирләр...
Кыз: Бәнем йөзем гүзәл дирсәң, тау битендә
Кызарып пешкән җиләкләрне күрмәдеңме?

Миңа үзе исән чагында Уфада әдәбият галиме Афзал Кудаш белән очрашып, аның 1940 елда Тукайның апасы Саҗидә Хәбибуллинадан алган хатны укуын тыңларга туры килгән иде. 1940 елның 5 июнендә язылган бу хатында С. Хәбибуллина әтисенең Кажмакты егете булуын, Күәм илендә укыганлыгын хәбәр итә һәм аның берничә шигырен язып җибәрә. Безне Зиннәтулланың үзе турында язганы аеруча нык кызыксындырды һәм шуңа күрә аны тулысынча күчереп алырга булдык. «Инде әтиемнең ата-анасыннан, туганнарыннан берүзе аерылып торуына моңланып үзенә әйткән шигырьләрен язам», дип хәбәр итә дә С. Хәбибуллина түбәндәге шигырьне китерә:

«Фәкыйрем Зиннәтулла булды намым,
Уса иле идер җай-мәкамем.
Туган илем Кожамакты карьяседер.
Пермь табгы, Усага мосафадыр.
Зәйнелбәшир идер нам атамыз,
Әмирхан ибне Әмирдер бабамыз».

Сүзлек: җай-мәкаме — туган ил; карья — авыл;
Пермь табгы — Пермь губернасы мәгънәсендә;
мосафадыр — биредә карын мәгънәсендә.

Зиннәтулланың шигъри йөрәкле кеше булуы, үзен дулкынландырган-тетрәткән һәр вакыйга уңае белән бәет чыгаруы, шигырьләр язуы аның балаларына, аерым алганда булачак шагыйрь Габдулла Тукайның әнисе Мәмдүдәгә дә йогынты ясамый калмаган. Кайгы-хәсрәтләрен ул да шигырь юлларына сала торган булган.

Менә аның шул ук С. Хәбибуллина кулы белән А. Кудашка язылган хатта китерелгән бер җыры:

Өй түрендә бакчада бер сандугач
сайрый,
Нигә сайрый бу сандугач сагынып?
Шуны сайрый:
Минем елаганымны белеп, баламны
сагынып.
Нигә сайрый бу сандугач, сайрый
үсеп җиткәнне;
Шуны сайрый:
Мине күреп, баламнан аерылып
киткәнне.

---

[3] Бу татар халкының «Хан кызы» әсәре, ул Зиннәтулла Әмировның оригиналь шигыре түгел. Кара: Госманов М. Эзләр дастанга илтә.— «Казан утлары», 1981, 8 сан, 143—148 бб. (Ред.)

Нигә сайрый бу сандугач кич белән,
Шуны сайрый:
Күрде бәнем ике күзне яшь белән.
Нигә сайрый бу сандугач сызланып,
Шуны сайрый:
Минем елаганны күреп, баламны кызганып.

Шушы мәкаләдә файдаланылган халык санын алу материалларыннан чыгып, без ышанып әйтә алабыз: Зиннәтулла һәм аның бабасы Әмирхан Әмиров — Каҗмакты (хәзерге Пермь өлкәсенең Барда авылы) кешеләре булганнар. Шул ук М. Укмасиның С. Хәбибуллина сөйләве буенча язып калдырган язмаларында күрсәтелгәнчә, «Зиннәтулланың атасы Зәйнелбәшир, аның атасы Әмирхан, аның атасы Тәүкил, аның атасы Бәгъдән булып, анасы: Әүзә булган».

Филология фәннәре кандидаты М. Әхмәтҗанов җыйган риваятьләргә караганда, Әмировларның кайсыдыр буыны хөкүмәткә каршы чыгышларда катнашып, властьлар тарафыннан эзәрлекләнә һәм чит илгә качып китә. Бер риваятьтә ул Әмирхан баба дип күрсәтелә. Безнең уебызча, ул элгәрәк буын, әйтик XVI гасырда яшәгән Бәгъдән яки фамилия барлыкка китергән Әмир булырга мөмкин. Пермь дәүләт архивында сакланган 1816 елгы халык санын алу мәгълүматлары шулай уйларга урын калдыра: Әмирхан Әмиров ул елны 40 яшендә булган, димәк, ул Е. И. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышында да катнаша алмаган, аның белән бергә Барда (Каҗмакты) авылында аннан өлкән кеше (әтисе яки бабасы) теркәлмәгән. Димәк, ул бирегә каяндыр күчеп килгән. Ә югарыда искә алынган риваятьләрдә М. Әхмәтҗанов җыйган шәҗәрәләрдә Әмирхан баба да Бәгъдән дә Идел буе авылларыннан (берсе Татарстанның хәзерге Куйбышев районына караган Ямбакты, икенчесе Апас районына караган Карабай авылыннан) дип күрсәтелә. Һәрхәлдә, болар бүгенге Барда районы кешеләре әйткән сүзләргә туры килә: алар үзләренең ата-бабалары XV—XVII гасырларда Кама аръягыннан күчеп килгән дип исәплиләр[4].

Бабасының Барда ягыннан булуын Тукай үзе белгәнме? «Тәрҗемәи хәл»ендә ул бу турыда язмый. Ләкин ул бабасы туып үскән як егетләре белән очрашып торган һәм бу якларга хатлар язган дип әйтә алабыз. Киң катлам укучыларга, мәсәлән, аның 1910—11 елларда Сәгыйть Сүнчәләйгә язган хатлары билгеле. С. Сүнчәләйнең «Сайланма әсәрләр»ендә алар «Уфа чорына карый» дип әйтелә. Безгә мәгълүм булганча, 1907—1915 елларда Сүнчәләйләр Пермь губернасы Уса өязе Сараш земство мәктәбендә укытканнар. Аларда укып белем алган кешеләрне әле бүген дә очратырга мөмкин. Аларның кайберләрен Сараш турындагы хатирәләрендә Риза Ишморат та искә ала.

Сараш земство мәктәбендә, ә аннары Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган һәм шул елларда Г. Тукай эшләгән «Әльислах» редакциясенең төрле йомышларын үтәгән, Октябрь социалистик революциясеннән соң өяз мәгариф бүлегендә эшләгән, Барда районын оештыруда катнашып, күп еллар партия райкомында һәм район советы башкарма комитетында эшләгән Әндәр ага Батыркаев безгә С. Сүнчәләйнең үзе эшләгән Сараш белән генә чикләнмичә, күрше авылларга да йөреп әдәби кичәләр үткәрүе, анда үзенең Тукайга багышлап язган шигырьләрен һәм шулай ук аерым шигырьләрен Тукайга җибәреп, аннан алган җавап-хатларны башта дәресләрдә, аннары кичәләрдә горурланып укуы турында сөйли иде. Бер сөйләвендә Әнвәр ага Батыркаев миңа болай дигән иде:

— Хәтеремдә нык сеңеп калганы — бер дәрестә Сәгыйть абзыйның Тукайга җибәргән берничә шигырен һәм аннан алган җавап-хатны укуы булды. Бөек әдип үсеп килүче яшь шагыйрьнең җирле сөйләш йогынтысына бирелүен ачы тәнкыйтьләгән иде анда.

С. Сүнчәләй бу хатларның уникелән булуы турында яза, ә матбугатта аларның әлегә сигезе генә басылып чыкты. Дүртесе кайда калган? «Бу күчертеп бастырган хатлары күк, калганнары да мөһим иде. Ул хатларда милли, сәяси мәсьәләләр дә бар иде. Алар да шаять бер табылырлар»[5],— дип яза ул. Без дә шулай өмет итик!

**Әмир ФАТЫЙХОВ.**

[4] Пермь татарлары турында тулырак мәгълүматларны кара: Пермские татары. Казань, 1983. (Ред.)
[5] Сүнчәләй С. Сайланма әсәрләр. Казан, 1961, 101—102 бб.

Зөлфирә Салихова

# ХАЛЫКЧАНЛЫК ТАМЫРЛАРЫ

## КОМПОЗИТОР НӘҖИП ҖИҺАНОВНЫҢ СИМФОНИК МУЗЫКАСЫ ТУРЫНДА

Танылган осталарның музыкаль стилендәге милли җирлек төшенчәсе турында сөйләшкәндә, фикер агышы, ирексездән, халык иҗаты белән профессионализм арасындагы бәйләнешләр проблемасына китереп чыгара. Татар профессиональ музыкасына нигез салышкан күренекле композитор Нәҗип Җиһанов иҗаты да шушы юнәлештәге уйлануларга этәрә.

Композиторның үзгә иҗат йөзен билгеләүдә татар халык җырының гаять көчле йогынтысы сизелә. Халык җыры аның музыкасын туктаусыз баетып кына тормый, ә иҗатының тирәндәге нигезен тәшкил итә.

Индивидуаль тематизмны һәм сурәтләү чаралары табигатен билгеләүче беренчел фактор буларак, татар халык җыры художникның идея-эстетик карашларын билгеләүгә дә көчле йогынты ясаган. Дөньяга халыкча карау, матурлыкны халыкча кузаллау халык эстетикасын тирәнтен белүче Н. Җиһанов әсәрләрендә шактый ачык сизелә. Шушы уңайдан аның «Сабан туе» симфониясен, «Кырлай» симфоник поэмасын, «Симфоник җырлар» циклын искә төшерик. Халык җырларына хас салмаклык, киңлек, тирәнлек... Композитор тормыш күренешләрен иҗтимагый-эпик киңлектә күрсәтергә омтыла, шулай итеп, әсәрләрендә халык сәнгатенең оптимистик рухын, дәртләндергеч көчен һәм матурлыгын чагылдыруга ирешә.

Халык җыры Н. Җиһанов иҗатының төп юнәлешләре — опера өчен дә, симфония өчен дә бетмәс-төкәнмәс чыганак буларак хезмәт итә. Музыка белгечләре композиторның халык иҗатын файдалануында ике алымны билгелиләр: халык көйләренә турыдан-туры мөрәҗәгать итү; халык җыр һәм инструменталь иҗатының традицион чалымнарын иҗади үзләштерү. Композиторның опера жанрында халык музыкасына таянуы чагыштырмача тулы өйрәнелгән, ә менә симфония өлкәсендәге тәҗрибәсе әлегә җитәрлек ачылмаган. Югыйсә симфоник музыкада мондый өйрәнүләр өчен кирәкле булган тамырлар бигрәк тә ачык күренә.

Сәнгать белгечләренең хезмәтләрендә симфонизм үзенчәлекләренең опера иҗатыннан килүе басым ясап әйтелә. Чыннан да, композитор үзенең симфонияләренә операдан килде шикелле. Беренче опера белән, әйтик, беренче җитди симфоник әсәр («Сабан туе») арасында утыз еллык гомер ята. Шушы еллар эчендә авторның иҗат осталыгы югары камиллеккә ирешә. Шулай да композиторның симфоник музыкасы үзенчәлекләре опера жанры йогынтысында гына барлыкка килмәгән. Болай уйлау симфониягә башка чыганаклар, әйтик, халык музыкасы йогынтысын чикләү булыр иде. Безнең ышануыбызча, татар халык җыры Н. Җиһановның операларын да, симфонияләрен дә бердәй баеткан һәм башка жанрлардагы әсәрләренә дә җирлек булып хезмәт иткән.

«Симфоник җырлар» циклы (1965) халык иҗатының бәһаләп бетермәслек хәзинәсенә, мәңге җуелмаслык матурлыгына мәдхия рәвешендә язылган. Әлеге әсәрнең барлык җиде өлеше дә татар халык җырларына нигезләнгән. Цикл тыңлаучыларның мәхәббәтен казанды. «Иҗат могҗизасына сокланудан беркайчан да туеп булмый,— дип язды А. Леман үзенең бер мәкаләсендә.— Н. Җиһановның оркестр өчен язылган «Симфоник җырлар» исемле яңа әсәрен тыңлаганнан соң, күңелдә әнә шундый хис барлыкка килә. Композиторның зур һәм гаҗәеп нәтиҗәле иҗат юлы үз халкының музыкаль даһилыгын, халык җырының чишмәдәй саф интонацияләрен, бию көйләренең үзенчәлекле ритмнарын газизанә ярату белән сугарылган».

«Симфоник җырлар»да, әлегрәк язылган әсәр — «Татар темаларына сюита»дагы (1949) кебек үк, халык җыры автор өчен турыдан-туры илһам чыганагы булып

хезмәт иткән. Композитор әлеге әсәрендә халык җыры образларын күпьяклап ачарга омтыла, халык җырының эмоциональ эчтәлеген симфоник башлангычны үстерүдә җирлек итеп файдалана. «Симфоник җырлар»ны тыңлаганда, ничектер, «музыкаль картиналар галереясы» күзаллана. Андагы һәрбер картина халык тормышы, табигать гүзәллеге турында сөйли. Композитор үз халкының тарихына, культурасына мәхәббәтен һәрбер образ-авазга салырга омтылган. Кыскасы, әлеге әсәрдә художникның бөтен игътибары халык җанын чагылдыручы милли җырга юнәлгән, профессиональ осталыгы халык җырыннан новаторларча файдалануга хезмәт итә. Халык җырлары үрнәкләрен, музыкаль идея гәүдәләнешенә ярашлы рәвештә, мөмкин кадәр киңрәк кулланырга омтылу «Татар темаларына сюита»да да шактый ук ачык сизелә иде.

Симфоник жанрда халык җырларыннан файдалану алымы башка төрле кануннарга таяна шикелле. Композиторның симфоник әсәрләрендә, гадәттә, программ характердагы күпкырлы концепция үткәрелә. Халык бәйрәменең ачык тасвирлы манзарасын гәүдәләндергән «Сабан туе», лирик цикллардан торган Өченче симфония, эпик-монументаль характердагы Бишенче симфония, бүгенге чорның киеренке драматизмын чагылдырган Унберенче симфония кебек әсәрләрдә, мәсәлән, авторның зур гомумиләштерүләр орбитасына чыгарга омтылуы, симфонияләрдә аның концепцион-жанр принципларына таянуы бигрәк тә калку күренә. Менә шуңа да Н. Җиһанов симфонияләрендә халык җыры аерым бер әһәмияткә ия булган чыганак-җирлек төсендә кулланылмый. Автор аңа, сюиталардан аермалы буларак, башка «вазифа» йөкли. Әйтик, халык җыры симфоник циклның бер өлешенә аерым тема булып керергә мөмкин. Мондый очракта, ягъни интенсив симфоник үсеш җирлегендә аның идея-эстетик яңгырашын көчәйтү өчен чикләнмәгән мөмкинлекләр ачыла. Икенче симфония ахырында, мәсәлән, «Яшьлек» исемендәге халык җыры ни өчен кирәк булган? Беренчедән, әлеге җырда бәйрәмдәгечә бию рухы көчле, һәм композитор аны симфониягә шундый стихияне бирү өчен кулланган. Икенчедән, «Яшьлек» күп санлы тамашачыларга яшьлек турындагы җыр буларак билгеле, һәм ул тантана итүче халыкның рухына туры килә, симфониянең асылын тирәнрәк аңларга ярдәм итә.

Профессиональ иҗатта халык җырларының яшәеш принциплары төрлечә. Кайвакыт композитор куллана торган үрнәкне жанр ягыннан бөтенләй башка төрле «төскә мана», шулай итеп, аны әсәрнең гомум концепциясен ачуга хезмәт иттерә. Халык җыры Н. Җиһанов өчен «бер якка да кушылмаучы» интонацион структура түгел, автор аны мөмкин кадәр тулырак ачылырга җирлек бирүче бүлеккә кертеп җибәрә. Әйтик, «Татар темаларына сюита»ның җилкендергеч бетем өлеше «Уфа-Чиләбе» темасына нигезләнгән. Ә «Симфоник җырлар»да, мәсәлән, «Рамай», «Бишек җыры», «Туган тел» кебек халык үрнәкләре лирикасы циклның сузып башкарыла торган өлешләренең эчтәлеген билгели. Югарыда телгә алынган сюитаның өченче бүлеге нигезендә исә «Колаксыз Зариф» исемле халык көе яңгырый. Әлеге җырның көлкеле булуы сюитаның скерцо рәвешендәге бүлегенә бик тә ятышып тора.

Композитор иҗатында халык көен жанр ягыннан бөтенләй яңача аңларга омтылу очраклары да күзәтелгәли. Мондый алым, әлбәттә, яңа түгел. Мисаллар шактый. Мәсәлән, П. Чайковскийның Беренче фортепиано концерты финалында язга багышланган озын көй (веснянка) дәртле бию көенә әверелә. Шулай ук Н. Җиһановның Дүртенче симфониясе скерцосында да «Каръят батыр» көенең җиңел маршча яңгырашы бирелә. Киная катыш шаянлык — гадәттә, мондый жанрга хас үзенчәлек. Әлеге сыйфат югарыда телгә алынган скерцода да чагыла.

Профессиональ музыка иҗатында, әйе, халык җырлары беренчел рәвешләрен саклаган хәлдә файдаланыла. Әмма болай әйтүдә күпмедер шартлылык бар, чөнки зур симфоник әсәргә килеп кергән халык җыры үзгәрешсез кала алмый. Симфоник җирлектә ул гомум канунnarга буйсына, кыскасы, интонациясен котылгысыз рәвештә үзгәртә. Әлеге мәсьәләгә Н. Җиһанов ничек карый? Композитор фикеренчә, автор чыганак «хакимияте»нә бирелмәскә, киресенчә, халык темасын үзенең музыкаль идеясенә буйсындырырга тиешле. Татар халык җырларының күп кенә үрнәкләренә хас үзенчәлекләр, аерым алганда, кабатлануларның күп булуы, үлчәмнәрдәге «алдан билгеләнгәнлек» фольклорга мөрәҗәгать итүчеләргә өстәмә кыенлыклар тудыра. Симфоник әсәрләр тукымасына җиңел генә кушылырга теләмәгән җыр менә шундый «карышучанлык» та күрсәтә. Бу уңайдан Н. Җиһановның «Җыр белән көрәшергә» туры килә» дип әйтүе бик урынлы.

Симфоник музыка жанрында файдаланыла торган халык җырларын Н. Җиһанов форма кысаларын киңәйтү, лад-интонациясен «ачыгайту» юнәлешендә үзгәртергә омтыла, шушы максатка ирешү өчен гармония, синтаксис, фактура, тембр һ. б. күп төрле чаралардан файдалана. Әйтик, «Симфоник җырлар»ында ул «Рамай» темасына шушы яктан якын килә, шулай итеп, әсәрнең киңлегенә һәм тыгызлыгына ирешә. Мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин.

Татар халык җырлары белән күпкырлы бәйләнеш композиторны музыкаль фоль-

клор үзенчәлекләре белән өртелгән оригинал көйләп тудыруга да китерә. Мәсәлән, «Кырлай» симфоник поэмасының керешендәге сузынкы көй борынгы уен коралы — курайның яңгыраш мөмкинлекләрен киңәйтеп җибәрә. Курай яңгырашы ритмик бәйсезлеге белән аерылып тора. Төрле бизәкләргә бай булуы кереш музыкасын лирик озын көйләргә якынайта. Гомумән, «Кырлай» халыкчан яңгырашы белән генә түгел, ә татар халык җырының мөһим сыйфаты — көй фактурасының «күпкатлылыгын» ачып күрсәтүе белән дә кызыклы. Композитор әлеге катламнарны аерым скрипкалар, флейта белән кларнет дуэты ярдәмендә аерып-аерып күрсәтүгә ирешә.

Төрле стиль һәм жанр катламнарына таяну үзенә күрә яңа тематик синтез тудыра. Мондый «эретмә-темалар»да, гадәттә, татар халык җыры жанрындагы төрле стилистик элементларны күпләп табып була: шәһәр лирикасы үзенчәлекләрен дә, бизәкләргә бай озын көй аһәңнәрен дә... Бүгенге көннәр музыкасында мондый күренеш шактый очрый. Мисал өчен Р. Щедрин иҗатын алырга мөмкин. Мәсәлән, аның «Мәхәббәт кенә түгел» дип исемләнгән операсы фольклор жанры — такмакка нигезләнгән, һәм анда озын көйләр, шәһәр романслары һәм лирик «өзгәләнүләр»нең стилистик үзенчәлекләрен синтезлаштырган темалар да очрый.

Композитор Н. Җиһановның симфоник музыкасында такмаклардан ялалган оригинал темалар да шактый, һәм алар циклларның скерцо өлешләрендә күбрәк кулланыла. Моңа мисал итеп Өченче симфониянең — икенче, «Симфоник җырлар»ның өченче өлешләрен китерергә мөмкин.

Темаларның интонацион яктан бай булулары Н. Җиһанов музыкасының күркәмлеген билгеләүче сыйфатлардан санала. Әлеге үзенчәлек халык иҗатыннан килә. Халыкчан нигез темаларда гына түгел, ә аларны гәүдәләндерү алымнарында да күренә. Авторның симфоник әсәрләрендә «йөртүче-хәрәкәтләндерүче» вариацияләр алымы үзенең тамырлары белән халык музыкасына тоташа. Җырның аерым куплетларын төрле-төрле интонацияләрдә башкару, тема-идеяне төрле яклап яктырту әлеге алымның төп принципларыннан берсен тәшкил итә.

Вариацияле алымы рус композиторлары М. Глинка, М. Мусоргский, Н. Римский-Корсаков, С. Рахманинов, С. Прокофьев иҗатларында аеруча көчле үстерелде. Эпик колачлы иҗатларда мондый алымның өстенлек алуы бик табигый, һәм, гомумән, масштаблы симфонизм авторның хыял-фантазиясе белән турыдан-туры тоташкан вариацияле ләккә алып килә. Композитор Н. Җиһанов музыкасында вариацияләр алымы күп төрле сурәтләү чараларын колачлый. Метроритмик вариацияләүгә ул күбрәк таяна шикелле. Мондый үрнәкләр Өченче симфониядә, шулай ук Унынчы симфониянең финал өлешендә очрый. Н. Җиһанов иҗатында вариацияле лек алымы төрле музыкаль төзелешләрне колачлый. Шулар арасында мөстәкыйль форма барлыкка китермәгән вариацион бүлек рәвешендәгеләре аеруча еш очрый. «Татар темаларына сюита», «Симфоник җырлар», «Кырлай» поэмасының экспозицион бүлемнәре шундый принципка буйсындырылган. Соңгысының төп партиясендәге тема биш вариациядән тора, һәм алар үзләренә күрә бер микроцикл тәшкил итәләр. Шуның искәртеп үтик: мондый принцип М. Глинкадан килә.

Гомумән алганда, үзенә аерым төгәлләнгән форма буларак кабул ителә торган вариацияләр композиторның симфоник әсәрләрендә бөтенләй диярлек очрамый. Шулай да «Симфоник җырлар»дагы «Бишек җыры»н дүрт тактлы кыска темага вариация итеп карарга мөмкиндер. Шактый ук тыгыз теманы автор кискен кульминацияле, көчле динамик яңгырашлы зур симфоник полотно рәвешендә «җәеп салу»га ирешә.

Татар халык җырының композитор Н. Җиһанов стиленә йогынтысы мәсьәләсе, күргәнебезчә, күптөрле өйрәнү тармакларын эченә ала. Кыска мәкалә кысаларында билгеле, аларның бөтенесен дә колачлап булмый. Әлбәттә, татар профессиональ музыкасында «композитор һәм фольклор» темасы Н. Җиһанов симфонизмы белән генә чикләнми. Мондый күркәм традиция төрле буын композиторлар иҗатында чагылыш таба. Шулай ук яшь авторлар тарафыннан да шушы юнәлештә нәтиҗәле эзләнүләр алып барыла. Мәсәлән, Ш. Шәрифуллин музыкасында татар халкының инде онытыла башлаган борынгы көй-аһәңнәре шактый ук уңышлы яңгырый. Шул рәвешле яшь музыкантлар, күренекле композиторлар ирешкән казанышларны ишәйтергә омтылып, татар музыкасының беренчел интонацион нигезе — пентатоника чикләрен киңәйтүдә мактауга лаек өлеш кертәләр.

Композитор Нәҗип Җиһановның иҗаты — чын мәгънәсендә прогрессив һәм заманча сәнгать, совет һәм дөнья музыкаль культурасы үсешенең төп юлыннан баручы сәнгать. Билгеле ки, милли җирлексез сәнгать булмый. Үз халкының тарихына һәм культурасына таянган композитор гына чын милли һәм интернациональ художник дәрәҗәсенә күтәрелә, П. Чайковский әйткәнчә, дөнья музыкаль сәнгате бакчасында «үз агачын үстерә» ала.

**Диас Вәлиев**

# СӘЕР КЕШЕЛӘР

## Очрашу

Иң әүвәл, моннан ун-унике ел элек язылган трагикомедиям турында сөйләмәкче булам. Дөресрәге, аның баш герое «тумыштан бәхетле» Мәгъфур хакында. Ул һөнәре белән эшче кеше: үз йорты янында бакча ясый. Алмагач, чия утырта, чәчәкләр үстерә. Аңардан көләләр. Ике эчкече, аны кыйнап, милициягә тапшырмакчы булалар. Күрше хатыны аның өстеннән Мәскәүгә дәгъва яза. Мәгъфур үстерә башлаган бакчада хосусый милекчелек чире күрәләр. Ниһаять, өч егет — аларга Мәгъфурның үз малае да буйсынырга мәҗбүр була — алмагач үсентеләрен төбе-тамыры белән йолкып ташлыйлар.

Мәгъфур нишли? Мәгъфур тагын алмагачлар утырта. Аның фәлсәфәсе бик гади: «Монда бакча булыр һәм анда бәхетле кешеләр утырып ял итәрләр». Ләкин әлеге бушлыкта, канализация өчен дип, ялгышып, канау казыйлар — бакча тагын юк ителә. Мәгъфур аны өченче тапкыр тергезә...

Минем бу пьеса идеаль герой, икенче төрле әйткәндә, уңай герой турында иде. Әйтик, Сервантесның Дон Кихоты яки Достоевскийның князь Мышкины кебегрәк. Әдәбиятта чаң тавышлары ирекле һәм ирексез рәвештә яңгырый. Бүтән төрле яңгыраш — җиңелчә ирония югарылыгындагысы — тәүрат пәйгамбәрләре турында уйлаганда барлыкка килә. Матфей, Марк, Лука, Иоһаннан — инҗил бар, ә нигә Мәгъфур фәлсәфәсе булмаска?

Пьеса язылганнан соң бик күп еллар үткәч, бер якшәмбедә, хатыным базардан кайтты да әйтеп ташлады: «Җитәр сиңа һаман китапка багынып утырырга! Бар, әнә үзеңнең Мәгъфурыңа кара!» — «Кайсы Мәгъфурга?» — «Ничек, кайсы? Үзеңнең пәйгамбәреңә! Безнең өйдән ун минутлык юл. Ибраһимов урамындагы тугыз катлы ике йортны беләсеңме? Квартал уртасында — эре панельдән салынган биш катлы йорт. Күрерсең!» Аңа канәгатьсез генә карап алдым да теләмичә генә күтәрелдем: «Ниндидер сафсата?»

Бөтен тирә-якта ком, ватылган плитәләр аунап ята, җир өсте чокыр-чакырлы, ә монда, йорт янында — алмагачлар үсентеләре, чия, шомырт куаклары. Тәбәнәк капкадан эскәмиягә узасың. Яңгырдан саклану беседкасы, өстәле дә бар, анда газета һәм журналлар. Ике кыз комда уйныйлар. Һәр нәрсәгә кемнеңдер мәрхәмәтле кулы кагылганы сизелә...

Кечкенә капканы ачып, эчкә кердем, эскәмиясенә утырдым, көйрәтеп җибәрдем. Елмаясы килә. Йөзем үзеннән-үзе, минем ихтыярымнан башка елмая. «Хәерле көн, кешеләр! Бәхетле булыгыз! Бүген 1981 елның 6 сентябре!» — дип язылган.

Боларның барысы да мин пьесада язган һәм хыялымда тудырган Мәгъфур бакчасына охшаган да, охшамаган да. Ләкин бу бакчада да трагикомик атмосфера сизелә.

Ике егет — алар тәбәнәк койма янында күптән басып торалар — берсе олырак, икенчесе яшьрәк, кызу-кызу сөйләшәләр: ниндидер чалбарлар, тире, аларны каян табу хакында.

— Егетләр, әйтегез, зинһар, моны кем ясаган?

Өлкәнрәге борчулырак кебек. Икенчесе канәгать һәм тук елмая, күрәсең, аңа ниндидер файдалы эш килеп чыккан. Миңа соравымны тагын кабатларга туры килде, чөнки болар мине ишетмәделәр.

— Сиңа нәрсә кирәк соң?— Яшьрәгенең кесәсеннән шешә күренеп тора иде.

— Бу бакчаның авторы кем дип сорыйм.

— Нинди автор? Ә-ә, мондамы? Әзмени дөньяда тиләләр!

— Тиле? Ә кайда тора ул? Бу йорттамы?
— Ә нигә ул сиңа?
— Карарга.
— Карар нәрсә тапкан! — Яшь егет ахмакларча көлә иде.— Нәрсә ул, хатынкызмыни? Андыйларга карап күз әрәм иткәнче...
— Чәчәкләр утырткан, ахмак,— диде өлкәнрәге ачу белән.— Кичә шешә белән кайтып килә,— егет миңа игътибар итмичә сөйләнүендә булды.— Казына. Әйдә, мин әйтәм, «сибик», бакчаңны «яктыртыйк».
— Ә ул? — яшьрәге кешнәде.
— Аракыга аллергия миндә, ди. Ахмак! Тиле!
Мин аларны тыңламый идем инде. Тәрәзәләргә, балконнарга карыйм. Шундый уй туды: теләсә кайсы квартирага шалтыратырга, белергә. Ишек ачылыр һәм... Юк, иң әйбәте — аңа монда, бакчада эшләгәндә карап тору. Танышырга соң түгел... Башта еракτан карарга — кешене хәрәкәтләреннән, аяк атлавыннан аңларга кирәк. Күрәсең, мин күңел кайтудан курыкканмындыр. Минем хыялымда әчкерсез кеше образы туып килә. Җаныңны кешеләргә ачып салырга да батырлык сораладыр, мөгаен. Яхшылык итәргә тырышу билгеле бер күләмдә генә хуплана, чамасы артып китсә, сине акылдан язганга саныйлар. Күрәсең, мин әнә шул киртәне чыгуны телләгәнмендер?! Шулмы соң ул? Мәгъфурмы? Әгәр дә ул булмаса? Бәлки, аңа охшаган бүтәндер, ләкин ваграктыр?

Мин күңел кайтудан курыктым. Ләкин икенче иртәдә мин тагын әлеге билгесез кеше яшәгән йортка таба атладым. «Хәерле көн, кешеләр! Бәхетле булыгыз!» Мин тагын ялмаям. Бакчада беркем дә юк. Нишләргә? Тагын әйләнеп килергәме? Өй ишеге төбендәге эскәмиядә ике хатын һәм кулына себерке тоткан бер карт утыра.
— Сезнең монда бакча икән... Кем утыртты аны? — дим.
— Нигә бу сезне кызыксындыра әле? — ди апаларның берсе.
— Үзегез каян буласыз? — дип сузып кына сорады икенчесе.— Милициядәнме, райисполкомнанмы?
— Мин узып баручы. Нигә мине исполкомнан дип уйладыгыз?
— Берәрсе зарланадыр инде? Узып баручылар монда күп булды инде. Аннары... хат язалар!
Мин пьесамда язган, хыялымда тудырган дөнья белән чынбарлык арасындагы чикнең әкрен генә юкка чыга башлавын тойдым.

Татар апасы башын иеп:
— Фәтхулла абзый, сиңа килгәннәр! — диде.— Комиссия!
Шулай итеп мин Мәгъфурның прототибы белән таныштым. Мин уйлап чыгарган герой белән аларның охшашлыгы гаҗәп иде. Аерма тик шунда: Мәгъфур — пьеса герое, завод кешесе, Фәтхулла Шабанов — чын кеше, игенчеләр нәселеннән, үзе дә иген игүче. Ләкин тегесе дә, бусы да җирнең бакча булуын телиләр... Бу фикер икесендә дә сугыш вакытында туган. Икесе дә беренче алмагачларын анда чакта утырткаңнар. Кан эчендә, үлем дәһшәтендә.
Бакча эскәмиясендә карт үзе турында сөйләде.
— Кырык беренче елның унсигезенче июлендә мин сугышка киттем. Башта элемтәче идем, аннары җиде олау бирделәр, хозротада эшләдем. Кырык икедә яраландым, сигез ай ятып чыктым. Кырык өчтә һәм кырык дүрттә тагын эшләдем. Гомель тирәсендә булды бу хәл. Җирдә бер капчык ята, арыш белән. Нишләп, мин әйтәм, бу байлык әрәм булып ята, хозротада кирәге чыгар. Капчыкка тотынуым булды, аякка һәм корсакка — бер-бер артлы ике пуля. Немец капчыкны прицельдә тоткан икән. Тагын госпиталь. Тугыз ай яттым. Аннары тазардым, ахырга хәтле сугышта эшләдем. Бөтен Европаны йөреп чыктым.
Иң авыр елларда — утыз алтыдан, кырык бергәчә, ә аннан соң кырык алтыдан илле икегә тикле — ул үзенең туган авылы Күлле-Кимедә колхоз председателе була. Илле алтыдан алтмыш бергә кадәр авыл Советын җитәкләгән. Шабанов хисапчы, бухгалтер, кибетче, төзүче булып та эшләгән. Иген дә иккән, йортлар да салган. Үзенә байлык тупламаган.
Мин аның өендә дә булдым — ике бүлмәле фатирның бер бүлмәсе аныкы, хатыны белән икәве, икенче бүлмәдә — күрше.
Гадәти тормыш. Хезмәт. Ләкин хезмәтне ул эш өчен генә, үз тамагын туйдыру өчен генә башкармаган. Аның хезмәтендә тирән мәгънә бар. Хәтта сугышта катнашуны да ул эш, хезмәт дип кабул иткән.
Һәм менә соңгы эш. Инде «финиш сызыгына» җиткәндә, бушлыкта бакча үстерү уе. Кер, утыр, саф һава сула, күккә кара. Бәлки синең дә күңелеңә якты уйлар килер?!

Купме инде ул пенсия акчасы?! Шулай да азрак янга калдырып була икән һәм ул эскәмия ясарга, яңа үсентеләр алырга өлеш чыгара. Әмма һәр матур эш — ул әле каршылыклар белән көрәшү дә, чөнки синең эчкерсезлегеңне аңламыйча син нән үк шикләнә башлыйлар.

Тормышның бу ягы турында, явызлык белән көрәшү хакында, карт, эскәмиягә утырганда, миңа болай диде:

— Чүп-чар өелеп ята иде, плитәләр, ком. Үлән үсми. Торф алып килдем, бакча үстердем. Икенче каттагы бер хатын көнләшә башлады. Бөтен җиргә шикать яза. Кемнәр генә килмәде! Участок инспекторы килде.— «Синме Шабанов?» — «Мин Шабанов».— «Нигә беседка ясадың?» — «Кешеләр яңгырдан ышыклана алсын өчен. Журнал укыйлар».— «Җимер!» — «Юк, ватмыйм».— «Синең ни хакың бар? Кем рөхсәт итте? Үзең дүртенче катта, монда алмагачлар үстерәсең?» — «Мин уңынчы катта да яши алам».— «Җимер!» — «Син ват, мин тагын утыртырмын».— «Ә-ә! Шулаймы?! Буйсынмыйсыңмы? Яхшы чакта сүтеп ташла!» — «Мин сугыш һәм хезмәт ветераны, мактау грамоталарым бар, алты бүләк алдым, гомеремдә, бернәрсә дә җимергәнем юк»,— дип аяк астына төкердем дә исполкомга киттем. Икенче көнне бакчада милиция киемендә ике кеше күрдем. «Нәрсә, ватарга килдегезме?» — «Ник ватарга? Маладис!» — «Участковый бәйләнә».

— Шуннан? — дип сорыйм мин карттан.

— Хәзер миңа сәлам биреп китә, «сез» дип кенә эндәшә.

— Теге шикаять язган хатын нишләде?

— Белмим әле. Минә кәтәм инде.

— Озак көтәргә туры килер микән?

— Үземне дә кызыксындыра. Монда төп нәрсә — хезмәт,— карт миңа җитди, тыныч итеп карады.— Үсентеләр өскә үрмәли. Бакча күтәрелер. Хезмәт кирәк.

Мин шаккатып куйдым: минем алда бирчәйгән кулына себерке тоткан, иске бишмәт кигән карт түгел, бөек бер утопист, тәҗрибәче утыра бит. Ул яхшылык белән яманлыкны сайлап тормаган, күзгә артык бәрелмичә, сабыр гына үз хәленчә, дөньяны явызлыктан арындырырга керешкән. Үзенең очраклы реаль яшәешен ул кеше чынбарлыгының идеаль асылы белән куша. Бәлки ул моны белмәгәндер дә. Мөгаен, белмәгәндер, борчулары, теләкләре, хисләре белән, дөньяны бер бөтен кабул итеп тыныч кына яшәгәндер.

«Хәерле көн, кешеләр! Бәхетле булыгыз!» — аның бу өндәмәсендә эшлекле из гелек һәм бернигә дә дәгъва кылмый торган эчкерсезлек бар. Бу кеше субъективлык богауларын өзеп ташлаган. Фәтхулла Шабанов минә шушы сирәк очрый торган көчле кешеләр токымыннан.

Озакламый мин шәһәрнең икенче районына күчтем һәм бу картны ике елдан соң гына кабат күрдем. Килдем һәм бу тирәне танымадым. Бакча актарылып ташланган. Бер генә агач та, үлән дә юк. Шундук, Фәтхулла Шабанов белән бер-бер хәл булгандыр дигән уй туды. Исән булса, бакча да яшәр иде. Шулай булып чыкты да: картның йөрәге күтәрә алмаган. Бакча аша җылылык трассасымы, канализацияме үткәргәннәр. Нәкъ пьесамдагы кебек.

Мин аның хатыны белән сөйләшеп утырдым һәм уйладым: аның хезмәтендә берәр мәгънә бар идеме соң? Бернәрсә дә калмаган бит. Шулай да мәгънә бар! Истәлек калды. Кешеләр күңелендә. Мин мондый кешеләрнең киләчәгенә ышанам. Андыйларны очратсаң, җанга шатлык тула. Мондый кешеләр өмет бүләк итәләр.

## Гаделлек сакчысы

Урта Уралда, тар гына елга үзәнендә, Татар Яман Елгасы дигән мәзәк исемле, бәләкәй генә авылның өйләре таралып ята. Бу авылга XVI гасырның уртасында Идел буеннан күчеп килгән кешеләр нигез салган.

Гасыр артыннан гасыр узган. Бер буын кешеләрен икенчесе алыштырган. Татар Яман Елгасы авылы көчле һәм мостәкыйль кешеләре белән тирә-якта билгеле булган. Ат каракләры аны читләтеп үткән. Күрше авыл кешеләре дә аларны юк бар белән борчымаска тырышканнар. Екатерина II заманында, Урал һәм Идел буенда Пугачев явы күтәрелгәч, бик күпләр восстание җитәкчесенең якын көрәштәше «полковник» Канкаев отрядына язылган. Бик күпләр яу кырында һәлак та булган.

Архивларда кызыклы гына тарихи истәлекләр саклана. XIX гасырның җитмешенче елларында бу төбәк татарларын чорнап алган зур чуалышларда Яман Елга кешеләре күкерт кебек кабынганнар, үзләренең «генетик» «юлар» гадәтләрен күрсәткәннәр. «Властьларга буйсынмаган өчен» берничә кеше Себер каторгаларына җибәрелә һәм шунда гүр иясе була.

Менә шул чорда хуҗасыз калган бер гаиләдә Афзал Исламов дөньяга килә.

Афзаллар токымына көчле һәм акыллы кеше нигез салган. Тырышлыгы һәм хезмәте белән кеше рәтенә чыккан, авылдашлары өчен аның сүзе сүз булган. Шуңа күрә дә революциядән соң Яман Елга кешеләре аны ярлылар комитетының беренче председателе итеп сайлаганнар. Ләкин ярлылар комитеты җир бүлә башлагач кына — 1918 елның җәй башында — чех корпусы фетнә күтәрә һәм Идел буеннан Себергәчә бөтен юлларны биләп ала. Авылларга җәза отрядлары тарала, партия членнарын һәм башка активистларны эзәрлекләп. Подпоручик Кобяков командалыгындагы шундый җәза отряды Татар Яман Елгасына килеп төшә. Бер мәгълүмат та бирмәгән һәм башка активистларның исемен дә әйтергә теләмәгән Афзал Исламовны Кобяков бишкисәрләре, бөтен халык алдында, үтергәнче кыйныйлар. Җәза отрядының ат тояклары ишетелми башлагач кына, кемдер канга баткан җансыз гәүдәне калын киндер белән каплый. Афзал Исламов шәһит китә, аның алты улы, ике кызы кала.

Афзалның беренче кызы җиде бала үстерә. Аның өлкән улы фронтта, Сталинград тирәсендә һәлак була. Афзалның иртә үлгән икенче кызыннан бер малай кала, ул да Кенигсбергта һәлак була.

Беренче улы 1914 елны, урман өчен дәгъвада эләгеп, җиде елга каторгага хөкем ителә. Февраль революциясеннән соң гына авылына кайта, яңа власть урнаштыруда актив катнаша. 1926 елда сугышта алган яралардан вафат була.

Камчылап үтерелгән ярлылар комитеты председателенең икенче улы беренче бөтендөнья сугышында катнаша, әсир төшә. Германиядән 1919 елны гына туган авылына кайта, «Яңа тормыш» коммунасын оештыручыларның берсе була. Биш малаеның икесе, Бөек Ватан сугышында катнашып, хәбәрсез югалалар.

Афзалның өченче улы 1919 елның көзендә Кызыл Армия сафларына языла һәм, татар-башкорт бригадасы составында, гражданнар сугышында, Урта Азиянең төрле төбәкләрендә басмачыларга каршы көрәштә катнаша. Яралану сәбәпле, 1924 елда демобилизацияләнгәч, беренчеләрдән булып «Яңа тормыш» колхозына керә һәм Бөек Ватан сугышы башланганчы төрле эшләрдә йөри. 1941 елның сентябрь аенда үзе теләп фронтка китә һәм, ике айдан, Мәскәү янындагы сугышларда һәлак була. Аның ике кызы һәм өч малае кала.

Афзал Исламовның дүртенче улы революциядән соң укытучылар хәзерләү курсларында укып чыга, авыл Советы рәислегенә сайлана, укытучы була, «Яңа тормыш» колхозы оешкач, унбиш ел — аның беренче председателе. Аның унбер баласы була.

Ярлылар комитеты председателенең бишенче улы егерменче елларда авыл Советы секретаре, аннары председателе вазифаларын башкара, Урал коммунистик университетында белем ала. Укуын тәмамлагач, партия райком секретаре, райисполком председателе булып эшли.

Алтынчы улы, Мәннәф Афзалов, крестьян яшьләре мәктәбен тәмамлап, Свердловскида рабфакта укый, укыта, Кызыл Армиядә хезмәт итә. Армиядән соң НКВДның район бүлегендә эшли, урта мәктәптә директор була. 1938 елны партия райкомының инструкторы итеп билгеләнә, акфиннар белән сугышка үзе теләп китә һәм 1940 елда һәлак була. Аның кызы белән ике малае кала.

Монда мин Афзал Исламов токымының берсе, Мәскәү янындагы сугышта һәлак булган Бәдретдин Афзаловның малае Наил Афзалов турында гына сөйләмәкче булам. Ләкин мин Афзаловлар токымының шәҗәрәсенә очраклы рәвештә тукталмадым. Без нигәдәр беркайчан да гади гаиләләрнең — крестьяннарның һәм эшчеләрнең шәҗәрәсе турында язмыйбыз, ул агач исә бик киң тармаклы, көчле тамырлары гасырлар тирәнлегенә китә. Афзаловлар буыны да бик гыйбрәтле. Ул баш күтәрүчеләр, күчеп утыручылар, берничә буын каторжаннар, партизаннар, ярлылар комитетчылары токымы, яңа тормыш коручылар, укытучылар, партиянең принципиаль эшлекләре, ирекле солдатлар. Беренче бөтендөнья сугышында, гражданнар сугышында, ак финнар белән һәм Бөек Ватан сугышында көрәшкәннәр. Кыскасы, көчле кешеләр, заманның иң авыр йөген үз җилкәләренә салучылар — сугышта да, тыныч тормышта да.

Бөтен вакыйгаларга кагылып тормыйм. Мәсәлән, Афзаловларның, бөтен ил белән бер булып, сугышта катнашып, ничек һәлак булуларын тасвирлап тормыйм. Бу аерым сюжет һәм бик гыйбрәтле. Шулай да, ике генә сүз белән... Аларның беренчесе, әйтик, Сталинградта һәлак булганы, бөтен расчетын югалтса да, берничә сәгать буена үзенең пушкасы белән танкларга каршы оборона тота; аны яралыйлар, ул танкларга каршы туры наводка белән бәрә; икенче пуля тия аңа, тагын — туры наводка; өченче яралану...

Документаль шаһитлар бар. Кеше үлә, шаһитлар кала.

Афзаловлар токымының икенчесе, Мәскәү янында үлгәне — безнең геройның атасы, пулеметчы. Бер-берсенә гаҗәп охшаш күренешләр: сурәтләп тормаска да мөмкин. Пулемет уты белән туракланган немецлар һәм дүрт мәртәбә яраланган үз гәүдәсе...

Шундый тәэсир кала: Афзаловларны үтерергә мөмкин, ышанычлы булсын өчен,

берничә мәртәбә атарга мөмкин, әмма, әгәр алар исән калсалар, алар аша атлап чыгып булмый. Кешенең соңгы минутлары хакында тагын шундый ук сюжет — нәселдән килә торган ниндидер тетрәндергеч сыйфат — Кенигсберг янында үлгән Афзалов турында укыйм мин. Хыялда гаҗәеп картина туа; инде ике мәртәбә яралы кеше тагын атакага күтәрелә. Аңа ике генә пуля аз, өченчесе, соңгысы кирәк!

Исең китәрлек үҗәтлек, аңлап бетерүе кыен булган, нәселдән килә торган омтылыш — үз тормышыңны иң ахыргы сызыкка китереп җиткерү. Әллә кеше куркыныч кәтә, әллә куркыныч үзе кешене эзли?

Һәм тагын бер сыйфат — бала-чаганы күп калдыралар. Монда, күрәсең, тормышка, аның куәтенә ышану көчле. Үрентеләр үссә — әрәм булмаслар, тормыш үзе аларны күтәрер, дип уйлый торгандыр бу тамыр кешеләре. Шунысы кызык, чынлыкта бу шулай да. Бер карасаң, хәерчелек, үксезлек, бөтен ил хәрабәләрдә һәм ялангачлыкта, җирне салкын җил каезлый, шулай да Афзаловлар шытымы күтәрелә. Яңадан шул ук каты, үҗәт яшь ботаклар үсә. Аларда — шул ук оптимизм, шул ук кодрәт. Һәм бөтенесе яңабаштан башлана. Ыру яшәешенең яңа әйләнеше.

Герой рухының табигатен билгеләгәч, ул хәл итәргә омтылган мәсьәләләр чиген билгеләргә телим. Көчле шәхесләр, эпохалар сынганда, янәсе, «бөтен җәмгыять тормышының тамырдан яңарган» чорында барлыкка килә дигән фикер яши. Ләкин хәзер мин бүтән кеше турында язам. Ниһаять, Наил Афзалов, тикшерүче, милиция капитаны... Укучым атышлар һәм эзәрлекләүләр көтә? Юк. Дөрес, аның тормышында тегесе дә, бусы да булган, сүз башка нәрсәләр хакында. Сүз бер кешенең икенчесе артыннан куы турында түгел, ә дөреслек артыннан чабуы хакында барачак. Менә бу кешенең егерме ике ел шөгыльләнгән мәсьәләсенә кагылышлы мәгълүматлар.

1965 елның август аенда «Известия» газетасында милиция капитаны Д. Ермаковның Львовтагы бер хәл турындагы мәкаләсе. Өч яшь егет, төрле вакытта бер үк кеше тарафыннан каты яраланганнар. Мәкаләдә шундый сорау куела: нишләп бу кеше беренче җинаятеннән соң иректә калган? Ни өчен милиция хезмәткәрләре аны тоту чарасына керешмәгәннәр һәм шуның белән яңа җинаятьләр эшләнүгә булышлык иткәннәр? Хикмәт шунда ки, беренче җинаять, күрсәткечләрне «бозмас» өчен, хәтта исәпкә дә алынмаган...

«Советская милиция» журналы, 1966 елның январе. РСФСРның җәмәгать тәртибен саклау министры В. Тикунов мәкаләсе. Министрлык бригадасы тикшерүеннән күренгәнчә, Архангельск өлкәсендә йөздән артык җинаять теркәлмәгән. Йөз кешедән гариза да алып тормаганнар. Северодвинскида егерме сигез очракта җинаятькә каршы эш кузгатылмаган.

Шулай итеп, мәсьәләнең беренче чикләрен ачыкларга мөмкин. Вакыйга урыны — Львов, Архангельск, Северодвинск... Җитмешенче еллар... Матбугатта беренче чаң кагыла. Бәлки ул типик күренеш түгелдер, очраклы гына булгандыр һәм җәмәгатьчелекне әллә ни борчымагандыр?

«Известия» газетасы, 1979 елның март ае. Грозный шәһәре Советы депутаты слесарь А. Рябухин мәкаләсе. Депутат буларак, сессия вакытларында һәм сайлаучылар белән очрашканда, аңа еш кына «хулиганлык очракларын яшереп калдыру» турында ишетергә туры килә. Милиция отчетында барысы да ал да гөл, чынында исә, кич белән кешеләр урамга чыкмауны хәерлерәк дип саныйлар.

Бу «мәсьәләгә» карата капитан Афзалов җыйган материаллар тау кадәр — барысы да охшаш. Полтава өлкәсендә, Молдавия ССРда, Енакиев, Чита, Чимкент, Кустанай, Тула, Пермь, Казан шәһәрләрендә... Тик мәсьәлә сиксәненче елларда үзенең үткерлеген югалтмадымы? Бәлки капитан инде юк ителгән күләгә белән көрәшкәндер?

«Правда» газетасы, 1983 елның декабрь ае. СССР эчке эшләр министры В. Федорчук шушындый ук «волокиталар», «яшереп калдырулар» хакында газета укучыларына үзенең җавабында Днепропетровск һәм Донецк өлкәләрен искә алып китә.

Бер шәхси вакыйга, икенчә факт, өченче, унынчы... Аның артында ни ята? Социаль мәсьәлә, куркыныч чир. Һәм вакытта, һәм тирәлектә киңәя баручы чир. Сиксәненче елларда илебездә тәртип саклау органнарының эшчәнлеген яхшырту буенча җитди һәм зур эш алып барыла.

Җинаятьчеләрне эзләү, тапкач, аларның гаебен исбат итүгә караганда, җинаятьләрне «күрмәү», әлбәттә, җиңелрәк. Ләкин аңардан җәмгыятькә җиңеллек киләме? Бер төрле исәп-хисап аерым кеше күңеленә хуш килергә мөмкин,— аның өчен премия дә, бүләк тә алып була,— ләкин аңа карап кына тормыш яхшырамы?

Капитан Афзалов, гади тикшерүче, шул сораулар хакында беренчеләрдән булып уйлана башлый. Бер кеше нишли ала? Фараз кылыйк, берәү «чир» күрде ди, аңа диагноз куйды. Ләкин ул көрәшкә чыгарга батырчылык итәрме? Әгәр инде тәвәккәлләсә, ул нәрсә эшли ала?

Капитан тәвәккәлли. «Матур отчет» уены ул эшләгән бүлектә дә «чәчәк ата» һәм ул җыелышта чыгыш ясарга карар кыла.

Ләкин бернинди дә үзгәреш сизелми, гадәти уен дәвам итә, мөнәсәбәтләр исә шундук үзгәрә: элек тикшерүчене «тел тидермәслек» эшләгәне өчен мактасалар, хәзер орышкалый башлыйлар. Дусларча гына әйтелгән беренче кисәтүләр ишетелгәли: җилгә каршы төкермә. Ләкин үз намусы кисәтүләрдән көчлерәк булып чыга һәм капитан тагын чыгыш ясый... Билгеле, кинәт «набат каккан» кешеләрнең кайберләре шәхси файда өчен тырыша. Ләкин арада җәмгыять мәнфәгатен кайгыртучылар да бар. Үзләренчә, алар, берәр төрле фикернең күңелле яклаучылары, Дон-Кихот кебек хәтта аңлашылмый торган сәер көрәшчеләр. Һәрхәлдә, алар шундый ук куркусызлар. Аларны шәхси җиңелү, бу адымның үзләренә күңелсезлекләр китерәчәге һич куркытмый шикелле.

Күңелсезлекләр исә һич кичекмәстән ява башлый.

Н. Афзаловның доклад язмасыннан: «Минем гаризаны тикшерү нинди сәбәпләр аркасында сузыла. Бу вакыт эчендә бүлек җитәкчелеге журналларны тикшерү белән шөгыльләнде, кайбер җинаятьләр, ашыгыч рәвештә, узган көн белән теркәлделәр. Комиссия җитәкчесе полковник Дорофенко (фамилиясе үзгәртелде. Д. В.) бер айдан килеп төште һәм миңа тупас рәвештә басым ясый башлады. Фактларны тикшереп тормастан, нигезсез рәвештә «Фактлар расланмады»,— диде һәм мине яла ягуда гаепләп, мыскыл итә-итә органнардан куу белән янады. Полковник Дорофенко җыелышта да, «тикшерү» нәтиҗәсе турында сөйләп, бер генә факт та расланмады, диде, һәм, ышанычлырак булсын өчен, аңа тикшерү эшен тапшырган авторитетлы органнарга таянды. Ялган информация нәтиҗәсендә мине яла ягуда, җыелышта үз-үземне дөрес тотмауда һәм үз хаталарымны танымауда гаепләделәр. Хәзергесе вакытта мин фактта эштән читкә тибәрелгән, һәм бүлек җитәкчеләре, һәм Дорофенко минем белән исәп-хисап өзүне ахыргача җиткерергә омтылалар, ягъни минем эштән китүемә ирешергә телиләр...»

Ай буе капитан эшкә йөри һәм көннәр буе буш өстәл артында утыра. Хезмәт хакын аңа әле түлиләр, ләкин җинаятьчеләрне тикшерүдән ул инде читләштерелгән. Бер айдан хезмәт хакы килү дә туктый. Армиядә өч ел хезмәт иткән һәм унҗиде ел «тел тидермәслек» эшләгәннән соң, кеше үз һөнәреннән читләштерелә. Эштән азат итү турындагы приказда: «хезмәт буенча яраксызлыгы аркасында» дип языла. Күп айларга сузылган йончыткыч дуэль башлана.

Аның хатыннан: «Мине эштән җибәрү мәсьәләсе берьяклы һәм алдан ук ялгыш фикер йөртү аркасында, вакыйганың асылын исәпкә алмыйча хәл ителгән...»

Җавап хаттан: «Сезне эшегезгә кайтару турында шикаятегез каралды. Сез эштән дөрес азат ителгәнсез, шуның аркасында Сезнең үтенечне канәгатьләндерә алмыйбыз».

Аның гаризасыннан: «Сез минем хатны укып та карамагансыз. Гомеремнең иң яхшы елларын милиция органнарында эшләүгә биргән кешенең язмышы Сезне кызыксындырмый да. Урынбасарыгыз, эшнең төп асылын белмичә торып...»

Җавап: «Икенче тапкыр белдерәбез: гаризагыз алынды һәм каралды. Үтенечегез кире кагылды».

Һәр хат белән җавап арасында ай, ай ярым, хәтта ике ай вакыт үтә бара. Аларның һәр көне, һәр төне көтеп, өмет һәм сабырсызлану белән узган. Һәр көне учакка тиң, анда — җан яна.

Җавап тагын кыска һәм эдәпле: «Гаризаларыгыз каралды. Хәбәр итәбез: кабул ителгән карарны яңадан тикшерү өчен нигез юк».

Ул: Мине ялганда, яла ягуда һәм җыелышта үземне дөрес тотмауда гаепләделәр. Ләкин райком бюросында гаепләүнең төп пункты — ялган һәм яла ягу төшеп калды. Җыелышта, янәсе, үземне дөрес тотмавым һәм иптәшләремне мәсхәрә итүем — төп гаеп булып калды. Ләкин миңа аңлашылмый, закон бозучыларны ачып салу — аларны мәсхәрәләү микәнни? Мин ни өчен эштән куылган һәм яшәү чыганагыннан мәхрүм ителгән соң? Еллар буена закон бозу практикасын туктатырга, дөреслекне эзләгән һәм хәзер дә аның өчен көрәшергә теләгән өченме?»

Җавап: «Сезнең эшегезне карау белән берничә мәртәбә шөгыльләнделәр. Тикшерү нәтиҗәләре Сезгә мәгълүм. Без ни эшләргә дә белмибез, чөнки Сез күтәргән мәсьәләләрне хәл итә торган органнар тикшерүе Сезне канәгатьләндерми. Сәлам белән...»

Капитанның хатыны сөйләвеннән:

— Эштән чыгарып, ул тугыз ай буена эшсез торганда, бик кыен булды. Көчләрен һәм төннәрен утыра, яза. Мин аның белән утырам. Мин хәтта искә төшерергә дә куркам. Авылдан кунаклар килә иде. Без аның эшсез икәнен әйтмибез, бурычка акча алып, аларны сыйлыйбыз, театрларга йөртәбез. Ул райкомга яки обкомга барып кайта, аннары — тагын кунаклар белән. Аларга шәһәр күрсәтә. Шәһәр тарихын бик яхшы белә: кайда нинди йорт тора, ничәнче елны салынган... Минем оклад медицина лаборанты акчасы, җитмеш биш сум иде. Бу хәл алдыннан гына без кооператив квартира төзеп, әҗәткә кергән идек. Безнең үз балаларыбыз юк. Ләкин без беркайчан да баласыз яшәмәдек. Илленче елның сентябрендә без язылыштык, туй ясадык, январь-

да безгә Робертны, аның энесен бирделәр. Без гомер буе кемгәдер булыштык: эти-әниләргә, энекәшләргә, сеңелләргә. Аның сеңелесенең кызы бездә өч ел торды. Ике яшеннән минем бертуганымның кызы яши. Менә без дүрт җан, ә эш хакы җитмеш биш сум. Балалардан яшерергә тырыша идек, сизмәсеннәр дип, ә ничек яшерәсең: өстәл буш. Мин бер ярым ставкага эшли башладым. Ә ул төннәрен йокламый, нидер яза, ерткалый. Мин аңа, җитәр, беркемгә дә бернәрсә дә исбат итә алмассың, икенче эшкә урнаш, дим. Ул — юк, хаклык барын исбат итәм, ди. Бер тиен акча юк, аңа дәреслек кирәк! Бөтен кәгазьләреңне яндырам, дим. Ул миңа: юк, Аня, чигенергә ярамый, сабыр ит, әйләнә-тирәдәге кешеләр дә хакыйкатьсез кала, ди. Алар хакына сабыр ит...

Тормышта чишелмәгән мәсьәләләр күп. Еш кына без лаф орабыз: тегесе болай түгел, бусы тегеләй түгел. Тик нинди дә булса мәсьәләне хәл итү өчен, үз өстенә җаваплылык алып, халык алдына чыгарга — ходай сакласын! Нигә? Куркыныч! Кайберәүләр ачыктан-ачык әйтә: «Ә җиңүеңә гарантияң бармы?» Яхшылык эшләү өчен — гарантия кирәк, ә?! Гарантия булса (тик аңлашылмый), аны кем бирергә тиеш? Без явызлык белән көрәшә башлыйбыз, хәтта җиң сызганып, юк икән — гафу итегез...

Ни әйтсәң дә, күпмедер дәрәҗәдә, болай уйлаучылар хаклы. Әйтик, без нинди дә булса «яман шеш» күрәбез. Кайчагында җәмгыять тә авырый, һәм бу авыру астан гына безнең яшәешебезне ашый, җимерә. «Гарантиялеләр», күрәсең, авырулардан өстен, шулай булгач, эч пошуны тәмәке тарта торган урында яки коридорда бетерү хәвефсезрәк дип фикер йөртәләр. Ә «гарантия» таләп итмәүчеләр? Кем аларны (кайчагында берүзләре генә) җәмгыятьнең авыр тәгәрмәчен әйләндерергә һәм хәтта кайчак аның астына ятарга мәҗбүр итә? Нигә алар, без инде «машина» гасырына кердек, кеше ихтыяры бетте, дип уйламыйлар һәм гасырны үз кулларына алырга батырчылык итәләр?

Катлаулы вакыйгаларга бәйле кеше язмышы кайчак кеше мөмкинлекләренең гомум дәрәҗәсенә күтәрелә, мин әйтер идем, гомумән, кешелекнең «булу-булмавы» дигән глобаль мәсьәләгә әверелә.

«Гарантиялеләр» ягына басу — кешенең бәләкәйләнгән, ихтыярсызлыгын, бернигә дә ярамаганлыгын тану. Әмма саф күңелле кеше үзенең өметен әхлакның башка нигезләренә бастырырга тели. Монда фәлсәфә дә бүтән, ниндидер гарантия турында уйламыйча, җәмгыять күләм фикер йөртү чагыла.

Н. Афзалов хатыннан: «Миңа һәм минем якыннарыма төзәтеп бетерә алмаслык әхлакый җәрәхәт ясадылар. Минем сәламәтлегемә дә зыян килде. Болары хосусан безгә генә кагыла. Ләкин аннан битәр коточкыч мораль зыян әйләнә-тирәдәгеләргә төшәргә мөмкин бит, чөнки алар гади кешенең намуслы бер талпынышы ни белән тәмамлануын күреп торалар. Менә ни өчен мин мәсьәләне әлегәчә чишелеп бетмәгән дип уйлыйм».

Битарафлык, ваемсызлык машинасы җавапларны штамп белән бирә торды, ләкин инде анда да ару һәм аптырау галәмәтләре сизелә иде.

Аңа җибәрелгән хаттан: «Гаризагыз буенча үткәрелгән тикшерүдән соң законлылык бозуның кайбер фактлары расланды. Бу эштә булган кимчелекләрне бетерү буенча тиешле чаралар күрелә».

Һәм мондый җаваплар күбәйгәннән күбәя бара.

Капитанга каршы кешеләр, никадәрле генә көчле булмасыннар, ялгыштылар. Алар нинди токымнан икәнен игътибарга алмаганнар. Мин юкка гына Афзаловларның сугышта үз-үзләрен ничек тотуларын язмадым. Аларны бер генә пуля белән егып булмый, өч, дүрт мәртәбә атарга кирәк, исән булсалар, алар аша атлап узу мөмкин түгел. Шундый токымнан булган капитан түзмәскә тиеш идемени?!

Хәлдән тайдыргыч дуэль тугыз ай буена дәвам иткән. Эшсез калдырылган, яла ягылган, хур ителгән кеше япа-ялгыз көрәшә. Көрәш шуны раслый: дөреслек ягындагы кешене җиңеп булмый. Үлчәү тәлинкәсе әкрен генә, ләкин сизелерлек рәвештә аның файдасына авыша. Ниһаять, КПСС Үзәк Комитеты каршындагы комиссия аны тулысынча аклый һәм кичекмәстән эшенә кире кайтару мәсьәләсен куя.

Тугыз айдан соң, формасын киеп, дулкынланып, капитан иртә белән яңадан бүлек бинасы янына килә, үз кабинетына аяк баса. Башка бүлеккә билгеләүләрен үтенеп тә булыр иде, җитәкчеләр дә шулай телиләр, ләкин ул нәкъ үз урынына кайтаруларын сорый. Хакыйкать өчен көрәш бетми, бары аның бер этабы гына тәгәлләнә, капитан әле үзен җиңүче итеп сизми. Хәер, нинди җиңү турында сүз булуы мөмкин? Эш алымнары шул килеш кала. Мәсьәләне чишү өчен гомуми тәртиптә кардиналь чаралар күрергә кирәк. Һәм көрәш дәвам итә. Көчләр элеккечә. Бөтен «катнашучылар» элеккечә үз позицияләрендә кала бирәләр. Хакыйкатьне яклаганы өчен аңа бирәү дә җиңү таҗы кидерергә җыенмый. Хаталарны, җитешсезлекләрне күрсәтү, җәмгыять мәнфәгатен алга сөрү юлында фаш ителгән гаепле кешеләрне ачыклау көрәшне кискенләштерә бара. Беркем дә үз-үзен гаепле итеп танырга ашыкмый. Киресенчә, көчле саклану ныгытмасы кора. Көрәшкә күтәрелә, һич кенә дә уйламаган чаралар эшкә

җигелә. Мондый чараларның берсе — Дорофенко һәм аның яклаучылары әвәләгән ялган документ. Ул уйдырманы тикшерү өчен ике тапкыр бригада килә. Ләкин моннан да берни барып чыкмый.

Элекке урынында яңадан эшли башлауга, капитан бик яхшы аңлый: аңа мөмкин кадәр төгәл булырга, кечкенә генә хата да җибәрмәскә кирәк. Һәм ул ювелирларча төгәллек белән эшли. Соңыннан аны барыбер икенче урынга эшкә күчерәләр. Аңа башта майор, ә бераздан подполковник дәрәҗәсе дә бирәләр. Бәлки кеше тынычлангандыр, чаң сугудан туктагандыр? Юк, хәл ителмәгән әһәмиятле социаль мәсьәлә аны барыбер борчый.

Кырык сигез яше тулгач, бу вакыйгалар башлануга унбер ел узганнан соң, ВТЭК аны инвалид дип таба. Афзалов сукырая. Күпьеллык көрәш эзсез үтми, аның күзләренә суга.

Ул отставкага чыга. Айлар, еллар буе дәвалану, күз больницаларына йөрү. Бәлки инде кеше тынычлангандыр? Ни әйтсәң дә — инвалид. Башкалар көрәшсен! Мөгаен, аның җәмгыятькә булган хисләре дә тоныклангандыр, бәлки, сүнгәндер? Юк, бу кеше элекке еллардагы кебек үк, һич курыкмыйча һаман да шул ноктага бәрә: «матур отчетлар» уены илдә җинаятьчелек белән көрәшүгә комачаулый, алдашу һәм үз-үзеңне алдау гадәтен бетерергә кирәк...

Мин документлар актарам: «Сез куйган сораулар һәрвакыт игътибар үзәгендә...» «Исәпкә алу һәм регистрацияләүне яхшырту турындагы тәкъдимнәрегез каралды...» «Безнең тарафтан тиешле тәкъдимнәр кертелде һәм алар Сезнеке белән тәңгәл киләләр...»

Чыннан да, тәртип саклау органнарының эшен яхшырту буенча илдә җитди эш алып барыла. Бу турыда ишеткәч, минем күңелдә егерме ел буена, бары үзенә генә ышанып, берүзе бу мәсьәләне күтәргән капитан турындагы хатирәләр яңара. Үзенең яшәү факты белән генә дә башкаларны бу мәсьәләне чишәргә мәҗбүр иткән бит ул.

Шулай да ни өчен шул кадәр үҗәтләнеп көрәшкән соң безнең капитан? Нәрсә хакына? Аның берәр төрле югары идеясе булганмы?

Бу турыда үзеннән сорыйм. Инде утыз җиде яшьлек капитаннан түгел (көрәш башлаганда аңа шулай була), илле тугыз яшьлек кешедән сорыйм.

— Ни өченме? Чөнки кешенең яши торган өе чиста булырга тиеш. Ләкин чисталыкны куллары чиста кеше генә урнаштыра ала.

— Үкенү юкмы? Ихтимал, әлегрәк үкенгәнсездер? — Мин дә үҗәтләндем.— Бу вакыйга сезнең үзегезгә ни бирде? Инвалид булып калдыгыз. Күзләрегез күрми, аягыгыз йөрми.

— Юк. Үкенмәдем. Мин дөреслек җиңәчәген күреп тордым.

— Кайсы яхшырак: күзләрнең күрүеме, әллә башка кешеләр өчен яуланган хакыйкатьнең күренүеме?

— Бу сорауга һәркем үзенчә җавап бирә. Минемчә, яшәү мәгънәсенең һәлакәтен күргәнче, сукыр калуың яхшырак.

— Ә сез ышанып әйтәсезме, яшәүнең мәгънәсе бармы?

Ул мине көйдереп карады. Аның күрми торган караңгы күзләрендә ышаныч уты дөрли иде.

## Шәфкатьле кеше

Горький тимер юлының Казан бүлегенә караган 13 нче ашханә мөдире белешмәсеннән:

«1983 елның 4 июнендә ашханәгә Казан шәһәренең Ухтомский урамы ... йортта ... квартирада яшәүче г-н Ә. Г. Галимҗановтан гомуми авырлыгы 1468 килограмм булган дуңгыз ите алынды. Ә. Г. Галимҗановның гаризасы буенча, 1622 сум 96 тиен акча Ленин районының Сәламәтлек саклау бүлегенә күчерелде».

Казан шәһәренең 1 нче Балалар йорты каршындагы Җәмәгать советы члены, СССР фәннәр академиясенең А. Е. Арбузов исемендәге институтының кече фәнни сотруднигы, химия фәннәре кандидаты Р. М. Сәгыева хатыннан:

«Сүз Казан шәһәренең Бауман райпищеторгына караган 117 нче кибетендә йөк ташучы Ә. Г. Галимҗанов хакында бара. Аның хезмәт хакы күп түгел —110 сум, ул читкә дә эшләштергәли, колхоз базарында сату итүчеләрнең әйберләрен китереп куя, саклый. Аңа акчаның әллә ни кыйммәте юк. Аның балачагы сугыш вакытына туры килгән, белем алу мөмкинлегеннән мәхрүм булган. Ләкин ул җир йөзендә үз эзен калдыру теләге белән яна.

Җәмәгатьчелек ярдәме белән, Бауман район советы башкарма комитеты тарафыннан Межлаук урамы башында аңа җир бүлеп бирелә. Элек бу урынга теләсә кем чүп

ташлый торган була. Ул аны чистарта, җиләк-җимеш куаклары утырта. Ул аны тигезли, сазлык урынына вак таш, ком җәя, ватык колонкадан аккан суны читкә борып җибәрә. Урам кешеләре аңа рәхмәт укый. Аннары агай иске-москы материаллардан корылма ясый — дуңгыз абзары һәм азык кухнясы.

Соңгы елларда гына да бу кеше тынычлык фондына — 600, балалар йортына 13 000 сум акча күчерә. Бер уйласаң, гомуми эшкә керткән өлеш шактый һәм ул моңа каршы бернәрсә дә сорамый, карусыз эшли. Без, кызганычка каршы, аңа берничек тә ярдәм итә алмыйбыз, чөнки аның бу «хуҗалыгы» законлаштырылмаган: ул беркемнеке дә түгел һәм бу мәсьәләне һичничек хәл итеп булмый. Ә. Г. Галимҗановка азык табуы, бигрәк тә кыш көннәрендә, ифрат авыр. Без, 1 нче Балалар йорты каршындагы җәмәгать Советы членнары, гомумтуклану баш идарәсендә, торак-коммуналь хуҗалыгында булдык, район администрациясенең һәм тиешле министрлыкның ярдәм итүен үтендек, ләкин үтенечебезне кире кактылар. Балалар йортының филиалы булырлык бу ярдәмче хуҗалыкның һәм иптәш Галимҗановның хәле безнең өчен барыбер түгел. Әгәр җәмәгатьчелек гадәттән тыш игелекле бу кешегә карата ваемсызлык күрсәтсә, бу зур гаделсезлек булыр иде».

* * *

Казан шәһәренең Бауман район Советы башкарма комитеты председателе язмасыннан:

«Гр-н Ә. Г. Галимҗановка телдән генә, 5 дуңгыздан артык асрамаска, дип, рөхсәт бирелде. Хәзерге көндә ул 22 дуңгыз тота, ә бу — санитария нормаларын бозу. Моннан тыш, ул үз белдеге белән бу участокта йорт һәм хуҗалык биналары төзегән. Гр-н Ә. Г. Галимҗановка язма рәвештә йортын җимерергә кушылды...»

* * *

Казан шәһәренең 1 нче Балалар йорты баш врачы гаризасыннан:

«1979 елдан бирле 1 нче Балалар йортына Ә. Г. Галимҗанов күчерә килгән акчага соңгы вакытта физиотерапия кабинеты өчен җиһазлар, пианино, төсле телевизор, электр мичләре, җиһазлар, киемнәр һ. б. әйберләр сатып алынды. Халык депутатларының Бауман район Советы башкарма комитеты тарафыннан Ә. Г. Галимҗановка тимер юл вокзалы янындагы тупикта, элек чүп-чар ташлый торган урында участок бирелә. Тиз генә дуңгыз абзары һәм азык кухнясы корып, Ә. Г. Галимҗанов күп күләмдә дуңгызлар үрчетергә һәм аларны сатудан килгән акчаны Балалар йортына күчерергә ниятли.

Дуңгызларга азык табуда кыенлыкларга дучар булгач, ул, әлеге участокны юридик рәвештә Балалар йортының ярдәмче хуҗалыгы итеп раслауда булышуыбызны үтенеп, миңа һәм Җәмәгать советына мөрәҗәгать итте. Аңа азык сатып алуда булышуларын сорап, без җәмәгать туклануы идарәсенә, шәһәр торак идарәсенә, коммуналь хуҗалык министрлыгына һәм район Советы башкарма комитетына бардык.

Бу участокны юридик рәвештә безгә беркетүдән һәм аны ярдәмче хуҗалык итеп раслаудан Балалар йорты катгый рәвештә баш тарта...»

* * *

Әкрен генә, игътибар белән аяк астына карап, шәһәрнең иң таушалган урамы буйлап барам. Дөресен генә әйткәндә, ул шәһәрнең уртасында диярлек, янәшәдә — базар, тимер юл вокзалы. Тик тыкрыкка борылсаң — каршыда пычрак диңгез. Безнең борынгы Казанда капма-каршылыкларны шактый күрергә мөмкин. Һәм менә шул шәһәрнең бер кешесен, үз дә бөек капма-каршылыклар иясе булган кешене очратырга барам. Мартын Межлаук урамының кайсыдыр ташландык почмагында яшел коймалы ак йорт булырга тиеш.

Бу кеше турында мин ниләр беләм соң? Соңрак, берничә айдан соң, шәһәр Советы башкарма комитетына кергәч, шикаятьләр кабул итү бүлмәсендә миңа шактый калын папка бирерләр. Аңа: «№ 2891 нче эш. Галимҗанов» дип язылган. Ә аңарчы мин бу кешенең кырыкның өстендә икәнен генә белә идем. Аракы кибетендә йөк ташучы, үзе гомерендә бер тапкыр да исерткеч татып карамаган. Бу йөк ташучының (әлегрәк ул — милиционер, шофер, слесарь) ниндидер аңлашылмый торган альтруист (кешеләргә яхшылык итәргә теләүче) икәнен белә идем: соңгы унбиш елда төрле матди ярдәм күрсәтүләр белән шөгыльләнә, ата-аналары ташлаган балаларны карый. Кыскасы, имешмимешләр күп, алар дөреслеккә күпме дәрәҗәдә туры килә?..

Кечкенә капканы ачам. Эреле-ваклы этләр өрә. Авыр сынлы чучкалар каты борыннары белән җир сөрә. Телогрейка, кирза итек кигән бөрәү миңа таба килә. Бүреге түбәсенә чак кына эләгеп тора, күзләре ут яналар. Кабаланып миңа кул суза, елмая.

— Менә карарга килгәнсең!.. Яхшы! Әйдәгез — Ул безгә сөйләшергә комачаулаучы этккә дәшә.— Артур! Фу!

Ике минуттан миңа без инде гомер буе танышлар кебек тоела. Яңа танышым үзенең хуҗалыгын күрсәтә, нидер сөйли, кулларын бутый, көлә. Киң күңелле, ышанучан кеше.

— Менә монда буа ясыйм әле, ә бирегә агачлар утыртам! Әле тагын ком алып кайтырга кирәк. Сазлык иде, чүплек башы. Атна-ун көн элек ике кеше килде. Карап-карап йөрделәр дә, берсе сүтеп ташлыйбыз ди. Мин әйтәм: монда буа ясыйм, балык җибәрәм. Икенчесе әйтә: «Аңа сүтү турында әйтәләр, ул балык үрчетүен сөйли. Нәрсә тиле белән сөйләшеп торырга?» — ди.

— Шуннан? — дип елмаям мин.

— Киттеләр.

— Ә сез нәрсә?

— Ком алып килдем. Әйбәт, чиста бит, әйеме?

Яңа танышым үз-үзен шаярткан кебек тагын елмайды. Тикшерергә килгәннәрдән дә көлә иде бугай ул. Соңыннан, кайда гына күрсәм дә, аның арбасына утырып йөргәндәме, кибет янында җәһәт-җәһәт тартма төягәндәме, яки дуңгызлары янындамы — һәрчак минем каршыда үз-үзенә нык ышанган, шат, бәхетле һәм хәтта гамьсезрәк кеше тора иде.

— Яшәве рәхәт бит, ә? Кояш ничек яктырта, ә?

Аның яшәү мәгънәсе булган шөгыленә балта чабарга йөриләр. Бу хәл бүтән берәүне хафага салыр иде. Ә аның исе дә китми.

«Дон-Кихот» җене кагылган, сәер кеше.

Шундый кешенең барлыкка килүе очраклымы, әллә ниндидер закончалыклы күренеш бармы монда? Унбиш ел буена, үз эшеннән тыш, тагын бик авыр физик эш башкарып, аннан үзеңә бер тиен дә алмау? Зур-зур акчалар эшләп тә аны үзең күрмәү? Акча Әсгат Галимҗановның кулына кермәгән дә бит, гаризасы буенча күчерелгән генә. Мондый адымга үз теләгеннән башка аны берәү дә мәҗбүр итмәгән.

Ачкүзлелекнең табигате аңлашыла. Ә менә хирыссызлыкның асылы кайда? Кешедә табигый мин-минлек булмавының сәбәбе нәрсәдә?

Хәтерлим, Галимҗанов дуңгызларына карадым да сарыф ителгән хезмәт турында уйладым. Егерме биш дуңгызга, ким дигәндә, илле чиләк азык кирәк. Табарга, алып кайтырга, пешерергә. Яз һәм җәй айларында бу әллә ни четерекле хәл түгелдер, колхоз базарында калдык-постык өелеп ята. Ә кыш көне? Аның бит әле аты, көчекләре белән ике овчаркасы һәм тана хәтле ньюфаундленды, өйдә болонкасы һәм анкә мәчесе, ниндидер сайрар кошлары да бар. Бервакыт дуңгызлар янына килгәч, тагын ике эт өстәлгәнен күрдем — урам көчеге һәм овчарка. Каян килгән болар? Бактың исә, Әсгат Галимҗанов аларны ветеринария институтының виварионнан алып кайткан. Алар тәҗрибә этләре булганнар, операциягә эләккәннәр, аннары кирәкләре калмаган...

«Гомер буе хайваннар белән,— диде ул миңа бервакыт сүз арасында гына. Соңыннан белдем, ике ел элек ул әле бүре баласын да тәрбияләгән. Аның гаиләсендә бүре баласы сигез ай яшәгән, аннары Галимҗанов аны урманга җибәргән. Бу юлларны үз героемның сәерлеген ассызыклау өчен язмыйм (билгеле, ул сәеррәк кеше), ә шундый тормыш аның өчен гадәти хәл икәнен күрсәтергә телим. Әгәр ул хайваннар турында да шулай кайгырта икән, ата-анасы ташлаган балаларны күреп, аның йөрәге ничек сыкранмасын? Балалар йортларындагы сабыйларны ничек кызганмасын?! Дөрес, аның тарафыннан күрсәтелгән кайгыртучанлык аңа кыйммәткә төшә. Төнге бердә генә йокларга ята ул, иртәнге биштә эшкә тотына. Гомер буе шулай.

Әлбәттә, болар барысы да бераз гына фантастикага тартым, ышандырмый. Ләкин һәр кеше үзенчә яши...

Галимҗанов үз-үзенә әнә шундый тормышны сайлаган һәм ул, ни дисәң дә, бәхетле кеше тәэсире калдыра. Аның урынында башка берәү булсамы?.. Унөч ел элек аның хатыны бәлагә тарыган, беренче группа инвалид, өйдән чыкмый. Димәк, өйдәге бөтен эш тә Әсгат өстендә. Дөрес, балалар да булыша. Улы Радик инде заводта эшли, Ләлә училищеда тегүчелеккә өйрәнә. Алар — атаның фикердәшләре. Улы, беренче хезмәт хакы алып кайткач, утыз сумны аерып куйган: «Балаларга акча күчергәндә моны да җибәр»,— дигән.

Гадәти булмаган гаилә. Ятим балаларга берьюлы өч-дүрт мең акча күчерү Галимҗановка кызганыч түгел, ә менә үз балаларына кулдан ике йөз тәңкәлек джинсы чалбар алу акылсызлык. Андый әрәм-шәрәм итүгә Галимҗанов беркайчан да барачак түгел. Шунысы гаҗәп, аның балалары да киндер чалбарга акча әрәм итү турында уйлап та карамыйлар.

Элек Әсгат Галимҗанов дуңгызларын үзе яшәгән йорт янындагы гараж астында тоткан. Гаражда үзе эшләгән кибетнең атын асраган, гараж эчендә зур баз казыган

да дуңгызларын шунда япкан, аларны ашату һәм асларын чистарту өчен төрле җайланмалар көйләгән. Төннәрен ике овчарка яки ньюфаундленд белән тирес ташып түккән.

Фантастик һәм чын мәгънәсендәге «җир асты» предприятиесе күп еллар бары бер максат өчен — аннан кергән акчаны Балалар йортына җибәреп тору өчен тотылган.

Аның бу эшчәнлеген хуплап каршылаганнардыр дип уйлау беркатлылык булыр иде. Киресенчә, игелекле кеше кайбер эшкуарларга шикле булып күренгән. Төрле яклап тикшерүгә дучар булган ул. Иәк ташучы район властьларыннан үзенә кечкенә генә урын сорый — «җир астыннан» чыгып, җайлырак эшлисе килә аның. Ул чорда илебездә Азык-төлек программасы кабул ителә. Балалар йортының җәмәгатьчелек советы юллавын истә тотып, ниһаять, аңа урын бирәләр. Андагы чүп-чар ике катлы йорт биеклегендә була.

Хәзер генә ул районның санитария эпидемия станциясе Галимҗанов үрчеткән дуңгызлар «чебеннәрнең баш санын арттыруга» китерә, дип борчыла. Ә ул чүплектә кемнәр генә череп ятмаган? Аны еллар буе күрмәмешкә салышканнар. Галимҗановка чүплек нәрсә генә ул? Ул бульдозер, машина таба, атна дигәндә чистартып чыгара, вак таш, ком, балчык, торф алып килә, гипс белән пычкы чүбен болгатып, измә ясый, бина сала — азык кухнясы. Каяндыр сумала эретә торган ярым җимерек казан табып ала да, ремонтлап, дуңгызларга ашарга пешерергә көйли. Кыскасы, ике атнадан сәер кешенең «җәмгыяте хәйрия предприятиесе» яңа урында үз функцияләрен башлап та җибәрә. Дуңгызлар санын арттырганда, Галимҗанов аны Балалар йортының ярдәмче хуҗалыгы итәргә, үзе шунда бушлай эшләргә хыялланган. Һәм хыялында ул әлеге хуҗалыкта бакча үстереп, балаларны яшелчә белән сыйлавын, буада карплар үрчетеп, аларны балалар табынына куюын да күргән.

«Җир астында» ул җиде-сигез дуңгыз асраган. Яңа урында исә башта егерме ике, ә аннары егерме бишне тота башлый. Аның якын киләчәктәге планнарына Балалар йортын чыршылар белән урап алу, капка төбенә балаларга һәйкәл салу да кергән.

Тормыш кайчак комедиягә, вакыт-вакыт трагикомедиягә охшап куя. Ул үзе бөек рәссам һәм вакыты белән шундый — фантастик сурәтләр ясый, андыйны.хәтта язучы хыялы да уйлап таба алмый.

Галимҗановның планнары һәм хыяллары беркемгә дә кирәк булып чыкмый. Галимҗановка чүплек башын биләргә рөхсәт биргән башкарма комитет председателе, хәзер аны күрсә, кача: «Үзеңнең чучкаларың белән син мине каберга кертәсең!» Балалар йортының баш врачы да паникага бирелә: «Карпларың да, һәйкәлең дә, ярдәмче хуҗалыгың да кирәкми!..»

Күпмедер дәрәҗәдә бу аңлашыла да. Әгәр әлекке елларны Галимҗановның «эчкерсез ярдәм» взнослары чагыштырмача аз булып, елына сигез йөз — бер мең сум тәшкил итсәләр, хәзер исә — «предприятие «җир астыннан» якты дөньяга чыгып, колачны җәеп җибәргәч (соңгы ике елда еллык взнослар дүрт меңнән артып китә),— аның кайгыртучанлыгы башкалар өчен авыр йөккә әйләнә. Аның белән нишләргә белмиләр. Гамәлдәге параграфларга, нормаларга, инструкцияләргә, положениеләргә ни Галимҗановның үзен, ни аның дуңгызларын дыңгычлап та кертеп булмый. «Ферма»ны ярдәмче хуҗалык итеп расласак? Ләкин кайсы администраторның андый «камытны» киясе килсен? Ул үзе анда бушка эшләүче булсамы? Әгәр авырып китсә? Һәм нәрсә ул — бушка эшләүче? Бер генә җәмгыятьтә дә булмаган нәрсә. Ярамый, мөмкин түгел. Нәрсә мөмкин соң? Нәрсә кирәк?

Беләсегез килсә, бу кешене тагын бер кат тикшерергә кирәк икән! Сәер дуңгыз карауччы белән ОБХСС һәм угрозыск кызыксына — аның игелекле эшенең нәрсәгә «нигезләнгән» булуын тикшерергә. Аның белән янгыннан саклау хезмәте кызыксына — «электр үткәргечләре» ничек икән анда? Санэпидстанция дә борчыла — һаман да шул «чебен населениең арту-артмавы борчый. Аны районның бөтен инспекторлык хезмәтләре тикшереп чыга. Шәһәрнең баш архитекторы хезмәте Галимҗановны җирдән үз белдеге белән файдалануда гаепли. Хәр күңелле альтруистның түбәсе өстендә яшен утлары уйный. Бервакыт шундый приказ белән бульдозер китерәләр: бөтенесен җәһәннәмгә олактырырга! Җәмәгатьчелекнең көчле яклавы гына изге эшне һәлакәттән коткара.

Кайбер шикләнүчән укучыларның, шикләнеп, иңбашларын җыерулары ихтимал.

Чыннан да, бер якта, изгелек эшләргә атлыгып торган сәер кеше, икенче якта — изгелеккә карата көлке мөнәсәбәт. Булуы мөмкинме моның? Шулаймы бу?

Минем алда рәсми рәвештә кузгатылган 2891 нче эшнең материаллары ята. Рәхим итеп, бергә-бергә танышыйк!

Казан шәһәре эчке эшләр идарәсе начальнигының белешмәсеннән:

«М. Межлаук урамында Ә. Г. Галимҗанов бүгенгесе көндә егерме биш баш дуңгыз һәм биш эт тота. Галимҗанов дуңгызларын рөхсәтсез тота башлаган. Соңыннан, янәсе, аңа totarga рөхсәт биргәннәр, ләкин кулына документ бирмәгәннәр. Ел саен

ул дуңгызларын Казан шәһәренең Бауман районындагы үзәк базарында килосын өч сум илле тиен һәм дүрт тәңкәдән саткан. Сатудан кергән акчаны ул Ямашев проспектының 88 нче йортына урнашкан Балалар йортына күчергән. Бу 1983 елга хәтле дәвам иткән. Шушы вакыт эчендә Галимҗанов Балалар йортына ун мең сумнан артык күчергән.

1983 елның язында Галимҗанов үзенең ярдәмче хуҗалыгын законлаштыруны үтенеп, Бауман башкарма комитетына мөрәҗәгать иткән. Бинаны архитектор Э. Дубивко белән район СЭС баш врачы Р. Караулова караганнар һәм, янәсе, аңа дуңгызлар тотарга рөхсәт иткәннәр, тик унбер баштан артык түгел, ләкин соңыннан Караулова бу рөхсәт язуын Галимҗановтан кире ала. Дуңгызларга ашату өчен ризык калдыкларын ул торак йортларның ишегалларында, колхоз базарында, янә килеп, Сул-Болак урамындагы 1 нче педагогия институтындагы 44 ашханәләрдән, Нариман урамындагы 151 балалар бакчасыннан җыйган. Ашханә администраторы Н. Сәйфуллина һәм балалар бакчасы мөдире Н. Бушуева белдерүенчә, калдык-постыкларны Галимҗанов гадәттә төнлә урлаган. Моннан тыш, розыск чаралары белән шунысы да ачыкланды, Галимҗанов дәүләт атын файдаланып Бауман районы колхоз базарында сәүдә итүче гражданнарга авыл хуҗалыгы продуктлары ташу белән дә шөгыльләнә, ә алар аңа акчаны үз кулына бирәләр. 1984 елның 16 апрелендә Галимҗанов Ленинабад өлкәсеннән килгән колхозчы О. А. Джураевка М. Межлаук урамыннан базарга хәтле өч капчык өрек китерә һәм шуның өчен 3 (өч) сум ала. 1984 елның 18 апрелендә Галимҗанов Ленинабад өлкәсе Исфарин районы кешесе М. Р. Роджобовка ун капчык өрек китереп ташлый — Тукай урамыннан базарга чаклы — 10 (ун) сум акча ала.

Дуңгыз асрау өчен салынган ярдәмче хуҗалыкны нинди төзелеш материалларыннан коруы хакында Галимҗанов бернинди дә документ күрсәтмәде һәм төзү материалын каян туры килсә шуннан, нигездә, сүтелә торган яки капиталь ремонтка ябылган йортлардан алуын әйтте».

110/117 нче кибет йөк ташучысының эш режимын тикшерү актыннан:

«Безнең, ягъни торг хезмәткәрләре кадрлар бүлеге инспекторы Сөләйманова Л. П., хезмәт хакы бүлегенең өлкән бухгалтеры Кудрявцева В. И. һәм финанс бүлегенең өлкән бухгалтеры Бакирова Ф. Л. тарафыннан йөкче Галимҗановның эше тикшерелде. Тикшерү вакытында 15 сәгатьтән 16 сәг. чаклы Галимҗанов эш урынында юк иде».

117 нче кибет директорының аңлатма язуыннан:

«Шуны җиткерәм ки, 4 майда 9 сәг. тән 10 сәг. 30 мин. ка хәтле Галимҗанов, аңлатма бирү максатыннан, минем белән бергә эчке эшләр идарәсендә булды. Аннан соң ул пыяла савыт-саба кабул итү пунктына 110 кибеттән әрҗәләр илтте һәм товар алырга барырга тиеш иде. Хәзер кайда икәнен белмим».

Менә шулай, хөрмәтле укучы! Игелекле булу алай бик гади генә түгел. Үзегез булып карагыз! Шундук әйләнә-тирәдәгеләр сезнең һәр адымыгызны тикшерә башлаячаклар.

Тагын бер кәгазьгә мөрәҗәгать итик! Казан шәһәр Советы башкарма комитеты председателе урынбасарының аңлатма язуыннан:

«Шәһәр Советы башкарма комитеты Ә. Г. Галимҗановның шәһәр эчендә урнашкан мал-туар абзарын ярдәмче хуҗалык итеп рәсмиләштерүне һич тә ярамый торган эш дип саный. Үз белдеге белән төзелгән корылмалар сүтелергә, ә территория төзеклəндерелергә тиеш».

«2891 нче эш»нең бик күп кәгазьләрендә хупламау сизелә. Эчтәлегендә генә дә түгел, беренче чиратта сүз сөрешеннән, фикерне нинди сүз белән аңлатудан ук бөркелеп тора ул хупламау.

Гаҗәп. Нигә без, кешеләр, яхшы эшкә кырын карыйбыз? Нигә берәүнең изгелеге безне кимсетә кебек? Аның җаны тели!.. Инде җаны да теләгәч, нигә ярамый соң?

Галимҗанов турында үземнең танышларыма сөйлим. Мөнәсәбәтләрен күзәтәм. Нигә ул күпләр өчен күзгә кергән чүп кебек? Сөйлим һәм сүзләремә шикләнеп карауны сизәм. Нигә? Башка сыймый. Аның кылганы өстәмә аңлатмага мохтаҗ. Үзенең сәер юмартлыгы белән үк ул башкаларны мыскыл итә кебек. Чыннан да, ике полюс бар: дуңгызлар һәм ирешеп булмаслык (һәм акыл җитмәслек) олы җанлылык. Аларны нинди «күпер» тоташтыра соң?

Әңгәмәдәшләремнең берсе:

— Ул әүвәл моның нормаль хәл икәненә ышандырсын! — ди.

— Нигә әле ул сине инандырырга тиеш?

— Шулай булмаса, ул — эт кеше!

Менә сиңа мә!

Нишлисең, үзенә файда ясарга теләмәгән кеше аңлашылмый. Берәүләр Галимҗановны ишерен кулак дип атады. Икенчеләр Галимҗановның башкаларга ярдәм итәргә тырышуын аның тормышта морадына ирешә алмаучылар токымыннан булуы белән аңлатырга тырышты. Монда логика бик гади. Нормаль, сәламәт кеше андый эшләр белән ул кадәр озак шөгыльләнә алмас иде. Аның адресына бирелгән атама-

ларның иң таралганы — ул кеше акылга сай, янәсе. Шундый фикер дә бар иде: яхшылык итәргә тырышуы белән ул үзенең ниндидер гөнаһларыннан котылырга тели. Күп еллар буена да тукталмагач, аның гөнаһлары коточкыч, күрәсең. Аны берәзлексез шуңа тикшермиләр микән? Ныклабрак тикшерергә иде. Ниһаять, 117 нче кибетнең йөкчесе, бөтен кешегә ачу итеп, Балалар йортына һәм башка оешмаларга аеруча күп акча күчерә. Дөньяны явызлык белән генә түгел, яхшылык белән дә кимсетеп була бит. Бу игелекне, ирешеп булмый торган идеал итеп, кешеләрнең борын төбенә китереп күрсәтергә генә кирәк!

— Балалар турында кайгыртырга кем кушкан аңа? Алар турында дәүләт кайгыртмыймы әллә? Шәфкать итүче табылган! Каяндыр тирес арасыннан чыккан да дөньяны шаккатыра, имеш!

— Дәүләт карый, әлбәттә. Көчен дә, игътибарын да кызганмый. Ләкин гади бер кешенең алар турында кайгыртуында да һичнинди начарлык юк.

— Ник шулай кылана ул? Аннан башка балалар кырылып үләр идеме?

— Күптән түгел шул балалар әйбәт, иркен яңа бинага күчтеләр. Дәүләттән бүләк. Ләкин кинәт салкыннар башланды, яңа йортта җылыту системасы көйләнеп җитмәгән иде. Галимҗанов шуны белгән дә, арбасына дистәләгән электр мичләре төяп, балалар янына килде. Өч-дүрт йөз сумга кибеттән сатып алган. Моның нәрсәсе дәүләт эшенә каршы килә?

— Барыбер синең ул Галимҗановың юләр! Яки спекулянт!

Әңгәмәдәшемне кешенең теләсә нинди начарлыгына ышандырырга мөмкин иде, ләкин менә кешенең тумыштан игелекле булуын ул һич тә аңламый. Турысын әйтим: мин үзем дә танышларымнан ерак китмәгән идем, Галимҗановның холкына тиз генә төшенеп җитә алмадым.

Ярар, ә ул үз фәлсәфәсен ничек аңлата? Үзе ни сөйли?

Ул бу хакта сөйләми дә диярлек. Һәм фикерләрнең капма-каршылыгы, мөгаен, шунда да инде. Ул күбрәк дуңгызлары, аларны ничек тәрбияләве хакында сөйли. Ничек ашата, ничек чистарта — бөтен кайгысы шул кебек.

Сабырлыгым җитмичә, мин аңардан «кырт» кисеп сорадым.

— Әсгат, карале, син моны нигә эшлисең?

— Минем хатынның әнисе дә балалар йортында тәрбияләнгән.

— Шуннан?

— Онытмаска кирәк. Аннары, без авылда чагында... Сугыштан соң бик авыр иде. Безгә колхоз булышты.

Кайсыдыр бер очрашуыбызда, ул: «Мин дә, хатын да, балалар да акча яратмый»,— дип ычкындырды. Тагын шуны да исенә төшерде. Беренче тапкыр акча күчергәч, әти-әнисе (алар ул чагында исән була әле) аны хуплаганнар. Икенче бер сөйләшүебездә Галимҗанов, аңа «шулай» яшәве «ошавын» әйтте.

— Суыткыч тулы! Телевизор бар! Хатын пенсия ала,— дип бармакларын бөкте ул.— Кыз — стипендия, малай хезмәт хакы кайтара. Минем оклад. Артык акча нигә кирәк? Артык акча бәхет китерми. Күп акчадан кеше бозыла!

Бу аңлатмалар сезне канәгатьләндерәме? Менә алар, гомумән алганда, канәгатьләндерде.

1984 елның җәендә Галимҗанов үзе карап үстергән дуңгызларны әзерләүләр конторасына тапшыра. Контораның бухгалтериясе аңа тиешле 4168 сумның нәкъ өч мең сумын, аның гаризасы буенча, Иваново шәһәрендәге Стасова исемендәге Интернациональ мәктәп-интернатның 18911082 нче счетына күчерә. Анда ата-анасыз калган төрле ил балалары — Палестина, Ливан, Әфганстан, Никарагуа ятимнәре яши икән.

Португалия журналисты Жузе Серра белән танышкач, мин аңа, сүз уңаенда, Әсгат турында сөйләдем. Португалияле иптәшнең күзенә яшь чыкты. Аның әти-әниләре алты ел подпольеда яшәгәннәр, ә Жузе Ивановодагы мәктәп-интернатта тәрбияләнгән. Әсгат Галимҗанов андый балалар хакында да уйлаган.

Әлеге акчаның биш йөз тәңкәсе Казандагы 1 нче Балалар йортына — үзенең элекке танышларына күчерелгән. Калган акча дуңгыз балалары алуга китә.

Монда тормыш — Галимҗанов белән бу еш була — тагын үзенең трагикомик хикмәтен күрсәтә. Лаеш районының «Победа» колхозыннан алынган чучка балаларының яртысы шундук үлә. Алар чирле булалар. Ветеринар килә, кешенең хәленә кереп: «Алар сиңа брак сатканнар,— дип аңлата.— Мин хәзер справка бирәм! Колхоздан акча таләп итәрсең!» «Нигә? — Галимҗанов баш тарта.— Минем акча әрәмгә китмәгән бит. Колхозга, дәүләткә кергән». Акча җәлләп әрнеми Галимҗановның йөрәге. «Победа» колхозында дуңгызчылыкның начар торуына гына борчыла ул. Якшәмбе көнне колхоз базарыннан унбиш чучка баласы сатып ала. Монда аларның һәрберсе 35-40 сум тора.

Шул ук әйләнеш кабатлана. Кыш көне симез, зур дуңгызларны тапшыра, балаларын сатып ала...

Кешеләрнең вак-төяк эгоизмын күреп туйгач һәм тормыш миңа өметсез нәрсә бу-

лып күренә башласа, җанымны тынычландыру өчен мин Галимҗанов янына барам. Бернәрсәдән дә курыкмый торган, тормышның бөтен тискәре, иң кара якларын күреп тә, аңа булган ышанычын һич кенә дә югалтмаган кешеләр булуы — нинди шәп! Без Галимҗановның азык әзерләү бүлмәсендә өстәл янында утырабыз һәм политика турында да, кешелекнең киләчәге яки сәнгать турында да түгел, ә дуңгызлар һәм чучка балалары хакында сөйләшәбез. Һәм, ни гаҗәп, мин күңелемнең күтәрелгәннән-күтәрелә баруын тоям.

Соңгы елларда без яңа кеше турында тау-тау кәгазь язып тутырдык. Ниһаять, ул кеше бар, безнең янәшәдә яши, тик без аны танымыйбыз. Без аны тешләп карыйбыз — шулмы, без аны кат-кат тикшерәбез — алдакчы түгелме, ялган исем белән йөрүче түгелме? Алдакчы түгел. Аның ихласлыгын Галимҗановны фаш итәргә дип ачылган «2891 нче эш» үзе үк раслый. Аны Казан шәһәр Советының шикаятьләр кабул итү бүлмәсендә эзләп табарга була.

Укучым, әлбәттә, бу кешенең сәер шөгыле ни белән бетәр икән, дип кызыксынадыр. Кабул ителгән резолюциягә таянып, дуңгызлар абзарын җимереп атарлармы һәм бу урынны яңадан «чүплек башы»на әйләндерерләрме, әллә изгелеккә мөмкинлек калдырырлармы?

Халыкның ачуы озакка бармый дип уйлыйм. Яңа кешене алар кай арада танып өлгерсеннәр соң? Аның бит әнә гәүдәсе дә күзгә ташланмый, чалбары да йомарланып беткән, баш түбәсенә генә эленеп торучы бүреге дә — ташка үлчим, һөнәре турында, әйткән дә юк, бетеп бара торган эш — йөк тәяүче...

Әсгать Галимҗанов турындагы мәкалә «Смена» журналында басылып чыккач, редакциягә илебезнең төрле якларыннан йөзләгән хатлар килә башлады.

«Мин аннан көнләшәм, ул кеше тормышта үз юлын тапкан. Почтага барып, телеграф аша күпмедер акча җибәрү ул кадәр үк мәшәкатьле эш түгел, андый кешеләр очраштыргалый, ләкин бит бу кеше җыйган акчасын гына түгел, бөтен гомерен, бөтен вакытын ятим балаларның «смета»да, «бюджет»та каралганнан тыш, яңа уенчыкларын булдырырга багышлый. Әлбәттә, ялганчы аңлашыла, ул уч төбендә кебек, ә мондый кеше?..» (Н. Карпенко, Макеевка). «Баштарак мин бу мәкалә «социаль экзотика» өчен язылган, дип уйладым. Ләкин сез хаклы: бу конкрет кешенең шөгыле — фәлсәфи яктан төшенеп җитүне сорый торган күренеш. Ягымлы, кызыклы, хыялны киңәйтә торган. Кем белә, бәлки, Казанның Межлаук урамына килеп чыккач, кешеләр, бигрәк тә читтән килүчеләр, кайда монда Әсгат Галимҗанов йорты, дип сорарлар. Бу кеше — иң яхшы мәгънәсендә, билгеле шәһәрнең истәлекле урыны кебек». «Бу — яңа, коммунистик җәмгыять кешесе, җәмгыятькә хезмәт итү — бу кеше өчен гадәти бер ихтыяҗ. Тагын шунысы гаҗәп. Ул тормышның кара якларын күрми дә, сизми дә кебек, үз максаты белән бәхетле. Һәм мин, мөгаен, аны аңлыймдыр: ул үзенең бөтен хыялларын тормышка ашырыр өчен гомере җитмәс дип кенә курка торгандыр...» (В. Чемурзиев, Дубровское авылы).

Илебез җәмәгатьчелеге, журналның күпсанлы укучылары сыйфатында, Әсгат Галимҗанов сайлаган тормыш рәвешен әнә шулай бәяләде. Һәр хатта диярлек сорау: Әсгат Галимҗанов хәзер ничек яши, аның эшенең язмышы ни хәлдә?

Көтелмәгән хәл килеп чыкты. Элек аңа азык-төлек калдыкларын бирмиләр иде,— каян туры килсә, шуннан үзе таба иде. Кинәт кенә — биргәннәр. Ике мичкә. Районда калдык-постык җыю хезмәтенең бригадиры үзе тәкъдим иткән. Галимҗанов яңа чучка балалары сатып алганның өченче көнендә була бу хәл һәм шул көнне үк биш чучка баласы үлә. Тикшерү шуны күрсәтә» алар күсе агуыннан үлгән. Күңелсез хәл тагын да кабатлана, чучка балалары бер-бер артлы үлеп кенә торалар. Базардан сатып алганнары да үлә.

Әсгат Галимҗановның ятим балалар файдасына башкара торган изге эшенә күсе агуы белән китереп бәрәләр. Башка берәү булса, ачуы килеп, кул селтәр иде. Ләкин Галимҗанов башка токымнан шул. Бурычка батып бетә, дуңгызларны үстерә. Дөрес, бу юлы әллә ни күп түгел. Чыгымнары өч мең тәңкәлек, кереме — мең дүрт йөзлек кенә. Үзе турында уйларга кирәк шикелле, ләкин 22 апрель көне якынлаша, В. И. Ленинның туган көне — Галимҗановның балалар учреждениеләре счетына акча кертә торган көне. Һәм ул бер меңне Ивановодагы интернациональ мәктәп-интернат счетына (№ 18911082), ә дүрт йөзне Казандагы 1 нче Балалар йорты счетына (№ 142411) күчерә. Шунда ук ул Шәпше авылындагы «Урак һәм Чүкеч» колхозы белән үгезләр үстерү турында килешү төзи.

— Үгезләрне берәү дә агуламады,— ди Әсгат Галимҗанов, үзеннән һәм аңа бәлаказа китергән кешеләрдән көлгәндәй итеп.— Килешү бар бит. Тавыш чыгар дип куркалар. Шәпшенең үз ветеринар врачы бар...

Журналда мәкалә басылу Галимҗановның тормышын үзгәртмәде. Көндез, гадәттәгечә, ул үзенең атлы арбасына утырып, кибетләргә хезмәт күрсәтә. Иртә-кич үгезләр ашата, авыру хатынын карый. Берсендә Одесса телестудиясеннән ике хатын-кыз

кила — аның турында кино төшерергә. Казан студиясе дә кызыксына. Кайчакларда Галимҗановка үзе булып уйнарга туры килә. Әйтергә кирәк, аның бу эше бик үк шәп килеп чыкмый.

— Миңа үгезләр ашатырга кирәк,— дип офтана ул кайчагында кинокамера каршында торганда,— эштә дә сүгәләр.

Одесса белән казанлылар төшереп бетерүгә, Новосибирскидан кинематографистлар килеп төшә — аның хакында фильм эшләргә. Әсгатне эштә чынлап та орышалар. Сәүдә системасында шактый зур һәм җаваплы постлар биләп торсалар да, кино төшерүчеләр алар белән кызыксынмый бит, йөк ташучыны төшерәләр. Монда да үзенчә көрәш бара — телефоннан шалтыратулар, әреләнеп сөйләшүләр, гаҗәпләнүләр...

Галимҗановка хатлар килә. Орлов өлкәсеннән таныш түгел бер хатын аннан әҗәткә мең ярым акча сорый, икенчесенең нәфесе тагы да шәбрәк — өч мең сорый. Аның каравы, бүтән бер хат иясе аңа кешене аңлап, теләктәшлек белдерә. Воронеждан элекке укытучы Г. И. Кондрашова унбиш сум акча җибәрә — «балалар өчен» ди һәм ай саен шушы кадәр җибәреп торачагын әйтә. Галимҗанов бу кешегә шакката: «Җир йөзендә нинди күркәм кешеләр бар! Туп-туры балалар йорты исәбенә күчерсен дип ничек әйтергә икән!»

Беркөнне бөтенләй трагикомик хәл була. Аның бусагасында балалы бер хатын пәйда була. Төмәннән килгән,— атап аның янына. Хәле бик мөшкел икән. Казанның балалар йортына урнаштырырга булышмас микән. Авыр мәсьәлә була бу. Балалар йорты хатынның үтенечен канәгатьләндерә алмый. Чөнки ул Татарстандагы ятимнәрне генә кабул итә. Төмәннең үзендә балалар йорты бар. Хатын исә аның бала ташлавын Төмәндәге танышлары белмәсен өчен Казанга килгән икән.

Галимҗанов өендә киңәшмә булып ала. Хатыны, беренче группа инвалид, кызчыкны үзләренә алу ягында. Уллары Радик, кызлары Ләлә дә каршы түгел.

— Матур бала,—дип сөйләде Галимҗанов миңа ул чакта.— Яшь ярымлык. Бала— бала инде, гөнаһсыз, ярдәм сорый. Әгәр безнең гаиләгә килеп эләккән икән инде, аша-тып-эчертербез, урын табарбыз!

Галимҗановларның гадәти квартира — егерме җиде квадрат метр, ике бүлмә, кухнясы юк, миче, газы бар. Әсгат Галимҗанов кибеттән агач карават алып кайтырга җыена.— «Хатынныкы белән янәшә куярга булган идек»... Казанның 1 нче Балалар йорты үзенең күптәнге танышын кызганып булса кирәк, баланы үзенә ала. Әле монда да безнең Әсгат тынычланмый. Бала асрауга кирәкле акчаны (аена егерме-егерме биш сум чамасы) якындагы ел ярым эчендә миннән алыгыз дип гариза яза: теге хатын хәленең мөшкел икәнлегенә аны тәмам ышандырган. Галимҗанов исә үзен Балалар йортына бурычлы дип саный башлаган.

Район җитәкчелеге даирәсендә Галимҗанов хакында үз драматургиясе, үз сюжеты төенләнә.

«Тикшерү шуны күрсәтте: гр. Галимҗанов Ә. Г. үз участогында 16 баш эре мөгезле терлек (үгезләр), кәҗәләр һәм тавыклар асрый. Маллар торган җирдән, Межлаук урамындагы ике катлы (32 нче һәм 32 нче А) йортларга кадәр ара бик аз —29 һәм 38 метр... Ишегалдында тирес җыела, чебеннәр үрчи. Шәһәрләрдә мал асрау хосусый йорты булган кешеләргә генә рөхсәт ителә. Югарыда күрсәтелгәннәр нигезендә, санитария хезмәте, шәһәр уртасында хайваннар асрау һич тә ярамый, дип таба».

Укучыга яхшы таныш булган Р. В. Караулова фикере бу. Энтомолог В. В. Соколова һәм энтомолог ярдәмчесе Р. Г. Малютова имзалары да шул фикерне куәтлиләр.

Ул комиссиянең килүен Әсгат Галимҗанов болайрак аңлатты:

— Янәсе, черки эзләргә килгәннәр. Бауман районы — шәһәрдә иң иске район. Алар башка җирдәге җыелып утырган юынтык суларны да, чебеннәрне дә күрмәгәннәр, миндә өч чебен тапканнар. Урамга карагыз! Теләсә кемнең күзен бәйләп монда алып килеп бастырыгыз. Бу урамга карап, кем моны шәһәр, бигрәк тә, шәһәр уртасы дип белер икән? Әнә алар үлчәгән йортларның берсе. Төртсәң, ишелергә тора, иртәгә ул да булмас, утынга ташып бетерерләр. Аварийный хәлдәге барак ул, кешеләрен күчерделәр инде, йортын ишәселәре генә калды. Шуннан черки эзлиләр. Мин арбада барганда еш кына: «Әсгат абый, утырт әле! Әсгат абый, күлдәвек аша чыгар әле!» — диләр. Әгәр берәр акыллы хуҗа табылып, миннән сораса икән: Галимҗанов, сез малтуар яратасызмы? Яратам. Без сезгә уналты түгел, ә йөз, илле баш мал асрарга рөхсәт итәбез. Участок бирәбез. Булдыра алырсызмы? Алам! Ял көне базарга каян ит килгәнен карагыз сез? Ульяновск һәм Горький өлкәләреннән! Алар безне туендыра. Татарстаннан бик аз. Ник икәнен чамалап карагыз?!

...Тормыш экият түгел, хәер, кайчагында экияткә тартым моментлар да очрап куйгалый.

Казан шәһәр Советы председателе урынбасары Р. Р. Насыров белән сөйләшәм.

— Тормыш күпкырлы, билгеле, анда барысы да кануннарга сыешып бетми. Әхлак ягыннан килгәндә без Галимҗановны гаепләмибез. Без аның бик яхшы кеше икәнен

беләбез. Ул гына да түгел, әхлак ягыннан үзенә бертөрле характердагы, уникаль кеше. Ләкин бер зур «ләкин» бар. Аның фермасын бүтән урынга чыгарырга кирәк. Галимҗановның үз ризалыгы белән без аңа яхшы участок бирү ягында, кыскасы, аны берәү дә кыерсытырга җыенмый.

Казан шәһәр Советы председателе Р. Р. Һидиятуллин белән очрашам.

— Галимҗановның изгелеге мине сокландыра. Безнең аңа булган мөнәсәбәтебез исполком карарында ачык чагылган. Аңа бу эшләрен дәвам итәргә кирәк. Без — каршы түгел. Киресенчә, тулысы белән аның ягында. Ләкин бөтенебез өчен дә кулай вариант табарга кирәк. Казан шәһәре ул әле утыз сигез поселок та, ә аларда мал һәм кош-корт тотуны без хуплыйбыз. Ә Галимҗановныкы кебек максатка — бигрәк тә. Рәхим итсен, без аңа йорт төзергә булышырбыз, кирәк кадәр җир бирербез, азык... Бәлки ул уналты түгел, ә йөз баш асрарга телидер? Рәхим итсен! Бөтенесен дә закон юлына кертербез. Межлаук урамы очы, әлбәттә, бүгенгә бик начар. Ләкин бу урам акгвардиячеләр пулясыннан һәлак булган революционер исемен йөртә, без аны элекке хәлендә калдырырга теләмибез. Без аны төзекләндерәбез. Бөтен мәсьәләне — урамны да, Галимҗанов фермасын да, бүген үк капитально хәл итәргә кирәк. Нигә аны иртәгәгә калдырырга?

Галимҗанов яшәешенең төп сюжетына — аның үгезләренә һәм аларга бәйле хыялларга әйләнеп кайтыйк. Галимҗановның Балалар йорты ишегалдына зәңгәрсу чыршылар утырту, «Ленин һәм балалар» дигән темага һәйкәл кую турындагы хыялын язып үткән идем инде. Зәңгәрсу чыршылар табылмаган, яшелләрне утырталар, һәйкәл турындагы уй торган саен реаль булып бара. Берсендә Галимҗанов янына килгәч, аның уйланып калуын күрдем.

— Үгезләр әйбәт, җитдиләр. Инде сугыша башладылар.

Үгезләр чыннан да җитдиләр. Галимҗанов үзе генә аларны карый алмый. Улы Радик та булыша. Тыныч, гадәттән тыш эш сөючән егет. Шәһәрнең икенче якларыннан Әсгатнең туганнары да булышырга килә. Без монда матодорлар кебек. Шушы арада гына зоотехник булып китте. Тиздән тапшырырга мөмкин. Кайберләре 460 килограмм тартыр дип уйлыйм. Миңа, 420 кг — норма, диделәр. Димәк, һәр үгез мең дә ике йөз китерә. Гомуми суммасы унҗиде-унсигез мең дип исәплә. Азыкка тотып калырлар, җиде-сигез машина алган идем. Димәк, һәйкәлгә унбиш меңләп бирергә була».

Татарстанның танылган скульпторлары Рада Нигъмәтуллина белән Виктор Рогожин янына барам. Алар ирле-хатынлы, кайчагында бергә эшлиләр. Рада Нигъмәтуллина балалар темасын яхшы белә, ә Виктор Рогожин социаль карашлы рәссам. «Смена»дагы мәкаләмне укыдылар микән? Гадәти заказ түгел, моңарчы күрелмәгән — гади йөкче шәһәрнең иң төп проспектларында урнашкан Балалар йортына куелачак монументка заказ бирә.

Заказ кызыксыну уята. Иртәгәсен рәссамнарны заказчы Әсгат Галимҗанов белән очраштырам. Усал кара үгезне сыйпап, ул болай ди:

— Минем эш — үгезләр, сезнеке — чын һәйкәл ясау. Бронзадан! Балалар кечкенәдән матурлыкны күреп үсәргә тиеш.— Көлә, авызында бер теш тырпаеп тора.— Һәйкәл ясагач, тешләрне дәваларга барам. Хәзергә вакыт юк әле!

Һәйкәлне ясау башланды. Галимҗанов хыяллана — Казанда куярга, аннан икенчене Ивановода, Стасова исемендәге интернациональ мәктәп-интернат ихатасында. Мәсәлән, «Төрле халыкларның балалары дуслыгы» темасына. Хыяллана һәм, эш кешесе буларак, «Урак һәм Чүкеч» колхозы белән утыз баш үгез үстерү турында килешә...

*Галимҗанов фидакарьлегенең соңгы айлардагы нәтиҗәсе турында яңа хәбәр: 9 июньдә ул Чернобыль АЭСында булган фаҗига эзләрен бетерү өчен ун мең сум акча күчерде.*

Кеше тормышы гаҗәп. Озаграк яшәгән саен сораулар да күбәя. Вакыты белән кеше гаҗәеп, табышмак, акыл җитмәслек. Бик күп укучылар сорый: Әсгат Галимҗанов үз тормышы турында ни уйлый?

Һәрвакыттагы елмаюы белән җавап бирә:

— Кирәк, яшьләргә үрнәк булсын өчен. Тормыш яхшырак булырга тиеш. Мәрхәмәтлерәк.

Мәскәүдә португалияле яшь коммунист Жузе Серра белән танышуым хакында әйткән идем инде. Ул МГУ бетерә, журналист, Португалия компартиясенең «Аванте» газетасында эшләячәк. Әти-әнисе — Португалиянең танылган революционерлары, Салазар режимы чорында озак вакыт подпольеда булалар. Жузе Серра үзенең бертуган сеңлесе белән беренче тапкыр унөч яшьтә генә күрешә. Сеңлесе бүтән илдә тәрбияләнә. Ә егет, әйткәнемчә, СССРда, алты ел Стасова исемендәге мәктәп-интернатта. Егеткә йөк ташучы Әсгат Галимҗановның һәйкәле турында әйтәм. Үзе бер тапкыр да күрмәгән Иваново шәһәрендәге интернациональ мәктәп-интернатта да һәйкәл куелачагы хакында сөйлим. Португалия егетенең күзендә яшь тамчылары...

## Зэки Нури

# КУРКЫНЫЧ КУНАК

### КЫСКА ФЕЛЬЕТОННАР БУКЕТЫ

Бусагада тавыш... Бу, йөрәккәй,
Ишегеңне ямьсез кагу... Ник? —
Бел, онытма, ача күрмә, Кешем!
«Кунагың»ның исеме — Агу бит!

Тел әйләнми хәтта әйтергә дә,
Ул бит явыз, юньсез, бик усал.
Бу кисәтү — юк, җирлексез түгел,
Китереп була моңа күп мисал...

### Ник төшә?

Билет ала да утыра.
Тукталыш саен төшә:
— Бәлки, монда саталардыр...
Өч борынга бер шешә?!

### Югач... утырды

Унбиш сумга чалбар сатып алды,
Ә «юарга» ун сум тотылды.
Ә аннары...— шушы юудан соң —
Унбиш тәүлек рәттән утырды.

### Урганда... чәчкәннәр

Аларны куе камыл яшергән,
Күмелеп ятмый алар тирәнгә —
Урганда «чәчкән» шешәләр чыңлый
Туңга сөргәндә бәрелеп төрәнгә.

### Өч минут... һәм өч ел

«Аракылы кибет кайда?» диеп
Сораучыга бер абыстай әйтте:
— Кибет юлы — өч минутлык юл ул...
Ә минем ир... тик өч елдан кайтты.

### Финал

Дүрт якын дус «Шумел камыш...» диеп,
Дүрт ел буе бергә эчтеләр.
Мастерлыктан инде очтылар да
Таш ташырга бергә күчтеләр...

### Стакан зары

— Күпме кешене аяктан ектым,
Хәтта балалар ятим калалар...
Корал түгел мин, ләкин ник көчле?!
Ник соң, ник миңа хәмер салалар?

---

ЗӘКИ НУРИ (1921) — шагыйрь, татар, рус телләрендә басылган кырыктан артык шигырь китабы авторы. Казанда яши.

## Билгесез маршрут

Тар сукмактан сәрхүш чак-чак «атлый»,
Юлын капшап ике кул белән.
Тонган күзләр сыкрап әйтә төсле:
«Беркая да илтмәс юл беләм...»

## Эчәсе килми

Исереп ауган юан бер абзыйны
Бер эт ялый... Тимик без аңа.
Чөнки абзый үзе куа аны:
— Эчмим, кода! Үпмә, кыстама.

## Кафега йөрим

«Яратмыйм мин кафе сыйларын —
Йөри анда затсыз агалар...» —
Диде берәү... Үзен пивнойда
Өстәл астыннан гел табалар.

## Катыдан йомшару

Каты зәм-зәм капкач йомшап ауган да
Башын куеп ята юлда ташка ул.
Һәм сөйләнә: — Тора алсам әгәр мин,
Мамык җәяр идем, диеп, аска — ул.

## Шатлыгын юган

Дүрт аяклы җәнлек аулаган ул,
Дүртаяклап кайта өенә:
— Ярый әле бүре очрамады,
Мин исәнмен!..— диеп сөенә.

## «Сусамас»

Сусамас нәрсә дисезме,
Кушамат ул — Сусамас:
Эсседә дә сусамас ул,
Ник?.. Эчүдән бушамас.

## Икесе дә эчә

Урман юлыннан борылып кинәт,
Якында гына бер ат кешнәгән...
Аланга чыксам, күрәм, эчәләр:
Пегасы — күлдән, җайдак — шешәдән.

## Аракы түгә

— Белеп әйтәм, аңлап әйтәм
Сүземнең өстен чыгасын:
Мин сине җиргә түкмәсәм,
Син мине җиргә егасың.

## Аю махмыры

— Үтереп баш чатный... Һич булмый хәтерләп:
Кем белән эчтем дә мин кайда исердем?
Чү! Кичә якшәмбе иде бит! Һәм мин дә
Кешеләр янында көн буе... ишелдем.

---

## ТАТАРСТАНДА ЧУВАШИЯ АССР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ СӘНГАТЕ КӨННӘРЕ

25—30 майда Татарстанда Чувашия АССР әдәбияты һәм сәнгате көннәре булып узды.

Республикабыз хезмәт ияләре зур шатлык хисе белән кадерле кунакларны — тугандаш Чувашия АССР әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә катнашучыларны кабул итте. Күрше республика вәкилләре безгә Чабаксар промышленность тракторлары заводы һәм ГЭСын төзүчеләрдән, машиналар һәм приборлар эшләүчеләрдән, агач эшкәртүчеләрдән, игенчеләрдән һәм терлекчеләрдән, әдәбият һәм сәнгать, культура работникларыннан туганнарча кайнар сәламнәр, олы дуслык хисләре алып килделәр.

26 майда М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында Татарстанда Чувашия АССР әдәбияты һәм сәнгате көннәре ачылуга багышланган тантаналы кичә булды. Кунаклар белән очрашуга хезмәт коллективлары вәкилләре, язучылар, художниклар, композиторлар, артистлар, культура эшлеклеләре килде.

Президиумда КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Г. И. Усманов, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ә. Б. Баһаветдинов, ТАССР Министрлар Советы Председателе М. Ш. Шәймиев, КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев, ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПССның Казан шәһәр комитеты беренче секретаре М. М. Сухов, КПССның Чувашия өлкә комитеты беренче секретаре И. П. Прокопьев, КПССның Чувашия өлкә комитеты секретаре Л. Я. Тянгов, Чувашия АССР Министрлар Советы Председателе урынбасары Н. И. Викторов, КПССның Чувашия өлкә комитеты культура бүлеге мөдире О. Г. Денисова, Чувашия АССР культура министры И. А. Кочетова, Чувашия АССР Верховный Советы Президиумы секретаре И. И. Стекольщикова, Социалистик Хезмәт Герое, СССР Верховный Советы депутаты, КПССның Чувашия өлкә комитеты бюросы члены, Чабаксар машина төзү заводы шомартучысы А. А. Александров, КПССның Яңа Чабаксар шәһәр комитеты беренче секретаре А. И. Андрианов, Социалистик Хезмәт Герое, КПССның Батыр райкомы беренче секретаре В. А. Никитин, Социалистик Хезмәт Герое, Урмары районының Мичурин исемендәге колхоз председателе С. Л. Лукин, Социалистик Хезмәт Герое, Шумерля автофургоннар комбинаты отделкачылар бригадиры Н. И. Иванова, композитор, РСФСРның халык артисты, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Ф. М. Лукин, Татарстан һәм Чувашия иҗат союзлары һәм коллективлары житәкчеләре, производство алдынгылары, культура эшлеклеләре.

Тантаналы кичәне кереш сүз белән КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Г. И. Усманов ачты.

Кунакларны КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев тәбрикләде.

Җавап сүзе белән КПССның Чувашия өлкә комитеты секретаре Л. Я. Тянгов чыкты.

Кичәдә шулай ук ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, Чабаксар машина төзү заводы шомартучысы А. А. Александров, ТАССР Верховный Советы депутаты, Мамадыш районының «Мамадыш» совхозы сыер савучысы С. В. Гарифуллина, Социалистик Хезмәт Герое, КПСС өлкә комитеты бюросы члены, предприятие фрезерчысы Н. В. Фролов чыгыш ясадылар.

Кичә Чувашия АССР сәнгать осталарының зур концерты белән тәмамланды.

26 майда «Татарстан» кинотеатрында совет Чувашиясенә багышланган документаль фильмнар күрсәтү башланды. Кинофестивальне ачу тантанасына Казан шәһәре җәмәгатьчелеге вәкилләре, республикабыз кунаклары җыелган иде. Аны ТАССР Кинофикация дәүләт комитеты председателе Р. Х. Ногманов ачты. Казан киностудиясе директоры И. Н. Алексеев, студиянең Чабаксардагы кинокорпункты җитәкчесе А. А. Дымич, дубляж группасы режиссеры М. Г. Антонов үз коллективларының иҗади планнары белән таныштырды.

Кинофестиваль ачу тантанасында КПССның Чабаксар шәһәр комитеты пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Г. Н. Горшков чыгыш ясады.

Аннары Виктор Деринг җитәкчелегендәге «Экран» джаз оркестры концертын тамашачылар яратып каршылады. Концертта РСФСРның атказанган артисткасы Зилә Сөнгатуллина, Татарстанның атказанган артистлары Зиннур Нурмөхәммәтов һәм Рафаэль Сәхәбиев катнашты.

Соңыннан тамашачылар «Исәнме, Чувашия!» дигән документаль тасма карадылар.

Атна ахырына кадәр Казанның «Родина» һәм «Комсомолец» кинотеатрларында «Таныш булыгыз, Чабаксар», «Чувашия юллары» дигән ленталар, «Кин Иделдә» киножурналының Чувашиягә багышланган махсус чыгарылышлары күрсәтелде.

26 майда ТАССР Художниклар союзының күргәзмәләр залында Чувашия АССРның рәссамнары, сәнгать осталары иҗатына багышланган күргәзмә ачылды. Тантананы ТАССР Художниклар союзы председателе Э. И. Тумашев ачты.

Чувашия АССРның сәнгать осталары иҗатына багышланган күргәзмәне ачу тантанасында, Чувашия АССР Художниклар союзы председателе Р. Ф. Федоров, язучы Р. Мостафин, «Спартак» аяк киемнәре производство берләшмәсе эшчесе Т. Сергеева иптәшләр чыгыш ясады.

Күргәзмәне ачу тантанасында КПССның Чувашия АССР өлкә комитеты секретаре Л. Я. Тяпгов, ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов иптәшләр катнашты.

30 майда иртән Татарстан язучылары-ның Г. Тукай исемендәге клубында республикабыз әдипләре Чувашия әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә катнашучы каләмдәшләрен кабул иттеләр.

Очрашуны ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе, КПССның XXVII съезды делегаты драматург Туфан Миңнуллин ачты һәм илебез коммунистлары форумыннан алган тәэсирләрен сөйләде, тугандаш әдәбиятлар алдында торган җитди бурычларга тукталды.

Аннары Чувашия Язучылар союзы идарәсе председателе Порфирий Афанасьев, Татарстанда яшәүче чуваш язучысы Василий Юдин, профессор Хатип Госман, Чабаксарда чыга торган «Туган Идел» журналының баш редакторы Лаврентий Таллеров, «Ялав» («Байрак») журналының баш редакторы урынбасары Аристарх Дмитриев, философия фәннәре кандидатлары А. Хузангай, Р. Мостафин, профессор И. Нуруллиннар чыгыш ясады. Чыгышларның һәммәсендә килер көннәрдә эшлекле элемтәләрне тагын да ныгыту зарурлыгы ассызыклап әйтелде.

Чуваш шагыйрәсе Раиса Сәрби рус һәм чуваш телләрендә шигырьләр укыды.

Очрашу азагында чуваш әдипләренә КПССның Татарстан өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы һәм Министрлар Советының рәхмәт хаты һәм истәлек бүләкләре тапшырылды.

Татарстан Композиторлар союзында да Чувашия АССР әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә катнашучылар белән иҗади очрашу булып узды. Социалистик Хезмәт Герое, СССР халык артисты композитор Нәҗип Җиһанов күрше республиканың музыка эшлеклеләренә Татарстан тамашачыларына яңа әсәрләр бүләк итүләре өчен рәхмәт хисләрен белдерде. Ул соңгы вакытта Чувашия композиторларының симфоник музыканы үстерүдә уңышлы эшләүләрен аерым билгеләп үтте.

Чувашия АССР композиторларына һәм музыка белгечләренә, республикабыз хезмәт ияләренә культура һәм сәнгать хезмәте күрсәтүләре өчен КПСС өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы һәм Министрлар Советының рәхмәт хатлары тапшырылды.

Ике автономияле республиканың сәнгать осталары Чувашия һәм Татарстан композиторларының әсәрләрен башкарды.

Концерттан соң, музыка турында сөйләшү түгәрәк өстәл янында дәвам итте. Анда сүз КПССның XXVII съезды халкыбыз алдына куйган җитди бурычларны тормышка ашыруда музыка сәнгатенең һәм аның вәкилләренең роле, милли культураларның үзара бәйләнеше һәм йогынтысы турында барды. Сөйләшүдә Чувашия АССР Композиторлар союзы идарәсе председателе, Чувашия АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе А. Васильев, РСФСРның халык артисты, СССР дәүләт премиясе лауреаты Ф. Лукин, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе В. Ходяшев һәм башка иптәшләр катнашты.

ТАССР Художниклар союзының күргәзмәләр залында үткән очрашуны ТАССР Художниклар союзы идарәсе председателе Э. И. Тумашев ачты. Ул ТАССР Художниклар союзы эшчәнлеге белән таныштырды. Аерым әсәрләргә, рәссамнар иҗатына тукталды.

Аннан соң Чувашия АССР Художниклар союзы идарәсе председателе Р. Ф. Федоров чыгыш ясады.

РСФСРның атказанган, ЧАССРның халык художнигы Н. Карачарсков, скульптор С. Кадакин, СССРның халык художнигы Х. Якупов, РСФСРның атказанган художнигы В. Куделькинның да сөйләшер сүзләре, уртаклашыр фикерләре күп булды әлеге очрашуда.

Бу очрашу ике тугандаш халык арасында дуслык җепләрен тагын да ныгытырга ярдәм итте.

Казанда башланып киткән дуслык һәм туганлык бәйрәме Брежнев һәм Түбән Кама, Мамадыш, Алабуга һәм Зеленодольск шәһәрләрендә, Арча, Балтач һәм Саба районнарында дәвам итте. Кунаклар төзелеш мәйданнарында, производство коллективларында, колхоз-совхозларда, предприятиеләрдә, культура-агарту учреждениеләрендә булдылар, аларның эшләре, тормышы белән якыннан таныштылар, тәҗрибә уртаклаштылар, һәркайда җыр-музыка яңгырап торды.

30 майда республикабызның хезмәт коллективлары вәкилләре, язучылар, художниклар, композиторлар, артистлар, культура работниклары М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрына Татарстанда Чувашия АССР әдәбияты һәм сәнгате көннәре тәмамлануга багышланган тантаналы кичәгә җыелдылар.

Президиумда — Татарстан АССРның житәкче партия, совет, профсоюз һәм комсомол работниклары, Чувашия АССРның рәсми делегациясе членнары, производство алдынгылары, иҗат союзлары һәм коллективлары җитәкчеләре, һәр ике автономияле республиканың күренекле культура эшлеклеләре.

Тантаналы кичәне кереш сүз белән КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев ачты.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Э. Б. Баһаветдинов КПССның Татарстан өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы һәм Министрлар Советы, республиканың барлык хезмәт ияләре исеменнән КПССның Чувашия өлкә комитетына, Чувашия АССР Верховный Советы Президиумына, Министрлар Сове-

тына, Чувашия эшчеләренә, колхозчыларына, хезмәт интеллигенциясенә, барлык хезмәт ияләренә чын күңелдән рәхмәт белдерде, экономиканы һәм культураны үстерүдә, Ленин партиясенең XXVII съезды билгеләгән социаль-экономик үсеш программасын уңышлы үтәүдә яңа җиңүләр теләде.

Җавап сүзе белән Чувашия АССР Верховный Советы Президиумы Председателе А. П. Петров чыкты.

А. П. Петров КПССның Чувашия өлкә комитеты, Чувашия АССР Верховный Советы Президиумы һәм Министрлар Советы, республиканың барлык хезмәт ияләре исеменнән әдәбият һәм сәнгать көннәрен бик яхшы оештырганнары, республика тормышы һәм аның эшләре белән якыннан танышу мөмкинлеге тудырганнары, туганнарча җылы кабул итүләре өчен КПССның Татарстан өлкә комитетына, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумына һәм Министрлар Советына, министрлыклар һәм ведомстволарга, иҗат союзлары һәм оешмаларына, хезмәт коллективларына, тугандаш Татарстанның барлык хезмәт ияләренә чын йөрәктән рәхмәт белдерде.

Кичәдә шулай ук КамАЗның ремонт-инструмент заводы бригадиры, Ленин ордены кавалеры В. А. Ватагин, Социалистик Хезмәт Герое, ЧАССРның Урмары районы Мичурин исемендәге колхоз председателе С. Л. Лукин, ТАССРның халык артисткасы Р. М. Ибраһимова, ЧАССР Язучылар союзы идарәсе председателе, Чувашия комсомолының М. Сеспель исемендәге премиясе лауреаты П. В. Афанасьев чыгыш ясадылар.

Кичә зур концерт белән тәмамланды. Коммунистлар партиясенә һәм Ватаныбызга, халыклар дуслыгына дан булып яңгыраган бу концертта ЧАССР һәм ТАССР дәүләт җыр һәм бию ансамбльләре, Чувашия АССР Телевидение һәм радиотапшырулар комитеты хоры, Ф. Павлов исемендәге Чабаксар музыка училищесы скрипкачылары ансамбле, Чувашиянең һәм Татарстанның танылган артистлары катнашты.

Кичәдә ТАССР Министрлар Советы Председателе М. Ш. Шәймиев, КПССның Татарстан өлкә комитеты икенче секретаре Л. М. Смагин, КПССның Чувашия өлкә комитеты секретаре Л. Я. Тянгов, КПССның Казан шәһәр комитеты беренче секретаре М. М. Сухов, Чувашия АССР Министрлар Советы Председателе урынбасары Н. И. Викторов катнашты.

Бер атна элек Татарстанда Чувашия АССР әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә катнашучыларны каршылагандагы кебек үк, Казан елга вокзалының төп бинасы каршындагы мәйдан тагын шау-гөр килеп торды, бәйрәм рухына күмелде. Бирегә шәһәребезнең хезмәт коллективлары вәкилләре, язучылар, рәссамнар, композиторлар, артистлар чуваш дусларны озатырга килде. Ут күршеләребезгә рәхмәт белдерүче, хәерле юл теләүче транспарантлар, чәчәкләр, музыка.

КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев Чувашия әдәбияты һәм сәнгате көннәренең республикабызда зур бәйрәмгә әверелүен, һәркем күңелендә онытылмас тәэсир калдыруын, бу очрашуларның һәр ике як өчен дә зур әһәмияткә ия булуын әйтте, анда катнашучыларның барысына да рәхмәт белдерде һәм хәерле юл теләде.

КПССның Чувашия өлкә комитеты секретаре Л. Я. Тянгов Чувашия әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә катнашучыларны чын күңелдән җылы кабул итүләре өчен зур рәхмәт белдерде. Татарстан хезмәт ияләренә КПССның XXVII съезд карарларын тормышка ашыруда уңышлар теләде.

Аннары чуваш һәм татар артистлары, балалар үзешчән коллективы рус, татар, чуваш җырларын, биюләрен башкарды.

Кунакларны КПСС өлкә комитеты бюросы члены, ТАССР Халык контроле комитеты председателе И. П. Наумов, ТАССР Верховный Советы Президиумы секретаре Д. С. Дәүләтшина, КПСС өлкә комитетының бүлек мөдирләре А. И. Афанасьев, Д. Х. Зарипова, ТАССР культура министры М. М. Таишев, халык депутатларының Казан шәһәр Советы башкарма комитеты председателе Р. Р. Идиятуллин, партия, совет һәм җәмәгать оешмалары, иҗат союзлары һәм оешмалары вәкилләре озатып калды.

## ГАБДУЛЛА КАРИЕВ ЮБИЛЕЕ

12 майда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында татар театрына нигез салучы Габдулла Кариевның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды. Монда республикабызның производство коллективлары, партия, совет, профсоюз, комсомол оешмалары вәкилләре, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, культура работниклары, шулай ук Г. Кариевның якташлары — Октябрь районы хезмәт ияләре вәкилләре килгән иде.

Кичәне кереш сүз белән халык депутатларының Казан шәһәр Советы башкарма комитеты председателе Р. Р. Идиятуллин ачты.

Г. Кариевның тормыш һәм иҗат юлы турында ТАССР культура министры М. М. Таишев сөйләде.

Кичәдә ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова, КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре Ф. Г. Зыятдинова катнашты.

## ТӨРЛЕ ТЕЛЛӘРДӘ

Язучы Әхәт Гаффарның татар һәм рус укучыларына таныш булган «Бабай чишмәсе» («Хәтер») дигән хикәяләр циклы «Советская литература» журналының апрель санында француз телендә чыкты. Моңа кадәр ул әсәр поляк, чех, словак һәм немец, испан һәм инглиз телләрендә дөнья күргән иде.

Шушы ук әсәр Германия Демократик Республикасында чыга торган атналык «НБИ» («Новый Берлинский иллюстрированный журнал») журналында да басылды.

# ЧӘЧӘК ВАКЫТЫ

СССРның халык рәссамы Харис Якуповның инде утыз ел дәвамында иҗат итеп торган «Питрәч циклы»нда «Мәрзия һәм тузганаклар» исемле портрет (1973) үзенең шигърилеге, образның табигать белән гармоник бөтенлектә гәүдәләндерелүе ягыннан аерылып тора. Чәчәк вакыты!.. Әсәрдә тантана иткән җәй фасылында гына түгел, героиняның үзендә дә менә шундый гүзәл вакыт чагыла.

Колхоз эшеннән соң ял итәргә тукталган Мәрзия җәйнең аллы-гөлле келәмендә сурәтләнә. Матур буй-сынына ятышып торучы әфлисун төсендәге күлмәк һәм ак алъяпкыч бөтен болынны күмеп җилфердәгән чал чәчле тузганакларга үзенчә ямь өсти. Ягымлы кояш нурларында коенучы чәчәкләрне Мәрзия тагын да матуррак итеп күрсәтә шикелле. Аксыл шәмәхә, алсу, ачык яшел, сары төсләр балкышында җилкәндәй янып торучы алъяпкычның аклыгы җетерәк булып күренә. Хәер... Мондагы төсләрне бер-берсеннән аерып та булмый. Алар — бербөтен. Картина декоратив мозаика буларак кабул ителә. Салават күперендәге төсләр шикелле, монда барысы да бер-берсенә ятышып торадыр.

Табигатьтәге төсләр гаммасында нинди-дер салкынлык та сизелә (мөгаен, ул тузганак мамыгыннан киләдер). Әмма Мәрзиянең йөзенә бәреп чыккан күңел җылылыгы полотнодагы һәрбер төскә җылылык өсти. Шуңа күрә дә әсәрдән илаһи бер җылылык сирпелеп тора.

Мәрзия һәм чәчәкләр, чәчәкләр һәм Мәрзия... Шагыйрьләр чәчәкләрдә җирнең елмаюын күрәләр. Мәрзиядә дә туган җирнең елмаюы, хезмәтне бәйрәмгә әверелдерә белүче авыл елмаюы, яшәү шатлыгы чагыла. Әлеге елмаю безгә дә көч, хезмәт дәрте белән канатланып яшәргә чакыра, һәрьяктан матур булырга өнди.

**Людмила КОРОБЦОВА,**
Татарстан сынлы сәнгать
музееның фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Татар дәүләт опера һәм балет театры солисты, РСФСРның атказанган, Татарстанның һәм Каракалпакстанның халык артисты Юрий Борисенко.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотолары.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

Илебездәге газета-журналларга киләсе ел өчен язылу вакыты якынлашып килә.

Тәҗрибә күрсәткәнчә һәм сездән килгән күпсанлы хатлар раслаганча, журналга язылу өчен иң уңайлы вакыт — подписканың беренче көннәре, беренче атналары.

«Казан утлары» журналына подписка илебезнең «Союзпечать» агентлыкларында һәм барлык элемтә бүлекчәләрендә кабул ителә. Бер елга язылу хакы — 10 сум 80 тиен. Бөтенсоюз каталогындагы индекс — 73210.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)